ЖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВ

# Лобачевскийның яшьлеге

**ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВ**

# *Лобачевскийның яшьлеге*

РОМАН

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1986

ББК 84.4(2Р-Тат)
Т87

Рецензенты:

Филология фәннәре докторы ГАЛИ ХАЛИТ

Т $\frac{4803010200-162}{М132(03)-86}$ 160—86. ББК 84.4(2Р-Тат)

© Татарстан китап нәшрияты, 1986.

**Даhи галим — ректор Николай Лобачевскийның һәм бөек язучы Сергей Аксаковның остазы булган талантлы шагыйрь вә педагог Н. М. Ибраһимов истәлегенә багышлыйм.**

***Автор.***

## *Беренче бүлек*

### I

1802 елның октябрь азагы. Олы юлдан таза, көр атлар җигелгән тройка килә. Тарантаска мәшһүр Казан сәүдәгәре Жарковның приказчигы һәм аның юлдашы, коллежский регистратор Лобачевский хатыны Прасковья Александровна утырган. Өч малай, кысылышып, алдагы тар эскәмиягә урнашканнар.

Тройка артыннан олаулар тезелеп киткән; Жарков приказчигы ул олауларда Мәкәрҗә ярминкәсеннән Казанга иләнмәгән тире алып кайта иде. Тире әшкәр-

ту буенча Казан борын-борыннан дан тота. Тире-яры мәсьәләсендә Жарков үзе дә һәм аның компаньоны — Подлужный бистәсендә күн заводы тотучы Гогулин да төшеп калганнардан түгел.

Юлчылар бик нык арыганнар: ни әйтсәң дә, Мәкәрҗәдән Казанга чаклы өч йөз чакрымнан артык ара үтәргә кирәк, ә сәфәргә чыгуларына дүртенче тәүлек киткән иде инде. Юл ифрат начар булганга, йөк атлары бик тиз эштән чыкты. Ярый әле бәлагә юлыкмадылар. Ватылып-җимерелеп яткан арба, экипажлар әледән-әле очрап кына тора. Олаучылар һәм кучерлар, юлны каргый-каргый, сынган күчәр, ватылган тәгәрмәчләрне рәткә кертеп азапланалар иде.

Юл күбесенчә кара урман аша уза. Йөзәр еллык калын-калын имәннәр күкне каплаганнар, кояшның барлыгы да сизелми.

Юллар тыныч түгел иде: Иделне кичкәч, юлчыларга мылтык, сөңгеләр белән коралланган казаклар отряды очрады. Юлбасарлардан саклану өчен шәһәрдән махсус җибәрелгән бу отрядны күргәч, малайлар җанланып киттеләр, арыганлыклары онытылды.

Казанга якынлашкан саен, аркаларына капчык аскан крестьяннар еш очрады: татар, рус, чирмеш, чувашлар... Ач-ялангач бу бичаралар шәһәргә эш эзләп, бәхет кошы тотарга өметләнеп киләләр, күрәсең.

Быел көз иртә килде. Башта коеп яңгырлар яуды, аннары туңдырып җибәрде. Яңгыр суларының өсте кабырчыкланып, тәгәрмәч астында чытырдап боз ватылып кала. Көнчыгыштан кара болыт агыла; инде бөтен күкне каплап алган — күп тә үтмәс, кар явар.

Казанга ни өчен килүләре искә төшеп, малайлар юл газабын бөтенләй уйламыйлар иде: алар бит Казанга укырга — гимназиягә керергә дип киләләр! Иптәшләре һәм укытучылары нинди булыр? Нинди форма бирерләр икән? Аларга бит форма бирәчәкләр!

Малайларның уртанчысы — ябык гәүдәле, кылыч борынлы, янып торган зәңгәр күзле Коля аеруча нык борчыла һәм дулкынлана иде. Аның яңгыравык тавышын ишетеп, арыган җәяүлеләр дә борылып карыйлар һәм елмаеп куялар.

— Гимназия! Ул нинди булыр икән? — дип, малай әнисен алҗытып бетерде. Әнисе аңа җавап итеп мөлаем гына елмая.

— Баргач күрерсең,— ди.

Коля, күзен кысып, хыялга бирелә. Аның күз ал-

дына, әкияттәге сарай кебек ап-ак булып, Нижний Новгородтагы банкныкы шикелле биек болдырлы гимназия килеп баса. Атлар нигә бу чаклы акрын атлый соң? Болай ташбака адымы белән барсаң, Казанга кайчан барып җитәрсең?

Кучер артыннан сузылып карый-карый, Коляның муены авыртып бетте. Әмма юл, бераз гына туры бара да, я уңга, я сулга борыла — шәһәр күренми дә күренми.

— Нәрсә ул анда? Казан түгелме әле? — дип, кучерны йөдәтә малай.

— Юк шул әле, улым, әнә теге үрне үткәч күренер,— дип җавап кайтара кучер һәм дилбегәсен тарткалый: — Әйдәгез әле, малкайлар, җитезрәк!

Ләкин малкайлар, чак кына юырткандай ителәр дә яңадан адымга күчтеләр. Кучер аларны үз ирекләренә куя: тарантаста барин үзе түгел ич. Приказчикның да олаулардан аерыласы килми: юлда әллә ниләр булуы мөмкин.

Атлар юыртып барганда тарантас чайкала һәм сикерә; малайлар, егылып төшмәс өчен, бер-берсенә тотыналар. Атлар тагын атлап бара башлагач, Коля авыр сулап куя, арык кулы белән бөдрәләнеп торган саргылт чәчен рәтли.

Прасковья Александровна балаларына карап уйга калган. Аның чәченә чал керә башлаган, маңгаенда җыерчыклар... Кем уйлар аңа утыз гына яшь дип! Шулай да аның мөлаем елмаюы, сөрмәле озын керфек астыннан караган акыллы күзләре ничектер күңелне тартып торалар.

Әйе, соңгы ун елда Прасковья Александровнага бик күпне күрергә, кичерергә туры килде. Менә хәзер, тормышында кискен борылыш булганнан соң, аның уйлары ирексездән үткәнгә кайта, күп нәрсәне искә төшерә. Тарантас кинәт сикереп алганда гына фикере беразга өзелеп тора.

— Зинһар, әкренрәк! — дип үтенә ул, борчылып. Аннан тагын уйга чума...

...Кайгысыз үткән балачагы, күңелле кыз вакыты — соңгы ун елдагы тормышыннан ничек аерылып тора бит! Аларның Макарьевы өяз шәһәре генә булса да, җәй көне Мәкәрҗә ярминкәсенә Россиянең төрле почмакларыннан, хәтта чит илләрдән дә сәүдәгәрләр җыела. Гөрләп сату-алу итәләр. Әмма кыз баланы болар кызыксындырмый. Төрле телдә сөйләшүче бу

халык өчен бирεдә бик күп кызык күрсәтелә. Энҗе белән бизәлгән көймәле карусельгә утырып әйләнүе яки таган атынуы нинди рәхәт! Ә кичке уеннар, җырлар...

Ул кыз чагында коңгырт-сары чәчен, толымлап үреп, кызыл тасма белән бәйли торган иде. Аның мөлаемлегенә һәм тыйнаклыгына шәһәр егетләре дә, читтән килгәннәр дә сокланып карыйлар иде.

Кызның атасы зур булмаган куну йорты тотып, анда Мәскәүдән һәм Казаннан килгән олаулар туктый иде. Үзе бистә кешесе генә булса да, кызын чук кебек итеп киендерде, белем бирергә дә онытмады. Кызның әнисе дә моңа каршы килмәде. Өяздә танылган землемер Сергей Степанович Шебаршин — аларның ерак кардәшләре — ягымлы һәм акыллы баланы бик яратты, кызга белем бирүне үз өстенә алды. Ул нәрсә генә белми, нәрсә генә күрмәгән дә кайда гына булмаган — ни теләсәң, шул хакта сөйли ала иде. Хуҗалыксәүдә эшләре турында да әтисе аның белән киңәшә иде. Күпне белергә теләгән Параша еш кына аннан ерак илләр турында берәр китап укуын сорый, болай гына үтенсә бер хәер, ялынып сорый иде. Буйдак Шебаршин акрынлап нечкә күңелле бу акыллы кызны бөтен йөрәге белән үз күрде, якын итте.

— Сережа абый, мин укырга телим,— дип, эчендәге яшерен уен әйтеп ташлады бер көнне аңа эчкерсез кыз.

Икенче көнне әлифба белән грифель тактасын күтәреп, ишектән Шебаршин килеп кергәч, Парашаның әнисе, теләктәшлек күрсәтеп, башын гына чайкады. Шушы беренче көннән үк башланган дәресләр сабак тыңлаучыга да, тыңлатучысына да олы куаныч китерде. Йортка нинди генә каза килсә дә, Сергей Степановичның ярдәм итәчәгенә кыз бөтен җаны-тәне белән ышана иде.

Ә аннан соң...

Прасковья Александровна көрсенеп куйды һәм, кызыклы төштән уянган шикелле, күзен сыпырып алды. Истәлекләре аны кайгысыз чагыннан аерып торган бер вакыйгага китергән иде.

Унике ел үтүгә карамастан, әле кичәгедәй күз алдында. Шимбә көнне шулай, кичкә таба, дус кызлары аны алмага керделәр. Әнисе риза булып җибәрде. Ерак китәргә өлгермәделәр, Шебаршин коляскасы каршы очрады. Параша моңа бик шатланды. Әмма укытучы янына ике ят кеше утырган иде.

Кыз оялып, югалып калды. Сергей Степанович, аны күреп, кул болгады һәм кучерга туктатырга кушты.

— Кая барасың, Парашенька? — дип, ягымлы итеп эндәште укытучы.— Иптәш кызларың уенга синнән башка да барырлар. Сине бик сагындым мин. Утыр, өеңә илтеп куям.

Параша тагын да ныграк кызарды, әмма баш тартырга ярамый иде. Шул вакыт алгы эскәмиядән зәңгәр мундир кигән утыз яшьләрдәге егет, сикереп торып, баш иде дә:

— Сергей Степанович, мин җәяү барырмын, сезнең кардәшегезгә кысан булмасын,— диде.

Шебаршин шаркылдап көлде:

— Бер дә кысан булмас, биш минутлык кына юл калды. Утыр, Парашенька.

Ишетелер-ишетелмәс кенә исәнләшеп, кыз алгы эскәмиягә менеп утырды һәм Сергей Степанович белән янәшә утырган кунак ягына кыюсыз гына күз салды. Анысы, Параша янына кысылып кына утырган чибәр егеткә караганда, картрак та, бераз шадрасы да бар икән. Зур зәңгәр күзлек астыннан ягымлы итеп карый, бер дә усал түгел, янәшәсендә утырган егетнең зәңгәр күзләре кебек оялтмый да.

Юл, чынлап та, биш минуттан артыкка сузылмады. Кайтып җиткәч, Параша үз бүлмәсенә йөгереп кереп китте.

— Нигә куркасың? — дип, йомшак тавыш белән сорап куйды әнисе.— Безнең хәлебезгә күрә бик дәрәҗәле кунак болар: Аверкиев әфәнде — губернабызның казенный палата казначее... Кулындагы йөзекләрен күрдеңме? Сергей Степановичны дус итеп килгән. Кардәш егетен ни өчен алып килүен үзең дә сизәсеңдер.

— Ой, әнкәем! — диде дә Параша кулы белән битен каплады.

Әнисе аңа ягымлы карап, көрсенүен сиздермәстән:

— Кыз баланың язмышы шул инде,— диде ул акрын гына.— Син курыкма, Парашенька, чәй янына чык. Белмәссең, язмышың булса...

Шулай булып чыкты шул. Егор Алексеевич Аверкиев кебек дәрәҗәле кешегә кардәш булгач, ул егетне иң кулай кеше дип уйладылар. Җитмәсә тагын Нижнийда межевой конторада хезмәт итә, ди.

— Хәзергә чины бик зур түгел — коллежский регистратор,—дип сөйләнде кичен Парашаның әтисе.— Аңа карап тормабыз. Яшь бит әле, күтәрелер. Агасы ярдәм итәр.

Картларны тик бер сорау борчыды: ни өчен Аверкиев үзенең кардәшенә аларның Парашаларын сайлады икән?

— Сизгер кеше ул,— диде Сергей Степанович, аңлатып бирергә тырышып.— Безнең Парашаның һәр яктан килгәнлеген: акыллы, матур, тыйнак булуын күреп алгандыр. Мин дә киңәш иттем.

Параша аларның сүзенә колак салмый — Иван Лобачевскийның чибәрлегенә, аның зәңгәр күзенә гашыйк булып өлгергән иде ул.

Һәммәсе риза булгач, эшне озакка сузмадылар. Тиз көндә вәгъдәләшеп тә алдылар. Моннан да артыгын көтмәгән юмарт Аверкиев кызның калтыранган бармагына кыйммәтле якут кашлы йөзек кигезде.

— Әле монысы, киленкәем, башлап җибәрү өчен генә,— диде ул ягымлы итеп.— Минем йортыма төшәрсез, шунда гомер итәрсез.

Тагын бер атнадан Макарьевның биш гөмбәзле чиркәвендә никах укылды. Уналты яшьтәгеләргә никахка керергә ярамаганлыктан, Аверкиев кызга егерме бер яшь дип яздырды. Туйдан соң ук яшьләр Нижний Новгородка, Аверкиевның Сретенский урамындагы иркен йортына күчтеләр. Өйнең тәрәзәләре Кремльгә һәм югары базар мәйданына карап тора иде.

Параша бераз вакыт төштәге кебек яшәде. Бер җәйге кичтән башка һични хәтерендә сакланмаган. Ул кичне Параша кунак бүлмәсеннән, тулган ай яктысында Иделне күрү өчен, балконга чыкты. Кичке тынлыкны ярып бурлаклар җыры — сагыш һәм моң тулы җырлар яңгырады. Яшь килен аларны яратып тыңлады, ә шулай да ниндидер авыр газаплар киләчәген сизенеп йөрәге әрнеде.

Көн артыннан көн узды, бәла-каза килмәде. Аверкиев аңа кардәш итеп карый, яшьләрнең тату тормышына соклана, шатлана иде. Бай йорт, бакчадагы беседкалар һәм оранжереялар, өйдәге хезмәтчеләрнең һәм абзарлардагы атларның күплеге яшь киленне таңга калдыра, әмма иренең мәхәббәте аның өчен барысыннан кадерлерәк иде. Ире аның янында бер адым да читкә китми, һәрвакыт игътибарлы иде. Алар Аверкиевның туган--тумачаларына һәм таныш-белеш-

ләренә кунакка йөрделәр. Аларга зур хөрмәт күрсәтәләр, әмма ире кунакта үзен бик тыйнак тота, аракыдан баш тарта килде.

Аверкиев, аның аркасыннан каккалап, бик канәгать булып:

— Эшләр җайга тәгәрәп тора шикелле! — дип сөйләнгәләде.

Тегесе андый чакларда ояла, уңайсызланып кала. Аның яшь бикәче, моны күреп, аптырый, әмма төпченеп торырга кыюлыгы җитми иде.

Тагын берничә атна шулай үтте. Болар Парашаның гомерендә иң бәхетле көннәр иде. Аның гаҗәпләнүенә каршы, хезмәтенә ире бик сирәк йөри һәм әзгәненә китеп тора. Бергә булгач, шул җитмәгәнмени!

Ләкин кинәт барысы үзгәреп китте. Ире аңа карата суынып, үзе йокысыз, ашаусыз калды. Йөзе чырайсызланды. Яшь хатын сизеп тора: бу хәлне хезмәтчеләр дә күрәләр һәм астыртын гына, кызыксынып, аны күзәтәләр. Әмма Аверкиевлар гаиләсе гүя бу үзгәрешне күрми, ә Параша сорашырга кыймый иде.

Ниһаять, беркөнне Иван Максимович хезмәтемә барам дип чыгып китте дә әйләнеп кайтмады. Параша нишләргә белмичә йөрде, ә Егор Алексеевич бик тыныч кыяфәт белән аны юатырга тырышты.

— Хезмәттә бит өйдәге шикелле түгел,— диде ул.— Җир эшләре белән җибәргәннәрдер, өйгә кереп чыгарга өлгермәгәндер. Борчылма син, Парашенька.

Икенче көн дә узып бара, ире һаман күренми. Аверкиевлар кунакка киттеләр. Буш бүлмәләрдә Параша бер ялгызы калды. Ул ни уйларга да белмәде.

Асрау кыз Анюта, почмакта нәрсәдер җыештырган булып, озак кына аны күзәтеп йөрде дә, ниһаять, түзмәде, якын ук килеп сүз кушты:

— Анакаем, барыня, зинһар, мин әйткәнне сиздермәгез. Сезнең газаплануыгызга тыныч карый алмыйм, барын да сөйләп бирәм.

Ул, куркынып, як-ягына каранды, аяк очына басып кына, ишек янына барып тыңлап килде һәм Парашаның колагына ук иелеп:

— Эчә бит сезнең ирегез Иван Максимович,— диде пышылдап.— Алла күрсәтмәсен, бик эчә. Хезмәтеннән шуның өчен кудылар. Тик Егор Алексеевич аңа кәгазь тапты: бума авыруы булу сәбәпле, имештер, хезмәткә яраклы түгел. Эчкәнгә кудылар. Эчмичә тора алмый. Аракы сорап аякларыңа егыла. Бер дә

бирмәсәң, алла күрсәтмәсен, ул кыланганны ерткыч җанвар да эшләми.

Кыз Парашаның йөзенә күтәрелеп карамады, сүзен дәвам итте:

— Сезне алдадылар, анакаем. Егор Алексеевич, егет сезне сөйгәч аракысын ташлар, дип исәп иткән иде. Без сезне бик кызгансак та, әйтергә батырчылык итмәдек.

Кыз сүздән туктап, Парашаның йөзенә караган иде, куркып кычкырып җибәрде:

— Анакаем, барыня, ни булды сезгә?.. Һай, нигә генә сөйләдем... Гафу итегез мин тинтәкне!

— Юк, юк,— диде Параша акрын гына тавыш белән.— Аннушка, әйтүең өчен рәхмәт. Хәзер бар, ялгызым калыйм. Берәүгә дә сөйләмәм, курыкма.

— Рәхмәт яусын, анакаем, барыня,— диде кыз, пышылдап.— Зинһар, кызганыгыз, белсәләр, башымны ашарлар.

Ул йөгереп чыгып китте. Параша озак кына бер урында таш сын кебек катып утырды, аннары акрын гына урыныннан күтәрелде, төштәге кебек, тавышсыз гына чайкала-чайкала, бүлмә буенча атлады. Почмакка җиткәч, егылып китмәс өчен, бәләкәй өстәл читенә тотынды. Өстәл кыйшайды, аның кайсыдыр тартмасы атылып чыкты да эчендәге кәгазьләре келәм өстенә сибелде. Параша чүгәләде һәм кәгазь битләрен бик тәфсилләп, берәм-берәм тартмага тутыра башлады. Шунда аның игъибарын пөхтә итеп басылган герблы кәгазь җәлеп итте. Параша янә, төштәге кебек тын гына урындыкка килеп утырды, зәңгәрсу кәгазь кисәген шәмгә якынрак китерде.

«Ошбу аттестатны күрсәтүче Иван поляк милләтеннән улмыш. Аның атасы Максим Василий углы Лобачевский 1757 елда минем тарафымнан Малороссиядән китерелмеш вә хорда җырчы хезмәт кыйлмыш, һәм дә Животово дигән җирдә көн итмеш. Анасы минем крепостной Аграфена, Андрей кызы, улмыш. Аңа атасы белән 1775 елны ирек бирелмеш.

Кайчан тууын вә иреклe булуын раслаучы ошбу аттестатка 1777 ел февраль аеның 24 көнендә Мәскәү каласында герблы мөһеремне басам вә имзам куям: князь Михаил Долгоруков, лейб-гвардия капитаны» *.

---

* Борынгы актлар саклана торган Үзәк дәүләт архивы (ЦГАДА), ф. 1294, оп. 2, 1777, № 2896, 2 бит.

«Аттестат» инде кат-кат укылса да, Параша, уйфикеренең очына чыга алмыйча, тавыш-тынсыз утыра да утыра. Аның кулындагы зәңгәрсу кәгазь генә сизелер-сизелмәс дерелди. Һәм менә ул герблы кәгазьне бер читкә алып куйды да тартмадагы кәгазьнең барысын да бер-бер артлы укып чыкты. Хәзер инде Параша ире хакында туйга кадәр үк үзенә, әти-әнисенә һәм Сергей Степановичка мәгълүм булырга тиешле нәрсәләрнең һәммәсен дә белде. Сережа абый боларны алданрак сизенсә, үзенең сөекле кызына шундый кияү алып кайтыр идеме икән? Ә Парашага менә нәрсәләр мәгълүм булды.

Аның ире бу Аверкиевларга бөтенләй кардәш тә түгел икән ләбаса. Чыбык очы гына икән аларның якынлыклары: Лобачевскийның бабасы Андрей Яковлевич Гусенцов, яшь хатынга өйләнгәч, Егор Алексеевич белән баҗай булган.

1777 елның 20 мартында, башлангыч мәктәпне тәмамлагач, уналты яшьлек Иванны Мәскәүдәге межа канцеляриясенә копия алып торучы хезмәтенә урнаштыралар һәм Ростов землемеры Настеров партиясенә билгелиләр: таныклыгында «буш вакансиягә елына алтмыш тәңкә жалованье куеп, шуннан госпиталь өчен тотып калырга», диелгән. 1786 елның башында Иван Максимовичны канцеляриягә күчерәләр һәм җиденче июльдә губерна регистраторы чины бирәләр. 1787 елның азагында ул Нижнийдәге межа конторасына күчеп килә, ләкин озак та үтми, аны отставкага чыгаралар. Табип тарафыннан бирелгән таныклыкка карагандa, «ул, ягъни Лобачевский, бума авыруы һәм цинга белән җәфалана. Шул сәбәпле хезмәткә яраксыз табыла». Иван Максимовичның кәгазьләре арасында шулай ук межа канцеляриясенең 1789 ел, икенче майда чыгарган указы да саклана, ә анда түбәндәгечә язылган:

«Регистратор Лобачевскийны, авыруы сәбәпле бирелгән үтенече нигезендә, межа эшләреннән азат итәргә һәм Россиядә иректе рәвештә яшәү өчен паспорт, ә хезмәте хакында махсус аттестат бирергә».

— Махсус! — дип бик озак кабатлады Параша бер үк сүзне. Әйе, хәзер инде ул бу сүзнең мәгънәсен яхшы белә. Һәм шуның белән бергә аның ни эшләп йөргәнен дә белә!

Егор Алексеевич Аверкиевка гына хәйран калырсың! Яшь киленгә шулчаклы ягымлы булып кыланды,

аталарча мөнәсәбәттә булды лабаса! Кыз баланы кемгә кодалаганын белә торып әйтмәгән. Алдаган. Кызны да, аның әти-әниләрен дә, атасы кебек якын күргән Сергей Степановичны да алдаган... Белгән булсалар, исерек башка бирерләр идемени? Кыз үзе теләсә дә, бирмәсләр иде.

Ә хәзер? Нәрсә эшләргә соң хәзер? Ирен ташлап китәргәме? Аверкиевлар өен ташлап кайтса, әти-әнисе нәрсә дияр? Әнисе болай да үлем түшәгендә ята. Аннан соң кардәшләре нәрсә әйтер? Дус кызлары, күз атып йөргән егетләр?

Параша бүлмә буйлап йөренде. «Нәрсә эшләргә?» дигән сорау аңа тынгылык бирми иде. Ире яхшымы, начармы, ташлап кайтса — күзен ачырмаслар. Юк, Параша ул хурлыкка түзә алмаячак. Ләкин ире белән бергә алдакчы Аверкиевлар өендә калырга аңа горурлыгы кушмый.

Төнне Параша әнә шул рәвештә уздырды. Яңа көн туды. Исерек ире кайтты. Моннан өч көн элек Параша озатып җибәргән кешегә бөтенләй охшамаган иде ул. Башын игән кызганыч бер кеше иде ул хәзер. Параша үзенең нәфрәтен әйтә алмады — борылып, бүлмәдән чыгып китте. Бусаганы узганда әйләнеп карады: ире чишенмәгән килеш кроватька егылган иде.

Фәкать өч көн үткәч кенә Иван Максимович сөйләшә алыр хәлгә килде. Яраткан кешесенең шундый кызганыч кыяфәттә булуы Парашаның күңелен йомшартты. Аны ташлап китәчәген әйтә алмаса да, алдакчы Аверкиевлар өендә яшәмәячәген һәм алардан бер тиен акча да алмаячагын аңлатты.

— Эчүеңне ташламый торып, хезмәткә урнашмый торып, минем күземә күренмә! — диде ул иренә.

Аверкиев тәрәзәдән аның сүзләрен ишетеп торды. Параша күңелендәген аңа да әйтмичә кала алмады:

— Сездән шулчаклы мәкерле алдау көтмәгән идем, Егор Алексеевич,— диде.

— Мин уйлаганча барып чыкмады шул, күрәм,— дип уңайсызланып җавап кайтарды Аверкиев аңа.— Гафу ит син мине, киленкәем. Моннан соң миндә яшәргә теләмәсәң, һич югы шуңа ризалык бир: мин хәзер үк сезгә аерым өй сатып алам.— Шуннан ул каршысында басып торган Иван Максимовичка төртеп күрсәтеп: — Моны бер көн кичектермичә хезмәткә урнаштырам,— дип өстәде.— Хезмәтен намус белән баш-

кармаса, губернаторга кыланышларын сөйләп бирәм дә ул кабахәтне Себергә олактырам.

Хатынының шулчаклы кырыс холыклы булуын күргәч, Иван Максимович куркуга төште. Аверкиев тапкан урынга өяз землемеры булып вакытлыча эшкә урнашты.

1791 елның мартында Аверкиев элеккеге губерна секретаре хатыныннан каралты-курасы, бәрәңге бакчасы белән йорт сатып алды. Черек күл буендагы Алексеевский һәм Вознесенский урамнары кисешкән җирдәге бу өйне, яшәп тору өчен, Параша кабул итәргә мәҗбүр булды. Ишегалдында ике өй; һәркайсында хуҗалар өчен икешәр һәм хезмәтчеләр өчен берәр бүлмә иде. Лобачевскийлар күчеп килгән өй үзенең бизәкләп эшләнгән яшел капкачлы тәрәзәләре белән Алексеевский урамына карый. Өй тирәсендә бакча, тау астында гына Почайна инеше — җәй көне бу тирә дачага әйләнә.

Аверкиевларның таш пулатыннан яңа өйгә күчкәч, Параша йорт эшенә күмелде. Киләчәк турындагы күңелсез уйдан, язмышның рәхимсезлеге турындагы хәсрәттән аерылу, онытылу иде аның теләге. Ләкин соңгы кичерешләрдән сәламәтлеге какшаган иде, һәм ул бер айга якын түшәк өстендә ятты. Хәтта энисенең каты авыру хәбәрен дә ул, күңелсез хәлнең асылына төшенеп җитмәгәндәй, илтифатсыз гына тыңлады.

Әмма озакламый яшь организм табиплар нәрсә дип атарга да белмәгән бу сәер чирне дә җиңеп чыкты, һәм Параша август азагында малай тапты.

Шушы чордан аның тормышында бәхетле көннәр башланды. Беренче баласы Сашага кайнар мәхәббәт, уртак мәшәкатьләр, уртак шатлыклар һәм борчулар аны ире белән ахыргача килештергәндәй булды. Әти кеше өйләнешкән көннәрдәге кебек йомшак күңелле, тәмле телле, кайгыртучан иде хәзер. Эшенә вакытында йөри башлады, эчүне дә ташлады...

Гомеренең әнә шул онытылмас чорын искә төшергәч, Прасковья Александровна үзалдына елмаеп куйды. Аның йокы пәрдәсе белән авырайган керфекләре ачыла төштеләр... Ямщик йокымсырап киткәнгә, атлар үз җайларына юырталар һәм тояк тавышы күптәннән булып узган вакыйгаларны хәтергә төшерергә комачауламый иде. Алгы утыргычка менеп кунаклаган малайлар да — әллә алҗыганнар, әллә инде төрле

мавыктыргыч хәлләр һәм серле маҗаралар вәгъдә иткән киләчәк турында хыялга чумганнар — үзара сөйләшмичә, оеп кына баралар.

— Эчүен ташлады, — дип ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады Прасковья Александровна һәм тирән итеп көрсенде.

Кыш азагында ире шулай бервакыт хезмәтеннән соңга калып, исереп кайтты. Шул көннән башлап яңадан эчәргә кереште, югалып та торды. Бу хәл иренең төзәлүенә булган ышанычны челпәрәмә китерде. Тормыш алып бару тулысынча аның үз җилкәсенә төште.

Аверкиев аңа ярдәм итәргә теләгән иде, ләкин Параша элеккечә үз сүзендә нык торды, аның ярдәмен кабул итмәде: күңелдәге рәнҗү хисен тиз генә онытырлык түгел иде әле. Кабат Макарьевога кайтыргамы? Анда бит Парашаны әте-бете белә. Шуларга үзеңнең кайгыңны күрсәтергәме? Юк, булмый! Бөлгенлеккә төшкән карт әтидән ярдәм көтәргә ярамый.

Ире төзәлерме, юкмы — алла белә. Кайткан очракта да гаилә терәге була алмас инде ул хәзер. Ничек яшәргә соң, ничек яшәргә бу якты дөньяда?!

Шунда ул Сережа абзыйсының сабакларын исенә төшерде. И, хода, ул чагында хатын-кызларга сабак укыту бик сирәк хәл иде бит әле. Инде менә хәзер, ниһаять, Параша үзе купец һәм чиновник малайларына сабак укыта. Аларның әтиләре исә аның хезмәтеннән оятсызларча файдаланырга тырышалар — балаларын укыткан өчен сукыр тиен төртәләр. Параша алар белән бәхәсләшеп маташмый. Кичләрен тегү тегә, чигү чигә. Шул рәвешчә очын-очка ялгап бара. Чөнки ачтан үләсе килми, бала хакына булса да яшәргә кирәк, җитмәсә икенчесе булырга тора иде.

Бу чорда Парашаның өйгә язган хатлары саран булып, ул болай да бәхетсез авыру әти-әнисенә коточкыч хакыйкатьне ачып салырга курка иде. Алар шул рәвешчә соңгы минутка кадәр газиз кызларына ир белән гомер итүнең нинди авыр газапка әверелгәнен сизмәделәр.

Ире кайтса, аңаниләр әйтәчәген белми иде әле Параша. Шуңа күрә үзенең аяныч хәле турында абзыйсы Сергей Степановичка язып, аннан киңәш сорарга карар кылды.

Шебаршин исә хатны алу белән Нижнийга юл тотты һәм, иске дустын тозлап-борычлап орышу нияте белән,

Аверкиев йортына атылып барып керде. Тик кайгы белән тәмам бетәшкән картның мескен кыяфәтен күргәч, азрак йомшый төште. Парашаның бәхетсезлегендә Аверкиев үзен гаепле сизә һәм, аңа ярдәм итәргә теләсә дә, моңа ирешә алмавы өчен икеләтә хәсрәтләнә иде. Чөнки Параша, яңгыр үтми торган җылы почмактан гайре, бер генә нәрсә дә алмаячагын картка кистереп әйтте.

— Ярдәм итегез, коткарыгыз шуны,— дип ялынды ул Шебаршинга.— Хатыныгыз күптән инде гүр иясе булды, балаларыгыз юк. Макарьеводагы буш йортка кайткач, сагыштан нишләргә белми торгансыздыр әле үзегез дә.

— Була инде төрле чак,— диде Шебаршин.— Мондый бәхетсезлек турында эти-энисенә әйтергә куркам. Болай да чак-чак гомер сөрәләр, шуңа тагын бу хәсрәт тә өстәлсә.

Аверкиев тирән итеп көрсенде:

— Үзем дә Парашаның балалары белән юанып яшәрмен, шулар белән бергә гомер кичерермен, дип өметләнгән идем. Ә тормыш-ормыш арты белән борылды да куйды...

Картлар байтак кына сөйләшмичә утырдылар. Ниһаять, Аверкиев, торып, Шебаршинга якынрак килде.

— Димәк сез, Сергей Степанович, аны канат астына алырлык бердәнбер кеше. Алексеевский һәм Вознесенский урамнары чатындагы ике йортымны ярты бәясенәме, бушлаймы алыгыз. Берсендә Параша яшәр, икенчесендә сез торырсыз, ярдәм итәрсез... Алла хакы өчен дип сорыйм, күчеп кайтыгыз монда. Нишлим соң, минем ярдәмне кабул күрми бит Параша.

— Ярар, мин риза,— диде Шебаршин, ниһаять, иске дустының ничектер кечерәеп калган кулын нык итеп кысып.

Сату-алу кәгазьләре белән эшне тиз тоттылар.

Ә тагын ике атнадан, май башларында, Шебаршин Макарьевтан бөтенләйгә китте. Парашаның эти-энисенә ул Нижнийда әйбәт эш таптым, диде. Бу яңалыкны картлар шатланып кабул иттеләр. Чөнки Парашаның аны бик тә якын иткәнен беләләр иде. Үзләре дә Парашаны күреп кайтырга талпынып куйганнар иде, тик ерак юл булгач, сәфәр чыгарга кыюлыклары җитмәде. Хәер, Сергей Степанович аларга киләсе җәйдә, әгәр дә кияүләрен хезмәтеннән җибәрмәсәләр,

Парашаны ике баласы белән кунакка алып кайтырга вәгъдә биреп китте.

Шебаршинның Нижнийга баштагы сәфәре һәм Аверкиев белән булган әңгәмәсе турында Прасковья Александровна берничә ел узгач кына Сергей Степанович авызыннан ишетте.

Теге чакта ул аның үзен күрәсе итмәде, хәлбуки, кош теле чаклы гына хат язып, күченеп килүен сиздерде. Параша ул хатны якшәмбе көнне иртә белән алды,— дәрес бирергә йөгерәсе булмаганга, кәефе чагыштырмача әйбәт иде. Сергей Степановичның эре хәрефләр белән язылган сүзләрен күргәч, конвертны түземсезлек катыш шомлану белән ачты, хат-хәбәрнең һәркайсын сагаеп, хәтта хәвефләнеп каршыларга өйрәнгән иде инде ул — соңгы елларда куанычлы хәбәре булмагач, нишләсен соң инде?

«Кадерле дустым, Парашенька,— дип башланган иде хат.— Әгәрдә син тагын берәр атнадан Алексеевский урамындагы усадьбаң капкасы төбенә килеп туктаган олау башында мине күрсәң, бер дә гаҗәпләнмә. Егордан ишетүемчә, андагы бер йорт сиңа кирәкми икән.

Ә килгән шәпкә ул миңа ярап торыр иде. Ни өчен дисәң, мине Нижнийга эшкә чакырдылар. Бик тиз килергә кушалар. Синең белән Саша тирәсендә минем дә ялгызлыктан күшеккән җаныма җылырак булыр, дип өметләнеп калам...»

Параша укуыннан туктады да хатны кинәт кенә яңагына кысты һәм, башын өстәлгә салып, үксеп елап җибәрде. «Җылырак... Җылылык...» Аның тормышында бик аз булды шул һәркем өчен бик тә кирәкле җылылык — җан җылылыгы. Ә бит ул бөтен йөрәге белән шундый җылылыкка омтылды, шуңа өметләнеп яшәде...

— Тагын бер атна көтәргә,— дип пышылдады Парашаның кайнар иреннәре.

Ләкин, никадәр генә озын булып тоелмасын, ниһаять, бу атнаның да азагы җитте.

Көннәрдән бер көнне Алексеевский урамындагы тып-тын ишегалды ыгы-зыгы белән тулды. Шар ачып куелган капкадан йорт кирәк-яраклары, өй җиһазлары, китаплар белән дыңгычлап тутырылган галәмәт олы эрҗәләр төялгән олаулар керде. Шебаршинның хезмәтчеләре йөкне җәһәт кенә бушаттылар да Лоба-

чевскийлар күршесендәге буш йортка ташый башладылар.

Бу эшләрнең барысына да өлкән яшьтәге хезмәтче Алексей җитәкчелек итте. Ул Парашага юлда бариннын коляскасы ватылуын һәм Сергей Степановичның урнаштырырга рөхсәт соравын хәбәр итте.

— Нинди рөхсәт сорау?! — дип эче-тышы белән балкып елмайды Параша.— Инде син, Алексеюшка, үзең белгәнчә урнаштыр бариннын әйберләрен.

Ачык капкада юл коляскасы күренгәндә Параша, кулына баласын күтәреп, әле һаман кечкенә болдырда басып тора иде. Кыңгырау чылтыравын ишеткәч, сабый кызык кына итеп кулын бутады: ишегалдындагы гадәти булмаган ыгы-зыгыны ошатты булса кирәк. Ул арада коляска басма алдына килеп туктады. Шебаршин, фуражкасын салып, коляскадан җиңел генә сикереп төшүгә, бала аңарга кулын сузды. Параша эндәшмәде, аның яңагы буйлап күз яше тәгәрәп төште. Сергей Степанович кулын сузып килде дә аны сизелерсизелмәс кенә калтыранган иңеннән кочып алды.

— Бар да рәтләнер, Парашенька, бар да рәтләнер,— диде ул калтыравык тавыш белән.

Өй җиһазларының бер өлешен Лобачевскийларга ташыдылар. Параша, тынычланып, ашарга-эчәргә әзерләү һәм кешеләрне урнаштыру эшенә керешге. Бу соңгы ике елда беренче мәртәбә аның җаны җылынды, ялгыз тормышның салкын бозы эреде; хәзер аңа таянырлык, ә балаларына сыенырлык кеше бар иде.

Шебаршинны Параша кыз чагыннан ук бик ярата, ләкин шул ук вакытта ятсына һәм бераз курка да торган иде. Хәзер, күршеләр булып яши башлагач, күңеле белән аңа ышанып омтылды.

Тышкы кыяфәте белән бераз тупасрак, кызып китүчән бу кеше, бүтәннәрнең әйтүенә караганда, ачуы килсә бик усал да, ләкин һәрвакыт гадел була иде. Шебаршин бик акыллы һәм укымышлы кеше: университет бетергән, берничә тел белә, матур гына рәсемнәр ясый, шигырь яза. Ул Декарт философиясен яклый — математиканы башка фәннәр өчен үрнәк саный. Ләкин ул, барыннан да бигрәк, политиканы күзәтеп бара һәм бәхәсләшергә ярата. Җирле халык аны бик тиз танып өлгерде һәм, Макарьевтагы шикелле үк, хөрмәт итә башлады. Бәхетсезлеккә очраганнарга ярдәм кулы

сузарга әзер торган бу мәрхәмәтле һәм намуслы картның сүзенә һәркем ышана иде.

Аның акылы һәм гаделлеге Парашаның күңелендәге хәсрәт эзләрен киметте. Хатын акрынлап тынычланды һәм тормышка яңадан ышаныч белән карый башлады. Күп газаплар күреп, рухи сынау узган Параша унсигез яшендә зур милекнең хуҗасы булып китте: Шебаршинның йорт мәшәкатьләренә вакыты калмый, эше күп иде.

1792 елның 20 ноябрендә Лобачевскийлар гаиләсендә икенче малай — Коля туды.

Иван Максимович тагын эйләнеп кайтты, Параша аны янә бер мәртәбә гафу итте. Ләкин аңа карап кына гаилә башлыгы хатыны һәм балалары өчен җаваплылыкны үзенә алырга җыенмады. Әйдә, энә Сергей Степанович кайгырта бирсен. Моңа ул бик канәгать иде.

Тагын бер мәртәбә «авыру сәбәпле» отставкага чыкканнан соң, Аверкиев аны 1795 елның азагында Нижнийдагы межа конторасына кечкенә генә бер урынга урнаштырды. Иван Максимович бу хезмәтендә дә уңышка ирешә алмады...

Ә Шебаршинның эшләре әйбәт кенә тәгәри. Коля тугач, өй кысан була башлады. Сергей Степанович Печера урамында яңа йорт һәм буш җир сатып алды. Алексеевский урамдагы йорттан ерак түгел, каршыда гына иде ул йорт. Шебаршин анда зур бакча утыртты, аның оранжереясы Аверкиевларныкыннан да матуррак булды.

Нижний Новгород губернасында иң яхшы землемерлардан саналган Сергей Степановичның эше баштан ашкан, ул һәрвакыт юлда йөри иде. Балаларны сагынып, бераз ял итәргә дип кайтып өлгерми — икенче көнне үк ишек төбенә коляска килеп туктый. Елгыр пар атны кучер көчкә тыеп тора, Авдотья кузла астындагы әрҗәгә таба ашлары тәргән төенчекләрне һәм башка юл кирәк-яракларын куя. Кечкенә Саша Сергей Степановичка килеп сырпалана, күзенә туры карарга тырыша, карт моны күреп читкә борыла, елмаюын яшерә иде.

— Парашенька,— ди ул буш чынаягын читкә этеп,— көн бик матур, әллә бер йөреп керәбезме? Үзебез белән тагын берәрсен алырбыз, бәлки.

Параша эченнән генә көлә. Сергей Степанович белән алар алдан ук сөйләшеп куйганнар, шулай да берни белмәгәндәй кыланалар иде.

— Белмим шул,— дип куя ул.— Кемне алырбыз икән соң?

Бу сүзне ишеткәч, Сашаның түзеп торырлыгы калмый:

— Мине алыгыз, мине! — дип кычкырып җибәрә ул.— Сережа абый, мин зур үстем, кузлага кучер янына утырып барам. Аннан яхшы күренә.

— Юк, юк,— дип каршы төшә ана.— Минем янга утырырсың, ерак бармабыз. Коленька...

— Коленькадан Устинья күзен дә алмаячак, белеп торасың лабаса,— ди моңа каршы хуҗа, урыныннан җиңел генә күтәрелеп.— Тизрәк бул, Парашенька, төшке чәлләгә чаклы атларга кигәвен дә артык каныкмый.

...Вакыт уза торды. Коля да инде үсте. Балалар тәрбиясе турында кайгыртып, Сергей Степанович аларны җир үлчәү эшен яратырга өйрәтте. Ул бик кызык итеп сөйли; Сережа абыйлары белән бергә уздырган һәр көн малайлар өчен бәйрәмгә тиң иде.

Андый кичләрдә ул еш кына:

— Карап-карап торам да, Парашенька, безнең сәфәр йөрүләр Саша өчен бик-бик файдалы бит,— дип сөйләргә тотына.— Мин межа уздырганны ул бик зур кызыксыну белән күзәтә. Үлчәүгә яки план төзүгә кагылышлы нәрсәләрне зурларча хәтеренә сеңдерә. Күр дә тор, землемер булачак! Аллага шөкер, файдалы һәм кирәкле һөнәр. Җирне дөрес итеп бүлеп бирү — изге эш ул: бәхәс туктый, ызгышырга сәбәп калмый, хуҗалык эшләре бөтен дәүләтебез күләмендә ныгый...

Сергей Степанович хатынга киңәш тә бирә:

— Исеңдә тот, Парашенька, Сашаны Мәскәү гимназиясенә бирергә кирәк булыр. Бер дигән землемер чыгар аңардан.

Аларның гаиләсенә карт якын туганнарча карый иде һәм Лобачевскийларның өченче малайлары — Алексей тугач, ул аны үз исеменә яздырды.

Бу мәсьәләгә Иван Максимовичның бер дә исе китмәде. Күпчелек вакытын ул юлда йөреп үткәрә, өйдә чагында да балалар аңардан нык ятсыналар. Алар аның янына килергә дә куркалар, ә кече күңелле Сергей Степановичны торган саен ныграк яраталар иде.

1797 елны көзен, көтмәгәндә, Нижний Новгородтагы межа конторасын яптылар һәм бөтен чиновник-

ларны Уфага күчерделәр. Ирен озаткач, Параша җиңеләеп калды. Тыныч тормыш итәргә моннан соң берни комачауламас дип уйлады ул. Тик ул уйлаганча булмады. Бер атна узгач, Сергей Степанович каты авырып китте. Ул озак авырмады. Кайгыдан ябыгып киткән Парашага, бәхилләшү өчен, балаларны алып керергә кушты.

— Укып кеше булуларын күрә алмадым шул, Парашенька. Тагын бер ялгызың кайгыртырга туры килә инде. Кара аны, университет бетереп кеше булсыннар. Бар милкемне сиңа калдырам,— диде карт һәм калтыраган кулы белән Парашага рәсми кәгазь суздш.

Кичен ул вафат булды.

Параша мирас булып калган өйдә яшәвен дәвам иттерде. Шебаршинны истә тотып, ул үзенең өч улын да «мәрхүм капитан Шебаршин тәрбияләгән балалар» дип атый иде.

Ә Иван Максимович, хатыны һәм балаларының ничек яшәве белән бер дә кызыксынмыйча, Уфада тора бирде. Ул 1800 елны гына алар янына кайтып килде. Ләкин ул кайтканнан өйдә шатлык өстәлмәде. Аек чагында ул бернигә катнашмыйча һәм бернигә исе китмичә, юньләп сөйләшмичә йөрде. Озакламый тагын эчәргә тотынды, исергәч, һәркемгә бәйләнде. Елау-ялварулар ярдәм итмәде. Параша аның белән бергә тормыш алып бару мөмкин булмаячагын тәмам аңлады.

Ире кайтып киткәннән сон, Прасковья Александровна Шебаршинның милкенә рәсми рәвештә рөхсәт алды. Балаларын тәрбияләп үстерергә җитәрлек акча булгач, иреннән аерылырга һәм Нижнийдан китәргә дә була иде.

1801 елның көзендә Прасковья Александровна, Нижнийдагы йорт-җирен сатып, балалар белән Макарьевка әтисе янына кайтып төште. Бу вакытта әнисе гүр иясе булган иде инде.

Киләсе елда кече улы Алешага җиде тула. Сергей Степановичның соңгы васыятен үтәү йөзеннән, Прасковья Александровна Казанга барырга, балаларын гимназиягә бирергә булды. Идел буеннан алып Камчаткага чаклы булган арадагы бердәнбер гимназиягә разночинец балаларын урнаштыру бик авыр мәсьәлә иде. Ләкин тормышта очраган кыенлыклар аның ихтыярын сындырмаган, киресенчә, ныгыткан гына иде. Ул тәвәккәлләп юлга чыкты...

Кучерның кинәт кенә атка чыбыркы белән селтәве Прасковья Александровнаны уйларыннан тагын аерды. Тарантас таудан кызурак тәгәри башлаган иде. Юл кирәк-ярақлары салынган кәрзиннәр һәм төеннәр сикерешеп алалар.

— Аллага шөкер, Казанга җитәбез! — дип куйды кучер.

Урман бетеп, татарларның борынгы башкаласы күренә башлады. Ак йортлар кояш нурында коена, алар арасында мәчет манаралары һәм чиркәү гөмбәзләре кукраеп утыралар. Шәһәр заставасына җитәргә әле тагын берничә чакрым бар иде.

— Әнкәй,— диде Коля түземсезләнеп,— болай артка карап бару алҗытып бетерде. Кучер янына утырып, алга карап барасым килә. Утырыйм инде?..

— Утыр,— диде әнисе, бераз көттереп, истәлекләреннән аерылып бетмәгән хәлдә.— Тик егылып төшмә.

Шатлыктан Коляның авызы ерылды, ул тиз генә кузлага менеп утырды.

— Эх, малкайлар, кызурак кыймылдагыз! Эх!..— диде Коля атларны куалап. Ул чыбыркы шартлатып алды, тыңлап торды.— Ишетәсезме?.. Ишетәсезме, ничек шартлады? — дип сөйләнде.— Һава бар анда. Буш урында көтүче чыбыркысын селтәсәң дә, бу чаклы шартламас.

Приказчик белән кучер шаркылдап көлеп җибәрделәр. Прасковья Александровна да елмаеп куйды. Малай боларның көлүен күтәрә алмады — гарьлегеннән кызарып, чыбыркыны кучерга бирде һәм кире үз урынына төште.

Атлар, тиздән ял итү һәм ашау мөмкинлеге булачагын сизенеп, үзлекләреннән юыртып киттеләр. Приказчик сүз әйтмәде. Казанга җиткәндә, олауларны артта калдырганда да куркыныч юк иде.

Прасковья Александровна авыр юлның бетүенә сөенде. Ләкин аның йөрәге ешрак тибә башлады: Казан, Казан дип киләләр дә бит, шәһәр ничек каршылар аларны? Аның улларын нинди язмыш көтә?

Юл кырыенда утырган багана шәһәргә җитәргә нибары өч чакрым калганын белдерде. Чыннан да, Казанканың сулъяк ярындагы иң биек җиргә урнашкан Кремль диварлары, ак ташпулатлар һәм атаклы Сөембикә манарасы яхшы ук ачык күренә башлады. Биек агачларга яртылаш томаланган тәрәзәләр һәм өй түбәләре, баеп бара торган кояш нурларында

коенып, аллы-гөлле төсләргә керәләр һәм шәһәрне әкияттәге шикелле гүзәл итеп күрсәтәләр иде.

Атлар дамба буйлап юырталар: дамбаның кырыйларына кыска баганалар утыртылган, гүя, ниндидер землемер аларны юри, юлчылар адашмасын өчен утырткан инде. Коля юлның ике ягыннан еракка тезелеп киткән баганаларга озак карап барды. Ул баганалар аңа юл күрсәткеч маяклар булып тоелды. Кая юл күрсәтәләр соң алар? Әлбәттә, гимназиягә. Шуның өчен бу авыр юлга чыктылар бит алар.

Баганалар берәм-берәм артка чаба башлагач, Коляның күз алдына янә әлеге серле, тылсымлы гимназия килеп басты. Менә ул якты зур залга килеп керә. Түрдә озын өстәл, ә өстәл артында — укытучылар. Алар бик күп. Һәммәсе дә кара сюртуктан, һәммәсе дә чал сакаллы. Өстәл янына килгәч үк, аңа сорау яудырырга, бөтен фәннәрдән берьюлы имтихан алырга керешәләр... Җавапларын тыңлаганнан соң: «Кызганычка каршы, сезне гимназиягә кабул итә алмыйбыз. Сез бик аз беләсез», дисәләр, нишләрсең? Нинди хурлык! Ул чагында әнисе ни әйтер? Сергей Степанович исән-сау торса, аның күзенә ничек күренгән булыр иде? Ә бит ул: «Имтиханнарыгызны тапшыргач, гимназиягә минем җир үлчи торган чылбырны һәм эккерымны бүләк итеп бирерсез. Анда бардыр, әлбәттә, андый инструментлар, тик дәрестә минем әйберләрдән файдалануыгыз турында уйлау җаныма рәхәтлек бирер...» дигән иде. Менә хәзер алар мирас итеп бирелгән ул коралларны үзләре белән алып баралар.

Укырга керә алмасалар?! Ул чагында чылбыр белән эккерны нишләтергә? Гимназиягә биреп калдырыргамы, әллә кире Макарьевога алып кайтыргамы?..

Коля, әнә шул сорауга җавап эзли-эзли, дамбаны чыгуларын һәм утын складлары, сәүдә лабазлары, тоз һәм тире өемнәре яныннан бара башлауларын сизми дә калды.

Юл бер пычрак урамга килеп керде. Әйләнә-тирәдә сасы ис — тире, дегет, балык, сабын исе бергә буталган иде. Күрше тыкрыктан тигезсез таш юл буйлап дөбер-шатыр килеп узган арба тавышы ишетелә. Ул арбаның майламаган тәгәрмәчләре шыгырдавыннан колакны томалыйсы килә. Шул вакыт кемдер әче тавыш белән: «Су са-там! Ка-ба-а-ан суы!» дип сузып җибәрде. Аңарга карлыккан тавыш кушылды: «Әй,

балалар, бер тиенгә сыер ала алмассыз, миннән кабартма алып ашагыз!»

Һәркайда көл өеме, чүлмәк ватыгы, чүпрәк-чапрак. Нижнийдагы кебек, монда да чүп-чарны юлга ташлыйлар икән.

Заставаны үткәч — элек монда әби патшаның, ягъни Екатерина Икенченең Казанга килүен хөрмәтләп Триумфаль арка эшләнгән булган, әмма ул Пугачев явы заманында янган — тарантас Триумфаль урамга килеп керде. Биек коймалар эченнән бәйдәге усал этләрнең һау-һайлап өргәне ишетелде, өйләрнең киң кәрнизләре, яшел һәм кызыл төскә буялган очлы түбәләре күренде. Капка төпләрендә шәһәр халкы кайнаша. Балалар һәрнәрсәне кызыксынып күзәтте. Әнә җитез приказчиклар амбар яки лабаз тирәсендә бозау башы кадәрле йозакларын биклиләр, ачкыч бәйләмнәре белән шалтыр-шолтыр киләләр; әнә симез купец хатыннары, такта кибетләреннән башларын чыгарып, әче тавыш белән нәрсәдер кычкыралар; әнә каракүл бүрек, билле бишмәт, читек-кәвеш кигән кәҗә сакаллы татарлар юл уртасында кызып-кызып сөйләшәләр. Әнә бик зур һәм бик матур чиркәү алдында сәләмә киемле, озын чәчле, куркыныч хәерчеләр, көйләп-көйләп, язмышларын каргыйлар.

— Ипилек кенә... Алла ризалыгы өчен, ипилек кенә бирсәгез лә...

Кинәт урам чатыннан крестьян киеме кигән бер төркем кеше һәм аларны урап алган конвой килеп чыкты. Бунт күтәрүче ул крестьяннарны башта крепостька алып барачаклар, аннан этап белән кырыс табигатьле Себергә озатачаклар икән.

Урам буйлап, бунтарьлар алдыннан, мичкәле арбасы янынннан, су сатучы татар агае килә. Ул үзенең ябага атына чыбыркы белән дә селтәнде, ләкин аты ун-унбиш сажень гына юырткан булды да бөтенләй туктап калды.

— Юлны бушат! — диде конвой начальнигы, карлыккан тавыш белән җикеренеп.

— Менә сиңа Казан! — дип бәя бирде Саша үзенең күргәннәренә.

— Бу әле Казан түгел, улым... Чын Казан түгел дигәнем... Дворяннар яши торганы әнә тегендә! — Кучер кулын сузып тау башында утырган ак ташпулатларны күрсәтте. — Анда урамнар киң, матур...

— Монысы нәрсә тагын, чылбырлы? Күпер

түгелме соң? — дип сорап куйды Прасковья Александровна.

— Әйе, әйе, күтәрмә күпер... Болак аркылы...— диде аз сөйләүчән приказчик та сүзгә катнашып.— Көндез аннан кеше йөри, төнлә күтәреп, Иделдән пароход кертәләр. Иван Степанович үз акчасына эшләтте. Тегенди-мондый гына купец түгел шул безнеке — бөтен Россиядә сәүдә итеп йөри. Күпме машина тота. Армия өчен күлмәклек һәм кием эчлек киндер, итек, каешны ул эшләтә. Яз һәм җәй айларында Иделдән чыпта, тугым, кайры, киндер, тире-яры, сабын, шәм кебек нәрсәләр озатыла. Әнә теге амбарлар һәммәсе безнең Жарковныкылар... Менә килеп тә җиттек...

Атлар Болакның сулъяк ярында беренче булып утырган ике катлы зур таш йортның тимер капкасы төбенә туктадылар. Приказчик тарантастан сикереп төште һәм кучерга Лобачевскийларны Лядской урамга илтеп куярга кушты. Үзе Адмиралтейство тирәсендә артка калган олавын көтәргә калды.

Прасковья Александровна юлдашы белән әдәпле итеп саубуллашты, ә малайлар, түземсезләнеп, зурларның сөйләшеп бетергәннәрен көттеләр — аларның тизрәк кузгалып китәселәре килә иде.

Кабан күлен Казанка белән тоташтырган яшел һәм пычрак сулы Болак аркылы чыккач, юлчылар халык гөр килеп торган Проломный урамын уздылар һәм Кремль стенасы буйлап тауга юнәлделәр. Авыр тарантасны арыган атлар көчкә тарта. Менә Спасск манарасы алдындагы мәйданга җиттеләр. Бу — халыкка патша указларын укый һәм, хөкемнәр чыгарылып, җәза бирелә торган мәйдан иде. Ләкин хәзер бу тирәдә күңел ачып йөрүчеләр генә очрый.

Воскресенский урамының почмагында гаҗәеп зур йорт — гостиный двор салынып ята. Аның каршында бай фабрикант Дрябловның мәһабәт сарае. 1767 елда Казанга килгәч, Екатерина Икенче шунда туктаган. Әби патшага Казан ошаган, һәм ул аның турында болай дип язган: «Ошбу шәһәр, шик юктыр, Мәскәүдән соң Россиядә беренче шәһәр».

— Кара! — диде Саша акрын гына, Коляны җиңеннән тартып.

Алар яныннан сөлек шикелле пар ат җигелгән алтын бизәкле һәм лаклы карета чабып үтеп китте. Атларның сыртына күк ятьмә ябылган, дагаларын

урам ташына тигезмиләр дә шикелле. Укалы кием кигән ике лакей каретаның артына баскан.

— Егылып төшсәләр! — диде Алеша, коты алынып...

— Сезнең гимназиягез ө-ө-нә кайда,— дип, кучер кулы белән Воскресенский урамының аргы башына күрсәтте.

Малайлар ялт итеп башларын уң якка бордылар, ләкин анда урамның ике ягыннан да матур йортлар тезелеп киткән иде; аларның кайсысы гимназия икәнен малайлар белә алмый калдылар.

Кремльнең зур сәгате дүртне сукты.

Тарантас, мәйданны үтеп, кәкре тыкрыктан Черек күлгә таба төшеп китте. Анда, Воскресенский тавыннан башлап, такта кибет, палаткалар һәм ларлар тезелгән. Бу — азык-төлек белән сәүдә итә торган урын. Монда он, ярма, бәрәңге, суган, май, икмәк, калач, бәлеш һәм башка төрле ашамлыклар сатыла. Яшелчә һәм җимеш олаулары тирәсендә яланаяклы, сәләмә киемле малайлар йөренә. Алар җиргә коелган алмаларны җыялар, олаучы авызын ачып торса, капчыкларын яралар. Һәр җирдә халык кайный.

Черек күл буенда, аш исе бөркеп, мунча шикелле каралып беткән берничә алачык утыра. Анда җитез карчыклар коймак, токмач, пилмән пешерәләр. Шунда ук ачык һавада, җиргә кагып утыртылган өстәлләр янында, тәбәнәк эскәмияләрдә ашаучылары да күренә, чират көтүчеләр дә бар. Аннан чак кына арырак комач: сабын, ислемай, кызыл мал белән сәүдә итәләр. Парикмахерлар, кайчыларын шак-шок китереп, халыкны чакыралар. Чәчен тигезләтергә теләүче табылса, алар аны бүкән өстенә утыртып, башына чүлмәк кигезәләр дә, чүлмәк кырыеннан чыгып торган чәчен тигезләп кыркып ташлыйлар.

Тимерче алачыклары һәм башка төрле тимер эшләре биналары тезелеп киткән Кузнечныйны үткәч, тарантас сулга борылды һәм Лядской урамга керде. Ике катлы бер йортның парадный ишеге төбенә туктады. Йортның аскы каты таш, өсте агач иде.

— Менә килеп тә җиттек,— диде Прасковья Александровна улларына.

Коля тарантастан сикереп төште дә болдырга йөгереп менде һәм җәһәт кенә ишек кыңгыравының бавын тартты. Җиз чыңы тынып та өлгермәде — тупса-

сына кадәр ачылып киткән ишектә тәбәнәк буйлы, тулы гәүдәле карчык күренде.

— Парашенька,— дип каушап төште ул.— Көтә-көтә зарыгып беткән идем. Ходавәндәм, ничек чибәрләнгәнсең, нинди баһадирлар үстергәнсең. Ә без...— карчыкның соңгы сүзләрен кунаклар артыннан тавышсыз гына ябылган ишек йотты.

## 2

Казанга килеп төшкән беренче көннәрдә малайлар өйдә бикләнеп утырырга мәҗбүр булдылар. Прасковья Александровна иртә таңнан эш белән чыгып китә һәм улларына: «Бәлкем, кирәк булырсыз», дип, өйдә утырырга кушып калдыра. Иске танышларына төшүгә һәм аларның бик кунакчыл булуларына да карамастан, чит кеше өендә вакыт бик акрын уза иде.

Прасковья Александровна Казандагы дәрәҗәле дусларының адресларын Сергей Степановичтан алып калган иде. Ләкин аларның кайберләре үлгән, кайберләре бу шәһәрдән күчеп киткән булып чыкты. Әзли торгач, ниһаять, кирәкле кешеләр табылып, аңа балаларын гимназиягә урнаштырырга ярдәм иттеләр.

Беркөнне Прасковья Александровна шатланып кайтты. Кайтып керүгә улларын кочаклады:

— Алдым... Өчегезне дә гимназиягә урнаштырырга рөхсәт алдым...— дип сөйләнде ул, күзеннән шатлык яшьләрен сөртеп. Аннары сумкасыннан пөхтә итеп бөкләнгән кәгазьне алып укып күрсәтте:

— «Укырга кабул итәргә. Казна исәбенә вакансия ачылганга кадәр, үз исәпләренә тәрбия кылырга», диелгән.

— Кабул иттеләрме? — дип, хуҗа хатын да сорады.

— Әйе... иттеләр...— Прасковья Александровна авыр сулап куйды,— экзаменнарын тапшыра алсалар...

Ул заманда гимназиядә барлыгы өч — түбән, урта һәм югары — класс була торган иде. Болардан тыш, гимназиягә хәзерләү өчен башлангыч класс бар иде. Гимназияне тәмам итүчеләр тулы урта белем алып чыгарга тиешләр. Шуңа күрә түбән класска керер өчен дә шактый читен сынау узарга туры килә иде.

Казанга килер алдыннан ике ел элек Прасковья

Александровна балаларын үзе укыта башлады: аларны грамматика нигезләре һәм арифметиканың башлангыч дүрт гамәле белән таныштырды.

Балалар укырга һәвәс булып чыктылар һәм күп укыдылар. Бер елны Саша белән Коля хәтта Нижнийда халык училищесында да укып йөрделәр. Эмма Прасковья Александровна хәзер балаларның үзләре кебек үк дулкынлана, тик ул моны сиздермәскә тырыша. — Менә сынаулар көне килеп җитте.

Кояшлы матур иртә. Өрәңгеләрнең соңгы яфраклары һавада акрын гына бөтерелеп җиргә төшәләр. Анда-санда юл кырыйларында комачтай кызарып яткан бу яфраклар гүя җылы көннәрнең үтеп киткәнлеген сөйлиләр, шуңа зарланалар иде.

Прасковья Александровна улларын гимназиягә озата барды. Куртка кигән Коля, иртәнге салкыннан бөрешеп, иң алдан йөгерә. Бераз баргач, ул артына борылып карый һәм:

— Әнием, гимназия күренмиме әле? — дип сорап куя.

Аның артыннан Саша бара. Уң кулында өчаяклы эккер, сулында — землемер чылбыры. Саша үзенең дәрәҗәсен белеп, башын артка ташлап, горур кыяфәт белән бара. Иң арттан Прасковья Александровна үзе атлый. Җилкә аркылы бау белән язу тактасы һәм грифель аскан кече малаен җитәкләгән.

Шәһәр инде йокыдан уянган. Балык базары кибетләре тирәсендә халык аеруча күп. Алдан йөгерүче Коля урам тыкрыгында, кая барырга белмичә, туктап калды. Аның күзе коймага ябыштырылган кәгазьгә төште. Якынрак килеп, укый башлады.

«Игълан.

Ошбу игълан аркылы Казан губерна идарәсе түбәндәгеләрне белдерә: штабс-капитан Попов милкендәге ундүрт яшьлек Иван исемле крестьян угылы сатыла, бәһасе 300 сум, еллык доходы 30 сум. Вә янә өч яшьлек озын торыклы, соры төстәге алаша сатыла. Бәясен килешергә мөмкин».

Коля үзенә таба якынлашып килүче әнисенә күтәрелеп карады.

— Әйдәгез, балалар,— диде Прасковья Александровна, койма яныннан читкә атлап.— Бернәрсәгә дә шаккатмагыз. Гаделсезлек бу шәһәрдә дә бар. Сез моны соңыннан аңларсыз, укып чыккач. Ә хәзергә имтихан турында гына уйлагыз.

Ана үзенең балаларын Воскресенский урамга алып менеп китте. Урам башында матур булып ак таш бина утыра иде.

Гимназия Казандагы иң матур йортларның берсенә — элеккеге губернатор сараена урнашкан иде. Коринф стилендә салынган бу мәһабәт йортның фасадын калын һәм төз баганалар бизи. Ул колонналар өстендә өчпочмаклы фронтон булып, яңа глобус, лира һәм математика инструментларының рәсеме төшерелгән. Бинаның түбәсенә гөмбәз сыман бернәрсә эшләнгән.

Малайлар гимназия алдындагы мәйданда сүзсез генә басып тордылар. Гимназия чыннан да экияттәге кебек гүзәл бер сарай булып чыкты. Әнә укучылар килә. Һәрберсенең өстендә яшел постау куртка. Кызыл яка һәм кызыл кант, ялтыравык сары сәдәфләр. Тик кайберләренең генә кызыл кантлары юк. Сәдәфләре дә ак.

— Мин сезне әнә тегендә, кояш сәгате янында көтәрмен,— диде Прасковья Александровна, кулы белән урам чатындагы кечкенә бакчага күрсәтеп.— Сез, икенче катка менеп, инспектор Илья Федорович Яковкинны эзләп табыгыз. Сездән экзамен алуны гимназия советы аңар тапшырды.

Ана үзенең улларына тагын, инспектор Яковкиннан тыш, экзаменда математик Григорий Иванович Корташевский, физик Иван Ипатьевич Запольский һәм рус теле укытучысы Лев Семенович Левицкий булачагын хәбәр итте.

— Алдан сөйләшкәнчә эшләгез — эккерны һәм чылбырны гимназиягә бүләк итеп бирергә онытмагыз... Башта, әлбәттә, экзаменыгызны тапшырырсыз. Йә, барыгыз. Кыю булыгыз, кыю булсагыз — бар да рәтләнер,— диде ана һәм, улларын үбеп, озатып калды.

Малайлар, төз колонналар арасындагы болдырның авыр имән ишекләрен ачып, каравылда торучы инвалид солдат янына килеп керделәр. Бу киң вә иркен вестибюльгә яктылык түшәмдәге пыяла гөмбәз аша төшә иде.

— Ә сез кая? — дип сорады инвалид, агач аягын тукылдата-тукылдата якынаеп.

— Без... без имтиханга килгән идек,— диде Саша һәм үзе инвалидка таба бер адым атлады.

— Имтиханга булса, баскычтан менегез дә сулга борылыгыз. Имтиханга килүчеләр шунда җыелалар. Өс киемнәрегезне биредә салып калдырыгыз. Анда

мengәч актарынып йөрмәгез, карагыз аны. Мин астан күзәтеп торам.

Инвалид шулай диде дә, идәнне тукылдатып, үз урынына барып басты.

Югарыдан башка малайлар гөрләшкәне ишетелә иде.

Кинәт кенә, бина эчендәге барча авазларны күмеп, колак пәрдәсен зыңгылдатып, кыңгырау чылтырады. Тавышлар тынды.

— Киттек,— диде Саша.

Алар — шундый киң һәм иркен баскычта өч бәләкәй малай — дулкынлануларын тышка чыгармас өчен бер-берсенә карамыйча, иңнәрен-иңгә терәп, янәшә атладылар.

Ниһаять, менеп җиттеләр. Олы ак ишек алар теләгәннән якынрак булып чыкты. Ул тоткасына орыну белән тавышсыз гына ачылып китте һәм Коля тәбәнәк бусага аша иркен залга килеп керде.

Воскресенский урамга караган зур тәрәзәләр буена куелган озын өстәл артында олы яшьтәге, ягымлы кызыл чырайлы юан гына укытучы утыра. Бераз читтәрәк, класс тактасы янында, көмеш укалы күтәрмә якалы, зәңгәр постау мундир кигән ике егет тора. Аларның берсе тактага нәрсәдер яза һәм тыныч тавыш белән аңлата. Тавышына һәм хәрәкәтләренә караганда, ул бик кырыс холыклы булырга тиеш. Икенчесе, киресенчә, бик юаш кыяфәтле. Монысы буйга да тәбәнәгрәк, бераз юанрак та.

«Кырыс холыклы»сы малайларны күреп алды.

— Иван Ипатьевич, Лобачевскийлар килде. Хәтерегездәме, безгә алар турында әйткәннәр иде,— дип, ул каршы алырга юнәлде.

Малайлар исәнләшкәннән соң, ул алардан:

— Экзамен тотарга килдегезме? — дип сорап куйды.— Бик шәп... Өстәл янына рәхим итегез... Исемнәрегез ничек соң? Николай Лобачевский дисезме? Бик шәп! О, ничаклы китап алып килгәнсез! Укырга яратасызмы? Күрсәтегез әле, нинди китаплар икән...

Һәм «кырыс холыклы»сы китап исемнәрен укый башлады:

— Ломоносовның «Грамматика»сы... Бик шәп... Монысы нәрсә? «Евклид геометриясе»... Кара син аны! Димәк, сез яшь геометр, яшь Евклид буласыз?..

— Инспектор әфәнде...

— Укытучы,— дип төзәтте Коляның сүзен «кырыс холыклы».

— Укытучы әфәнде, гафу итегез, мин землемер булырга тели идем шул...

Бу вакытны «Инспектор Илья Федорович Яковкин» дип кечкенә генә такта кадакланган ишектән кырык яшьләрдәге бер кеше чыгып, залдагыларга баш иеп, кызу адымнар белән өстәлгә таба юнәлде. Өстендә кара фрак, ак жилет һәм зәңгәр панталон. Аның җәенке башы, ябышып торган майлы чәче, мыскыллы елмаюы, мәче башлы ябалакныкы кебек күзе Коляның хәтеренә онытылмаслык булып кереп калды.

— Башлыйбызмы, әфәнделәр?! — диде ул түгәрәк яшькелт күзен әле бер, әле икенче малайга күчерә-күчерә. Аннары, «кырыс холыклы»га мөрәҗәгать итеп, өзелгән сүзен ялгап китте: — Корташевский әфәнде, сез Иван Ипатьевич белән өлкәненнән имтихан алырсыз.— Ул Сашага ымлап алды.— Ә без Лев Семенович белән уртанчысын сынап карарбыз... Кил әле бирегәрәк, егет!

Инспектор йомшак креслога кереп чумды да, кул изәп, үзе янына Алешаны чакырды. Буена карап, «уртанчы Лобачевский» дип кабул итте бугай ул аны.

Коляның башы әйләнеп китте. Саша, моны күреп, энекәше янына атлады һәм кешегә-карага сиздерми генә аның биленнән тотты. Ләкин Коля аның кулын читкә этәрде.

— Борчылма,— дип пышылдады ул,— узды инде.

Яковкин бернәрсә дә сизмәде.

— Син... ничек әле исемең?.. Николай бит?.. Әнә тегендә утыр, рәсем ясый торсаң да ярый,— диде ул боерулы тавыш белән, аннары Алешага борылды.

Коля күрсәтелгән урынга утырды һәм, үз-үзенә ачуы килеп: «Бәләкәй Лобачевский», дип мыгырданып куйды. Нәрсә эшләвенә хисап биреп тормастан, кулын сул кесәсенә тыгып грифельне тартып чыгарды. Аның уң кулында әле баярак кына китап иде. Инде хәзер, бакса, китабы өстәлдә ята, кулында — аспид такта. Менә ни өчен «рәсем ясый торсаң да ярый» дигән икән аңа Яковкин.

«Ясамыйм!» дип сөйләнде малай үҗәтләнеп һәм тәрәзәгә карады. Урамда җил көчәйгән, агач ботаклары, кемнәндер ярдәм сорагандай, кызганыч тавыш чыгарып шыгырдый, зарланышып чайкалалар иде. Шул

чагында карт юкә ботагына ала карга килеп кунды. Бик нык күшеккән иде бугай ул.

«Шул кирәк сиңа. Җылы якларга китеп кояшта җылыныр идең син акыллырак кош булсаң», дип уйлады малай йодрыкларын бит алмаларына батырып. Карга кинәт кенә муенын сузып тәрәзәгә карады. Коляның кулы ихтыярсыздан аспид тактасына үрелде. Ул бик җиңел ясый иде рәсемнәрне. Тактада нәкъ юкә ботагындагы шикелле, хәтта аныкыннан да акыллырак карашлы карга сурәте барлыкка килде. Моның белән генә канәгатьләнмәде әле Коля. Карга янәшәсенә саескан, аның янына инспекторныкы шикелле сытык йөзле ябалак ясап куйды. Шул чагында Яковкин тавышы ишетелде:

— Кече Лобачевский, кил әле өстәл янына, күрсәт әле, нәрсә маташтырдың анда? — Ул, урыныннан торып, малай янына килде. Берничә секунд дәшми-тынмый рәсемгә карап торды.— Сөрт,— диде аннары ачулы тавыш белән.— Һәм марш өстәл янына!..

Корташевский белән Левицкий гаҗәпләнеп берберсенә карап алдылар. Рәсемне алар да күрергә теләгәннәр иде бугай, тик ул арада Коля тактаны куртка җиңе белән сөртеп алды.

— Йә, башладык,— диде Яковкин, креслога утырган уңайга.

Имтихан уңышсыз башланды. Коля шулкадәр каушады ки, хәтта беренче сорауны бөтенләй ишетми калды. Сорауны кабатладылар. Малай бу юлы да бик кыюсыз гына җавап бирде. Аннары арифметиканың дүрт гамәлендә чак кына хата җибәрмәде. Ә Левицкий аны тынычландырырга тырышты:

— Борчылма син, туганкай... Белүең күренеп тора. Хәзер звательный падеж турында сөйләп бир.

Коля агарынып басып тора.

— Ну, берәр кешене чакырган чагында син ничек дисең?

— Әй! Әй, син!.. Монда кил! — дип кычкырып куйды Коля, әмма имтихан алучыларның йөзләрендә елмаю күреп гаҗәпләнде.

Лев Семенович уңайсызланып калды. Ләкин Яковкинның мыскыллы елмаюын күреп, малайга ярдәм итәргә ашыкты:

— Бәлки, үзең яраткан шигыреңне сөйләрсең...

— Уртага чыгыгыз! — дип, аңа ялгап китте Корташевский, кашын җыерып.

Коля уртага чыгып басты. Аның йөзе ап-ак, ирене кысып йомылган иде. Хәтереннән Кантемир, Дмитриев шигырьләре үтеп китте. Менә ул башын күтәрде һәм күтәренке тавыш белән латин телендә Горацийның «Мельпоменага» шигырен сөйләп китте. Бераз тыңлагач, Яковкин, учы белән өстәлгә сугып:

— Җитте,— диде.— Попугайны да өйрәтергә була болай. Тәрҗемә итеп бир син безгә, тыңлап карыйк.

— Тәрҗемәсен дә беләм.

— Йә, йә, башла!

— Сөйләмим,— диде малай кинәт ярсып, кызарынып.

— Ничек?! — дип аптырап калды инспектор.

Имтихан Коля өчен бик күңелсез тәмамланырга мөмкин иде.

— Тынычланыгыз! — диде «кырыс холыклы» укытучы арага кереп, эшнең кая таба барганын күргәч.— Хәзер үк гафу үтенегез!

— Укытучы әфәнде, мин бүтән алай итмәм...— диде Коля, авыз эчендә ботка пешереп.

Аның аска караган күзләре һәм йөзенә чыккан пошынуы гафу үтенүнең ничаклы авыр булганын сөйли иде. Левицкийның үткен күзе моны шунда ук күрде, һәм ул сүзне шаяртуга борып җибәрде:

— Мине дә әбием кечкенә чагымда бик кире малай булган дип сөйли. Үсә-үсә, әфәнделәр, үзгәрдем шикелле. Моннан кем чыгачагын хәзер үк әйтүе кыен... Йәле, Коля, үзебезнең рус шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләп бир...

— Михаил Васильевич Ломоносов шигыре,— диде Коля саңгырау тавыш белән һәм, бераз көч җыйганнан соң, башлап китте:

Фани дөньядагы кешеләр
Күтәрелеп күккә менә алсак,
Гади күз белән без Кояшны
Якын килеп янына күрә алсак,

Ачылыр иде аның һәр ягыннан
Мәңге янып торган океан.
Сугылыр ярлар таба алмыйча,
Анда чаба утлы дулкыннар.

Күп гасырлар бергә көрәшеп
Котыра өермәле ялкыннар.
Ташлар эри анда судай кайнап,
Һәм утлы яңгырлар ява шаулап...

Коля теләр-теләмәс кенә башлап җибәргән иде —

тора-бара җанланды, рәнҗүен бөтенләй онытты һәм бик матур итеп сөйләп бетерде.

Корташевский белән Запольский бер-берсенә карашып алдылар һәм, малайны хуплап, баш кактылар. Ләкин ачуы килгән Яковкин һаман бәйләнергә урын эзләде.

— Ху-у-уш,— диде ул сузып кына.— Әйтче, Лобачевский, сиңа бу шигырьне кем өйрәтте?

Коляның тавышы шунда ук сүнде, ул башын аска иде.

— Әни,— диде ул, теләр-теләмәс кенә...

— Уңышлы сайлаган димәс идем... димәс идем,— дип кабатлады инспектор.— Син әле мәгънәсенә төшенә алмаган шигырьне өйрәтмәскә иде... Әйе, башыңны катырмаска иде. Әйтче безгә, Иерусалим храмы кайчан салынган?

Коля, гаҗәпләнеп, инспекторга күтәрелеп карады. Ләкин арага Левицкий керде.

— Инспектор әфәнде, гафу итегез,— диде ул әдәпле генә итеп.— Без бит Николай Лобачевскийны түбән класска кабул итү турында сүз алып барабыз. Хәзер генә сез бик акыллы фикер әйттегез: ул аңлый алмаган сораулар белән аның башын катырмаска кирәк.

Яковкинның кашы җимерелде.

— Мондый попугайны түбән класска ничек кертеп утыртыйк?! Мин аны бөтенләй якын китермәс идем, тик инде мәрхүм Шебаршинның үтенечен искә алып кына... Әйдә, хәзерлек классында укып карасын...

Корташевский белән Запольский аның фикеренә кушылдылар, һәм шуның белән мәсьәлә хәл ителде. Экзамен тәмамланды. Инспектор таныклыкка кул куйды.

— Укытучы Федор Петрович Краснов әфәндедә укырсың,— диде ул Коляга кәгазь сузып: — Арифметиканың башлангыч гамәлләрен һәм рус теленең беренче кагыйдәләрен өйрәнерсең.

Гимназиягә эккер белән землемер чылбырын тапшырганнан соң, малайлар ашыгып урамга чыктылар. Саша һәм Алеша, кулларын болгый-болгый, әниләре янына йөгерделәр. Ә Коля гарьләнүеннән аягын көчкә өстери иде. «Димәк, мин попугай икәнмен! Димәк, мин энекәштән дә ахмаграк икәнмен!» дип кабатлый. Аңа, гүя, үзе дә кечерәеп калгандыр төсле тоела. Кинәт аның башы әйләнеп, күңеле болганып китте, һәм ул, егылудан куркып, колоннага сөялде.

Прасковья Александровна балаларын күптәннән көтә иде инде. Алар ишектән күренүгә, каршыларына китте. Коля булмагач, ул ниндидер күңелсезлек килеп чыкканын йөрәге белән сизенде һәм Сашага дөресен сөйләп бирергә кушты. Улы сөйләгәндә ана, сулу алырга да куркып, бүлдермичә тыңлап торды. Коляның горур холкын бик яхшы белә иде, һәм ул:

— Ах, Коля, Коля,— дип кенә пышылдап куйды.

Шулчак ана үзенең уртанчы улын күреп алды. Коля ашыкмыйча гына, ныклы адым белән аларга таба килә. Башын артка ташлаган.

Ана ике кулын да аңа сузды. Коля бер генә минут туктап торды һәм әнисенә ташланды, аны муеныннан кысып кочаклады. Улының кинәт үсеп киткән кебек булуы, җитдиләнүе ананы хәйран калдырды.

— Әнием, гафу ит, яме,— диде Коля, шыпырт кына.— Минем... барыннан да бигрәк, сине борчыйсым килмәгән иде... Шигырьнең мәгънәсен сөйләп бирә алмадым, әнием...

Прасковья Александровна саклык белән генә улының кулын ычкындырды.

— Бер дә кайгырма, улым,— диде ул ягымлы тавыш белән.— Син әле үзеңнең бүтәннәр сүзен генә кабатлаучы попугай түгел икәнеңне, сандугач икәнеңне, үз тавышың, үз көең барлыгын күрсәтерсең. Хәзер, балалар, әйдәгез доктор Бенес янына. Лядской урамда яши ул, бездән ерак түгел...

Табип аларны зурлап каршылады, Александр, Николай һәм Алексей Лобачевскийларның сәламәтлекләре яхшы булу турында өч таныклык бирде.

Шулай итеп, рәсми баскычлардан үткәннән соң, 1802 елның 5 ноябрендә гимназия советы түбәндәге карарны чыгарды:

« ...коллежский регистратор Лобачевский җәмгатенең үтенечен искә алырга, ягъни аның өч улын да гимназиягә кабул итәргә».

Карарны кулына алганнан соң шатлыгыннан яшәреп киткән Прасковья Александровна, шунда ук гимназия конторасына кереп, укытырга дип алдан акчасын түләде һәм урамда аның чыкканын көтеп торган уллары янына ашыкты.

Ана берүк вакытта көлде дә, елады да. Ул малайларның өчесен берьюлы кочаклап алды. Шатланмаска һич мөмкин түгел — аларга яңа тормыш үзенең капкасын ача иде.

## *Икенче бүлек*

### 1

Лобачевскийларның гимназиягә җыенулары озакка сузылмады. Ноябрь аеның салкын иртәсе иде. Капка төпләренә «барабыз» килеп туктады. Әниләре кухняда мәш килә — уллары яраткан таба ашы хәзерли. Ләкин бүген майда чыжлап пешкән тәмле кабартмаларга кызыгучы булмады. Иртә торып юынган, бәйрәмчә киенгән малайлар, тынгысызланып, бүлмә буйлап ишекле-түрле йөренәләр. Күңелләре белән алар инде күптән гимназиядә.

Чәй эчкәч, тиз генә киенеп чыгарга теләгәннәр иде, әниләре ашыкмаска кушты һәм сәфәр алдыннан бераз утырып торырга кирәклеген әйтте.

Бер минут сүзсез утырганнан соң, ниһаять, ана үзенең улларына фатихасын биреп:

— Ходай юлдашыгыз булсын! — диде.

Һәммәсе дә, урыннарыннан торып, иконага карап чукынып алдылар; Прасковья Александровна улларының һәркайсын аерым-аерым кочаклап үпте.

Алар чыкканда, «барабыз» хуҗасы татар агае шактый туңып өлгергән һәм, дилбегәсен тоткан килеш, тире бияләй кигән кулларын бер-берсенә шапшоп суккалый иде.

— Гимназиягә! — диде Прасковья Александровна, «барабыз»га акча сузып. Ул туң чана табаннарының карны шыгырдатып кузгалып китүен, балаларының, тыкрыктан борылып, күздән югалуын карап калды. Җиңелчә генә киенеп чыккан ана җилне дә, салкынны да тоймыйча, юлдан күзен ала алмый болдырда озак басып торды.

Малайлар, бер-берсенә сыенып утырган көе, сөйләшми генә бардылар. Тик чаттан борылгач кына исләренә төште: әниләренә кул болгарга онытканнар ич!

Ләкин бу турыда озак уйланырга аларның вакытлары юк иде: «барабыз» хуҗасы атның дилбегәсен тарткалады, бер-ике мәртәбә чөңгереп алды, һәм алар кызурак бара башладылар...

Гимназияне күргәч, Алеша ирексездән:

— Килеп тә җиттек! — дип куйды.

Саша, абый кеше буларак, эшне кызу тотып:

— Тизрәк төшегез! — диде.

Гимназиянең тышкы ишеге авыр ачыла иде. Саша ул ишекне иңбашы белән этеп ачты, һәм алар өчесе бергә, як-якларына карый-карый, вестибюльгә керделәр. Алеша, абыйларыннан калмас өчен, Коляга ябышты.

Классларда дәрес барганлыктан, вестибюль тынып калган иде.

— Кая барыйк икән? — дип сорап куйды Коля.

— Сабыр итегез, хәзер килерләр,— диде ишек төбендә торучы инвалид солдат, киң таш баскычка ымлап.

— Әнә килә! — диде Алеша пышылдап һәм абыйларының артына яшеренде.

Икенче каттан, баскыч култыксасына тотынып, ашыкмыйча гына чал чәчле офицер — дежур укытучы Василий Петрович Упадышевский төшеп килә иде. Малайлар аның муенына таккан орденын да күреп алдылар. Ул кара перчаткалы сул кулын киң кара тасма белән муенына аскан. Аның кулын беләзек турыннан туп ядрәсе өзеп киткән икән,— бу турыда өч туганга соңыннан иптәш малайлары әйтте.

Упадышевский аларга бик ягымлы карап тора. Ул аларның тәрбиячеләре Шебаршинны яхшы белә һәм аңа хөрмәт саклый иде.

— Лобачевскийлармы? — дип сорады ул карлыкканрак калын тавыш белән.— Сезнең кайсыгыз әзерлек классына керәчәк?

Коля, башын аска иеп, абыйсына һәм энесенә күтәрелеп карарга да оялып, алга чыгып басты.

— Әйдә минем белән,— диде Упадышевский, бик ягымлы итеп.— Син Федор Петрович Красновта укыячаксың. Ә сез бераз сабыр итегез...

«Әзерлек классына... Әзерлек классына...» Баскычтан менгәндә, аяк баскан саен, әлеге сүзне кемдер кычкырып әйтә сыман тоелды Коляга. Ниһаять, ул менеп җитте.

Икенче катта Коля җыелыш залына керергә уйлаган иде дә, тик аны Упадышевский туктатты.

— Юк, безгә башка залга, уң якка — диде ул, каршыдагы ишекне ачып.

Искәрмәстән генә балкып киткән яктылык Коляны берничә секунд күзен йомып торырга мәҗбүр итте. Иртәнге кояш килеп капланган икән тәрәзәгә. Дежур офицерга ияреп, ул диварларының кеше буе җитәрлек җире коңгырт майлы буяуга, ә өске өлеше алсу төскә

буялган зур, иркен залдан узды. Тәрәзә арасындагы стеналарга Ватан тарихын чагылдырган буяулы картиналар эленгән иде. Малайның аргы почмактагы алтын суы йөгертелгән сыннарга алан-йолан каранып баруын күргәч, Упадышевский елмаеп куйды, биредәге тормышны анык белгән кыяфәт белән болай диде:

— Бу залда без гыйбадәт кылабыз, ягъни өй чиркәве була инде безнең бу... Ә менә монда әзерлек классы.

Василий Петрович класс ишеген ачып җибәрде.

— Кер әйдә,— диде ул малайга. Һәм укытучыга мөрәҗәгать итеп аңлатып бирде: — Федор Петрович, менә сезгә яңа укучы, Николай Лобачевский.

Чал чәчле офицер, ишекне акрын гына ябып, кире чыгып китте.

Коля башта югалып калды. Аптырап, тирә-ягына каранды. Биек түшәмле зур бүлмәгә тап-тар өстәлләр куелган. Өстәл араларындагы эскәмияләргә укучылар тезелеп утырган. Түрдә кафедра. Кафедра артында озын буйлы берәү бик тырышып тактага нәрсәдер яза. Упадышевскийның тавышын ишеткәч, ул башын күтәрде. Үткен карашын малайга текәде.

— Килгән икәнсең, утыр! — диде ул бик ямьсез тавыш белән.— Кая барасың?.. Шунда утыр, иң арткы эскәмиягә. Алга утыртырмынмы, юкмы, күз күрер әле.

Мондый күңелсез сүзләрдән соң Коля бөтенләй коелып төште. Ул, курка-курка гына арткы эскәмиягә утырды һәм укытучыга күз салды.

«Безнең Макарьев побына охшаган,— дип уйлап алды малай.— Чәчен үргән, сакалы иске себерке төсле сирәк... борыны да аныкы шикелле, почык борын. Укытучыга бер тамчы да охшамаган».

Шул чакта Краснов кулын күтәрде һәм тузгыган башын кашып алды. Кулын күтәргәндә тар җиңле сюртугының терсәк турысыннан ертылган булуы күренде.

«Ни өчен ул: алга утыртырмынмы, юкмы, дип әйтте икән?» дигән уй килде Коляның башына. Бу гимназиядә ялкау малайларны артка күчереп утырту гадәте барлыгын ул белми иде әле.

Коляны класстагы читтән тыш тынлык гаҗәпләндерде. Укучылар гүя тын да алмыйлар, сихерләнгән кебек, зәңгәр сюртуклы теге кешегә текәлеп карап торалар.

Кинәт кабер тынлыгын укытучының ютәлләве бозды. Ул, кафедраның ике канатына тотынган хәлдә, кызарынып-бүртенеп, күзен мәхәббәтсез әйләндереп, буылып үләргә җитеп ютәлләде. Укучылар авыр сулап куйдылар; укытучы ютәлләүдән туктагач, алар яңадан таш кебек катып калдылар.

Коляның күз алдына ирексездән бер картина килеп басты. Анда Испания циркындагы бер күренеш тасвирланган иде; бер төркем кешеләр, үгез аренага чыккач, аның һөҗүменә каршы торырга хәзерләнеп, катып калганнар.

Ләкин класстагы тынлык озакка бармады. Коля башын уңга борды, сулга борды, иңбашларын селкетеп куйды. Тагын бер минуттан күршесе белән сөйләшәчәк иде. Тик анысы яңа малайга шәфкатьлек күрсәтеп, алдан кисәтеп куюны кирәк тапты. Укытучыга туп-туры караган килеш, ул аягы белән Коляның аягына төртте һәм иренен кыймылдатмыйча диярлек:

— Селкенмә, сорый башлар! — дип куйды.

Менә укытучы урыныннан торды. Алдындагы тәмәке савытыннан ике бармагы белән чеметеп тәмәке алды һәм, аны борынына салгач, беренче рәттәге өстәлләргә күз йөртеп әйләнеп чыкты. Алгы рәттә иң яхшы укучылар утырганга, андагылар арифметикадан биремне дөрес эшләгәннәр иде. Укытучы һәрберсенең эшен алып күздән кичерә һәм дәфтәрен кире өстәлгә ташлый.

Икенче рәттә хәлләр кинәт кенә үзгәрде. Краснов хаталы дәфтәрне өстәлгә ташламый, идәнгә ыргыта һәм дәфтәрнең иясенә иелеп алырга куша. Яки дәфтәр белән гимназистның битенә китереп суга.

Өченче рәткә җиткәч, Краснов бөтенләй котырынды. Класста аның аяк типкәне һәм:

— Ахмак! Тинтәк! Ишәк! Дуңгыз! — дигән тиргәү сүзләре ишетелеп торды.

Ләкин тиргәү генә аз тоелды, күрәсең, Краснов былтырдан күчми калган ике малайны чәчләреннән әләктереп алды һәм бер-берсенә башлары белән китереп бәрде. Мескенкәйләрнең күзләреннән яшьләре атылып чыкты. Кычкырырга яки ыңгырашырга ярамый: укытучы шауламаска куша, сүзен тыңламасалар — тагын да ныграк җенләнә. Җәза алучыларның шундыйлары да була: алар, авыртуга түзеп, хәтта елмаялар, ә укытучы читкә борылгач, өстәл астыннан гына аңа йодрык күрсәтәләр.

Боларны күреп Коля шаккатты. Нижний Новгородтагы халык училищесында мондый явыз укытучылар юк иде.

«Ә эти?! — дип уйлап куйды ул һәм шунда ук үз-үзенә җавап та бирде: — Исерек чагында ул да шундый иде... Ә бу?..»

Җаен туры китереп, Коля күршесенә якынрак килде һәм:

— Ул... исерекме әллә?! — дип сорарга батырчылык итте.

— Әкрен! — диде тегесе, пышылдап.— Синең белән утырсаң, бәлагә тарырсың. Исерсә, ул яман котыра... Ул бит... ой!

Ни күрсеннәр: Краснов болар өстәле янында басып тора иде.

— Сөйләшеп утырасызмы әле! — диде ул, җикеренеп.— Базар ясыйсызмы әле!

Укытучы, Коля аркылы иелеп, аның күршесенең кулын эләктереп алды һәм зәһәрләнеп чеметә башлады.

Колянын бу хәлгә түзәрлеге калмады, ул эскәмиядән сикереп торды да:

— Тимәгез аңа! Хакыгыз юк! — дип кычкырды.

Мондый нәрсәне көтмәгән Краснов, гүя, телсез калды, теге малайның кулын җибәрде. Укучылар исә тын алырга куркып утыралар, кайберләре хәтта куллары белән битләрен каплаган иде.

Ләкин Красновның алай югалып калуы озакка сузылмады. Кинәт ул шартлап ярылырга җитеп кызарды, чигәсендә кан тамырлары бүртеп чыкты.

— Укытучыңны өйрәтәсеңме! Укытучыңны өйрәтәсеңме! — дип акырды ул чәрелдәвек тавыш белән һәм Коляны, якасыннан тотып, почмакка өстерәде.— Тизлән! Укытучыңны өйрәтәсеңме! Ишәк!

Коля үзенең колак төбендә бертуктаусыз яңгыраган чәрелдәвек тавыштан исенә килергә дә өлгермәде, Краснов аны мич янына китереп ташлады һәм кулына кисәү агачы тоттырды. Әтисенең, исерек баш булып та, бу чаклы мәсхәрәләгәне юк иде аны! Бөтен класс алдында кисәү агачы тотып тор әле! «Әллә кисәү агачы белән...»

«Әнигә күңелсезлек китерермен,— дигән уй килде аның башына кинәт кенә.— Түзәргә кирәк...»

Нәкъ шул вакыт кыңгырау тавышы ишетелде. Краснов кафедра өстендә яткан журналын алды һәм,

артына борылып карамыйча, йөгереп чыгып китте. Коля кисәү агачын почмакка ыргытты. Аны төрле яктан укучылар сырып алдылар, һәм, аркасыннан кагакага, мактарга тотындылар.

Коля, йокы арасында ишеткән төсле, берәүнең тавышын ишетте:

— Әйдә дуслашабыз!

Борылып караса, Краснов чеметкән малай икән. Авызы колагына җиткән ул малай Коляны ике иңбашыннан тотып селкеде һәм үзенең тәкъдимен кабатлады:

— Әйдә дуслашабыз! Син шәп егет икәнсең! Звонок булмаса, кисәү агачы белән кундыра идең бит, ә? — дип тә өстәде ул, тавышын әкренәйтеп, як-ягына карангалап.

— Кундыра идем... әнкәй генә искә төште,— дип җавап бирде Коля; күңел серен ачканга аның битенә алсулык йөгерде.

Тәнәфес тәмам булды. Укучылар урыннарына утырырга ашыктылар.

Краснов нидәндер кәефләнеп килеп керде, һәм рус теле дәресе җәнҗалсыз гына узды.

Коля да бераз тынычланган кебек булды, тик беренче дәрестәге җәберләнүен тиз генә онытa алмады, укытучы тарафыннан күрсәтелгән явызлык бала күңеленә гүя таш булып утырды.

«Иртәгә мәсьәләсен чишә алмасам, нәрсә эшләтер икән?» дип уйлады ул ирексездән.

Уйланып утырганга, аның башына граматиканың башлангыч кагыйдәләре дә кермәде. Бәхетенә каршы, Краснов аңарга игътибар итмәде.

Кыңгырау тавышы, ниһаять, икенче дәреснең дә тәмамлануын белдерде.

— Хәзер безне буйга карап тезәчәкләр,— дип хәбәр итте Коляның күршесе Миша.— Икебезне янәшә бастырсалар шәп булыр иде!

— Әйе шул,— диде Коля чын күңелдән.

Малайларның теләге кабул булды: икешәр-икешәр итеп тезгәндә, алар бергә туры килделәр. Ашауэчү бүлмәсендә дежур торучы гимназист «яңа малайга» агач кашык тоттырды да:

— Югалмасын өчен исемеңне язып куй,— диде.— Чыкканда әнә тегендә, стенага эләрсең.

Өйдә пешкән тәмле ашларга күнеккән Лобачевский болганчык суны кабып кына карады. Икенчегә

солы боткасы белән берәр калҗа сыер ите бирделәр. Коля анысын да ашый алмады.

— Ачтан үләсең килмәсә, күнегерсең әле,— диде Миша, кургаш миски төбен тыкырдатып.

Ашау-эчү бүлмәсендә тәртип саклау вазифасы тулы битле, җирән чәчле Сергей Александрович Поповка йөкләтелгән иде. Нindидер фаҗига булып, борыны яньчелгән бу тәрбиячедән гимназистлар курыкмыйлар. Аның алдында ук малайлар Коляның батырлыгын кабат телгә алып сөйләделәр, Красновны яманладылар. Коля ул Красновның гимназиядә иң надан укытучы булуын, һәрвакыт исереп йөрүен, директорга һәм инспекторга тәлинкә тотуын, шуның аркасында гына гимназиядән куылмый торуын белде.

— Җитмәсә, үзе безнең гимназияне бетергән, Преображенский полкта хезмәт иткән,— диделәр малайлар.— Аңа гимназиядә укытырга түгел, ә каторгада юлбасарлар надзирателе буласы калган...

Малайлар шау-гөр килә. Өлкән класстагылар гына беркадәр читтә, дәрәҗәләрен саклап, акыллы сүз сөйләшә иделәр.

Ашаганнан соң, малайларны парлап тезеп, түбән класска рәсем дәресенә алып киттеләр. Коля анда, абыйсы белән энесеннән качып, бер почмакка барып утырды.

Тегеләр исә мондый хәлне күргәч поплындылар, читтән генә Коляны күзәттеләр.

Рәсем дәресен алып баручы яшь, матур укытучы Федор Иванович Чикиев Красновка бөтенләй охшамаган иде. Атаклы Петербург художество академиясендә тәрбия алган укытучы буларак, ул рәсем сәнгатен бик ярата һәм гимназистлар белән үзен әдәпле тота иде. Ләкин Коля аңа да башта шикләнеп карады. Аның рәсемгә өйрәтү ысулы малайга сәер тоелды. Нижнийда Коля китаптан сурәт күчереп ясарга, хәтта йорт хайваннарын рәсемгә төшерергә ярата иде. Ә монда Федор Иванович фәкать сызыклар сыздыра, дәфтәрне борырга, җайлап куярга рөхсәт бирми.

— Башыңны туры тот, телеңне чыгарма, ялгыш тешләп өзәрсең,— диде укытучы Коляга, ягымлы итеп.

Коля кызарынды, ишетмиләрме икән дип, туганнары ягына күз ташлады. Ләкин бу ягымлы укытучыга үпкәләргә яки рәнҗергә мөмкин түгел иде. Дәрес

беткәнче, бу укытучы Коляның мәхәббәтен тәмам яулап өлгерде.

Звонок булгач, Коля тизрәк иптәшләре янына китәргә ашыкты. Ләкин шул вакыт ишектә Упадышевскийның мәһабәт гәүдәсе күренде.

— Лобачевскийлар, өчегез дә минем янга килегез,— диде ул карлыккан калын тавыш белән.— Аста сезне әниегез көтеп тора.

Прасковья Александровна залда, урындык аркасына тотынган хәлдә, тәрәзә янында басып тора: башындагы борчулы уйлар аңа тынгы бирми иде.

— Менә минем улларым! Гимназистларым! Йә, ничек, ошадымы сезгә гимназия? — диде ана һәм, улларына каршы килеп, өчесен бергә кочаклап алды.

— Ошады, әнкәй! — диделәр Саша белән Алеша икесе бертавыштан. Аларның йөзләрендә шатлык иде.

— Ошамаска! — дип сүзгә катнашты Упадышевский.— Безнең гимназиягә белем алырга Россиянең төрле почмакларыннан киләләр: Астраханьнан, Тоболдан, Бохарадан, Тифлистән, хәтта Петербургтан. Ат йөри алмаган җирне дөяләр белән кичәләр.

Упадышевскийның сөйләвен сокланып тыңлап торган Алеша:

— Без атка утырып килдек... тарантаска,— диде.

Ана уртанчы улы өчен борчылды: Коля елмаймый да, көлми дә, аска карап тик тора. Прасковья Александровна аның колагына иелеп:

— Кайгырма, Колюшка, бар да җайланыр,— дип пышылдады.

Коля, үзен көчкә мәҗбүр итеп, әнисенә күтәрелеп карады. Әнкәсе бит аның хәзерлек классында укып йөрүне үзе өчен хурлык санавын гына белә. Бүген беренче дәрестә булган җәнҗалны белми. Әгәр аңа иртәгә дә шундый ук хәлне кичерергә туры килсә?.. Юк, әнкәсе болай да михнәт чигә. Белмәсен әле...

Коля әнисенә елмаеп карады. Әнисенең йөзе ачылып китүен күргәч:

— Әйе, әнкәй, җайланыр әле,— дип куйды.

Упадышевский, анага хөрмәт күрсәтеп, ишеккә чаклы озатты һәм аннан соң:

— Хәзер өчегез дә конторага чабыгыз, анда буйларыгызны үлчәп, гимназист формасы тегәчәкләр,— диде.

Беренче көн тәмамланып килә иде. Малайларны йокы бүлмәләренә алып кереп, урыннарын күрсәттә-

лор: Саша белән Алешага урам яктагы бүлмә, Коляга исә ишек алдына караганы туры килде.

Кичке сәгать алтыда яңадан кыңгырау шалтырады. Гимназистлар, иртәгә булачак дәресләрне кабатлау өчен, иртәннән җыештырылмаган классларга кереп тулдылар һәм «хәзерләнә» башладылар. Гадәттә һәркем кычкырып укыганга, тавышка түзеп торырлык түгел иде. Тәрбияче исә тәртип урнаштырырга уйламады да. Шкафтан китап алып укырга утырды.

Иптәшләреннән күреп, Коля да колагын томалап карады. Ләкин тавыш аның башына капты. Бу шау-шу аңа Мәкәрҗә ярминкәсен хәтерләтте. Ул дәресләрен хәзерләргә керешкәнче, звонок та булды.

Кичке аштан соң гимназистларның һәммәсен дә залга кертеп тутырдылар. Йокы алдыннан, ашны тизрәк сеңдерү максаты белән, алар бераз селкенеп алырга тиеш иделәр. Стройда йөреп туйган балалар, аеруча башлангыч һәм түбән класстагылар, зал буенча шап-шоп йөгерүдән бертөрле ләззәт таба иделәр. Колның исә йөгергәндә дә башыннан «дәресләрем хәзерләнмәгән, иртәгә нәрсә булып бетәр?» дигән уй китмәде.

Йоклар вакыт җитте. Бүлмә надзирательләре, күзләрен чекрәйтеп, гимназистларның чишенүләрен күзәтеп тордылар. Мунчала тутырылган каты матрацлардан кибәк исе килә. Солдат одеялы тәнне кычыттыра.

— Базар ясамагыз! Йоклагыз! — дип боерык бирде шар күзле надзиратель һәм, бүлмәдәге берләнбер шәмне алып, шак-шок басып чыгып китте. Шунысы сәер иде: ишекне ябуга, аның адымнары шунда ук тынды.

Коля, моңа гаҗәпләнеп, Мишадан:

— Нәрсә, аяк очларына гына басып киттемени? — дип сорады.

Миша, көлеп җибәрмәс өчен, авызын кулы белән каплады.

— Тот капчыгың — китәр! Хәзер ул бер сәгать буена ишек төбендә тыңлап торачак, сөйләшкән, көлгән малайларны язып алачак. Иртәгә җәза бирдерәчәк.

«Иртәгә» дигән шомлы сүз Коляны тирән уйга алып кереп китте, ишекне колагын куеп тыңлап торган надзирательнең дөньяда барлыгын да онытырды. Нижнийда вакытта аларның йокы бүлмәләренә бик матур ай карый иде. Ә монда пәрдәсез, шәп-шәрә тәрәзәдән ямьсез ай карый. Анысы да Красновка ох-

шаган. Ишек артында тыңлап торган надзиратель кебек үк, ничектер, яшеренеп карый...

Коляның иптәшләре берәм-берәм йоклап киттеләр. Кайсылары гырлап йоклый, икенчеләре, көндез кичергән михнәтләрне төштә күреп булса кирәк, кычкырып җибәргәли. Кемдер төш күреп ыңгырашты, елады...

Коля моңа түзеп ята алмады, колагын томалады, бераздан башын бөтенләй мендәр астына тыкты. Һәм ул шулай, күзләре яшьле килеш, йоклап китте.

Төшендә ул Нижний Новгородны, таныш урамны күрде. Тирән чокырларга төшеп, текә ярлардан үрмәләве нинди күңелле! Сугыш уены уйнарга теләсәләр — әйләнә-тирәдә әрәмәлек. Камыш баскан Черек күл дә, Почайна инеше дә ерак түгел. Ул инеш кечкенә булса да, балыкның зурлары эләгә. Бервакыт шулай гаҗәеп эре чуртан тотып базарга китергәннәр иде, ерткычныкы төсле сары күзен, авызы тулы тешләрен күреп бөтен кешенең исе китте. Ә малайлар бу турыда атна буе сөйләп йөрделәр...

Коля, төшләнеп, елмаеп куйды, таш кебек мендәрен читкә этәрде.

...Менә алар шаулашып агач башларына, өй түбәләренә менеп йөриләр, җәяләрдән ук аталар, очырткыч җибәрәләр. Очырткычны алар дәү итеп ясыйлар, шалтыравыклар куялар, кызыл мунчаладан койрык тагалар.

— Әйдәгез, урамнан җибәрмик, ә Кикрик тавыннан җибәрик! — ди Саша, очырткычны ясап бетергәч.

Малайлар бу фикерне чыр-чу килеп каршы алалар:

— Кикриктән җибәрегез!

— Кикриктән очырабыз!..— диләр.

Алар һәммәсе бергә Лыков күперенә йөгерәләр. Ул Кикрик дигәннәре Ока калкулыкларының түбәсе. Ләкин дәү очырткыч күтәреп тауга менүе җиңел эш түгел иде: очырткыч тартыла, ычкынырга тели, шалтыравыклары колакны тондырып бетерә. Тау башына менеп җиткәч, ул хәтта бер малайны өстерәп алып китә язды, икенче бер малай бауның очын зур ташка бәйләп өлгермәсә, һичшиксез, алып китә иде.

Нинди шатлык, ничаклы горурлык китерде малайларга бу очырткыч! Җилдә тартыла, һавага омтыла, бөтен шәһәр халкын сокландыра кебек. Кешеләр:

— Шундый матур очырткычны текә тау башына алып менәргә кемнең башы җиткән икән! — дип әйтә-

ләрдер төсле. Очырткыч бик еракка очып китә. Малайлар таудан төшәләр, салкынча суга чумалар, йөзәләр, бер-берсен куалар, бер-берсенә су чәчрәтәләр.

Аннан соң учак ягып җибәрәләр, көлгә күмеп бәрәңге пешерәләр. Кичен арып-талып өйләренә кайталар.

Кулына газета тоткан Сергей Степанович кабинетыннан аларга каршы чыга.

— Күңелле булдымы? — дип сорый ул, ягымлы елмаеп.

Кинәт... Коля, бүлмәдәге башка малайлар кебек үк, ыңгыраша башлый, чөнки сөекле Сергей Степанович юкка чыккан һәм аның урынында кулына кисәү агачы күтәргән Краснов мәсхәрәле елмаеп басып тора икән...

Малай куркып уянды һәм торып утырды.

Камера тынып калган, хәтта юыну бүлмәсендә буш ләгәнгә сирәк кенә тамчы тамганы ишетелә.

Ай икенче урынга күчеп өлгергән инде, әмма аңа карап кына яктысы кимемәгән.

Авыраеп киткән башын Коля яңадан таш кебек каты мендәргә салды. Хәзер инде аны йокы алмый. Бик яхшы, алмасын әйдә, төшенә Краснов кереп интектереп кенә бетерер.

Коля тагын хыялга бирелде, ул туган шәһәрен исенә төшерә, өен сагына иде.

Зур булып үсеп киткән бакча эчендә аларның кечкенә өйләре күренми дә. Ләкин өйнең куе бакча уртасында булуы бик әйбәт. Әйләнә-тирәдә кошлар сайраша... Карлыган куагы янында сыерчык яши. Карт усак куышында песнәк бала чыгарды... Урам якта гаҗәеп зур тополь агачы үсеп утыра. Саша әйтә: ул тополь күкне терәп тора, ул булмаса күк гөмбәзе өстебезгә җимерелеп төшәр иде, ди. Абыйсы сөйләгән шул әкияткә ышана Коля һәм тополь башына менеп күкне күрергә тели. Кызык ич. Тик менә әнисенә сүз биреп кенә ялгыш итте. Сүз биргәч, тотмыйча ярамый шул. Менә ни сәбәпле Коля күкне күрмичә яшәргә мәҗбүр булды...

Коляның уена төрле нәрсәләр килде.

Кышкы кичләрдә аларның өенә, әнисе янына бөтен урам халкы җыела. Берданбер укый-яза белгән кеше булганга, аның «Изгеләр тормышы» дигән китабы бар. Күрше хатыннары, кулларына эш алып, бакыр шәмдәлле ут тирәли тезелешеп утыралар, ә Коляның

әнисе аларга кычкырып укый. Ул китаптагы изгеләрне һәрвакыт газаплыйлар, ә алар шуңа түзеп торалар. Кайбер вакыт фәрештәләр килеп юата үзләрен... Күрше түтиләрнең ай-ваен ишетеп, бервакытны Коля шулай:

— Ә ни өчен фәрештә ул залимны куып кына җибәрми? — дип сорап куйды.— Ул чагында изгеләрне юатып торасы булмас иде...

Хатыннар аңа юньләп аңлатып бирә алмадылар, ачуланып, тиргәп, бүлмәдән куып чыгардылар. Шуннан соң Коля аларның сүзенә катнашмады. Сөйләшкәндә дә бер кешенең явызлыгы, икенче кешенең фәкыйрьлеге турында сөйләшәләр икән,— моның ни кызыгы бар?

Ә менә аларның шәһәрләре — Нижний Новгородның ничек барлыкка килүе турындагы һәм башка нәрсәләргә бәйләнешле борынгы риваятьләрне Коля бик яратып тыңлый иде. Аларны күркәм кыяфәтле карчык сөйли. Ул карчыкның көйләп сөйләвен дә, шулай ук орчыгының җуылдавын да яхшы хәтерли малай.

— Нәрсәдән икән ул, ә? — дип кычкырып әйтеп куйды Коля, үзе дә сизмәстән.

— Нигә йокламыйсың? — дип пышылдаганны ишетеп, Коля сискәнеп китте.

Әмма шул чак ул күрше кроватьта яткан Мишаның да калкуын күреп алды.

— Үзебезнең Нижнийны хәтерләп ятам әле,— диде Коля әкрен тавыш белән һәм ишек ягына куркып карап куйды.— сөйлимме, тыңлыйсыңмы?

— Сөйлә! — диде Миша, пышылдап кына.

Ул кроватеннан сикереп төште, одеялын купертеп куйды. Башыннан ябынып йоклаган икән дип уйларга мөмкин иде.

— Күрдеңме? — диде ул һәм, көлеп җибәрмәс өчен, авызын учы белән каплады.— Надзиратель керсә, мине йоклый дип уйлар.

Миша күз ачып йомганчы дусты янына килеп ятты.

— Җелегемә үтте салкын. Икәү булгач җылынабыз инде хәзер. Сөйлә, әйдә. Пышылдап кына сөйлә тик.

Бераз вакыт Коля, фикерен җыеп, дәшми ятты. Аннан, теге карчык төсле, көйләп сөйли башлады:

— Почайна инеше башланган төштә чиксез зур бер таш ята, ди. Ул ташны анда кем китереп куйга-

ның бирәү дә белми. Ташка язган борынгы сүзләр дә шомарып беткән. Ә шулай да риваяте онытылмаган, телдән телгә йөри, ди. Әнә шул серле таш һәммә кешенең котын алып тора.

— Нигә котлары алына соң ул таштан? — дип сорап куйды Миша, түземсезлек күрсәтеп.

— Син сорауларың белән мине бүлдермә. Борынгылар турында сөйләгәндә тавышланмыйлар, белдеңме шуны? — дип аңлатты Коля үз тавышы белән һәм шуннан соң, баягыча ук көйли төшеп, сөйләп китте: — Көннәрдән беркөнне ул ташның астыннан су бәреп чыгачак та, безнең шәһәрне су басачак икән. Нижний Новгород бит тау башына урнашкан; аны күмәрлек булгач бик зур ташкын инде ул.

Булачак фаҗигане зурлыгына малайлар хәйран калдылар.

— Коля, әгәр дә... ул ташны синең белән икәү эзләп тапсак? — диде Миша.

— Тапкан белән генә эш бетми ич әле! — диде Коля һәм тагын кроватена торып утырды.

— Ул ташта язганча булып чыкмасын өчен, нәрсәдер эшләр идек...

Миша да аның белән янәшә торып утырды. Караңгыда аларның күзләре генә ялтырый. Хыялга бирелеп, туңуларын да сизмиләр. Нәкъ шул минутта ишек сизелер-сизелмәс кенә шыгырдап куйды.

— Надзиратель! — диде Миша пышылдап һәм одеял астына чумды.

Озын чандыр гәүдәле надзиратель, бер кулы белән шәмен ышыклап, сагаеп кына кроватьлар арасыннан үтте. Шәм яктысында аның кылыч борыны, шардай күзләре генә күренә иде. Бәйләнерлек әйбер тапмагач, ул ишеккә табан атлады һәм, кергәндәге кебек үк, мыштым гына чыгып та китте.

— Котылдык! Сизмәде! — диде Коля, пышылдап.

— Синең одеял астында тәмам җылынып җиткән идем... Тик, йоклауны да онытып бетермик әле. Ә таш турында уйларбыз, яме? — дип өстәде Миша һәм, үз урынына күчеп, башыннан ук одеялга төренде.

Ә Коля тиз генә йоклап китә алмады. Бер ягыннан икенче ягына әйләнде.

Тышта көчле җил исә һәм малайның күңелен шомландыра иде. Пәрдәсез тәрәзәдән инде таң яктысы керде. Коля йоклап китәргә өлгермәде, колакны тон-

дырып кыңгырау шалтырады. Сәгать алты булган икән!..

Аны ишетүгә дежурный малай, өстенә һәм аягына киенеп тә тормыйча, гимназистларны уята башлады.

— Торыгыз! Торыгыз! — дип, һәркемнең өстеннән одеялын йолкып атты ул.

Кайбер малайлар одеялларының бер читен эләктереп, үзләренә таба тарталар, тагын бер генә минут булса да йоклап алырга телиләр; ләкин дежурный сүзендә нык тора, одеяны икенче башыннан тарта иде.

— Сиңа берни түгел,— ди ул еламсыраган тавыш белән.— Йоклап калсаң, сине шелтәләмиләр, мине шелтәлиләр.

Коляның да одеялы, аякланган кебек, каядыр китеп барды. Малай урыныннан сикереп торып, куркынып, як-ягына каранды. Бүлмә кысан иде. Тар гына тугыз кровать, һәркемгә кечкенә генә аерым өстәл. Бүлмә биек булуга карамастан, һавасы авыр. Таш плиталар белән түшәлгән боз кебек салкын идән аякларны куырып ала.

Хәзер инде Коля шуны хәтерләде: торыр вакыт җиткәч әнисе аның кроватена килеп утыра, йомшак кулы белән башыннан сыйпый һәм: «Колюшкам, кабартма суына, тор», ди торган иде. Ә монда... Кемдер шул чак:

— Надзиратель! — дип кычкырып җибәрде.

— Тизрәк бул,— диде Миша.— Бәлагә эләгерсең.

Гимназистлар киемнәрен капшанып эзлиләр, чөнки иртән шәм бирелми, ә тәрәзә пыяласы аркылы таң яктысы бик аз төшә.

— Икешәрләп тезелергә! — дип, дежурный чәрелдәвек тавыш белән команда бирде һәм куркынган карашын керүче надзирательгә төбәде.

Малайлар тезелделәр. Бераз җылынып алу максаты белән, надзиратель күрмәгәндә, төрткәләштеләр дә...

— Алып бар! — диде надзиратель, кулын селкеп.

Малайлар дежурный артыннан юыну бүлмәсенә атладылар. Анда барып җитү белән көрәш китте, чөнки юынгычлар икәү генә, сабын кисәге бер булып — һәркем тизрәк юынырга тели иде.

Озын буйлы, киң җилкәле бер гимназист Миша Рыбушкинны этеп җибәрде.

— Читкәрәк кит, Смолиннан соң мин юынам,— диде ул.

— Ни өчен син? — диде Миша, кызып китеп.— Смолин, бирмә, шуңа сабынны!..

— Син — син бит, ә мин — мин! — диде озын малай, шаркылдап көлә-көлә.

— Кара, нинди белдекле булган! — диде Коля моңа каршы һәм, йодрыгын йомарлап, дусты белән янәшә басты.

Смолин да нәкъ теге озын малай кебек оятсыз җан булып чыкты. Ул, башкалар турында уйламыйча, тирә-якка су чәчрәтеп юына бирде. Юынып беткәч, сабын кисәген югары күтәрде:

— Кемгә бирәм? Смолинны кем сыйлар?!

Сигез яшьтәгеләр белән бер класста сакаллы сабыйлар да укыганга, малайлар арасындагы бәхәсне һәрвакыт диярлек көч хәл итә иде. Ләкин бүген мондый гаделсезлеккә озак түзеп тормадылар. Кемдер:

— Сабынны бир! Юкса надзирательгә әйтәбез! — дип кычкырды.

Смолинның ачуы килде:

— Кесәгез тулы кучтәнәч, миңа бирергә кызганасыз... Туктагыз әле, мин сезне! — дип янады ул, һәм, кечкенәләр арасыннан үзенә корбан табуына сөенеп: — Әй, Панкратов Гаврило! Мә сабынны! — диде.

Зур башлы ямьсез генә бер малай кыюсыз гына атлап аның янына килде.

— Ал, ал,— диде Смолин.— Кичә сиңа әниең кабартма китерде. Миңа да бирерсең...

Панкратов нәрсәдер әйтергә теләгән иде, ләкин дәшмәде; кызарып, кулын гына селтәде. Сатулашу әле дәвам иткән булыр иде, надзиратель кереп туктатты. Ул кергәч, сабын кулдан кулга тиз йөри башлады.

Малайлар, икешәрләп тезелеп, ашау-эчү бүлмәсенә киттеләр. Өстәл өсләрендә пар бөркеп кайнаган сөт һәм бер кисәк бодай ипие тора. Ләкин, ашарга тотынганчы, дога укыганны тыңларга кирәк иде әле.

«Һәркемнең күзе, ходаем, сиңа юнәлгән, ошбу сәгатьтә син аларга ризык иңдерәсең...» дип, дежурный кычкырып укый һәм, алдындагы кружкага күз салып, авыз суларын йотып куя.

Дога тыңлаганнан соң, эскәмияләргә тезелеп утырдылар. Бәрәүләре кесәләреннән тәмле-тәмле ризыклар чыгарып ашый башлады. Төрле яктан тавышлар ишетелде:

— Княжевич, бер клиндер төртсәң, мин сиңа мәсьәләңне чишеп бирәм.

— Сенька, мин сине сыйладыммы — сыйладым. Хәзер синең чират.

— Әйдә, сөтне ипигә алмашабыз!

Смолин теләнми, надзирательнең башы аска иелеп, күзе йомыла башлаганны күтеп утыра, аннан соң кулын Панкратов ягына сузып, зур осталык белән аның алдындагы кызарып пешкән кабартманы ала да авызына дыңгычлап тутыра.

Коля сикереп тормакчы булган иде, Миша аны тотып калды.

— Алдыңа кара,— диде ул, кырыс кына.— Бәйләнмә шуның белән!

Вакыт беткәнне белдереп звонок шалтырагач, малайлар урыннарыннан сикереп тордылар һәм өерелеп ишеккә ташландылар: һәркем үз классына ашыкты.

Шаулаша, кычкырыша башладылар. Бер малай, иптәшләрен көлдерү максаты белән, икенче малайның җилкәсенә менеп атланды.

Шул вакыт баскычтан төшеп килгән надзиратель, моны күреп:

— Маймылланасызмы?! — дип кычкырды һәм көтмәгәндә теге малайны җитез генә «атыннан» өстерәп төшерде. Баскыч астындагы чолан ишеген ачып, малайны шунда төртеп кертте дә чолан ишеген бикләп куйды.

Коля бу хәлне башта аңлый алмый торды. Гимназиядә аның икенче көне дә әллә ничек, көтелмәгәнчәрәк башланып китте шикелле...

— Нинди чолан соң ул, белмисеңме? — дип Мишадан сорады ул.

— Караңгы урын,— дип аңлатып бирде Рыбушкин тыныч кына.— Гимназиядә тагын карцер да бар. Зур гаеп эшләгәннәрне шунда ябалар. Сиңа да эләгер әле.

— Эләктереп кенә карасыннар! — Коля тагын йодрыгын төйнәде.

— Син куркаклардан түгел ахрысы? Әләкче дә түгелсең. Артык бәйләнмәсләр бәлки... Тик шулай да кыен ашыйсыбыз күптер әле. Түзәргә калган баш — түзәрбез. Син артык кызма.

Коляның гимназиягә килгәненә әле күпме генә, шулай булуга карамастан, күпне күрергә өлгерде.

Ләкин иң авыры алда булачагын ул белми, сизми иде.

Гимназистларны классларына куып керткәннән соң, надзиратель үзенең бурычы беткән дип санады һәм китеп барды. Ә Краснов дәрескә ул көнне соңлабрак керде.

Күзәтүчесез калган гимназистлар йөгерешә, шаулаша башладылар. Бер малай кәгазь чәйнәп, аны Княжевичның борынына тигезде. Анысы озак уйлап тормады, аспид тактасын алып тондырды. Такта теге малайга эләкмичә, тәрәзә пыяласына тиде.

Чыңлап пыяла ватылганны ишетеп, сторож йөгереп килеп керде.

— Кайсыгызның һөнәре? — диде ул усал гына.— Ваткан кеше монда чыксын!

Малайларның котлары алынды, алар авызларына су капкан шикелле утырдылар.

— Менә мин сезне инспектор әфәндегә әйтим әле! — диде сторож каты тавыш белән һәм, ишекне шап итеп ябып, аксый-туксый коридор буйлап китеп барды.

— Княжевич, дөресен әйтеп бир,— диде Рыбушкин әкрен генә.— Әтиең губерна прокуроры, сиңа бер этлек тә эшли алмаячаклар, безгә...

Миша сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, бусагада инспектор Яковкин күренде. Зәһәре йөзенә иңгән. Куркып калган малайларны берәм-берәм, мәсхәрәле карашы белән үтәли тишәргә җитеп, ашыкмый гына карап чыкты.

— Афәрин, афәрин,— диде ул, мыскыллы елмаеп.— Гимназия өчен сезнең әдәпле, итагатьле булуыгыздан да куанычлы нәрсә юк.

Таш кебек катып калган малайлар өстеннән тагын бер мәртәбә күз йөртеп чыкканнан соң, Яковкин Коляның агарынып калган йөзенә текәлде һәм татлы тел белән аңа мөрәҗәгать итте:

— Йә, Лобачевский, казна тәрәзәсенә кул күтәрүчене кем икәнен әйтеп бир әле?!

Коляның чыраена кызыллык йөгерде. Ул инспекторның мәкерле йөзеннән күзен алмыйча, җирәнгән шикелле иңбашын җыерып куйды. Һәм бу хәл Яковкинны чыгырыннан чыгарды.

— Нәрсә син башыңны җүләргә саласың! — дип чәрелдәде инспектор, аяк тибеп.— Экзамен тапшырганда попугай булып кыландың, инде биредә тинтәк

малай ролен башкарасыңмы? Күрмәвеңә, белмәвеңә барыбер ышанмыйм!..

Инспектор тын алу өчен туктарга өлгермәде, Коля әйтеп салды:

— Беләм шул. Тәрәзәне мин ваттым, инспектор әфәнде!

Гаҗәпләнүдән һәммәсе сүзсез калды. Ә бер минуттан инспекторның ярсып җикергән тавышына килгән сторож Коляны коридорның аргы башына сөйрәп алып китте.

— Карцерга ябыгыз! Ипи белән судан башка һичнәрсә бирмәгез! Гимназия советы аны нишләтергә икәнен хәл кылачак! — дип буыла-буыла кычкырды Яковкин һәм тиз-тиз атлап икенче якка китеп барды.

Сторож Коляны карцерга төртеп кертте һәм ишекне шапылдатып ябып бикләп алды.

Коля берничә минут хәрәкәтсез торды. Ләкин, аяк тавышлары ерагайган саен, ул аңына килә барды. Һәм, ишеккә ташланып, бөтен көченә дөбердәтә башлады.

— Җибәрегез! Бер көн тормыйм мин сездә! Качып китәм!.. Җибәрегез!..— дип кычкыра-кычкыра, аның тавышы бетте. Ишеккә бәрә-бәрә кулы канады.

Ләкин килүче-китүче булмады.

Малайның башы әйләнеп китте, һәм ул, аркасы белән шакшы стенага терәлгән килеш, идәнгә шуып төште.

Бүлмә кысан һәм караңгы иде. Тәрәзә юк. Түшәмгә пыяла куеп эшләнгән трубадан тонык кына яктылык төшә. Почмакларда пәрәвезләр... Малайга куркыныч булып китте.

Башындагы чуалчык фикерен җыеп, Коля эшнең ничек булганын хәтеренә төшерде. «Ахмак димә инде син! Нинди шатланып, канатланып Казанга кил-кил дә... Әниең акча туздырып шәһәрдән шәһәргә йөртсен, гимназиягә кабул итегезче дип, Яковкиннарга ялынып йөрсен дә... Краснов, аннары Яковкин бар шул монда... Шул әйтте ич әле: попугай булып кыланасың, дип. Юк, барыбер түзә алмыйм! Китәм! Качам!..»

Коля бераз кыймылдап куйды. Ятса, ихтимал, болай әйләнмәс иде. Ул идәнгә ауды. Уйлары, аны үз кочагына алып, әллә кайларга алып китте.

...Көз. Агачларны, ишегалдын, урамны йомшак мамык кар каплаган иде.

— Саша, кар ни өчен ява? — диде Коля.

— Салкын булган өчен. Мин укып утырам, башка комачаулама.

Коляны бу җавап тулысынча канәгатьләндермәде, әлбәттә.

— Ә салкын ни өчен була? — дип бәйләнде ул абыйсына.

Саша китабыннан башын күтәрде.

— Салкынны җил алып килә... Бар, энидән сора, күреп торасың, минем...— Абыйсы, аңа арты белән борылып, укуын дәвам итте.

Коля кухняга күз салды, ләкин анда әнисе таба ашы пешереп мәшәкатьләнә иде. Малай көрсенеп куйды һәм, өстенә-башына киеп, Сергей Степанович янына кереп чыгарга булды.

Күн белән тышланган иске диванга аягын бөгәрләп менеп утыргач, Коляга бик рәхәт булып китте.

— Сережа абый, кар ни өчен ява? — дип сүз башлады ул.

Сергей Степанович, сызым сызудан туктап, башын күтәрде:

— Ә белмәсәм?! — диде карт, трубкасын алырга сузылып.

— Сез белмәгән нәрсә юк ул,— диде малай бер дә икеләнмичә.— Дөресен сөйләмәсәгез, язык булыр.

— Әйе,— диде Сергей Степанович, уйланып, Коляның күзенә карап,— синең кебек егетне алдау гөнаһ, әлбәттә. Сөйләми дә булмас. Иртән болын өстеннән томан күтәрелгәнен күргәнең бармы синең?

— Бар,— диде Коля.

— Ә ул томан югары күтәрелеп, салкын һава белән очрашкач, нәрсә барлыкка килә?

— Болыт барлыкка килә,— диде малай, әйтеп калырга ашыгып.

— Әйе, әйе. Болытка әверелгән пар суынып, тамчылар хасил була. Һава бик салкын чагында ул тамчылар...

— Карга әйләнә! Карга әйләнә! — диде малай, кулын чәбәкләп.— Әйттем ич бөтен нәрсәне беләсез дип.

— Юк, юк! Син үзең ул һәммәсен беләсең, менә миңа, карт кешегә, аңлатып бирдең,— диде Сергей Степанович көлеп.— Аңламаган берәр нәрсә килеп чыкса, синнән сорарга туры килә, болай булгач.

Ишек шакыдылар. Коляның әнисе икән.

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны,— диде әни-

се.— Сережа абыеңны тузга язмаган сораулар белән алҗытып бетерәсең инде.

— Син нәрсә сөйлисең, Парашенька,— диде Сергей Степанович ягымлы тавыш белән.— Егетне һич тиргәргә ярамый. Ул аяк өсте йоклап йөри торганнардан түгел. Һәммә нәрсәне күрә, кызыксына, төпченә, белмичә туктамый. Һәр кешедә дә була торган сыйфат түгел ул, әйбәт сыйфат...

Карцер идәнендә яткан малайның ирене дерелдәп куйды, мәгәр йөзе елмая иде. Әнә шулай күңелле истәлекләргә бирелеп, ул шалтыр-шолтыр килеп йозак ачылганны һәм үзенең иңбашына кемнеңдер сакланып кагылганын да тоймады.

— Аянычлы хәл килеп чыкты шул,— диде сторож, артындагы надзирательгә таба карап. Ул аңардан нинди дә булса җылы, йомшак сүз көтте.

— Синең эш түгел анысын тикшерү! — Надзиратель малайны, иңбашыннан тотып, бик нык селекте:

— Торыгыз, Лобачевский! Тәрәзәне Княжевич ватканын әйтәсегез калган. Класска керегез.

Сторож, бераз читкә атлап, надзирательнең тупаслыгына шаккатып карап торды.

— Бу чаклы миһербансызлык булыр икән! — дип сөйләнде ул үзалдына.

Коля исенә килде. Йөзеннән елмаю качты. Үзсүзләнеп иренен кысып йомды. Яткан җиреннән сикереп торып, артка чигенде, надзирательнең күзенә текәлде.

— Нәрсә әйткәнне ишеттегезме? — дип кабат эндәште надзиратель, тавышын күтәреп.— Яңадан класска керергә рөхсәт иттеләр. Шулчаклы кире булмасагыз, бу бүлмәгә эләкмәс идегез.

Коля, тәмам аңына килеп җиткәнче, баскан урыныннан кузгалмады. Аннан соң, хурланудан башын да күтәрмичә, коридорга чыкты. Надзиратель аның артыннан ачулы тавыш белән:

— Башта юыныгыз, класска адәм рәтле кыяфәт белән керегез! — дип сөйләнеп калды...

Коля үзен карцерга япканнан соң класста нәрсәләр булганын белми иде. Ә класста мондый хәл булды: малайларның бик нык ачулары чыкты, алар Княжевичны инспекторга барып дөресен сөйләргә мәҗбүр иттеләр.

Инспектор Лобачевскийны чыгарырга теләмәсә дә, моны эшләргә тиеш булды. Аның ачуын бүтәннәрдән

кайтарды. Каршында басып торган инвалид сторожның өстенә төкереген чәчә-чәчә:

— Тинтәк! Күсәк! — дип чәрелдәде.— Ни өчен мине борчыдың? Надзирательгә әйтсәң, ярамаганмыни? Хәзер үк эзләп тап, чыгарыгыз шул тискәре Лобачевскийны карцердан! Тиз йөре! Күсәк!..

Коляны чыгару тәнәфес вакытына туры килде. Гимназистлар коридорга атылып чыктылар һәм, аны күреп, төрле яктан уратып алдылар. Гимназиягә әле башы керсә аягы керен җитмәгән бу яңа малайның игътибар үзәгендә артык еш булуына берәүләр гаҗәпләнде, икенчеләр көнләшеп карадылар. Княжевич, нәрсә эшләргә белмичә, бер почмакта басып тора. Аның ягына әйләнеп караган кеше юк.

Немец теле дәресе башланды. Класска Әхмәтев фамилияле яңа укытучы керде һәм тавыш тынганны көтә башлады. Сакал-мыегын кырган, бик пөхтә киенгән укытучыга, аның көязлегенә сокланып, балалар тынып калдылар. Әхмәтев алар белән немецча исәнләште — «г» авазын ул үзенчә, матур итеп әйтә иде.

Башкаларга ияреп, Коля да китабын ачып куйды. Ләкин кичерешләреннән арына алмыйча, берни аңламыйча газапланып утырды. Нижнийда ук өйрәнгән готик алфавитының бормалы хәрефләре күз алдында бии башладылар... Күзе китапка текәлгән, ә башы иелгәннән-иелә бара...

— Лобачевский, сез төш күреп утырасыз түгелме? Әллә немец теле калып торса да ярар дисезме?

Укытучының эндәшкәнен ишетеп, Коля кинәт сискәнеп куйды, дәреслеге идәнгә төште.

— Мин... юк... мин...— дип сөйләнде ул һәм китабын алырга иелде.

Укытучы тәрәзә вакыйгасын ишеткән иде. Ул Коляга шелтә ясамыйча, дәресен дәвам итте.

Коля читкә карамаска, укытучыдан күзен алмый утырырга теләде. Ләкин ул күп сүзне аңламый иде, шуңа күрә дәрестән бик тиз күңеле кайтты.

Звонок булгач, укытучы немецча саубуллашты һәм, журналны култык астына кыстырып, класстан чыгып китте. Хәзер гимназистларның буш сәгатьләре: ял итәргә, әти-әниләре белән күрешергә мөмкин. Алар һәммәсе дә күрешү бүлмәсенә йөгерделәр.

Зур караңгы залда кеше күп түгел. Улларын күрергә килгән ата-аналар анда-санда гына. Тәртип сак-

лап, бүлмә уртасында әрле-бирле надзиратель йөренә. Хәер, монда тәртип саклыйсы да юк. Ата-аналар әкрен сөйләшәләр. Ә инде кемнең дә булса калын тавыш белән кычкырып сөйләгәне ишетелә икән, надзиратель аның ягына кырын караш ташлаудан узмый. Үзен шундый иркен тоткан кеше берәр түрә булырга ихтимал. Димәк, сүз әйтергә, бәйләнергә ярамый.

Коля беркемне дә көтми: әнисе чирләп тора, бүген килә алмаячагын хәбәр иткән иде. Килмәве хәерле дә; Коля барыбер аны бүген үк күрәчәк бит. Бүген үк!.. Ничек килеп чыгар икән...

Коля, тәрәзә янына барып, тышка күз салды. Гимназиянең болын кебек иркен ишегалды койма белән икегә бүленгән. Койманың урта бер җирендә капка. Ул капка янында сторож будкасы. Гимназистларга койманың бу ягында, ишек алдының чиста өлешендә уйнарга рөхсәт ителә, теге ягына кирәк булса гына чыгаралар. Анда гимназиянең абзарлары, мунчасы, аннан ары күл, чокыр. Ул чокырдан шәһәргә чыгарга берәр җай булырга тиеш.

Койманың бу ягында берни юк, фәкать шәрә агачлар гына. Тәрәзә янындагы малайның да күңелендә хәзер шундый ук бушлык. Залдагы кешеләр бер-берсе белән сөйләшәләр, серләшәләр, ә аңа әйләнеп тә карамыйлар. Аны барысы да ят итәләр, чит күрәләр кебек. Ә ул гимназия дип күпме хыялланган иде. Барысы да юкка гына булган икән! Хәзер монда нәрсә эшләп калсын ул?

— Барыбер качам! — дип куйды малай, онытылып. Үз сүзеннән үзе өркеп китте, як-ягына каранды. Ләкин аңа караучы, аның сүзен ишетүче юк, ул монда берәүгә дә кирәк кеше түгел иде.

— Бүген төнлә,— диде ул, тавышын әкренәйтеп. Гүя, мондый фикер аның башына хәзер генә килмәгән, гүя, ул качу мөмкинлеген, качып китү юлларын төрле яктан уйлаган иде.

Пальтолар элгән шкаф бикләнә, аның ачкычы дежур надзирательнең тумбочкасында ята. Дежурный йоклап киткәч, Коля ачкычны алып шкафны ачачак. Ә гимназиядән ничек чыгарга? Тышкы ишекне кичтән бикләп куялар. Тукта, бая ул повар белән сторожның сөйләшеп торганын ишетте түгелме соң! «Көне буе арып-талып, бераз черем итеп алу теләге белән башыңны мендәргә куясың гына — су ташучы ишек дөбердәтә башлый. Ул суны ташып бетергәнче күпме вакыт

үтә, кабат йоклап та китә алмыйсың, ул арада мич ягып җибәрәсе була...» дигән сүзләрне исенә төшерде Коля. «Ишекне ачканнарын көтеп кенә торам да...»

Кинәт кемдер Коляны җиңеннән тартты. Ул сискәнеп куйды һәм Миша Рыбушкинның:

— Нәрсә курыктың? Кабыргаңа инә кадамадым ла,— дигәнен ишетте.

— Болай гына...

— Безгә яңа директор килә,— диде Рыбушкин, пышылдап кына.— Лихачев дигән кеше... Моңа чаклы училищелар директоры булган. Бик усал түгел дип сөйлиләр.

Ләкин дустының сер итеп әйткән сүзенә Коляның бер дә исе китмәде. Гимназия, директор... Яңасы килсә ни дә, искесе утырса ни... Коляның берсен дә күрәсе килеп тормый.

— Килсә ни...

— Син бигрәк инде! — дип куйды Миша, дустының салкынлыгына гаҗәпләнеп, һәм яңа хәбәрне сөйләргә бүтәннәр янына йөгерде...

Моңа кадәр бервакытта да кичнең болай озакка сузылганы, төннең бу чаклы ялыктырганы юк иде. Гимназистлар һәммәсе йоклыйлар. Надзиратель камерага кереп тикшереп йөргәндә, Коля тып-тын ятты. Ул надзирательнең үз почмагына кереп китүен дә, көчәнә-көчәнә итеген салып, пружинасыз диванга ятуын да ишетеп торды. Озак та үтмәде, надзиратель гырлап йоклый башлады. Коля әкрен генә кроватеннан торды да тирә-ягына колак салды. Аннан, ялан-аяк килеш, салкыннан һәм дулкынланудан дер-дер калтырап, надзиратель бүлмәчегенең ишегенә якынлашты... Бу чаклы шыгырдар икән!.. Әллә кире кайтыргамы? Юк, юк! Ул качарга тиеш!

Менә ул диванга якынлаша, менә тумбочкага кулын суза... йөрәге шашынып тибә. Аның тибүен ишетеп, надзиратель уяныр төсле... Менә ул тумбочканың капкачын ача, өске бүлегенә сузыла. Булды! Ачкыч эләкте.

Нәкъ шул минутта надзиратель, мыгырданып, икенче ягына борылып ятты. Коля кычкырып җибәрә язды, ачкычы чак кына кулыннан төшеп китмичә калды. Малай бүлмәчектән ничек итеп чыкканын да, ничек кроватена барып ятканын да сизмәде. Диван тагын шыгырдады, надзиратель тагын нидер мыгырданды... Хәзер һәр тавыш Коляны салкын тиргә ба-

тыра иде. Лэкин бүлмэгэ керүче кеше булмады. Надзирательнең яңадан гырлавы ишетелде. Болай булгач, Коля котылачак иде.

Йоклап китүдэн куркып, Коля башын мендэргэ куймыйча, терсэгенэ таянган килеш кенэ ятты. Төнге тынлыкта шулчаклы күп тавышлар ишетелэдер дип ул бервакытта да уйламаган иде: нэрсэдер шыгырдап куя, нидер кыштырдап китэ, чыелдаган тавыш ишетелэ... Тычканнар шулай сөйлэшэ, ахры...

Төнге авазларны тыңлап, Коля бик озак ятты. Вестибюльдэ сэгать сугуы гына малайны аңына китерде. Бер! Ике! Өч! Дүрт! Вакыт иде инде.

Аягына-өстенэ киеп, Коля коридорга чыкты. Хэзер, үч иткэн шикелле, итек шыгырдый. Күтэреп чыгасы калган икэн... Йөрэге шашып тибэ башлады: «ачкыч белэн тотсалар... каракка чыгам түгелме соң мин?!»

Лэкин шул чакны малайның күз алдына Яковкин, Краснов, карцер килде. «Юк, юк, үтерсэлэр дэ монда калмыйм!»

Коля калтыраган кулы белэн шкаф ишегендэге йозакны ачты. Ишек шыгырдавына кинэт уянып киткэн надзирательнең тавышы ишетелде:

— Иван абый, синме ул анда?

Коля баскан урынында катып калды. Бер минутка сузылган тынлык бер сэгать булып тоелды.

— Тычканнар йөри, ахры. Нэрсэ калган инде аларга?

Бу сүзлэрдэн соң надзиратель яңадан йоклап китте.

Коля үзенең пальтосын эзлэп тапты. Бүреген кигэндэ маңгаена салкын тир тамчылары бэреп чыкканны тойды. Шкафны ачык көе калдырды: иртэгэ барыбер белэчэклэр. Аннары аяк очына гына басып барып, коридордан ишегалдына чыга торган урынга, баскыч астына яшеренде.

Хэзер су ташучы килгэнне көтэргэ калды. Иң авыры, иң куркынычы үтелгэн иде, һэм ул бераз тынычлана төште. Йөрэге тигезрэк тибэ башлады.

Ниһаять, тышкы ишекне шакыган тавыш ишетелде. Башта экрен генэ, соңга таба шактый каты дөбердэттелэр. Кухня ишегеннэн аягына иске башмак кигэн повар чыгып, тиргэнэ-тиргэнэ ишек ачты.

— Кадалып та китэ белмэдең, кайчан гына йоклыйсыңдыр, син, Парфентий? — диде ул, исни-исни, һэм кире кухнясына кереп китте.

Коля моңа каршы әйтелгән:

— Аякны без юрганга карап сузабыз, шуннан артыгы ярамый,— дигән шаярту сүзләрен ишетте. Бу сүзләрне әйтүче егет, күрәсең, йокы дип бик уфтанмый иде.

Коля баскыч астыннан башын чыгарды. Су ташучы егет авыр чиләкләр күтәреп кухняга кереп бара. Ишек ачык калган... Тизрәк чыгып чабарга кирәк!

Ишектән чыккач, ул болдырдан сикереп кенә төште. Коймага күз салды. Капка шар ачык, сторож күренми. Коля капкадан чыкканда, будка эченнән сторожның тамак кырганы ишетелде. Күзәтеп тормыйдыр ич?

Тәвәккәл таш ярган, диләр. Коля, уйлап-нитеп тормастан, чокырга таба йөгерде. Анда койма астыннан язгы сулар ерганак ясаган иде. Чокырның төбе карап күренсә дә, Коляны куркыта алмады: Нижнийда ул моннан тирәнрәк чокырларны да күргән һәм кичкән малай. Куакларга ябыша-ябыша, ул түбән төште. Сөрлегеп тез капкачын авырттырды; шулай да туктап калмады. Авырткан тезен карап торырга аның вакыты юк иде. Аксый-аксый алга йөгерде.

Чокырның икенче ягына үрмәләп менгәч, ул урамга килеп чыкты. Туктап хәл җыйды. Хәзер аңа йөгерергә ярамый — урам каравылчылары туктатуы ихтимал. Тик аның атлап барырга түземе җитмәде. Аягының авыртуын бөтенләй онытып, алга ыргылды. Куып җитә алсалар тотсыннар! Ул иректә хәзер! Иректә!

Воскресенский урамына җиткәндә, Коля шактый арыды һәм атлап кына бара башлады. Бераз ял итәргә, сулу алырга кирәк. Тыкрыктан борылуга, ул Черек күлгә килеп чыкты. Монда инде юл таныш иде. Моннан өйгә дә ерак калмый.

Ләкин үз урамнарына якынлашкач, малай адымнарын әкренәйтә төште. «Әни нәрсә әйтер!» дигән уй килде аның башына.

Ул ике катлы таныш йортның болдырына менеп, ишек белән янәшә тәрәзәгә чиертте. Тагын, тагын чиертте. Ниһаять, тәрәзә пәрдәсе күтәрелде.

— Кем бар? — дип сорады борчулы хатын-кыз тавышы.

— Мин... Коля...— диде малай кыюсыз гына.— Прасковья Александровна улы,— дип өстәде аннары.

— Хәзер ачам,— диде тавыш.

Бераздан ишек ачылып китте.

Йокыдан айнып җитмәгән асрау, гаҗәпләнеп, Коляга карап алды һәм:

— Керегез,— диде.— Әниегез торды, юлга җыена.

Коля икенче катка ташланды. Хәзер инде ул: «Әни аңлармы хәлемне, әллә юкмы?» дип, үз-үзенә сорау бирми. Әнкәсен күрү теләге бөтен нәрсәдән өстен иде.

Әнисе өстен-башын киенгән, кыштыр-кыштыр килеп, юл кәрзине янында маташа иде. Ишек ачылып, кемнеңдер килеп кергәнен ишеткәч, ул сынын турайтты һәм бермәлгә өнсез калды. Аннан соң алга атлады, улын чишендерә башлады; салкын бармакларын учына алып җылытты, бит алмаларын уды. Улының җылынганын тойгач, аның башын күкрәгенә кысты һәм ягымлы итеп сорады:

— Нәрсә булды соң, балам?

Коляга шул җитә калды: ул тетрәнеп, үксеп елап җибәрде.

— Качтым!.. Качтым!.. — диде елый-елый.— Түзә алмадым. Китик моннан! Макарьевка алып кит мине!..

Прасковья Александровна улының башын күтәреп, күзенә текәлде. Бала күзләрендә коточкыч зур газаплану күргәч, көтелмәгән бер карарга килеп, катгый рәвештә әйтте:

— Алып китәм, балам. Калдырмыйм!

Берничә минуттан алар, икесе дә бераз тынычланып, диванда утыралар иде инде. Коля гимназиядә башыннан кичергән хәлләрне әнисенә сөйләп бирде. Прасковья Александровна бүлдермичә генә тыңлады. Битеннән күз яше тәгәри, ләкин ул аларны сизми иде.

— Колюшка, без болай итик,— диде Прасковья Александровна улы сөйләп бетергәч.— Боларны миннән башка беркемгә сөйләмә. Хәзер өйдә калып тор. Мин барып Саша белән, Алешенька белән саубуллашыйм. Директорны да күрермен... Аннары бүген үк Макарьевка кайтып китәрбез. Жарков приказчигын күреп сөйләштем инде.

## 2

Прасковья Александровна белән Коля Макарьевка, туган-үскән нигезләренә кайттылар.

Кечкенә генә бу шәһәрчек Иделнең сул як кушылдыгы — Керженец тамагына утырган. Йөгерек агымлы елга үзенең бормалы юлларын куе карурманнар аша

яра. Очсыз-кырыйсыз бу урманнарда киек-җанварның исәбе-хисабы юк. Адәм аягы басмаган чытырманлыкта йөнтәс аюлар, усал бүреләр, тармак мөгезле пәһлеван пошн көтүләре йөри. Алпавытлар, патша чиновниклары җәбереннән, ә бигрәк тә чиркәү һәм властьлар эзәрлекләвеннән качкан кырыс кешеләр шул ук урман куенына сыенган. Үзләре инанган борынгы гыйбадәт йолаларыннан баш тартырга теләмәгән диндарлар да биредә мәхәллә-скитларга берләшеп утырган. Аларның зиратында тәре юк. Кабер өстенә кечкенә такта түбәчекле багана куелган. Узгынчы бай сәүдәгәрләрнең котын алып торган башкисәр ир-егетләр дә Идел киңлекләренә шул Керженец урманнарыннан кузгалып чыгалар һәм тартып алынган малларны, алтын-көмешне куаклы-чытырманлы чокырларда яшереп саклыйлар иде.

1435 елда ук инде Нижегород-Печерский монастыре биредә, Иделнең Керженец үзәнендә чиркәү салып куя. Макарий кушаматлы монах «диннән язган» әлеге кырыс холыклы кешеләрне чиркәү йогынтысына буйсындырырга тиеш була. Макарийның «изге» максаты ни дәрәҗәдә тормышка ашкандыр — анысы тарих өчен караңгы, әмма шунысы билгеле: 1439 елны Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт бу гыйбадәтханәне пыран-заран китергән. Монахларны һәм Макарийның үзен, әсир итеп, Казанга алып киткәннәр һәм бераздан, Казан ханлыгы чикләрендә янә монастырь төземәскә ант иттереп, ирекка җибәргәннәр.

Шуннан соң ике гасырга якын вакыт узган. Макарийның анты онытылган. 1624 елны Тәтеш монахы Аврамий шул ук урында яңа монастырь оештырган.

Борынгы рус дәүләтендә монастырь — халыкны үз тирәсенә җыя-туплый торган үзәк булган. Аврамий гыйбадәтханәсеннән нибары чакрым ярым ераклыкта Крестцы авылы барлыкка килгән. Элеккечә үк изге Макарий исеме белән аталган бу яңа монастырь тирәсендә тиздән сәүдә эшләре дә җанлана. Сыртлап-сыртлап төрле товар төялгән зур-зур көймәләр, сәүдә кораблары килә башлаган. Алар Иделнең югары агымындагы рус җирләреннән дә, түбәннән — Каспий далалары ягыннан да килгәннәр. Июль урталарында сәүдәгәрләр биредә сату-алу иткәннәр, товар алышканнар һәм янә үз якларына юл тотканнар.

Мәскәү патшалыгы бик хуп күргән бу эшне. Идел буе сәүдә үзәгенең татарлар башкаласы читендәге

Арча кырыннан бирегә, рус җиренә күчүе Мәскәү өчен, әлбәттә, куанычлы хәл булган. Һәм менә 1641 елны Макарий монастыре янында сату итү патша указы белән рәсмиләштерелгән. Шулай итеп, мәшһүр Мәкәрҗә ярминкәсе барлыкка килгән.

Бу хәлдән монастырь әһелләре бик тә канәгать кала. Шулай булмый ни! Ярминкәдән килгән бөтен керем: привал, отвал салымнары, «камыт» акчасы, шәм өчен, ладан өчен, чиркәүләр салдыру өчен, монахларны ашату-эчертү өчен дип җыела торган акчалар һәммәсе монастырь казнасына бит. Хәер, патша да сирәк-мирәк бу бетмәс-төкәнмәс алтын чыганагына кулын сузгалый торган була.

Ярминкәне имеп яткан монастырь тиз арада гөрләп үсеп китә һәм өч меңләп крепостной крестьян бил бөккән эре феодаль хуҗалыкка әверелә. Сәүдәгәрләргә арендага амбарлар биреп тора, андагы товарларны саклар өчен махсус каравылчылар тота. Хак тагәлә, ахирәт эшләре белән шөгыльләнергә монастырь башлыкларының рәтләп вакытлары да калмый.

Биек таш койма белән уратып алынган гаять зур бу монастырь, гыйбадәтханә булудан бигрәк, ныгытылган крепостьне хәтерләтә. Аның дүрт почмагында түгәрәк башня, ә урталыктагы дүрт кырлы башнялар астында капкалар була. Көньяктагы олы капка Иделгә карый. Анысын монахлар: «Изге капка», дип йөртәләр. Монастырьның калын стеналары астагы сугышчылар өчен тар уклык-тәрәзәләр, ә өстән торып ату өчен махсус уемтыклар белән чуарлана. Ләкин аларның кирәге чыкмый диярлек. 1670 елда исә, Степан Разин восстаниесе вакытында, атаман Максим Осипов отрядын монастырь сакчылары капкаларны киң ачып каршылаганнар.

Тора-бара Мәкәрҗә ярминкәсенең даны Идел буена гына түгел, ерак-еракларга, хәтта чит илләргә дә таралган. Рус җирендә моңарчы күрелмәгән зур сәүдә үзәгенә Урта Азия һәм Европа илләреннән, Кытайдан һәм Һиндстаннан, Әфганстан һәм Ираннан сәүдәгәрләр агыла башлаган. Нинди генә затлы товар килми бирегә! Кытай чынаягы һәм иран келәменнән алып инглиз фаэтоннарына кадәр — җаның теләгән һәр нәрсәне сатып алырга мөмкин бу ярминкәдә.

Кечкенә генә Крестцы авылыннан үсеп киткән Макарьев шәһәре, әкияттәгечә, еллап түгел, көнләп, сәгатьләп зурайган вә баеган.

Хөер, узган көз, Нижний Новгородтан бирегә күчеп килгәч, Макарьев мескен бер шәһәрчек булып күренгән иде Коляга. Кыйшайган койма, янтайган иске йортлар, баткак урамнар, иске такталардан этмәлләнгән әвеш-түеш тротуарлар, уртасында ялгыз чиркәү тырпаеп утырган бердәнбер пычрак мәйдан... Һәркайда чүп-чар, сасы тирес өемнәре һәм... мәет чыккан йорттагы кебек, ниндидер сәер тынлык. Әйтерсең, бу шәһәрнең барлык кешеләре көпә-көндез ятып йоклаганнар, яисә, йортларын бөтенләйгә ташлап, каядыр олакканнар... Ә кышын... Кышын тагын да шомлырак, җан өшеткеч бушлык. Әмма яз җитеп, Идел вә Керженец бозлардан арчылгач, шәһәр, әйтерсең, үзенең кара япмасын ачып ташлый. Өненнән кузгатылган карт аю кебек, иң элек монастырь уяна: гыйбадәт кылучы монахларның сузынкы җырлары ишетелә, чаң тавышлары киң үзәнне яңгырата. Шуны гына көтеп торгандай, шәһәр халкы да кыймылдый башлый. Кайдадыр кала читендә балта тукылдавы, аңа пычкы зыңлап җавап бирүе ишетелә. «Үлгән» Мәкәрҗәгә җан керә, һәркайда кызу эш кайный.

Ике-өч атна узмады, әйтерсең, чуртан кушуы буенча, тип-тигез комлык җирдә Яңа Макарьев — биржасы, карван-сарай, кунак йортлары, трактирлары белән ярминкә шәһәрчеге үсеп чыкты. Алар тирәли йөзләрчә дисәтинә җирне биләп алган урам, тыкрыклар, аллы-гөлле буяулы челтәрле коймалар лабиринты, бихисап кибет, рестораннар, цирк, театр, балаганнар, әрмән чиркәве һәм мәчетләр...

Ярминкә ачылырга ике-өч атна кала Идел буйлап югарыдан һәм түбәннән Мәкәрҗә ягына төрле-төрле эреле-ваклы кораблар агыла башлады. Аккошлардай тезелеп, ак җилкәнле каеклар йөзә, авыр баржалар тартып, яр буеннан юан арканнарга җигелгән бурлаклар килә иде. Мәкәрҗә кешеләре телендә тихвинка, кладушка, соминка, расшив, гусянка һәм тагын әллә ни дип аталучы әкәмәт баркаслар. Ташбакадай акрын кыймылдаучы атлы баржа тагын да гаҗәбрәк. Арканга тагылган якорьны көймәдә алга илтеп салалар да, баржа чыгырын атлар белән әйләндереп, арканны тарттыралар һәм, шулай итеп, баржаны алга әйдиләр. Палубада чыгыр чыелдавы, тояк тавышы, алда якорь ташлаучы көймәчеләрнең үзара әрләшүе, хәлдән тайган бурлакларның әрнеп ыңгырашуы иртәдән кичкә кадәр Идел өстендә яңгырап тора. Каршы яктагы

текә яр астына җыелган судноләр көннән-көн ишәя баралар. Ә аннан товарларны, яссы төпле баржаларга төяп, бирге якка, ярминкәгә ташыйлар.

Килгән кунакларны монастырь чаңнарының еракларга яңгыраган бәрхет тавышы каршы ала. Болытларга кадәр күтәрелгән соры тузан әллә кайлардан: «Ярминкә монда, ярмәнкә башланды!» — дип хәбәр итеп тора кебек. Умарта күчедәй халык, меңләгән ат, йөк төягән олау, арбалар, кареталар моңа кадәр зарыгып-моңаеп буп-буш яткан Макарьев бушлыгын каплап ала. Кыңгыраулар чыңы, тәгәрмәч шыгырдавы, күчәр чыелдавы, ыгы-зыгы, этеш-төртеш, алыш-биреш, төрле-төрле телләрдә аңлашып-сатулашып учка уч суккан тавышлар — һәммәсе колак тондыргыч бер гөрелтегә әверелә.

Кыш буе үлеп йоклаган иске шәһәрнең үзендә дә мәхшәр туа. Баш тыгарлык барлык йорт-каралтыга мөсафирлар кертәләр. Хатын-кыз иртәдән кичкә кадәр казан-учак тирәсендә кайнаша. Аяк өсте тамак ялгарлык арзанлы азык-төлек пешереп, ярминкәгә йөгерәләр. Ризыкларын берәр кибеткә тапшыралар, яки урам чатына басып, үзләре үк саталар.

Мәкәрҗә шул рәвешчә ике ай буе шау-шулы күңелле тормыш белән яши дә, тынгысыз сәүдәгәрләрен, эреле-ваклы судноларын озатып, сырлап-бизәкләп вакытлыча эшләнгән каралтыларын сүтеп, тынып кала. Әйтерсең лә комлы яр үзәнлегендә берни дә булмаган. Шәһәр тирәсе яңадан буп-буш кала, көзге төн пәрдәсенә төренеп, тирән йокыга тала...

Кышкы салкыннан кызгылт-сары төскә кергән сүрән кояш Макарьев бистәләре артына төшеп килә.

Коля кулын бабасы бүләк иткән тире тунның кыйгач кесәсенә тыгып, лапас түбәсендә басып тора. Аның күз карашы монастырь янындагы киң тигезлеккә, җәй буе шау-гөр килеп торган ярминкә кырына юнәлгән.

Биредән ап-ак кар каплаган кырлар һәм калын боз катламы астына яшеренгән Идел өсте аръяктагы кызыл ярларгача ачык күренә. Кая карама, бары тик бушлык, бушлык... Тик ярминкә кырында дистәгә якын өнсез каралты һәм ни сәбәпледер китмичә, яр буенда бозга катып калган ялгыз баржа гына моңаеп утыра. Ә сулгарак карасаң, монастырь стеналары янәшәсендә мәһабәт биналар, очлы манаралар, чиркәү

гәмбәзләре... Әйтерсең алар кеше кулы белән төзелмәгән, әйтерсең шул якындагы урманның ябалдаш имәннәре кебек үк, табигый рәвештә җирдән үсеп чыкканнар.

Дөньясын онытып, зәһәр салкынны да тоймыйча лапас түбәсендә басып торган малай, исемнәре дә билгеле булмаган борынгы осталарның бу гаҗәеп сәнгатенә, кеше хезмәтенең һәм табигатьнең акыл ирешмәс дәрәҗәдә бер-берсе белән ярашып, килешеп, шулай тыгыз үрелүенә соклана иде.

Ниһаять, малай тәненә суык үтә башлаганны тоеп, ачы җилгә аркасы белән борылды. Хәзер аның күз алдында — карга күмелгән урамнар, тар тыкрыклар. Кыйшайган йортларның тәрәзәсендә батып барган кояшның алсу нуры чагыла.

Мәкәрҗәгә кайткач, Коля атна буе өйдән чыкмады. Бабасының кечкенә генә үз хуҗалыгы — бакчасы, мал абзары, кар базы, кош-корт сарайлары бар. Алма бакчасында дистәдән артык умарта тезелеп тора. Тәмам бөлеп, элекке зур йорты бурыч түләр өчен ярты бәясенә сатылгач, бабакай шушы урынга килеп төпләнгән. Ә әбисе, кайгыдан авыруга сабышып, тиздән дөнья куйган.

Каты бәгырьле кырыс карт оныгын чын күңелдән яратты һәм озакламый Коля гимназия газапларын бөтенләй онытты. Ул көненә әллә ничә мәртәбә бабасы бүлмәсенә керә, аңа ишеткән-күргәннәрен сөйли, башына ни килде, шуны тыкылдап, озак-озак утыра.

— Мин бүген «Телемак сәяхәтләрен» укып бетерәм, ярыймы, бабакай? — ди ул, иске кәнәфигә кунаклап.

— Анысы соңыннан,— ди карт.— Ә хәзер йөреп кайтабыз. Мин сине бер җиргә алып барам. Кая икәнен баргач күрерсең.

Һәм менә алар икәүләшеп урам буйлап баралар. «Кызык, кая алып барыр икән?» дип уйлый Коля. Әмма сораштырып бабасын йөдәтми.

Менә алар башка йортларның берсенә дә охшамаган сәер бер бина янына килеп туктыйлар. Аның тәрәзәләре бөтенләй юк, югарыда, түбә кыегы астында үк, пыяласыз-нисез озынча уентылар гына күренә. Тимерче алачыгы! Күн алъяпкыч, күн бияләй кигән тимерче корымга баткан. Ап-ак теше белән күз аклары гына ялтырап күренә. Ул кызган тимерне озын кыскыч белән эләктереп, утлы күмер өстендә әйләндергәли.

Сарык боты кыздырамыни! Аның ярдәмчесе — яшь кенә егет, озын колганы тарткалап, бик зур гармунга охшаган күрекне хәрәкәт иттерә. Бер караганда торна борынлы сәер җанварны хәтерләткән бу күрек, тыны кысылгандай хырылдап, уф-пуф итеп, утлы учакка өрә. Менә тимерче кызган тимерне учактан ала да, зур сандал өстенә куеп, әйләндерә-әйләндерә чүкеч белән тукмаклый башлый. Як-якка, утлы уклар булып, очкын чәчелә. Әйе, биредә күн алъяпкычтан башка эшләү мөмкин түгел икән шул. Алсу-аксыл төстәге кызган тимер тора-бара суынып, куе кызыл төскә керә. Әйтерсең, ул үзен шулай кеше алдында рәхимсез тукмаклауларыннан оялып кызара һәм менә күрек янәдән хырылдап өрә, учактагы утлы күмер янәдән зәңгәрләнеп ялкынлана башлый. Кызган тимер тагын учактан сандалга күчә...

Исе китеп карап торган Коля бабасының җиңеннән тарта:

— Күрче, бабакай! Әтәч бит бу! Тимер әтәч!

Тимерче белән Коляның бабасы бер-берсенә карашып елмаялар. Ә әлеге тимер әтәч, чыш-пыш итеп, лакандагы салкын суга кереп чума. Су өстеннән куе пар күтәрелә. Тимерче икенче бер тимер таякны алып бераз кыйнаштыра да, әтәчне шуңа утыртып, Коляга бирә.

— Менә булды,— дип елмая ул малайга.— Мә, миннән истәлек булыр, алып кайт та капка башына утырт.

— Рәхмәт!

Иске чүпрәккә төрелгән тимер әтәчне кулына алгач, Коля аның җылысын тоя. Әйтерсең, ул тимер түгел, җанлы әтәч!

Коляның бабасы әтәчне капка түбәсенә түгел, ә бүлмәгә, караватбашына куярга киңәш итә:

— Тышка куйсаң, я берәрсе алып китәр. Ә болай булганда иртән үзең дә, әтәч кебек таңнан ук, көр күңел белән уянырсың,— ди ул оныгына.

Бабасы белән Коляның мондый кызыклы сәяхәтләре еш-еш булып тора. Икенче бер көнне алар җил тегермәненә бардылар.

Гап-гади тегермәндә шундый кызыклар күрермен дип уйламаган да иде Коля. Тегермән, кунакларны үзенә чакыргандай, канатын болгый, авыр түгәрәк ташны зыр-зыр әйләндерә, алтын бөртекләрне тартып, ап-ак онга әверелдерә. Хәер, кешеләрдән ишетеп Коля

боларны электән дә белә иде. Әмма хәзер, бабасы сөйләгәннәрне тыңлагач, тегермәннән бигрәк әнә шул бодай бөртеге малайга бик кадерле нәрсә булып, экияттәгечә тылсымлы бөртек булып тоелды. Тегермәнгә килеп җиткәнче аны әле чәчеп үстерәләр икән, урып, сугып, киптереп, аннан соң гына тартырга китерәләр икән...

Шулай итеп, Мәкәрҗәдә өч атна узып та китте. Улының тазара, түгәрәкләнә барганын күреп, Прасковья Александровна бик шат булды. Инде, иптәшләреннән бөтенләй артта калмасын өчен, бераз дәрес караштыра башларга да вакыт иде. Моны алдан ук истә тотып, Коляның дәреслекләрен дә алып кайтканнар иде...

...Һәм менә:

— Коля, дәресеңә утырырга вакыт! — дип чакырды Прасковья Александровна, тышкы ишектән башын сузып.

Коля ашыга-ашыга лапас түбәсеннән төште. Шатлыктан чиный-чиный, чылбырын чылтыратып, үзенә каршы омтылган йөнтәс Шарикны башыннан сыйпап узды һәм энисе янына өйгә керде. Прасковья Александровна һәр нәрсәне кызык итеп, экият кебек ма выктырып сөйли белә. Шунлыктан Коляга дәрес материаллары да бик кызык тоела, өч сәгать вакыт һич сизелми узып та китә. Кызганычка, бергәләшеп тыңларга иптәшләре генә юк.

Дәрес, гадәттәгечә, арифметикадан башланды. Прасковья Александровна фикеренчә, математика баланы мөстәкыйль уйларга, үз фикерен ачык һәм кыска итеп әйтеп бирергә өйрәтә. Бу дәресне Коля аеруча ярата. Чишелгән мәсьәлә һәм мисаллар тиздән язу тактасына сыймый башлый. Прасковья Александровна улына кәгазь, кара һәм каурый каләм бирә.

— Яз, улым, тик хата ясамаска тырыш,— ди ул.

Прасковья Александровнаның оста тегүче дигән даны таралган. Ул кичләрен, кайчандыр асрау карчыктан отып алган борынгы рус җырларын көйли-көйли, кешегә тегү тегә. Коля оеп йокыга киткәнче, сулышын тыеп, аның бу моңлы җырын тыңлап ята. Кайчак Прасковья Александровна, шәм яктысын учы белән каплап, Коля яткан караватт янына килә, аның өстен рәтләп яба, улын маңгаеннан үбеп, шыпырт кына үз урынына барып утыра.

«Беркемнең дә шундый әйбәт әнисе юктыр»,— дип уйлый Коля. Әйе, аның әнисе кайчак Коляны сүзсез дә аңлый, йөзенә бер карау белән аның ни әйтәсен, ни сөйлисен белә. Искиткеч зирәк кеше аның әнисе!

Әмма, ничек кенә яратмасын, шук малайның әнисе сүзеннән чыккан чаклары да булгалый. Шулай бервакыт, әнисе аңа чарлакка менеп казынырга, зурлар өчен язылган андагы тузанлы китапларны рөхсәтсез алып укырга ярамавын әйтте. Тик мондый эштән алай җиңел генә тыелып буламы соң! Чарлакта төрле китап, кульязма һәм самовар торбасыдай итеп төрелгән ниндидер таушалган карталар белән шыгрым тулы сандык тора. Көннәрдән бер көнне качкын мәчене эзләп чарлакка менгәч, Коля бу гаҗәеп хәзинәне күреп таң калды. Нәрсә генә юк иде ул серле сандыкта! Тик алар барысы да тәртипсез актарылып яталар. Күрәсең, моңарчы анда кемдер казынган, актарынган. Мөгаен, абыйсы Сашадыр әле. Әнә шунлыктан ул күп беләдер!

Коля китапларны берәм-берәм актара, алып карый башлады. Һәм бераздан, үтә мавыгып, бер китапны аяк өсте үк укырга кереште. Үзе укый, үзе баскычтан ишетелгән аяк тавышларына колак сала. Алай-болай искәрмәстән берәрсе килеп менмәгәе дип, Коля бер хәйлә дә уйлап тапты: чарлакта кер бавы тарттырган булып кыланачак.

Баштарак бу хәйлә аны коткарып килде. Берәрсе якынлашканны ишеттеме, ул шунда ук әлеге бауга барып тотына иде. Әмма бервакыт, китап белән артык мавыгып, чарлакка әнисе менгәнен сизми калды.

Әнисенең гаҗәпсенеп карап торганын күргәч, Коля оятыннан кая керер тишек тапмады.

— Гафу ит, әнием! — дип чак-чак әйтә алды.

— Әй, Коля, Коля! Әйтмәдемме мин сиңа! — диде әнисе үпкәле тавыш белән.— Җитмәсә, катып-калчаеп беткәнсең...

Аларның тавышын ишетеп, чарлакка бабасы да менде.

— Табылдымы??. Әйттем мин сиңа, Параша, сәгатьләр буе югалып тора икән, димәк, ул һичшиксез биредә... Синең теш үтә торган китаплар түгел болар, Коля... Синең акыл җитә торган түгел... Әйтсәм әйтим инде, Параша, соңгы елларда, үләр алдыннан, Сергей Степанович тәмам ычкынды. Иске иконаларга һәм иске китапларга дөнья кадәр акча түкте. Берәр авыл-

да, берәр поп кулында борынгы китап барлыгын ишеттеме, күзе ут яна. Бөтен дөньясын онытып, тегене эзләп чаба иде. Әнә күрәсез, күпме китап җыйган мәрхүм... Ә син, Коля, колагыңа киртеп куй, яңадан монда аяк басасы булма! Ишеттеңме?!

— Ишеттем...— дип пышылдады Коля.

— Тагын бер менгәнеңне белсәм, аң бул, чарлакны биклим дә куям. Менә бу китапларны ал да марш моннан. Минем бүлмәгә алып кер...

Яшь чагында Коляның бабасы псалтырь һәм «Мәскәү хәбәрләре» газетасыннан башка бернәрсә дә укымаган. Ә хәзер исә, картлык көнендә, борынгы китап белән үтә мавыгып киткән. Үз бүлмәсендә ул кулына ни эләкте шуны укып, кич буе иске кәнәфидә утыра. Укыган китаплары турында озаклап-озаклап фәлсәфә корырга ярата.

Әлеге вакыйгадан соң бер-ике көн узгач, бабакай ниндидер сәер нәрсә турында сүз башлады.

— Ә сез шуны беләсезме? — диде ул, ничектер тантаналы итеп.— Беләсезме шуны: беренче карашка бер үк зурлыкта күренгән яссы фигуралар арасында иң зурысы — түгәрәк. Ә күләмле җисемнәр арасында — шар. Түгәрәкнең квадратурасы турында ишеткәнегез бармы? Күпме акыл ияләре түгәрәккә тиң зурлыкта квадрат төзергә тырышып баш ватканнар! Әмма шушы көнгәчә һичкемнең уңышка ирешә алганы юк әле. Ә менә тагын... кайдадыр софис баганасы дип аталган серле багана бар имеш. Меркурий исемле зур акыл иясе шул баганага геометрия башлангычын язып калдырган. Искитмәле хәл ич!..

Коля бабасының бу сәер хикәятен игътибар белән тыңлый. Беркем дә чишә алмаслык шундый авыр мәсьәлә чыннан да бар микән? Баганага язылган бу тылсымлы башлангыч нинди икән?..

— Бабай... бабакай, боларны сез кайдан укыдыгыз? Чарлактан алып төшкән теге китаплардан түгелме?

— Әйе, Санкт-Петербург Академиясе чыгарган фәнни журналдан. Ә бит, Параша, әлегә ул «Математика тарихы» Коля өчен файдалы булыр иде. Мин укып чыктым, анда балалар өчен зарарлы нәрсә юк.

Табын әзерләп, арлы-бирле йөргән Прасковья Александровна этисенең сүзенә каршы килмәде.

Көндезге аштан соң бабасы Коляны үз бүлмәсенә алып керде дә өстәлдә өелеп торган китапка ымлады:

— Әнә, ал, китап битләре буйлап сәяхәт кылып кайт. Нинди дөньяларда, нинди патшалыкларда булуың турында соңыннан миңа сөйләрсең...

Кичке кояшның сүрән нуры кыйгачлап Коля бүлмәсенә төшкәндә, әлеге иске китаплар киштәдә тезелеп тора иде инде. Малай бу искиткеч хәзинәгә карап туя алмый. Биредә соры тышлы «Академия хәбәрләре»нең 1779—1781 елгы саннары, ә аларда «Капитан Кук тормышы», «Америка тарихы», «Христофор Колумб», «Борынгы рус акчалары», «Балыклар», «Имән черегендә чебеш чыгару», «Математиканың төрле тармаклары һәм борынгы тарихы» һәм башкалар, һәм башкалар... Исемнәрен укып кына да әллә нинди хыялый дөньяга ашкына башлыйсың. Ә инде битләрен ачсаң, анда зәңгәр диңгезләр чайкала, джунгли ешлыкларында сөңге тоткан кыргый кешеләр йөри... Әмма син тукталып тормыйсың, үзең ачкан ерак утрауда бераз гына ял итәсең дә, тагын җилкән күтәрәсең, тагын йөзәсең. Шулай итеп, көн артыннан көннәр уза. Синең янәшәңдә, күзен офыкка текәп, батыр йөрәкле сәяхәтче Колумб басып тора. Колумб яр буенда ком киптереп ятмаган, шуңа күрә дә Американы ачу бәхетенә ирешкән. «Колумб кебекләр авырлыклардан курыкмаган,— дип уйлый Коля.— Тик шунысы кызганыч: иксезчиксез океан ярларына тиз генә ирешеп булмас әле...» Әйе, «Академия хәбәрләре»нең әллә ничә томы тезелеп тора! Әмма Коля укудан һич ялыкмый. Тыштагы әче салкыннар да гел өйдә утырырга мәҗбүр итә. Колянын бөтен вакыты бабасы һәм әнисе янында уза, ул аларга кычкырып китап укый. Ә кичләрен әле әнисе, әле бабасы алмашлап та укыйлар.

Ниһаять, җир калын кар юрганына тәмам капланды. Көчле бураннар кайчак тәрәзәләрне дә күмеп китә, хәтта такта ярыкларыннан өйалдына тула, абзар-кура тирәләренә сыртлап-сыртлап карны өя. Андый көннәрдә Коля өйдән борынын да чыгармый.

Зурлар арасында үз эшләреннән аерым үсә торган балаларның, гадәттә, өлкәннәргә билгесез үз дөньялары, үз уй-хыяллары була. Соңгы айларда Коля шигырь белән мавыгып китте. Чарлактагы сандыктан нинди генә шигырь китабы эләктермәсен, дөньясын онытып укый. Хәтта үзе дә иҗат итәргә тырыша. «Математика тарихы»ннан укып, ул бик кызык нәрсәләр белде: Пифагор шәкертләре үз иншаларын һәрчак шигырь белән язганнар имеш...

Малай кайчак үзен, дөяга атланып, Мисыр чүлләренә, гаҗәеп биек пирамида, сфинкслар янына барып чыккандай хис итә. Кайчак Александриягә, горур Евклид янына бара. Птолемей патша Евклидтан: «Геометрияне өйрәнү өчен җиңелрәк ысул юкмы?» дип сорый. «Юк,— дип җавап бирә галим.— Хәтта патшалар өчен дә юк андый ысул».

Коля, укый-укый, Анаксимандр ябылып яткан караңгы зинданга да барып керә. Ә Анаксимандр зинданда да түгәрәкнең квадратурасын табарга тырышып баш вата... Аннары малай кулына эләккән һәр кәгазь кисәгенә шигырь яза. Кайчан да булса шагыйрь булырга өметләнә ул.

Әлеге шул сандыкта актарынганда, Коля Державинның искереп, таушалып беткән шигырь китабын табып алды. Кашагаларына үрмәкүч ятьмә корган тузанлы тәрәзәдән төшкән томса яктылыкта Коля китапның беренче битләрен укыды һәм шунда ук хыял канатлары аны ерак-ерак дөньяларга алып китте. Державин шигырьләре малайның күңелен әсир итте.

Коля хәзер чарлакта — «үз китапханәсе»ндә сәгатьләр буе рәхәтләнеп казына. Инде моның өчен әнисе дә әрләми, хәйләгә кер бавы да кирәк түгел. Коля, китапларны сандыктан бушатып, эчтәлекләре буенча төрле өемнәргә аера, аларның исемлеген төзи. Бер исемлеккә типографиядә басылган китапларны, икенчесенә — бормалап-бөдрәләп, борынгы славян хәрефләре белән язылганнарын, эле үзе рәтләп укый алмаганнарын терки. Өченче өемгә калын тышлы иске дини китаплар өелә. Ә дүртенчесенә үзе өчен иң кадерлеләре — математика, тарих һәм философия томнары туплана. Державин китабын исә бөтенләй аерым, чарлак почмагындагы кечкенә генә иске өстәлгә куйды.

Әмма ул Сергей Степановичның китапханәсен тәртипкә салып бетерә алмады. Еллар узу белән тәмам саргаеп беткән газеталар өеме астыннан тагын бер таушалган китап табып алды. Бу китапта ерак Төньякта яшәүче гап-гади бер балыкчы улының ничек итеп Мәскәүгә укырга килүе турында язылган була.

«Була бит шундый хикмәтле хәлләр,— дип уйлый Коля, китапны укып чыккач.— Курыкмаган бит, бер ялгызы туган авылын ташлап киткән. Зәһәр салкында балык олауларын куып җиткән... Ә мин нәрсә?.. Уку-

ымны ташладым. Ни сәбәпле диген? Ломоносов булса ташламас иде...»

Коля чарлактан төште дә үз бүлмәсенә кереп бикләнде. Аның беркемне дә күрәсе килми иде. Әмма бераздан әнисе килеп ишек какты һәм аңа хат китереп тоттырды:

— Укы, улым, Сашадан.

Абыйсы аңа Алеша белән икесенең дә гимназиядә яхшы укулары турында язган. Тормышларыннан да канәгатьләр икән.

Коля туганнарыннан көнләшеп куйды... Ә ул бирелә, Мәкәрҗәдә, читлектәге кош кебек бикләнеп ята.

— Казанга кайтасым килә. Яңадан гимназиягә...

Әнисе аны, бер дә сәерсенү галәмәтләре күрсәтмичә, тыныч кына тыңлап торды.

— Ярый,— дип елмайды ул.— Ярый, илтермен.

Оныгыннан аерылу шактый кыен булса да, аларның бу ниятен бабасы да хуплады.

Март ахырында юллар ышанычлы түгел. Казанга кадәр дүрт көн барасы. Шуңа күрә ашык-пошык җыендылар да, өч ат җигелгән чыпта фаэтонга утырып, янәдән сәфәргә чыктылар. Дугадагы кыңгырау хәзер бөтенләй башкача чыңгылдый. «Казан-га, Казан-га!», дип шатланыша кебек иде. Шул малайның күңелен тынычландыра һәм аңа якты өмет бирә. Тик атлар, урам чатына җитеп, тыкрыкка борылганда, аның йөрәге сулкылдап, әрнеп куйды: капка баганасына сөялеп, алар артыннан моңаеп карап калган бабасы бик кызганыч тоелды аңа...

Һәм менә атлар кыңгырауны чыңлатып тагын алга таба чабалар. Һәр борылыш саен яңа күренешләр ачыла: әле кечкенә-кечкенә камышлы күлләр, әле кар каплаган тигез кырлар, әле каракучкыл булып утырган нарат урманнары күренеп кала.

Юлда көндез шәп иде, төнлә бигрәк тә рәхәт икән. Коля да, әнисе дә йокламый. Һәрберсе үз уена чумып, тып-тын гына утыралар. Язгы саф һаваны сулап туя алмыйлар.

Идел бозына кергәндә урман артыннан түм-түгәрәк тулган ай күтәрелде һәм карлы кырларны көмеш нуры белән балкытты. Анда ялгыз юлаучы күренде. Ул Коляга гыйлем эзләп авылыннан киткән балыкчы улын хәтерләтте. Ул да бит кайчандыр төн караңгысында ялгызы, биштәрен асып, газаплы, әмма матур тормышка таба атлаган.

Коля әнисенең иңенә сыенды.

— Туңдыңмы?

— Юк, әнием, син инде хәзер минем өчен борчылма. Мин яхшы укырмын.

Ана улының чандыр иңеннән кочты.

— Рәхмәт.

Төн кунарга тукталганчы да һәм аннан соңгы көннәрдә дә, Казанга кайтып җиткәнче, бу хакта кабат сүз булмады.

Ләкин гимназиягә, инспектор хозурына шундый гозер белән барырга җыенгач, Коля чыдамады:

— Әнием,— диде ул.— Яңадан кабул гына итсен ул мине. Мин аңа попугай түгеллегемне расларммын. Бүтән берчакта да сине хафага салмам. Бервакытта да.

Прасковья Александровна улын үбеп алды.

— Мин сиңа ышанам, Коля.

## 3

Яковкин белән әңгәмә шактый озакка сузылды.

— Кирәк бит шул кадәргә барып җитәргә! — дип мыгырданды ул кабинет буенча атлый-атлый. Аннары капылт кына борылды, хәтта аның кабарып торган түгәрәк корсагында сәгать чылбырының алкалары зеңгелдәп куйды.— Әгәр һәр гимназистка алай ирек бирә башласак, тиздән бөтен малайлар өйләренә таралып бетәчәк. Әйбәт үрнәк түгел бу, ханым, киресенчә, гыйбрәтле, бик гыйбрәтле хәл.

Прасковья Александровна ап-ак агарып утыра иде. Бер кулы белән икенчесенең бармакларын кыскан килеш, үз улының киләчәген хәл итәчәк кешенең җенләнүен ул аны-моны дәшмичә генә карап торды.

— Зинһар өчен, Сергей Степанович, зур өмет баглаган малайны гафу итә күрегез инде,— дип сүзгә керешә Прасковья Александровна, ниһаять, инспектор тынып торган арада. Аның сабырлык саклавы, итагатьле тавышы Яковкинны бераз йомшартты бугай. Чөнки күз яше, киресенчә, аны һәрвакыт ярсыта иде.

— Ярар, алайса,— диде ул креслога килеп утыргач.— Сезнеңчә булсын. Тик кисәтеп куям: үзегезнең хисапка. Сезнең олы улыгыз казна хисабына кабул ителде инде. Ә монысы үзен күрсәтсен әле. Аны махсус күзәтү астында тотачакбыз. Аңладыгызмы, махсус күзәтү астында! — Инспектор, әйткән сүзенең мәгънәсенә

басым ясап, итләч кыска бармагын югары күтәрде.— Андый-мондый хәл була калса...

Яковкин, сүзен әйтеп бетермичә, креслосын өстәлгә якынрак китерде һәм шуның белән әңгәмәнең тәгәлләнүен белгертеп, төрле кәгазь белән шыплап тутырылган калын папкасын ачты.

Прасковья Александровна аның белән ничек хушлашканын һәм ничек итеп гимназиядән чыгып киткәнен хәтерләми. Өенә кайтып җитәрәк кенә һушына килде ул. Баскычтан менгәндә, кулы белән яшьле күзен корытып алды һәм каршысына йөгереп чыккан Коля аның шатлыклы елмаюын гына күрде.

— Барысы да аллага шөкер, улым: сине кабул иттеләр.

Коля да, ничек кенә кырыс булырга тырышмасын, авызын ерып җибәрде. Аның күкрәгендә гүяки боз эреде. Хәтерендәге авыр, борчулы уйлар җуелды, грек сарайларына охшаган мәһабәт бинаны һәм иптәшләрен, бигрәк тә шат күңелле күршесе Миша Рыбушкинны сагыну хисе генә бимазалап тора иде хәзер аның җанын.

Шул ук көнне Коля гимназиягә килде. Янә аның чәчен тигезләп кистеләр, тарадылар. Мунча кереп чыккач, ялтыр төймәле мундир, галстук, перчатка, кулъяулык, тарак бирделәр. Шул рәвешчә ул гимназиянең тулы хокуклы укучысы булып китте.

Надзиратель Сергей Александрович Попов Коляны баштанаяк карап-тикшереп чыкты, галстугын рәтләде һәм, шат тавыш белән:

— Моннан да әйбәт итеп кем киенер икән тагын,— диде.— Хәзер инде залга рәхим итик. Улын формада күрүне зар-интизар булып көтә торгандыр әниең.

Коля көтү залында көзгегә карады һәм беркавым үзен таный алмый торды. Кием-салымнарын игътибар белән карап чыккач «мундирның миңа тиешлесен бирмәгәннәр икән», дигән уй узды аның башыннан.

— Сергей Александрович,— дип эндәште ул надзирательгә,— миңа ялгыш башка мундир биргәнсез ич. Барысының да куртка төймәләре алтыннан, ә минекенең ак калайдан гына...

Надзиратель кулъяулыгы белән пенсненен сөртеп алды, йөткерәсе килмичә генә йөткерде һәм теләр-теләмәс кенә әйтте:

— Патшаның указы бар ул хакта.

— Нинди указ?

— Алтын төймә — дворян балаларына, ә башка чиндагы кеше малайларына гади ак төймә.

Попов рәхимле кеше иде. Малайның ирене дерелдәп китүен күргәч, ул аны тынычландырырга ашыкты:

— Һәй, төймәдәмени хикмәт?! Иң мөһиме — уку. Күңел биреп укыгыз... Әйдәле, аска төшик. Әниең инде, мөгаен, абыеңның йокы бүлмәсендә утыра торгандыр.

Дворян балалары өчен йокы камераларының да аерым булуын, ә гади малайлар класста һәм ашханәдә до алардан арттарак утырырга тиешлекне әйтмәде Попов.

— Абыең белән бер бүлмәдә яшәрсең,— диде ул ишек янына җитәрәк.

Ләкин йокы бүлмәсендә абыйсы да, әнисе дә юк иде. Коля аларны икенче каттан эзләргә булды. Залга керергә надзирательдән рөхсәт сорады.

— Класс ишекләрен генә ачмагыз, анда хәзер дәрес бара,— диде Попов.

Баскычтан менеп барганда, Коля үзенә эндәшкән тавышка артына борылып карады.

— Туктагыз әле, туктагыз! — диде аңа таба ашыгып килүче сары чәчле, күк күзле малай. Ул, сулуы кабып, көлә-көлә йөгереп менеп килә иде.

— Сезнең аякларыгыз озын шул, һич куып җитә торган түгел,— ди малай.— Мин сезне күрү белән танып алдым. Теге вакытны, Княжевич ватмады тәрәзәне, мин ваттым, дигән малай бит сез... Абыең Саша белән бер класста укыйм. Аксаков мин, Сергей, таныш булыйк... Безнең полкка, димәк. Шат, бик шатмын!

Коля ни өчен шатланырга да белмәде. Тегенең куе яшел курткасында алтын төймәләр җемелди. Әллә каян күренеп тора — дворян малае. Ләкин әлеге гимназист аның күзенә шундый ышаныч белән карады, ә калын иренендә шундый йомшак елмаю уйнады ки, Коля ихтыярсыз:

— Мин дә бик шат, таныш булыйк, исемем Николай минем,— дип әйтеп ташлаганын үзе дә сизми калды.

— Лобачевский,— дип өстәде Аксаков һәм нык итеп аның кулын кысты.— Бик хуп... Ә хәзер нишлибез?.. Синең кая барасың килә һәм мин сиңа нәрсә күрсәтә алам?

Коляга аның тәкъдиме бик ошады.

— Һәммәсен күрсәт,— диде ул.— Теге вакытны, беренче килгәндә, мин һични күрергә өлгермәдем...

— Син өскә менә идеңме? — диде Аксаков, аның сүзен бүлдереп.— Әйдә, йөгердек. Бүген башым авырта, шуңа күрә класска кермәдем. Бик шәп булды бу! Әйдә тизрәк!

Өскә менгәч, Сережа үз өендәге кебек аңлатып йөрде.

— Менә бу бүлмәдә квартирмейстер поручик Михайлов яши. Боларында канцелярия кешеләре... Син гимназиягә кергәндә доктор Бенесның өенә барган идеңме? Менә шушы бүлмәдә утыра ул... Монысы больница... Менә монысы артиллерия һәм фортификация укытучысы яши торган квартира...

— Гимназиядә туптан атуны да өйрәтәләрмени? — диде Коля, гаҗәпләнеп.

— Артиллерия генә түгел, фехтование дә, хәрби белем тактикасын да укыталар. Гимназия бит безне гражданский хезмәткә дә, хәрби хезмәткә дә яраклы итеп чыгарырга тиеш.

— Син боларның барын да каян белеп бетердең? — дип сорады Коля, торган саен ныграк гаҗәпләнеп. Ул инде үзенең яңа иптәшенә зур хөрмәт белән карый башлаган иде.

Сережа моны сизеп алды һәм хозурланудан аның түгәрәк йөзе җәелеп китте.

— Әйдә шкаф артына! — диде ул һәм Коляны куртка җиңеннән өстерәде.— Анда беркем дә күрмәс. Гимназиянең бөтен тарихын сөйләп бирермен... әгәр теләсәң...

Теләмимме соң Коля! Тын алырга да куркып, ул Аксаков артыннан коридорның аргы башына атлады. Шкаф бик зур, аның күләгәсенә унлап малай сыярлык иде.

— Менә шунда! — диде Сережа һәм озак уйлап тормыйча, тузанлы идәнгә утырды.— Курыкма, утыр, ахырдан чистарырбыз. Аю өне кебек монда.

— Аю өне кебек! — Лобачевский көлеп куйды.— Син бигрәк инде...

Коля кинәт сүзен бүлде һәм тынып калды. Аның тизрәк дусты сөйләгәнне тыңлыйсы килә иде.

— Бер укытучының әйткәнен ишеттем. Язып алдым хәтта.— Сережа тезен кочаклап, бик җайлап утырды. Ашыкмыйча, тәмләп сөйләргә җыенган иде ул.

— Элек Казанда духовная семинария, духовное училище гына булган. Дин әһелләре чыккан алардан,— дип аңлатты Аксаков.— Дини фәннәр укыткаплар. Ә бер заман Мәскәү университеты ректоры Казанда гимназия ачу турында сүз кузгаткан, киләчәктә студент буласы халыкны тиешенчә хәзерли башларга вакыт, дигән ул.

— Гимназия кайчан ачылган соң? — дип сорап куйды Коля.

— Ул кадәресен хәтерләмим, илле ел чамасы элек булса кирәк *,— диде Сережа, төгәл белмәвенә гарьләнеп.— Безнең гимназиянең беренче директоры язучы Веревкин булган. Аның драмалары хәтта Петербург театрында куелган, дип сөйлиләр... Беренче елны барлыгы ундүрт укучы укый. Шулар арасында,— дип өстәде ул җанланып,— Державин була. Бөек Державин!

Коля моңа шаккатты.

— Геометрия укыганнармы алар?

— Каян килсен аларга геометрия! — Сережа көлеп куйды.— Мин бая әйткән теге укытучыдан Державинның истәлекләрен сорап торган идем. Шуннан күчереп язып калдым...

Сережа кесәсенә тыгылды:

— Кая китте соң? Менә ич! Таптым! — Ул юка куен дәфтәре тартып чыгарды.— Тыңла! — диде. Почмакта караңгы булу сәбәпле, дәфтәрен борын төбенә үк китереп, акрын гына укый башлады: «Барыннан бигрәк, безне укырга, язарга, сөйләргә, азмы-күпме грамматиканы белергә, әдәпле булырга өйрәтергә тырыштылар. Гимназистларны укытучы язган нотыкны күңелдән ятларга һәм кафедрадан торып сөйләргә мәҗбүр итәләр иде. Сумароков трагедияләре, парлап бию һәм фехтование буенча халык алдында экзамен алалар иде. Ул заманда безне тел гыйлеменә — грамматикасыз, санау һәм үлчәүгә — исбатлаусыз, музыкага нотасыз өйрәттеләр. Дин китапларыннан башка нәрсә укытмадылар».

Сережа кәгазьне дүрткә бөкләде дә саклык белән генә кесәсенә салып куйды.

— Чынлап та шулай начар укыдылар микән?! — диде Коля гаҗәпләнеп.

---

* Казанда беренче гимназия 1758 елны ачыла.

— Ә яшәвен тагын да начаррак яшәгәннәр,— дип тагын сөйләп китте Аксаков.— Бер танышымның бабасы әйтүенә караганда, гимназистлар ачлы-туклы торган, өс-башларына да теләсә ни кигәннәр. Мәскәү университеты вакытында ни акча җибәрмәгән, ни уку әсбаплары. Веревкин тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарыннан уку өчен кирәкле әйберләрне натуралата җибәрүләрен сораган. Чөнки гимназистларның иң ярлылары теләнеп тамак туйдыра башлаганнар. Аннары инде гимназияне бөтенләй япканнар. Ун елдан соң гына яңадан ачылган безнең уку йорты. Менә шушы йортта, губернатор өендә. Павел Беренче, Казанга килгәч, гимназиянең яңа уставын раслаган. 1798 елны килә Павел патша Казанга.

— Боларны язып алуың әйбәт,— дип мактады Коля.

Сережа күз кысып куйды.

— Кирәге чыгар әле. Ишеткән-белгәннәрнең һәммәсен дә кәгазьгә теркәп барам. Әле менә боларын расписаниедән күчереп алган идем.— Аксаков икенче кесәсеннән озын исемлек чыгарды.— Мәҗбүри фәннәрдән тыш монда гидравлика, бухгалтерия, архитектура белеме керә. Алты тел өйрәнәбез: рус, татар, латин, грек, француз, немец телләрен...

— Геометрия дә керәчәкме? — дип сорады Коля.

— Геометрия дә керәчәк... Йә, җитте! — дип сүзен бүлде Сережа.— Хәзер дәрес бетә, күреп калулары мөмкин. Миңа ятып кына торырга кушканнар иде. Хуш!

Коля аңа:

— Хуш! — дияргә өлгермәде, яңа дусты, өстендәге тузанны кага-кага, баскычтан йөгереп төшеп тә китте.

Коля да өстен каккалады һәм баскычка таба юнәлде. Гимназиянең язмышы белән кызыксынуы һәм көтмәгәндә башланып киткән дуслык аркасында ул энисен һәм туганнарын хәтердән чыгара язган лабаса!..

* * *

Төшке аш вакытында Коля үзенең иске танышлары белән очрашты. Яковкин аны, элеккегечә үк, әзерлек классына билгеләгән һәм иптәшләрен куып җитү өчен бик тырышып укырга кушкан иде.

Ә Коля, ул әйтмәсә дә, җаны-тәне белән шуңа омтылды. Укытучылар аңа үтелгән материалдан өстәмә

рәвештә ике-өч дәреслек эш бирәләр һәм көн дә сорыйлар. Коля һәрвакыт дәресен өйрәнеп килә. Аның сәләте, тырышлыгы бер ай эчендә иптәшләрен куып җитәргә мөмкинлек бирде. Ул хәтта түбән класстагы абыйсы Саша белән бергә латин телен дә өйрәнә башлады, энеләре Алешага исә андый рөхсәт бирелмәгән иде әле.

Коляның уңышлары укытучы Красновка да тәэсир итми калмады. Краснов үзен һаман әшәке тота, ләкин Лобачевскийга каныкмый, вакыт-вакыт сәер итеп карап кына куя иде.

Көннәрдән беркөнне, туйганчы башбаштаклык кылганнан соң, Краснов әйберләрен күтәреп чыга башлады. Коля турыннан үткәндә, аның алдына арифметикадан мәсьәлә язылган бер бит кәгазь куйды һәм:

— Дәресне үткәреп бетерерсең,— диде, башын читкә борып.— Шушы мәсьәләне чишегез. Тик карагыз аны!..— Сүзен әйтеп бетермәде, ишекне каты ябып чыгып китте.

Берникадәр вакыт класс тынып торды. Шуннан, гүя команда булды, һәммәсе урыныннан сикереп торды. Шау-шу башланды:

— Ура!.. Яңа укытучы! Исәнмесез!..

Коля да чөгендер кебек кызарып торып басты, берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, мәсьәлә язылган кәгазьне бөтерә иде.

Бу уңайсыз хәлдән аны Миша Рыбушкин коткарды.

— Silentium *! Әфәнделәр! Silentium! — дип кычкырды ул, өстәлгә менеп басып.

Һәммәсе кызыксынып аның ягына борылдылар. Тавыш басыла төште.

— Сез ничек уйлыйсыз,— дип сүзен дәвам итте Рыбушкин, тавышын акрынайтып,— сөекле укытучыбыз нәкъ менә шушы минутта ярыктан күзәтеп, тыңлап тормыймы икән?

Бер минут кына элек шау-шу килгән класс бөтенләй тынып калды. Бу хәлне күреп, Рыбушкин кычкырып көлеп җибәрде.

— Менә шулай, менә шулай, дускайларым,— диде ул көлә-көлә яшьләнгән күзен сөртеп.— Хәзер әйтегез миңа: мәсьәләне ничек чишү рәхәтрәк булыр, укытучы беләнме, әллә укытучысызмы?

— Укытучысыз! Укытучысыз!

---

* Silentium — тынычлык (лат.)

— Шулай икән, рәхим итеп чишегез, кыланмагыз,— дип киңәш бирде Рыбушкин һәм өстәлдән сикереп төште.

Класста инде тынлык урнашкан иде.

— Николай, нинди мәсьәлә анда? Әйдә, сиптер! Красновка, бәлки, ошап китәр дә, шулай тагын үзебезне генә калдырыр.

Коля үзен кулга алып өлгерде. Ул мәсьәләне кычкырып укыды, аңламаучыларга төшендереп бирде. Алай гына да түгел, бер кызып киткәч, ул һәркемнең ялгышын күрсәтеп, өстәлләр арасында йөрде. Малайлар уен катыш үткәрелгән бу дәреснең бетүен дә сизмәделәр.

Икенче көнне дәфтәр тикшергәндә Краснов, кызмача булса да, малайларга бәйләнерлек сәбәп тапмады. Үзе дә гаҗәпкә калды һәм Коляның аркасыннан кагып:

— Молодец, рәт чыгачак синнән!..— дип куйды.— Инде шушы өч мәсьәләне чишегез, мин китәм...

Бу юлы укытучы ишекне бәреп япмыйча чыгып китте. Коля ишек ябылганын көтеп торды да, урыныннан торып, беренче мәсьәләнең шартын укый башлады. Һәм шунда ук укучыларның аны игътибар белән тыңламауларын сизеп алды. Аңа карап торган йөзләр чытык, карашлар ышанычсыз иде. Кайберәүләр көчәнеп елмайгандай иткәннәр. Ләкин андый елмаюлардан җан өшеткеч салкынлык бөркелә иде.

— Нәрсә булды? — дип сорады, ниһаять, Коля күршесеннән.

— Ни бит,— дип аска карады Миша.— Красновны өнәп бетермиләр алар...

— Краснов яраткан кешене дә,— дип өстәде кемдер.

— Әмма барыбер укырга кирәк ич,— диде Коля аптырый төшеп.

— Укы, тик белдембаш булып китмә! — дип яңадан кисәтте уң яктан бер малай.

— Долой, хаҗәтең бер тиен,— дип шауладылар алгы рәттәгеләр дә.

Коля урынына утырды. Аның күзенә яшь бәреп чыкты.

— Әйдә, дәвам ит! — дип сорадылар басынкыраклары.— Юкса укытучы үзе керер, җиде кат тиребезне тунар.

Коля кыюсыз гына торып такта янына килде, кулына акбур алды.

— Мәсьәләнең бирелешен укыйбыз,— дип башлады ул акрын гына.— «Ике җәяүле ике пункттан...»

— Берсе «А» пунктыннан,— дип бүлдерде аны кемдер.

— Икенчесе «Б» дан,— диде тагын бер мәсхәрәләшаян тавыш.

Миша түзмәде:

— Әфәнделәр! Лобачевский гаепле түгел ләбаса,— дип урыныннан сикереп торды.— Лобачевский гаепле түгел, тавышланмый гына тыңлыйк без аны.

Башка дәресләр ничек узса, бусы да шулай гадәти генә узды.

Мәсьәләләр чишелдә, Коля әүвәлгечә артка калганнарга булышты, тегеләр исә аның ярдәмен шулай булырга тиеш, дигән сыманрак кабул иттеләр. Шулай да Коля белән класс арасыннан салкын җил узды. Тәнәфестә аны берәү дә ишегалдына уйнарга чакырмады, хәер, ул үзе дә анда чыкмады.

Читләшү көнләп түгел, сәгатьләп үсә барды. Үзе уздырган һәрбер дәрестән соң Коляны ялгызлык хисе газаплый иде. Ләкин ирексез ярдәмчесенең күңел тойгыларын аңлаудан мәхрүм иде шул Краснов әфәнде, һәм ул Лобачевскийга арифметика дәресен язга кадәр алып барырга кушты.

Бер ай вакыт бик күңелсез үтеп китте. Менә беркөнне...

Май уртасы, чәчәкле яз иде инде. Түбәнге латин классына эштән куылган Васнецов урынына яңа укытучы билгеләнде. Класска кереп исәнләшкәч үк, ул такта янына узды һәм, акбур алып, җитез хәрәкәт белән уңнан сулга нәфис итеп ниндидер ярымтүгәрәк, дугалар сызды, өскә дә, аска да икешәр төртке куйды.

— Менә минем исем-фамилиям шушы була инде,— дип киң итеп елмайды ул.— Аңлашыламы, әфәнделәр?

— Аңлашылмый,— дип шауладылар малайлар.

— Алайсам аңлатам. Уңнан беренче сүз — минем фамилиям, икенчесе — исемем, өченчесе — әтиемнең исеме.

— Хәрефләре биеп тора, бу сүзләр җанлы кебек,— дип мактады Рыбушкин.— Ләкин без аларны укый белмибез шул.

— Гарәпчә өйрәнмәдегезмени әле?

— Юк шул.

— Алайса, шул ук сүзләрне мин сезгә латинча язам.

Акбур янә шома такта буенча, бу юлы сулдан уңга, йөгереп узды.

Класс җанлана төште. Төрле яктан шат авазлар ишетелде:

— Монысын укый алабыз!

— Ибраһимов Нигъмәт Мирсәети!

— Укытучы әфәнде! — Миша Рыбушкин, кулын күтәреп рөхсәт алырга да онытып, урыныннан сикереп торды.

Яңа укытучы үзен шулчаклы гади тоткач, моңа кадәр тыелып килгән укучылар да үзләрен иркенрәк тойдылар.

— Укытучы әфәнде, русча ничек була инде ул?

— Безнең татар халкы байтак исемне гарәптән алган. Русчага күчергәндә минем исемем «ашамлык», әтиемнең исеме «олуг» яки «өлкән» дигән төшенчәләргә тәңгәл килә.

Бу сүзләр һәркемгә кызык тоелды һәм класс күңелле итеп гүләп алды.

— Фамилиям генә тәрҗемә ителми, — дип, гүләвгә исе китмичә, аңлатуын белде укытучы. — Ибраһим ул пәйгамбәр исеме. Французча сез мине Ibragime Nourriture Doyen дип, немецча Ibrahimman Nahrung Senior, ә инде латин теленә тәрҗемә иткән тәкъдирдә Ibrahim Cibus Magistre дип йөртергә тиеш булырсыз. Димәк, җир йөзендә ничә телдә сөйләшсәләр, минем исемем дә шулчаклы.

Укучылар моңа шаккаттылар. Миша Рыбушкин исә куркуга төште:

— Укытучы әфәнде, ул чагында сезгә ничек диярге соң?

— Элек мин Мәскәү университетында укыдым, соңрак шунда укытырга калдым. Анда мине русчалатып Николай Мисаилович дип йөртәләр иде. Сез дә, әфәнделәр, шулай дип атый аласыз.

Укытучы класска күз йөртеп чыкты һәм тагын елмайды. Аның елмаюы ничектер бик сөйкемле тоелды укучыларга.

— Хәзер, әйдәгез, чынлап торып танышыйк, — диде укытучы, кафедра янына килеп. — Кем нинди шигырь белә? Кайсы телдә булса да ярый. Укыгыз. Мин кемнең нәрсә яратканын күрермен.

Коля кыймылдау түгел, тын алырга да куркып утыра иде. Карашын яңа укытучыга текәгән. «Терекөмеш кебек» дигән уй килде малайның башына, тик ул аны шунда ук куды. «Юк, юк, аны берни белән чагыштыру мөмкин түгел. Бу укытучының елмаюы да, сөйләшүе дә, хәрәкәте дә фәкать аның үзенә генә хас...»

Малай, үзенең уена бирелеп, класста барган хәлне бөтенләй күрмәде һәм ишетмәде. Ә аның иптәшләре бер-бер артлы сикереп торалар да төрле телдә шигырь сөйлиләр. Рус, татар, немец, француз, грек телләрендә яңгыраган шигырьләрне Ибраһимов, күрәсең, бик ләззәтләнеп тыңлап утыра: елмая, башын селки һәм, шигырь уңаена, кечкенә генә кара тутлы кулы белән өстәлгә бәргәләп ала.

— Афәрин! Афәрин! Монысы бик матур...

Берьюлы ике-өч малай кул күтәрә, шигырь сөйләргә ашкынып торалар, чөнки һәркемнең шундый күңелле укытучыдан мактау сүзе ишетәсе килә.

— Яхшы! Бик әйбәт! — дип йомгаклады Ибраһимов, һәм берничә минут тын утыргач: — Кайсыгыз латинча белә? — диде.

Коля кулын күтәрде.

— Башла,— дип ым какты аңа Ибраһимов.

Җырлап торган латин теле укытучының күңелен сихерләде. Ул «Мельпоменага» дигән оданы ахырына кадәр тыңлады да Коля янына килде, кулын аның иңенә куйды.

— Афәрин! Ритмны шәп тоемлыйсыз. Шагыйрь буласыгыз гына калган. Тәрҗемәсен дә беләсезме?

Коля кинәт кереш имтиханда да шундый ук сорау ишетүен исенә төшерде. Ул чагында бик рәнҗегән иде шул аның күңеле.

Лобачевский укытучының йөзенә күтәрелеп карады. Юк, бу Яковкин түгел, моның күзе җылы нур белән, теләктәшлек, соклану нуры белән яктырып, балкып тора иде.

— Тәрҗемә итеп карагыз,— диде Ибраһимов.— Бәлки, чынлап та булдырырсыз.

— Булдырам,— диде Коля ышанычлы тавыш белән.

Горацийның одасын бик җиңел һәм төгәл тәрҗемә итте ул.

Укытучы аңа рәхмәт әйтте.

Менә кыңгырау шалтырады. Соңгы дәрес бетте. Ләкин Ибраһимов класстан чыгарга ашыкмады.

— Кемнәр минем белән Кремльгә бара? — диде ул, һич көтмәгәндә.— Сөембикә манарасыннан язгы ташкынны карарга! — дип өстәде.

Малайларның шатлыклы чыр-чуы аны тагын елмаерга мәҗбүр итте.

Чирек сәгатьтән алар инде крепость эчендә иделәр. Хәрби складларны, гауптвахтаны, җәмәгать биналарын, архиерей йортын һәм консисторияне үткәч, татар ханнарының соңгы вәкиле Сөембикә исеме белән аталган манара янына килеп җиттеләр.

— Син әнә тегендә кара,— диде Миша Рыбушкин кулын югары күтәреп. Анда ямь-яшел очлы гөмбәз өстендә ай урагы белән алтынсу шар ялтырап күренә иде.

Коля башын күтәреп югарыга карады. «Мондый биеклектән егылып төшсәң, юләр... Шулай да күпме вакыт узар икән төшеп җиткәнче?..» Каерылып карый торгач, аның фуражкасы җиргә төшеп китте.

— Ташлама, кирәк булыр,— дип шаяртты Миша.— Әйдә тизрәк, без бик артта калдык бугай.

Алар нәүрәп авызындагы шикелле салкын бәреп торган ишек янына килделәр.

— Анда караңгы бит,— дип бусага төбендә туктальш калды Коля.

— Аста гына караңгы, ә без өскә менәбез. Өстә яктырак. Әнә басмалары да бар. Атла шул таш баскычтан.

— Ә син?

— Мин синең арттан.

Караңгыда капшана-капшана, малайлар таушалып беткән текә таш басмалардан югарыга күтәрелә башладылар. Кайдандыр өстән алгарак узган укучыларның бер-берсенә эндәшкән тавышлары ишетелә. Коляның йөрәге биек яр читенә килеп түбәнгә сикерергә тәвәккәлләгән мизгелдәге кебек ярсып типте. Менә алар икәүләп йөз сиксән җиде басманы хәвеф-хәтәрсез генә үтеп, тар тәрәзәле иң өске яруска менеп җиттеләр. Манараның кәрнизе буйлап күк күгәрченнәр гөлдерәшеп йөри иде.

Коля, курка-курка гына, тар тәрәзәнең берсенә күз салды һәм баскан урынында катып калды: кара чүмәләләр арасында нинди сукмаклар тагын анда? Баксана, сукмак түгел ич, озын-озын урамнар шулай күренә

икән югарыдан. Өй янындагы бакчалар яшел буй төшкән одеялларга охшап, чокыр буйларында йөргән кәҗәләр, бөтенләй бәләкәйләнеп, бөҗәккә әйләнеп калган.

— Карале, кара, нинди хозурлык! — дип кычкырып җибәрде шул чагында Рыбушкин.— Син монда кил, монда! Аннан берни дә күренми ич.

Ярусның каршы як стенасындагы тәрәзә янында Ибраһимов басып тора һәм, укучыларның әле берсенә, әле икенчесенә карый-карый, гүзәл күренешне тәфсилли иде:

— Казан тирәсендә Идел суы унҗиде чакрымга җәелгән. Көньяк-көнбатышка карагыз әле. Әнә Ослан таулары чагыла су көзгесендә. Бераз уңдарак, кояш баешында Бишбалта. Петр патша фәрманы белән Каспий диңгезенә төшереләчәк корабларны шунда ясый башлаганнар. Арырак Ягодный, татарлар аны Чегән бистәсе дип йөртәләр. Ә тагын да арырак Елан тавы монастыре агарып күренә. Татар легендасы Елан тавында канатлы елан яшәвен бәян итә. Тик бер сихерче карчык өн авызына учак яга да еланны төтенгә булыктырып үтерә. «Казан патшалыгы турындагы риваять»тә бу тирәләрдә Иске Бряхов каласы булуы искә алына. Имештер, Саин патша үзенең халкын әнә шуннан Идел ярына, рус дәүләте белән күрше җирләргә алып килеп урнаштырган һәм «төрле-төрле җәнлек-җанварга, балыкка, көтүлекләргә, умарталыкка бай урын» аңа бик ошаган. Ләкин шундый әйбәт җирдә ике башлы аждаһа яшәгән, ди. Бер бик кыю сугышчы патшага: «Ул явыз аждаһаның җанын җәһәннәмгә олактырам һәм үзебезгә тыныч тормыш корырга урын әзерлим»,— дигән. Чынлап та, көннәрдән бер көнне еланны һәлак иткән батыр егет. Менә шуңа күрә кызыл канатлы, ике аяклы, бөҗрадай койрыклы һәм башына таҗ кигән кара елан сурәте төшерелгән дә инде Казан гербына... Ә-нә тегендә, тагын да көнбатыштарак, зәңгәр томан эченнән Кизий монастыреның гөмбәзе шәйләнә. Биредәрәк, Подлужный бистәсендә җәйге дачалар тезелеп киткән...

Язгы ташу вакытында Казан каласының матур күренешен моннан соң да күп мәртәбә сокланып күзәтәчәкләр әле Коля һәм аның иптәшләре. Ә инде шушы беренче тәэсир аларның күңеленнән гомер буе җуелмаячак.

Инде гимназиягә кайтыр вакыт җиткән иде. Укучылар баскычтан түбән төшә башладылар. Тик ни хикмәттер, төшкәндә менгәндәгегә караганда начаррак хис иттеләр алар үзләрен.

— Тормышта да һәрвакыт югарыга, әле ачылмаган белем тауларына гына омтылыгыз,— дип елмайды Ибраһимов,— җиңел юл түгел бу. Ләкин яшәү дигән сүз бөтен кешелек бәхете өчен яну дигән сүз ул.

Укытучының бу сүзе дә Коляның хәтеренә гомергә сеңеп калды.

## *Өченче бүлек*

### 1

1804 елның эссе җәй башы. Казанда инде икенче атнага сузылган түзеп булмаслык кызудан хәтта күк йөзе дә көеп төссезләнгән кебек тоела. Болытның әсәре дә күренми. Төшкә таба шәһәр урамнары бушап кала: һәр җан иясе ышыкка үрмәли. Агач йортларның тәрәзә капкачлары шыплап ябыла.

Шушындый чиктән ашкан эсседә дә гимназия бинасында киеренке шау-шу тынып тормый. Гимназистлар, балга җыелган күч кебек, бер караңгыдан икенче караңгыгача китапка капланып, дәрес ятлыйлар. Ләкин болай җыйган «белем балы»ннан мөгаен әрем ачылары киләдер.

Миләрне кайнатырлык эссе, ашгырып якынлашкан имтиханнар күңелсез казарма көнкүрешен түзеп булмаслык итәләр. Гимназистларны чиркәүгә дә, ашханә һәм классларга да, элеккечә үк, сафка тезеп «куалый»лар. Көннең көнендә өстенә карауга күңелне болгата торган солы боткасы ашаталар. Үзең теләгән ризык сатып алу тыела. Әти-әниләрдән килгән акча надзирательгә сакка тапшырыла, аны рөхсәтсез тотып булмый. Һәммәсе өйгә кайтырга талпына, туйганчы ашыйсы, ял итәселәре килә.

Дәрес ятлау ыгы-зыгысында нәфрәт авазлары һаман ешрак яңгырый. «Бал кортлары» инде чагар кәл-

го җитеп ярсыганнар, әлегә тик сылтавы гына табылмый. Һәм менә ул...

Шимбә көн эсседән һәм дәрес ятлаудан тәмам тинтерәгән гимназистларны икенче каттагы иркен ашханәгә төшке ашка алып килделәр. Тәрәзәләрнең шар ачык булуы да эсседән коткармый. Ашханәнең «разночинец»лар өстәле урнашкан аргы башында бигрәк тә эссе. Аларга ашны да иң соңыннан, дворян балаларын ашаткач кына, бирәләр.

Коля Лобачевский булачак каникул, Мәкәрҗә ярминкәсе турында уйланып, такыр башын сыйпыйсыйпый, энесе янәшәсендә утыра иде. Залда кинәт кузгалган тавышка башта игътибар да итмәде.

Ашханәгә директор Лихачев килеп кергән икән. Тәрбияләнүчеләрнең аның белән очрашканы юк иде диярлек: гимназиядә ул бик сирәк була, уку-укыту, бигрәк тә хуҗалык эшләре белән бөтенләй шөгыльләнми, директор урыны аңа бары дәрәҗәсе өчен генә кирәк иде. Аның кыяфәте үк килбәтсез: аскы ирене шөпшә чаккан кебек бүртеп тора.

Лихачев, әпен-төпен атлап, өлкән класслар өстәле янына килде һәм ясалма күтәренке тавыш белән сорау бирде:

— Йә, әфәнделәр, тамакны туйдырдыкмы?

Гимназистлар бер-берләренә карашып алдылар.

— Туйдырмый ни! Безне хәзер сукага төшәчәк атларны симерткән кебек ашаталар бит,— дип җавап бирде өлкән Княжевич * һәм, кабып карарга тәкъдим иткән кебек, солы боткасы салынган кургашын коштабакны директорга сузды.

— Бик дөрес. Әйбәт ашатмый ярамый, чөнки озакламый сезнең урып-җыю чоры башлана,— дип ризалашты Лихачев.

Шулчак гимназиянең иң яхшы укучысы Федор Пахомов өстәл артыннан торды һәм үҗәтләнеп кычкырды:

— Ялгыш сөйлисең, Княжевич! Сукага төшкәндә дә атларга мондый майлы ризык тәтеми. Ә безнең хакта, күрәсең, ничек кайгырталар! — һәм ул бармак

---

* Ул чакта гимназиядә бер үк гаиләдән агалы-энеле берничә малай тәрбияләнгән. Мәсәлән, Лобачевскийлар укыган чорда Казан гимназиясендә: Княжевичлар — өчәү, Перевощиковлар — икәү, Панаевлар — дүртәү, Балясниковлар — икәү, Манасиннар — өчәү була. Туганнарны: беренче, икенче, өченче дип, яисә өлкән, уртанчы, кече дип йөрткәннәр.

башы хәтле генә май салынган агач кашыгын өскә күтәрде.

Зал шаркылдап көлеп җибәрде. Ләкин Пахомов, шауламаска кушып, кул изәде.

— Шунысы кызганыч: эти картның шәм заводы юк. Юкса, кыш өйләнәсенә мин аңа нихәтле чимал җыйган булыр идем. Череп баер идек бит, әй!

Лихачев, үзен-үзе белештермичә, ярсып аяк типте:

— Ни сөйлисең син!

— Хак сүз! — Гимназист аңа тыныч кына җавап бирде.— Карагыз менә, мондый терлек маен кешегә ашаталармы соң? Бу бит сабын белән шәм ясарга гына яраклы.

Зал көлми иде инде. Тәрбияләнүчеләр урыннарыннан сикереп тордылар. Өзек-өзек тавышлар яңгырады:

— Бу сасы үләксәне үзегез татып карарсыз, бәлки!.. Директор әфәнде, без дуңгызлар түгел, адәм балалары!

Ачы итеп сызгырып җибәрделәр, коштабаклар идәнгә атылды, зал гөрелтегә күмелде. Лихачев, ике кулы белән башын учлап, ишеккә ташланды. Надзирательләр, директорны гимназистлардан аралап, ялагайланып, аңа тизрәк ишек ачтылар.

«Тузгытылган умарта күче» кара төн җиткәч кенә тынды. Арыганлык җиңде, тәрбияләнүчеләр йокыга талдылар.

Коляны йокы алмады. Май башларында, эчке тәрәзә рамнарын алгач һәм гимназия бакчасында үлән яшәреп, тал песие йомшак бөдрәләрен яргач, ул үзенә куркыныч та, шуңа күрә үтә мавыктыргыч та яңа шөгыль уйлап тапты.

Төнен, бөтен йорт йокыга талгач, Коля ашыгып киенә дә ачык тәрәзә янына килә. Барыбер күзенә йокы керми. Тәрәзә аша сихерле ай карый, аның яктысында гап-гади бакча да тылсымлы булып күренә. Коля тәрәзә төбенә үрмәли дә шыпырт кына дымлы, йомшак җиргә сикерә. Кесәсенә алдан ук хәстәрләп куйган ипи кисәге белән каравылчының Акбаен сыйлый. Эт, шатлыклы ырылдап, рәхмәт йөзеннән аның кулын ялый. Коля каравылчы карт белән дә дуслашты. Ул аны надзирательгә әләкли дә ала, ләкин бабай үз вазифасын яхшы белә: гимназияне ул карактан, юлбасарлардан сакларга тиеш, урыс малае йөрсен әйдә рәхәтләнеп, мөгамәләсе дә бик итагатьле...

Коля инде бакчага берничә тапкыр чыкты. Мондый сәфәрдән соң ул сиздермичә генә тәрәзәдән кире керә һәм иртәнгә чаклы каты йокыга тала иде.

Бу юлы ул, тәрәзәдән бүлмәгә кергәндә, икенче катта пышылдашып сөйләшкәнне ишетте. Аннары, түбәдән бер чүмәлә печән аудардылармыни, стена буенда нидер кыштырдады. Коля кире бакчага сикерде һәм үз күзенә үзе ышанмый торды: пыяла түбәнең бер бүлеме ачык иде. Шуннан бауга асылынып бер кеше тирбәлә. Бер кулына — пумала, икенчесенә чиләк тоткан. Кемдер өстән:

— Петя, каушама,— дип пышылдады.

«Княжевич! Митя!» Коля аны тавышыннан танып алды.

— Нык тотабыз, тизрәк яз...— дип ашыктырды Княжевич.— Арканның бер очын бәйләп куйдык...

Петя, пумаласын стена буйлап кызу-кызу йөртеп, ниндидер хәрефләр яза иде. Ниһаять, ул нокта куйды һәм канәгатьләнеп пышылдады:

— Булды бу! Тартып алыгыз!

Ул кереп югалуга, өстәге тәрәзә өлгесе тавышсыз гына ябылды.

Бу шундый тиз эшләнде ки, Коля: «Әллә соң күземә генә күренәме?» — дип аптырап торды. Юк, әнә стенада тонык кына хәрефләр абайлана. Тик әлегә аларны укырга гына мөмкин түгел.

Йокы бүлмәсендә, кытыршы одеял астында, бик озак борсаланып ятты малай. «Кем ул Петя? Узган ел Мактау кәгазе белән бүләкләнгән Петр Алехин түгелме икән? Стенага нәрсә язды икән ул?»

Иртәгесен, өстеннән кемдер одеялын өстерәгәнгә, Коля уянып китте. Алеша икән.

— Тизрәк! Тизрәк тор! — дип ашыктырды аны энесе.— Дежурныйлар юып төшерә, күрми каласың!

— Нәрсәне?!

— Анда инде, гөмбәз астында...

— Ә,— дип шәйләп алды Коля. Тиз генә киенде дә, уктай атылып, ишегалдына чыкты.

Ишегалдына гимназистлар җыелган иде инде. Шаулашалар, көлешәләр, куллары белән гөмбәзгә төртеп күрсәтәләр. Гөмбәз астында ут кебек кызыл буяу белән: «Бетсен хокуксызлык! Лихачевны долой!» дигән сүзләр язылган иде.

Надзирательләр көч-хәл белән гимназистларны

классларга куып тараттылар. Фетнәле язуны юар өчен ашыгыч рәвештә янгынчылар чакырылды.

Инспектор Яковкин тикшерү эшенә керешге. Бик теләп керешге, чөнки яңа директорны хурлау өчен моннан да кулайрак сылтау табып булмас иде. Ай-һай, нык комачаулый аңа бу Лихачев!

Яковкин укучыларны берәм-берәм кабинетына чакырды. Үгет-нәсихәт, юмалау, янау, куркыту — һәммәсе эшкә җигелде. Аның яныннан чыкканда малайларның күзләре кызарган була иде.

Надзирательләр төн ката йокы бүлмәләрендә чуалалар, саксыз әйтелгән сүзләрне сагалап, ишек артларында посып тыңлап торалар. Әмма кем эше икәнен барыбер белә алмыйлар.

— Җүләрлек! Саташканлык! Фетнәчеләр үстергән тәрбиячеләр! Сукырлар! Властька буйсынмаучылар! — дип, аяк тибә-тибә акырына иде Яковкин.

Надзирательләр куркудан дерелдәп төшсәләр дә, инспекторга берничек тә ярдәм итә алмыйлар иде. Ул арада бунтарьлык рухы көннән-көн үсеп, көчәя барды. Коридорда пышылдашып кына сөйләшкән караңгы чырайлы гимназистларны очратасың, надзирательләр күренүгә алар шып булалар иде.

Директор Лихачев курка калды. «Укучылар арасында кузгалыш! Соң бу бит иҗтимагый тәртипсезлек, начальствога каршы оешкан төстә чыгыш ясау. Властьларга ишетелә калса... алла сакласын...»

Ул, алдын-артын уйламый, барлык укучыларга берьюлы җәза бирергә боерды: өч көн буе һәммәсен коры ипи белән суда гына тотарга!

Тәрбияләнүчеләрнең сабыры сынды. Җыелып килгән ачу-нәфрәт хәйләкәр Яковкинны кинәндергән чын бунтка әверелде.

Шимбә көн, дүртенче июнь җитте. Гимназистлар төшке аштан соң ишегалдына йөрергә чыктылар. Шулчак каралты-кураларны аерып торган биек койма артында авыртудан ыңгырашкан тавыш ишетелде. Укучылар койма ярыгына ташландылар: ат абзары алдында квартирмейстер поручик Михайлов капка каравылчысы булып эшләүче гарип солдатны таяк белән кыйный иде.

— Әйдәгез! — Дмитрий Княжевич боерык бирде.

Гимназистлар, барысы бердәм булып, ачык капкага ябырылдылар һәм шундук квартирмейстерны чолгап алдылар.

— Поручик әфәнде! — диде өлкән класс укучысы озын буйлы Иван Крылов.— Карт кешене, хөрмәтле Георгий кавалерын кыйнау — оят һәм хурлык! Бу — вәхшилек!

Михайловның шәфкатьсезлеге турында күп тапкырлар ишеткән укучылар күтәреп алдылар:

— Вәхши! Дәҗҗал!

Өлкән Княжевич экзекутор кулыннан таякны тартып алды. Поручик сүгенеп гимназистка ташлануга, Иван Крылов аның терсәгенә кагылды:

— Туктагыз, поручик әфәнде!

— Пугачев маймыллары белән сөйләшергә дә теләмим! Каһәр суксын! — дип акырынды квартирмейстер.

Дәһшәтле тавышлар аңа җавап булды. Поручик баскычка йөгереп менде һәм үз артыннан ишекне шапылдатып япты.

Яраткан надзирательләре Сергей Александрович Попов кына гимназистларны класс бүлмәләренә таралырга үгетли алды. Аларның таләбен Лихачевка җиткерүне дә үз өстенә алды. Таләп шуннан гыйбарәт иде: гарип кешегә карата шәфкатьсез мөгамәләдә булганы һәм гимназистлар намусын пычратканы өчен, квартирмейстерны эштән куарга!

Ләкин яшьләрнең бу изге омтылышына Лихачев бәя бирә белмәде, киресенчә, аларны тәртипсезлектә гаепләде, «котқы салучыларга» җәза бирергә вәгъдә итте, йокы бүлмәләренең ишекләрен бикләргә кушты.

Мондый чаралар гимназистларның ачуын кабартты. Княжевич, Пахомов, Алехин һәм Крылов, үзләре нәфрәт тоткан надзирательләр кичке ашка киткәч, аларның бүлмәләренә кереп караватларын ватып ташладылар, мендәр һәм түшәкләрен пычак белән кискәләп бетерделәр.

Икенче көнне өлкән класс укучылары: «Квартирмейстерны эштән алмый торып, дәрескә йөрмибез»,— дип белдерделәр. Аларга урта һәм түбән класслар да кушылды. Гимназия советы, нишләргә белми аптырап, өч көн буе киңәш тотты. Ул арада «фетнә» кызганнанкыза барды. Кискен таләпләр яңгырады:

— Лихачевны куарга!

— Тагы озак түзеп торырбызмы?!

— Безнең аппеляцияне карамаса, директор үзенә үпкәләсен...

Лихачев курка калды. Ул гимназия бинасында да,

ишегалдында да сакчысыз күренергә җөрьәт итмәде. Совет утырышына да инспектор квартирасы аша кача-поса гына килә иде. Укучылар белән үзе очрашмый, аларны үгетләргә йә укытучыларны, йә надзирательләрне җибәрә иде.

Ләкин гимназистлар нык тордылар. Тугызынчы июнь көнне егерме сигез өлкән класс укучысы, кларнетта марш уйнап баручы унтугыз яшьлек Петр Балясников артыннан, советның «экстраординар» утырышы бара торган конференц-залга үтеп керәләр һәм Михайловны кичекмәстән эштән алуны таләп итәләр.

Яковкин коты алынган булып кыйлана һәм калтыранган тавыш белән директорның колагына пышылдый:

— Александр Логинович, безне тотып үтермәсеннәр тагы! Ризалашыгыз! — ди.

Запас ишек янында сакта торучы гимназистлар чыгу юлын томалыйлар. Лихачев ризалашырга мәҗбүр була.

Квартирмейстерны эштән алу турында ашыгыч приказ языла һәм аны шундук гимназистларга кычкырып укыйлар. Укучылар тынычланалар, таралышалар.

Кичен гимназиядә тынлык урнаша. Ләкин Яковкин бүлмәсендә төннең-төн буе шәм яна һәм каләм кыштырдый. Хәйләкәр инспектор, «буйсынмаучылар фетнәсен» иң кара буяуларда сурәтләп, губернатор Мансуров һәм халык мәгарифе министры граф Завадовский исеменә тырышып-тырышып рапорт яза. «Патша законы буенча эш йөртмәүче» Лихачев «галиҗәнапнең боерыгын үтәмәүдә» һәм дворянин Михайловны хаксыз рәвештә эштән алуда гаепләнә.

Яковкин, «коты алынган Лихачевка болай эшләргә мин киңәш бирдем», дип өстәргә генә оныта.

Доносның файдасы тия. Губернатор, ачуланып, берничә көннән хәрби часть чакырта.

Гимназиягә коралллы солдатлар килеп тула. Аларга ияреп Лихачев һәм генерал формасында юан гәүдәле Мансуров керәләр. Сак астында залга китерелгән укучыларны бер рәткә тезәләр. Үлем тынлыгы урнаша. Директор тантана итә. Ул Дмитрий Княжевич, Федор Пахомов, Иван Крылов, Петр Балясников, Петр Алехин...— барлыгы унсигез өлкән класс укучысының исемен атый. Гимназиянең даны һәм горурлыгы саналган укучылар кулга алына. Коралллы солдатлар аларны шундук карцерга алып китәләр.

Гимназия мәет чыккан йортка охшап кала. Тәрбияләнүчеләр иртәдән кичкә хәтле тавышсыз-тынсыз гына коридорда болганалар. Гаскәр китерелгәч, гимназиядә тагы да катырак тәртип урнаштырыла. Иптәшләрең белән аралашу тыела, шәһәргә чыгу тыела, туганнарың белән дә бик сирәк кенә очрашырга мөмкин. Әти-әниләргә язган хатларны цензура тагын да җентекләбрәк тикшерә башлый.

Музыка һәм бию дәресләре маршировка һәм мылтык белән эш итү алымнарын өйрәнү белән алыштырыла. Атта йөрү дәресе кертелә. Моның өчен ишегалды артындагы тау итәгендә манеж төзиләр.

Шулай итеп, гимназистларның буш вакыты бөтенләй калмый.

Хәрби укулар Коляга башта кызык тоела. Ишегалдында ать-двага атлап, җилкәңә агач мылтык асып йөрүе Яковкин дәресләрендә утыруга караганда мең күңелле. Шунысы начар: Коля хәрбиләрчә, бер үк вакытта кулны да селтәп, аяк белән дә таптанып тора алмый, гел берәрсенең үкчәсенә баса.

— Нәрсә син һаман бәтереләсең? Тагын аякка бастың бит,— дип кисәтте аны Миша Рыбушкин.

— Күкрәгемдә ут дөрли,— дип елмайды Коля.

— Кара син аны, янып китмә...

— Стройда кем сөйләшә?! — Таушалып беткән хәрби китель кигән унтер аларның сүзен бүлде.— Телегезне тыям хәзер мин сезнең. Йәле, алга чык! Аягыңны күтәрә төш! Ныграк атла! Аяк астыңда җир тетрәсен! Җәһәтрәк бул! Җәһәтрәк!..

Аның яныннан арыган-талган, әлсерәгән гимназистлар йөгереп уза. Кайберәүләренең инде аягын өстерәр хәле дә юк, ә дәһшәтле унтер һаман канәгать түгел, куалый да куалый.

— Ать-два, ать-два!.. Башыңны күтәрә төш! Югарырак! Кем ул анда ишәк кебек теркелди? Хәзер үк инспектор янына озатам үзегезне...

Гимназистлар унтер-офицерның Яковкин белән сөйләшүен белмиләр иде әле. «Укучыларны тәмам азындырдыгыз! Кыяфәтләре кыяфәт түгел. Җиде кат тирләре чыкканчы стройда йөртергә кирәк үзләрен»,— дип каты итеп кисәтте аны Яковкин.

Мондый занятиеләрдән соң Коля тәгәрәп йоклый иде. Башы да әйбәт эшли. Күчерү имтиханнарында ул, катехизис белән изге тарихтан кала, барлык фәннән «бик яхшы» билгесе алды. Июльнең беренче числоларында

рында, тантаналы җыелышта, башкалар белән бергә, аңа да алтын йөгерткән кысалы Мактау кәгазе тапшырдылар. «Тырышлык өчен», дип кат-кат укыды ул алтынланган хәрефләрне, үзе күңеле белән үткәннәргә кайтты. Менә энисе әйберләрен кәрҗингә тутырган, Макарьевка кайтып китәргә тора. Ә ул, күз яшенә буылып, энкәсенең муенына сарыла. Ул чагында аңлады шул аның күңелен энкәсе. Бер сүз каршы әйтмәде. Казаннан алар бергә киттеләр. Өйләренә кайткач, һәммәсе җайланды, берничә айдан соң Коля гимназиягә кире әйләнеп кайтты. Менә хәзер алтын хәреф белән язылган бу Мактау кәгазе икесенә дә бүләк иде. Энкәсенә тизрәк, тизрәк күрсәтергә кирәк аны!

Каникул да үтеп китте. Гимназистлар: «Укучылар арасында кузгалыш» исеме алган эш инде күптән онытылгандыр», дип уйлыйлар иде. Юк икән шул! Тикшерү тәгәрмәче һаман тәгәри торган икән!

Укулар башлангач, беркөнне Яковкин актлар залына барлык укучыларны, тәрбиячеләрне, хезмәткәрләрне җыйды. Губернатор Мансуров үзе килгән!

Гимназистлар, нидер буласын сизенеп, тынып калдылар. Инспектор Петербургтан, Халык мәгарифе министрлыгыннан яңа алынган карарны, бик канәгатьләнеп, кулын уа-уа укырга кереште:

— «Уку йортындагы тәртипсезлекнең төп сәбәпчеләре өлкән Княжевичны, Пахомовны, Алехинны, Крыловны гимназиядән аттестат бирмичә чыгарырга, калганнарын исә, ягъни Балясниковны, Петровларның икесен дә һәм өлкән Упадышевскийны бер атна буе ябылуда тотарга!..» дип язылган. Димәк, берсүзсез буйсыну таләп ителә! — диде инспектор. Аның кыяфәте шундый һавалы — танырлык та түгел: гәүдәсе төз, башын артка чөйгән, күзе ут яна.

— «Директор хезмәтен башкаручы надворный советник Лихачев, яшьләрнең әхлаксызлыгына юл куеп, бу явызлыкны бетерү өчен тиешле чара күрмәде һәм, ул эш фаш ителгәч тә, аңа көчәергә ирек бирде. Киләчәктә мондый буталчыклыкка юл куймас өчен, директор вазифасын гимназия инспекторы Яковкинга тапшырырга...»

Аның чыңлап торучы авазы бөтен дөньяга: «Менә ул власть! Чын власть. Ирештем!» дип, гөрләп сөрән сала кебек иде.

Коля абыйсы белән энесенә, иптәшләренә күтәрелеп карады. Саша ихтыярсыз калтыранып алды. Кеч-

кенә Алешаның йөзе үк төссезләнеп китте. Аксаковның түгәрәк йөзендә чиксез аптырау һәм каушау чагылды. Мишаның карашы гына берни аңлатмый, ул инспекторга каш астыннан сөзеп карап тора иде.

Кәгазь укылып бетүгә, укытучылар да бер-берсенә карашып алдылар. Губернатор Мансуров хәрби каравылда торучы солдатларны гимназиядән чыгарырга боерды. Тәрбияләнүчеләргә бүлмәләргә таралырга куштылар: бу истәлекле көнне дәрес булмады.

Коля көннең төнгә алышуын сизми дә калды. Ул, койма буендагы карт өянкегә текәлеп, тәрәз төбендә утыра иде. Ләкин аның күзе өянкене бөтенләй күрми дә, колагы да берни ишетми: ярылырга җитеп башы авырта. «Ничек була инде бу? — дип газапланып уйлый иде ул.— Гимназиядән иң яхшы укучыларны кудылар. Кыюлык белдергән, карт солдатны яклаган өчен генәме?.. Ярый әле берсе дә гафу үтенмәде, җиңүчеләр кебек горур булдылар...»

## 2

Кечкенә вә чандыр, чүл гарәбе кебек каралган унике яшьлек Коля, кулына таянып, олы гәүдәле энесе Алеша белән тәрәзә буендагы озын өстәл янында утыра. Ниһаять, укуда ул аны «куып җитте» һәм хәзер алар урта класска абыйлы-энеле йөриләр. Күптән түгел икесе дә «казна тәрбиясенә» күчтеләр, бүтәнчә әйткәндә, хәзер гимназиядә уку чыгымнарын алар өчен казна күтәрәчәк.

Гадәттә белемнең төп нигезе урта классларда салына, шуңа күрә монда укуы да күпкә авыр. Түбән классларда барлык фәннәрне бик шәп белүче малайлар да, урта класска күчкәч, еш кына «урта кул»дан уза алмыйлар. Коля байтак балаларның монда ике-өч ел утыруын белә. Әмма үзе бу хәлгә калырмын дип уйламый. Бүлмә укучылар белән «шыплап» тулган булганлыктан, укытучылар һәркемгә дә тигез игътибар бирә алмыйлар. Бәхеткә каршы, тарих һәм география укытучысы Яковкиннан кала барлык укытучылар да Коляны электән үк яхшы беләләр иде.

Һәркемнең мәхәббәтен яулаган Ибраһимов берьюлы өч фәннән — югары арифметикадан (алгебра), славян теленнән һәм әдәбияттан керә. Ул русча бик матур, тәэсирле итеп, искиткеч чиста сөйли, ара-тирә генә аерым сүзләрне бераз бозып әйткәли. Бөтен күңеле

белән әдәбиятка гашыйк, җор телле һәм талантлы бу укытучы үзенең укучыларын да мавыктыра белә иде. Ул беркайчан да кызып китмәс, тавышын күтәрмәс. Ә иң мөһиме — Ибраһимов дворян балаларына да, разночинец малайларына да бертигез карый. Тәрбияләнүчеләр, бигрәк тә яңалар, һәр нәрсәдә аңа охшарга — аныңча атлап йөрергә, аныңча сөйләшергә омтылалар. Алар укытучы яратып әйтә торган сүзләрне кабатлыйлар, ул мактаган малайларга көнләшеп карыйлар. «Мисаилыч» (укучылар аны үзара шулай йөртәләр) үз-үзен тотышы белән дә башка укытучылардан нык аерыла. Ул класска бернинди кыланусыз, һаваланусыз ачык йөз белән, әйтерсең лә озак күрешми торганнан соң туган йортына әйләнеп кайткан әти яки абый кеше кебек килеп керә һәм укучылар аның дәресен бәйрәм көткән кебек көтеп алалар.

Бүген славян грамматикасы дәресендә гадәти булмаган тынлык хөкем сөрә. Бу тынлыкны укытучының әледән-әле ишетелеп киткән тавышы гына боза. Бүген Ибраһимов яңа укучыларга әйтеп яздыра.

Алеша белән чиратлашып язганлыктан, Коляның буш чагы иде. Эшсезлектән нишләргә белмәгәнлектән, ул тәрәзәгә күз салды. Болытлы күңелсез иртә. Өстән сибәләп торган вак яңгыр кешеләрне тизрәк атларга мәҗбүр итә. Кинәт болытлар таралды, күк йөзе ачылды һәм тузанлы тәрәзә аша бүлмәгә кояш елмайды. Аның нурлары белән класска гүяки Ибраһимов дәресләренә генә хас җанлылык үтеп керде.

Коля кесәсеннән металл көзге кисәге алды да аны кояш нурына каршы куйды. Көзгедән төшкән яктылык соры, корымлы түшәмнән штукатуркасы коелган ак стенага, ә аннары тактага сикерде.

«Куян», һич көтмәгәндә, укытучының күзен чагылдырып үтте.

— Бу нинди хәл? — дип сорады сискәнүле тавыш белән Ибраһимов.— Кем «куян» уйната?

Класста берничә секундка тынлык урнашты. Коля җәһәт кенә урыныннан торып басты.

— Бу мин, укытучы әфәнде... Лобачевский... Николай.

— Һәм сиңа оят түгелме? — дип көтмәгәндә кызып китте Ибраһимов.— Үзең урта класс укучысы, үзең «куян» уйнатасың. Язмый утыруың җитмәгән, башкаларга да комачаулыйсың. Бар, чыгып кит класстан!

Оялудан һәм уңайсызланудан комач кебек булган Коля коридорга чыгып басуга, каршы яктан директор килгәне күренде. Аның артыннан, башын аска иеп, Сережа атлый иде.

— Сез монда нәрсә эшлисез? — дип сорады дәһшәтле тавыш белән Яковкин.

— Мин... мин чыктым... Илья Федорович...— дип мыгырданды, бөтенләй югалып калган Коля.

— Хәзер үк кире керегез! — дип кычкырды директор.— Барыгыз да дәрестән качу җаен гына эзлисез!

Коля кыяр-кыймас кына класс ишеген ачты. Аның артыннан ук Яковкин белән Сережа килеп керде.

Директор күренү белән, гимназистлар дәррәү торып бастылар.

— Николай Мисаилович,— дип сүз башлады директор ачулы тавыш белән.— Дәрес вакытында сорап чыгучы эшлексезләр сездә генә була! Моның өчен тәнәфес бар, ә дәрес барганда укучылар эш белән шөгыльләнергә тиеш... Кисәтеп куям: күрсәтмәләремнең үтәлүен мин катгый рәвештә тикшерәчәкмен!

Директор нотык сөйләгәндә укучыларның күзе Ибраһимовта булды: Лобачевский сорап чыкмады, ә класстан куылды, дип әйтерме, юкмы? Әйтсә, малайга каты җәза биреләчәк.

— Күрсәтмәгезне истә тотармын,— диде Ибраһимов, Яковкинга түгел, ә өстәлдәге журналга карап.— Лобачевский, утырыгыз!

Барысы да җиңел сулап куйды. Коля шыпырт кына үз урынына узды.

— Ә Аксаковны класс журналына теркәгез,— дип дәвам итте директор, башы белән Сережага ымлап.

— Ничек? Илле дүртенче итепме? Аксаков нишләп яңадан бирегә күчә? — дип каршы төште Ибраһимов.— Ул бит рус һәм славян грамматикасы буенча бүләккә лаек булды һәм...

— Аның каравы ул башка фәннәрдән берни дә белми,— диде директор кистереп.— Мин аны тагын бер елга урта класста калдырырга карар бирдем...

Укучыларга утырырга кушып, Яковкин чыгып китте. Малайлар пыш-пыш сөйләшә башладылар: Ибраһимов Коляга нәрсә әйтер икән?

Әмма укытучы, тынычланырга ишарә ясап, бернәрсә булмагандай дәресне дәвам итте.

Көндезге аштан соң, озын тәнәфес вакытында Сережа Лобачевский янына йөгереп килде:

— Урта класста булса булсын, аның каравы, сезнең белән бергә,— диде ул күтәренке тавыш белән һәм Коляны кулыннан эләктереп алды.— Әйдә бакчага чыгабыз. Сиңа әйтәсе сүз бар иде.

Бүген иртән булган күңелсез вакыйгадан соң әле исенә килеп өлгермәгән Коля ихтыярсыз аның артыннан иярде. Малайның уе һаман бер тирәдә бөтерелә иде: Яковкин Ибраһимовка нәкъ менә аның аркасында шелтә белдерде бит. Ә укытучы, аны коткарып калып, шелтәне үз өстенә алды. Аның бу изгелеген ни белән акларга мөмкин?

— Син мине тыңламыйсың да бит,— дип бүлдерде Коляның уйларын Аксаков. Дулкынланудан, ул маңгаена төшеп торучы чәченә ябыша һәм аны әледән-әле сыпыргалап куя иде.— Сизгәнсездер, Яковкин мине күралмый. Нәкъ Камашев кебек бәйләнә. Хәер, син Камашевны белмисеңдер дә әле. Моннан дүрт ел элек булды бу хәл... Мин ул чагында казна тәрбиясендә идем, ә Камашев инспектор иде. Аннан директордан да болайрак куркалар иде. Мине нәрсә өчен шулай күралмагандыр, белмим. Бөтенләй тын алырга да ирек бирмәде ул. Класска керә, китап-дәфтәремне тикшерә, укытучыларны миннән дәрес сорарга мәҗбүр итә, ә үзе тыңлап утыра иде. Бәйләнергә җай гына эзли. Бөтен кеше алдында мине, беләсеңме, кем дип атый иде? Елак, җебегән, әнисенең иркә малае дип. Бу хәлгә түзмәгәч, хәтта авыруга сабыштым, һәм мине бер елга өйгә алып киттеләр. Шул вакыт эчендә Камашев отставкага чыккан. Мине кабат бирегә китерделәр. Тик бу юлы казна исәбенә түгел, хәзер укыган өчен үзебез түлибез.

— Менә ничек?! — дип гаҗәпләнде Коля. Хәзер ул иптәшен игътибар белән тыңлый иде.— Син гафу ит, Сережа. Директор белән килеп кергәч, мин уйлап куйган идем... Бу, мөгаен, үзе шундыйдыр дип... Ә син теге кеше аркасында... Кем диден әле?

— Камашев.

— Камашев аркасында ике ел югалткансың икән.

— Коля, син дә бит...

— Шуңа күрә мин дә Яковкинны күралмыйм! — диде Коля, тавышын күтәрә төшеп.— Ярый, ә шуннан син ничек тагын бирегә килеп эләктең?

— Дөресен генә әйткәндә, мин, чыннан да, иркә малай булганмын,— диде Сережа чын күңеленнән, кызара төшеп.— Гел өйгә кайтасы килеп тора иде... Миңа шул Григорий Иванович белән Ибраһимов кына

ярдәм кулы сузды. Аннары... мин гимназияне дә, иптәшләремне дә бик яратам. Укуым да яхшырды. Хәзер математикадан кала барлык фәннән дә өлгерәм. Ибраһимов укыткан фәннәр турында әйтеп тә торасы юк. Аның дәресләрендә мин һәрвакыт беренче. Күңелемне күтәрүче, хыялымны канатландыручы ул булды бит...

Коля җанланып китте: яраткан укытучысы турында үзе дә нәкъ менә шушындый сүзләр әйтә алган булыр иде. Ләкин уңайсызланып кына болай диде:

— Ул безне дәрестә шигырь язарга өйрәтә. Беләсеңме, кайбер малайларныкы шундый шәп килеп чыга. Ә үзе, үзе ничек яхшы яза!

— Сөйлисе дә түгел! — дип җөпләде аны Аксаков.— Ә син беләсеңме, аны Казанның беренче шагыйре, диләр. Мәскәү университетын Корташевский белән бергә тәмамлаган. Латин, немец һәм француз телләрен бик яхшы белә. Өстәвенә, әле математик!

— Ә ул сиңа ничек ярдәм итте соң?

— Анысымы, ә анысы менә болай булды. Үзең беләсең, дәрес биргәндә аның класс буйлап йөри торган гадәте бар. Мин ул чагында яңа укучы идем әле. Шулай класс буйлап йөргән җиреннән кинәт кенә минем яныма җитеп туктады да сорый башлады. Сорый да сорый, сорый да сорый... Башта славян грамматикасы буенча куды. Мин сөйлим, ә ул елмая һәм хуплап башын селки. Аннан рус грамматикасы буенча: әле бер бүлекне, әле икенчесен. Ә үзе һәр җавабымнан соң елмаеп: «Бик дөрес, әйбәт!» — дип кабатлый. Җавап бирә-бирә хәтта арып беттем. Ә ул кинәт кулымнан тотты да класс буйлап алып китте. Үзем барам, үзем аның нәрсә эшләргә теләгәнлеген аңларга тырышам. Беренче өстәл янына алып килде дә: «Утырыгыз, сезнең урыныгыз менә монда!» — ди. Мондый бәхетнең төшемә дә кергәне юк иде. Аның миңа булган шундый яхшы мөнәсәбәтен аклар өчен тагын да тырышыбрак укый башладым.

— Искиткеч! — дип кычкырып җибәрде Коля, чын күңеленнән сокланып.— Ибраһимовны шулай ошатуыңа мин бик шат. Ул бит миңа да...— Уңайсызланып, бераз сүзсез торганнан соң, Коля тагын сорау бирде: — Ә син теге коры һәм каты күңелле кешене ничек ярата алдың?..

— Кемне? — дип сорады Аксаков, берни дә аңламыйча.

— Соң, теге инде... Корташевскийны? Ул сине нәрсәсе белән үзенә тартты?

— Әйе, аның акылы тегенди-мондый гына түгел! — дип сөйли башлады Сережа, кызып-кызып.— Григорий Иванович чын галим, алай гынамы әле, гимназиядә укыту өчен геометрия курсын ул үзе яза. Борынгы һәм хәзерге философларны күп укый. Ә латин һәм грек телләрен менә без синең белән русча сөйләшкән кебек яхшы белә.

— Ә син боларның барысын да каян беләсең? — диде Лобачевский шикләнә төшеп.— Син әллә аның классында укыйсыңмы?

— Соң бит мин аның өендә яшим.

— Ничек?! Күптәнме?

— Әллә кайчаннан бирле, инде ике ел,— дип җавап бирде Сережа, җанланып.— Ә бәлки миңа гына шулай озак тоеладыр. Мине этиләр яңадан гимназиягә китерделәр һәм үзләре түләп укыту шарты белән бергә урнаштырып киттеләр дигән идем бит. Китерделәр дә фатир эзли башладылар. Ә әнием Григорий Ивановичны гыйлемле дә, кырыс холыклы булганы өчен дә бик ихтирам итә. Ул аны тәрбиячем булырга, ягъни мине үзе янына алырга күндергән. Ләкин Григорий Иванович моның өчен акча алырга һич тә риза булмаган, ә фатир һәм ашау хакын уртактан түләргә тәкъдим иткән. Шуннан бирле мин аның янында торам...

— Ә кайда? — дип сорап куйды Коля.

— Грузинский урамда, Елагин йортында. Изге Варвара чиркәве һәм Себер заставасына якын гына... Башта ул миңа җиң сызганып чит телләрне, бигрәк тә француз телен өйрәтте.

— Йә, шуннан? — дип бүлдерде аны Лобачевский, түземсезләнеп.

— Өч ай эчендә тотлыкмыйча укырга өйрәндем һәм теләсә кайсы француз китабын аңлый ала башладым. Грамматика үз җае белән класста өйрәнелде. Әмма өйдә мин бер нәрсә дә ятламадым. Григорий Иванович миңа француз телендә басылган «Мең дә бер кичә» әкиятләрен яки «Дон Кихот»ны тоттыра һәм, укып, тәрҗемә итәргә куша. И-и, шундый күңелле китаплар буенча тел өйрәнүе ничек җиңел иде! Әйтерсең без укытучы белән гимназист түгел, ә агалы-энеле туганнар. Мин Григорий Ивановичны өлкән абыем кебек яратсам да, аннан бераз шүрлим дә. Ә бервакыт,— дип дәвам итте Аксаков, күңелле генә,— мин аның үз-үзе белән сөйләшкән һәм кычкырып көлгән чагына

тап булдым. Григорий Иванович кулына ниндидер математика китабы тоткан да уйнап яткан песи балаларына карап көлеп тора. Ул чагында аның йөзе шундый мөлаем, нарасый иде ки, мин, ирексездән, песи балаларыннан көнләшеп куйдым.

Сережа рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Хәзер гимназиядә уку минем өчен әллә ни кыенык та түгел,— диде ул, яшермичә.— Кайбер укытучыларның дәресенә генә даими йөрим, ә калган вакытны өйдә шөгыльләнәм. Бәлки директор әфәнденең шуның өчен дә ачуы киләдер. Тик шунысы бар, математиканы һич аңлый алмыйм. Григорий Иванович башта минем белән бик тырышып шөгыльләнде. Ул аңлатканда барысы да гади, аңлашыла кебек. Әмма берничә көн үтүгә бер генә формула да хәтердә калмый. Григорий Иванович, бик нык ачуы чыгып, миңа үзенең геометрия классына йөри башларга боерды. Берсекөннән ул анда яңа курс укыта башлый...

— Сережа, анда синең белән бергә миңа да барырга мөмкин булмас микән?

— Ә нишләп булмасын? — диде Аксаков.— Ярый, класска керергә вакыт! Йә, кем тизрәк барып җитәр! — дип кычкырып җибәрде ул һәм малайлар, берсен-берсе уза-уза чатыр чабып, китеп бардылар.

## 3

Геометрия классы күңелле авазлардан гөж килә: кыңгырау шалтырап, укытучы кергәнче, һәркемнең үзе турында сөйлисе һәм башкалар сөйләгәнне тыңлыйсы килә.

Такта янындагы ундүрт-унбиш яшьләрдәге киң җилкәле, тәбәнәгрәк буйлы малай иптәшләрен үзенә каратырга тырыша иде.

— Әфәнделәр! Әфәнделәр! — дип, бар көченә кычкыра-кычкыра ул кулындагы таушалган китабын селки. Алай гына игътибар булмагач, тәрәзә төбендә яткан төргәктән киң ак җәймә тартып чыгара, шуңа борынгы римлян кебек төренеп, урындыкка менеп бик мәһабәт поза ала.

Малайларга бусы ошап куйды, сөйләшүдән туктап, алар аңа текәлделәр.

— Әфәнделәр! — дип игълан итте гимназист тантаналы тестә.— Геометрия фәнен өйрәнүгә багышланган беренче дәресебезне башлыйбыз. Колак салып тыңлагыз! Гафил булып калмагыз!

Ул имән бармагы тырпайган уң кулын мәгънәле итеп югары күтәрде, сул кулындагы ачык китапка бераз иелә төшеп, нечкә тавыш белән көйләп сөйләвен дәвам итте:

— Ошбу Мусейон *га сезне, мөхтәрәм шәкертләрем, «Башлангыч» исемле китабымдагы тәгълиматларны зиһенегезгә салу максаты белән чакырдым.

Гимназистлар көлешә-көлешә оратор янына тупландылар. Уен ошап китте аларга.

— Мин өйрәтәчәк гыйлем билгеләмә, постулат һәм аксиомалардан башлана,— дип акыл сатуын белде оратор.— Ошбу фәнгә тирәнрәк үтеп керәсегез килсә, иң элек аның төп төшенчәләрен үзләштерергә тиеш булырсыз.

Оратор үзенең тыңлаучыларына кырыс караш ташлады һәм тагын да тантаналырак кыяфәттә сүзен дәвам итте:

— *Беренче билгеләмә.* Нокта — кисәкчекләре булмаган нәрсә ул... Үзләштердегезме?!

— Хөрмәтле «Евклид» галиҗәнапләре,— дип, карлыкканрак тавыш белән мөрәҗәгать итте тәрәзә төбендә утыручы озын буйлы, ак чырайлы гимназист,— ни өчендер минем башыма сыеп бетми: кисәкчекләре булмагач, ул нокта үзе дә юк дигән сүз түгелме соң?

«Пьедестал»ында бераз вакыт аптырап басып торган «Евклид» шулай да җавабын таба белде.

— Хөрмәтле Дмитрий Перевощиков әфәнде,— диде ул эре кыяфәт белән,— сезнең соравыгызга җавабымны Бруккерның «Философия тарихы» китабында әйтелгән сүзләргә таянып бирәм: «Философия — төшенчәләр ярдәмендә әйберләрнең сыйфатын һәм үзенчәлекләрен танып-белергә өйрәтә торган фән ул».

Шулвакыт арткы рәттән кемнеңдер:

— Юк, алай түгел, нәкъ киресенчә,— дип кычкырганы ишетелде. Ләкин гимназистлар, яңа уен белән артык мавыгып киткәнлектән, аңа игътибар итмәделәр.

— *Икенче билгеләмә!* — дип игълан итте «Евклид».— Сызык — киңлеге булмаган озынлык ул.

— Кара әле, «Казан Евклиды»,— дип кабат аның сүзен бүлдерде Митя Перевощиков һәм, тәрәзә төбеннән сикереп төшеп, такта янына килде.— Нәрсә булгаткан буласың әле?

---

* Мусейон — борынгы Александрия шәһәрендә фән үзәге.

Ул, акбур алып, кара тактага калын итеп сызык үткәрде.

— Менә сиңа сызык. Синеңчә, нәрсә, аның калынлыгы юкмыни? Ә нәрсә соң ул озынлык? Гомумән, башта сызык төшенчәсен билгеләми торып, озынлык турында сүз алып барырга мөмкинме?

«Евклид»ны уратып алган гимназистлар җанланып куйдылар.

— Хәйран чуалчык фән икән бу геометрия дигәннәре! — диде берсе төшенке күңел белән. Класс тынып калды.

Менә шул вакыт «Евклид» каршына зифа буйлы матур бер гимназист килеп басты. Моңысы да кулына китап тоткан.

— Кадерле укытучыбыз, рөхсәт итсәгез, сезнең өчен җавап бирер идем,— диде ул, көлүен көчкә тыеп.

— Рәхим ит, Саша... Лобачевский әфәнде! — дип, «Евклид» үзенең дәрәҗәсен саклап кына урындыктан төште.

— Миңа пьедестал кирәкми,— диде Саша, елмаеп, һәм кулындагы ачык китабын баш өстенә күтәрде.— «Казан Евклиды» безгә аңлатып бирә алмады... Менә бу китап «Кыскача математика» дип атала. Авторы — Фәннәр академиясе адъюнкты Румовский. Кереш сүзендә нәрсә язганын укып биримме, теләгегез бармы?

— Бар, бар! — дигән тавышлар ишетелде.

— Евклид аңлата алмаганны Румовский дигәннәре төшендерә алыр микәнни? — диде бер калын тавышлысы.

— «Гәрчә математика үзенең тәгәллеге ягыннан барлык башка фәннәрдән өстенрәк торса да, һәм аның башлангыч өлешен үзләштерү һәркемгә диярлек кирәкле булса да, аның ошбу кереш өлеше яңа өйрәнә башлаучыларның гайрәтен чигерә. Шул сәбәптән математикларны: сез математик хакыйкатьләрне танып-белүнең бүтән ысулын уйлап чыгарырга тырышмыйсыз, дип гаепләүләре мөмкин, әмма бу очракта аларны Евклидның үз падишаһына биргән җавабы аклый ала...»

Саша Лобачевский «Казан Евклиды»на серле итеп бер карап куйды һәм укуын дәвам итте:

— «Птолемей патша Евклидтан, математиканы өйрәнүнең болай ук кыен булмаган бүтән юлы юкмы, дип сорагач, Евклид аңар: математиканы үзләштерүдә хәтта патшалар өчен дә махсус ансат юл юк, дип җавап бирде, ди...»

Шулчак кыңгырау шалтырады. Укучылар үз урыннарына утырып җиткәнче, класска ышанычлы адымнар белән математикадан өлкән укытучы Григорий Иванович Корташевский килеп керде. Ул кулына журнал һәм юка китап тоткан, ә култык астына зур гына кәгазь төргәк кыстырган иде. Аның артыннан ук каравылчы карт күрсәтмә әсбап һәм җиһазлар тутырылган кәрҗин кертте.

Корташевский торып баскан гимназистларга кырыс гына күз ташлады да:

— Утырыгыз, әфәнделәр,— диде һәм, кафедрага да менеп тормастан, дәресне башлап җибәрде.

— Математиканы — төгәл фән теле, диләр. Чыннан да, әфәнделәр, математик хисаплауларны, кагыйдә, формула һәм теоремаларны белмичә торып, механика, физика, архитектура, артиллерия кебек фәннәрне өйрәнеп булмый. Әлеге фәннәрдән башка Ватаныбызның алга китешен, фәнни ачышлар ясалуны күз алдына китерергә дә мөмкин түгел.— Корташевский, зиһенен туплап, бер кавым сүзсез торды.— Әйе, шулай,— дип дәвам итте ул,— бүген без математиканың яңа өлкәсен — геометрияне өйрәнүгә керешәбез. Геометрия искиткеч зур «математика агачының» иң борынгы тармагы булып тора. Аны гадәттә Евклид исеме белән бәйлиләр. Ул...

Шулвакыт кемдер йөткереп куйды, гимназистлар кыймылдаша-пышылдаша башладылар. Корташевский сөйләүдән туктады һәм җиңелчә генә өстәлгә шакып алды. Класс тагын тын калды.

— Евклид,— дип кабатлады ул,— Христос туганга кадәр чама белән өч йөз ел элек яшәгән. Ләкин геометрия аңа кадәр үк барлыкка килгән. Геометрия грек сүзе, безнеңчә әйткәндә, ул җир үлчәүне, межа яруны аңлата... Әйе, әйе, гаҗәпләнмәгез. Бу фәннең исеме җисеменә бик туры килә. Мин борынгы геометрлар кулланган кайбер әсбаплар: линейка, почмаклык, циркуль, транспортир алып кердем. Алар ярдәмендә без киләчәктә төрле фигура сызачакбыз, шуларның зурлыгын, мәйданын үлчәячәкбез.

— Гафу итегез, укытучы әфәнде, сорау бирергә мөмкинме? — дип кулын күтәрде «Казан Евклиды».

— Фамилиягез?

— Панаев... Александр.

— Сорагыз, Панаев,— диде Корташевский ачык йөз белән.

— Сез, укытучы әфәнде, геометрия — җир үлчәү фәне, дидегез. Ләкин шундый кечкенә инструментлар белән җирне ничек үлчәмәк кирәк?

Корташевский, канәгатьләнү белдереп, башын селкеде.

— Хуп, урынлы сорау. Чыннан да, йөзләрчә чакрымга сузылган җирне ни рәвешле төгәл бүләргә, мәйданын үлчәргә мөмкин?!

Григорий Иванович каравылчы алып кергән корҗиннән шактый озын сүс бау һәм ниндидер тимер чылбыр тартып чыгарды.

— Әйтегез әле, сезнең фамилиягез ничек? — диде ул арткы рәттә мундирының алтын төймәсенә җеп чорнап-сүтеп уйнап утыручы кызыл битле һәм ут чәчле симез гимназистка.

Гимназист иренеп кенә торып басты һәм теләр авырлык белән әйләндереп җавап бирде:

— Овчинников... Дмитрий...

— Ярый, Овчинников, сезнеңчә, бу чылбыр нәрсә өчен кулланыла? Бәлки, сез аның ничек дип аталуын да беләсездер?

Овчинников, җавапны түшәмнән эзләгән кебек, карашын югарыга төбәде. Аннан кыюсыз гына сөйләп китте:

— Бу... ни бугай... мондый чылбырны әти Мәкәрҗә ярминкәсеннән алып кайткан иде. Эт бәйләү өчен, чөнки безнең эт гади сүс бауны тешләп өзә...

— Утырыгыз, Овчинников,— дип кырт кисте Корташевский.— Без хәзер этләр турында түгел, ә җир үлчәү турында сөйләшәбез.

Овчинниковның кашы җимерелде.

— Утырыгыз,— дип кабатлады укытучы тагын да кырысрак тавыш белән,— җебегезне алып куегыз да дәресне дикъкать белән тыңлагыз.

Аннары ул бөтен класска мөрәҗәгать итте:

— Хуш, бу чылбырның нәрсә өчен хезмәт иткәнен һәм ничек дип аталуын кем әйтеп бирер...

Кинәт иң арттагы рәттән кемдер акрын гына тавыш бирде:

— Укытучы әфәнде, рөхсәт итсәгез, мин җавап бирәм...

Бу ят тавышка гимназистлар һәммәсе дә борылып карадылар: кем булыр икән?

Стена буендагы арткы эскәмиядән уңайсызланып

кына Коля Лобачевский торып басты. Аның янәшәсендә, эчкерсез елмаеп, Аксаков утыра иде.

Симез гәүдәле Овчинников «чит» гимназистның мундирындагы ак төймәләрен күздән кичергәннән соң, иренен мыскыллы кабартып, барысына да ишетелерлек итеп әйтеп куйды:

— Ул безнеке түгел... Ул бит... куян-разночинец...

Бу сүздән соң Корташевскийның йөзе кинәт үзгәреп китте: куе кашы җыерылды, күз карашы кырысланды.

— Овчинников,— дип боерды ул катгый рәвештә,— чыгып китегез класстан! Инспектор янына барып, сезне тәртип бозганыгыз һәм иптәшегезне мәсхәрәләгәнегез өчен куып чыгарганымны әйтегез! Тизрәк кыймылдагыз!

Овчинников җыерылып килде һәм, башын аска иеп, тизрәк ишеккә таба атлады. Аны усал карашы белән озатканнан соң Корташевский Коляга таба борылды: югары класс егетләре арасына нинди дер могҗиза белән килеп эләккән бу кыю малайны аның кайда күргәне бар иде соң?

— Сез кем буласыз? — дип сорады ул, таркау уйларын тәртипкә салырга тырышып.

Көтелмәгән сорау малайны сагаерга мәҗбүр итте. Ләкин укытучының ягымлы карашы белән очрашкач, ирексездән, елмаеп җибәрде.

— Коля... Николай Лобачевский.

— Ә-ә, алайса сез Александрның туганы инде... Такта янына чыгыгыз, Лобачевский,— диде укытучы йомшак тавыш белән.— Менә сезгә чылбыр. Аның турында нәрсәләр сөйли аласыз.

Чылбырны тоткач, Коляның кулы дерелдәп китте. Шул үзе! Бу бит гимназиягә алар — Лобачевскийлар бүләк иткән чылбыр! Ләкин шунда ул дулкынлануын җиңеп, кәрзиннән казыклар, эккер, өчаяк алды һәм кырда туры сызыкның ничек үткәрелүе, туры почмакның ничек ясалуы турында җентекләп сөйләп бирде.

— Бу хакта борынгы Мисырда да белгәннәр,— диде Коля, нәтиҗә ясап,— ләкин андый эшләрне башкару өчен гарпедонаптлар...

— Кем, кем? — дип сорады укытучы, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

— М-м... ягъни шул замандагы җир үлчәүчеләр. Алар биш, дүрт һәм өч үлчәмдәге өчпочмак рәвешендә тарттырылган баудан файдаланганнар, кыска баулар

арасындагы почмакның турыпочмак булуын бик яхшы белгәннәр... Аннан соң мин ниндидер бер китапта укыган идем: борынгы Вавилонда үзәк урамнар туры почмак ясап кисешкәннәр. Димәк, анда да бу хакта белгәннәр...

Гимназистлар аны авыз ачып тыңладылар.

Кайнар канлы Панаев түзмәде, сабырлыгын җуеп, сикереп торды.

— Ә син, Коля, безнең гимназия ишегалдының мәйданын билгели аласыңмы?

— Нәрсә ул ишегалды! — дип кычкырып җибәрде икенче гимназист, Коляның җавап бирүен дә көтмичә.— Минем бабай геометрия булмаса канал да төзи алмыйсың дип сөйли иде. Ул Болак күпере сызымын эшләгән.

— Сызымнан башка яхшы бина салып булмый,— дип өстәде кайсыдыр.

— Менә ишеттегезме инде,— дип түгәрәкләде Корташевский укучылар фикерен,— геометрия бөтен җирдә дә кирәк икән. Бу зарурлык инде борынгы заманнарда ук туган.— Укытучы үзе алып кергән кәгазь төргәкне җәеп җибәрде һәм тактага беркетте. Бу — кулдан эшләнгән Борынгы Шәрекъ картасы иде.

— Борынгы тарих дәресләрендә сез төрле дәүләтләр географиясен өйрәндегез,— дип дәвам итте ул, озын таягы белән картага ишарәләп.— Һәм, мөгаен, Африканың төньяк-көнчыгышында урнашкан борынгы Мисыр турында укытучыгыз сөйләгәннәрне хәтерлисездер. Гомер-гомергә бу илне Нил үзәнлегендәге уңдырышлы җир туйдырып килгән. Ә елга тирә-юнендә иксез-чиксез ком чүле. Чүл гүя Нилне һәм яшел үзәнлекне, анда күптәннән яшәүче кешеләрне күмеп китәргә җыена. Ләкин куәтле елга әлегә дәһшәтле комга бирешми.

Мәгълүм ки, җәй башының эссе кояш нуры Абиссин тауларының кар түбәләрен эретә һәм Нил үз ярыннан ташып чыгып, бөтен үзәнлекне су баса торган була. Калку җирләрдәге шәһәр һәм авыллар ташу вакытында аерылып утрау-утрау калалар. Халыкның үзара бәйләнеше өзелә. Һәм ташкын суның җимергеч көчен буйсындыру өчен, борынгы мисырлыларга ясалма дамба һәм буалар төзергә туры килә.

Нил дүрт ай буе диярлек ярсына, аннан кабат элекке эзенә төшә, ә үзән туфрагы туйганчы су эчеп, куе ләм белән ашланып кала. Шул ук вакытта җир билә-

мәләре арасындагы ызаннар да юыла. Уңдырышлы туфрак бик исәпле булганлыктан, кыйммәтле җирне ияләренә гадел һәм дөрес бүлеп бирү бик мөһим. Шуңа күрә борынгы мисырлыларга җир үлчәү фәнен, ягъни геометрияне яхшы белү кирәк булган. Сугару каналларын, фиргавеннәргә мәһабәт сарай һәм табут-пирамидалар төзегәндә дә, үзенең аңлатмасында Николай Лобачевский бик дөрес әйткәнчә, һәрбер шәһәр төзелешендә дә геометриядән башка эш итеп булмаган...

Корташевский тынып калды. Үзенең геометрик белеме белән укучыларны һәм укытучысын таң калдырган ябык гәүдәле, куе бөдрә чәчле малайга күз ташлады.

Бу вакытта Коля, кымшанырга һәм сулыш алырга да куркып, игътибар белән укытучыны тыңлый иде. Аңа борынгы заманның бөек математиклары турында абыйсының да сөйләгәне бар, бу хакта үзе дә күп китап укыды, әмма геометрия тарихы турында ул кабат-кабат тыңларга әзер. Укытучы шундый җанлы һәм мавыктыргыч итеп сөйли ки, аны тыңлаганда моннан дүрт мең ел элек булган хәлләрне үз күзең белән күргән кебек тоела.

— Борынгы Вавилонда, Һиндстанда, Кытайда, Грециядә дә,— дип дәвам итте Корташевский,— шулай ук җир биләмәләрен үлчәгәннәр, су корылмалары һәм зур биналар төзегәннәр, савытларның күпме су сыйдыруын исәпләгәннәр, күктәге йолдызларны өйрәнгәннәр. Шулай итеп, геометрия өлкәсендә бик күптөрле мәгълүмат тупланган. Ләкин бу вакытта әле кешенең табигать өстеннән хакимлеген күп тапкырлар арттырырга мөмкинлек биргән чын фән булмаган,— дип кабатлады укытучы, басым ясап.— Фән кайчан туа? Фән ул, дусларым, кешеләр күзәткән күптөрле күренеш арасыннан иң гомумиләрен аерып алырга өйрәнгәч, тәҗрибә ярдәмендә мәгълүматлар җыю һәм әйләнә-тирәдәге үзгәрешләрне гади күзәтү белән генә чикләнмичә, бу үзгәрешләрнең нинди сәбәпләр аркасында, табигатьнең нинди законнары тәэсирендә килеп чыгуы турында уйлана башлагач барлыкка килә. Борынгы греклар әнә шундый кызыксынучан, эзләнүчән булганнар.

Табигатьтә кайчак шулай була: яз салкын килү сәбәпле күтәрелеп китә алмаган үсемлекләр, җылы көннәр җитү белән, котырып үсә башлыйлар. Моннан ике мең ел ярым элек тә шуңа охшаш хәл булган: гүя

вулкан атылган сыман, антик цивилизация барлыкка килгән, бөек акыл ияләре калкып чыккан. Алар арасында иң күренекле шәхесләрнең берсе — геометрия кояшы — Евклид.

Кызганычка каршы, аның турында бик аз беләбез. «Зенарх улы Наукратның улы, Геометр дип мәгълүм булган Евклид милләте буенча — грек, яшәү урыны — Сурия, чыгышы белән Тирдан...» XII гасыр гарәп чыганагы буенча аның бөтен тәрҗемәи хәле менә шул. Кайбер тарихчыларның фараз итүенә караганда, ул Афинада Платон шәкертләреннән белем алган, аннары сәнгать һәм фәннәрне химая кылучы патша Птолемей Беренче чакыруы буенча грек-мисыр дәүләте башкаласы Александриягә күчеп килгән, шундагы Мусейонда — фән сараенда үзенең математика мәктәбенә нигез салган. Бу хәл үзе генә дә аның зур галим һәм педагог булганлыгы турында сөйли...

Коля, сулыш алырга да кыймыйча, Корташевскийны тыңлый, аның күз алдына үткән гасырларның гаҗәеп картиналары килеп баса.

Әнә — нәрсәсе беләндер Мәкәрҗә ярминкәсенә охшаган, төрле телдә сөйләшүче халык белән тулы шәһәр. Тик ул Идел ярларында түгел, зәңгәр сулы Урта диңгез буенда урнашкан. Урамнарда — греклар, мисырлылар, гарәпләр, яһүдләр; һәркайда кәрҗин яисә кувшин күтәргән сатучылар мәш килә. Бәйдәге ишәкләр үкерә, дөяләр тыныч кына күши...

Шәһәрне төрле корабль, мачталы зур көймәләр тулы гавань урап алган. Ул чакта Александрия дә, Мәкәрҗә кебек, дөньяның бөтен илләре белән сәүдә иткән. Баш гаваньга керү юлында, уң якта, Фарос утраучыгы. Аның таш кыясында өч яруслы — күккә ашкан — гаҗәеп маяк күренә. Ә утраучыкны яр белән тоташтырган буаны ике канал кисә, анда җәяүлеләр өчен ике күпер салынган. Шушы каналлардан кораблар бер гаваньнан икенчесенә иркен күчеп йөриләр.

Александриянең горурлыгы — музалар сарае Мусейон. Аның ботаник һәм зоологик бакчалары, обсерваториясе, анатомия театры, бергәләшеп шөгыльләнү һәм ялгыз эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләре, шәкертләр һәм галимнәр ашханәсе (алар барысы да дәүләт тәрбиясендә), зиннәтле ял парклары, йөз меңнәрчә төргәк-томнары һәм алар арасында Платон вә Аристотель кулъязмалары булган бай китапханәсе. Биредә чын

математик, астроном, философ, тарихчы, шагыйрь, рәссамнар яши һәм эшли.

Мусейоннан туп-туры Птолемей сараена илтүче Патша юлы салынган. Бу — шәһәрнең иң җанлы һәм иң бай урамы. Биредә бик еш кына киң маңгайлы, бөдрә сакаллы, өстенә тога * кигән мөхтәрәм картны очратырга мөмкин. Аңа барысы да олылап юл бирәләр: патша кадәр патшаның мөгаллиме — Евклид килә. Ул сәлам бирүчеләргә түбәнчелек белән җавап кайтара. Шәһәр кешеләре аны керсез намуслы, тыныч холыклы, тыйнак һәм фәнгә җаны-тәне белән бирелгән укымышлы буларак беләләр. Халыкта шундый риваять йөри. Евклидтан әле яңа гына геометрия сабагы ала башлаган яшь егет беренче дәрестән соң ук: «Ә моннан миңа ни файда соң?» — дип сорый. Шул чагында Евклид колын чакыртып китерә дә аңа болай ди: «Син бу егеткә бер тиен акча бир, аңа белем кирәкми, ул үзенә файда гына эзли...»

Буш вакытын Евклид китапханәдә үткәрә, биредә Анаксимандр, Пифагор, Демокрит, Гиппократ, Евдокс һәм башка бик күп акыл ияләренең кульязмаларын өйрәнә. Геометрияне фән итү өчен, моңа кадәр билгеле булганнарның һәммәсен бергә тупларга, аерым кисәкләрдән бербөтен булдырырга кирәклеген аңлый ул.

Менә ул, уйга чумган хәлдә, Мусейонның җиләс бакчасында йөри. Тынлык. Бакчада бары тик пальмалар кыштырдавы гына ишетелә...

Коля, шушы картинаны күз алдына китереп, күзен йомды. Шулвакыт, әллә йоклап киттеме дип шүрли калган Сережа, башкаларга сиздермичә генә аның кабыргасына төртте.

Ниһаять, геометрия тарихына сәяхәт тәмам. Корташевский өстәлгә төрле модельләр урнаштыра башлады, аннан, бу эшеннән кинәт кенә бүленеп, дулкынлануын яшерә алмыйча, класска мөрәҗәгать итте:

— Әфәнделәр, бөтен гомерегез буена исегездә калдырыгыз: теләсә кайсы башка фән кебек үк геометриянең нигезләре дә тәҗрибә юлы белән табигатьтән, төрле җисемнәрнең үзлегеннән алынырга тиеш, чөнки, күренекле ватандашыбыз Ломоносов әйткәнчә, кешенең практик эшчәнлеге тормышны танып-белүнең нигезе булып тора...

---

* Борынгы римлыларда ирләр кия торган өске кием.

Корташевский, өстәлдән кечкенә катыргы тартма алып, сүзен дәвам итте:

— Кайсы гына предметны алып карасак та, без аның өч үлчәнеше, ягъни, озынлыгы, киңлеге, биеклеге булуын күрербез. Менә шушы тартма белән класс бүлмәсен генә алыйк. Табигатьтәге башка предметлар кебек үк, аларның да өч үлчәнеше бар, әмма зурлыклары төрлечә. Ә менә бу агач кубикның өч үлчәнеше дә бертигез. Чуен ядрә яки бильярд шары исә пространствода бөтенләй үзгә урын, ягъни башка форма биләп тора. Димәк, без тирә-юньдәге предметларның үлчәмнәрен дә, формаларын да аера белергә тиеш...

Григорий Иванович түш кесәсеннән сәгать чыгарып аңа күз салды һәм башын чайкап куйды.

— Һм-м, вакыт бик аз калган икән, ә мин сезгә бүген төп геометрик төшенчәләрне дә аңлатырга уйлаган идем. Күрәсең, өлгермәбез.

Гимназистлар, бер-берсен бүлдереп, шаулаша башладылар:

— Өлгерәбез, Григорий Иванович, өлгерәбез! Без тәнәфескә чыкмыйбыз, сез сөйләгез!

Корташевский елмаеп җавап бирде:

— Алай ярамый, әфәнделәр. Вакытында укып, вакытында ял итә белергә кирәк... Мин сезгә бүген геометрик җисем турында беренче төп төшенчәне генә аңлатырмын. Нәрсә ул өслек, сызык һәм нокта — без хәзер шуларны ачыкларбыз һәм сезнең өй эшегез дә шушы темадан булыр. Дәреслек итеп Тимофей Осиповскийның «Математика курсы» дигән китабын файдаланыгыз. Аның икенче томы геометриягә багышланган. Ул китапны Гостиный дворда, Пугин кибетеннән сатып алырга мөмкин. Гимназия китапханәсендә дә бар.

Гимназистларга өй эше яздырганнан соң, Корташевский геометрик җисемнең нәрсә булуын аңлата башлады.

— Сезнең барыгызга да аңлаешлы булсын өчен, әфәнделәр, без менә мондый бер мисал алыйк...— Укытучы кәрҗиннән ниндидер сыеклык салынган пыяла колба һәм, гимназистларны гаҗәпкә калдырып, гади салам алды.— Менә монда сабын суы,— дип дәвам итте ул һәм колбаны тәрәзә төбенә урнаштырды. Аннан кинәт көлеп җибәрде.

— Сезнең сабын куыклары җибәрергә өйрәтеп торасы юктыр?!

Укучылар җанланып киттеләр, ә Корташевский саламның изелгән башын суга манчып алды да аның икенче очыннан сак кына өрә башлады. Салам очында сабын куыгы хасил булды. Ул, кояш нурына җемелди-җемелди, зурайганнан-зурая барды. Аннан саламнан аерылды һәм, һавада салмак кына йөзеп, ачык тәрәзә аша урамга очып китте.

Класс бер мәлне гөр килеп алды.

— Очты бит, очты!.. Тагын җибәрегез әле...— дигән тавышлар яңгырады.

Укытучы, елмаеп, бер-бер артлы берничә куык очырды: икенчесе, өченчесе, дүртенчесе... Алар күңелле җемелдәп, кояш нурында төрле төс белән уйнап, тәрәзәдән тышка оча тордылар.

— Ә хәзер миңа чуен шарны бирегез,— диде Корташевский, укучыларның берсенә мөрәҗәгать итеп.— Рәхмәт. Сабын куыгы һәм шар. Аларның нинди дә булса уртак сыйфатлары бармы?

— Алар икесе дә түгәрәк,— дип тавыш бирде кайсыдыр кыюсыз гына.

— Бик дөрес,— дип раслады Корташевский,— куык белән шарның формасы бер үк. Шуңа күрә, үзләренең физик үзлекләре һәм зурлыклары белән аерылсалар да, алар бер үк геометрик җисемне — шарны тәшкил итәләр. Кыскасы, мондый нәтиҗә ясарга була: физик җисем — билгеле бер пространствоны биләп торучы материя ул, ә геометрик җисем — материя биләп торган, яки биләп торуы мөмкин булган пространство гына. Сабын куыгы геометрик җисемнең бик шәп моделе. Буп-буш булса да, бездә шар турында тулы бер төшенчә тудыра. Менә тагын бер тапкыр карагыз әле...

Григорий Иванович янә саламга өреп алды һәм һавада салават күпере төсле балкып тагын бер куык хасил булды. Шулвакыт коридорда кызу-кызу тәпелдәгән аяк тавышлары һәм кемнеңдер ярсып сөйләве ишетелде: «Директор әфәнде, нинди хурлык! Бу класста гимназистлар дәрес вакытында сабын куыгы очыралар... Ышанмыйсызмы? Губернатор Мансуров үзе күрде. Без гимназия каршында басып тора идек һәм кинәт...»

Каты итеп тертүдән дөмбердәп класс ишеге ачылды. Бусагада төсе киткән һәм сулуы капкан Яковкин басып тора иде. Корташевский аңа тыныч кына күз ташлады да бармагы белән җәһәт кенә саламга чиерт-

то: һавага тагын аллы-гөлле бер куык күтәрелде. Класс тынсыз калды. Шаккаткан Яковкин, ниһаять, иснә килде һәм аның күзе салкын ялтырап китте.

— Алай икән! — дип уһылдап куйды ул һәм, ишекне каты итеп ябып, класстан җилле генә чыгып китте.

Шул ук минутта колакларны ярып кыңгырау шалтырый башлады. Ләкин бу минутны гадәттә түземсезләнеп көтеп алган гимназистлар аны әйтерсең ишетмәделәр. Алар, сихерләнгән төсле, укытучыдан күзләрен ала алмыйча утыралар иде.

— Николай Лобачевский,— диде Григорий Иванович,— сез бүген минем дәрескә керер өчен үз классыгыздан киткәнсез. Моңа сезнең рөхсәтегез бар идеме?

Коля урыныннан торып басты, башын аска иде һәм уңайсызланып җавап бирде:

— Юк... рөхсәт алмаган идем мин.

Корташевский кашын җыерды.

— Григорий Иванович,— дип сүзгә кушылды шунда Аксаков.— Сез аны гафу итегез инде. Сезнең дәресегездә буласы килде. Ул геометрияне үлеп ярата...

Ләкин укытучы Аксаковка башын бормыйча гына әйтте:

— Сезнең өстәр сүзегез юкмы?.. Алайса барыгызга да китәргә мөмкин. Ә сез, Лобачевский, калыгыз.

Гимназистлар, теләр-теләмәс кенә, класстан чыгып киттеләр.

— Ягез, яшь Коля, геометрияне тыңлау өчен сез кайсы дәрестән качтыгыз? — дип сорады Корташевский ягымлы тавыш белән.

— Катехизистан... алла законыннан,— дип җавап бирде Коля акрын гына.

Корташевскийның йөзе җитдиләнеп китте:

— Монысы бигрәк тә начар, Яковкин белә калса, сезгә нык эләгәчәк. Нишләп ахырын уйламадыгыз?

Коляның башы тагын да аскарак иелде.

— Уйладым,— дип җавап бирде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.— Тик бит, укытучы әфәнде, геометрия дәресләре башлануын мин ике ел көттем. Көн саен расписаниене карый идем. Ә геометрия булмады да булмады. Һәм менә хәзер аны кемдер өйрәнәчәк, ә мин... катехизис кануннарын тыңларга тиеш!.. Минем сездән күп кенә нәрсәләр турында сорыйсым килә иде.

— Нәрсә турында? — диде укытучы.

— Менә, мәсәлән, нишләп Евклидның китабы аңлаешсыз төшенчәләрдән башлана? Аларның бит үлчәү эшләре өчен дә, исбатлаулар өчен дә һич кирәге юк,— дип башлады Коля.— Укытучы әфәнде, нишләп кайбер нәрсәләр исбатлаусыз кабул ителә һәм постулатлар дип йөртелә, ә башкалары теоремалар, исбатлауны таләп итәләр...

Евклидны аңларга теләгән бу чандыр малай белән җитди кызыксына башлавы Корташевскийның йөзенә чыккан иде. «Их, дустым, олылар да аңлап бетермәгән нәрсәләр белән син иртәрәк, артык иртә кызыксына башлагансың», дип уйлап куйды укытучы, җавап көтеп басып торган Колягa карап. Ә җавап бирергә кирәк иде. Тик малайның чын белем эзләү юлындагы кызыксынуын һәм дәртен сүндермәслек итеп җавап бирергә кирәк иде.

Корташевский Коляның арык җилкәсенә кулын куйды да болай диде:

— Күрәм, безнең сөйләшү озын-озак булырга охшаган. Тик бередә урыны да, вакыты да түгел. Якшәмбе көн көндез, минем фатирга килегез. Кайда яшәгәнемне беләсезме? Юкмы? Ярый алайса, югары класс гимназисты Аксаков белән сез, ялгышмасам, таныш бугай?

— Сережа беләнме? — дип сорады Коля, кинәт җанланып.— Аны югары класска кире күчерделәрмени?

— Әйе, гимназия советы шундый карар чыгарды... Аның белән килегез. Тик бернинди аңлашылмаучылык килеп чыкмасын өчен, бүлмә надзирателеннән рөхсәт алырга онытмагыз. Минем исемнән әйтегез... Төшендегезме?

Шулчак ишек кабат дөмбердәп ачылды һәм бусагада яңадан Яковкин күренде. Буш класска күз йөртеп чыкканнан соң ул, очынып, Колягa ташланды:

— Сез нишләп монда, нишләп классыгызда түгел?

— Директор әфәнде, Лобачевскийны бирегә мин чакырттым,— дип ашыгып сүзгә кушылды Корташевский һәм, малайга таба борылып, болай дип өстәде:

— Минем сезгә сүзем бетте, китәргә мөмкин.

«Коткарды!» дип уйлады Коля рәхмәт хисе белән һәм тизрәк коридорга ашыкты. Ләкин чыгуга, кисәк кенә туктап калды.

«Минем өчен түгел микән?» — дип уйлап куйды ул.— Шулай булса, кире керәм!»

Лəкин Яковкинның чəрелдек тавышы аермачык ишетелə һəм класста сүзнең нəрсə турында барганлыгын аңларга мөмкинлек бирə иде.

— Корташевский əфəнде! Сезнеңчə, бу гимназиямə, əллə кəмит күрсəтү урынымы?! — дип кычкыра башлады ул, сүзенə буылып. Аннан, əле һаман өстəлдə тора биргəн кулланмаларга карап, мыскыллы тавыш белəн дəвам итте:

— Димəк, менə шушы уенчыклар белəн һəм сабын күбеге очырып гимназистларның күңелен күрəсез! Һəм боларның барысы да көпə-көндез, хəтта губернаторның борын төбендə эшлəнə! Адəм көлкесе! Нинди хурлык! Гимназиябезнең ярты гасырлык тарихында мондый хурлыкның əле булганы юк иде... Аңлашылмый, сез кем — укытучымы, əллə сəйяр фокусчымы?!

«Алай икəн! Димəк, минем аркада түгел...— Коля инде тəмам гайрəтен чигергəн үз классына таба атлады.— Григорий Иванович... менə, ичмасам, укытучы!»

Яковкинның сулыш алырга туктаганын сабыр гына көтеп торганнан соң, Корташевский үзен бик тыныч тотып җавап бирде:

— Директор əфəнде, сез бик əһəмиятле нəрсəне — күрсəтмəле укыту турында онытасыз. Аңлавы гаять авыр булган геометрияне өйрəнгəндə бу аеруча мөһим, чөнки...

— Аңлавы авыр? — дип чинады Яковкин, нəфрəтлəнеп.— Хак тəгалə зирəклеге салынган фəн авыр аңлашыламы? Бу бит динне мəсхəрəлəү! Ə сезнең сабын күбеклəре белəн шарлатанлык кылуыгыз...

Корташевский, чирканып, җилкəсен сикертте.

— Шарлатанлык?! Бу сүзлəрнең чын инану белəн əйтелүенə ышанасы килми. Авыр аңлашыла торган һəр нəрсə иң гади ысул белəн исбатланырга тиеш. Бу бит аксиома. Барысы да укучыларның кул астында һəм күз алдында булырга тиеш.

— Һаман да бер балык башын чəйнисез! — дип кычкырып җибəрде директор һəм, түземлелеген җуеп, йодрыгы белəн өстəлгə китереп сукты.— Яхшы, без сезнең белəн тиешле җирдə бəхəслəшербез əле.

— Бəхəслəшербез. Лəкин котырынмыйча гына! Бəхəстə дөреслек туа, ə кешелəр арасында ызгыш-талаш исə шайтан вəсвəсəсе...

— Нəрсə дидегез? Миңа шундый сүз? Я, кода! — Яковкин Корташевскийның нəфрəтле күз карашы астында, тиз-тиз чукынгалап, ишеккə таба чигенде.

Якшәмбе көнне үзләренең чиркәүләрендә төшке гыйбадәтне кылгач, казна исәбенә укучы гимназистлар төрлесе төрле җиргә таралыштылар.

Класслар, коридорлар, йокы бүлмәләре бушап калды, шунлыктан шау-шуга тонып беткән колакларга тынлык башта бераз сәер тоелды. Коля бер ялгызы калуына чиксез шатланды. Ичмаса, укып утырырга комачауламаслар.

Абыйсы аңа Румовский дәреслеген калдырып киткән иде. Артсыз урындыкны тәрәзә кырына китереп куйды да, китабын ачып, урамга күз салды. Көн бүген үзгәреп тора: әле кайчан гына вак яңгыр сибәләгән иде, хәзер менә сирәк болытлар арасыннан кояш күренде, дымлы һавада салават күпере хасил булды. Даң-доң чиркәү чаңнарын суктылар.

— Укырга ирек бирмиләр! — дип ачу белән үз-алдына сөйләнде Коля һәм, тәрәзәнең ике катын да ябып, китабына иелде.

*«Ике төрле математика китаплары басылып чыга,*— дип укыды ул пышын-пышын килеп.— *Кайберләрендә кагыйдәләр бирелеп, исбатлау китерелми, ягъни мисаллар ярдәмендә генә аңлатыла, ә икенчеләрендә, моннан тыш, исбатлаулар һәм төрле очракларны дәлилләү өчен сәбәпләр дә тәкъдим ителә...*

*Математик тәртип нидән гыйбарәт соң?..»* — «Малай бер минут чамасы уйланып торды.— Кая, карап карыйк әле!

*«Математик фикерләүләрдә хакыйкатьнең нигезе итеп иң гади, иң мәгълүм төшенчәләр алына, ә моның өчен, беренчедән, тәкъдим ителгән әйбер хакында ачык аңлаешлы билгеләмә, ягъни бер исемнән төрле мәгънәләр аңлашылмасын өчен теге яки бу сүзнең аңлатмасы бирелә. Аннары* аксиомалар*, *ягъни һичнинди исбатлаулар таләп итми торган, дәреслеге үзеннән-үзе билгеле булган чынлыклар китерелә... Математиклар шуннан соң кыенрак төшенчәләргә күчәләр, аңлашылмаган һәм исбат ителмәгән бернәрсәне дә нигез итеп алмыйлар. Берничә билгеләмә һәм аксиомаларның эчтәлекләреннән генә килеп чыгуы мөмкин булган раслаулар* теоремалар *дип аталалар...»*

---

* Аксиос — грекча ышанычлы дигән сүз.

Коля китапны тәрәзә төбенә ташлады һәм, уйга калып, чәчен кирегә сыпырды:

— Минә шәп әйткән, ичмасам! — диде ул, урыныгыннан кубып.— «Аңлашылмаган һәм исбат ителмәгән бер нәрсәне дә нигез итеп алмаска» ди бит! Академик Румовский шулай ди. Ә үзе нәрсә тәкъдим итә икән, укып карыйк әле...

Маңгаена төшкән чәчен алып ташлап, Коля тизтиз китапны актарырга керешге.

— Әһә!.. *«Теоретик геометриянең башлангыч нигезләре...*

Беренче билгеләмә. *Геометрик җисем — барлык якларга мәгълүм сузылышы булган нәрсә ул. Җисемнең сузылышы өслекләрдән, өслекнеке — сызыклардан, ә сызыкныкы — ноктадардан тора.*

Искәрмә. *Һәр әйбернең өч үлчәнеше, ягъни биеклеге, киңлеге һәм озынлыгы була, әмма бу үлчәнешләрнең берсен дә һичничек әйбердән аерып алу мөмкин түгел...»*

Коля, укудан туктап, кабат уйга калды. Григорий Иванович та нәкъ әнә шулай диде бит. Беренчел итеп әйберне алабыз, диде. Тагын нәрсә бар икән?..

*«Геометрик җисемнең билгеләмәсеннән күренгәнчә, аның турында төпле рәвештә фикер йөртергә керешкәнче, ноктадар, сызыклар, өслекләрнең яки яссылыкларның үзлекләрен тәгаен ачыкларга кирәк, моның өчен иң әүвәл ноктадан башлап, сызыкка күчәргә, сызыктан өслеккә һәм иң соңыннан геометрик җисемнең үзен ачыклауга күчәргә тиешле».*

Коля әрле-бирле йөренә башлады һәм, уйга бирелеп китеп, үзалдына сөйләнүен дә сизмәде:

— Моңа кадәр аңлап килдем... Һәммәсе аңлашыла иде. Ә менә монысы һич башыма керми. Ни өчен нокта, сызык һәм өслекнең үзлекләрен белмичә дә, геометрик җисем турында нигезле фикер йөртүе мөмкин булмасын икән? Григорий Иванович сөйләгәнне бик шәп аңлап бардым бит...

Коля кинәт кенә үзалдына сөйләнүдән туктады: ул тәрәзәдән очып чыгып киткән сабын куыгын һәм ишектән атылып кергән Яковкинны хәтерләде... Ләкин малай ул күңелсез күренештән бик тиз арынды. Кашын җыерып, яңадан уйга калды:

— Кем хаклы соң? Геометрияне нәрсәдән өйрәнә

башларга икән: ноктаданмы әллә табигатьтәге җисемнәрдәнме?.. Укып карыйк әле. Менә ич!

«Икенче билгеләмә. *Нокта — бернинди зурлыгы булмаган билге... кайбер галимнәр нокта дип өлешләре булмаган нәрсәгә әйтәләр. Ләкин ни рәвешле билгеләнүенә карамастан, шуны истән чыгармаска кирәк: математикада нокта дип аталган нәрсә, ул әйбернең үзендә булмыйча, безнең уебызда гына туа».*

Коля аңлаудан бөтенләй өметен өзде, шулай да кабат-кабат укып карады.

«Өченче билгеләмә. *Сызык — калынлыгы да, киңлеге дә булмаган озынлык ул».*

Менә аңлап кара син! Ничек була инде ул?.. Ноктаның һичнинди кисәкчекләре булмагач, аны кәгазьгә иң нечкә грифель белән дә тамгалый алмыйсың инде. Алай булгач, аны ничек итеп күз алдына китермәк кирәк?.. Ә сызыкны?.. Башта бит Румовский үзе үк, тәгаен аңлаешлы булмаган нәрсәне нигез итеп алмаска, дигән иде, хәзер нәкъ киресен эшли... Бәлкем, мин генә аңламый торганмындыр...

Коля шунда гына бүлмәнең эссе һәм бөркү икәнен сизде. Тәрәзәне ачып, урамга башын тыгып карады. Яңгыр чылатып киткән урамны кояш киптереп өлгергән. Чаң тавышлары әле һаман ишетелә. Еракта гармонь тарталар, күңелле җыр җырлыйлар. Ләкин Румовский дәреслеге һич тә тынгылык бирми. Шул турыда Григорий Ивановичтан сорашсам, ничек булыр икән?.. Ой, онытып җибәргәнмен! Сәгать унбердә кояш сәгате янында Аксаков белән очрашасым бар ич минем!

Малай китабын тумбочкага яшерде дә урамга йөгерде.

Ләкин билгеләнгән урында Сережа юк иде. Коля, гимназия бакчасының ышык кына бер эскәмиясенә утырып, көтәргә булды. Бераздан башы авыртуы кимүен сизде. Күрәсең, яфракларның үзара әкрен генә сөйләшүләре күңелне тынычландыргандыр. Куе яшеллек арасында берән-сәрән генә саргылт яки кызгылт яфраклар — көз якынлашканны белгертүче беренче билгеләр күренгәли иде.

Воскресенский урамда бәйрәмчә күңел ачып йөриләр. Көр атлар җигелгән зиннәтле фаэтоннарга купшы

киемле ханымнар, симез купец хатыннары үзләренең бала-чагалары белән утырган. Аларның ашыгыч эшләре юк, шуңа күрә ашыкмыйлар; кучерлар да атларга тик ара-тирә генә чөңгереп куйгалыйлар.

Коляның йөрәге әрнеп куйды. Әнкәсен искә төшерде... Әнкәсенең гомер эчендә бер затлы күлмәге булмады. Болар шикелле күңел ачып йөрергә аның вакыты да юк. Тизрәк гимназияне бетәрәсе иде. Сережа абзыкае кебек, землемер булып алыр иде. Әнкәсе турында бик-бик кайгыртыр иде. Михнәт күрүдән котылыр иде, бичаракай...

— Син нәрсә, көпә-көндез төш күреп утырасың? — дигән таныш тавышка ул уянып киткәндәй булды. Башын күтәреп караса — каршысында күм-күк күзле Сережа Аксаков басып тора. Сережа белән бергә аның тәрбиячесе Евсеич — мәһабәт кыяфәтле карт та килгән.

— Йокламыйм, уйга калганмын,— дип оялчан гына елмайды Коля.— Утырыгыз!

— Уйга калгансың...— дип кабатлады Сережа аның сүзен.— Кайберәүләр уй-хыялдан көләләр. Ә миңа калса — хыяллану бик яхшы гадәт.

Коля да җанланып китте. Иптәшенең сүзләре аның күңеленә ятты. Ләкин оялчан холкы аңа сүз куертырга ирек бирмәде. Ул арада Евсеич та үзенең барлыгын сиздерде:

— Сорарга рөхсәт итегез... Извозчикка утырасызмы, әллә җәяүме?

— Җәяү... җәяү.

— Алайса извозчикны җибәрәм.

Карт ашыгып китеп барды.

— Без базарда булган идек,— диде Сережа, Коля янына килеп утыргач.— Григорий Иванович сине кереп алырга кушты.

— Рәхмәт инде.

— Безгә җәяү рәхәтрәк, шулай бит. Моннан ерак түгел. Көне дә бик матур.

Коля аның сүзен раслап баш какты.

— Синең нигәдер кәефең юк кебек.

— Әй, һаман шул геометрия инде. Румовский китабына кереп баттым да һич чыгар хәл юк.

— Алай булса гына ярый. Григорий Иванович булышыр...

Тагын ярты сәгатьтән малайлар Грузинский урамындагы ике катлы йорт янына килеп туктадылар.

Кыңгырау бавын тарткач, асрау кыз ишек ачты һәм кабинетка кадәр озата барды.

Кыюсыз гына ишек шакыганнар иде, эчтән бик таныш көләч тавыш ишетелде:

— Керегез, кер,— диде.

Малайлар, бер-берсенә карашып, кабинетка керделәр.

Түрдә бик дәү язу өстәле. Өстәл өстендә төпләнгән һәм төпләнмәгән, зур һәм кечкенә китапларның күплегенә Коля хәйран калды. Ләкин шунда, өстәл артында утырган кешене күреп, Сережаны кулыннан эләктереп алды. Башына ука белән чигелгән түбәтәй кигән, сюртугын муенына чаклы каптырган, киң җилкәле кадерле укытучылары аларны ачык йөз белән каршылады.

— Нигъмәт... Николай Мисаилович?! — дип, куанычыннан кычкырып җибәрде Коля.— Мин бит әле...

— Сихер ярдәмендә Корташевский Ибраһимовка әйләнгән дип уйладыгызмы? — дип көлә-көлә, аның сүзен очлап куйды укытучы һәм алдындагы китабын ябып читкәрәк этте.— Әллә мине күрәсегез килмәгән идеме?.. Шулай дисәгез генә, юкса мин күңелсезләнә идем.— Ул, хәйләле елмаеп, малайларга каршы килде һәм, Сережаның аркасыннан сөеп, сорау бирде: — Минем Телемакның * хәле ничек?

— Яхшы, Нигъмәт абый.

Ибраһимов Коляга карап алды:

— Геометрия патшалыгында нинди уңышлар бар?.. Ишетүемә караганда, катехизис чаклы катехизис та сезне геометрия дәресенә качудан туктата алмаган.— Ибраһимов көлеп җибәрде, һәм аның кара күзендә очкыннар чагылды.

«Минем турыда барын да каян белә икән ул?» дип аптырады Коля.

— Качкан идем шул...— дип сөйләнде малай.— Тик менә геометрия мин уйлаганнан авыррак булып чыкты. Бүген өч сәгатькә якын Румовский дәреслеге белән утырдым. Тагын да ныграк бутала гына төштем...

Ибраһимов тәрәзә янына барып, аның ике канатын да ачып җибәрде. Бүлмәгә алма исе килеп керде. Яфраклар кыштырдаганы ишетелде.

— Сәламәтлекнең кадерен белмичә, ял көнендә дә китап укып утыруыгыз миңа ошамый,— диде укытучы,

---

* Т е л е м а х (Телемак) — Одиссейның улы (борынгы грек эпосыннан).

бераз сүзсез торгач.— Геометрия... геометрия ул усал ханбикә, аның өчен зирәк башың булу гына җитми, сәламәтлегең дә бер дигән булырга тиеш. Юкса аның гаскәрләрен — теоремаларын тиз генә җиңә алмассың. Искиткеч үзсүзле, чая сугышчылар. Сезгә ничә яшь хәзер? — дип, көтмәгәндә сорап куйды ул.

— Унике... тула.

— Ала-ай икә-ән,— диде Ибраһимов сузып кына.— Әтиегез бармы соң?

Коля кызарынып китте, аның өчен бу бик четерекле сорау иде.

— Барын бар да, безнең белән тормый.

— Юк дип исәпләргә була,— диде Ибраһимов уйчан гына, башын тәрәзәгә таба борып.— Аңа таяна алмаячаксыз, үзегезгә таянырга кала, үз көчегезгә. Тормышта көч күп сорала. Акыл да, шулай ук сәламәтлек тә бик кирәк була.— Кинәт ул, әсәрләнеп: — Бура уйный беләсезме? — дип сорап куйды.

Малайлар бер-берсенә карашып алдылар, тик инде Ибраһимов моңа игътибар итеп тормады, Сережаның аркасыннан кагып:

— Үткән якшәмбедә оттырганыгызны оныттыгызмыни, Телемак? Хәзер үк сарайдан бура таякларын алып чыгыгыз. Сәламәтлек шунда. Мин хәзер чыгып җитәм.

Малайларның үкчәләре генә ялтырады. Баскычтан атылып төштеләр һәм узыша-узыша сарайга таба йөгерделәр.

— Беләсеңме, ни өчен бура уйнарга ярата ул? — дип кычкырып сорап куйды Сережа.— Геометрияне яхшырак аңлар өчен! Менә күрерсең әле!

Малайлар таяк һәм чүрәкәйләр күтәреп Ибраһимов янына килгәндә, ул инде бакча ишеген ачып өлгергән иде. Кытай һәм энис алмалары белән сыйлангач, алар арткы капка аша бушлыкка чыктылар. Анда ни эшләргә белмичә каңгырып йөргән берничә үсмер малай бар иде, боларны күреп, йөгереп килделәр. Ике командага бүленеп уйнарга булдылар.

— Ну, геометр, белемеңне практикада күрсәт әле,— диде укытучы Коляга, «конверт» итеп тезелгән чүрәкәйләргә ымлап.

Коля оялып китте: моңа кадәр аның бура уйнаганы юк иде.

— Тизрәк инде, тизрәк! — дип ашыктырды Сережа...

Ул инде җайлырак таяклар сайлап алган һәм, түземсезләнеп, баскан урынында тора алмый иде.

Коля аткан таяк «конверт»ның өстеннән генә очып узды һәм ерак барып төште. Икенчесе дә тимәде.

Ибраһимов таяк тоткан кулын тырышып-тырышып төзәде дә «конверт»ка ыргытты. Таяк «конверт»ның нәкъ уртасына төшеп, берничә чүрәкәйне бәреп чыгарды.

...Уйный торгач мавыгып китеп, Коля үз яннарына Корташевскийның килеп басуын сизми дә калды.

— Ерактан сезнең чыр-чуыгызны ишетеп килдем... Исәнмесез, дускайларым! — диде Григорий Иванович һәм кинәт Колядан: — Лобачевский, Сергей Александрович сезне сәгать ничәгә чаклы җибәрде? — дип сорады.

Коляның чырае ап-ак булды:

— Рөхсәт сорарга оныткапмын,— диде ул.

Корташевский сәерсенеп:

— Аптыраган инде сезнең белән,— диде.— Яковкин кулына кабат эләгәсегез килмидер ич? Әйдәгез, Сергей Александровичка язу язып җибәрим. Сезнең китүегез турында, ихтимал, хәбәр итеп өлгермәгәндер әле... Городкины җыймый торыгыз, мине дә кызыктырдыгыз.

Кабинетына кергәч, ул тиз генә кәгазь алып берничә сүз язды һәм Коляга сузды.

— Хәзер инде сөйләшер чак түгел, икенче килерсез,— диде һәм китаплар арасыннан берсен алып сузды.— Менә Ломоносов биографиясе... Ә менә бу дәфтәрдә Радищевның «Ломоносов турында сүз»е. Укыганда сак булыгыз, начальство күзенә эләкмәгез. Хәзер йөгерегез!

Коля, укытучыга рәхмәт әйтергә дә онытып, ишеккә атылды.

## 5

...Очсыз-кырыйсыз кар диңгезе. Көчле җил исә. Күз ачып күз йомганчы кеше биеклеге көртләр өеп ташлый. Кар сибереп юлны күмә. Суытканнан-суыта бара. Туңмас өчен Коля йөгерә дә йөгерә, ләкин салкын аның җелекләренә кадәр үтә... Күз күреме җирдә һич бертөрле җан иясе юк.

Берзаман алда еракта ниндидер карачкы күзгә чалынган сыман була. Олау икән ич! Бер олау, ике, өч...

Кешеләр... Коля актык көчен җыеп йөгерә һәм олауларны куып җитә. Чаналарга туң балык төягәннәр. Арткы чанадан чуртаннарның ачылган авызлары күренә, гүя алар нәрсәдер әйтергә телиләр. Чү! Коля олаулар артыннан баручы киң җилкәле үсмер белән тигезләнде түгелме! Ул үсмернең аркасында капчык, адымнары кызу. Аның йөзе Коляга таныш төсле тоела. Кайда күрде икән?..

— Кая ашыгасың болай? — дип сорый Коля.

— Мәскәүгә, укырга барам,— дип җавап кайтара теге.— Исемем Михайло, фамилиям Ломоносов минем.

— Чынлап та шулай ич әле,— ди Коля, шатланып.— Мин сине таныдым. Бүген портретыңны күргән идем. Тик анда син бик олы. Хәзер ник бәләкәй? Син нәрсә, кирегә үсәсеңме әллә? Күр, ничек җил котыра. Кире кайтмыйбызмы?

Үсмер, үзсүзләнеп, башын чайкый.

— Гадәтем шундый минем,— ди,— юлга чыксам — кирегә борылмыйм. Эшкә тотынсам — бетермичә ташламыйм. Сиңа да шулай эшләргә киңәш бирәм...

Шул вакыт кар бураны бөтерелә — атлар, чаналар, авызларын ачкан туң балыклар һәм аркасына капчык аскан үсмер каядыр китеп югалалар.

Коля тагын берүзе генә. Ул кычкырып карый, ләкин аңар берәү дә җавап кайтармый. Карны ерып бара торгач, ул биек тау янына килеп чыга. Менә башлаган иде, бик тиз хәлдән тайды. Шул чак кайдандыр югарыдан Ибраһимовның: «Бирешмәгез, бирешмә!» дигән тавышы ишетелә. Соңгы көчен җыеп, ул тагын күтәрелмәкче була, ләкин аягы таеп китә дә түбәнгә оча...

Коля, куркынып, кычкырып җибәрде һәм күзен ачты. Одеялы идәнгә төшкән, ачык тәрәзәдән салкын җил өрә. Янәшәсендә Саша белән Алеша тыныч кына йоклап яталар. Коля тәрәзәне ябарга дип урыныннан торды. Кроватеннан идәнгә шапылдап китабы килеп төште. Ломоносов биографиясе. Әнә каян икән аның хәзер күргән төше! Ничек диде әле? «Юлга чыксам — кирегә борылмыйм. Эшкә тотынсам — бетермичә ташламыйм», дидеме? Яхшы төш. Гомереңдә онытмассың.

Сызылып таң атып килә иде инде. Коля китапны кадерләп кенә тумбочка өстенә куйды. Ләкин йоклый алмады. Мендәр астыннан теге серле дәфтәрне тартып чыгарды да, ишек ягын одеялы белән пәрдәләп, укырга кереште.

«Ата-анасының өендә ул юньле тәрбия алмаган,

тик шулай да белем ачкычына ия булган: укырга һәм язарга өйрәнгән, ә табигать аңарга кызыксыну кебек асыл сыйфат биргән...»

Гимназистлар һәммәсе йоклыйлар. Коля, инде укуга бер бирелеп киткәч, саклык дигән нәрсәне хәтереннән үк чыгарды, иңбашыннан шуып төшкән одеялын да сизмәде. Ул фәкать кулдан күчереп язылган юлларны гына күрде.

Кинәт ул абыйсының:

— Коля, минем янга килеп ят, бер сүз әйтәм,— дип пышылдаганын ишетте.

Саша йокламый икән. Бәлки, бүтәннәр дә шулайдыр? Малай тирә-ягына каранды. Юк икән, йоклыйлар икән. Ул абыйсы янына күчеп ятты.

— Син нәрсә укыйсың? — дип кырыс тавыш белән төпченергә тотынды абыйсы.— Баядан бирле карап ятам — нигәдер яшерәсең. Тыелган әсәр укыйсыңмы?

— Әйе шул,— дип җавап кайтарды Коля оялып кына.— Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт»е. Миңа аны Григорий Иванович бирде. Укыганың бармы синең?

— Бар,— диде Саша.— Ул әсәрне язган кешене императрица Екатерина Икенче Петропавел крепостена ябарга кушкан. Язучыны үлем җәзасына хөкем иткәннәр, ләкин асмаганнар, Себергә сөргәннәр.

Коля тын да алмыйча тыңлап ятты. Бер ара гына:

— Григорий Иванович миңа аларны сөйләмәде бит, өлгермәгәндер инде,— дип куйды.

— Беләсеңме, Радищев без Казанга килер алдыннан бер ай элек кенә үлгән. Кәгазьләрен актарып карасалар — «Киләчәк буыннар минем өчен үч алыр» дигән язу ята, ди.

Бераз вакыт, шул сүзләрнең тәэсиренә бирелеп, дәшми яттылар. Коля беренче булып телгә килде:

— Син, абый, нинди фәнне яратасың? — дип сорады ул.

— Философияне.

— Бөтен гомереңне шул фәнгә багышларга ризамы син?

— Риза булмыйча! — дип әсәрләнеп җавап бирде Саша.— Кешеләргә чак кына булса да файдам тиячәгенә ышансаммы!..

Бу сүзләргә Коля сөенеп бетә алмады.

— Мин дә шулай бит,— диде ул.— Тик менә син философияне яратасың, ә мин геометрияне... Хәзер үз

урыныма ятам: акай күз кергәнче, Радищевны укып чыгасым бар, бүген үк кире кайтарам...

Ул көнне Коля дәрес тәмамланганын түземсезлек белән көтеп алды. Аннан соң, рөхсәт сорап, Корташевский квартирасына китте.

Григорий Иванович аны ачык йөз белән каршы алды.

— Бүген надзирателегездән рөхсәт сорап килгәнсездер инде,— дип шаяртты укытучы.— Шулай булгач, утырыгыз да сөйләп җибәрегез. Нәрсә турында сорарга теләгән идегез?

— Геометрия турында. Ул фәнне ничек өйрәнергә? Нәрсәдән башлап җибәрергә?

— Уйлашып карыйк бергә-бергә,— диде Корташевский.— Әйтик, менә сез Ломоносов биографиясен укып чыктыгыз. Хәтердә саклар өчен нинди дә фикерләрен күчереп яздыгыз?

— Күчереп язмадым мин,— диде Коля, бөтенләй югалып калып.— Белмәдем мин... Яткан килеш кенә укыган идем.

— Аннысы жәл. Күрәсең, сез гомумән укыганда игътибар биреп җиткермәгәнсез. Нәрсәдән башлап җибәрергә икәнен Ломоносов турыдан-туры әйткән.— Корташевский китапны ачты.— Менә өченче биттән укып карыйк әле: «...зур белемле вә янә галим булу өчен латин телен белү зарурдыр». Бераз арырак киткәч, алтынчы биттә Ломоносов турында автор болай дип яза: «Бер ел эчендә ул латин телен шул чаклы яхшы үзләштерде ки, хәтта шигырь дә язгалый башлады. Аннан соң грек телен өйрәнергә кереште. Моның максаты Эллада математикларының хезмәтләрен үзгәртелеп тәрҗемә ителгән нөсхәләреннән укымыйча, төп чыганагында танышып, чагыштырып карау иде...» Менә шушы сүзләрне сезгә, һичшиксез, күчереп язарга кирәк булган...

Коля шатланып кычкырып җибәрде:

— Төшендем хәзер! Ләкин грек теленнән тыш, мин француз телен дә өйрәнергә телим.

— Күп булмасмы? — диде Григорий Иванович.— Ике кеймә койрыгын тотарга җыенасыз түгелме соң?

— Күп булмас. Мин «Дон Кихот»ны да, Шәһрезадәне дә укырга телим.

— Әнә эш нәрсәдә икән,— дип елмайды Корташевский.— Сережа ут салган бугай сезнең күңелгә. Ярар, алайса, өйрәнеп карыйк! Әгәр дә барып чыгарлык

булса, «Дон Кихот»ны француз телендә, ә «Башлангыч»ның грекча оригиналын бирермен мин сезгә.

Укытучы өстәл артыннан чыкты да этажерка янына килде, саклык белән генә күн тышлы бер китап алды һәм бик нык дулкынланып сүзгә керешә:

— Хәтеремдә, сез геометрия дәресендә: «Евклидның китабы ни өчен аңлашылмый торган билгеләмәләрдән башлана, ни өчен геометриянең төп кагыйдәләре шулай буталчык?» — дип сораган идегез. Җавапны, минемчә, менә шушы китаптан эзләргә кирәк. Бу китап Евклид «Башлангыч»ының иң беренче басмасы ук булмаса да, кем белә, бәлки, басу станогыннан чыккан китапларның тәүгеседер. Биредә «Башлангыч»ның грекча тулы тексты һәм шуларның латинчага тәрҗемәсе бирелгән. Борынгы классик әсәрләрнең берсенә дә бу китапка табынгандай табынмаганнардыр. Ул чакта ук инде бу китап бик күп телләргә тәрҗемә ителгән, бөтен илләрдә диярлек йөзләрчә мәртәбә күчереп язылган яки күчереп басылган. Соңгы елларга кадәр геометрия фәнен өйрәнүчеләргә бердәнбер дәреслек булып хезмәт итә ул. Ләкин бер генә китап та тәрҗемәчеләр, нәширләр, күчереп язучылар тарафыннан шушы «Башлангыч» кебек үк күп мәртәбә үзгәртүләргә дучар ителмәгәндер. Шуңа күрә геометриягә буталчык төшенчәләрнең кайчан, кайда, кем тарафыннан кертелүен ачыклар өчен, иң әүвәл грек телендәге менә шушы «Башлангыч»ны укырга кирәк.

Григорий Иванович тынып калды, күзен киң ачып, дулкынланып тыңлаган Коляга игътибар белән карап торды һәм кинәт, үзенең тиңдәше белән сөйләшкәндәй, яшерен серен ачып салды:

— Дөресен әйткәндә, мин үзем дә әлеге сораулар өстендә берничә елдан бирле баш ватам. Аларга җавап тапканда, геометрия генә түгел, башка фәннәр дә бик нык үсәр, алга китәр иде. Шул максат белән өйрәндем дә инде мин грек телен. Аннан гарәпчә дә өйрәнергә туры килде.

— Гарәпчә?! — дип кайтарып сорады Коля.

— Әйе, әйе! Ә беләсеңме ни өчен? Гарәпләр кайчандыр борынгы Греция белән яңа Европа фәннәрен тоташтырган арадашчы булганнар. Тугызынчы гасырның беренче яртысында ук инде Хәҗәҗ дигән галим Евклид «Башлангыч»ының тулы һәм кыскартылган тәрҗемәләрен эшләгән.— Корташевский өстәлдә яткан калын дәфтәрне ачты.— Кыскартылган курсның кере-

шенә менә болай язылган: «...Хәлиф Һарун әл-Рәшид патшалык иткәндә Хәҗәҗ, Евклидның «Башлангыч»ын тәрҗемә итү өчен, Византиягә җибәрелә. Әл-Мәмүн холиф булгач исә, Хәҗәҗ, әгәр дә яңа патшам өчен Евклид китабын кыскартып һәм гадиләштереп тәрҗемә кылсам, аны, әлбәттә, куандырыр идем, дип фикер йөртә!..» Шулай әшли дә Хәҗәҗ... Менә күрәсең,— дип елмайды Григорий Иванович,— Евклид бабаң белән чагыштырганда, Хәҗәҗ абзаң үз патшасына бирелгәнрәк галим була: ул аңа геометрия фәнен кыскарак юл белән төшендерү ысулын таба... Уникенче гасыр башында «Башлангыч» гарәпчәдән латинчага тәрҗемә ителә, ә 1482 елда, ниһаять, беренче мәртәбә китап булып басыла... Мин хәзер Евклид «Башлангыч»ының грек, гарәп, латин телләрендәге төрле басмаларын бик җентекләп чагыштырып утырам. Һәм мин ышанам, Лобачевский, грек телен үзләштергәч, сез дә миңа булышырсыз.

— Тырышып карармын,— дип җавап бирде Коля.— Бүген үк тотынырга исәп...

Корташевский яныннан ул кич белән генә кайтырга чыкты. «Француз, немец, латин телләрендә сөйләшергә өйрәтүче», «Грек теле лексиконы», «Грек грамматикасы» дигән китапларны, бик кыйммәтле әйбер алып кайткандай, күкрәгенә кыскан иде ул. Соңгы китап бигрәк тә кадерле иде аңа. Чөнки ул Мәскәүдә, кайчандыр Ломоносов укыган Славян-грек-латин академиясендә басылган. «Кем белә, бәлки, нәкъ менә шушы китапны кулына тотып, нәкъ менә шушы китап буенча укыгандыр да әле ул!..»

Шундый уйга бирелеп барганда, Коляның колак төбендә генә ачы тавыш яңгырады:

— Кит юлдан!

Коля күтәрелеп караганда, аның йөзенә орынырорынмас ат башы чалынып узды. Ниндидер хатын-кыз коты алынып чәрелдәп кычкырып җибәрде. Чак кына читкә тайпылып өлгерде егет — фырт кучер кукраеп утырган зиннәтле карета аның борын төбеннән генә выжылдап үтте.

Шунда гына Коля үзенең урам уртасыннан баруын абайлады. Китапларын күкрәгенә кыскан килеш, якягына карана-карана, урам аша чыкты да ул гимназия бинасына таба атлады.

Хәзер инде һәр көнне дәресләрдән соң буш классның аулак почмагында грек теле грамматикасы өйрәнә

яисә французча сүзләр ятлый, атнага ике тапкыр Григорий Ивановичтан дәрес тыңлый иде Коля.

Телләр өйрәнү, гомумән, җиңел бирелде аңа. Французчаны бигрәк тә ансат үзләштерде. Чөнки бу телнең күп кенә сүзләре ул инде яхшы ук белә торган латиннан алынган иде.

Шул рәвешчә өч айлап вакыт узып китте. Лобачевский французча инде шактый йөгерек укый, укыганын аңлый башлады. Үз системасы буенча сүзлек тә төзеп карады. Башта француз сүзләрен, янәшәгә аларның русча мәгънәләрен язып чыкты. Аннары инде әлеге сүзләргә мөнәсәбәтле башка төшенчәләрне терки барды. Әйтик, французча «өй»нең ничек дип әйтелүен белгәч, «дивар», «түшәм», «идән», «түбә», «ишек», «бусага» кебек сүзләрне ничек өйрәнмисең, ди!

Кайчагында, сүзләр белән мавыгып, Коля кичке аштан да мәхрүм калгалады.

Уртанчы Лобачевскийның грек һәм француз телләрен үзлегеннән өйрәнүдәге уңышлары нииндидер юллар белән директорга да барып ишетелде.

Һәм менә берчакны, кичке тикшерү вакытында, ул Коляны зал уртасына чакырып чыгарды һәм һич кызганусыз мактау сүзләрен сибә башлады. Менә нинди шәп егет, үзлегеннән телләр өйрәнә, тырыш, янәсе. Башкалар да аннан үрнәк алырга тиеш, янәсе.

Икенче көнне — якшәмбе иде ул — Коля, грек теленнән әзерләнермен дип, иртәнге аштан соң ук бүлмәсенә кайтты. Тагы бер сәгатьтән аңа Корташевский янына барырга иде. Тик өстәл артына кереп утырырга да өлгермәде, надзиратель аны директорга чакырды.

«Нәрсә кирәк икән инде аңа тагын?» дип уйлады Коля кабинет ишегенең тоткасына кулын куйгач.

Ниһаять, шакыды.

Эчтән директорның боерулы тавышы ишетелде:

— Керегез!

Коля керде.

Яковкин аңа аркасы белән әйләнеп, тәрәзәгә карап тора иде.

— Кем бар анда? — дип сорады директор, борылып карамыйча гына.

— Мин бу, Лобачевский.

— Ә-ә! Сезмени ул! — Яковкин кисәк кенә борылды һәм диван уртасына килеп утырды.— Узыгыз бирегә! Утырыгыз. Мин бик шатмын!

Коляны ул янәшәсенә утыртты. Бераз сүзсез торгач, Лобачевскийларны үз улларыдай яратуы, бигрәк тә аларның тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге, белемгә омтылулары аның күңеленә хуш килүе хакында сөйләп китте. Ләкин ул аларның сәләтләре тулысынча ачылып бетүен тели икән. Әле ул гына да түгел, шундый булдыклы укучылар өчен патша хәзрәтләреннән Казанда университет ачарга рөхсәт бирүен сораячак икән.

— Хак сүз сөйлим, хак сүз. Сез миңа шикләнеп карамагыз. Шуны аңларга тырышыгыз берүк: мин бит сезгә чын күңелемнән уңыш телим, Ватанга лаеклы кешеләр булып үсеп җитү өчен чын күңелдән ярдәм итәргә телим мин сезгә. Ә инде сезне әйбәт итеп тәрбияләр өчен, миңа әчке рухи дөньягызны белү зарури. Ә сез, кадерлем, миңа ярдәм итәргә теләмисез, минем алда ахыргача ачылып бетмисез. Мактамыйм мин сезне моның өчен.

Әңгәмә вакытында Илья Федорович шундый җылы, ягымлы сүзләр катнаштырып сөйләде ки, бермәлне Коля, элеккеге рәнҗүләрен, үпкәләрен онытып, кара, әйбәт кеше икән ләбаса бу, дип уйлап куйды.

Ул арада директор диванны шыгырдатып урыныннан торды да ишекне ныгытып ябып килде, шкафтан бер савыт варенье белән ак күмәч телемнәре алды һәм Коляга эндәште:

— Кил әле, дускаем, сыйланыйк әле!

— Рәхмәт, минем ашыйсым килми.

— Ә сез оялып тормагыз, килегез, кил, ашагыз! — диде директор боерулы тавыш белән һәм күз ачып йомганчы күмәч телеменә варенье ягып, Коляга тоттырды.

Коля телемне кыяр-кыймас кына алды, бер читен тешләп капты.

— Тәмле варенье, шулай бит? Ие, Макарьев вареньесы ул... Йә, ничек?.. Әниеңне, бабакаеңны сагынмыйсыңмы? Хәер, монда дуслар тапкансыңдыр инде. Сине Аксаков белән дус, диләр. Еш буласыңмы соң аларда? Ә син аша, аша! Оялып утырма.

Коля кыстатмады. Макарьево вареньесы булгач, бигрәк тә яратып ашады. Ә үзе эченнән генә һаман: «Күр инде, әйбәт кеше икән ич, ничек болай ялгыштым икән соң мин?» дип үз-үзен битәрләп утырды.

— Әйе, Григорий Иванович кебек укытучыдан дәрес алуы үзе бер бәхет инде,— дип дәвам итте директор.— Сез аның өенә дә барып чит телләр өйрәнәсез

икән бит. Аннан соң Корташевский җитәкчелегендә борынгы фәннәр тарихы белән танышасыз, безнең Ломоносов турында кайбер нәрсәләр беләсез, шулай бит?

— Шулай,— диде Коля.

— Радищев турында да укыйсызмы? — дип сорады директор малайның күзенә туп-туры карап.

Яковкинның чәнчүле һәм таләпчән карашын тоеп, Коля сагая төште.

— Радищев турындамы?.. Юк, аның турында бернәрсә дә ишеткәнем юк. Ә «Ломоносовның тормышы»н Макарьевода ук укыган идем.

— «Ломоносов турында сүз»не? — дип анықлап сорады директор.

— Юк, анысын укымадык. Класста да булмады. Әллә...

— Анысын мин болай, сүз уңаеннан гына сорадым. Син, Николай, акыллы һәм намуслы малай,— дип мактарга кереште аны директор.— Мин сиңа ышанам. Кара аны, онытма: мин синең дустың. Гимназиядә нинди яңалык ишетәсең — теләсәң кайсы вакытта минем янга киңәшергә кер. Әгәр кем дә кем кагыйдә боза икән, укучымы ул, надзирательме, берсен дә кызганма, туп-туры үземә кереп әйт. Мин һәрвакыт сине ачык чырай һәм дә,— директор елмайгандай итте,— тәмле варенье белән каршы алырмын.

Ләкин ирене елмайса да, карашы сагаюлы иде аның.

Директор белән сөйләшкәннән соң Коля үзенең йокы бүлмәсендәге тәрәзә каршында, кайнар маңгаен салкын пыялага терәп, озак кына уйланып торды.

Кичкә таба ул үзен начар хис итә башлады. Абыйсы төн буе аның янында утырып чыкты, ә иртән дежур лекарьны чакырды. Табип Бенес урынына килгән лекарь — Риттер фамилияле булып, авырулар һәм дарулардан бигрәк шәрабларны яхшырак белә торган кызыл йөзле, шат күңелле яшь кеше иде. Күптән түгел генә Казанда бизгәк чире таралганлыктан, ул һәрбер авыруга, аны-моны карап-тикшереп тормастан, күп итеп бизгәк даруы — хина агачының кайрысын һәм глаубер тозын бирә иде. Коляны күргәч тә ул: «Бизгәк инде, бизгәк!» дип кулын гына селкеде, авыруны палатага илтеп салырга боерык бирде.

Бал белән ике стакан чәй эчеп җылы юрганга төренгәч, Коля көне буе саташып, төш күреп яткан иде. Төнлә аның хәле тагын начарланды, йокысы качты,

температурасы күтәрелде. Саша кабат Риттерны чакырып китерде. Ул исә кулын уып: «Йә, ничек, егеткәй, терелләбезме?» дип шаяртып сөйләнгәч, Коля кайнар иренен генә кыймылдатып куйды һәм, күзен кыса төшеп, ут ягына борылды. Шул килеш бераз яткач кына көч-хәл белән терсәгенә таянды. Лекарь аның эчен капшап карады да хина дозасын арттырырга кушты. Бәхеткә каршы, ул киткәч үк палатага надзиратель Сергей Александрович килеп керде һәм, авыруны бик игътибар белән карагач, кирәкмәгән дарулар бирмәскә киңәш итте.

— Бизгәк түгел бу,— диде ул, икеләнергә урын калдырмаслык итеп,— суык тигән аңа... әйе, суык тигән...

Бер атнадан Коля савыкты. Ниһаять, лекарь аңа палатадан чыгарга рөхсәт бирде. Ә тагын бераз вакыттан соң, якшәмбе көнне ул Корташевский янына барырга да рөхсәт алды.

Тиз-тиз киенде һәм, китапларын култык астына кыстырып, урамга чыкты. Тротуарга аяк басу белән, аңа әллә нәрсә булып китте, башы әйләнергә тотынды... колоннага сөялеп кенә аяктан егылмый калды. Салкын саф һава кан тамырларына үтеп хәл кертеп җибәрде.

Төн буе котырынган буран иртән басылган, нурланып кояш чыккан. Зур-зур булып өелгән көртләргә карарлык түгел — күз чагыла. Дворниклар көрәк-себеркеләрен күтәреп кар көрәргә чыкканнар. Аларга ярдәмгә хатыннары, хәтта бала-чагалары да килгән иде.

«Григорий Иванович грек теленнән нинди сораулар бирер икән?..» Ирексездән малайның хәтеренә исемнәр һәм фигыльләр килде... Теләсә нәрсә сорасын, Коля һәммәсен белә.

Менә ул Григорий Иванович яшәгән Елагиннар йортына килеп җитте һәм, капка төбендә Сережа Аксаковның зур агач көрәк белән кар көрәвен күреп, туктап калды.

— Син түгелме соң?! — дип гаҗәпләнеп сорап куйды Коля, исәнләшергә дә онытып.

Ә аның дусты, бит алмалары алсуланып киткән Сережа, көлә-көлә көрәген җайлы гына итеп селтәп җибәрде һәм икесенең дә өстенә кар тузаны очырды.

— Күрдеңме абыеңны? Дворниктан көчкә алдым мин бу көрәкне. Бирмәскә маташа. Барин эше түгел ул кар көрәү, ди. Мин әйтәм аңа: фәннәрне үңышлы-

рак үзләштерү өчен, акыл сафлыгыннан тыш тән сәламәтлеге дә кирәк, дим. Син аякка баскан икәнсең инде. Әйдә, урамны бер урап килик!

Коля дустының теләгенә каршы килә алмады, әлбәттә. Сережа теленә һич тә ял бирергә уйламый иде.

— Мин дә бизгәк белән яттым бит,— диде ул.— Өч тәүлек Григорий Иванович янымнан китмәде. Беләсеңме...— Кинәт Сережа тотлыгып калды. Бераз уйланып баргач: — Беләсеңме нәрсә? — дип кабатлады.— Хәзер безнең арада укытучы белән укучы мөгамәләсе бетте, хәзер без иптәшләр, якын дуслар булып киттек. Аның 26 яшьлек галим икәнлегенә ышанасы да килми...

Сүзгә мавыгып китеп, Сережа дустының пальто сәдәбен тарткалый башлавын да сизмәде. Коля исе китеп тыңлый иде. Үзалдына сөйләнгән кебек сөйләнеп куйды:

— Иптәшләр, диген!.. Дуслар, диген!..

— Әйе шул! Өйдә мине аерым укыта. Гимназиянең кирәге дә калмады, ахры. Тик менә...— Сережаның кинәт башы аска иелде, аның аяк астына боз кисәге килеп эләкте, һәм ул аны тибеп очырды.— Тик менә математикадан эш пешми.

— Математикадан? — дип кабатлап сорады Коля, бик гаҗәпләнеп.— Арифметика белән алгебраның ние бар инде аның? Үзеннән-үзе башка кереп утыра. Геометрия дисәң инде...

— Үзеннән-үзе кереп утыра! — диде Сережа, көлемсерәп.— Ә менә минем башыма бүген кереп утырса, иртәгә җилләр исә. Еларга җитәм. Әдәбиятны, тарихны көч белән дә куып чыгара алмыйсың менә...

Малайлар кирегә борылдылар.

— Беләсеңме нәрсә? — диде Сережа, сүзен дәвам иттереп.— Григорий Иванович миңа әдәбиятка күбрәк игътибар бирергә куша. Ломоносов, Державин, Сумароков китапларын укытты. Әдәбият турында, шигырь турында сөйләгәнен тыңлыйсың да: их, язучы булсам иде! — дисең.

— Булырсың әле,— диде Коля уйчан гына.— Бәлки, синең тормыштагы юлың шулдыр. Бәхетле кеше син, Сережа!

— Юк шул,— диде Сережа, башын чайкап.— Алай ансат түгел ул. Беләсеңме, Григорий Иванович бәяне ничек саран бирә? Күптән түгел бер нәрсә язып ташладым мин. Ибраһимовка бик ошады. Ә Григорий Ива-

нович беләсеңме нәрсә диде? — Сережа уңайсызланып куйды, шуннан аңлатып бирүне кирәк тапты: — Тыңлап торган дип уйлый күрмә, алар күрше бүлмәдә кычкырып сөйләштеләр, шуны ишеттем. «Сережаның язмасына бүтән кеше әсәреннән җиде җөмлә килеп кергән, шуңа күрә бәя бирергә ашыкмыйк әле»,— диде. Аннары тагын...

— Тагын нәрсә диде? Аның үз сүзләре белән әйт син!

— Гомердә онытасым юк аның сүзен,— диде Сережа һәм, бер минут чамасы дәшми баргач, ашыкмыйча гына, күз алдында торган юлларны укыган сыман, тезеп алып китте: — Иң әүвәл үзенчәлекле һәм игътибарга лаек каләм осталары язган китапларны укып яшьләр үзләрендә матур зәвык тәрбияләсеннәр иде. Шуннан инде аларга каләм тибрәтергә мөмкин булачак...

— «Каләм тибрәтергә мөмкин булачак»,— дип кабатлады Коля.— Тибрәтеп тә рәт чыкмаса, нишләргә ди?

— Анысын әйтмәде... Ул чагында көчтән килмәслек эшкә тотынмаскадыр инде...

Коляны гүя корт чакты, барган җирендә читкә сикереп куйды һәм, аны-моны әйтмичә генә, саубуллашырга тотынды.

— Григорий Ивановичны күрми китәсеңмени?

— Юк, бүген кермим аның янына,— диде Коля һәм кискен итеп әйтә куйды: — Син сөйләгәннәрне тыңлаганнан соң, мин аның күзенә тиз арада гына күренмәскә булдым әле. Авырган чакта бик нык артта калынды, шуларның һәммәсен үзләштергәч, иптәшләрне куып җиткәч килермен.

Кырт борылып китеп барган иптәше артыннан Сережа гаҗәпләнеп карап калды.

Икенче көн Коля өчен бик зур күңелсезлектән башланып китте. Болытлы ямьсез көн иде. Хәтта ак кар да ничектер соры булып күренә иде.

Яковкин дәрес алып бара. Күңелсез, ялыктыргыч дәрес. Кинәт болытлар таралып, күктә кояш күренде. Укучыларның кәефләре яхшырып китте. Бу үзгәрешне сизеп, Яковкин гимназистларга үткен күзен чекерәйтеп карады: һәртөрле күңеллелекне ул тәртип бозу дип бәяли иде. Менә бервакыт аның күзләре, класс өстеннән йөри торгач, Лобачевскийга тукталды. Ә теге, аны-моны абайламыйча, әдәбият дәресеннән бирелгән эшне язып утыра. Җитмәсә тагын каурый каләме

белән берүзенә мәгълүм ритмны чыгара — селтәнеп куя да кәгазьгә төшерә.

Яковкин, сөйләвен дәвам иткән булып, гамьсез кыяфәттә класс буйлап йөреп китте һәм кем дә булса эшне сизәргә өлгергәнче, Коляның артына килеп басты.

— Шаярып утырасызмы әле дәрестә? — Яковкинның юан симез бармаклары өстәлдә яткан бер язулы кәгазьне алып, күзенә якын китерде.— Афәрин! Бу нәрсә Лобачевский әфәнденең матбугатта чыкмаган әсәре булса кирәк?

Коля, агарынып, аның артыннан талпынды.

— Бирегез! — дип кычкырып җибәрде.

— Мондый эш белән шөгыльләнгән өчен, мондый тәртибегез өчен класстан чыгарып җибәрмәгәч, шыпырт кына утырыгыз, шагыйрь әфәнде,— диде Яковкин мыскыллы елмаеп һәм бөтен класс алдында шигырьне кычкырып укып чыкты:

Кыю Колумб алга йөзде,
Эзләп яңа җирләрне.
Тик озын юл ялыктырды,
Диңгезчеләр чирләде.

Күзләде Колумб океанны,
Шул борчыды йөрәген:
Ул соң дөрес юл тотамы,
Үтәлерме теләге?..

Һәм менә — зарыктырган яр,
Кычкыра диңгезчеләр:
«Җир!» — диләр.— Колумб, иленне
Данга күмдең син!» — диләр.

Яковкин кәгазьне дүрткә бөкләде.

— Гүзәл әсәр! Киләчәк өчен сакларга тырышырбыз...

Ләкин шул чак аны Коля бүлдерде. Киндер кебек агарынган малай, урыныннан торып, Яковкинның тычканныкыдай түм-түгәрәк, кечкенә, йөгерек күзләренә кадалды.

— Минем шигырь ул. Бирегез,— диде ул кискен итеп.

— Кара син аны, ә!.. Элек синеке булган, хәзер минеке,— дип җавап кайтарды Яковкин һәм кәгазьне сюртук кесәсенә тыга башлады.

Шул чак арткы рәттән бер гимназист үзе дә сизмәстән:

— Алай эшләү намуссызлык була! — дип кычкырды.

— Намуссызлык була? Миңа әйтүегезме моны? Кем ул? — дип чәрелдәвек тавыш белән җикеренде Яковкин.

Класс тынып калды. Һәркемнең ачулы күзе директорга текәлде. Бу хәлне күреп, Яковкин йомшарды:

— Лобачевский үзенең поэмасын дәрес беткәч алыр, ә сез, әфәнделәр, ихтирамсыз булуыгыз өчен классыгыз белән төшке аштан мәхрүм ителерсез.

Гимназистларның бервакытта да болай ансат котылганнары юк иде әле.

Дәрес беткәч, Коляны йокы бүлмәсендә Сережа көтеп утыра иде. Яковкин белән булган бәрелеш турында бөтен гимназия белә икән инде. Сережа дустының муенына ташланды.

— Молодец та инде үзең! Молодец! Менә кем язучы булачак! — диде ул сөенеп.— Синең янга килүемнең икенче сәбәбе дә бар: Григорий Иванович хәзер генә мине чакыртып алды. Алар бүген Ибраһимов белән театрга бармакчы булганнар икән, ләкин ниндидер эш килеп чыккан. Билетларын безгә бирәләр. Белдеңме шуны? Сергей Александрович сиңа рөхсәт итте инде. Ул да бара.

Коляның куанычы әйтеп бетерерлек кенә түгел иде. Бүгенге бәрелештән соң каядыр китеп онытылып тору һәм бераз ял итү, әлбәттә, шәп булачак. Шуның өстенә ул, ниһаять, театрны күреп кайтачак. Күптәнге хыялы тормышка ашачак.

Менә ул Сережа һәм Сергей Александрович белән бергә театрга барырга чыкты. Кичкә табан суытып җибәргән. Морҗалардан төтен баганалары күтәрелгән. Агач ботакларын челтәр-челтәр бәс сарган. Аяк астында кар шыгырдый. Кичке эңгердә болар һәммәсе дә әкияттәге сыман булып күренә.

Балык базары урамында халык мыж килә иде. Кайсы җәяү, кайсы атка утырып театр мәйданына агылалар. Караңгы төшәр-төшмәс үк, бозланган тәрәзәләрдән саран гына саркып утлар күренә. Ерактан, салкын һаваны ярып, төнге каравылчының шакылдавык тавышы ишетелә.

Малайлар һәм Сергей Александрович, Грузинский урамына җиткәч, әле узган ел гына салынып беткән мәһабәт агач бина каршында туктап калдылар. Казанның беренче даими театры шунда урнашкан иде. Афишаларга күз салдылар. Алпавыт Есиповның крепостнойларыннан оешкан труппа Фонвизинның «Җитлекмәгән

егет» комедиясен куя, бүген шуның премьерасы икән.

Сергей Александровичка ияреп малайлар театрның вестибюленә керделәр. Партердан үзләре утырачак урыннарны таптылар. Шуннан Сергей Александрович аларга звонок булганчы галеркага менеп төшәргә рөхсәт бирде. Малайлар галеркадан түбән караганнар иде — исләре китте: театр ифрат зур коега охшап тора, ә стенага уеп эшләнгән яруслары исә карлыгач ояларын хәтерләтә.

Звонок булгандырмы, юктырмы — малайлар аны ишетмәделәр. Тик менә берзаман, аларның күз алдында түр стена, чайкала-чайкала, түшәмгә менеп китте. Пәрдә күтәрелә дигәннәре шул икән. Коля, барьерга ябышкан көе, урыныннан кузгала алмыйча торды. Шул чаклы гүзәллекне күреп сокланды. Актерларның гаҗәп оста уйнавы малайны көлдерде дә, шулай ук уйланырга да мәҗбүр итте. Митрофанның ничәмә-ничә ел дәверендә укып та, чеп-чи надан калуын күреп ничек көлми түзәсең? Әнисенең мәзәклеге... Скотининның тупаслыгы... Фамилиясе дә табылган бит үзенә! Чиләгенә күрә капкачы. Дөрес, сәхнәдә Правдин, Стародум һәм Софья кебек әйбәт кешеләр дә бар. Гадел һәм кискен Стародум, инде карт булуына да карамастан, нәрсәсе беләндер Григорий Ивановичны хәтерләтә иде. Ятим кыз Софья ролен башкаручы уртача буйлы, ябык чырайлы, зур кара күзле крепостной кыз Феклуша Аникиева үзенең гади, әмма бик табигый уйнавы, тыйнаклыгы белән һәркемнең мәхәббәтен яулап алды.

Театрдан кайткач, Коля таң алдыннан гына йоклап китте. Спектакльнең тәэсире белән тузга язмаган төшләр күреп бетерде. Имеш, Скотинин белән бергә Яковкин дә сәхнәдә чуала, ә Митрофан иң симез, иң ялкау гимназист Овчинниковка әйләнгән. Тәэсирләре нәтиҗәсендә малай, иртәнге уяутудан соң, киенү вакытында да, нәрсәнең төш, нәрсәнең өн икәнлеген аера алмый торды.

Ләкин театр караудан алган ул тәэсирне оныттырырлык зур вакыйга булыр дип кем уйлаган. Иртәнге аш вакытында өстәлдән өстәлгә канатлы яңалык таралды: Казанда университет ачу турында Петербургтан ашыгыч хәбәр алынган. Ул чакта Россиядә бөтенесе өч университет бар иде: Мәскәүдә, Дерптта * һәм Вильнода. Казанныкы дүртенче булачак.

---

* Хәзерге Тарту шәһәре.

Гимназиянең югары класс укучылары аерылып чыккан умарта күчедәй гөрләде. Бер-берсен кочаклыйлар, тәбриклиләр, университетка кергәч, «Ватан данын арттыру өчен» көчләрен кызганмаска ант итәләр.

Коля Лобачевский университетның булачак студентларына көнләшеп карады: аны әле бер елдан соң гына алачаклар, ә аларны, югары классларда укучыларны — инде хәзер үк. Абыйсы Саша белән дусты Сережа Аксаков, әлбәттә, беренче булып анда әләгәчәкләр.

Бу көнне расписание буенча төштән соң югары арифметика дәресе булырга тиеш иде. Өлкән укытучы Ибраһимов, гадәтенчә, класска кыңгырау белән бергә үк килеп керде. Ул кафедрага үтә җитез менде һәм, үрә каткан укучыларга күз ташлап, дулкынланудан калтыранган тавыш белән болай диде:

— Безнең өчен мондый шатлыклы көндә өйгә бирелгән мәсьәләләрне тикшерү белән шөгыльләнергәме?!

— Юк, куеп торыйк,— диде бер гимназист.

— Өлгерербез,— дип куплады икенчесе.— Бөтен Казан өчен зур бәйрәм бу!

— Әйе, бүген бөтен дәресебез җыр булып яңгырасын! — Ибраһимов дәртләнеп яттан шигырь сөйли башлады:

Җырлый миңа, җырлый арфа кыллары
«Килде,— дип,— шау чәчәкле яз анда».
Сөйли миңа арфа Ватан шатлыгын,
Алтын көннәр агылуын Казанда.
Тәпи йөреп киткән җирем, бишегем,
Садә чагым һәм яшьлегем атавы,
Улың булып, таңнарыңның нурында
Коенырмын инде кайчан мин тагы?
Җилкән корып, Идел киңлекләрендә
Тагын кайчан җитез коштай очармын,
Кама буе имәннәрен күрермен.
Атам-анам каберләрен кочармын?
Җырла миңа, арфа, Казан турында!
Җырла анда шатлык килгән саф кичне!
Туган җирнең хәбәрләре кадерле,
Төтене дә җанга якын, хуш исле.

— Үзенең төгәл, җанны иркәләп яңгыраган, һәр сүзе музыка булып агылган «Арфа» шигырендә поэзия баһадиры Державин әнә шулай дип язган. Сүз һәм музыка — бертуган ике сеңел,— дип тәэсирләнеп дәвам иттерде укытучы, кафедрадан тәрәзәгә таба тизтиз атлап.— Әфәнделәр, хәтерлисезме, Державинда тагын мондый юллар бар:

Кара карлыгачкаем,
Кардай ап-ак түшкәең,
Җәй кунагы, дускаем,
Җырчым, сылу кошкаем.

Нинди илаһи, нәфис сүзләр! Нинди яңгыраш! Музыкаль энҗеләр бәйләме!

Малайлар бөтен күңелләре белән бирелеп, селкенмичә, аягүрә басып тыңладылар.

— Утырыгыз, әфәнделәр, утырыгыз...

Ибраһимов үзе дә урындыкка утырды, елмайды һәм яңадан сөйли башлады:

— Мавыгыбрак киттем бугай. Түбәнчелек белән гафу үтенәм. Поэтик куанычларым кайчак үземнән дә көчлерәк минем. Чөнки Державин шигырьләре минем төшенчәдә кешелек сыйфатларын тәшкил итүче һәммә нәрсә белән — намус, хаклык, изгелеккә вә табигатькә мәхәббәт, Ватанга тугрылык, әчкерсез хезмәт, Россия халкының бетмәс-төкәнмәс көченә һәм аның якты киләчәгенә ышану, кешелек өчен кадерле булган бар нәрсәне хөрмәт итү белән бәйләнгән...

Ибраһимовның кара күзләре нур чәчә, ул үзен бил әп алган шатлыктан бөтен халәте белән балкый иде. Мондый минутларда Коля аңа чиксез гашыйк!

Арифметика онытылды, дәрес тормышның мәгънәсе һәм кешенең бурычлары турында әчкерсез әңгәмәгә әверелде.

— Сезнең алда юллар ачык,— диде Ибраһимов, урыныннан торып һәм яңадан дулкынланып атлавын дәвам иттереп.— Киң һәм тар, җиңел һәм авыр юллар. Сез теләсә кайсы юлны сайларга хаклы, дигән сүзме соң бу? Юк! Бары тик акыл һәм намус кушканнарын гына. Юлларыгызда кешеләрнең дә төрлесе очраячак. Яхшыларын яманнарыннан аера белегез. Әмма, үзегезнең шәхси өстенлекләрегезгә ышанып, кешеләргә югарыдан карауга, үзегез белән килешмәгәннәрне дошман күреп, тормышта бары тик үз юлыгыздан гына бару хокукын яклауга йөз тотмагыз. Андый кеше белә торып үзен рухи ялгызлыкка дучар итә, ул дуслык һәм мәхәббәтнең татлы минутларыннан, үзенә ләззәтле нәрсәләрдән дә ваз кичү бәрабәренә башкаларга изгелек кылу шатлыгыннан мәхрүм була. Мондый ялгызлыктан йөрәк никадәр ныграк суынса, андыйларга кешелек юлына кире кайту шулкадәр авыррак, хәтта мөмкин дә түгел. Кешелекнең бәхетсезлегенә каршы, мондый характердагы адәмнәр еш кына властька ур-

мәли, халык өчен бәлагә әверелә. Сулла, Мария һәм башка шундыйларны атап торыйммы сезгә?..

Гимназистлар, укытучының кызулыгы белән әсәрләнеп, дәшмәделәр. Укытучы да сүзсез калды. Уйга чумып тәрәзә янында басып торды һәм яңадан класска борылды.

— Әфәнделәр, хәзер сезгә Державинның минем әйткәннәргә тәңгәл килә торган одасыннан өзек укыйм,— диде ул тынычрак тостә.

Яхшы атым чыксын иде,
Телим кеше булырга мин.
Җанны йөгәнсез теләкләр
Агуламасын иде, дим.
Сукырайтмасын мине
Дәрәҗә, үч, дөнья малы.
Өйрәтсен фәкать хакыйкать
Сөяргә барча дөньяны.
Мәгърифәтле якты сөю белән,
Шагыйранә татлы көю белән...

— Әйе, Державин, гимназиябезне үз даны белән балкыткан Державин әнә шулай уйлаган һәм язган,— дип тантаналы төстә төгәлләде укытучы.

Шул чак бөтен класс бер кешедәй аягүрә басты.

— Николай Мисаилович! Сөйләгез әле безгә аның турында!

Моны Гаврило Панкратов әйтте, әмма бөтен класс, әйтерсең лә бер сулыш булып кабатлады:

— Сөйләгез!

Шундый дәрт белән әйтелде бу, Ибраһимов, бер минутка уйга калып, кинәт кулын селтәде.

— Утырыгыз да тыңлагыз,— диде ул гади генә итеп.— Моннан ярты гасыр элек булган бу. Казанда гимназия ачканнар. Аның беренче 95 укучысы арасында Казаннан 35 чакрым ераклыктагы Кармачи авылыннан 15 яшьлек Гаврила Державин да бар. Державиннарның нәсел башы — морза Нарбековның улларыннан берсе Держава исемле булган. Гаврила баштан ук бик яхшы укыган. Булачак шагыйрь бигрәк тә «хыялга тәэсир итүче фәннәрне» — рәсем, музыка һәм поэзияне ярата. Укуның беренче ярты елы тәмамлангач, «Московские ведомости»да Казан гимназиясенең иң яхшы укучылары исемлеге, шулар арасында Гаврила Державин исеме дә басылып чыга. Аның каләме белән эшләнгән сызымнар һәм рәсемнәр безнең беренче директор, язучы Михаил Иванович Веревкинга шул-

кадәр ошый, хәтта алар белән Мәскәү университеты кураторы, Казан гимназиясенә турыдан-туры җитәкчелек итүче Шувалов алдында да мактанасы килә. Ял вакытында Веревкин Державинның һәм башка кайбер укучыларның иң яхшы эшләрен алып Мәскәүгә китә. Казан губернасының төрле фигуралар вә ландшафтлар белән бизәлгән картасы һәм геометрик сызымнар була алар. Россиядә сәнгатьнең үсеше белән аерата кызыксынган һәм шул елларда Художество академиясенә нигез салган Шувалов Казан гимназиясенең беренче уку елы җимешләреннән үтә дә канәгать кала. Веревкин үз максатына ирешә: аның бик тә мөһим үтенечләре, мәсәлән, ярлы укучыларны — разночинец балаларын казна исәбенә тотуны кертү, гимназия өчен ниндидер бер генералның зур таш йортын сатып алу, кайбер укытучыларның эш хакын арттыру турындагы үтенечләре канәгатьләндерелә...

Коля дикъкать белән тыңлады һәм Ибраһимовтан күзен алмады. Әнә ничек бит? Ә ул, Лобачевский? Аның башка кешеләргә йогынтысы тиде, ул халык файдасына эшләде, дип әйтерме аның турында кем дә булса?..

Бүлмә караңгыланып һәм тагын да сихриләнебрәк калгандай булды. Ибраһимовның хикәяте сизелми генә тагын җанлы әңгәмәгә әверелде. Югары математика дәресендә нәрсә турында гына сөйләшмәделәр бу юлы: укытучыга яшәү насыйп булган башкалалар Мәскәү белән Петербург турында да, Ломоносовның тирән акылы турында да, кызык китаплар турында да, Бөек Петр патша турында да сөйләштеләр алар. Гимназистлар беренче чорда укуның бик авыр булуын искә алдылар, ә аннары сүз искәрмәстән үзләреннән кече класстагыларга ярдәм итү тиешлегенә барып тоташты. Моның өчен Лобачевскийга һәм башка сәләтле укучыларга әзерлек классындагы укучылар белән дәрес үткәрү өчен берничә сәгать вакытларын җәлләмәскә кирәктер, диелде. Ибраһимов моңа бик куанды.

— Молодцы! Трай тибеп йөрүләр бетсен, эшкә тотыныгыз! — диде ул, дулкынлануын шаян сүз белән каплап.— Фәннәр әлифбасы белән шөгыльләнү үзегезгә дә файдалы; мөгаен, инде сез икене икегә дә тапкырлый белмисездер, ә хәзер мена кабатларсыз. Шуның белән үзегезне укытучылык эшенә дә әзерләрсез. Мин директордан сорармын: ул, мөгаен, сезнең уйны тормышка ашырырга рөхсәт итәр. Озакламый рәсми

булмаган имтиханнар башланачак бит... Менә кыңгырау да шалтырады. «Алтын көннәр агыла Казанда!..» Бу дәрес өчен сезгә дә зур рәхмәт,— бу урында укытучының тавышы сизелерлек калтыранды, әмма ул шундук үз-үзен кулга алды һәм гадәттәге: «Сау булыгыз, әфәнделәр!» дигән сүзләрне тыныч кына әйтеп, класстан чыкты.

Берничә көннән директорның ризалыгы алынды. Ибраһимов, тәрбияләнүчеләрнең директорга мәхәббәтен белдереп, Яковкинны кечкенәләр турында кайгыртучы урта класс укучыларының укытучыларга һәм надзирательләргә ярдәм итәргә теләүләренә ышандыра алды. Шул рәвешчә, директорның мин-минлеген сыйпап, Ибраһимов эшне гимназия советы карарына кадәр үк җиткерә алды.

Изге ниятләре турында Лобачевский һәм аның иптәшләре әзерлек классына үзләре үк әйттеләр. Баштарак күзәтү астында дәрес әзерләргә теләүчеләр аз табылды, әмма көннәр үткән саен, башкалар бу азчылыкның дәресне яхшырак белүен, җәза белән нульләрне азрак алуын күреп тордылар, һәм өлкән класс күзәтүендә әзерләргә теләк белдерүчеләр дә тиз артты. Рәсми булмаган имтиханнар башлангач, ике әзерлек классы белән инде тулы составта шөгыльләнергә туры килде. Яковкин бу файдалы эшне бөтен көче белән яклады һәм, әлбәттә инде, бу башлангычның шөһрәтен үзенеке итте.

Гомуми мавыгу укытучыларны да билә́п алды. Алар өлкән класстагылар белән кичләрен дә, якшәмбе көннәрдә дә шөгыльләнделәр, гимназистларны университетка әзерләргә алындылар. Корташевский исә аеруча сәләтлеләргә гамәли математика курсы укый башлады.

Коляның әле беркайчан да тормышта үзен болай әйбәт хис иткәне юк иде. Ул мәҗбүри белемнәрне арттыручы күпләгән җитди кулланмалар укыды, элеккечә үк грек һәм француз телләрен тырышып өйрәнде, кече класс укучылары белән бергәләп ишегалдында сугыш уеннары уйнап, кар крепостьлары өйде. Әле өстәвенә, Мәкәрҗәдән килгән хәбәрләргә җавап итеп, әнисенә һәм бабасына хатлар язарга да өлгерде, аларга гимназия яңалыкларын, шулай ук үзенең уй-фикерләрен белдерде.

# 6

1805 елның үтә салкын 29 январь иртәсендә Санкт-Петербургның карлы урамнарыннан тугыз ат җигелгән зиннәтле карета выжлап узып китте. Тиздән ул шәһәрне чыгып, борынгы Мәскәү трактының очы-кырые күренмәгән якты кар даласына кереп югалды...

Каретада баручы җитмеш яшьлек юлчы, суыкны якын җибәрмәскә тырышып, бай төлке толыпка төренгән иде. Петербург Фәннәр академиясенең вице-президенты, соңгы гомеренең кырык елдан артыгын башкаладан чыкмыйча, бөтен көчен фәнгә сарыф итеп үткәргән кеше. Хәзер ул С.-Петербургтан ике атналык озын һәм ялыктыргыч юлга, ерак Казанга барырга чыкты. Аның портфелендәге рәсми кәгазьләрнең берсендә: «Казан уку-укыту округының попечителе, действительный статский советник Степан Яковлевич Румовский әфәнде, падишаһ галиҗәнаблары боерыгы буенча, башкаладан Казан округындагы кайбер училищеларны тикшерү өчен бара» дип язылган иде. Аның «серле сәфәренең» чын максаты исә әле 1804 елның 5 ноябрендә үк патша тарафыннан уставы расланган Казан университетын ачып җибәрү иде.

Әйе, ул яңа университет ачарга, Россиянең Идел ярларыннан алып Тын океангача сузылган иксез-чиксез биләмәсендә беренче югары белем учагын кабызырга бара. Бу хакта күбрәк уйлаган саен, Румовскийның Казанга шул кадәр тизрәк барып җитәсе килә иде.

Ә хәзер аның үткән тормыш күренешләрен, яшь рус фәненең сикәлтәле юлын искә төшерергә дә, киләчәктәге эшләр турында уйланырга да вакыты аз түгел.

Петр патша Россиядә Фәннәр академиясе оештырганнан соң сиксән ел үтеп китте. Баштарак үз галимнәребез бик аз иде. Югары белем бирүне һәм фәнни эшне оештыру өчен күпләп чит ил кешеләрен чакырырга туры килде. Бернули, Эйлер, Рихман кебек үз көчләрен һәм белемнәрен кызганмыйча фәнгә намус белән хезмәт иткән күренекле галимнәр белән берреттән, Россиягә, җиңел байлык эзләп, профессор исеменә төренгән күп кенә авантюристлар да килде.

Беренче рус академигы Михаил Васильевич Ломоносов, Академия башында торган Шумахер, Тауберт һәм башка чит ил кешеләренең ярсулы каршылыгына

карамастан, яшь рус галимнәрен үстерү өчен бөтен көченә көрәште.

— Руслар фән белән шөгыльләнергә сәләтле түгел,— дип бертуктаусыз тукыганнар тегеләр.— Ломоносов булгач, бик җиткән аларга.

Михаил Васильевич бирешмәгән. «Табутыма ятканчыга кадәр мин Россия фәне дошманнарына каршы көрәшәчәкмен», дип яза ул.

1748 елның апрель көнендә Ломоносов нәкъ әнә шундый көчле, ару-талуны белмәс кеше булып хәтерендә калды Румовскийның. Ул көнне «беренче рус галиме» Санкт-Петербургның Алесандровский семинариясендә тәрбияләнүчеләрдән Академия гимназиясенә укучылар сайлап алды. Сайланганнар арасында яшь Румовский да бар иде. Аның математика фәненә сәләте шушы гимназиядә, Рихманда укыганда ук ачылды. Ул елларда алар өчәүләп — ул, Рихман һәм Ломоносов — атмосферадагы электр үзенчәлеген өйрәнделәр. Бервакыт, 1753 елның июль ахырында шундый тәҗрибә уздырганда яраткан укытучысы Рихманның яшен сугудан үлүен авыр кичерә Степан Яковлевич. Бу фаҗигале вакыйгадан соң аның күңеле бик озак тынычлана алмады. Петербургка ул бары тик дүрт елдан соң гына әйләнеп кайтты һәм, Фәннәр академиясе кушуы буенча, педагоглык эшчәнлеген башлап җибәрде. Аннары «Математика» дәреслеге өстендә киеренке эшләде. Шул вакыттан бирле Румовскийның тормышы Петербург Фәннәр академиясенә тыгыз бәйле.

Казан юлы Степан Яковлевичка Венераның Кояшны каплап үтүе белән истәлекле булган 1761 елны да хәтеренә төшерде. Бу күренешне күзәтү өчен Россия Академиясе Себергә ике экспедиция оештырган иде. Аларның берсенә Румовский җитәкчелек итте. Моннан кырык ел элек нәкъ шушы ук юлдан бардылар алар.

Аннан соңгы чор Румовский тормышында туктаусыз үсү еллары булды. Академик булып сайлангач та ул беренче фәнни «Рус теле сүзлеге»н төзүгә актив катнашты. 1798—1799 елларда диңгез офицерларына гамәли астрономия укытты. Ә аннан соң, 1800 елда, Фәннәр академиясенең вице-президенты итеп сайланды. Ә 1803 елның 20 июнендә Румовскийны яңа оешкан Казан уку-укыту округының беренче попечителе итеп тә билгеләделәр. Ә бит ачылачак университетның уставы расланудан бер атна элек кенә аңа җитмеш яшь тулган иде. Әмма ул сынатырга теләми, үзен нык

һәм көчле ихтыярлы итеп тотарга тырыша. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки аның алдында гадәттән тыш җаваплы бурыч, моңарчы башкарырга туры килмәгән олуг бурыч тора.

Казан университетының киләчәге турындагы уйлар Румовскийны бөтен юл дәвамында борчыды.

Ул Ломоносовның 1755—1760 елларда үзе нигез салган Мәскәү университетының язмышы өчен нинди зур дәрт белән көрәшүен хәтерләде. Әйе, Казан университетын оештыру өчен дә аннан ким көч соралмый. Әнә бит Мәскәү университетына нигез салынуга ярты гасыр үтсә дә, Россия фәненең эчке һәм тышкы дошманнары бетмәгән. Аларга каршы шәфкатьсез көрәшергә туры киләчәк. Хәтта җәмгыятьнең өске катлауларында, дворяннар арасында да «Югары фән сарайларының Ватанга китергән файдасына караганда казнага зыяны күбрәк» дип раслаучылар очрый әле.

Моннан тыш Казан университетының җирле үзенчәлекләргә бәйле үз кыенлыклары булачак. Аларның кайберләрен Румовский хәзердән үк күреп тора. Әйтик, быелгы уку елында Казан гимназиясенә нибары 173 яңа укучы килде. Ул яшүсмерләр дә дистәләрчә губернадан җыелган. Димәк, яңа университетка студентлар туплау мәсьәләсенең бик үк җиңел булмавын күзалларга мөмкин.

Узган ел гына уку йортларының Баш идарәсенә Казан алпавытлары тарафыннан җибәрелгән рәсми кәгазьдә: «Биредә университет ачканда, аның фәкать дворян катлаудан чыккан һәм дәүләт эшендә мөһим бурыч үтәрлек яшьләр өчен булуын күздә тотарга кирәк», дип тәкъдим ителгән иде. Шулай итеп, яңа университет нигездә дворяннар уку йорты булачак, ягъни түбәнрәк катлау һәм гади халык балалары югары белем алудан мәхрүм ителәчәк. Ә югыйсә бит дворяннар үзләре балаларын югары фән йортына түгел, ә хәрби хезмәткә бирүне мәгъкульрәк күрәләр. Чөнки хәрби карьера аларны фәнгә караганда күбрәк кызыксындыра. Румовский өчен бу яңалык та, ачыш та түгел иде. Әле ярты гасыр элек Мәскәү университетын оештырганда, Ломоносов халык арасыннан чыккан кешеләргә фән юлын бикләргә тырышучы дворяннарның шундый ук дәгъваларына очраган иде.

Ломоносов башлаган көрәшне дәвам иттерергә лаеклы, шундый көчле ихтыярга ия булган нык характерлы, тирән акыллы һәм армас-талмас кешене Казанда

табып булырмы? Ул кеше чын мәгънәсендә халык университетын тудыра, аны үстерә алырмы? Чөнки мондый авыр бурычны карт Румовский үзе генә башкарып чыга алмаячак — моңа аның үз көче генә җитмәячәк. Димәк, яхшылап кабынырга да өлгермәгән яңа фән учагының сүнүе мөмкин.

Шундый авыр уйлар белән Румовский 11 февральдә Казанга килеп җитте.

* * *

Өч көннән соң, 14 февральдә, гимназиянең актлар залында булачак университет советының киңәйтелгән беренче утырышы чакырылды. Билгеләнгән сәгатьтән күп элек өлкән укытучылар, губернатор Мансуров канаты астындагы рус дворяннары һәм татар морзалары җыелды. Алар, пышын-пышын гына сөйләшеп, башкала вәкилен көтеп утырдылар.

Ниһаять, актлар залының киң, авыр имән ишекләре ике якка ачылып китте. Барысы да урыннарыннан торды. Залга тоныклана төшкән алтын каймалы иске модадагы камзул кигән, тәбәнәгрәк буйлы, таза гәүдәле карт — Румовский килеп керде. Аның артыннан канцелярия эшләрен башкаручы Соколов күренде, ярты адым чамасы арттарак һәм яндарак ялагай кыяфәттә гимназия директоры Яковкин юргалый иде.

Румовский өстәл янына килде, хөрмәт белән баш иючеләргә ягымлы эрелек белән җавап кайтарды һәм, кулын сузып, Соколовтан күн тышлы зур папканы алды. Папканың озын ефәк шнурына сугылган сургуч печать авыр булып аска салынып төште.

Яковкин, тай кебек юргалап, академикның икенче ягына барып чыкты һәм аңа креслоны якынрак китерде. Румовский җиңелчә генә баш селекте, әмма, утырмыйча гына, папканы ачты һәм залдагыларга карап ташлады. Аягүрә торган хәлдә, барысы да баш иделәр. Румовский картларча, чак кына калтыранган тавыш белән Казан университетын раслау грамотасын укый башлады:

— «Мәрхәмәтле әбиебез мөхтәрәм императрица Елизавета Петровна, Россияне яңабаштан үзгәртеп коручы бөек Петрның изге юлын дәвам иттереп, башка данлыклы казанышлар рәтеннән, 1758 елны Казанда гимназияне рәсми ачып, зур илтифат күрсәткән иде һәм шуннан элек кенә Мәскәү университетына биргән кайбер хокукларны аңа да бүләк иткән иде. Заманы-

бызның аң-белем дәрәҗәсенә туры китереп, шул уж урында университет оештырырга карар кылынды. Бу затлы йортның яшәвен мәңгеләштерү һәм аңа Ватаныбызга файдалы гражданнар хәзерләүдә, гыйлем тарату да мөмкинлекләр бирү өчен, Без император сүзебез белән түбәндәгеләрне боерырга тиеш таптык...»

Шушында җиткәч попечитель тирән сулап куйды һәм инде тантаналы тонны шактый кимәтә төшеп, грамотадагы аерым пунктларны санарга кереште. Аларда исә, әле кәгазьдә генә «яшәүче» уку йортының — бинасы да, аны төзергә акчасы да, уку әсбаплары да, студентлары да булмаган, кыскасы, бер нәрсәсе дә булмаган Казан университетының хокуклары һәм структурасы турында язылган иде.

Ниһаять, Румовский раслау грамотасын ахырынача укып чыкты да аны тантаналы төстә җыелышка тапшырды. Аннары ул халык мәгариф министры граф Завадовскийның 1805 елның 23 гыйнварында чыгарган боерыгын игълан итте. Гимназия директоры Яковкин яңа университетка Россия империясенең тарихы, географиясе һәм статистикасы профессоры итеп, ә гимназиянең өлкән укытучылары Корташевский, Запольский, Левицкий һәм Эрих адъюнктлар итеп билгеләнделәр. Әмма соңгылары арасында Ибраһимов фамилиясе булмау һәркемгә бик сәер тоелды.

Приказны укыганнан соң яңа билгеләнгән университет укытучыларын тантаналы шартта ант иттерү церемониясе булып алды. Ант бирүчеләрнең тавышы сизелерлек калтыранып чыкты. Яттан әйтелгән купшы сүзләр бу минутның изгелеге белән рухландырылды: Россия дәүләте тарихы мәгърифәт юлында яңа адым ясый иде.

Ниһаять, утырыш тәмамланды. Румовский гимназиядә тәрбияләнүчеләрнең тормыш-көнкүреше белән танышырга теләк белдерде.

Дәреслеккә хилафлык китермик — Яковкинны начар укытучы яисә булдыксыз хуҗа, дип әйтеп булмый инде. Өстәвенә, товарын күрсәтә дә белә иде ул. Гимназиядә уку сәгатьләренең төптән уйланып бүленүе дә әнә шул хакта сөйли иде. Укучылар класста көн саен сигезәр һәм хәтта унар сәгать утырсалар да, ялыкмыйлар, алҗымыйлар. Тәнәфесләрдә һава алу, ә кайчагында, җилгә-яңгырга яки кар-буранга карамый, өс һәм баш киемнәрен салып йөгерүләр дә бик нык ярдәм итә гимназистларга. Чит телдән дәрес ятлаганнан,

Цицерон нотыкларын өйрәнгәннән, Овидий элегияләрен укыганнан, математик башваткычлар чишкәннән соң тарих фәненнән кызыклы күнегүләр башлана. Укытучылар да, бүлмә надзирательләре дә тарихи вакыйгаларны кызык һәм мавыктыргыч итеп сөйлиләр. Төшке аштан соң сәгать ярымлык мәҗбүри йокы да кичке дәресләр алдыннан бик тә файдалы ял була. Көннең икенче яртысында, гадәттә, матур язу, рәсем, танцы, шпага ярышлары яисә атка атланып йөрү кебек күңелле дәресләр үткәрелә.

Румовскийны яңа университетның һәм гимназиянең барча хезмәткәрләре озатып йөрделәр. Ул бөтен классларны диярлек йөреп чыкты. Кухняга вә ашханәгә баш тыгып карады, йокы камераларына төште. Һәркайда кырыс тәртип, чисталык, пөхтәлек хөкем сөрә иде. Ишекләрдә — яшел портьерлар, тәрәзәләрдә — яңа гына крахмалланган пәрдәләр, тәрәзә төпләрендә — гөлләр (аларны олы кунак хөрмәтенә барлык укытучы һәм хезмәткәрдән җыйганнар иде). Класс-бүлмәләрдә һәммәсе дә шыпырт кына сөйләшә, тавышсыз гына атлый. Чөнки алдан ук йомшак табанлы үкчәсез туфлиләр әзерләнеп куелган һәм барысы да аякларына шул туфлиләрне кигәннәр иде.

Бу сәгатьтә укучылар барысы да ишегалдында ял итеп йөргәнлектән, камералар буш, тик бер өстәл артында гына башыннан ук китапка күмелеп, ялгыз гимназист утыра. Нәни кулы белән яңагына таянган килеш, шул кадәр уку дәртенә бирелгән ки, хәтта ишек шыгырдавын да ишетмәде, аяк тавышларын да сизмәде.

Румовский, кулы белән ишарә ясап, үзен уратып алган кешеләрне туктатты. Аннары шыпырт кына килде дә гимназистның җилкәсе аша аның алдындагы китапларга күз төшерде. Сул якта, Сервантес романы һәм грек сүзлеге белән янәшә, Румовскийның үз китабы — математика дәреслеге, ә уңда — Евклид «Башлангыч»ы һәм ачык дәфтәр ята иде. Гимназист, аны-моны абайламыйча, Евклидны грекчадан русчага тәрҗемә итүен дәвам итте. Өстәлдә үз китабын күргәч, Румовскийның күңеле нечкәреп китте, калтыранган кулы белән кесәсеннән кульяулыгын чыгарды да күзен сөртеп алды.

Яковкин алга ташланмакчы булып талпынып куйды, әмма Корташевский, тиз генә өстәл янына килеп, малайга эндәште:

— Лобачевский әфәнде!

Коля башын күтәрде. Янында ук Корташевскийны һәм таныш булмаган картны күргәч, каушап калды, урыныннан сикереп торды.

— Гафу итегез, Григорий Иванович...

— Галиҗәнаб,— диде Корташевский, малайның сүзен бүлеп.— Таныштырырга рөхсәт итегез: урта класста укучы Николай Лобачевский. Математика фәненә сәләте бар. Әйтик, аны геометриянең аңлаешсыз башланып китү сәбәбе кызыксындыра. Сез дә, галиҗәнаб, «Кыскача математика» дигән китабыгызда бик урынлы рәвештә шулай дип әйтеп китәсез бит...

Яковкинның ачуы ташып чыгарга җитеште, нидер әйтергә кыймылдап куйды, тик исенә килеп, шунда ук тынды.

— Әйе шул, башлангыч төшенчәләрнең ни дәрәҗәдә аңлаешлы булуына бик күп нәрсә бәйләнгән,— диде Румовский. Ул, тәмам тынычланып, оялчан малайны бик җентекләп күзәтергә кереште.— Менә сез, егетем, «Башлангыч»ны грекчадан өйрәнәсез икән. Афәрин. Евклид җөмләләре рус теленә аңлаешлы бирелгәнме, шул хакта нәрсә әйтә алырсыз?

Коляга фикерен тупларга бераз вакыт калдырыр өчен, җавап бирүне Корташевский үз өстенә алды.

— Галиҗәнаб, сез үз дәреслегегездә геометриянең башланып киткән өлешендәге сөрем — ялгыш тәрҗемә нәтиҗәсе генә түгел дип бик хаклы күрсәттегез,— диде.

Көтмәгәндә Россия академиясенең вице-президенты белән күзгә-күз очрашудан Коля исә бөтенләй югалып калган иде. Уен эшмени: Румовский бит Ломоносов шәкерте, үткән гасыр галимнәре вәкиле!

— Алай икән!.. Димәк, сез, егетләр, Евклидтан соң дөньяга килгән галимнәрне математикада ансатрак юллар эзләп тапмаган өчен гаепләргә, җыенасыз?.. Ә бу хакта Евклидның җавабы сезгә мәгълүмме? — дип сорап куйды академик, тавышын әллә чынлап, әллә юри күтәрә төшеп. Аның Коляга төбәп каравы җавапны малайдан ишетергә теләвен күрсәтә иде.

Коля башындагы фикерен тупларга өлгергән иде инде.

— Әйе, галиҗәнаб, бу хакта сезнең китабыгызда бар,— диде ул.— Евклид, геометрияне үзләштерүдә падишаһлар өчен дә махсус ансат ысул юктыр, дигән.

— Минем китапны укыгансыз һәм үзләштергәнсез, күренеп тора.— Галимнең йөзенә елмаю чыкты.— Бу сорау ике мең ел дәверендә бөтен математикларны борчып килә. Мине дә борчый, әлбәттә. Сезне дә тыныч калдырмый, күрәм... Математик хакыйкатьнең чишмәсе башланып киткән җиргә җитү өчен күпме көч куйдым, тик уңышка ирешә алмадым.— Шуннан ул, малайга төбәп караган килеш, сүзен тәмамлады:— Менә сезнең күзегездә, егетем, шушы изге максатка ирешү теләге күрәм, ялкын күрәм... Уңыш телим!

Попечитель Коляның аркасыннан сөйде һәм ишеккә табан атлады. Ишек төбендә ул ымлап кына Яковкинны үз янына чакырып китерде дә:

— Директор әфәнде, сез бу укучыга игътибар иттегезме? — дип сорады.

— Игътибар иттем, иттем, галиҗәнаб,— диде Яковкин, кабалана-кабалана.— Николай Лобачевский иң тискәре...

— Мин сездән ул хакта сорамыйм,— дип, ачуланып аның сүзен бүлде Румовский һәм, камзулының эчке кесәсеннән күн тышлы кенәгә алып, буяу карандашы белән: «Гимназист Николай Лобачевскийның чын математик булуына өмет бар», дип язып куйды.

Язуны директорга күрсәтте:

— Шушы гимназистның язмышы өчен Ватан каршында җавап бирәсез. Төшендегезме?! — диде.

Директорның җавабын да көтеп тормыйча, сөйләшүнең тәмам икәнен сиздереп, Румовский бүлмәдән чыкты. Башкалар аңа иярде. Аптыраган Яковкин артка калды. Озын коридорның икенче очына җиткәндә генә ул үзен кулга алган сыман булды һәм, башкалардан алгарак чыгып, академик артыннан йөргалый башлады. Корташевский белән Запольский бер-берсенә мәгънәле генә карашып алдылар.

...Гимназия ашханәсендә төшке ашны ашагач, Румовский ял итеп алырга кунак бүлмәсенә юл тотты. Әмма йоклап — ял итеп алу мөмкин булмады. Аның күзе язу өстәлендә яткан, әлеге тәмамланмаган хатка төште. Халык мәгарифе министры граф Завадовскийга җибәрелергә тиеш иде ул. Чөнки министр аңа юлга чыгар алдыннан: «Казанның төп урамнарын карап чыгыгыз һәм университет өчен яраклы биналарны сайлап алыгыз», дигән иде.

Румовский бүлмә хезмәтчесен чакырды, Яковкинны дәшәргә һәм карета бирергә боерды.

Әйе, министр да, ул үзе дә университет бинасының нинди булачагын аз гына да күз алдына китерә алмыйлар әле. Шуңа күрә аңа урындагы шартлар белән якыннан танышырга кирәк иде.

Румовский белән Яковкин каретага кереп утыруга, кучер кузлага сикереп менде дә дилбегәне кагып куйды, елгыр атлар шундук кузгалып китте. Башта алар Воскресенская урамы буйлап Кремль ягына үттеләр, Черек күлгә төштеләр, ә аннан Лядская һәм Арча кыры аша Грузинская урамына борылдылар. Ара-тирә, зуррак бина очраганда, Румовский каретадан төшә һәм юл уртасына чыгып, күзе төшкән йортка озаклап, җентекләп карап тора, ләкин һәр очракта да диярлек канәгатьсез кала иде. Шулай итеп, кичкә таба карета Рыбнорядский аша тагын Воскресенская урамына күтәрелә башлады. Шулчак үзенең зур ак колонналары, глобус һәм математик фигуралар төшерелгән өчпочмаклы фронтоны белән һәммә таш пулатлардан аерылып торган мәһабәт гимназия бинасы калкып чыкты.

«Әйе, бу — Казанда иң яхшы йорт, калкулыкта салынганлыктан, бөтен шәһәрне колачлап тора!» — дип уйлады Румовский. Ләкин моннан биш ел элек кенә губернатор өчен дип төзелгән һәм соңыннан гимназиягә бирелгән бу таш пулат университет өчен кечерәк, киңәйтелүне, янкормалар салуны сорый иде.

Яковкин белән киңәшкәннән соң, попечитель хәзер үк губерна архитекторын чакырырга, аның белән бергә гимназия күршесендәге йортларны һәм урыннарны карарга булды.

Ул төп подъездда туктарга кушты да Яковкин булышлыгы белән каретадан чыкты.

Гимназиягә барыннан да якынрак, Казанның хәзерге губернаторы Мансуров яши торган «Тенишев йорты» дип йөртелгән бина тора иде. Румовский архитектор һәм Яковкин белән бергәләп иң элек шунда керергә булды.

Попечительгә бу йорт гимназия бинасына караганда да ныграк ошады: аның түбәнге һәм өске катларында коридорлар бар, алардан аерым бүлмәләргә ишек уелган, ә гимназиядә барлык бүлмәләр дә үтәли йөрмәле, бу хәл исә класста дәрес барышына комачаулык тудыра иде. Губернатор йорты элекке хуҗасы князь Тенишев утырткан шактый зур һәм әйбәт

каралган җиләк-җимеш бакчасы белән дә ошады. Ә аның янәшәсендә шәһәр коменданты генерал-майор Кастеллиның шулай ук таш, әмма ахырынача төзелеп бетмәгән ике катлы, балконлы зур йорты тора иде.

Ниһаять, иң почмакта Воскресенская чиркәвенә кыйгач, инженер-подпоручик Спижарный өе урнашкан. Шулай итеп, бу дүрт бина тау итәге буйлап аскы урамга — Проломнаяга ук төшкән зур кварталны тәшкил итә иде.

Румовский архитекторга бу кварталның планын эшләргә кушты, ә үзе Училищелар баш идарәсеннән гимназия янәшәсендәге губернатор йортын университетка бирүне һәм, булачак югары уку йорты биналарын бер бөтен итеп берләштерү максатында, күршедәге тагын ике таш пулатны сатып алуны сорарга булды. Университет өчен аерым яңа бина төзү фикере берәүнең дә башына килмәде.

Училищелар баш идарәсенә язган аңлатмасында Румовский әле тулысынча төзелеп бетмәгән манежны типография өчен үзгәртеп корырга кирәклеген дә әйтергә булды. Әлеге типография гимназиянең уртанчы катында, шуның аркасында анда гел тавыш, ә бу исә дәресләргә комачаулый иде.

Попечитель Румовский картның төзелеш турындагы беренче уйлары шундый иде. Ләкин, билгеләнгән йортларны үзгәртеп коруга һәм бердәм университет кварталы оештыруга керешкәнче, проектлаштырыла торган эшләрне финанслау турында «патша хәзрәтләре күрсәтмәсе»н алырга һәм гимназия өчен аерым бина табарга кирәк иде. Бу мәсьәләләрне практик яктан хәл кылу билгесез вакыткача кичектереләчәк. Әле күп еллар, Николай Лобачевский төзелеш комитеты члены, ә аннары комитет председателе булганга кадәр, Казан университеты гимназиянең яраклаштырылмаган аерым бүлмәләрендә көн күрәчәк.

«Яңа югары уку йортына Казан гимназиясе белән бер йортта кысанрак булса да, әгәр инде ул ачылган икән, яхшымы-яманмы, аның эчке төзелешен җайга салу һәм укыту эшчәнлегенә юнәлеш бирү турында кайгыртырга кирәк. Гимназия инде ике тапкыр коткарды: университетка кайбер укытучыларын һәм үз бинасын бирде; мөгаен, ул бу юлы да коткарыр». Гимназияне озаклап караганнан һәм кичке ашны ашаганнан соң, кунак бүлмәсенә кайтып йокларга яткач,

Румовский үз-үзен тынычландырып әнә шулай уйлады.

Икенче көнне үк Румовский әмере белән гимназиядә зур мәшәкатьләр башланды. Югары классларның иң яхшы укучыларын студентлыкка «билгеләргә», моның өчен аларның ата-аналарының ризалыгын алырга, студентларга аерым йокы һәм класс бүлмәләре бирергә, алар өчен зур булмаган башка залда аерым ашханә ачарга һәм, иң мөһиме, яңа университетның лекцияләр курсын башларга кирәк иде. Бу оештыру мәшәкате бер атна диярлек барды.

Ниһаять, 22 февраль, студент итеп алынган укучылар исемлеген белдерү көне килеп җитте. Тантана зур залда булды. Попечитель килүгә махсус тегелгән яңа мундир кигән, галстук таккан гимназистлар буйларына карап сул якка тезелгән. Исемнәре аталганнан соң, университетка алынучылар уң якка күчәргә тиеш иде.

Куе кызыл постау ябылган өстәл артында горур кыяфәттә университет профессорлары һәм адъюнктлар утыра. Председатель креслосында — Румовский. Аның алдында берничә минуттан студент булачак бәхетлеләр исемлеге ята. Укучылар гадәттә булмаганча селкенми басып торалар: пышылдашу да, кыбырсыну да юк. Фәкать председатель кулына текәлгән күзләр генә тере, хәрәкәттә иде.

Һәм менә ул шул исемлекне алып, үзенә якынрак китерде.

— Аксаков Сергей,— дип белдерде картларга хас калтыравык тавыш.

Гимназистлар сафы чак кына сискәнеп куйды, әмма Сережа урыныннан тиз генә кузгала алмады.

— Бар инде, нишләп торасың?! — дип әйтә аңа күршеләре.

Сережа оялып кына сафтан алга чыга. Попечительгә һәм университет укытучыларына җиңелчә генә баш иеп алгач кына ныклы адымнар белән залның уң ягына күчә. Биек буш стена янында 14 яшьлек студентның гәүдәсе тагын да кечерәебрәк калган кебек.

Румовский карт урыныннан күтәрелә төште, учын учка шапылдатып алды һәм ике бөртек яшен сөртер өчен кулъяулыгына үрелде.

Сергей Аксаковтан соң уң якка әле күптән түгел генә гимназиядәге фетнә өчен бер атна карцерда утырган Петр Балясников күчте. Аның артыннан Казан уку округының булачак попечителе Еварист Грубер, була-

чак финанс министры Александр Княжевич, Александр Лобачевский, булачак танылган язучылар агалы-энеле Панаевлар, булачак академиклар агалы-энеле Перевощиковлар һәм башкалар — барысы 38 кеше күчте.

Коля Лобачевский, уртанчы класс укучысы, гимназистларның икенче рәтендә тора, аңа Румовский күренерлек түгел. Әмма бу минутта Румовскийның аның турында уйлавына, хәтта күзе белән нәкъ аны эзләвенә инанган иде ул. Чак кына аяк очына күтәрелүгә, Коля остазы Корташевскийның җылы карашы белән очрашты. «Григорий Иванович та нәкъ шул хакта уйлый!» дип шатланды ул.

Рәсми өлеш тәмамланды, студентлар белән гимназистлар яңадан үзара бергә кушылды... Әмма инде алар арасындагы элеккеге ирекле мөнәсәбәтнең югалуы ничектер сизелә иде.

Университет Советы членнары, президиум өстәле янынннан китеп, беренче рәттәге креслоларга утырдылар. «Өр-яңа» студентлар Петр Кондырев, Александр Панаев һәм Василий Перевощиков университетны ачу тантанасына багышланган үз шигырьләрен укыдылар, ә Павел Попов попечительгә «үз сәнгатенең кайбер тәҗрибәләрен» — асыл сөяктән эшләнгән әйберләрен бүләк итте. Румовский карт үтә дә тәэсирләнгән иде.

Ике көннән гимназия бинасының университетка бирелгән берничә бүлмәсендә студентлар өчен беренче лекцияләр башланды.

25 февральдә Румовский Санкт-Петербургка кайтып китте. Бу — аның сигез елга сузылган попечительлек эшчәнлегендә Казанга беренче һәм соңгы мәртәбә килүе булды.

## *Дүртенче бүлек*

### 1

Геометрия классының яртылаш ачык ишегеннән Панкратовның аксыл чәчле башы күренде.

— Коля кайда икән, белмисезме?

Класста җиде малай — Афанасьев, Балясников, Зыков, Корсаков, Княжевич, Упадышевский һәм Лоба-

чевский — барысы да Николай исемле, шуңа күрә аларның һәркайсының кушаматы бар иде.

— Әй, Коляны күрмәдегезме, димен?

Ләкин Панкратовка бу юлы да җавап бирүче булмады, чөнки барысы да үз эшләре белән мәшгуль иде. Кайсысы кәгазьдән ашыга-ашыга өчпочмак кисә, кайсысы колагын томалап чыш-пыш дәрес кабатлый. Берничә минуттан Ибраһимов дәресе башланачак. Бүген ул укучыларга өчпочмакның яңа үзлекләре турында сөйләргә тиеш.

Панкратов, түземен җуеп, класска йөгереп керде һәм сабагын ятлап утырган малайларның берсен иңбашыннан тотып җилтерәтте.

— Чукракландыгызмы әллә? Коля кайда, дим?

— Кайсы Коля?

— Математик.

— Әй, кит әле, белмим!..

Панкратов ачуланып кулын селтәде дә, ишекне шапылдатып, класстан чыгып китте.

«Математик» — уртанчы Лобачевскийның кушаматы. Коляга бу исемне академик Румовский белән сөйләшкәннән соң тактылар, һәм малай әлеге кушаматы белән эчтән генә горурлана иде. Математикада ул барлык иптәшләреннән алда бара, өстәвенә, гимназия китапханәсендә рус, француз һәм латин телләрендә җитди хезмәтләрне укый һәм хәтта яшертен генә университетка — Корташевский лекцияләренә йөри иде.

Әйе, 1805—1806 уку елында Григорий Иванович гимназиядән китте — фәкать студентларны укыта башлады. Аның урынына геометрия укытучысы итеп Ибраһимовны билгеләделәр. Бу хәл гимназистларны бик гаҗәпкә калдырды. Алар Ибраһимовны латин, славян һәм арифметика класслары укытучысы буларак беләләр һәм хөрмәт итәләр, әмма аның болардан тыш геометр да булуын башларына да китермиләр иде.

Бу хәбәрне беренче булып ишетеп кергән Гаврило Панкратов тәмам кайгыга сабышты.

— Университетка имтихан тотасы бар, күпме генә вакыт калды,— дип сөйләнде ул.— Уен эшмени...

— Корташевский безгә җил-яңгыр тидерми иде шул,— дип сүзгә катнашты гимназиянең иң яхшы укучыларыннан саналган Павел Петров.— Һәммәсен аңлатып, төшендереп бирер иде. Монысы ничек булыр икән, ә математик?

Коля аңа тыныч кына карап куйды.

— Ибраһимов сөйләгәнне бик аңлап җиткермәсәң, китаптан укып үзләштерерсең.

— Сиңа ансат ул алай сөйләшү, чит телләр белгәч,— диде шулчак кемдер.

Коля иңнәрен генә биетеп алды, җавап кайтармады, чөнки юктан гына сүзгә килергә теләми иде.

...Менә хәзер дә, иптәшләре һәммәсе класста әзерләнеп утырганда, Коля ишегалдындагы биек трапециядә чайкала иде.

— Әһә, менә син кайда икән! — дип кычкырып җибәрде Панкратов.— Ә мин сине бөтен гимназия буйлап эзләп йөрим!

Янәшәдә генә студентлар басып тора иде.

— Комачаулама,— дип туктатты аларның берсе Панкратовны.— Ул Овчинников белән бәхәсләште. Әгәр Коля баштүбән килеш чайкалган шәпкә җиргә сикереп төшә алса, Овчинниковның маңгаена йөз тапкыр чиертә. Әгәр барып чыкмаса — үзенә эләгә.

— Күрмисеңмени, Овчинников инде маңгаен әзерләп тора,— дип өстәде икенче бер студент, көлемсерәп.

Ул арада трапециягә тез асты белән баштүбән асылынган Коля тизлекне арттырды һәм чайкалган шәпкә җиргә җитез генә сикереп төште.

— Әйдә, чиертә башла! — диде студентларның берсе.

Коля кулын селтәде һәм Овчинниковка эндәште.

— Ярый, Митя, мин чиертеп тормыйм. Тик бүтән вакыт уйламыйча бәхәсләшмә. Ә хәзер — дәрескә...

Алар класска соңгы звонок белән бергә килеп керделәр һәм тизрәк урыннарына барып утырдылар.

Ишектә Ибраһимов күренде. Ул кулына куппочмак моделе, аршын һәм зур циркуль тоткан иде. Укучыларны барлап та тормастан, бернинди кереш сүзсез дәресне башлап җибәрде:

— Рәхим итеп такта янына чыгыгыз. Икегез дә.

Барысы да укытучы күрсәткән якка борылдылар, ә анда, уңнан икенче партада, Коля кызып-кызып Панкратовка нидер аңлатып маташа иде. Бәхәс белән мавыккан малайлар укытучының сүзен ишетмәделәр.

Арттагы иптәше аркасына төрткәч кенә, Коля сикереп торды. Аның белән бергә диярлек үк, Панкратов та аягүрә басты.

— Минме? — дип сорадылар алар икесе бертавыштан.

— Әйе, әйе, икегез дә,— дип кабатлады Ибраһи-

мов.— Карап карыйк, узган дәресне — өчпочмак тигезлегенең өченче билгесен ничек үзләштердегез икән?

Малайлар, такта янына чыгып, икесе ике очка бастылар. Коля, акбурны урталайга сындырып, яртысын Панкратовка сузды.

— Укытучы әфәнде,— диде ул,— теореманы без икәүләп исбатлыйбызмыни? Мин аны үзем генә дә исбатлый алган булыр идем.

Ибраһимов кашын җыерды.

— Сезгә беркем дә булышырга җыенмый. Тактаны урталай бүлегез дә тотыныгыз. Башта шартын языгыз...

Малайлар язып куйдылар.

— Хуш,— диде укытучы.— Ә хәзер теореманы һәрберегез үзенчә исбатлап карасын. Әмма һәр адым дәлилләнгән һәм нигезләнгән булсын.

Укучыларның сәерсенүе кызыксыну белән алмашынды. Моңа кадәр аларның бер үк теореманың төрлечә исбатлануы турында ишеткәннәре юк иде.

Панкратов әллә ни уйланып тормады. Кулындагы акбуры белән шак та шок яза да башлады. Аның сызган өчпочмагы да, язган хәрефләре дә нәкъ дәреслектә күрсәтелгәнчә иде.

Коля исә, кулындагы саламны боргалап, һаман да тик тора бирде.

— Лобачевский, ә сез нишләп туктап калдыгыз? — дип сорады аннан Ибраһимов.— Ничек исбатлыйсын белмисезме?

— Беләм,— дип җавап бирде Коля.

— Алайса, ник сызымыгызны сызмыйсыз?

— Ә миңа сызымның кирәге юк. Мин бер өчпочмакның өч ягы икенче өчпочмакның өч ягына тиңдәшле рәвештә тигез булса, аларның үзара тигез икәнен болай да исбатлый алам. Бернинди сызымсыз һәм сүзсез.

Класс гөжләп алды һәм шунда ук тынды. Берничә малай, үзләре дә сизмәстән, урыннарыннан күтәрелә төштеләр. Ибраһимовның карашында, кызыксыну очкыны кабынды.

— Исбатлагыз,— диде ул бер сүз белән.

Коляның ирене кысылды, бите алсуланып китте. Кызылга буялган өч салам алып, аларны һәркайсын урталайга бөкләде һәм, берсе эченә берсен кертеп, өчпочмак ясады. Аннан буялмаган саламнар алып, шундый ук ысул белән тагын бер өчпочмак ясады. Са-

ламнарны керткәләп-чыгаргалап, өчпочмакларның яклары тәңгәл килүенә иреште.

— Әйбәт, бик әйбәт! — диде Ибраһимов, аны хуплап.— Өчпочмакларны бик үзенчәлекле эшләдегез һәм аларның тигез булуын бер-берсенә куеп карап исбатлавыгыз да кызыклы вә ышандыргыч. Евклид та фигураларның тигезлеген шулай билгеләгән. Бу яхшы ысул. Утырыгыз!

— Тик шулай да,— дип дәвам итте Ибраһимов, бөтен класска мөрәҗәгать итеп,— элеге ысулны һәрвакыт куллану мөмкин түгел. Әйтик, җир үлчәгәндә һәм йорт салганда башка ысул сорала. Шуңа күрә Панкратов исбатлавын тыңлап карыйк.

Үзенә чират җитүен түземсезләнеп көтеп торган Панкратов җәһәт кенә тактага таба борылды.

— ABC өчпочмагында A һәм C нокталарыннан AB һәм CB радиуслы дуга сызабыз...— дип башлап китте ул һәм, бер җирдә дә терәлеп тормыйча, исбатлауны сөйләп чыкты.

— Яхшы,— дип мактады аны Ибраһимов.— Ләкин без моны дәреслектән укып беләбез. Ә менә сезнең кайсыгыз теореманы исбатлауның башка ысулын тәкъдим итә ала? Бу эшкә, бәлки, класстан берәрегез алыныр.

Гимназистлар бер-берсенә карашып алдылар.

— Исбатлауның өченче юлы да бармыни? — дип сорады кайсыдыр, гаҗәпләнеп.

— Бар,— дип җавап бирде Ибраһимов.— Мәсәлән, шул ук Румовскийда. Монысы хәтта гадирәк һәм җыйнаграк та. Әгәр тагын да яхшылабрак уйласаң, үз исбатлавыңны табарга була. Дәреслек буенча уку — тапталган юл, анда көтелмәгән киртәләр аша үтәсе юк. Ә менә үзеңә беренче булып ачыш ясау — монысы мактауга лаек эш.

Игътибар белән тыңлап утырган Коля инде берничә тапкыр кулын күтәрергә омтылып карады. Ибраһимов моңа игътибар итте.

— Лобачевский, сез нәрсәдер әйтергә телисез бугай?

Алтынсу-сары һәм кызыл төстәге өчпочмакларын кулына тоткан килеш, Коля торып басты.

— Әйе. Укытучы әфәнде, сез әле генә яңа, мөстәкыйль исбатлау эзләү турында сөйләдегез. Мин бер нәрсәне аңлап җиткермим: безнең теореманың дәрес-

леге беренче карауда ук, исбатлаусыз да аңлашыла бит. Нигә кирәк аны исбатлап маташырга?

Ибраһимов, тагын берәрсе кулын күтәрмәс микән дип, класс буйлап узды. Ләкин эндәшүче булмады.

— Сез, Лобачевский,— диде ул, көлемсерәп,— тиз генә бирешә торганнардан түгел... Чыннан да, геометрик фигураларның сызымы яки моделе аларның кайбер үзенчәлекләрен табарга мөмкинлек бирә. Борынгы мисырлыларның геометриясе әнә шундый күзаллауга нигезләнгән булган. Алар моннан практик максатлар өчен файдаланганнар. Хәзер салам өчпочмаклар ярдәмендә сез безгә моның үрнәген күрсәттегез... Утырыгыз, утыр! Ләкин табигатьтә җисемнәрнең катлаулырак геометрик үзенчәлекләрен ачыклау өчен мондый ысул ярамый. Хәер, сез моңа хәзер үзегез дә ышанырсыз.

Дәрес кызыклы әңгәмәгә әверелеп килә иде. Малайларның бите алсуланып чыкты.

— Без бүген өчпочмакның эчке почмаклары суммасы ике туры почмакка тигез булуы турындагы теореманы караячакбыз,— дип дәвам итте Ибраһимов.— Ул менә болай исбатлана...

Коля, укытучыны тыңлап та бетермәстән, тагын кулын күтәрде.

— Ягез, Лобачевский, әйтеп карагыз.

— Укытучы әфәнде, ләкин бит биредә дә исбатлауны бер сүз — «Карагыз!» дигән сүз белән алыштырып була,— дип каршы төште ул.

Укучылар өнсез калды: шулай ук Коля бәхәстә укытучыны җиңәр микәнни?

Ләкин Ибраһимов тыныч кына җавап бирде:

— Менә сезгә тагын бер Бехаскер Чарж. Әйдәгез, чыгыгыз бирегә, безне дә ышандырыгыз.

Коля такта янына чыгып басты һәм алгы өстәл артында утырган укучыдан калын кәгазьдән ясалган өчпочмагын сорап алды.

Аннан ул, өчпочмакның кырыйдагы ике почмагын өзеп алып, аларны ике яклап өченче почмак белән янәшә куйды. Шулай барлыкка килгән җәенке почмакны баш өстенә күтәрде.— Карагыз!

— Барыгызга да аңлашыламы? — дип сорады Ибраһимов.

Укучылар берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә кычкыра башладылар:

— Аңлашыла!

— Җәенке почмак ике туры почмакка тигез.

— Исбатлады!

Ибраһимов туктарга кушып кулын күтәрде.

— Тынычланыгыз, әфәнделәр. Сез дәрестә. Утырыгыз, Лобачевский. Бик яхшы. Димәк, сезнеңчә, исбатлау артык хезмәт? Димәк, барысы да ачык һәм аңлаешлы болай да?

— Әйе...— диде Коля.

Ләкин бу юлы аның тавышында элекке ныклык юк иде. Укытучының күзендә чагылып киткән шаян очкыннар аны исбатлавының дөрес булуына шикләнергә мәҗбүр итте.

— Борынгы Һинд математиклары да шулай эшләгәннәр,— дип дәвам итте Ибраһимов.— Теоретик нигезләүне кирәк санамыйча, алар ачык аңлаешлы сызымнар эшләгәннәр һәм аларның өстенә әле генә Лобачевский әйткән сүзне язганнар: «Кара!» Уникенче гасырда яшәгән индус математигы Бехаскер Чарж үзенең «Лилавати», ягъни «Гүзәл» дип исемләнгән китабында Пифагор теоремасын ике сызым белән аңлаткан һәм башка исбатлау кирәкми дип санаган.

Ибраһимов сөйләүдән туктады һәм, укучыларга әйтелгәннәр турында уйланырга вакыт бирергә теләгәндәй, сүзсез генә класс буйлап әйләнеп чыкты.

— Исбатлауның төп асылы турында ныклап уйланганда гына аның әһәмиятен тиешенчә бәяләргә мөмкин. Ә менә сезнең теге яки бу исбатлауның асылы турында уйланганыгыз булдымы?.. Юк, димәк. Шулай булгач, әлеге исбатлауның яки фикерләү нәтиҗәләренең ролен ничек кире кагарга мөмкин? Бу бит, беркайчан да ашап караган юк дип, тәмле һәм файдалы азыктан баш тарту белән бер.

Класс янә гөжләп алды.

— Христос туганга кадәр дүртенче гасырда,— дип сүзен дәвам итте Ибраһимов,— Аристотель үз чоры өчен гаять кыю фикер әйткән. «Беренчедән,— дигән ул,— Ай тотылганда аңа Җирдән күләгә төшә. Ә ул күләгә һәрвакыт түгәрәк була. Икенчедән, мондый күләгә, һичшиксез, шардан гына төшәргә мөмкин». Шулай итеп, дәлилле ике хөкемгә таянып, Аристотель Җирнең шар формасында булуын исбатлаган. Күрәсез, логик исбатлау нинди көчкә ия.

Укытучының бер җепкә тезелгән фикер агышы укучыларны үзенә әсир итте. Биредә барысы да уйланылган, логик яктан нигезләнгән иде. Исбатлау дигән нәр-

сә укучыларга мавыктыргыч яклары белән ачылып китте.

— Ә хәзер индусларга һәм Лобачевский мисалына әйләнеп кайтыйк,—дип дәвам итте Ибраһимов.—Ул безне «Карагыз!» дигән бер сүз белән инандырырга теләде. Ләкин бу очракта исбатлау булмады дип әйтә алабызмы? Әлбәттә, юк. Лобачевский күрсәткән өчпочмакларга уй-фикерсез, битараф карасак, бернинди нәтиҗәгә дә килмәс идек. Иң элек, без җәенке почмакның ике туры почмакка тигез булуын искә төшердек. Аннары без өч почмактан хасил булган фигураның җәенке почмак булуын таныдык. Һәм, ниһаять, әлеге фикерләрдән чыгып, өчпочмакның эчке почмаклары суммасы ике туры почмакка тигез дигән нәтиҗә ясадык. Күргәнегезчә, без күзәтүдән тыш фикер дә йөрттек. Тагын шуны әйтим...— Укытучы класс буйлап узды да Лобачевский янында тукталды.— Тагын шуны әйтим, әфәнделәр,— дип кабатлады ул серле елмаеп,— Лобачевскийның «сүзсез» исбатлавы, беренче карашка бик тәэсирле тоелса да, бик үк дөрес түгел һәм бәхәсле.

Укучылар пышылдаша башладылар, ә Ибраһимов берни дә ишетмәгәндәй дәвам итте:

— Үзегез уйлап карагыз: өчпочмакның почмакларын бергә китереп куйганнан соң нишләп әле без аларның ян як кырыйлары, һичшиксез, бер-берсенең дәвамы булып торалар һәм җәенке почмак тәшкил итәләр дигән нәтиҗәгә килергә тиеш?

Класста шау-шу күтәрелде.

— Бу бит ап-ачык күренеп тора!

— Әлбәттә!

— Чөнки шулай — бәхәссез!..

— Һәр геометрик раслау, әгәр ул аксиома булмаса, һичшиксез, исбатланырга тиеш. Хәтта барысы да бәхәссез кебек тоелса да. Сез шуны беләсезме? — дип сорады Ибраһимов.— «Ап-ачык бит» дигән төшенчә алдаучан. Кемгә ачык, ә кемгә юк. Исегезгә төшерегез: кешеләр ничә гасыр буе Кояш Җир тирәсендә әйләнә дип уйлаганнар, чөнки аларга шулай күренгән. Бу сезгә «ап-ачык»лыкка бер мисал. Димәк, өчпочмакның почмаклары суммасы өчен дә исбатлау кирәк.

— Почмакларны транспортир белән үлчәргә кирәк,— диде Лобачевский,— шунда барысы да ачыкланыр.

— Бик яхшы,— дип хуплады аны Ибраһимов.—

Хәзер һәркайсыгыз алып килгән өчпочмагыгызның почмакларын үлчәгез, аларны бергә кушыгыз һәм нәтиҗәсен әйтерсез. Ә сез, Лобачевский, иптәшләрегез әйткәнне тактага язып барырсыз.

Гимназистлар дәртләнеп һәм мавыгып эшкә керештеләр, ә Ибраһимов урындыкка утырып аларны күзәтә башлады.

Берничә минуттан гаҗәпсенгән тавышлар яңгырады:

— Минем 181 градус чыкты!

— Ә минем нишләптер 179!

— Ә минем 180 градус 30 секунд!

Коля иптәшләре әйткән саннарны яза барды һәм, озак та үтми, бөтен такта сан баганалары белән тулды.

Ибраһимов Коляга таба борылды.

— Я, Лобачевский, нәтиҗә әзерме?

— Юк әле,— дип җавап бирде Коля,— хәзер исәпләп бетерәм... Сәер, уртачасы 178 градус белән 181 градус арасында килеп чыга,— диде ул гаҗәпләнеп.

— Менә шул шул,— диде укытучы, елмаеп.— Димәк, һәркемнең күзе үзенчә күрә булып чыга.

Коля дәшмәде.

— Ышандыгызмы инде? — дип сорады Ибраһимов ачык чырай белән.— Кәефегез төшмәсен. Эш күздә түгел, ә карандашларда, линейкаларда һәм транспортирларда. Кыскасы — сызганда һәм үлчәгәндә киткән хаталарда. Бу хаталардан котылып булмый. Сез ничә өчпочмакны үлчәсәгез дә шундый ук хәл кабатланачак. Иң әһәмиятлесе шул: безгә өчпочмакның эчке почмаклары суммасы ике туры почмакка тигез булуын белүдән тыш, моның ни өчен шулай булырга тиешлеген аңларга кирәк. Үлчәү һәм тәҗрибә юлы белән исбатлау моны аңлатмый. Бу — теореманы тупас һәм якынча нигезләү генә.

— Хата әллә ни зур түгел,— диде Коля һәм, укытучының рөхсәт бирүен дә көтмәстән, үз урынына барып утырды.

— Ничек? Сезнең бөтен аңлаган нәрсәгез шушымы? — диде Ибраһимов кәефе китеп.

Класс киеренке хәлдә тынып калды. Нәрсә булыр? Укытучы тәрәзә янына килеп, форточканы ачып җибәрде. Класска саф һава бәреп керде.

Гимназистлар Коляга ачулы караш ташладылар. Ә ул, башын түбән иеп, аска карап утыра иде.

Укытучы үзен кулга алырга өлгерде һәм кафедра янына килеп басты.

— Лобачевский,— диде ул сабыр тавыш белән.— Кешенең үз сәләтенә ышануы яхшы нәрсә. Ләкин масаю рухи көч бирми. Киресенчә, ул аңны томалый. Шуның аркасында кеше үзенең кимчелекләрен күрә белү сәләтеннән мәхрүм кала, башкаларның фикеренә ихтирамын югалта.

Ибраһимов кабат класс буйлап әйләнеп узды һәм, такта янына килеп, дәвам итте:

— Менә сез, Лобачевский, хата зур түгел, дидегез... Әгәр өчпочмакларның эчке почмаклары суммасы тәптөгәл ике туры почмакка тигез булмаса, беләсезме, нәрсә булыр иде? Евклидның бөтен геометриясе ялгыш булыр иде. «Бу теорема Евклидның параллельлек аксиомасына яки бишенче постулатына тиң», дип язды Иран математигы Әбүҗаффар Мөхәммәт Насретдин Туси үзенең «Геометриягә кереш» дигән китабында. Бу теоремага нигезләнеп җир участокларының мәйданын хисаплап чыгаралар, менеп булмый торган биеклекләрне, барып булмый торган араларны үлчиләр, шәһәр планнары һәм географик карталар төзиләр. Әгәр әлеге гаҗәеп почмакларның суммасы 180 градуска тигезлеге тырнак очы кадәр генә шик уятса да, боларның берсе дә мөмкин булмас иде.

Класста тынлык урнашты. Бу тынлыкта ачык калган форточканың җилдән шыгырдавы гына ишетелә иде. Гимназистлар каршыларында яткан өчпочмакларга гүя тирән серләр тулы могҗизалы сыннарга караган кебек ихтирам катыш курку белән карадылар. Дәрес озакка сузылды, ләкин моны беркем дә сизмәде.

— Борын-борын заманнарда ук галимнәр әлеге гади геометрик фигурага — өчпочмакка — аерым әһәмият биргәннәр,— диде укытучы.— Алар аны барлык җисемнәрнең төп башлангычы дип уйлаганнар. Өчпочмакның үзенчәлекләрен өйрәнеп, галәм законнарын аңларга омтылганнар.

Классыннан күчми калган Овчинников күршесенә терсәге белән төртте дә:

— Гап-гади өчпочмак аркасында күпме сүз боткасы,— дип пышылдады.

— Аңгыра баш,— дип җавап бирде аңа иптәше.— Тыңларга теләмәсәң, тик кенә утыр, башкаларга комачаулама.

Ул арада укытучы өстәлдән юка агач кисәкләрен кадак белән тоташтырып ясалган бишпочмаклыкны алды.

— Борынгыларның акылын әсир иткән өчпочмакның сере нәрсәдә соң? — дип дәвам итте ул.— Менә, карагыз, бу күппочмакны мин теләсә ничек киңәйтә һәм тарайта алам, ул үзенең формасын бик җиңел үзгәртә. Хәзер бер планканы алып ташлыйк: дүртпочмаклык та хәрәкәтчән — я квадрат, я ромб килеп чыга. Инде тагын бер планканы алыйк. Монысы өчпочмак. Аның формасын үзгәртеп, чалышайтып карагыз... Мәгез,— дип тәкъдим итте ул Овчинниковка.— Я, ничек? Барып чыгамы?

— Юк, чыкмый,— дип җавап бирде сәерсенеп калган малай.— Каты. Сындырып карасаң гына инде.

— Туктагыз, тукта! — дип тотып калырга ашыкты аны Ибраһимов.— Каергаламагыз! Өчпочмакның могҗизалы үзлеге нәкъ менә шушы инде. Аннан техникада да, төзелештә дә файдаланалар. Өчпочмаклы ферма ярдәмендә ныгытылган күперләрне, өй кыекларын, йортларны сез һәр җирдә очратырсыз. Тагын шуны хәтерегезгә сеңдереп калыгыз: теләсә кайсы күппочмакны өчпочмакларга бүләргә мөмкин. Шуңа күрә дә борынгыларның өчпочмакны барлык башка фигуралардан өстен күрүе бер дә гаҗәп түгел. Өчпочмакның эчке почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез булмаса, Евклид геометриясе үзе дә булмаячак, дигән Аристотель...

— Менә бит ул ничек икән! — диде иптәше Овчинниковка.— Ә син гап-гади өчпочмак дисең!.. Тыңла!

— Хәзер үзегез дә аңлагансыздыр,— дип дәвам итте укытучы,— безнең бу теорема математик төгәллек белән исбатлауны сорый. Шулай итеп, өчпочмакның эчке почмаклары суммасы 180 градуска тигез дип раслыйбыз...

Укытучы тактага тиз генә өчпочмак сызды һәм теореманы исбатлый башлады. Гимназистлар каләм-кәгазьләрен кыштырдата-кыштырдата язарга керештеләр.

— Математик исбатлауның зарури булуына сез, әфәнделәр, үзегез дә ышангансыздыр,— дип йомгак ясады укытучы.— Шуның ярдәмендә геометрик хакыйкатьләрне гомумиләштерәләр һәм төгәл фәнни системага салалар. Бу система алар арасында булган бөтен эчке элемтәләргә карый. Менә шуңа күрә дә

Италиянең бөек галиме, рәссамы, шагыйре Леонардо да Винчи кеше тарафыннан башкарылган бер генә тикшеренү дә, әгәр ул математик исбатлау аша үтмәсә, чын белем дип санала алмый дип раслаган. Ләкин шунысы бар: чын белемгә ирешү өчен тәҗрибә юлы белән исбатлау да зур әһәмияткә ия. Алар бер-берсен тулыландыралар. Образлы итеп әйткәндә, болар фәндә ике баскыч, ләкин, бу баскычларның араталары сирәк булу сәбәпле, аларның һәркайсыннан аерым гына менеп булмый. Ә менә аларның икесен бергә файдалансаң, өскә менү җиңеләшә, чөнки... араталары ешая...

Ибраһимов тынып калды. Ул кафедрага таянып тора һәм читтән караганда бик арыган кебек күренә, шул ук вакытта аның кара күзендә дәртле очкыннар яна иде.

— Бәлки, сораулар бардыр?

Коридорда, ишек төбендә үк, кыңгырау тавышы яңгырады. Аннары көтмәгәндә ишек ачылды һәм бусагада кулына бакыр кыңгырау тоткан дежур-каравылчы күренде.

— Гафу итегез, җәнапләре. Теге тәнәфескә шалтыратканны ишетмәдегез бугай, бусын икенче тәнәфескә шалтыратам,— диде ул ихтирам белән.

Класста гаҗәпсенгән авазлар яңгырап үтте:

— Кара, сизми дә калганбыз!

— Ике дәрес очкан да киткән.

— Ике сәгать бер минут кебек.

Ибраһимов елмайды.

— Зыян юк, куып җитәрбез...

Коридорда кыңгырау чыңлый-чыңлый ерагая барды, ә укучылар урыннарыннан торырга ашыкмадылар. Аларның Ибраһимов белән сөйләшәселәре килә иде.

— Ярый, әфәнделәр, алдагы очрашуларга кадәр. Теләгән кеше икенче дәрескә кайсы да булса берәр теореманы мөстәкыйль рәвештә исбатлап килә ала. Тик исбатлавыгыз Осиповский дәреслегендәге кебек булмасын.— Ибраһимов башын иеп саубуллашты да гадәтенчә җитез адымнар белән класстан чыгып китте.

Лобачевский аны баскычта куып җитте.

— Николай Мисаилович! — диде ул дулкынланган тавыш белән.— Гафу итегез! Мин сезнең хәтерегезне калдырырга теләмәдем... Тәртибем өчен теләсә нинди билге куегыз, тик ачуланмагыз гына.

Ибраһимов көлеп җибәрде һәм Коляны җилкәсеннән какты.

— Сәер малай син, Лобачевский! Шундый уй ничек башыңа килде! — диде ул гаҗәпләнеп.— Ә бит нәкъ менә сезнең аркада класста шундый кызыклы сөйләшү килеп чыкты. Сез бөтен класска исбатлауның асылына төшенергә ярдәм иттегез.

— Мин?! — диде Коля, ышанырга теләмичә.— Мин бит исбатлауларны танырга теләмәдем. Әле хәзер дә бик үк төшенеп җитмим.

— Вакыты җиткәч аңларсыз! Һәр нәрсәдә дә кинәт кенә оста булып китә алмыйсың. Геометриядә бигрәк тә! Геометрия, кадерлем, гаҗәеп фән. Аңа тирән үтеп керергә теләгән кеше бик күп хезмәт түгәргә, ул үткән юлны борынгы тарихыннан башлап бүгенге көненә кадәр биш бармагы кебек белергә тиеш.

— Димәк, беренче төшенчәләрдән башлап барысын да үзләштерергә кирәк? — диде Коля, җанланып.

Ибраһимов хуплап башын селкеде:

— Һичшиксез, шулай. Башта нигезен кормый торып йорт салып булмаган кебек, фәндә дә башлангычсыз мөмкин түгел. Ә хәзер, бар, ял ит.

## 2

...Коля, кулына таянып, кечкенә өстәл янында Евклидның «Башлангыч»ын укып утыра. Урамда — җил. Көзге кояш болыт арасыннан бер мизгелгә генә күренеп китә дә тагын кереп югала. Күбрәк укыган саен, Коляның йөзе дә көзге болыт кебек караңгылана иде.

— Менә бәла: билгеләмәләр берсеннән-берсенә томанлырак һәм буталчыграк була бара.

Шул вакыт ишек шыгырдап ачылды һәм Панкратовның башы күренде:

— Математик, әйдә, геометрия бүлмәсенә.

— Нәрсәгә?

— Теоремалар исбатларга. Үземнең генә хәлдән килми.

Бераз уйлап торганнан соң Коля ризалык бирде.

— Тик кара, алдан ук килешик: беребез исбатлый, беребез сорау бирә. Һәм һәр фикерне нигезләргә. Хәтереңдәме, Николай Мисаилович ничек киңәш иткән иде: һәр яңа раслауны элек кабул ителгән хакыйкатьләр ярдәмендә логик яктан нигезләргә.

— Аңлашылды,— диде Панкратов,— әйдә, киттек.

Кулларына китапларын кыстырып, малайлар икенче катка менделәр һәм, караңгы тар коридор буйлап барып, геометрия бүлмәсенә керделәр.

— Бер кеше дә юк икән, әйбәт,— диде Панкратов, шатланып.— Я, такта янына беренче булып кем чыга? Күнме, иләкме? — ул акча чөйде һәм һавада килеш үк тотып алды.— Күн. Димәк, мин башлыйм.

Ул тиз-тиз атлап, такта янына барды һәм, кафедрага менеп оялаган Коляга таба борылып, түбәнчелек белән аңа мөрәҗәгать итте:

— Укытучы әфәнде, минем сезгә бер гозерем бар иде...

— Ташла инде! — дип бүлдерде аны Коля.— Тизрәк эшкә тотыныйк.

— Мин эш турында ич! — диде Гаврило, үпкәләп.— Син миңа авыррак теореманы бир. Җиңелен мин үз сүзләрем белән исбатлый белмим. Әйтик, перпендикуляр авыш сызыктан кыскарак була. Сызымын сызасың, ә сөйләргә сүз дә калмый — болай да аңлашыла. Тагаракта йөзгән кебек. Ә менә авыр теореманы исбатлавы күңелле. Бусагалы, тиз ага торган елга кебек. Йөзүе читен булса да, бөтен сәләтеңне күрсәтергә мөмкин...

— Бөтенләй йөзеп китмәсәң ярый да бит,— дип, Коля аның сүзен бүлде.— Вакыт аз. Акбур ал да яз: «Һәр өчпочмакның тышкы почмагы үзе белән чиктәш булмаган эчке почмакларның һәркайсыннан зуррак». Яздыңмы? Исбатла!

Панкратов көрсенеп куйды һәм, көрәшергә хәзерләнгән батыр кебек, курткасының җиңен сызганып, тактага тырышып-тырышып зур итеп өчпочмак сызды.

— Кара син аны, нинди авыр теорема бирде,— дип сөйләнде ул.— Монда бер ай элек үткәнне дә искә төшерергә туры киләчәк.

— Укучы Панкратов, акыл сатмый гына,— дип бүлдерде Коля, тавышын бик оста итеп Яковкин тавышына охшатып.

Гаврило пырхылдап көлеп җибәрде, ләкин шунда ук үзен кулга алды һәм тактага таба борылды.

— Өчпочмакны ABC дип билгелик. BC кырын Дга кадәр дәвам иттерик. АСД тышкы почмагы ВАС һәм СВА эчке почмакларының һәркайсыннан зуррак, дибез. АС кырын Е ноктасында урталай бүләбез...

— Тукта, тукта! Ашыкма, ашка пешәрсең. Өчпочмакның тышкы һәм эчке почмаклары дигәнеңне ничек аңларга?

— Шуны да белмисеңмени? — диде Панкратов, гаҗәпләнеп.

Коля елмаеп куйды.

— Ә ничек дип вәгъдәләшкән идек? Онытгыңмыни?

— Үзебез кулланган барлык төшенчәләр тулысынча аңлатылырга тиеш. Әйе бит?

— Шул шул менә! — диде Коля, җитди кыяфәттә баш кагып.

— Өчпочмакның нинди дә булса почмагы белән чиктәш почмак шул өчпочмакның тышкы почмагы дип атала. Бу очракта АСД почмагы тышкы почмак була. Тышкы почмаклардан аермалы буларак, өчпочмакның үз почмаклары эчке почмаклар дип атала. Шуның белән, вәссәлам!

— Юк, бер дә вәссәлам түгел әле,— диде Коля тыныч кына.— Мин бит синең чиктәш почмак дигәнеңне дә белмим.

— Ә-ә...— дип сузып кына әйтеп куйды Панкратов һәм аңлатырга кереште: — Әгәр ике почмакның берәр яны уртак булып, калган яннары берсе икенчесенең дәвамын тәшкил итсә, андый почмакларга чиктәш диләр.

— Бик дөрес. Дәвам ит!

— Нәрсә дәвам итәргә соң? — дип сорап куйды Гаврило, күңел төшенкелегенә бирелеп.

— Нәрсә булсын?.. Әле бит почмакның нәрсә икәнен дә аңлатып биргәнең булмады. Аннары мин почмакның яннары дигән сүзне дә аңламый утырам...

— Уфф!..— дип көрсенде Панкратов.— Син бигрәк инде...

— Ачуың килеп шартлый күрмә.

— Син көлмә, математик... Хәзер мин сиңа һәммәсен аңлатып бирәм. Почмактан башлыйк. Бер ноктадан чыгучы ике нур тарафыннан ясалган фигура почмак дип атала. Ә ян яклар дип... Син нәрсә авыз ерасың әле?.. Берәр төшенчәне онытып калдырды дип уйлыйсың булыр?.. Юк, туган, шаярма! Анысын мин соңыннан әйтәм. Почмак ясаучы ярымтурылар ул почмакның ян яклары дип атала. Хәзер менә нурга да билгеләмә бирергә мөмкин. Бер генә яктан чикләнгән туры сызык нур яки ярымтуры дип атала.— Гав-

рило тантаналы кыяфәт белән Коляга карап куйды.— Хәйләмә төшендеңме инде?

— Молодец, бер атуда ике куян баласын үтердең... тик минә куянның үзен качырдың!

— Куянны? — Панкратов уйга калды.— Нинди куян турында сөйлисең әле син?

— Ә менә нинди... Почмак турында сөйләгәндә син Евклидның тәүге төшенчәсен — ноктаны телгә алдың. Ни өчен аңа билгеләмә бирмәдең?

— Ни өчен, ни өчен! — дип үртәнеп сөйләнде Гаврило.— Нәрсә, әллә син миннән ноктаны кисәкчекләре булмаган нәрсә дип яки туры сызыкны туры булган нәрсә дип билгеләтер идеңме?

— Нокта... сызык... Их! — дип әйтеп куйды Коля, кинәт кенә маңгаена шапылдатып сугып.— Бу турыда әле үткән елны Корташевскийның беренче дәресендә үк ишеткән идем. Ничек шуңа башым җитмәгәндер инде?! Чынлап та, безнең моңа кадәр кулланган төшенчәләребез ахыр чиктә әнә шул нокта белән туры сызыкка кайтып калды. Әгәр бүтән геометрик төшенчәләр дә шуларга ук таянса, аларның ни өчен...

— Кит инде! — дип аның сүзен бүлдерде Панкратов.— Алай булмас! Мисал өчен параллель турылар дигән төшенчәне алыйк. Николай Мисаилович сүзләре белән әйткәндә, бу — бер яссылыкта ятучы һәм уртак ноктасы булмаган ике туры сызык. Нокта һәм туры дигән ике төшенчәдән тыш, әле тагын яссылык дигән төшенчә дә килеп катнаша. Ә аңарга нокта һәм сызык төшенчәләре ярдәмендә билгеләмә бирергә мөмкинме икән?

— Кара әле! — дип куйды Лобачевский, дәртләнеп.— Яссылык та бит, нокта яки туры сызык кебек үк, үзбилгеләнешле тәүге төшенчә.

— Шулай икән шул! — диде Гаврило, җанлана төшеп.— Ничек әле? Яссы өслек ул — яссы нәрсәме? Ә бәлки, мондый башлангыч төшенчәләр тагын да табылыр?.. Тикшереп карыйкмы?

— Карасак карыйк! — дип куйды Коля һәм шунда ук нечкә тавыш белән мәзәк итеп җырлап җибәрде:

> Яшәгән патша,
> Зур йорты булган,
> Сарае таштан...
> Тотындык баштан.

Җырлап бетергәч, ул дәреслеккә ябышты.

— Берәр нәрсә төшеп калмасын өчен, син «Башлангыч»ны кара, мин — Осиповскийны. Беренче биттән алып барлык геометрик төшенчәләрне тикшерик. Тик бер-беребезгә комачауламыйк кына.

Яктырак килеп тәрәзә буена урнаштылар һәм игътибар белән укырга тотындылар.

Тик аларның һәркайсы үзенчә укый: Лобачевскийның кулында кәгазь-карандаш, алдагы билгеләмәләргә һәм теоремаларга кайта-кайта күз сала, үзенә кирәген кәгазенә төшерә. Панкратовның хәтере искиткеч әйбәт, ул шактый авыр математик исәпләүләрне күңелдән эшләргә күнеккән, хәзер дә ул аеруча кирәкле урыннарга гына кабаттан кайтып күз салгалый.

Ул арада кич якынлашты. Кичке шәфәкъ, тәрәзә пыяласында уйнап, сүнде. Класс бүлмәсе акрын-акрын караңгыга күмелде.

Панкратов укудан туктап, Коля янына килде.

— Җитәрдер инде? Берни күреп булмый, күз бозудан ни мәгънә,— диде.— Баягы сүзең дөрескә чыгар, ахры. Укый торгач, параллелограммга кадәр килеп җиттем, төшенчәләр бөтенесе һаман да шул нокта, туры сызык, яссылык ярдәмендә билгеләнә. Димәк, төп төшенчәләр барлыгы өчәү.— Гаврило кинәт бер адым артка чикте дә бик тәкәллефле итеп баш иде.— Нокта, Туры сызык һәм Яссылык ханымнар, гафу итегез, мин үземнең наданлыгым аркасында сезне кирәкми торган нәрсәләр дип йөргән идем. Чынлыкта исә бер генә геометрик корылманы да, бер генә төпле фикер йөртүне дә сездән башка үтәп булмый икән. Менә, ичмасам, ханымнар!..

Лобачевскийның ачуы килде.

— Нәрсәсенә сөенәсең аның, дивана? — диде ул һәм кулына тоткан китабын тәрәзә төбенә тондырды.— Коточкыч хәл бит бу! Башың булса, уйлап кара бераз. «Нокта — кисәкчәләре булмаган нәрсә», диелә. Шундый томанлы, мәгънәсез төшенчәләргә корылган фәннән нинди ачыклык көтәргә мөмкин? Юк, без нәрсәне дә булса аңлап җиткермибездер...

— Тәмам башым катты инде,— дип, Гаврило көрсенеп куйды.— Әйдә урамга чыгып керик, саф һава сулыйк. Бәлки, бераз җиңелрәк булыр.

Тик урамда йөреп керү дә, кичке аш та аларга җиңеллек китермәде. Дуслар янә геометрия бүлмәсенә кереп утырдылар. Нокта, сызык һәм яссылык төшенчәләренә кагылмаска сүз куештылар.

— Вакытлыча гына,— дип аңлатты Коля.— Теореманы кайчан үзебезчә исбатларбыз...

Малайларның һәркайсы яңа исбатлауны мөстәкыйль рәвештә эзләде. Ләкин, ничек кенә тырышсалар да, уңышка ирешә алмадылар. Алар сукыр лампада май беткәнче сыздылар, яздылар, бәхәсләштеләр. Әмма яңа исбатлау табылмады.

— Әйдә, ятып йоклыйк, бәлки, төштә күрербез,— диде Панкратов.

Коля кулын гына селтәде.

* * *

Икенче көнне геометрия классына җыелган гимназистларның күбесенең сөмсерләре коелган иде. Узган дәрестә туган кутәренкелек бернинди нәтиҗә бирмәде: аларның берсе дә яңача исбатлау таба алмады. Гимназистлар ишеккә әледән-әле борчулы караш ташлап, укытучы керүен көттеләр. Ибраһимов исә килеп керүгә үк һич көтелмәгән тәкъдим ясады.

— Әфәнделәр! Ишеккә чыгарга — кояшта җылынып керергә теләмисезме?.. Бүгенге дәресебезне без бу юлы Казанка буенда, болында үткәрәчәкбез. Шунда геометриянең ата-бабасы — җир үлчәү фәне белән танышырбыз. Ризамы? Җыенырга биш минут!

Гимназистларны алыштырып куйдылармыни. Йөзләрендә елмаю пәйда булды. Кабаланып, этешә-төртешә ишеккә юнәлделәр.

Аста Ибраһимов күрсәтмәсе буенча таяклар, җир үлчәү чылбыры, эккер — кыскасы, кырда эшләү өчен кирәкле әсбаплар әзерләп куелган иде. Малайлар тизрәк нинди дә булса корал алып калырга ашыктылар. Коля җир үлчәү чылбырын эләктерде.

Сентябрь көне гадәттән тыш җылы һәм болытсыз диярлек иде. Халык белән тулы урамда шундый күңелле. Ибраһимов малайларны сафка тезеп тормады. Бу аларның шатлыгын тагын да арттырды. Ә иң күңеллесе Казанка буена җиткәч башланды.

— Биредә, әфәнделәр,— диде Ибраһимов килеп туктагач,— без суның теге ягына чыгабыз. Ләкин беренче эш итеп безгә елганың киңлеген үлчәргә кирәк.

Ике укучы, үлчәү бавын күтәреп, яр буендагы көймәгә таба йөгерде.

— Туктагыз, тукта! — дип кычкырды укытучы.— Шнурларның озынлыгы җитмәячәк. Ә иң мөһиме, без бу киңлекне көймәдән һәм баудан файдаланмыйча үлчәргә тиеш.

Малайлар, аптырашып, бер-берсенә карашып алдылар.

— Бәлки, күз белән чамалап үлчәргәдер? — диде Коля кыюсыз гына.— Монда, мөгаен, егерме сажинлап бардыр, артык түгел.

— Сезнең күз үлчәме начар түгел,— диде укытучы хуплап.— Җир үлчәүче өчен бу бик кыйммәтле сыйфат. Хәзер сезнең чынбарлыкка күпме якын килгәнегезне ачыкларбыз. Моның өчен... Панкратов, әйтегез әле, өчпочмакларның үзара тигезлеген күрсәтүче беренче билге нидән гыйбарәт?

— Әгәр бер өчпочмакның ике ягы һәм шулар арасындагы почмагы икенче өчпочмакның ике ягына һәм шулар арасындагы почмагына тигез булса, бу өчпочмаклар үзара тигез булалар,— дип җавап бирде Гаврило, чатнатып.

— Бик яхшы! — диде Ибраһимов.— Ә хәзер, әфәнделәр, елганың киңлеген шушы теоремадан чыгып үлчик.— Ул Панкратовка карап алды.— Әйтик, фуражка козырегы ярдәмендә...

Малайлар кабат бер-берсенә карашып куйдылар.

— Үлчәргә дигәндә бик шәп корал инде бу,— дип пышылдады Овчинников.

— Ә барып чыгармы соң? — дип сорады Панкратов.

Ибраһимов көлемсерәп куйды:

— Ышанасы килмиме? Ярый, сынап карыйк... Сез, Панкратов, елгага йөз белән басыгыз. Фуражкагызны күзегезгә төшереп киегез, козырекның кыры каршы яр белән тәңгәл килерлек булсын. Ә хәзер башыгызның торышын үзгәртмичә генә сулга борылыгыз һәм бу як ярда козырек астыннан күренгән ноктаны карап калыгыз. Булдымы? Яхшы! Хәзер сезгә шул ноктага кадәр булган араны адымлап үлчәп чыгасы гына калды. Теорема буенча ул — елга киңлегенә тигез. Игътибар итегез, без кабат өчпочмакның үзенчәлегеннән файдаландык. Аңлашылдымы?

Озынлыкны үлчәргә Панкратов артыннан башкалар да йөгерде. Практик дәрес теләсә нинди уеннан да кызыграк иде.

— Күрәсезме,— диде укытучы.— Адым да үлчәү

коралы була ала икән һәм бик мөһим корал. Җитмәсә, ул җир үлчәүченең һәрвакыт үзе белән.

Чираттагы практик эшкә күчкәнче шактый вакыт узды, чөнки һәр укучы фуражка козырегының тылсымлы үзлеген сынап карарга ашкына иде.

Кырда үткәрелгән җир үлчәү эшләре аеруча кызыклы килеп чыкты. Малайлар тартылган бау белән туры сызык үткәрделәр, җир өстендә почмаклар төзеделәр һәм аны үлчәп карадылар, кыр участокларының планнарын төшерделәр.

— Укытучы әфәнде... Укытучы әфәнде,— укучылар киңәш сорап Ибраһимовны әле теге, әле бу башка чакырып кына тордылар.

Ә Ибраһимов исә барысы янына да өлгерә, күрсәтә, аңлатып бирә. Ул, сәгатенә күз салып: «Безнең вакыт бетте. Гимназиягә кайтырга кирәк»,— дигәч, укучылар канәгатьсезлек белдереп гөжләп алдылар.

Кайтканда күңелле кайттылар. Дәрестә рухланып киткән Гаврило Панкратов шагыйрь Державинның үзе туган шәһәрнең планын төзегәндә көлкегә калуын искә төшерде.

Бу вакыйга һәркем өчен кызык тоелды, тыңларга дип алар яшел чирәм өстенә утырдылар.

— Кайчан булган вакыйга ул? Сөйләгез әйдә,— диде Ибраһимов.

— 1760 елда булган хәл. Минем үземә бабай сөйләгән иде. Ул чакны әле безнең гимназия директоры Веревкинны командир дип йөрткәннәр. Бервакыт моңа Чабаксарның планын төзергә кушып, Сенаттан фәрман килә. Геометрия укытучысы капитан Морозовның яңарак кына үлгән чагы була. Веревкин нәрсә эшләргә дә белми аптырап кала. Шуннан бу эшне Державин җилкәсенә аудара. Ә Державин шул елны гына гимназияне бетергән икән. Веревкин аңарга ярдәмгә берничә укучы да бирә. Болар һәммәсе дә геометрияне исбатлаусыз гына өйрәнгән халык, тәҗрибәләре булмый. Нишләсеннәр? Киталәр Веревкин янына. Ничек үлчәргә икәнен өйрәт, диләр.— Үзен тыңлап утыруларына канәгатьләнеп, Панкратов сүздән туктап бераз кыстатып торды.

— Шуннан нәрсә эшлиләр?

— Нәрсә эшләсеннәр, шуннан Веревкин өйрәтә тегеләрне урам үлчәргә,— дип Гаврило хикәясен дәвам итте: — Иңе сигез сажин, озынлыгы уналты сажин рам эшләттерә, аны калай белән тышлаттыра. Аннан

инде шул рамны чылбыр белән тартып урам буйлап сөйрәп китәләр. Рам сыйса — йорт урынында кала, рам эләксә — ул йорт капкасына акбур белән «ватарга» дип язалар.

— Шулай ук язганнармы? — дип куйды Ибраһимов, тыела алмыйча көлеп. Гимназистлар яшел чирәмдә тәгәрәп-тәгәрәп көлделәр. Ибраһимов тизрәк хикәянең азагын тыңларга теләде һәм: — Аннары нишләгәннәр? — дип, сөйләүченең исенә төшерде.

— Державин бер өйгә дә сыймаслык зур итеп план төзегән. Чормага менеп сыза торган иде, ди бабай. Ләкин ул планны эшләнеп тә бетмәгән көе Казанга алып киткәннәр. Ә йортлар җимерелми калган...

— Кызык нәрсә! — диде Ибраһимов.— Шундый нәрсә сөйләгәнегез өчен рәхмәт, Панкратов. Күңелебезне ачтыгыз, рәхмәт! Ә хәзер, әфәнделәр, гимназиягә ашыгыйк. Соңга калуыбыз ихтимал.

* * *

Бүген Лобачевский көн буена башкалар белән бергә укыды, уйнады, шаярды. Төн җитеп, йокы бүлмәләрендә утлар сүндерелде. Дежур надзиратель яткан алгы бүлмәдән дә гырлаган аваз ишетелә башлады. Ә менә Коляны йокы алмый, ул бер ягыннан икенче ягына әйләнгәләп ята. Менә ул, одеялын читкә этеп, урыныннан сикереп торды, киенде һәм грифелен, аспид тактасын, көндез яшереп куйган шәм кисәген алды. Тәрәзә янындагы өстәл өстенә шәмен яндырып куйды һәм ут яктысын китабы белән ышыклады.

Коля бүлмәнең салкынлыгын да сизмәде, чөнки уйларына бик нык бирелгән иде. Бүген Казанка буенда үткәрелгән дәрес вакытында ул кабат яңа исбатлау эзләргә карар бирде. Ибраһимовның дәрестә әйткән сүзләре һич исеннән чыкмый: «Әгәр өчпочмакның эчке почмаклары суммасы ике туры почмактан бер генә почмак минутына аерылса да, Евклид геометриясе булмаячак!» Табарга иде яңа исбатлауны. Ничек тә табарга иде!

Ул «Башлангыч»ны алды һәм, кирәкле битен ачып, укый башлады:

«32 нче раслау. *Һәрбер өчпочмакта аның бер ягын дәвам иттергәндә барлыкка килгән тышкы почмак каршы якта ятучы ике эчке почмакка тигез, һәм өчпочмакның өч эчке почмагы ике туры почмакка тигез»*.

Теореманы акрын гына яңадан укып чыккач, китабын читкә куйды, сызым сызды да фикер йөртергә кереште:

— Теләсә нинди өчпочмак бирелгән. Шуның теләсә кайсы тышкы почмагының бу тышкы почмакка чиктәш булмаган ике эчке почмагы суммасына тигез булуын һәм эчке почмаклар суммасының ике туры почмакка яки 180°ка тигез булуын исбат итәргә кирәк. Әлбәттә, моны бирелгәннән чыгып, ягъни өчпочмакның үзенең почмакларыннан чыгып исбатларга да мөмкин. Әйтик, почмакларны кисеп аласың да өчесен бергә китереп кушасың, шуннан эчке почмаклар суммасына тигез җәенке почмак хасил була. Тик мин инде бу юл белән дәрестә исбатлап караган идем — оятка гына калдым.

Малай бераз вакыт уйланып торды. Кинәт аның башына ап-ачык булып бер фикер килде.

— Әгәр мин кире баштан фикер йөртергә тотынсам? Әйтик, эчке почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез булсын, диик. Нәрсә соң ул ике туры почмак? Нинди почмаклар ике туры почмакка тигез була?

Коля өчен бу иң бәхетле көн булды, ахры. Әллә озак вакыт аерылып торганнан соң туйганчы җир үлчәү килештеме, әллә җәйге каникул бетеп, уку башлангач беренче мәртәбә кәефе ачылдымы — аның башына фикерләр бер-бер артлы килеп кенә тордылар. Үтелгәннәрне хәтеренә төшереп, ул үзенең дәфтәренә тиз-тиз язып куйды:

«Беренчедән, *җәенке почмак ике туры почмакка тигез.*

Икенчедән, *ике чиктәш почмакның суммасы 180° ка тигез.*

Өченчедән, *бер туры почмак янына тагын берне китереп куйгач, ике туры почмак килеп чыга*».

Язганны игътибар белән күздән кичерде һәм уйга калды. «Менә хәзер башым эшли башлады шикелле... Әгәр өчпочмакның эчке почмаклары өчесе бергә җәенке почмак хасил иткәнне, яки ике чиктәш почмак, яки туры почмак плюс туры почмак барлыкка китергәнне исбатласам...»

Үз фикеренә үзе сокланып:

— Шулай ич инде! — дип сөйләнеп куйды.

Кычкырыбрак әйтте булса кирәк, якын тирәдәге кроватьлар шыгырдап алдылар. Бер малай хәтта ба-

шын күтәрде, йокы аралаш нәрсәдер әйтеп куйды, тик инде, ахыр чиктә, йокысы барыбер җиңде: одеялы астына чумды.

Ләкин Коля боларның берсен дә күрмәде, ишетмәде. Ул сөйләнә-сөйләнә, ашыгып-ашыгып сызым сыза иде.

— Беренче раслаудан файдаланып карыйк... Өчпочмакның кайсы да булса бер түбәсе аша, әйтик С түбәсе аша, теләсә нинди туры сызык, әйтик ДЕ турысы, үткәрик. Моннан җәенке почмак барлыкка килә. Боларның берсе өчпочмакның үзенең эчке С почмагы. Кара син, нәрсә килеп чыга бит! Хәзер инде калган ике почмак — ДСА һәм ЕСВның икесе бергә А һәм В эчке почмаклары суммасына тигез булуын исбатларга гына кала... Тик мәнә ирекле рәвештә уздырган ДЕ турысы андый нәтиҗә ясарга ирек бирмәс, ахры... Ә ул туры сызыкны тикшерелә торган почмаклар арасында нинди дә булса геометрик бәйләнеш сизелеп торырлык итеп үткәрергә мөмкин түгелме? Ике параллель һәм кисүче ярдәмендә ясалган почмаклар турындагы теореманы алыйк. Моның өчен фәкать ДЕны АВга параллель итәргә генә кирәк. Шуннан инде ДСА почмагының А почмагына һәм ЕСВ почмагының В почмагына тигез икәнлеге ачык күренә, чөнки алар параллель турыларны өченче туры белән кисештергәндә ясала, ә андый почмаклар тигез була. Әгәр шулай икән, өчпочмакның эчке почмаклары чыннан да җәенке почмак хасил итәләр. Димәк, аларның суммасы ике туры почмакка тигез була һәм алынган теорема исбат ителә.







Тукта, Коля ни өчен бер дә шатланмый соң әле? Болай исбат итү күңеленә ошамыймы әллә? Ошавын ошый да бит: барыбер яңабаштан тотынырга туры киләчәк... Мондый исбатлауны Ибраһимов дәрестә күрсәткән иде... Хәер, син үзеңчәрәк килдең дә бит, башкалар белгәч, аны инде яңа дип булмый.

Коля, кәефе кырылып, шактый вакыт бер ноктага

карап утырды. Аннары аспид тактаны якынрак китерде дә:

— Барыбер китереп чыгарам! Барыбер үземчә исбатлыйм! — дип пышылдап әйтеп куйды.

Бу юлы Коля нигез итеп, ике чиктәш почмакның суммасы ике туры почмакка тигез, дигән раслауны алды.




— Әгәр ABC өчпочмагының бер ягын, әйтик, AB ягын, Д га кадәр дәвам иттерсәк, СВД тышкы почмагы хасил була. Аның эчке В почмагы белән чиктәш булуын һәм чиктәш почмакларның суммасы турындагы раслауны искә төшерсәк, аларның суммасы ике туры почмакка тигез икәнне белербез. Шуннан безгә ул тышкы СВД почмагының калган ике, ягъни аның белән чиктәш булмаган эчке А һәм С почмаклары суммасына тигез икәнен генә расларга кала. Әгәр шуны раслый алсам, теорема тулысынча исбат ителгән була. Тик моны ничек эшләргә?

Шәм төти башлады. Йокы бүлмәсендә шәмнең филтәсен рәтли торган кечкенә кыскыч юк иде, шунлыктан Коля шәмнең «борынын» кулы белән сындырды. Ут яктырып киткәч, гүя аның уе да яктыра төште.

— Тукта әле, ярдәмгә мин тагын ике параллель турындагы теореманы алып карыйм. Чыннан да, В түбәсеннән АС га параллель рәвештә ВЕ турысын үткәрсәк, менә нинди нәрсә килеп чыга бит: параллель сызыкларны кистергәндә ясалган тиңдәш ЕВД һәм А почмагы тигезләр, аркылы ятучы почмаклар буларак, СВЕ һәм С почмаклары да үзара тигезләр, димәк, бөтен тышкы СВД почмагы каршы ятучы эчке А һәм С почмакларына тигез булып чыга. Шулай булгач, теорема яңадан исбат ителде дигән сүз. Ләкин бу юлы да...

Коля, көрсенеп, урындыктан торды һәм тиз-тиз «Башлангыч»ны актарырга кереште.

— Кая китте соң әле ул теорема?.. Хәзер генә күчереп яздым бит... «10 нчы... 19 нчы раслау...» 32 нчесе кайда соң? Әһә, таптым! «Әйтик, ABC өчпочмагы бирелгән булсын... Туры үткәрик...» Шул ук бит бу! — дип, Лобачевский кинәт, тыела алмыйча, кычкырып җибәрде.— Тик мин барыбер бирешмәячәкмен! Яңа юл

белән исбатларга мөмкинлек бар икән — йөз мәртәбә башласам башлармын, ләкин тапмый ташламам. Бераз ял гына итеп алыйм.

Малай арыган башын аспид такта өстенә салды, һәм шунда аның күз алдына чал чәчле, сөйкемле Сережа абыйсы килеп басты, аның акыллы сүзләре хәтеренә төште.

«Крестьянның, һөнәрченең хезмәтен камилләштерүгә һәм җиңеләйтүгә, шулай ук табигать көчен йөгәнләүгә — боларның һәммәсенә фән аркылы ирешергә мөмкин... Бүгенге надан һәм кара халык гыйлем эстәр, акыл иясенә әверелер. Боларның һәммәсенә фән сәбәпче булыр... Бөтен фәннәрнең нигезе — математика».

Коляның кашлары җыерылды: бервакыт үзенең иптәшләренә фән турындагы әнә шул акыллы сүзләрне кабатлап әйткәне исенә төште. Малайларның күпчелегенә ошады ул сүзләр. Тик менә башкалар сөйләшкәндә йокымсырап утырган Овчинников кына, урындыгыннан кинәт сикереп торып:

— Мәгънәсез акыл сату бу,— диде.— Уйлап кына карагыз инде: надан һәм кара халык гыйлем эстәр. Без дворяннарга моның бер дә файдасы юк. Җир сөрсеннәр әнә, оброк түләсеннәр. Гыйлемле булу — бу безнең эш, дворяннар эше,— диде ул һәм Коляга таба мыскыллы итеп карап куйды.

Коляның йодрыгы төйнәлде.

Ике арага Княжевич килеп керде.

— Юкны сөйлисең, Митя! — диде ул, ачу белән.— Синең кебек дворянинга бернинди гыйлем ярдәм итә алмаячак. Лобачевскийның сүзләре башлырак кешеләргә карый.

— Дворянин булган,— дип нәфрәтләнеп кабатлады хәзер Коля һәм, күңелсез күренешне күз алдыннан куу өчен, башын чайкап алды.

Малайның күзе грифельгә һәм аспид тактага төште. Алар гүя исбатлау тапканны көтеп яталар иде. Яңа исбатлау эзләми чара юк. Теленә таныш җыр килде:

Яшәгән патша...

Бәхеткә каршы, дежур надзиратель һәм барлык гимназистлар үлгән кебек йоклыйлар. Салкын аларның һәрберсен башыннан ук одеялга төренергә мәҗбүр иткән, күрәсең.

Коля грифелен кулына алды.

— Теләсә нинди өчпочмакның эчке почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез икәнен исбат итәргә кирәк. Ике туры почмак дип нинди нәрсәгә әйтәләр?.. Туры почмак плюс туры почмакка,— диде ул шыпыртлап кына.— Бер дә аптырыйсы юк. Әйтик, АВ нигезенә перпендикуляр рәвештә өчпочмакның ике түбәсеннән АД һәм ВЕ турыларын үткәрәбез икән, туры почмак плюс туры почмак була. Ул чагында теоремабызның дөреслегенә ышандыру өчен безгә эчке С почмагының перпендикулярлар белән өчпочмакның ян яклары арасында хасил булган ике өстәмә почмакның суммасына тигез икәнлеген исбатларга кала...




Малай бераз вакыт уйланып торды.

— Тукта әле! — дип куйды ул кинәт.— Мин бит бу очракта да ике параллель турындагы теоремага таяна алам. АВ нигезенә С түбәсеннән шулай ук перпендикуляр төшерәбез, ул АД һәм ВЕ перпендикулярына параллель була. Аркылы яткан почмаклар тигезлегеннән чыгып, ДАС почмагының АСК почмагына һәм СВЕ почмагының ВСК почмагына тигез икәнен раслыйбыз, шуның нәтиҗәсендә эчке С почмагының тулы көенчә без тикшерә торган ике өстәмә почмак суммасына тигез булуын исбатлыйбыз. Димәк...— Коля утырган җиреннән сикереп торды, ләкин үзенең кайда икәне исенә төшеп, кычкырып җибәрүдән тыелып калды.— Димәк, теореманы тагын бер мәртәбә исбатладым,— диде ул үзалдына сөйләнүен дәвам итеп.— Ышанасы килми. Әгәр тагын берәр юл табылса?.. Булырга тиеш... Кызык нәрсә бит, ә?

Исбатлавының дөреслеген белү максаты белән, ул сызымны кабат-кабат тикшерде. Һәммәсе дөрес икәнлегенә тәмам ышангач кына, ул үзенең арыганлыгын тойды, аның йокысы килә башлады. Шәмне сүндереп, караңгыда чишенде. Ятар алдыннан кадерле аспид тактаны кровать астына идәнгә куйды. Мендәр астына кыстырса, язуы сөртелер дип курыкты.

Иртән күзен ачып җибәргәч, берни дә аңлый алмый торды. Бөтен тәне җылыга рәхәтләнеп оеп киткән. Кемдер аның өстенә икенче одеял китереп япкан. Абыйсыдыр инде — аның одеялы. Энеләре турында

Саша һәрвакыт кайгыртып тора. Әнә ул тәрәзә янына баскан да иптәшләренә нәрсәдер сөйли, кулында аспид такта.

Коляның башыннан яшен тизлеге белән, «Ул исбатлауны күргән» дигән фикер үтте.

— Саша! — дип дәште ул абыйсына.

Александр:

— Уянды! — дип кычкырып җибәрде һәм тиз-тиз атлап энесенең кроватена якынлашты. Одеялның бер читен кайтарып, кроватька утырды һәм энесенең бөдрә чәчле башыннан иркәләп сыйпап алды.

Ул бик нык дулкынланган иде. Энесенә ниндидер бер горурлык хисе белән текәлгән килеш:

— Молодец син! Молодец! — диде.— Кровать янында тактаны күргәч тә аңлап алдым. Дөрес исбатлагансың! Яңача! Үзеңчә!

— Тикшердеңмени? Чыннан да үземчәме? — дип, Коля торып утырды.— Мин бит дәреслеккә карарга курыктым. Китапны ачарсың, ә ул анда булыр...

— Юк, юк. Үзеңчә исбатлагансың. Ә хәзер бар, тизрәк юынып кил. Инспектор керсә, ач калдырыр.

...Шул көннән башлап теоремаларга яңа исбатлау эзләү Коля өчен гимназиядә иң кызыклы нәрсәгә әверелеп китте. Дәрес бетеп, төшке ашны ашагач, ул йокы бүлмәсенә чаба. Иптәшләре һавада йөреп керергә, бура уйнарга чакырсалар, «бүген чыга алмыйм шул», дип җавап кайтара һәм китапларына яки аспид тактага иелә. Ул үзен беренче тапкыр чит җирләргә сәяхәт итәргә чыккан кеше кебек сизә иде. Бер яктан, кызыклы сәяхәт, ә икенче яктан, бик читен. Фактлар кинәт аның алдына тау булып өеләләр, һәм аңарга яңадан-яңа исбатлаулар эзләргә, бик еракка китеп барырга туры килә. Әмма инде кечкенә генә җиңүгә ирешсә, ул чакта Коляның шатлыгы ташып чыга...

Әнә шулай акрынлап тәҗрибә өстенә тәҗрибә өстәлде, белеме артты, адымнары торган саен ныграк була барды: Лобачевский үзе исбатлаган һәр теореманың үзе өчен кыйммәтле белем багажына әверелүен, яңа геометрик фактларны һәм элементләрне ачарга ярдәм итүен, практикада көннән-көн киңрәк кулланылуын ачык аңлады.

Хәзер инде ул, яңа теореманы уку белән, аны ничек исбатларга икәнлегенә төшенеп ала. Хәтта тагын да ниндидер теоремаларның барлыгын, булырга тиешлеген сизенә һәм, аларны дәреслектә күреп, иске дус-

ларын очраткан кебек шатлана, геометрияне инде бик күптәннән белә, хәзер исә аны өйрәнми, бәлки исенә генә төшерә сыман иде.

Ләкин бер көнне ул көтелмәгән хәлгә очрады.

Кич ашап-эчкәннән соң, Лобачевский, гадәттәгечә, китапларын, кәгазен, шәмен алып, тынычрак урын эзләп китте. Классларына кереп утыргач, кинәт ул дәфтәрен читкә этәрде дә сикереп торып басты. «Ничек инде ул алай? — дип, тәмам аптырап фикер йөртте Коля.— Һәрбер яңа теорема үткәннәргә таянып исбат ителә. Алары тагын да алдагылар нигезендә исбатлана. Тегеләр үз чиратында шулай ук алдагыларга таяна... Панкратов белән без төп геометрик төшенчәләрне табарга тырышкандагы кебек, тоташ бер чылбыр хасил була икән шул. Ә бит иң беренче теоремалар булырга тиеш! Алар нәрсәгә таяна икән?»

Коля шулай аптырап бик озак хәрәкәтсез утырды. Шәмнең филтәсе күмерләнеп, факел сыман көйрәде, шәм уртасындагы «уймакның» кырые кыйпылып, эрегән май өстәлгә ага башлады. Малайны шәмнең чытырдап януы исенә китерде. Коля филтәнең көйрәгән өлешен өзеп алды, аннары дәфтәрен япты һәм дәреслеген актарырга кереште.

— Бернәрсә эшләп булмый! Алга чабарга дип торганда, артка борылырга туры килә! — диде ул, авыр сулап.

Исбатлауларны кире юнәлештә бер-бер артлы карый торгач, шактый вакыт утырылды. Ләкин иң гаҗәбе шул булды: Коля үзенә таныш билгеләмәләр, постулатлар, аксиомаларга барып терәлде. Аның башында бер генә сорау бөтерелде: «Болары нәрсәгә таяна икән? Алардан элек бушлык хөкем сөрәме икән?»

Дәреслектән аңарга саф-саф булып тезелгән биш постулат карап тора. Менә алар:

*«Таләп ителә:* I. *Теләсә нинди ноктадан теләсә нинди икенче ноктага туры сызык үткәреп булсын.*

II. *Һәм һәрбер чикләнгән туры сызыкны туры буенча өзлексез дәвам иттереп булсын.*

III. *Һәм теләсә нинди үзәктән теләсә нинди радиуслы әйләнә сызып булсын.*

IV. *Һәм барлык туры почмаклар үзара тигез булсын.*

V. *Әгәр ике туры сызыкка төшүче туры ике туры почмактан кечкенәрәк булган эчке һәм бер якта ятучы почмаклар хасил итсә, бу туры сызыкларны чиксез*

*дәвам иттергәндә, алар почмаклары ике туры почмактан кимрәк булган якта очрашалар».*

Латин сүзе «постулатум»ның «таләп итү» мәгънәсендә кулланылганын Коля Лобачевский белә иде. Мөгаен, шуңа күрә беренче дүрт постулат «таләп ителә» дип башлана торгандыр да. Ләкин нигә алай дип куюлары һич аңлашылмый, чөнки ул раслауларның дөреслеге беркайчан дәлилләнми һәм тикшерелми, ә, бәлки, ышанып кына кабул ителә. «Мин Пифагор теоремасына ышанам», дип кенә инану, билгеле инде, математик өчен көлке булыр иде. Аның дөреслегенә исбатлап инанабыз. Нигә соң без постулатларга ышанырга тиеш әле? Бу раслауларның кайсы да булса калганнарының нәтиҗәсе — теорема гына түгелме икән?

Коля, бик пошынып, Евклидның «Башлангыч»ын һәм геометрия буенча бүтән дәреслекләрне актарды.

Ачыкланмаган яки исбат ителмәгән бернәрсә дә төп төшенчә (нигез) итеп алынмый, дип яза бит Румовский. Алай булгач, ни өчен соң геометриянең нигезендә ятучы постулатлар һәм аксиомалар берниндн дәлилләүсез генә түгел, хәтта һичбернинди аңлатусыз китерелә. Нәрсә нәтиҗәсендә, нинди юллар белән килеп чыккан соң мондый раслаулар? Әллә алар тәңре тарафыннан иңдерелгәнме? Әллә аларны, куркыту җәтмәсенә төренгән дин кануннарын тәкрар кылгандай, сукырларча кабул итәргәме? Ышан һәм төпченеп маташма! Ышан?! Кемгә, нәрсәгә? Хакыйкатькә юл әллә, чынлап та, дин кануннары аша микән?

Коляның бөтен барлыгын, бөтен җанын әнә шундый сорау тетрәндерде. Математика булып математикада, фәннәр фәнендә әнә шундый чишеп булмый торган сорауларга тап булырмын, дип уйламаган иде ул.

Һәм менә тынгысыз уйлары аны Макарьевка алып китте.

...Шулай кышкы бер кичтә, Казан гимназиясенә әйләнеп кайтырга бер атналап вакыт калгач, Коля ялгызы гына үз бүлмәсендә утыра иде. Тирә-як тын. Кинәт шул тынлыкны бозып капка ишегенең тимер алкасы зыңлап куйды. Кемдер чак-чак кына ишетелерлек карлыккан тавыш белән чит йортка кергәндә әйтелә торган гадәти дога сүзләрен укып алды. Коля, йөгереп чыгып, өйалды келәсен ачуга, ишектән озын буйлы ябык бабай күренде. Аны картлык вә хәерчелек тәмам бөккән иде — чуалып киезләнгән чал чәче бүрек астыннан җыерчыклы маңгаена төшкән. Иске

җиләненең бер чабуы юк, аягында ямьшәеп беткән чабаталар, аркасында юкәдән үрелгән кәрҗин.

Алгы якка узгач ул иң әлек, почмактагы иконага карап, чукынып алды, аннары гына йөзен хуҗа хатынга борды.

— Нинди эшләр белән, кем сез? — дип сорады Прасковья Александровна.

— Алла колы мин, мосафир,— дип тешсез авызын чапылдатты карт чак-чак кына сулыш алгач.— Изге кешеләр миңа шушы йортны күрсәттеләр: сезнең ишекне кем генә какса да, бусагагызда алла исемен кем генә телгә алса да, якты чырай, ипи-тоз белән каршы алырлар, җылы почмак бирерләр, диделәр.

— Утыр, бабай, утыр, җылын! Әнә бит җиләнең ничек теткәләнеп беткән. Өстеңне сал да утыр.

Коляның әнисе чишенергә булышу нияте белән карт янына килде, ләкин аның гәүдәсенә орынгач ук, сискәнеп, артка тайпылды, авыз эченнән генә укынып куйды. Картның арык иңбашларына авыр тимер чылбыр уелып кергән иде.

«Каторгадан качкандыр», дип уйлады Коля коты очып. Дини максатлар белән тәнгә уралган чылбыр аның күзенә богау булып күренде бугай.

Карт, дога укый-укый, җиләнен үзе салды. Бүлмәдә ят тавыш ишетептер, ахры, Коляның бабасы да кабинетыннан чыкты.

— Алла хакы өчен, мәрхәмәтле кеше! — дип башын иде аңа мосафир.— Мин гөнаһлы бәндәгезгә бик аз вакытка гына олы йортыгызның бер бәләкәй почмагында яшәп торырга рөхсәт итегезче!

— Рәхим итегез, без бик шат, изге адәм,— диде Коляның бабасы бик дикъкать белән юлчының җыерчыклы йөзенә карап торганнан соң.— Исемең ничек синең?

— Гөнаһлы монах Варфоломей булам мин!

— Ә-әй, аллам! Синмени инде ул Варфоломей атакай?! — дип кычкырып җибәрде Прасковья Александровна.— Ишеткән идек синең турыда, бик күп ишеткән идек. Кайлардан киләсең, кай тарафларга юл тотасың? Утыр әле син, утыр! Хәл ал.

— Бүген торыр урыным юк, киләчәккә барышым,— дип җавап бирде карт урындыкка килеп тәрәлгәч,— җан авазы безне, җир кешеләрен, кояшка, хакыйкать юлына чакыра.

Ул башын иеп бераз тынып торды. Тик ирене кый-

мылдавыннан аның авыз эченнән генә ниндидер дога укуын шәйләп була иде. Аннары, берничә мәртәбә чукынып алды да, яңадан сүзгә керешге:

— Мин, анакай, караңгы Керженец урманнарында яшәдем. Үз кулым белән бәләкәй хөҗрә өлгертеп кердем. Кышкы суыктан җанымны саклар өчен мичен дә чыгардым. Үземнең әҗәлемне шунда көтәргә ният кылган идем дә бит... Гөнаһ шомлыгына каршы, насыйп булмады. Бер көнне коры-сары җыярга киткән идем, кайтсам — хөҗрәмнән кара күмер генә калган. Ә бит, мин ул хөҗрәдә аз гомер итмәдем, анакай, нәкъ кырык ел. Шунда ятып җан бирермен дигән идем. Инде агачтан чокып табуткаемны да әзерләп куйган идем. Табуткаем да янды. Картайдым инде, дәрманым-көчем бетте. Җәйгә кадәр генә яшәп торыймчы сездә. Алла хакы өчен мин гөнаһлы бәндәгезне ярдәмегездән ташламагыз!

Карт түбәнчелек белән билен бөгә башлаган иде дә Прасковья Александровна аны туктатып калды.

— Ишеттек, Варфоломей атакай, ишеттек сезнең бәхетсезлегегез турында. Макарьевога хәбәр килде. Патша солдатлары, Керженец урманнарында иске диндәге кешеләрне аулап, йортларын яндырып йөргәннәр икән. Ошбу гөнаһлары өчен теге дөньяда җавап тотсыннар, ярабби бер ходаем!

— Син аларны каргама инде, анакай,— диде монах кырыс тавыш белән.— Нинди киңәш биргән әле тәңребез безгә? Киңәш кенә дә түгел, үгет, бик гыйбрәтле үгет. Дошманнарыңны ярат, дигән. Менә! Укыганың бар идеме?

— Укыдым, укымый теге... Ләкин нишләп әле алар шулай азыналар? — дип баягы сүзенә ялгап китте Прасковья Александровна.— Алар да ходайга ышаналар лабаса.

— Ничек инде нишләп? Православие чиркәвеннән аерылып чыккан раскольниклар, ягъни иске диндәге кешеләр турында патша указы булды бит,— диде карт әле хуҗа хатынга, әле аның улына карый-карый.— Яңача чукынырга теләмичә иске диндә калган кешеләрне һәм шулай ук аларның яклаучыларын җәзаларга, диелгән ул указда.

Шунда Коля да түзмәде — сүзгә кушылды:

— Бабакай, ә, бабакай! Сезнең ул иске динегез бик шәпмени соң?! Нишләп әле гел аңа ябышып ятасыз? Ташлагыз сез аны...

— Динне ташларга? Үзебезнең хак динне?! Һәй, динсез малай! — дип беркавым бик нык рәнҗегән кыяфәттә башын селкеп торды монах.— Син нәрсә, әле тегеләй, әле болай борылып торырга, җил тегермәне түгел ләбаса мин. Юк, улым, мин хак дин юлында дәрвиш Варлаам кебек үк тугрылыклы. Ишеткәнең бар идеме Варлаам хакында?

— Юк, ишеткәнем юк,— диде Коля.

— Ишеткәнең булмаса, ишет. Безнең яктагы урманнарга Галич якларыннан килеп төпләнде ул. Анда мәхәллә побы булган. Әнә шул чиркәвен ташлап килгән. Әйткәнемчә, көннәрдән бер көнне безнең якларда төпләнеп калды һәм, өч шәкерте белән бергәләп, урман уртасындагы хөҗрәсендә яши башлады. Әй, хөрмәт итте дә инде, изге җан, иске динебезне. Патриарх Никонга кадәр чыккан китаплары да күп иде мәрхүмнең. Иске дингә тугрылыклы кешеләрне җыеп, шул китапларны көннәр буе тыңлатыр иде.

Бер заманны Галичтагы власть башлыклары сизгәннәр бит моның бу эшен. Кай арада отряд җибәргәннәр, кай арада бөтен урманны айкап, шарт-шорт мылтыктан атып, атабыз Варлаамны һәм аның шәкертләрен эзли башлаганнар. Алты атна йөргәннәр алар сазлык, чытырманлыклар кичеп. Һәм, ниһаять, килеп тапканнар. Яхшы чакта бирел, шәкертләреңне дә күндер, дигәннәр Варлаамга. Ә болар нишләгәннәр? Хөҗрәне эчтән бикләп, ут төрткәннәр һәм үзләре дә шунда янып үлгәннәр...

Бераздан Варфоломейны ашатып-эчерттеләр. Аннары Коля аны буш бүлмәгә озатып куйды.

— Алла ярлыкар, туганым! Алла ярлыкар! — дип кабатлады карт ике сүзнең берендә.— Без барыбыз да гөнаһлы бәндәләр, алла ярлыкар!

— Сезнең нинди гөнаһыгыз булсын, бабакай,— дип гаҗәпләнде Коля, әлеге сүзләрнең мәгънәсенә төшенмичә,— сез аллага ышанасыз ич...

— Һәммә кешенең асылы җаннан һәм тәннән гыйбарәт, улым. Җанны ходай яраткан, ә тәнне — иблис. Шуңа да инде тән туганнан бирле гөнаһлы. Шуңа да инде җан белән тән көрәшеп яши. Әгәр дә җанны тән җиңә икән, теге дөньяда җан явыз рухлар хөкеменә тапшырыла. Әгәр дә инде бу көрәштә җан өскә чыкса, бәндә бу дөньяда ук гомерен рәхәттә һәм ләззәттә үткәрә. Әмма хәзерге заманда дөнья хак дигәннән тайпылучылар белән тулды. Элеккеге ышаныч, хак тәга-

ләгә элеккеге тугрылык юк инде хәзер халыкта. Дошманыбыз антихрист Никон кешеләрне үз властена буйсындырды. Никонның ялчылары сарык тиресе ябынган бүреләр сыман, халык арасына чыгалар да: «Безнең динебез хак!» дип кычкыралар. Алар белән бәйләнгән кешеләрне алла каргар, ә инде алла каргаган кешеләр мәңге-бакый тәмугта янар. Кем дә кем чын хак дин юлына басарга тели икән, ерак сахраларга, кара урманнарга, таш-тауларга качарга тиеш. Безнең динне тотмаган кешеләрнең барысы да иблис токымнары.

— Туктагыз әле,— дип бүлдерде картны Коля.— Алла бер генә. Һәркем — иске диндә калганнар да, яңа динне тотучылар да — алланың берлегенә ышана. Ни өчен соң, алайса, алар бер-берсенә каршы чыгалар?

Варфоломей бераз уйланып торгандай булды да ышанычлы рәвештә дәвам итте:

— Рус диненең изге аталары тәңребезне фәкать ике бармак белән хөрмәтләргә кушалар, карт эт Никон һәм аның әшәке иярченнәре кебек өч бармаклы «чеметем» белән чукынып түгел.

— Шуның өчен үлемгә барганнармы инде? — диде Коля исе китеп.

— Аның өчен генә түгел,— дип дәвам итте карт,— башка сәбәпләре дә бар. Безнең дин китапларында Христосның исеме «Исус» дип бирелә, ә яңа китаплар бер хәрефкә арттырып, «Иисус» дип язалар. Безгә. иске диндәге кешеләргә, алай әйтеп дога уку түгел, бу турыда уйлау да куркыныч.

— Бер хәрефтән шулай куркасызмы?

Варфоломей Коляга төксе генә карап, чукынып алды.

— У-у, динсез малай! Минем җаныма тимә син, җәме! Телеңдә котыртучы шәйтан утыра синең. Бар инде, бар, йокларга вакыт сиңа.

Коля үз бүлмәсенә кереп яткач та тиз генә йоклап китә алмады. Дин өчен теләсә нинди корбаннарга да әзер торган Керженец урманы качакларының батырлыгы таң калдырган иде аны. Бер уйлап карасаң, чынлап та, алар дөреслекне, хакыйкатьне эзлиләр лабаса. Моның бәрабәренә нәрсә алалар инде алар? Фәкать эзәрлекләүләр генә. Кайдан килә соң аларга мондый көч? Һәм ни өчен алар үлемгә баралар? «И» хәрефе һәм ике бармак белән чукыну өчен генәме?

Коляның бабасы исә, тормышта диннән гайре яшәү мөмкин түгел, дип саный иде. «Нәрсәгә булса да ышанырга тиеш ич инде кеше», дияргә яратыр иде ул, «иске дин» белән «яңа дин» турындагы бәхәсләрне тавыш-тынсыз гына тыңлап утырганнан соң.

Бервакытны Коляның әнисе аннан:

— Нишләп әле син чиркәүгә йөрмисең? — дип сорады.

— Кайчандыр йөрдем, Пашенька, ә хәзер миңа анда ни калган? — диде карт эчендәген яшереп-нитеп тормыйча.

— Ә ходай тәгалә ни әйтер?

— Алла ул кешенең үзендә,— дип җавап бирде Коляның бабасы, һәм чиркәү йолаларын мал җыю өчен руханиларның уйлап чыгаруын, илаһи башлангычны җанның үзеннән, аның киләчәккә омтылуыннан, кешенең фикер хөрлегеннән эзләү кирәклеген бәйнә-бәйнә аңлатырга кереште.

— Алай булгач, алла кайда була инде?! — дип, сүзгә кушылып китте Коля. Бабасы исә имән бармагын оныгының маңгаена тидереп алды:

— Менә монда, синең фикер чыганагында. Беркатлы наданнар гына алла шәүләсен чиркәү эңгереннән эзлиләр.

Прасковья Александровна да поплар каршында тез чүгә торган ханым түгел инде түгелен. Бүлмәсендә почмак саен сын торса да, өстәл өстендә күн тышлы дини китаплар ятса да, балаларына беркайчан да догаларны көчләп укыттырмады ул.

Монах Варфоломей белән сөйләшкәннән соң Коля бабасы янына керде.

— Әйт әле син менә, бабакай, ни өчен патша фәрманы белән иске диндәге кешеләрне җәзалап үтерергә кушылган? — диде ул, ярсуын көчкә җыеп.— Патшага барыбер түгелмени анда: ике бармак белән чукынабызмы без, өч бармак беләнме?

— Хикмәт иске диндә генә булса иде, Коленька, хикмәт иске диндә генә түгел шул,— дип сузды Коляның бабасы һәм, берничә минут идән буенча әрле-бирле йөрде дә, диванга килеп утырды.— Сөйләсәң бик озын тарихы бар бу хәлләрнең. Борын-борын заманнарда безнең ерак бабаларыбыз славяннар Христоска түгел, ә Илгизәр Болытка — Сварогага табынганнар. Аннары инде Кояшка баш орырга керешкәннәр. Ниһаять, Кояш белән Болытны Яшен һәм Җир-Ана алыш-

тырган. Безгә христиан дине унынчы гасыр азагында гына килеп җиткән. Византиядән килгән ул. «Владимир заманында Русьны чукындыру турында риваять»тә бик тәфсилләп язылган бу хакта. Безгә беренче руханилар Грециядән килгәннәр. Русларның күбесе чукынырга теләмәгән. Ләкин князь Владимирның кырыс фәрманы белән халыкны елгаларга куып керткәннәр һәм көчләп чукындырганнар. Чукынырга теләмәгән кешеләр урманга качканнар. Шулай итеп славяннарның борынгы диннәре озак еллар сакланган әле. Бигрәк тә Идел арты һәм Төньяк урманнарына күпләп качкан халык арасында. Качаклар христиан динен генә түгел, гомумән, чиркәүне, попларны, патша яраннарын таныргa теләмәгәннәр. Хәрби хезмәттән качкан солдатлар да, крепостной крестьяннар да, казнага бурычлы кешеләр дә шул ук урманнарда яшеренеп яткан. «Нечем платить долгу, катай за Волгу» дигән мәкаль әнә шул еллардан туган инде. Безнең Керженец урманнарында да күп инде андый кешеләр. 1653 елны Алексей патша һәм яңа патриарх Никон рус диненә яңалык кертергә карар кылалар. Һәрбер чиркәүгә указ җибәрелә. Җиргә ятып маңгай оруны бил бөгү белән алыштырырга, ике бармак белән түгел, өч бармак белән чукынырга, диелгән була ул указда. Иске диндәге кешеләр указга буйсынудан баш тарталар һәм Керженец урманнарына күчеп утыра башлыйлар. Өстәвенә, халыкны мур кыра башлый. Кайбер төбәкләрдә үләт чире халыкны авылы-авылы белән алып китә...

Аннан соң корылык башланган, ачлык еллар килгән. Дөньяда явыз рух тантана итә, дип сөйләргә ятратканнар ул чагында иске динлә калучылар. Кяфер Никонга иярүчеләргә алла каргышы төште... Яңа патриарх кына түгел, бөтен газап-җәзаларны уйлап табучы патша үзе дә иблис хезмәтчесе, имеш. Мондый вәгазьләргә каршы патшаның «Бөек патша йортына тел тидергән өчен, терелләй утта яндырырга!» дигән боерыгы чыга. Һәм озакламый Нижегород архиепископы Питирим кушуы буенча, капитан Ржевский, Керженец урманнарында качып ятучы «дәрвиш»ләрнең хөҗрәләрен көл итәр өчен, махсус отрядлар оештыра башлый. Җитмеш җиде мәхәллә-скит тар-мар ителә. Иске дингә күчкән дьякон Александрның башын балта белән чабып өзәләр. Тагын берничә кеше Пафнушево авылы янында утта яндырыла. Иске диндәгеләрнең

кырык меңләбе Керженец урманнарыннан Литва җиренә, Польша короле кулы астына качып китә.

— Кырык меңләбе?! — дип гаҗәпкә калды Коля.— Һәммәсе чит илгә киткәнме?.. Анда тәкъва тормышмы?

Карт бу сорауга җавап бирә алмады, бары тик иңбашын гына сикертеп куйды...

Үз бабасыннан тыш тагын бер картның сүзләрен тыңлаганы бар Коляның. Анысы Макарьевның җилкәнле корабларында койрыкчы булып эшли торган иде. Инде күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше. Кытайда да булган, Һиндстанда да. Төрле ил кешеләренең төрле аллаларга табынуларын Коля беренче тапкыр әнә шул картның авызыннан ишетте.

— Йөз чакрым узасың — бер алла, елганы яисә тау сыртын кичеп чыктың исә — икенче алла. Ә диңгезнең аргы ягында башка алла буласын көт тә тор,— дип сөйләгән иде ул койрыкчы.

Коля исә әйтә куйды:

— Бәлкем, ул илләрдә алла түгел, ә уйлап чыгарылган нәрсә генәдер. Күктәге аллалар өчен җирдә чикләр була димени?

Карт диңгезче мыек астыннан гына елмаеп сүзен болай төгәлләде:

— Менә бу кадәресен әйтә алмыйм, улым. Күктә булганым юк, аларның чикләре ничектер анда, үзләренә генә мәгълүм.

Коляның андый сорауларны күрше йортта торучы карт дьяконга да биргәне бар иде. Дьякон аны зур дикъкать белән тыңлап торды да болай диде:

— Чын алла бер генә. Башка аллаларга табынуга килсәк, монысы хак юлдан тайпылу, адашу, ягъни мәсәлән. Юк шул әле, юк, бу җиһанда барлык кешеләр дә Христос нуры белән яктыртылмаганнар әле...

Коляның бу хакта башка диндәге кеше белән дә сөйләшеп карыйсы килде. Озак еллар патша хезмәтендә солдат булган татар карты гимназиядә төнге каравылчы иде. Ул гаиләсе белән шул ук бинаның подвалында фатирда яшәгәнлектән, Коляга еракка китеп йөрисе булмады. Мөхәммәт өммәтенә ышанган, мөселман бәйрәмнәренең вә йолаларының һәркайсын зур төгәллек һәм хөрмәт белән искә алып, үтәп барган карт иде. Коляның:

— Ни өчен кешеләр төрле аллаларга табыналар? Аллаларның кайсы кодрәтлерәк — мөселман алласымы, әллә христианнарныкымы? — дигән соравына каршы уйлап та тормастан җавап бирде. Ул: — Барча бәндәләр өчен алла бер. Безгә ул Мөхәммәт пәйгамбәребез аша ачылган, ә сезгә Христосыгыз аша...

— Ничек инде ул алай? Алла бер, ә диннәр төрле?..

Бабай ачулана башлады.

— Синең гакылың җитми аңа. Алланың кодрәте киң. Тәңребез ничек тели, шулай эшли.

— Ә безнең дьякон атабыз әйтә, алланың бердәм өч сурәте бар, ди.

— Алдый ул сезнең дьяконыгыз,— дип Коляны бүлдерде бабай.— Аның үзенә өйрәнергә кирәк әле. Сезнең Иисусыгызның җиргә аяк та басканы юк, диләр. Ә менә Мөхәммәт пәйгамбәр турында берәү дә алай әйтми. Аңлашыламы?

— Аңлашыла,— диде Коля бабайны үпкәләтмәс өчен. Чынлыкта исә ул берни дә аңламады. Киресенчә, тагын да ныграк буталды.

Шул рәвешчә, өлкәннәр авызыннан рәтле-юньле җавап ала алмагач, Коля гимназия китапханәсенә кереп, «Изгеләр тормышы», «Христосның газаплары һәм үлеме» кебек дини китапларны укып карады. Библия белән дә танышты. Тик берсенең дә файдасы тимәде. Ул китаплардагы дөньяның яратылуы һәм ахырзаман, алла кодрәте турындагы беркатлы аңлатмалар Коляның күңелен генә болгаттылар. Чиркәү китаплары акрынлап-акрынлап Коляның өстәленнән югала торды. Алар урынында, надзирательләрне һәм дин укытучысы протопоп Михаилны гаҗәпкә калдырып, Бюффонның «Табигать тарихы» томнары, Галилейның «Йолдыз дөньясы илчесе», «Мәгърифәтчелекнең беренче адымнарыннан Еликурга кадәр кеше акылы тарихы» кебек китаплар пәйда булды. Борынгы философларның әсәрләре аның башында кайнаган сорауларга, һәрхәлдә, тулырак җавап бирәләр иде.

— Сез, Лобачевский әфәнде, хәвефле сукмактан киттегез,— дип кисәтеп тә куйды хәтта бервакытны аны протопоп.— Гөнаһлы китаплар гына укыйсыз. Сезне Христостан аерачак андый китаплар, карагыз аны! Миңа калса, сез кичә инанган нәрсәләргә бүген шикләнеп карый башладыгыз шикелле. Шулай түгелме?

— Бәлки, атакай, бернинди шик-шөбһәләрдән курыкмый торган дин дә бардыр дөньяда, ә?

Протопоп Михаил кулын югары күтәрде, янагандай итеп бармак селкеде.

— Бу хакта иртәгә сөйләшербез.

Икенче дәрестә исә «зилзилә» купты. Христиан диненең асылы — изге «өчлек» хакында, ягъни алланың бер булуы, ләкин шул ук вакытта өч рәвештә, ягъни алла-ата, алла-ул һәм алла-изге җан сыйфатларында чагылыш табуы хакында сөйләде. Сөйләде дә укытучы, әңгәмәсен:

— Менә шуңа күрә дә инде өч бармак белән чукынабыз,— дип төгәлләде.

— Башым җитми,— диде шунда Коля,— кайчан әле бернең өчкә тигез булганы бар?

— Сез... сез, Лобачевский,— диде укытучы кызарынып-бүртенеп.— Сез бөтенләй динсезләнгәнсез. Дин хакында бәхәсләшү алла каршында бик зур гөнаһ. Зирәклекнең башы — алла хөкеменнән куркуда...

— Менә син ышан! — дип кычкырып җибәрде Коля буш класста берьялгызы, уку китапларына мөрәҗәгать итеп.

Ул шәмне өреп сүндерде дә, дөм караңгыда куркуның әсәрен дә тоймыча, йокы бүлмәсенә юнәлде.

## 3

Апрель азагы җитте. Ул елны яз иртә килде. Боз әсирлегеннән котылган Казанка, җәелеп, киң дәрьяны хәтерләтеп ялтырап ята. Чиркәү гөмбәзләре, Сөембикә манарасының очлы башы, сарай түбәләре, экипажлар — барысы да, барысы да алтын суында манчылгандай җемелдәп, тирә-якка нур чәчеп тора. Шәһәр урамнары халык белән шыгрым тулы. Яшәрә башлаган ботакларда чыпчыклар чекердәшә, бакчаларда яшь үлән борын төртеп килә.

Гимназиядә соңгы атнадагы дәресләр барысы да диярлек дини темаларга гына багышланганнар иде. Менә, ниһаять, пасха бәйрәме дә килеп җитте. Бу көнне укучылар, икона каршында тез чүгеп, гыйбадәт кылырга тиешләр.

Билгеләнгән сәгать сукты. Укучылар, парлап-парлап икенче катка күтәрелеп, залга үтә башладылар.

Ишектән уңдарак тәрәзә янында уртанчы класслар хоры урын алды.

Залга өлкән класс укучылары кергәндә, түбән һәм уртанчы класслар инде рәт-рәт булып басканнар, бер-берсенә кысылышып, гыйбадәт башланганын көтәләр иде.

Ишектә Яковкин күренде.

— Ә кайда Матвей Никитич? — дип сорады ул кырыс кына.— Кем укый бүген?

Директор янына, кызарынып-бүртенеп, сүзен әйтә алмаслык дәрәҗәдә дулкынланып, класслар буенча дежур офицер Перевощиков килде дә, «Догалык» һәм «Евангелие» укырга билгеләнгән гимназистларның икесе дә булмавын белдерде.

— Соң, алайса, яңаларын билгеләргә кирәк,— диде Яковкин, чыраена канәгатьсезлек билгеләре чыгарып.— Нишләп әле бу турыда алданрак кайгыртмадыгыз?

Бик тә уңайсыз хәлдә калган Матвей Никитич директор янынннан китте дә өлкән класс укучылары рәтенә таба атлады, чак-чак кына ишетерлек мескен тавыш белән:

— Әфәнделәр, кайсыгыз булса да чыгыгыз инде укырга,— диде.

Селкенүче күренмәде. Гимназистлар бары тик бер-берсенә генә карашып алдылар.

Ә директор сабырсызлык белән көтеп тора иде.

— Уртанчы Лобачевский, Панкратов!.. Әйдәгез әле, әйдә чыгыгыз, рәхим итегез! — Матвей Никитич стена буенда торган Коляның җиңеннән тартты.

— Менә сезгә китаплар. Панкратов әфәнде, сез дога укыгыз. Ә сез, Лобачевский әфәнде, Евангелие укырсыз.

Дуслар теләр-теләмәс кенә алга чыгып бастылар.

Панкратов үз-үзен тиз кулга алды һәм карлыккан тавыш белән укырга да керешге:

— Во имя отца, и сына, и святого духа...

Хор дога сүзләрен көйгә салып кабатлады. Аннары янә Панкратов укыды. Аннары тагын хор...

Ниһаять, Гаврило, дусты ягына карамыйча гына тиз-тиз пышылдап алды:

— Синең чират, Коля! Син укы!

Лобачевский аны-моны уйлап тормыйча, дустына борылып карады, үзенә дә сәер булып тоелган ят тавыш белән башлап җибәрде:

— Евангелие от Луки...

Бик тибеш укыды ул. Ничек укуы турында үзүзенә хисап биреп тормыйча, әйткән сүзләренең мәгънәсен үзе дә аңламыйча укыды. Кыскартылган «Евангелие»не әнә шулай бер сулыш белән укып чыкты да китапны шапылдатып ябып та куйды.

Залда чыш-пыш китте, кемнәрдер тавышланып урыннарыннан кузгалышып куйдылар, бүлмә надзирательләренең кычкырып сөйләшкәннәре ишетелде, чырае сытылган директор дежур офицер каршына килеп басты.

— Перевощиков әфәнде,— диде ул кулын бутыйбутый.— Панкратовыгыз ярый әле, бераз бутаса да, түзәргә була. Ә Николай Лобачевский укуы адәм көлкесе! Кысладай кызарынып, янгынга барырга җыенгандай ашыгу нигә? Башлап өлгермәде, тәмамлап та куйды. Нәрсә соң бу, алла белсен!

Директор Коляга «Евангелие»не, чиркәү этикасының бөтен кагыйдәләре кушканча, ун тапкыр ачыпябарга кушты.

Гимназистлар һәм студентлар аның яныннан парлашып уза тордылар. Берәүләре көлемсерәп, икенче берәүләре битараф рәвештә, ә кайберләре (мондыйлары күбрәк иде) аның хәленә кереп, дусларча елмаеп узды.

Ниһаять, җәза тәмамланды. Коля хор җырчылары чыгып беткәнче көтеп торды да алар артыннан ишеккә юнәлде...

Менә хәзер, төшке аштан соң үз урынына менеп яткач, иртән гыйбадәт кылганда булган хәл аның күз алдына килеп басты. Бөтен барлыгын газаплы хис биләп алды. Йоклаучыларга бүлмә надзирателе Сергей Александрович Попов берничә мәртәбә күз салып узды. Аны күргәч Коля йоклаганга сабышып ятты. Ләкин ул йокламый, аның уйлары еракта, бик еракта калган Макарьев якларында адашып йөри иде...

Балалар бүлмәсе кояш нурына мөлдерәп тулган. Ә ул, Коля, үтә күренмәле юка чаршау белән уратып алынган йомшак урында йокымсырап ята. Менә: «Торыгыз, кияү егетләре!» дигән назлы тавыш ишетелә. Чаршау чите аз гына ачыла. Кояш нуры туп-туры аның йөзенә төшә һәм ул чытырдатып күзен йома. Бераздан ике бите мич кызуыннан алсуланган әнисе күренә. Ул кардай ак алъяпкыч бәйләп җибәргән, җиңнәрен терсәккә кадәр сызганган. Ул нәрсәдер пешерә һәм монда, узышлый гына, улкайларын иртәнге

чәйгә чакырырга гына кергән булса кирәк. Бераздан Коляның колагына ниндидер тантаналы чаң тавышы килеп керә. «Күр әле, онытa язганмын, бүген бәйрәм лабаса», дип шатлана ул эченнән генә.

— Ә пирог пешердегезме? — дип сорый Коля энисеннән. Ә үзе күзен ачмый, энисен керфек арасыннан гына күзәтә.

— Пешердек, пешердек,— ди энисе ачуланмыйча гына.— Торыгыз инде, кияү егетләре алай озак йокламый, йә кәләшсез калырсыз.

Вакыт дигәнең ничек тиз уза. Коляның Казан гимназиясе бусагасын атлап кергәненә дә кырык ике ай тулган икән инде. Тиздән ул студент булачак. Өлкән абыйсы Александр аны бүген студентлар җыенына алып барырга вәгъдә бирде.

Менә шуңа күрә дә йоклыйсы килми инде Коляның. Йоклап китмәс өчен ул узган җәй Макарьевода ничек итеп өч туган бергәләшеп урман-кырларны, басуларны гизеп йөрүләрен, ерак күлдә балык каптыруларын искә төшереп ята.

Нинди күңелле иде ул сәяхәтләр!

Коляның әле дә күз алдында тора: берчакны төнен кармак белән балык каптырыр өчен алар күл буена кичтән үк төшеп утырырга булдылар.

Күлгә кадәр җиде чакрымлап җәяү барырга кирәк иде. Шуңа күрә кояш баеганчы ук юлга чыктылар.

Күз алдында вак куаклык һәм камыш белән уратып алынган иксез-чиксез күл көзгесе ачылып киткәч, Коляның бер мәлгә сокланудан хәтта сулышы кабып торды. Күлнең нәкъ урта бер җиренә сихри алтын сукмак булып ай юлы сузылган, бөтен тирә-як тын, ара-тирә күлдә балыклар сикереп кенә илаһи тынлыкны бозалар иде.

Туганнар, табигатьнең шушы хозур халәтен, әкият мизгелен хәтерләренә сеңдереп калырга теләгәндәй, үзара сөйләшмичә генә кармакларын әзерләделәр.

Кармак салгач Коля әле йолдызлы күк йөзенә, әле күктән коелган нурлар белән тоташкан су өстенә сокланып карап торды. Бу күренеш үзеннән-үзе аны татлы хыял диңгезенә, могҗизалы хәятнең чиксез сахраларына, серле билгесезлек дөньясына алып китте...

Александр Коляны чак-чак кына төрткәләп уятты:

— Тор дим, тор, йокы чүлмәге! Соңга калабыз.

— Кая?.. Ни өчен?..— дип, караватына бөкләнеп

утырган килеп эшнең асылына төшенергә тырышты Коля. Күзе чүп кергәндәй авырта иде аның. Шулай, керфеген челт-челт китереп утыра торгач, ниһаять хәтеренә төшерде:

— Җыенга дүрткә барырбыз дигән идең ич син.

— Ә хәзер бишенче.

Коля айнып китте. Күр әле, йокламаска тырышып, йокы белән көрәшеп ятсаң да, җиңеләсең икән. Ул тиз генә караватыннан сикереп төште дә киенергә тотынды.

Абыйлы-энеле Лобачевскийлар әле күптән түгел генә университетка бирелгән Тенишев йортының чарлагына менделәр. Морҗа янында, тузанлы әрҗәләр өстендә, бер-берсенә сыенышып утырган студентлар арасында сүлпән генә башланган әңгәмә бик тиз җанланып китте. Унҗиде яшьлек күрер күзгә күркәм егетнең сүзләрен иптәшләре бигрәк тә бирелеп тыңладылар. «Василий... Дмитрий Перевощиковның өлкән абыйсы», дип пышылдады Александр Коляның колагына.

— Табигатьне танып-белү сизү тойгысы белән генә чикләнсә,— дип сүзен дәвам итте Василий,— бик сай булыр иде белемебез. Сөйләшә алмый торган хайваннарныкыннан аз гына артыграк булыр иде ул. Сизү тойгысы чиге акылыбызның чиге булыр иде. Ләкин кеше моннан ничә мең еллар элек булган һәм һәр төрле сизү тойгысыннан иксез-чиксез киңлекләр вә вакыт белән аерылган нәрсәләрне белә. Акыл моңа хыялфараз ярдәмендә ирешә: һәммәсен-һәммәсен, әйтерсең лә ниндидер тылсымлы, әмма дөрес күрсәтүче көзгедә күрә. Фараз итү, күз алдына китерү сәләтеннән башка акыл хәтта абстракт төшенчәләргә дә үтеп керә алмас иде: гомум төшенчә чыгару өчен, бик күп, бик күп аерым хакыйкатьләрне хәтерләү, күзаллау лазем.

— Әллә шуңа күрә немец философлары язган китапларның күбесе бик авыр аңлашыла микән? — дип, ак тешен күрсәтеп елмайды бер таза гәүдәле егет.

Өлкән Лобачевский аңа шауламаска кушып ишарә ясады.

— Авызыңны ерма әле, Зыков. Мәсьәлә бик җитди бит.

Студентлар игътибар беләнрәк тыңлый башладылар.

— Дәвам ит, Василий! Син кызык нәрсәләр турында сөйлисең, ләкин...

Александр тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, тик Василий, аны бүлдереп, янә сөйләргә тотынды:

— Күз алдына китерү, фараз итү безгә танып-белүебезне баету өчен генә түгел, дәртләребезне кузгатыр өчен дә хезмәт итә. Руссо, Рейналь һәм аларның теләктәшләре тигезлек, ирек, гомумән ниндидер алтын гасыр турындагы фикерләре белән французларның хыялларын кабыздылар һәм французлар файдасыз, фаҗигале революция ясап маташтылар.

— Юк, юк! Мең мәртәбә юк! Кайда гына ясалса да — җәмгыятьтәме, фәндәме — революция файдасызга булмый,— дип чәчрәп чыкты Петр Балясников, күптән түгел булып узган гимназистлар бунтын оештыручыларның берсе. Петр шактый эре гәүдәле егет булып, аның бөтен кыяфәтеннән, килеш-килбәтеннән гайрәтлелек бөркелеп тора иде. Борын астына тибеп чыккан куе төк сызымы аның егетлек сыйфатларын тагын да көчәйтә төшәләр, аны үз яшеннән өлкәнрәк итеп күрсәтәләр иде.— Әйтик, математиканың, аерым алганда, геометриянең үсәргә, үзгәрергә хокукы юкмы? Эвклид безнең өчен чик булмаска тиеш. Ул тукталган урында гына таптанып торырга тиеш түгелбез. Безнең дә үз фикеребез, тормышка вә җәмгыятькә үз карашыбыз һәм, ниһаять, үз зәвыкларыбыз булырга тиеш лабаса. Минемчә, Василий киләчәк турында ифрат кырыс һәм консерватив фикер йөртә. Йә, син нәрсә диярсең, математик? Дөрес әйтәмме мин?

Барысы да морҗага сөялеп торган уртанчы Лобачевскийга борылып карадылар. Көтелмәгән сорау гәрчә аны бераз каушатып җибәрсә дә, күңелендәгеен түкми-чәчми әйтеп салды ул.

— Минемчә, француз революциясе кешелекне якты киләчәккә илтә торган баскычның бер басмасы гына әле ул.

Николай тынып калды. Иптәшләре аның илһам уты белән яктыртылган йөзенә текәлделәр. Бу минутта ул шигырь юлларын ачык итеп кенә түгел, матур итеп әйтеп бирә белгән шагыйрьгә охшаган иде. Нинди чос студент Василий да аның сүзләренә каршы торырлык дәлил таба алмады.

— Әфәнделәр, уртанчы Лобачевскийны үзебезнең союзга кабул итәбезме?! — дип кычкырып җибәрде Петр.

— Итәбез, итәбез! — диделәр студентлар бертавыштан.

Петр Балясников һәрвакыт нинди дә булса идея белән янып яши торган егет булып, үзендәге энтузиазмны иптәшләренә дә йоктыра белә иде.

— Без әйбәт укымыйбыз,— дип башлап китте ул беренче җыелышта,— укытучыларыбызны алдыйбыз. Әйтерсең лә алар өчен укыйбыз инде. Ә бит халкыбызның барыр юлын мәгърифәт нуры белән яктырту — безнең иң изге бурычыбыздан. Халык белемле булса гына үзенең тормышын яхшырта алачак. Шуңа күрә фән безгә нәрсә бирә алса, без һәммәсен алырга тиешбез. Мин шәхсән үзем математика белән физиканы бик ныгытып өйрәнәчәкмен һәм бөтен көчемне табигатьне өйрәнүгә багышлаячакмын.

Балясников артыннан берәм-берәм башкалар да (алар барысы да беренче йокы бүлмәсендә торалар, ә ул бүлмәдә «начальствоның күзе һәм колагы» булган камерный студент хезмәтен студент Петр Кондырев кирәгеннән артык тәгәл башкара иде) аяк өстенә басып, тантаналы вәгъдә бирделәр. Александр Лобачевский, «философиягә мөкиббән егет, меланхолик» (Петр Кондырев үзенең Яковкинга язган рапортында аны әнә шулай дип атаган иде) һәм «табигать фәненә тугрылыклы, начальство белән дорфа сөйләшсә дә, тумыштан йомшак күңелле» Павел Чуфаров, мәсәлән, Галәмне барлыкка китерүче беренче сәбәпләрне ачыкларга кирәк таптылар. «Үзеннән өлкәннәрне хөрмәт итүче, тиңдәшләре белән үтә горур, ә үзеннән түбәннәргә боерырга ярата торган» Владимир Граф университетта укытучы булып калырга теләк белдерде. «Татар телен бик теләп өйрәнүче һәм кушканны җиренә җиткереп башкара торган» Федор Риттау һәм «шат күңелле, акыллы» Петр Зыков «башка халыкларның, бигрәк тә болгар татарларының» төрле җырларын, риваятьләрен, кулъязма китапларын, кабер ташларына язылган язуларын җыярга алыначакларын әйттеләр. Василий Перевощиков исә, «нәфис сәнгать һәм матур әдәбият турында докладлар әзерләргә», әле тагын — шигъри әсәрләр алып килеп укырга сүз бирде.

«Беренче бүлмә студентлары»ның җыены әнә шундый мәсьәләләрне көн тәртибенә куйды. Ярымкараңгы чарлакка җыелуның төп сәбәбе үзләренең иң мөкатдәс уй-фикерләрен Яковкин шымчысы Кондыревка белгертәсе килмәүдән иде. Чарлактагы әңгәмә бер-

кайчан да күңелсез булмый. Холык-фигыльләре белән бер-берсеннән аерылып торган студентларны бирелә һәрвакыт фикер уртаклыгы берләштергәнлектән, хакыйкатьне, бер-берсен кызганып, нәзакәт саклап тормыйча, күзгә карап әйтсәләр дә, алар арасында бернинди дә күләгә юк иде әле.

Александр Лобачевский мондый бәхәсләрне — акыл канатларының биниһая биеклеккә омтылган минутларын, күңелләрнең бер-берсенә шыр ачык булган, күзләрнең очкынланып янган, тавышларның алга әйдәүче тыелгысыз көч белән тулышып яңгыраган мизгелләрен бик ярата иде. Мондый чакларда ул кешекарага сиздерми генә бер читкә китә дә, йөрәгендә кайнаган илһам уты сүрелгәнче, сүз белән мавыккан иптәшләренең портретларын сызгалап ташлый. Кәгазь бите буйлап карандаш очы берничә мәртәбә йөгереп үтүгә Василийның тулы яңагы, Балясниковның бөркетнекенә охшаган гайрәтле борыны, Федорның киң маңгае, Зыковның шаян кысык күзе, Владимирның озын муены төсмерләнә башлый. Янә берничә штрих — аларның елмаюлары, төс-кыяфәтләре, килеш-килбәтләре кәгазьгә төшеп мәңгеләшә. Карандаш белән уйный-шаяра гына ясалган мондый рәсемнәр иптәшләрен ирексездән көләргә мәҗбүр итә, нервыларын тынычландыра, әңгәмәне тагын да кызыклырак, җанлырак, мавыктыргычрак итә иде.

Бу юлы да Александр үзенең шаржлары белән мавыккан иде. Иптәшләре аны күрмәгәнгә салышып, әңгәмәне дәвам иттерделәр. Сөйләшү инде кешеләргә аң-белем бирү юлында шигъриятнең тиңдәшсез куәтле корал булуы турында бара иде.

— Шигырь кешенең күңелен сихерләп, аның фикерләвенә тәэсир итәргә, дәртен кузгатырга, акылны яктыртырга тиеш! — дип дәвам итте оратор.— Әле кичә генә мин Радищевның кулъязма китабын укып чыктым. Аны миңа Ибраһимов биргән иде. Тыңлап карыйсыгыз киләме? Әйбәт шигырь!

Студентлар тынып калдылар.

— Укы, Василий, укы! — дип пышылдады бераздан кайсыдыр.

Перевощиков чалбар кесәсеннән бәләкәй генә дәфтәр чыгарды һәм аны, сул кулында тотып, уң кулы белән кискен хәрәкәтләр ясый-ясый, әйткән һәр сүзенә көч-куәт биреп, тантаналы тавыш белән укырга тотынды:

Әй, син, кеше, әй син, җир патшасы,
Мескенләндең, көчең беттеме?
Бик зәгыйфь син, корттай бәләкәй син,
Галәмдә бер тузан бөртеге.
Тик илаһи зат син, беләм, беләм,
Син куәтле, син кодрәтле,
Син бит бөек гакылың белән!

— Шәп! — дип утырган әрҗәсеннән сикереп торды Балясников.— Бернинди эчкерлелек юк. Ләкин бит җәмгыять һәм шул җәмгыятьне оештыручылар бик тә мәкерле халык. Шагыйрьләр алардан сакланырга тиеш. Шундый гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат итүчеләрне мәзәкчеләр белән бер рәткә куеп йөртергә ярыймы соң инде, йә? Алар, минемчә, ил батырлары белән бер дәрәҗәдәге кешеләр. Сарай җырлары җырлап яшәү бөтенләй чит нәрсә булырга тиеш алар өчен. Талантлы кешеләргә теләсә нинди орденга, дан-шөһрәткә, ялтыравыклы кареталарга караганда, горурлык килешәрәк төшә. Исегездәме, Радищевның мондый шигыре бар:

Язмыш кушып бу көн юкка чыккач,
Яңа көннәр туар ич тагын,
Нуры белән шушы җырларымның
Балкып китәр салкын туфрагым.

Данга сусап килер дә бер егет,
Әйтер каберемә текәп күзен:
«Карамыйча власть изүенә,
Богаудагы шушы кеше менә
Башлап әйтте «Азатлык» сүзен...

Студентлар шигырьне сулыш та алмый тыңладылар. Чарлакта тып-тын иде. Шул тынлыкны бозып, читтәрәк кемдер ютәлләде.

Егетләр дерт итеп киттеләр, дәррәү борылып карадылар. Анда, ишек яңагына сөялеп, укытучы Ибраһимов тора иде. Аның куе кара чигә сакаллары белән уратылып алынган ябык, төссез йөз сызыклары ачылып калган ишек авызында рәсемдәге кебек төгәл, ачык булып күренә. Ибраһимов күптәннән каты авырый, шуңа күрә геометрия дәресләре булмаганга да ике айлап вакыт узган иде инде.

Беренче булып Василий Перевощиков аңына килде: ул сөекле укытучылары янына йөгереп барды да, аны култыклап, тынып утырган студентлар янына алып килде.

Исәнләшкәннән соң Ибраһимов өзек-өзек кенә сөйләргә кереште:

— Доктор Бенестан кайтып барганда чарлакта тавыш ишеттем... Бала-чагадыр, дип уйлаган идем, сез икәнсез... Шулай бергә җыелып тыелган китаплар укырга гимназия Советы рөхсәт бирдеме соң сезгә? Әгәр бирмәгән икән, киләсе утырышта мин бу хакта әйтергә тиешмен. Законга каршы эш белән шөгыльләнгән өчен, сезне аттестат-фәлән бирмичә генә университеттан сөрәчәкләр. Гимназия тарихында андый хәлләр булгалады инде...

Ибраһимов тагын ютәлли башлады. Тын алгач, дәвам итте:

— Сезнең арада сатлык җаннар юктыр. Шунда булган шунда калыр, дип ышанам мин...

Барысы да җиңел сулап куйдылар. Ләкин Петр Балясников ярсып һәм гасабиланып ярып салды:

— Алайса, без ирек сөючеләр булудан баш тартырга тиешбезмени инде? Алайса, тормышта һәм җәмгыятьтә үзебезне кызыксындырган нәрсәләр турында да сөйләшергә ярамыймы икән инде безгә?

— Юк, киресенчә,— дип каршы төште Ибраһимов.— Сезгә бер гаилә булып тупланырга кирәк. Әйтик, берәр түгәрәк яисә җәмгыять оештырсагыз бик әйбәт булыр иде. Менә шул чагында инде кешене эзләнергә мәҗбүр итә, дулкынландыра, уйландыра торган, кыскасы, күңелдә бик күп фикер уята торган этикага һәм җәмгыятькә кагылышлы мөһим мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкин булыр иде. Ләкин, әлбәттә, башта рөхсәт алырга кирәк. Мин сезне, яшь дусларым, бөтен йөрәгем белән аңлыйм. Һәм мин, һичшиксез, сезнең матур башлангычыгызны якларга кирәклеген беләм, башлыкларга раслап күрсәтергә тырышырмын... Ә хәзер таралышыйк. Ләкин берәм-берәм генә. Күрегез әле, язгы кояшның яктылыгын! Безнең өчен коя бит кояш илаһи нурын!

Карсак буйлы, авыру чырайлы бу кеше әйткән сүзләрнең һәркайсы яшьләрнең йөрәгенә сары май булып ята иде. Аның дәресләрендә көлгән чаклар да була, елаган чаклар да. Әмма беркемне дә битараф калдырмый иде аның дәресләре...

«Әгәр дә бу хакта Яковкин белсә», дип борчылды Коля үз бүлмәсенә кайткач, укытучысын уйлап.

Гимназиядә Пасха бәйрәме тәмамланды. Лобачевский, коридор буйлап йөргәндә, башка гимназистларның да чырайлары чытык булуын абайлады. Беркем-

не дә күрәсе, беркемгә дә барып кул сузасы килми иде аның. Чөнки аларның күбесенә ышанмый иде. Чарлактагы әңгәмә хакында боларның кайсына сөйләмәк кирәк инде? Йокы бүлмәләренә Кондырев кебек ялагай алабайларны билгеләп, укучы һәм студентларның эч серләрен алу максатын күздә тота да инде Яковкин.

Тенишев йортының чарлагында Ибраһимов белән булган очрашудан соң бер атналап вакыт узгач, гимназия конторасында яңа дело барлыкка килде. «Укытучы Ибраһимов, студент Васильев һәм башкалар төзегән Россия әдәбияты җәмгыяте турында. 1806 елның 9 нчы мае», дип язылган иде анда *.

# *Бишенче бүлек*

## 1

Китапханә гимназия бинасының аскы катындагы дүрт бүлмәне алып тора. Иң зур бүлмәдә — уку залы, ә калган өчесендә китаплар, кульъязмалар, атласлар, ноталар, эстамп һәм портретлар саклана. Сирәк очрый торган минераллар, спиртлы банкалар эчендәге төрле бөҗәкләр, борынгы болгар-татар акчалары да шунда ук куелган иде. Аннары җир һәм күк глобуслары, Казан губернасының зур итеп эшләнгән планы, хәтта телеграф моделе дә булып, ул китапханә бер үк вакытта музей ролен дә үти кебек иде.

---

* «1806 елда Н. М. Ибраһимов җитәкчелегендә без артык зур булмаган әдәби түгәрәк оештырдык,— дип язды үзенең «Истәлекләр»ендә С. Т. Аксаков.— Без һәр атна саен шимбә көнне җыела идек һәм үзебез иҗат иткән шигырь, тәрҗемә һәм шулай ук проза әсәрләрен укый идек. Һәркемнең үз фикерен әйтергә хокукы бар иде. Беркайчан да низаглар булмый иде...» Бары тик 1814 елның 8 июлендә генә патша галиҗәкабларь «Туган телне сөючеләрнең Казан җәмгыяте» уставын раслый. Аның әгъзалары һәм почетлы членнарыннан күренекле шагыйрь һәм язучы Г. Державин, И. Дмитриев, Н. Карамзин, В. Жуковский, К. Батюшков, П. Вяземский, С. Аксаков, В. Панаев, А. Панаевларны, Россия Академиясе президенты адмирал А. Шишковны, Казан университеты ректоры Н. Лобачевскийны, бертуган академиклар Перевощиковларны, академик И. Симоновны күрсәтергә мөмкин.

Китапханә гадәттә атнага ике мәртәбә, чәршәмбе һәм шимбә көннәрне сәгать уннан гына ачылуга карамастан, бүген тугыз тулар-тулмастан ук Николай Лобачевский шунда утыра. Кояш үзенең көлтә-көлтә нурларын өстәл өстендә өелгән китапларга коя. Ачык тәрәзәдән иртәнге саф һава агыла, шакмак түшәлгән урамга шак-шок бәргән тояк тавышлары ишетелә.

Күңелең тулы шатлык булганда сиңа берни дә укырга комачауламый.

Әле узган дүшәмбе көн генә яңа инспектор Федор Эвест гимназия конторасына үзенең беренче рәсми кәгазен язып тапшырды. Ул кәгазьдә «югары классларда озак күнегүләре нәтиҗәсендә киләчәктә гимназиядә укудан бертөрле дә файда алмаячак» укучыларның исемлеге китерелгән.

Ул исемлектә Николай Лобачевский турында «иң белемлесе» диелгән.

Мондый куанычлы хәбәрне аңа өченче көн, дәрестән соң, Ибраһимов әйтте. Укытучы үзенең яраткан шәкерте белән кочаклап саубуллашты һәм тантаналы төстә Корташевскийга тапшырды. Ибраһимовның җылы сүзләреннән һәм тавышы калтырап китүеннән Коляга әллә нәрсә булды: күңеле нечкәреп, күзенә яшь килде. Малай, моны укытучыларына сиздермәскә тырышып, тәрәзәгә карагандай итте.

— Һи-һи! Үзе тагын студент булам, ди... Университетта укый башлаганчыниләр эшләргә кирәген уйлар идегез, ичмасам. Геометриянең башлангыч өлеше ни сәбәпле шулай аңлаешсыз икәнен белмисез ич әле. Борынгы бөек дәүләтләрнең, бигрәк тә Грециянең географиясен, тарихын, культурасын, философиясен ныклап торып өйрәнергә кирәк сезгә. Шунсыз берни ачыклый алмаячаксыз, чөнки Евклидның «Башлангыч»ы аша безнең көннәргәчә килеп җиткән фән тиңдәшсез логик системага шунда салынган,— диде Корташевский.

Менә хәзер Николай бөтен буш вакытын китапханәдә уздыра. Тәкъдим ителгән китаплардан «Борынгы тарих»ны, «Кеше акылының мәгърифәттә казанган тәүге уңышларыннан алып Эпикурга кадәр булган тарихы»н, «Пифагор сәяхәте»н, «Дөнья яратылганнан бирле тупланган философиянең кыскача тарихы»н укып чыгарга кирәк.

Бүген ул Иаков Бруккерның «Философия тарихы» дигән китабын укып утыра. Пифагор турындагы өлеше

малайның күңелен аеруча җәлеп итте. Кечкенәдән үк Пифагорны этисе Финикиягә илтеп, гыйлем алу өчен философ Ферецидка тапшыра. «Аннан соң,— диелгән китапта,— акыл вә гыйлем өстәп ул Мисырда, Вавилонда була, Һиндстанга чаклы барып җитә. Туган иленә әйләнеп кайткач, ул ишерен рәвештә мәгарәдә мәктәп ачып җибәрә...»

«Мәгарәдә укуны «Казан Евклиды» әнә каян алган икән!» дип уйлап куйды Николай, геометрия дәресе башланыр алдыннан Иван Панаевның шаяртуын исенә төшереп. Малай, үзалдына елмаеп, укуын дәвам итте: «геометриядә Пифагор фигураларны саннарга бәйли. Аның өйрәтүенчә, саннар илаһи акыл нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр һәм һәммә нәрсәнең башланғычы булып торалар. Пифагор геометриядәге һәркемгә мәгълүм төшенчәләрне иҗат иткән галим...»

— Тукта, тукта, ничек була инде ул алай?! — Лобачевский китапны читкәрәк этәрде.— Төп геометрик билгеләмәләр ни өчен илаһи акыл нәтиҗәсендә барлыкка килсен ди?.. Тукта әле, аларның аңлаешсыз һәм мәгънәсез булуы да шуннан килми микән?.. Алай булгач, ни өчен Корташевский һәм Ибраһимов, геометриянең нигезләре табигатьтән, төрле әйберләрнең үзенчәлекләреннән тәҗрибә кылу юлы белән алынырга тиеш, дип өйрәттеләр? Кайсына ышанырга? Геометриядәге тәүге билгеләмәләр табигатьтән килеп чыкканмы, әллә инде илаһи акылданмы?..

Ул яңадан укырга керешге.

«...Колофониядә туган Ксенофан...» Монысының фикере ничегрәк икән?.. «Аның әйтүенчә, дөнья һәм андагы үзгәрешләр — безнең күзебезгә күренгән төрле әйберләрдән тора. Шул фикердән чыгып, ул бар нәрсәне дә мәңгелек дип, элек-электән яшәп килә дип кабул итә, юктан бар була алмый дип өйрәтә...»

— Коля... Николай, бүген ничәсе? — дигән тавыш малайны китаптан аерылырга мәҗбүр итте.

Аңарга сүз кушучы Петровский күрше бүлмәдә утыра иде. Петровский гимназиядә артиллерия һәм фортификацияне укыткан кеше. 1803 елның башында аңа китапханәче вазифасын йөкләделәр.

— Егерме икенче август... чәршәмбе көн бугай, Степан Сергеевич...

Егерме икесе диген! Вакыт бу чаклы тиз үтәр икән. Моннан ике ай элек Николай Лобачевский җәйге имтиханнарын тапшырды һәм барлык класслардан да

отлично билгесе алды. Шунда ук Ибраһимов аны китапханәгә алып килде.

— Менә сезгә кирәкле гимназист,— дип тәкъдим итте ул аны Петровскийга.— Рус теле беләң беррәттән, латин, немец, грек һәм татар телләрен дә ярыйсы белә, французча өйрәнә башлады. Китапларны рәткә китереп урнаштыру өчен...

— Аннан да яхшы кеше табылмас! — дип, Ибраһимовның сүзен йомгаклады китапханәче.— Ничек хәтердән чыкты икән? Ул бит минем фәнне дә отличнога үзләштергән иде. Ну, егетем, ризамы сез шул эшкә?

Куанычтан Николайның бит алмалары кызарып китте. Петровскийны гимназистлар укытучы буларак та, кеше буларак та хөрмәт итәләр иде. Ул гимназиянең чарлагында яши һәм кышын, укучылар кардан крепостьлар ясаганда, сугыш уеннары уйнаганда, бик теләп катнаша — сугыш һөнәренә өйрәтә иде.

Китапханә оешкан көннән * алып ничәмә-ничә китапханәче алмашынды, ә китаплар һаман тәртипкә китерелмәгән иде әле. Бу эшкә Петровский тотынгач кына хәл үзгәрде. Ул махсус китап шкафлары эшләтеп алды, һәм Коля менә хәзер аңарга китапларны кайсы телдә язылган булуына һәм форматларына карап рәткә китерергә, каталог төзергә бик теләп булыша. Артык мавыгып китеп, дәресләрен хәтердән чыгарган чаклары да булмый түгел. Китапханә яшүсмергә ниндидер сихри дөнья булып, андагы китаплар кешеләргә үзләренең серләрен ачалар сыман тоела. Шуңа күрә ул аларның авыр күн тышларын сокланып, хөрмәт беләң сыйпап-сыйпап куя. Үзенең монда башкаларга кирәкгә

* Китапханә 1799 ел мартында оеша. 1798 елның май аенда Казанга килеп киткән император Павел әмере беләң, Новороссийсктан князь Потемкиннан калган китапларны унсигез олауга төяп китерәләр һәм гимназиянең бер бүлмәсенә бушаталар. Вольтер беләң дус булган Казан алпавыты Полянскийның һәм шулай ук доктор Франкның китапханәләрен дә шунда китереп өстиләр. Ул китаплар арасында төрле телләрдә — рус, латин, немец, француз, итальян, татар, фарсы, гарәп, еврей, голланд телләрендә язылган борынгы һәм хәзерге кулъязма һәм басма китаплар була. Алар арасында бик сирәк очрый торган китаплар, мәсәлән, Манилиусның «Астрономия»се (1499 ел), «Кытай теле грамматикасы» (1700 ел), Дантеның «Илаһи комедия»се (1564 ел), «Россия яки Московия, бүтән төрле әйткәндә Татария» (1630 ел), «Апостол»ның беренче басмасы (1564 ел), «Китабен хаким» (1518 ел), «Моисейнең биш китабы» — илле бозау тиресенә язылган борынгы еврей кулъязмасы һ. б. бар.

ярамаган көннәрне һәм сәгатьләрне дә керә алуына куана. Дәресләрен дә шунда гына хәзерли.

Николай, «Философия тарихы»ның тагын бер битен ачып, онытылып укырга керешге. Ксенофанның эшен Демокрит дәвам иттергән икән. Дөнья яратылуга сәбәпче итеп ул материянең бинибая вак һәм бүленми торган кисәкчәләрен, ягъни атомнарны саный; илаһи көчне инкарь итү максаты белән, ул атомнарны үзлекләреннән хәрәкәткә килергә сәләтле дип таба... Аннан тыш, Демокрит иксез-чиксез бушлыкта очсыз-кырыйсыз дөньялар бар дип һәм аларның күпчелеге бер-берсенә охшаган дип өйрәтә... Ул алланың булуын инкарь итә һәм диннең куркытуга таянганлыгын әйтеп үтә... Сөйләүләргә караганда, Демокрит көн вә төннәрен шәһәр читендә кабердә укып-язып үткәрә, өрәкләргә ышанмый. Ниндидер яшьләр, өрәк булып киенеп, Демокрит янына барганнар икән, ләкин ул язудан туктамыйча гына: «Шамакай булып кыланмасагыз иде», дигән...

Николай, укуын бүлеп, Демокритның куркусыз кырыс чыраен күз алдына китерергә теләде. Яшүсмернең күз алдыннан томан таралгандай булып, әле күптән түгел генә катлаулы тоелган нәрсә аермачык аңлашылган төсле тоелды. Кара инде син аны, Демокрит моннан ике мең елдан артык элегрәк алладан курыкмаска, табигатьне өйрәнергә, аның серләрен чишәргә өндәгән һәм галимнең яшәү максатын әнә шунда күргән! Демокритның искиткеч акыллы фикерләрен Николай көннәр буе укырга һәм үз дәфтәренә күчереп язарга әзер. Ләкин, сәгатькә карагач, бер көрсенеп куйды һәм китапны япты: француз теле дәресенә барырга кирәк иде.

Икенче көнне билгеләнгән вакытта ул Григорий Иванович квартирасына китте.

Август аеның җылы һәм аяз бер көне. Салмак кына җил исеп куя, атлап баруы рәхәт. Әллә остазы белән сөйләшергә сүзе булганга шулаймы икән?

Лобачевский ике катлы таныш йортның ишегеннән тиз-тиз кереп китте, икенче катка менеп, кыю гына звонок бавын тартты. Ишекне Евсеич ачты һәм, кунакка юл биреп, пышылдап кына кисәтеп куюны кирәк тапты:

— Акрынрак, акрынрак, хөрмәтле әфәндем! Григорий Иванович эшләп утыра. Төне буе йокламады.

Берәр сәгать ятып алды да яңадан эшкә утырды. Сережа әйтә, ниндидер гыйльми китап яза, ди.

— Гафу итегез, белмәдем,— диде Николай, колагына кадәр кызарып. Шуннан ул, коридорны шыпырт кына үтеп, Сережа бүлмәсенең ишеген ачты һәм, аптырап, кире чигенде. Иске мундир кигән, чал сакаллы, зур бүксәле, тәбәнәгрәк кенә бер кеше, көзге каршысына баскан килеш:

— Яле, кем кыюрак, синме, минме? — дип җикеренә иде.

Картның шпагасы көзге алдында бик кискен хәрәкәтләр ясаганга, Николайның коты алынды, һәм ул:

— Көзгене ватасыз ич! — дип кычкырып җибәрде.

— Сезнең анда ни эшегез бар, хөрмәтле әфәндем? — диде чал сакаллы кеше шактый ачулы тавыш белән һәм шунда ук шаркылдап көлеп җибәрде.

Николай фәкать шунда гына дустын таный алды. Ничектер кәефе кырылып:

— Синең башыңда һаман юк-бар нәрсәләр! — диде.

— Нигә юк-бар нәрсәләр булсын? Мин, бер карт генерал, яшь офицерны дуэльгә чакырам,— дип аңлатты Сережа, көлә-көлә.— Пьесадагы ролем ул минем... Беләсеңме, театрга кем мәхәббәт уятты? Туган абзам! Ул монда кунакка килгән иде. Берничә мәртәбә Есипов театрына бардык. Шуннан күңелем әллә нишләп китте бит...

Дустына башыннан кичкәннәрне сөйли-сөйли, Сережа тиз-тиз генә өстеннән мундирын салып, урындыкка ташлады, шпагасын да ыргытты, чал сакалын да йолкып атты.

— Кил, утыр, менә монда! — дип, ул Николайны диванга тартты.— Шул менә... Башымда рыцарьлар, гүзәл ханымнар, фәрештәләр... Укуны бөтенләй оныттым. Григорий Иванович моны сизеп алды да, абзамнан һәммәсен сораштырып, кирәгемне бирде, малай! — Сережа, чытлыкланып, ике кулы белән битен каплады.— Вәгазь сөйли-сөйли тәмам елатты бу мине,— диде ул, битеннән кулын алып.— Шуннан, малай, тотындым укырга, тотындым укырга. Хәтта Григорий Иванович та канәгать калды. Беләсеңме нәрсә турында үзе башлап сүз кушты?

Сүзгә мавыгып китеп, Сережа диванга аякларын бөкләп утырган җиреннән төшеп, Николай каршында кулын болгый башлады.

— Театр турында! Миңа сәхнә сәнгате турында, рус актерлары турында сөйләде. Ничек итеп сөйләде диген син! Көннәрдән беркөн бу мине үзе белән операга алып барды. Андагы кызыкны күрсәң! Минем күңел яңадан кузгалды бит, малай!

Сережа көлә-көлә сөйләвен дәвам итте:

— Укуын ташлаган икән бу, дип уйлама син минем турыда. Юк, ташламадым. Үз көчебез белән спектакль куеп карасак, ничек булыр икән, дип хыяллана башладым.

— Шәп фикер! — дип хуплады Лобачевский.— Шуннан нишләдең?

— Әле бу арада Александр Панаев белән икәү бергә кечкенә генә драма да яздык. Үзебез яздык бит! — дип, Сережа өстәлдә яткан дәфтәрне алып дустына бирде.— Менә ул. Панаевларда рольләргә бүленеп уйнап та карадык инде. Бик шәп чыга. Мине пистолеттан атып үтерәләр анда... Григорий Ивановичка гына сөйләгәнем юк әле, ул берни белми...

Шул вакыт алар артында Корташевскийның басынкы тавышы ишетелде:

— Ялгышмыйсызмы икән?

Яшьләр кырт борылдылар һәм оялып, аптырап калдылар. Бу хәлне күреп, укытучы үзенең гадәттәге кырыслыгын югалтты һәм ишек төбендә туктап калган Ибраһимов белән карашып алды. Ике укытучының да йөзендә елмаю чагылды.

— Генерал ролен оста башкаргансыз, мин бу турыда ишеткән идем,— диде Корташевский.

Сүзгә Ибраһимов та катнашты:

— Тик менә өйдә куела торган спектакльләрнең бер кимчелеге бар: аларны күп кеше карый алмый. Ә инде тамашачысы аз булгач, ул спектакльдән күпме генә файда көтәргә мөмкин? — диде.— Минемчә, сезгә университетта үз көчегез белән театр оештырырга кирәк. Студентлардан, гимназистлардан тыш, спектакльдә уйнарга шәһәрнең башка яшьләрен дә тартыр идегез. Григорий Иванович, бу мәсьәләгә сез ничек карыйсыз? — дип Ибраһимов сүзен тәмамлады.

Көтелмәгән бу тәкъдимнән Аксаков телсез калды, ялт-йолт килгән күзләрен әле Ибраһимовка, әле Корташевскийга текәде.

— Бу хакта уйлап карарга кирәк әле,— диде Григорий Иванович.— Николай, сез минем янга килгән идегезме?.. Әйдәгез.

Лобачевский җиңелчә генә Сергейнең иңбашына кагылып алды да:

— Соңыннан керермен әле! — диде һәм, өстәлдән китапларын алып, таныш кабинетка юнәлде.

Укытучысы күрсәткән урындыкка утыру белән ашыгып сүз башлады:

— Григорий Иванович, соңгы вакытта мин менә шушыларны укыдым. Бик кирәкле нәрсәләр, бик кызык үзләре. Тик сез әйткән иң мөһимен тапмадым...

Шулчакны кабинет ишеге ачылып китте һәм Николайга таныш түгел бер кеше килеп керде.

— Хәерле көн, коллега! — диде ул кеше калын тавыш белән.

Корташевский аны урыныннан торып каршылады.

— Казан университетының беренче медицина профессоры Каменский әфәндегә бездән сәлам! — диде Григорий Иванович, кулшылыкка бирелеп.— Ничек соң, Иван Петрович, яңа җиргә ияләшү читен түгелме?

— Ияләшеп киләм шикелле. Директорыгыз, профессор Яковкин, мине конторага әгъза итеп билгеләде инде,— дип җавап бирде Каменский, мыскыллы көлемсерәп.— Эшли башлавымның беренче көннәреннән үк шактый күңелсез хәлләрнең җанлы шаһитына әверелдем. Яковкин башбаштаклык итә, килмешәк профессорлар, икенче төрле әйткәндә, немец чиновниклары яңа барлыкка килгән университетка нәфрәт баглыйлар. Доктор Мартин Герман яки Генрих Бюнеман өчен Казанда профессор булу, һичшиксез, фәкать янчыкларын тутыру өчен генә кирәк. Русча бер авыз сүз белмиләр, лекцияне тик латин телендә укыйлар, ә студентлар аларның латин сүзләрен немецчалатып әйткәннәрен аңлый алмый газапланалар. Кичә минем күз алдымда студентлар, юкка вакыт әрәм итәселәре килмичә, Бюнеман лекцияләренә йөрмәскә Яковкиннан рөхсәт сорадылар. Мин сезгә шаккатам, Григорий Иванович: бу хәлгә ничек түзеп торасыздыр?!

Каменский кызып-кызып, кулын селкә-селкә сөйләде. Ул килеп кергәч тәрәзә буена барып баскан Николай аның һәр сүзен йотлыгып тыңлады. Зурлар сөйләшкәнне тыңлап тору бик килешеп бетмәгәнне аңласа да, ул нишләргә кирәклеген белмәде һәм баскан урыныннан кузгалмады.

— Түзми ни хәл итәсез! — диде Корташевский.— Мин бит фәкать адъюнкт кына, миннән сорап та тормыйлар, санга да сукмыйлар. Ә бит мондый көчле

идарә органы, мондый автономия җир йөзендәге бер генә университетта да юк дип исәпләнә. Тик болар һәммәсе фәкать кәгазьдә генә! — диде Григорий Иванович, бик нык ачынып.

Каменский, кашын җыерып, бүлдерми-нитми тыңлап торды.

— Чынбарлыкта нәрсә килеп чыга соң? Хәйләкәр Яковкин һәммә нәрсәне алдан күргән — чит ил профессорларын җыйган. Сез бик дөрес әйттегез, аларга янчыкларын рус акчасы белән дыңгычлап тутырсалар — шул җиткән, башка нәрсә кирәк түгел. Менә ни өчен алар директор әфәнде төрткән һәр кәгазьгә кул куеп яталар. Хәер, укып карарга тырышсалар да, берни чыкмас иде, чөнки алар русча бер авыз сүз белмиләр, чи наданнар,— Григорий Иванович кулын селтәде һәм читкә борылды.

Каменскийның түземе бетте, ул ярсыбрак сөйләргә кереште:

— Менә шуңа күрә бөтенләй сәләтсез, фәннең «ф» хәрефен дә белмәүче бер надан, университетның ничек булырга тиешлеген сизмәгән-белмәгән башы белән: «Университет — мин ул!» дип лаф ора да шул.

— Алай гынамы соң! — дип, Корташевский аның сүзен куәтләде һәм, нидер әйтергә теләп, дулкынланып, диваннан сикереп торды. Шул вакыт ул тәрәзә янында аптырап басып торган шәкертен күреп алды.

Сөйләшә торгач, артык тирәнгә кереп киттеләр шул. Егетне бу бәладән коткарырга кирәк иде.

Корташевский өстәлдән берничә табак ниндидер язулы кәгазьләрне алды һәм Лобачевскийга сузды:

— Гафу итегез, мин сезне хәтердән чыгарганмын. Шуларны алып, Сережа янына керсәгез иде. Без сөйләшкән арада укып та чыгарсыз. Анда сезне кызыксындырган кайбер сорауларга җавап булырга тиеш.

— Бик зур рәхмәт! — диде Николай һәм, укытучысы белән аның кунагына баш иеп, тиз-тиз атлап кабинеттан чыгып китте. Лобачевский кулъязма өчен сөенә идеме, әллә уңайсыз хәлдән котылуынамы — әйтүе кыен.

Сергей каядыр чыккан иде. Николай өстәл янына барып утырып, кулъязманы җәеп салды. «Платон вә Аристотель». Бәлки, остазы көннәр-төннәр буе шуны язгандыр? Николай шунда ук зур кызыксыну белән укырга тотынды. Аның күз алдында борынгы гасырларның атаклы галимнәре пәйда булды.

## 2

Егерме яшьлек Платон остазы Сократ * белән сөйләшеп-гәпләшеп утырган көннәрдән соң инде ике мең елдан артык вакыт узган. Философның зирәклегенә һәм акылына гашыйк егет тиз арада аның иң алдынгы шәкерте булып китә, Сократ язган хезмәтләрне тулыландыру, баету өстендә армый-талмый эшли башлый. Сократ үлгәннән соң, Платон Италиягә пифагорчылар янына китә, аларның җанга кагылышлы булган, ягъни җанның күчеп йөрүе, бер рәвештән икенчесенә әверелүе турындагы тәгълиматьләре белән таныша. Аннан соң ул озак еллар Мисыр буйлап сәяхәт кылып йөри, күк җисемнәре хәрәкәтеннән хәбәрдар булган белгечләр белән гәпләшә. Пирамида төзүчеләрдән геометрия башлангычлары турында мәгълүмат ала.

Беренче геометрлар сызык һәм фигураларны таяк белән комга сыза торган булганнар. Җирнең түгәрәк икәнен белмәгәнгә һәм аны ниндидер яссы нәрсә дип күз алдына китергәнгә күрә, алар ике ноктаны тоташтыручы иң кыска сызыкны туры дип атаганнар. Чынбарлыкта моның туры сызык түгеллеген, ә гаять зур дуга кисемтәсе булуын белмәгәннәр. Тактага, таш плитәгә, папируска алар шул ук фигураларның кечерәйтелгән үрнәкләрен сызганнар һәм бу, яссы сызымнар Җир өслеген дөрес чагылдыра, дип инанып йөргәннәр; фикерләрен үстергәннән-үстерә барып, шул яссылыкта һәм пространствода яңадан-яңа теоремалар китереп чыгарганнар.

Тик вакыт узу белән, күк җисемнәрен дикъкать белән күзәтә торгач, кеше Җирнең яссы түгел, бәлки шар сыман икәнлеген белгән. Кабул ителгән геометрик яссылык Җир өслеге белән тәңгәл килми, бәлки аның бер генә ноктасына орына икән. Бу ачыш геометрларны тәмам аптырашка төшергән. Соң шулай булмыйни, элек бернинди бәхәссез саналган раслаулар барысы да иллюзиягә, хыял җимешләренә әверелеп калсыннар әле! Инде җир өслеге йомры икән, туры сызыкны — ике нокта арасындагы бердәнбер иң кыска сызык дип билгеләү дөрес булмый ләбаса. Чөнки шарда, мәсәлән, аның диаметриаль капма-каршы якларында яткан ике нокта аша исәпсез-хисапсыз андый

---

* Сократ — Пифагор шәкерте, безнең эрадан 469—399 еллар элек яшәгән.

сызык үткәреп була ич. Ә геометрик яссылыкта исә — фәкать берне генә уздырырга мөмкин. Әле алай гынә да түгел, туры сызыкны ике якка да теләгәнчә дәвам итеп була, дип ышанып йөриләр иде, чынлыкта исә Җир өслегендәге һәркайсы сызык ахыр чиктә ябык түгәрәк тәшкил итә. Инде нишләргә?

Ләкин Сократның зирәк шәкерте моны бик гади генә төшендереп биргән.

— Безнең геометриянең Җир өслеге белән бернинди дә алыш-биреше юк,— дигән Платон.— Безнең геометрия идеаль яссылыкта һәм пространствода барлыкка килгән. Бәс шулай икән, нокта, туры сызык, яссылык һәм пространство турындагы төшенчәләрнең үзләрен дә тәҗрибә һәм үлчәү нәтиҗәсендә килеп чыккан дип түгел, ә кеше җанына тумыштан хас мәңгелек илаһи идеяләр дип карарга кирәк...

Геометрик хакыйкатьләрнең килеп чыгышын бу рәвешле аңлату — борынгы грек философлары һәм геометрлары арасында гаугалы бәхәсләр тудырган. Күпләр килешмәгәннәр. Ләкин Платонга иярүчеләр дә булган, һәм ул үзенең фикерен үстереп җибәргән:

— Безнең геометрия сизү, күрү, ишетү органнарыбыз тоя торган, әмма вакытлы гына булган ышанычсыз әйберләр дөньясыннан аерылып та торсын, ди. Әмма аның илаһи хикмәте Баш геометр — Тәңребез тарафыннан тудырылган. Шуңа таянып без нинди генә матди фактны да инкарь итә алабыз. Кызганычка каршы, геометрия ходай тәгалә күрергә теләгән фән дәрәҗәсенә җиткәне юк әле. Математиклар, үз фикерләрен күрү, ишетү вә сизү тәэсиренә бәйләгәнлектән, геометрия фәнен илаһи биеклеккә күтәрә алмыйлар. Ә инде тирә-юнебездәге әйберләргә әнә шулай искечә карау, тышкы күренешләр белән тәэсирләнү безне бабайларыбыз Җирне яссы дип ышанып йөргән чаклардагы шикелле үк хаталануларга, иллюзияләргә китерә. Шуңа күрә без, андый танып-белүләрдән арынып, мәңге үзгәрми яшәүче идеяләр дөньясына, күңел вә җан-рух тирәнлекләренә чумарга тиешбез...

Платон кырык яшендә, ягъни, греклар әйтмешли, кешенең нәкъ чәчәк аткан чорында, туган иленә кайтып, Афина каласы читендәге паркта, мифик герой Академ исеме белән аталган урманчыкта үзенең философия мәктәбен ача. Соңрак бу мәктәп академия дип атала башлый. Аның капкасына: «Кем дә кем геометрияне белми, шул монда керми!» дип язылган була.

Бу кисәтүле сүзләрнең тылсымлы көче Греция, Италия һәм Мисырның төрле почмакларында фәнгә сусап яшәгән бик күп яшьләрне үзенә тарта. Билгеле инде, һәркем өчен дә ачык булмый академиянең «авыр» капкасы. Шөһрәтле кешеләр, бай аристократ балалары гына укый ала анда.

Шәкертләре алдында геометрия «серләрен» чишкәндә, Платон аны фәннәр фәненә, илаһи идеяләр ачкычына әверелдерергә омтыла.

— Һәрбер геометрик фигурага чын белем һәм символ яшерелгән,— дип аңлатырга тырыша ул.— Геометрия, төрле фигуралар белән эш итүдән тыш, Галәм серләренә дә төшенергә ярдәм итә. Сез менә Җиргә генә күз салыгыз. Ул — безнең туендыручыбыз һәм шул ук вакытта беренче күк җисеме дә. Аллаһы тәгалә аны Галәмнең нәкъ уртасына хәрәкәтсез шар сыйфатында урнаштырган. Җир гомер-гомергә көннәрне һәм төннәрне тәртиптә тота, аларның чиратын саклый. Аннан соң, Кояш, Ай һәм планета дип аталучы адашкан йолдызлар яратылган. Алары инде кешеләргә вакытны билгеләү һәм исәпләү өчен хезмәт итә. Үзегез дә күрәсез, алар Җир тирәли Баш геометр-тәңре сызган түгәрәкләр буенча әйләнәләр.

Җир өстендә елгалар гөрләп ага, иксез-чиксез океан шаулый. Боларның һәммәсе өстендә һава. Менә шушы өч эссенция — җир, су, һава һәм янә табигатьнең дүртенче көче — ут һәммә нәрсәнең, ягъни кешеләрнең, җәнлекләрнең, агачларның, ташларның һәм башка әйберләрнең җисемнәрен тәшкил итә...

Аннары Платон әлеге дүрт стихиянең табигатен аңлатырга керешә:

— Ут, су, җир һәм һава, һәркемгә мәгълүм булганча — җисемнәр. Ә бит һәрбер җисем гадәттә билгеле сандагы яссылыклар белән чикләнә. Яссылыклар исә тагын да гадирәк геометрик элементлардан, ә атап әйткәндә — өчпочмаклардан тора... Утның да, башка җисемнәрнең дә башлангычына кагыла бу. Әлеге җисемнәрнең һәркайсы нинди геометрик формага ия булган һәм нинди беренче элементлардан тора соң? Җисемнәр арасында иң җиңеле, нечкәсе, нәфисе, үткене һәм хәрәкәтчәне, әлбәттә, ут: шуңа күрә аңа дүрткырлы пирамида тәңгәл килә. Шушы күзлектән чыгып караганда, уттан соң икенче урында — һава, өченче урында — су һәм, ниһаять, дүртенчесендә — җир җисемнәре тора. Димәк, һаваның геометрик формасы

төзек октаэдр (сигез кырлы фигура), суныкы — төзек икосаэдр (егерме кырлы фигура), җирнеке исә иң тотрыклы фигура, ягъни куб булырга тиеш...

Яшь аристократлар, остазларын мөкиббән китеп тыңлаганнар, аның дәлилләү ысулларына гына түгел, интонациясенә, ымларына һәм ишарәләренә дә сокланганнар.

— Инде әлеге дүрт стихиядән килеп чыккан әйберләргә килсәк,— ди Платон, сүзен дәвам итеп,— аларның күптөрлелеге шул җисемнәр составындагы ике башлангыч элементка, ягъни яклары тигез булмаган туры почмаклы өчпочмакка һәм тигезъянлы өчпочмакка бәйле. Чөнки һәр ике төп элементның да дөньяда бихисап эреле-ваклы төрләре бар. Ул төрләр соңра, үзара аралашып һәм башкалар белән кушылып, әйберләрнең күптөрлелеген хасил иткән. Табигатьне күзалларга тырышкан һәркем, һичшиксез, әнә шуларны исендә тотарга тиеш...

Ләкин Платонның вәгазьләре тантаналы дәвам итә алмый. Берзаманны, аяз көндә күк күкрәгәндәй, Афина мәктәбен гаҗәеп хәбәр дер селкетә: Платон кадәр Платонга каршы чыгучы адәм табылган, имеш. Андыймондый буш куык кына түгел, ә Платонның иң мактаулы шәкерте, Аминт патшасы табибының улы икән. Мондый кеше белән хисаплашмыйча да мөмкин түгел шул.

Ул — Аристотель була. Эгей диңгезе буендагы Стагир шәһәреннән академиягә килеп урнашкан чагында аңа нибары унҗиде яшь тула. Афина китапханәсендәге сирәк очрый торган гыйльми кулъязмаларны укып белем алу, гадәттән тыш абруйлы Платон ярдәмендә геометрия һәм философияне яхшы итеп үзләштерү турында хыяллана ул. Ләкин тәгәл егерме ел академиядә тору дәверендә Аристотель андагы халыкның фәкать тел тегермәне тарту, буш сүз сөйләү белән генә шөгыльләнүенә ахырынача төшенә. Идеяләр турында сафсата сатуларның тәҗрибәләргә һәм реаль фактларга, аларны дөрес аңлатуга нигезләнгән чын фәнгә нинди зур зыян китерүе аңа көннән-көн ачыграк аңлашыла бара.

Ниһаять, Платон яклыларның куршы сүз лабиринтыннан ычкынып, Аристотель:

— Минем өчен укытучы да, хакыйкать тә бер үк дәрәҗәдә кадерле, эмма изге бурычым һәм намусым хакыйкатьне өстенрәк күрергә куша,— дип игълан

итә.— Платонның табигать җисемнәре геометрик фигуралардан — өчпочмаклардан һәм ниндидер җисемсез нәрсәләрдән — идеяләрдән тора дигән сүзләре белән һич тә килешеп булмый...

Ул Афинаны ташлап китә һәм Мидиягә барып урнаша. Аннары берничә ел Македония тәхете варисы — булачак бөек полководец Александр Македонскийны укыта.

Афинага әйләнеп кайткач, Аристотель үзенең философия мәктәбен — «Ликей» *ны ача. Александр Македонскийның юмарт ярдәме белән аңа тиз арада ботаника, зоология буенча кыйммәтле коллекцияләр һәм шулай ук бик күп китап җыярга мөмкинлек туа. Биредә ул Платон идеяләрен түгел, ә табигать вә җәмгыять күренешләрен җентекләп өйрәнүне һәм төгәл сурәтләүне алга сөргән күренекле грек галимнәрен бергә туплый.

— Кеше, нинди генә даһи булса да, ирешкән уңышлары өчен үзеннән элек яшәгән тикшеренүчеләргә рәхмәт әйтергә тиеш,— дип өйрәтә Аристотель үзенең шәкертләренә.— Үткәннең тәҗрибәсен ныклап өйрәнми торып фәнне алга этәрү мөмкин түгел. Шуңа күрә Фалес заманыннан хәзергә кадәр барлык галимнәр һәм философлар иҗат иткән гыйльми хәзинәне бер төзек логик системага китерергә вакыт җитте. Ләкин бу гаять авыр бурычны берьялгызым, сезнең ярдәмегездән башка гына, һич башкарып чыга алмаячакмын...

Шәкертләре — фикердәшләре җиң сызганып эшкә башлыйлар. Шундый изге эштән берсе дә читтә калырга теләми. Менон медицина тарихын өйрәнергә керешә, Теофраст үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының тарихын яктыртуга алына, Евдем геометрия теориясенә һәм тарихына тотына, башкалар да муеннан эшкә чума...

Тырыш хезмәт нәтиҗәсендә тау чаклы материал җыйнала. Аны ничек итеп рәткә китерү, логик эзлеклелек белән билгеле бер системага салу ысулын берәү дә белми.

Чынлап та, һәр нәрсәне дәлилле вә нигезле башласаң, бик тирәнгә кереп китәсең, һәм ул чагында: иң әүвәл нәрсә булган соң, беренче хакыйкать кайдан килеп чыккан соң, дигән сорауга килеп төртеләчәксең.

---

* Ликей — Афинадан ерак түгел Аполлон храмы урнашкан парк.

Әйе, тәүге нигез итеп нәрсәне алырга? Кайдан башларга?

Шәкертләрнең борчулы карашлары остазларына төбәлә. Чуалган төенне тиз генә чишә алмаудан гаҗиз калган Аристотель ихтыярсыз Платон юлына кайтып төшәргә, ягъни һәр фәннең нигезендә бернинди аңлатуга мохтаҗ булмаган (кеше акылына тумыштан хас) төп төшенчәләр һәм исбат итмичә генә кабул ителә торган раслаулар — аксиомалар ятарга, ә калганнары барысы да әнә шул нигез итеп алынганнардан, алдан әйтелгәннәрдән, фикер йөртү юлы белән исбатлап кабул ителә торган нәтиҗәләр булырга тиеш, дип танырга мәҗбүр була.

Барлык җыелган материалны әнә шул күзлектән чыгып, билгеле бер системага салу — геометрия фәненә Аристотель васыять итеп калдырган тарихи бурыч шуннан гыйбарәт була.

Соңыннан грек комментаторы Прокл күрсәткәнчә, әлеге бурычны үтәү эшенә Гиппократ Хиоский, Февдий Магнезийский, Гермотим Колофонский һәм башка галимнәр алына. Әмма аларның хезмәтләре, бөек математик Евклидның үлемсез әсәре яктылыгында, бөтенләй тоныкланып кала.

Евклид Александриядә яши. Шунда үзенең геометрия мәктәбен оештыра. Ул геометриянең барлык тәгълиматларын җыеп кына калмый, аларны бер бөтен итеп берләштерә, үзенә кадәр бик үк ышандырырлык дәлилләнмәгән теоремаларны исбатлап бирә...

Корташевскийның кульязмасы шул урында өзелә иде. Николай, аны укып чыккач, шактый озак уйланып утырды. Кульязма бүгенге математикларны да борчый торган иң мөһим мәсьәләләргә кагыла бит. Аристотельнең кыюлыгына Николай сокланып баш иде. Тик шунда ук аның күңелен борчулы уйлар биләп алды. Ничек инде шундый бөек галим аксиомаларга берсүзсез ышанырга кушкан? Кызык бит бер уйлап карасаң: ышан һәм төпченеп маташма!

Монда икенең берсе: йә Григорий Иванович фикерен әйтеп бетермәгән, йә Николай үзе төшенеп җитми. Иң тәүге башлангыч итеп, нигез итеп нәрсәне алырга соң инде? Акылны алыргамы, әллә матди дөньянымы? Әгәр табигать һәммәсенең тәүге башлангычы икән, ул чагында геометрия кагыйдәләре вә кануннары акылдан

гына килеп чыга аламы? Евклид та үзенең хезмәтендә ялгыш юлга кереп китмәдеме икән?

...Николай, урыныннан торып, тәрәзә янына барды. Ләкин ул әле фикерләреннән арынып җитмәгән иде, тәрәзәгә карап торса да, берни күрмәде.

Теге вакытны «Философия тарихы»н укыганда туган төп соравына һаман җавап таба алганы юк. Инде кемгә мөрәҗәгать итәргә икән? Ломоносов белән Радищевтан ярдәм сорасаң, булышсагыз ла, дисәң, ә?!

Николайның йөзенә елмаю җәелде. Малайлык димә инде син!

Кульъязманы тоткан килеш, ул Сергей бүлмәсеннән чыкты һәм Корташевский кабинетына таба юнәлде. Кабинет ишеге ачык, анда яңа кунаклар өстәлгән иде. Адъюнкт Запольский, гимназия конторасы бухгалтеры Әхмәтов һәм рәсем укытучысы Чикиев килгән. Кунаклар кызып-кызып сөйләшәләр иде.

Николай кыюсыз гына бусага төбендә тукталды һәм, кунакларны баш иеп сәламләгәч, Корташевскийга кульъязманы сузды:

— Григорий Иванович, мин башка вакыт килермен инде,— диде.

— Киләсе атнада, дүшәмбе көнне килегез, яме! — дип җавап кайтарды укытучы һәм, гафу үтенгән сыман: — Килми калмассыз бит? — дип өстәде.

Кырыс холыклы укытучысының энә шундый ягымлы мөгамәләсе Николайның күңелен үстереп җибәрде. Ләкин бу йорттан чыгып барганда, бу ишекләрне тиз генә ача алмаячагы башына да килмәде.

Урамда ул йөгереп кайтып килүче Сергейны очратты.

— Николай? Менә шәп булды әле очравың,— диде Сергей, тыны бетеп.— Николай Мисаилович белән директор янында булдык. Күндердек бит үзен! Гимназистларның йокы бүлмәсендә спектакль куярга ризалык бирде. Веревкинның «Шулай булырга тиеш» дигән комедиясен уйныйбыз. Син судья роленә ризамы?

— Әйттең инде син дә! — дип куйды Николай, коты алынып.— Минем бит гомердә дә уйнаганым юк, уйнарга да җыенмыйм.

— Алай кырт кисмә әле син! Кызык ич ул уйнау,— диде Сергей һәм, дустының җилкәсенә сугып алып, өенә йөгерде. Ерактан да аның: — Уйлап кара! — дигәне ишетелде.

Алдагы көннәр «артистлар» өчен эш-мәшәкать белән үтте. Шимбәгә кадәр рольләрне өйрәнеп бетерергә, кием-салымнарны әзерләп куярга, урын җәймәләреннән чаршау тегеп, озын бүлмәнең бер очын шул чаршау белән бүлеп алырга һәм сәхнә ясарга, сәхнә каршына тамашачылар өчен эскәмияләр, урындыклар тезеп чыгарга кирәк иде.

Күңелле көннәр иде бу. Һәм алар ыгы-зыгы, ашыгу-каушаулар, әрле-бирле чабулап йөрүләр белән сизелмичә, бик тиз үтеп киттеләр.

Менә, ниһаять, тантаналы кичә дә килеп җитте. Озын, салмак көйгә кыңгырау чылтырады. Пәрдә күтәрелде. Тамаша башланды.

Карт Доблестин ролен Сережа Аксаков өйрәнгән иде. Ул сәхнәгә гимназиянең каравылчысы киеменә охшаган иске солдат сюртугыннан, башына акбур белән агартылган сүс-парик киеп чыкты. Аның кулында бу кич өчен бәйдән ычкындырылган һәм инде кемнедер тешләргә дә өлгергән эт чылбыры иде.

Тамашачылар күп булды. Университетның, гимназиянең начальствосы, укытучылары үзләренең хатыннарын һәм кызларын алып килгәннәр. Студентлар һәм гимназистлар да кергәч, бүлмә шыгрым тулды. Спектакль тоташтан кул чабулар белән үтте. Тамаша беткәннән соң Николай дусты янына барды. Бик нык дулкынланган Сергей аңа каршы атлады һәм, килеп җитәргә дә өлгермәде, кулъяулыгы белән битеннән акбурын сөртә-сөртә:

— Ничек соң, ә? — дип сораштыра да башлады.— Шәп киенгәнме мин? Икенче баш тартмассыңмы инде уеннан?

— Тартмам шикелле,— диде Николай оялчан гына.— Шунда бер кечкенә генә роль бирсәң...

— Менә булды! — дип, көлеп җибәрде Сергей.— Йогышлы чир кебек ул. Бер башлап кына җибәр.

Театр эшләре көннән-көн алга китте. Попечитель рөхсәтеннән чыгып, казна студентларына «итагатьле булганнары өчен» махсус бер класс бүлмәсен бирделәр. Элек ул бүлмә стена белән икегә бүленгән булган, хәзер шул стенасын алганнар, ике яктан ике колонна гына утырып калган — спектакль куярга шуннан да җайлы бүлмәнең булуы мөмкин түгел иде.

Ләкин көтмәгәндә бу уеннардан шактый күңелсез «уймак» килеп чыкты. «Килешү нәтиҗәсе» дигән драманы әзерли башлаганда Александр Панаев, «театр ди-

ректоры» Аксаковны үгетләп, генерал ролен алды. Шуның белән ул бер чибәр туташның күңелен яуламакчы булган икән. Рольне алуын алды, әмма репетицияләрдә бу искиткеч матур егетнең бөтенләй уйный белмәве күренде.

Студентлар арасында:

— Хур булабыз моның белән!

— Генерал ролен Балясниковка бирергә кирәк! — дигән ризасызлык авазлары ишетелде.

Ләкин «театр директоры» бу сүзләргә колак салмады. Бер көнне, репетиция барганда, үзара «бәхәсләшүче» Аксаков белән Панаев арасына Николай килеп керде дә:

— Александр, бу рольне булдыра алмыйсыз, баш тартыгыз,— диде.

Панаев агарынып китте, әмма ул авыз ачып сүз әйткәнче, кызу канлы Аксаков дары шикелле кабынып:

— Кем директор, синме, минме? — дип җикеренергә тотынды.— Дворянга акыл өйрәтмә!

Лобачевскийның тыны кысылды. Ул йодрыгын йомарлап:

— Нәрсә дидең? — дип, аның өстенә бара башлады.

Бәхетенә каршы, Балясников һәм башка студентлар аны тотып калдылар. Николай талпынып та карады, ләкин ычкына алмады.

— Җибәрегез, тимим,— диде ул акрын тавыш белән. Һәм беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, бүлмәдән чыгып китте.

Студентлар һәм гимназистлар Аксаковка шелтәле караш ташладылар. Иптәшләренең фикерен Зыков әйтте:

— Барыбер Александрның хәленнән килми,— диде ул.— Карышып тормагыз, Аксаков, рольне Балясниковка тапшырыйк.

Оятыннан нишләргә белмәгән Панаев тәрәзә янына барып, иптәшләренә арты белән басты.

Аксаков яңадан кабынып китте.

— Әле шулаймы? — диде.— Ул чагында мин директорлыктан да, ролемнән дә баш тартам.

Аның гаҗәпләнүенә каршы, моңа шунда ук риза булдылар.

— Бик дөрес, алып ташларга кирәк!

— Театрга килеп йөрмәсен. Борынын күтәрмәсен әле. Кемнәр, чыгарырга, ди? Кул күтәрегез.

Һәммәсе дә кулын күтәрде.

Бу хәлне күреп, Аксаков шаккатты. Ачуына буылып, ул:

— Үкенерсез — мин булмам! — дип куйды һәм, дәшми генә басып торган Панаевны кулыннан әләктереп, залдан атылып чыгып китте.

Студентлар һәм гимназистлар бер-берсенә караштылар. Бары тик Балясников:

— Кайгырмагыз, егетләр! — дигәч кенә, эчләренә бераз җылы кергән сыман булды...

Бу вакытны Лобачевский, җил-җил атлап, урам буйлап бара иде.

— Дворянга акыл өйрәтмә, имеш,— дип кабатлады ул, ярсуын баса алмыйча.— Өйрәтсәм, нәрсә диярсең? Дворян грамотасы белән генә галим була алмассың әле. Аның өчен баш та кирәк.

Ул көнне Лобачевский тәмам арыганчы урамда йөрде. Киредән университетка кайтып җиткәч, күңеле сыкрап, моннан ары Григорий Ивановичның өенә барып йөри алмаячагы турында уйлады. Юк, юк, Аксаков яшәгән йортка ул бүтән аяк басачак кеше түгел!

Әмма Николай кырыс холыклы сөекле укытучысыннан аны мәңгегә аерачак икенче бер сәбәпне белми иде әле.

Казан университеты яши башлауның беренче көненнән алып Корташевский бу югары уку йортын гимназиядән аеруны, устав кушканча мөстәкыйль итүне яклап килде. Гимназия Советы утырышларында шул фикерен көчәйтеп, Яковкинның башбаштаклык кылуына каршы тәнкыйть белән чыкты.

Аның хыялында яңа университет күп сандагы яшь галимнәрне тәрбияләп үстерергә тиеш иде. Ә немец профессорлары укытуга да, тәрбия эшенә дә эленкесалынкы гына карыйлар. Студентлар, имтиханнарын да юньләп алмыйлар, ничек тә безне мыскыл итәргә тырышалар, дип зарланалар иде. Тик Григорий Иванович студентлар белән якынлашкан саен, Яковкин һәм немец профессорларының нәфрәтен ныграк казанды. Университетта хәлләр кискенләшкәннән-кискенләшә барды. Моңа, әлбәттә, идарә итү эшенең куелышы төп сәбәп булды.

Моннан ике ел элек, Румовский киткәч тә, Яковкин профессор һәм адъюнктлар мәҗлесенең элеккечә Казан гимназиясе Советы дип аталуында дәвам итүе турында приказ чыгарган иде. «Университет әгъзала-

ры күпчелекне тәшкил итүгә дә карамастан, Совет, агымдагы мәсьәләләрне хәл иткәндә, университет уставындагы күрсәтмәләргә өлешчә таяначак» диелгән иде ул приказда.

Һәм әнә шул приказ нигезендә Яковкин теләсә нәрсә эшли ала иде. Корташевский мондый хәл белән килешмәде һәм язма рәвештә үзенең фикерләрен исбатлады. Университеттагы эшләрне идарә итү өчен гимназия Советының көче җитми, дип язды ул. Моның өчен Яковкин адъюнкт Корташевскийны «училищеларның баш идарәсе һәм халык мәгарифе министры тарафыннан расланган карарга каршы чыгучы» дип игълан итте. Ләкин Григорий Иванович бирешергә уйламады.

1806 елның язында, әйткән сүзендә нык тора торган тугры профессор Каменский Казанга килеп төшкәч, университетның үзидарәгә законлы хокукы өчен көрәш кызып китте. Җәмәгатьчелек кысуы астында Яковкин Совет турындагы бу мәсьәләне яңа уку елы алдыннан уздырылган махсус утырышка куярга мәҗбүр булды.

Җыелыш залына профессорлар, адъюнктлар, укытучылар һәм гимназия конторасы членнары җыелдылар. Озын имән өстәлнең бер башына үз-үзеннән канәгать кыяфәтле Яковкин килеп утырды. Аның тирәсендә немец профессорлары Герман, Бюнеман, Сторль урын алдылар. Икенче башка исә профессор Каменский, адъюнктлар Корташевский, Запольский һәм Левицкий, бухгалтер Әхмәтов, рәсем укытучысы Чикиев урнашты. Уртада, бер якка да катнашмыйбыз дигән сыманрак, аска карап, профессорлар Цеплин һәм Фукс, адъюнктлар Эвест һәм Эрих, аннан соң гимназиянең өлкән укытучылары утыралар иде.

Председательнең кыска гына кереш нотыгыннан соң беренче булып Корташевский сүз алды.

— Кызганыч, бик кызганыч, әфәнделәр,— дип ярсып сөйли башлады ул,— рус университетының югары дәрәҗәдәге Советында, ягъни галимнәр советында, без үзара тагын латинча аңлашырга тиешбез. Менә шушы кызганыч факт үзе генә дә безнең университет һәм Совет эшләренең нindирәк хәлдә булуын сөйли түгелме соң?..

— Менә син, ә! — дип төрттереп алды урыныннан гына Герман.— Корташевский, гадәтенчә, тагын безнең якага ябыша.

— Әйе шул, сөйләгәч берәр яңарак нәрсә сөйләргә кирәк иде аны. Югыйсә, һаман бер балык башы,— дип тегенең сүзен куәтләде Бюнеман.

Корташевский көрсенеп куйды да:

— Кызганыч, бик кызганыч,— дип дәвам итте.— Гап-гади хакыйкатьне төшенергә теләмәвегез кызганыч, дим. Сез бит Россия университетында дәрес бирәсез. Бәс, шулай икән, лекцияләрегезне рус телендә укырга тиешсез. Моннан да яңарак нәрсә таләп итмибез дә һәм итә дә алмыйбыз без сездән. Бу мәсьәлә тагын шуңа күрә аеруча мөһим: директорыбыз сезнең әлеге кимчелектән, фән йортына хас булмаганча, усал ният белән файдалана.

— Яла! — дип ярсулы тавыш белән бүлдерде Корташевскийны Яковкин.

— Без моңа юл куймаячакбыз! Без... без алдакчылар түгел,— дип бер тавыштан диярлек сөйләргә керештеләр чит ил профессорлары.

— Ә мин хәзер исбатлыйм,— диде Корташевский кызып китмәскә тырышып.— Мәгълүм булганча, гимназиянең өлкән надзирателе постына Совет һәрберебез хөрмәт итә торган коллежский асессор Николай Степанович Пухинскийны тәкъдим иткән иде. Попечитель дә яклаган иде аның кандидатурасын. Ләкин Пухинский өлкән надзиратель булып эшли башлауга, Яковкин Баш идарәгә аның «яшерен характеры», «өметсез кеше булуы» һәм башка «кимчелекләре» турында дәгъвалар юллый башлады. Ул кәгазьләрнең һәркайсын безнең немец дусларыбыз раславын да әйтеп китәргә кирәктер.

— Корташевский әфәнде, миңа калса, сез нәрсәдер бутыйсыз шикелле,— дип сүзгә кушылды профессор Цеплин.— Директор бездән, Советның даими членнары буларак, өлкән надзирательнең бурычлары турындагы кәгазьгә кул куярга кушты. Аңламыйм, Пухинский әфәнденең ни катнашы бар бирелә?

— Менә шунда да инде хикмәт. Директор, рус телен белмәвегездән файдаланып, сезгә бөтенләй башка кәгазь төрткән.

Цеплинның тавышы калтыранып китте:

— Дөрес сөйлиме ул, Яковкин әфәнде?

Барысы да, җавап көтеп, тынып калдылар. Яковкин кызарынып китте. Шулай да сер бирмәскә тырышып, сүз башлады:

— Әфәнделәр, мин... без, нитәбез бугай... Әйе, без

бер-беребезне аңламыйбыз... Пухинскийга килгәндә инде, мин...

— Директор әфәнде, зинһар, боргаламый гына сөйләгез,— диде бераз тынычланырга өлгергән Цеплин.— Күрәм, сез чынлап та безне төп башына утырткансыз, ахры.

Бөтенләй куркуга төшкән немецлар, үзләренең аяныч хәлдә калуларын тоеп, шундый тавыш-гауга куптардылар ки, хәтта кемнең нәрсә сөйләгәнен, төп гаепнең Яковкиндамы, әллә немецлардамы икәнен дә аңлап булмый башлады.

Корташевский немец коллегаларны көч-хәл белән генә тынычландыра алды.

— Менә хәзер аңладыгызмы инде? — дип мөрәҗәгать итте ул аларга.— Сезнең рус телен белмәвегез, безне, русларны, менә ни өчен борчый. Яковкинга бүген Пухинский ошамый, иртәгә — Корташевский. Эшләр болай дәвам итсә, сез үзегезне үзегез эштән китәргә мәҗбүр итүегезне дә сизми калырсыз. Баштанаяк пычранып калуыгыз да мөмкин әле. Ул бит сезне патша галиҗәнабләре белән өркетәчәк...

Яковчин, «галиҗәнаб» сүзен ишетүгә, аңына килде, олымсак кыяфәткә керде һәм Корташевскийны бүлдереп:

— Совет әле директор өстеннән хөкемдар түгел,— дип түшәмгә карады.— Министр язган фәрман нигезендә, мин эчке идарә турында сүз барганда, сезнең берегезгә дә буйсынмыйм...

— Әйе, директор әфәнде, сез дөресен әйтәсез,— диде Каменский кызулык белән.— Григорий Иванович сүзен тәмамлаган булса, бу җәһәттән мин дә кайбер фикеремне әйтер идем.

Яковкин үзен яклаучы табылганга эче-тышы белән куанып, Каменскийга сүз бирергә ашыкты:

— Рәхим итегез, рәхим итегез, кадерле Иван Петрович.

— Әйе, коллегалар, председательнең безгә буйсынмаска да хакы бар...

Әгәр дә тәрәзәдән бәхет кошы очып керсә, Каменский әйткән сүзләргә гаҗәпләнгән кадәр үк тәэсирләнмәс иде җыелыш халкы. Хәтта немецлар да, тагын ни әйтер икән бу дигәндәй, колакларын тырпайттылар.

— Дәвам итегез, дәвам итегез,— дип ашыктырды Яковкин.

Каменский дәвам итте:

— Әйе, әфәнделәр, әгәр дә шушы рәсми җыелышны элеккегечә гимназия Советы дип атаган очракта, гимназиянең җитәкче постында эшләми торган барлык профессорлар вә адъюнктлар үзләренең биредәге урыннарын, 1798 елда падишаһыбыз тарафыннан расланган Казан гимназиясе турындагы положениенең унберенче параграфы нигезендә, Совет членнары итеп билгеләнгән өлкән укытучыларга бирергә тиешләр. Димәк, без Советның действительный членнары түгелбез икән, Советта хәлиткеч тавышка ия түгелбез икән, ул чагында, билгеле инде, директор әфәнде хаклы. Әйе, ул безнең беребезгә дә буйсынырга тиеш түгел. Ә безгә нишләргә инде шулай булгач? Безгә моннан чыгып китәргә генә кала инде...

Каменский, чыгарга әзерләнеп, креслосын этәреп куйды. Адъюнкт Корташевский, һәм аның артыннан тагын берничә кеше урыннарыннан тордылар. Бары тик шул чакта гына Яковкин Каменскийның үтә хәйләкәр адым ясавын һәм эшнең кинәт куркыныч төс алуын аңлап:

— Сабыр, әфәнделәр, сабыр! Бер генә минутка сабыр,— дип башлаган иде, тик урам якта кемдер әче итеп сызгырды. Аннары тавыш-гауга күтәрелде.

Яковкин ашыгып урыныннан торды, ачык тәрәзә янына килде һәм, урамдагы күренештән коты очып, артка чигенеп куйды. Анда, нәкъ утырыш залы каршысында, студентлар һәм гимназистлар җыелган иде. Директор күзенә иң әүвәл Балясниковның киң җилкәсенә менеп баскан Паша Чуфаров чалынды. Ул бер кулы белән фонарь баганасын кочаклаган, икенче кулының бармагы авызында.

Яковкинның тез буыннары шәлперәйде. Университетта аның иң курыкканы — укучылар арасындагы чуалыш иде. Теге чакта Лихачевны урыныннан төшергән көннәр әле дә исеннән чыкмый. «Нишләргә, нишләргә соң?» Яковкин буй-сынын туры тотарга, төз атларга тырышып, үз урынына килде һәм утырышны ташлап чыгарга әзерләнүчеләргә карап тезәргә тотынды:

— Утырыгыз, әфәнделәр, хәзер тәмамлыйбыз. Шул рәвешчә, Каменский әфәнде әйткән сүзләр мине тирәнтен уйланырга мәҗбүр итә. Нишләп әле безнең Советта шундый хәл? Эш шунда, минемчә: бүгенге көнгә кадәр бер гимназия положениесенә дә, университет ус-

тавына да таянып килдек. Ә алар, билгеле булганча, бер-берсенә туры килмиләр. Шуңа күрә, киләчәктә мондый авыр хәлдә калмас өчен, каршылык һәм низаглар килеп чыкмасын өчен, мин сезнең игътибарга түбәндәгеләрне тәкъдим итәм: «Бөтен профессор һәм адъюнктлар исеменнән попечитель галиҗәнабләреннән Советны гимназиянең агымдагы эшләреннән азат итүне үтенергә...»

Мәсьәлә шундый ансат юл белән хәл ителер дип берәү дә уйламаган иде. Шуңа күрә Советның барча членнары, бертавыштан директор тәкъдиме белән ризалашып, бик канәгать төстә таралыштылар.

Баш идарәгә Совет карарын җибәргәннән соң, Яковкин шул ук кичтә «Халык Мәгариф Министры, Дәүләт Советы әгъзасы, сенатор, действительный тайный советник һәм кавалер граф» Петр Васильевич Завадовскийга, «Каменский белән Корташевскийның түзеп булмаслык эшләр белән шөгыльләнүен» бәйнә-бәйнә тасвирлап, озын дәгъва язды.

«Шушы елның мартында,— дип зарланды ул,— Каменскийны контора членлыгына билгеләп бик нык ялгыштым. Аш белән атканга таш белән ата торган зат икән ул. Холкы да бик каршылыклы. Нәрсә генә әйтсәң дә, кирегә сукалый. Корташевскийны да тыңлатып булмый. Икесе бер сүздә. Партияләргә бәйле кеше ул Корташевский. Яз көне аның белән Тенишев бакчасында йөргәндә мин моны төгәл белдем. Мәскәү университетындагы партияләр турында авыз ачарга да өлгермәдем, ул партияләр ягында торуын сиздерде. «Галимнәр сословиясе, үзлегеннән идарә итү хокукы яулап алыр өчен, югарыдагы башлыкларның фикерләрен санга сукмаска тиеш», дигән иде Корташевский. Мин тәгаен беләм: Каменский әфәнденең инспектор буласы килә. Ә Корташевский минем исемне караламтып, минем урынга утырырга, ягъни директор булырга хыяллана. Ә инде Советның гомуми карарын раслауга килгәндә, мин аны сездән җавап алганчы, уку йортында дошманлык белән андый-мондый хәл килеп чыкмасын, тынычлык булсын дип кенә расладым...»

Министр Завадовский кемнең хакка, кемнең нахакка гаепләнүен тикшереп тормады, 1806 елның тугызынчы ноябрендә каурый каләмен чалт итеп көмеш кара савытына тыгып алды да эре хәрефләр белән язарга тотынды: «Казан гимназиясе Советындагы тәртипсезлекләргә вә итагатьсезлеккә чик кую максаты илә,

башкаларга йогынтыларын булдырмау нияте илә, профессор Каменскийны, адъюнкт Корташевскийны вә янә алар коткысына бирелүчеләрне эш урыннарыннан алырга һәм башкалар белән алыштырырга...»

...Николай гимназия коридоры буйлап уйланып бара иде, кинәт җилкәсендә кемнеңдер кулын тоеп, борылып карады. Каршысында Аксаков басып торганын күргәч, ул бер-ике адым артка чикте.

— Ташла шул җыен юк-барга ачу саклавыңны! — дип сүз башлады Сергей.— Яковкинның соңгы этлеге турында ишеттеңме әле? Безнең Григорий Ивановичның башын ашаган. Каменскийның да. Әхмәтов белән Чикиевне дә куган. Бу Яковкин алланың кашка тәкәсенә әйләнде бит. Немецлар да бәйрәм итә...

Уртак кайгы иске дусларны кабат якынайтты. Дәрес беткәч, алар урамга бергәләп чыктылар...

— Григорий Иванович янына барасыңмы? — дип сорады Сергей.

Лобачевский сүзсез генә баш какты.

Алар барып кергәндә, Корташевский һәрвакыттагыча эшләп утыра иде. Бераз ябыккан да кебек, авырый да сыман. Әмма тавышы элеккегечә нык, ышанычлы, тыныч.

Григорий Иванович яшьләрне ачык чырай белән каршы алды. Аларга шатланып кулын сузды.

— Утырыгыз, утыр. Минемчә,— дип сөйләп китте ул эчкерсез тавыш белән,— тиздән барысы да җайланыр, чөнки без Каменский белән башкалага прошение җибәрдек. Кыскасы, кайгырырга иртәрәк әле. Сезгә, Лобачевский, бигрәк тә. Тагын ике атнадан сез университетка керү имтиханы тотачаксыз... Әйтмәделәрмени әле үзегезгә?

Корташевский Коляның иңеннән кочып алды.

— Сезгә бер генә минут вакытыгызны да әрәм итәргә ярамый. Һич кичекмәстән эшкә утырыгыз,— диде ул.

Күңеле тулган Лобачевский моңа каршы:

— Хушыгыз, рәхмәт! — дип кенә әйтә алды.

## 3

1807 елның 14 феврале, көн уртасы иде. Университетның авыр имән ишеге кинәт ачылып китте, һәм аннан мундир кигән, шпага таккан зифа буйлы бер егет атылып килеп чыкты.

Көчле җил исеп, егетнең коңгырт бөдрә чәчен тузгытты, битенә вак кына кар бөртекләре сипте. Ләкин егет моңа игътибар итмәде, авыр сулый-сулый, колоннага сөялде.

Озак та үтмәде, агач аягы белән шак-шок атлап, инвалид сторож килеп чыкты. Ул бер кулына шинель белән эшләпә тоткан иде.

— Нишләвегез инде бу, Лобачевский әфәнде? Яз җитмәгән ич әле, суык-фәлән тидерүегез бар.

Лобачевский ялт итеп аңа таба борылды да, шинелен ала-ала, бик ягымлы гына:

— Рәхмәт инде, Емельян агай,— диде.— Киенми генә чыгылган шул. Залда утырганда нишләптер баш әйләнеп китте, йөрәк урыныннан чыгарга җитеп тибәргә тотынды... Хәзер әйбәтләнде шикелле...

— Зур шатлыктан ул, зур шатлыктан,— дип сөйләнде карт.— Шатлыкның аның кайгыдан ныграк китереп суккан чагы да булгалый. Әйдәгез, шинелегезне миңа бирегез дә үзегез залга үтәрсез. Хәзер анда музыка, сый-хөрмәт башлана.

Солдат, чатанлый-чатанлый барып, ишекне тутырып ачты.

— Капельмейстер Новиков әфәнде боерыклар бирә калган иде инде. Укучылар, университетны олылап, кантата җырларга тиешләр. Әйдәгез, рәхим итегез!

— Рәхмәт, Емельян агай! — диде Николай, күңеле нечкәреп. Ул соңгы тапкыр үзенең эсселәгән маңгаен җилгә куйды, күкрәк тутырып бер сулу алды һәм ачык ишектән эчкә керде.

Өстән, актлар залыннан, тантаналы кантата җырлаулары ишетелде:

Фән бакчасына әйләнеп,
Дан алыр мәңге Казан...

Николай җырга колак салып һәм бүген кичергәннәрен искә төшерә-төшерә, акрын гына атлап өске катка менә башлады.

Юк, юк, бер дә төш түгел. Өлкән класстагы сигез укучы бүгеннән студент. Менә ич шпагасы!

Ул саклык белән генә шпаганың эфесына тотынды һәм кылычын яртысына кадәр тартып чыгарды. Шул вакыт ул, гүя шпага кулын көйдереп алды, баскыч уртасында туктап калды. Ничек итеп шундый хәлне абайламады соң әле? Университет ачылуга ике ел тулган көнне һәммә кеше бәйрәм иткәндә, укытучылардан

бер Корташевский гына юк. Ни өчен килмәде икән?

Николай кылычын кынына тыкты һәм кире түбәнгә йөгереп төште.

— Емельян агай, шинель белән эшләпәне тиз генә бирегез әле! Григорий Иванович юк бит, хәлен белеп кайтыйм...

— Шулаймыни? — диде карт сторож, элгечтән шинельне кабалана-кабалана алып.— Кара инде, әй!

Ул соңгы сүзләрен әйткәндә, Лобачевский инде вестибюльдән атылып урамга чыккан һәм Черек күл ягына таба йөгерә иде.

Буранда да халык урамда иде. Әнә бакчада балалар бик зур итеп кар бабай ясап куйганнар. Хәзер ярыш бара: шуның кишер борынына кем тидерә ала дип, йомарлам-йомарлам кар ыргыталар. Башка вакыт булса Николай да ярышка катнашмый калмас иде, хәзер әйләнеп тә карамады.

Елагиннар йортына җитүгә, ул күңеле нидер сизенеп, кинәт кенә куркынып китте. Парадный ишекне ни өчендер тупсасына кадәр ачып куйганнар. Баскычтан йөгереп менгәч, Николай аптырап калды. Григорий Ивановичның кабинет ишеге төбендә зур-зур әрҗәләр тора.

«Бәлки, бүтән квартирага күчәдер?» дип үзен-үзе тынычландырмакчы булды Николай, әмма күңеле моңа ышанмады.

Николай башын күтәреп караса, ни күрсен — Корташевский елмаеп бусагада басып тора. Менә ул егеткә таба атлады.

— Шпага бирделәрмени инде? Бик әйбәт! Тәбрик итәм, Николай... Иванович... Хәзер инде шулай дию дә килешә. Рәхим итегез.

Кабинет бушап калган. Киштәләрдән китаплар, стеналардан картиналар алынган. Егет күз йөртеп чыкты да, мондый хәлгә ышанырга теләмичә, сорау бирде:

— Григорий Иванович, әллә сез...— ләкин ул сүзен әйтеп бетерә алмады.

Корташевский аның иңбашына кулын салды.

— Әйе, китәм шул, Николай. Бүген иртән Петербургтан көенечле хат килде. Сенат безне университетка кабат эшкә урнаштыруга каршы. Туган шәһәр, университет... Әллә бирегә әйләнеп кайтам, әллә юк инде...

Корташевскийның тавышы калтырап китте. Ә Ни-

колай читкә борылды һәм күз яшен сөртеп алды. Әкрен генә сулкылдап Сергей килеп керде.

Ләкин Григорий Иванович үзен бик тиз кулга алды.

— Николай, сез бит шпага таккансыз! — диде ул кырыс тавыш белән. Хәзер инде ул әүвәлге тыныч кыяфәтле укытучы иде.— Сез киләсен белеп, менә кайбер нәрсәләр калдырган идем,— диде ул, өстәлгә таба борылып, һәм кулы белән күн тышлы калын-калын китапларны күрсәтте.— Болары Ломоносов. Ә менә дәфтәрдә философ Дидродан күчереп алган кайбер фикерләр. Сезнең белән безгә бик кирәкле нәрсәләр. Тыңлап карагыз әле менә.

«Фән өлкәсе иксез-чиксез кырны хәтерләтә; ул кырның кайбер урыннары караңгы, кайбер урыннары яктыдыр сыман тоела. Безнең хезмәтләребез әнә шул якты җирләрне киңәйтә төшәргә яки басудагы утларны ишәйтергә тиеш. Беренчесен даһи акылы булдыра алса, икенчесен үзгәртү һәм яхшыртуга сәләтле зирәк акыл иясе башкарып чыга...» Төшенәсезме?

Алар шулай бик озак сөйләшеп утырдылар. Корташевскийның әле моңа кадәр бервакытта да яраткан укучыларын болай үз итеп, якын күреп сөйләшкәне юк иде.

Лобачевский гимназиягә әйләнеп кайтканда, юбилей көне тәэсирләреннән алҗыган иптәшләре инде изрәп йоклыйлар иде. Шулай да Алеша уянды. Николай энесеннән:

— Тикшерү булдымы? — дип сорады.

— Булды,— диде Алеша.

— Мин йоклаган идемме?

— Әлбәттә. Әнә ич, әле хәзер дә одеял астында ятасың.— Алеша караватка ымлап алды. Одеял шул кадәр оста кабартып куелган, анда, чынлап та, кемдер яткан сыман иде.

Николай сүрән генә көлеп куйды. Ә инде чишенеп, башыннан ук одеялга төренеп яткач, күз яшенә ирек бирде. Бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике укытучы турында ачынып уйлады ул. Алар икесе дә яшьләрне үзләре теләгәнчә укыта алмыйлар. Икесе дә шундый акыллылар, кайгыртучаннар, мәрхәмәтлеләр... Үпкә авыруы белән интегүче Ибраһимов һәм урыныннан чыгарылган Григорий Иванович турындагы уйлар аның бәләкәй йөрәген кысып-кысып ала... Шуңа күрә егет үзалдына:

— Булмас!.. Хаклык җиңәр! — дип сөйләнеп ятты.

Ә инде күз алдына мәкерле елмаеп торучы Яковкин килеп баскач, үзе дә сизмәстән:

— Ул хаиннан яхшылык көтмә инде син! — дип шактый кычкырып әйтеп куйды. Һәм барыбер йоклап китә алмаячагын сизеп, урыныннан торды. Китапларын култык астына кыстырды да, кулына шәм тотып, икенче катка юнәлде.

Караңгы коридорда класс бүлмәсенең ишеген ул капшанып кына эзләп тапты һәм, эчкә кереп, ишекне япкач кына, шәмне яндырып җибәрде. Шуннан Григорий Ивановичтан алып кайткан Ломоносов китапларын актарып Аристотель турында язылганны эзли башлады.

— Бөтенләй тапмам кебек тоелган иде, менә ич! — дип куйды ул, бик озак эзләгәннән соң үзенә кирәген табып. Вольфның «Физика»сына язган кереш сүзендә Михаил Васильевич болай ди:

«Ошбу фәнгә * мөнәсәбәте булган галимнәр һәммәсе бер Аристотельгә ияргәннәр, аның фикерен хакыйкать дип кабул иткәннәр, хаталануы мөмкин түгел дип уйлаганнар, һәм шуның нәтиҗәсендә философиянең үсешенә, шулай ук ошбу фәнгә бәйле бүтәннәрнең үсешенә зур зыян килгән. Ошбу фикер нәтиҗәсендә фән белән шөгыльләнүчеләрнең берсе икенчесеннән уздырырга теләп, яңадан-яңа ачышлар ясарга булган изге омтылышлары юкка чыгарылган...»

Ломоносовның кереш сүзенә эчкәрерәк кергән саен Николай ныграк җанланды.

— Шулай шул менә! Бик дөрес! — дип җөпләде ул һәм кычкырып укый башлавын сизми дә калды.

«Кыскача итеп әйткәндә, соңгы вакытларда фәннәр искиткеч дәрәҗәдә алга киттеләр, һәм бу хакта, моннан мең ел элек яшәүчеләр генә түгел, хәтта йөз ел элек яшәүчеләр дә хыяллана алмаганнар булса кирәк. Ошбу хәлнең килеп чыгуына иң төп сәбәп менә нәрсә: хәзерге галимнәр, аеруча табигый әйберләрне тикшерүчеләр, берәүнең башында туган уйдырмаларга һәм купшы сүзләргә мөкиббән китмиләр, күпчелек очракларда хак сәнгатькә ** мөрәҗәгать итәләр».

Әнә бит ул ничек ди! Аристотель кебек даһиларга

---

* Философия күздә тотыла.

* Бу очракта М. В. Ломоносов эксперимент, ягъни тәҗрибә ясап карауны күздә тота.— *Ж. Т.*

да тәнкыйть күзлегеннән карарга куша. Язып алыйк әле.

Николай үзенең дәфтәренә каләме белән энҗе шикелле вак хәрефләр тезәргә кереште. Язып бетергәч, Ломоносов китабын читкә алып куйды һәм, бөдрә чәченә бармакларын батырып, ике учы белән күзен каплады.

— Бу мәсьәләне Дидро ничек аңлата икән, тукта, карыйм әле! — дип, Николай тиз-тиз генә Корташевский биреп җибәргән дәфтәрне актарырга тотынды. Эзли торгач, ул аннан «Табигатьне аңлатуга карата фикерләр» дигән хезмәттән алынган өзекләрне тапты. Анда болай диелгән иде.

«...математик фәннәр тәҗрибәдән башка гына бернинди төпле белем бирмиләр... Табигатькә таянычы булмаган төшенчәләрне төньякта үсә торган тамырсыз агачларга тиңләргә мөмкин. Андый агачлардан яки идеяләрдән торган урманны аудару өчен җил исеп куюы да, кечкенә генә факт та җитә».

Димәк, француз галиме дә, Ломоносов шикелле үк, табигатьтән өйрәнергә өндәгән философияне алга сөрә икән. Әмма Лобачевскийга барыннан да әһәмиятлерәк күренгән фикер дәфтәрнең соңгы битенә күчереп язылган иде. Шуны укыганда, Николайның берара хәтта тыны кысылган кебек булды.

«Материя хәрәкәткә һәм торгынлыкка битараф, дип философлар нинди мәгънәдә әйткәннәрдер, белмим... Философларның бу фикере математикларның: берничек тә үлчәнми торган нокта, бернинди киңлеге булмаган сызык, бернинди калынлыгы юк яссылык турындагы карашларын хәтерләтә».

Бу сүзләрне укыгач, Николай утырган килеш кала алмады, әлбәттә. Ул сикереп торып, кулын болгыйболгый, класс буйлап йөренде. Гүя бөек акыл ияләренең әле хәзер генә укылган фикерләре аңа да кагыла, аны да башын эшләтергә мәҗбүр итә иде. Аларның ачышларына хозурланып, хискә бирелеп:

— Димокрит! Ломоносов! Дидро! Радищев! — дип тезеп китте егет.

Хәзер инде ул нинди юлдан барачагын белә. Ихтимал, караңгылык, наданлык һәм искелек дөньясына каршы алып барылган бөек көрәшкә катнашачагын күңеле белән ул нәкъ әнә шул чакны сизенгәндер.

## 4

Яңа көн туып, Николай яңа мәшәкатьләргә күмелде. Тиз-тиз генә киенде һәм Балясниковны эзләргә тотынды. Кыю һәм тапкыр булганы өчен ул аны ихтирам итә иде. Коридорда очратуга:

— Петр! Сенат Корташевскийны университетка кире кайтармаган. Башкаларны да шулай ук,— дип еpактан ук эндәште һәм: — Нәрсә эшлибез? — дип тә өстәде.

Балясников аның янына җитеп туктады. Николай кабаланып:

— Кичә мин Григорий Ивановичның күчеп китәргә әзерләнүен күрдем,— диде.

Балясников бераз дәшми торганнан соң:

— Губернаторга барырга кирәк,— диде.— Бүген үк барырга, Яковкинны кудыртырга, ә Григорий Ивановичларны кире кайтарырга кирәк!

— Рәт чыгар дисеңме? Томана кеше ич ул Мансуров. Гимназия белән университет аның ике ятып бер төшенә керми торгандыр.

— Казанның югары даирәләрендә, кызганычка каршы, аңардан да акыллырак кеше юк,— диде Балясников, кырт кисеп.— Барына канәгатьләнергә туры килә.

Лобачевский күнде:

— Барабыз алайса! — диде.— Дәресләр беткәнче егетләрне күреп сөйләшергә өлгерербез бит.

— Өлгерербез! — Балясников уң кулын Николайга сузды. Бер-беренә ышанырга яраганын һәркайсы сизде.

Көн буена студентлар мыштым гына икәү-өчәү җыела, сөйләшә тордылар, ә надзирательләр күренгәндә, бернигә исләре китмәгән кыяфәт белән таралыштылар.

Кичке якта аларның яртысыннан артыгы кара ишегалдына җыелды һәм тиз генә җыелышсыман бер нәрсә үткәрде. Болай дип карар кылдылар: һәммәсе бергә җыелып барачаклар; губернатор белән өлкән студентлар исеменнән Балясников, кечеләре исеменнән Лобачевский сөйләшәчәк.

Студентларны күреп, Мансуров бер дә шатланмады. Ләкин губернатор, гәрчә аларның начальствога буйсынмавын күреп торса да, ачык чырай белән кабул итте һәм якын арада үтенечләрен тикшерергә вәгъдә бирде.

Әмма эшне кузгатып җибәрү-җибәрмәвен белергә икенче көнне тагын килүләрен күреп бик нык ачуы кабарды. Студентларны кабул итмәве бер хәер, ул хәтта дежурный офицерга аларны университет начальствосы карамагына илтеп тапшырырга кушты.

Шул рәвешле тәртип урнаштыргач, Мансуров тынычлап калырга уйлады булса кирәк. Ләкин аның мондый җиңел акыл белән кылган чарасына җавап итеп студентлар лекциягә йөрми башладылар. Бунтка охшаган бер нәрсә килеп чыкты.

Буш аудиторияләрне күргәч, Казанга зур акча эшләргә өметләнеп килгән немец профессорлары куркуга төштеләр. Алардан да бигрәк бунт күтәрүчеләрнең эти-әниләре һәм шәһәр җәмәгатьчелеге борчуга калды. Гомердә булмаган хәл бит! Университетның әле гимназиядән аерылып җиткәне дә, бинасы да, юньле профессорлары да юк. Мәгариф министрының ачуы килеп, бөтенләй ябып куюы бик ихтимал иде. Университеттагы хәлләр белән бөтен шәһәр кызыксынды. Бик зур җәнҗал купты. Җәмәгатьчелек Яковкинны тиргәде. Университетта эшләүчеләр һәм укучылар ачыктан-ачык ризасызлык белдерделәр.

Губернатор Мансуров студентлар бунтын, гадәттәгечә, полицияне өстереп кенә туктатырга мөмкин дип уйлавы ялгыш икәненә төшенде. Шуннан ул, университетка җитәкчелек итәр өчен Яковкинның ярамавы турында әйтеп, Эчке эшләр министрына хат язарга мәҗбүр булды.

«Шәһәребездә университет ачканда, акылы бар кешеләр мәгърифәтнең үсеп китәчәгенә зур өмет баглаганнар иде... Гимназиядә моңа нигез салына кебек тоелган иде. Әмма, кызганычка каршы, халыкның гадел фикерен көчәйтеп, түбәндәгене әйтергә батырчылык итәм: уку йортларына идарә итү эше сәләтсез профессор Яковкинга ышанып тапшырылган, ә гомуми фикер ул затның кешелек сыйфатларын, холкын хуплап бетерми. Тәрбия эшенең кулдан ычкындырылуына, әдәп-әхлакның булмавына карата ишетелгән ризасызлык авазлары нәтиҗәсендә кайбер укучыларны укып бетермәс борын кире алдылар, ә күпләр үз балаларын гимназиягә бирмиләр.

Ниһаять, җәмәгатьчелек алдында ышаныч казанган, тәртипсезлекләрне бетерергә омтылган университет әгъзалары кинәт чыгарып ташланды. Мәсәлән, профессорлардан доктор Каменский — үз өлкәсендә зур белем

туплаган, элекке начальствосы тарафыннан бик әйбәт аттестат белән бәяләнгән, шәһәребездә үзенең таланты һәм әхлагы җәмәгатьчелек тарафыннан хупланган кеше — бөтенләй эштән куылды. Шулай ук искиткеч сәләтле һәм мәгълүматлы, әхлак ягы тулысынча гамәлгә сыя торган адъюнкт-профессор Корташевскийны да кудылар... Вакытында алар икесе дә куылуның сәбәпләрен сорап мөрәҗәгать иткәннәр иде, тик аларга җавап булмады»...

Мансуров бу эш белән чынлап та кызыксына икән дип уйлау ялгыш булыр иде. Чөнки хатның ахырында ул университеттагы фетнә өчен үзенә эләкмәсен дип кенә тырышканлыгын күрсәтә:

«Әгәр халык файдасын хәл итәчәк фәннәр мәгърифәткә бәйле булмаса... әгәр куылганнарны яклап һәм тәрбия файдасын күздә тотып белдерелгән ризасызлык авазларына битараф калсам, кайгырмасам, миңа ышанып тапшырылган губернадагы чит бер эш белән Сез галиҗәнабны борчымас та идем».

28 нче февральдә студентлар, губернаторның Эчке эшләр министрына хат язганлыгын белгәч, лекцияләргә кабат йөрергә карар бирделәр. Лобачевский, Фукс лекциясенә керү урынына, Григорий Ивановичка барып, губернатор хаты турында әйтте һәм аның, министрдан җавап килмичә, шәһәрдән китми торуын үтенде. Шуннан соң гына бераз тынычланып университетка әйләнеп кайтты.

Кичке якта, йокы бүлмәсенә кереп барганда, аны Сергей туктатты. Уңга-сулга каранып, кулына бер язу тоттырды һәм:

— Григорий Ивановичтан,— дип пышылдап кына аңлатып та бирде.

Николай, тәрәзә яктысына барып дүрткә бөкләнгән кәгазьне ачты. Анда: «Бер сәгатьтән китәм. Кил», дип язылган һәм аста янә ике сүз өстәлгән иде: «Тавышсыз гына».

— Димәк, беркемгә дә әйтәсе түгел,— диде Николай, соңгы сүзләрне укыгач.

Бер-ике минуттан алар инде урам буйлап йөгерәләр иде.

— Петербургтан әле генә депеша килеп төште,— диде Сергей, барган шәпкә.— Григорий Иванович белән Каменскийны чакыралар. Ә нәрсәгә икәнен әйтмәгәннәр.

Алар йөгереп килеп кергәндә, Корташевский инде

чыгып китәргә тәмам әзерләнгән, юл киемнәре — туны, бүреге, тире бияләйләре — ишек төбендәге урындыкта ята иде.

Григорий Иванович тыны беткән Николайны кочаклап алды:

— Тиз килүең өчен рәхмәт. Бүген төнлә сәфәр чыгабыз... Петербургка... Синең турыда сөйләшеп калыйк...

Укытучы аңа яратып һәм үз итеп «син» дип эндәшүен сизмичә калды. Моны шулай ук Николай да абайламады. Аларга комачауламас өчен Сергей үз бүлмәсенә юнәлде.

— Син хәзер математика хакыйкатьләрен дөрес итеп өйрәнү юлына кердең,— диде Корташевский. Ул ашыкмыйча гына диванга утырды һәм Николайга кулы белән ишарәләп урын күрсәтте.— Ләкин әлегә син беренче адымнарыңны гына ясыйсың. Геометриянең чын-чын нигезенә үтеп керү юлын Демокрит, Ломоносов, Дидро һәм Радищев күрсәтеп бирерләр. Андый бөек эшкә мин катнаша алмам, күрәсең. Минем әйтергә теләгән фикеремне, хәтереңдә булса, Румовский әйтте. Киләчәктә, Николай, ул проблеманы син һәм синең иптәшләрең чишәргә тиеш. Радищев сүзләрен һич онытырга ярамый. Ә ул: «Эшкә тәвәккәл тотыну, армый-талмый башкарып чыгу — Россия халкына иң хас сыйфат»,— дигән.

Григорий Иванович бераз вакыт тынып торды. Николайга килсәк, ул авыз ачып сүз әйтерлек түгел иде. Укучысының хәлен аңлап, Корташевский урыныннан кузгалды.

— Вакыт җитте, дустым,— дип саубуллаша башлады.

Николай, иске баскычның кытыршы басмаларыннан ничек төшкәнен дә, төнге буш шәһәр урамнары буенча ничек кайтканын да хәтерләмәде. Университетка ул суыктан бөрешеп-туңып, култыгына остазы бүләк иткән китаплар кочаклап кайтты. Төнге каравылчы бабай аңа, кеше-кара күзенә чалынмыйча, эчкә узарга ярдәм итте һәм шуның белән аны күңелсез хәлдән коткарды.

## 5

Корташевский Петербургка киткәч ике-өч атна вакыт узмагандыр, Сергей Аксаков та университет белән саубуллашты. Чана юлы өзелер алдыннан, әти-әни-

се белән бергә өенә кайтып китте. Киләсе көзгә шулай ук башкалага барып гражданлык хезмәтенә урнашырга иде аның исәбе.

Ә бу көннәрдә Казан университетында хәрби рух хөкем сөрә иде. Чөнки Наполеон белән канлы сугыш бара. Бөтен Россия буенча милиция отрядлары төзелә, халык ополчениеләре оеша. Патриотик хисләр Казанга да килеп җитте. Әле 1806 елның декабрендә үк университет механигы Никита Филиппович Горденов Яковкинга бик зур сер итеп кенә «французларның һәлак иткеч батареяларына каршы тору» ысулын уйлап табуын әйтте һәм, яңа ачышын патша галиҗәнабларына күрсәтү өчен, үзен башкалага җибәрүен сорады.

Казна исәбенә укучы өлкән студентлар илбасарларга каршы изге көрәшкә катнашу өчен рус гаскәрләре сафына басарга ыргылдылар. Яковкин попечительгә: «Нишләргә?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды.

1807 елның 14 мартында Халык мәгарифе министры исеменә университетларда һәм гимназиядә укучы дворян балаларын хәрби хезмәткә алу тәртибен ачыклый торган патша указы килә. Бу указ буенча студентлар, махсус әзерлек узып һәм унтер-офицер чинын алып, туп-туры хәрәкәттәге армиягә китәргә тиеш иделәр. Шул турыда Казан гимназиясе Советына хәбәр итеп, Румовский болай дип боерды: «Хәрби хезмәткә китәргә теләгән студентларны тоткарламаска! Патша галиҗәнабларының әмере шундый».

Фронтка беренчеләрдән булып Петр Балясников китте. Балясников бик тә акыллы, куркусыз, һәрбер эштә иптәшләрен үзе артыннан ияртергә һәвәс егет булып, башка студентларның да күңелендә сугышка китү дәртен кузгатты. Сәламәтлекләре какшаган һәм хәрби хезмәткә бөтенләй битараф булган студентлар да торабара аңа иярә башладылар. Кыска гына вакыт эчендә, фронтка җибәрүләрен сорап, студентлардан 24, гимназистлардан 3 гариза керә. 1807 ел башына университетта җәмгысе 52 студент укуын искә алсак, бу, әлбәттә, шактый зур югалту була.

Гариза язган студентлар Казаннан киткәч кенә җитәкчеләр тәшвишкә төштеләр. Ләкин укуларын ташлаган студентларның инде берсе дә университетка әйләнеп кайтмады. Яковкин белән инспектор ярдәмчесе «аудиторияләрне тыңлаучылар белән тәэмин итү» ту-

рында хафаланып йөрсәләр дә, уку заллары ярты-ярты буш кала иде. Ә яз җиткәч инде укуларын ташламаган студентлар да, лекцияләргә йөрмәс өчен Тенишев бакчасындагы беседкаларда, куак араларында качып утыра башладылар. Инспектор ярдәмчесе еш кына директор исеменә «йокы камераларын иртәнге тикшерү вакытында студентларны йә йоклап яткан килеш, йә шашка-шахмат уйнап утырган килеш күрүе» турында рапортлар язды. Университетта тәртипсезлек шулкадәр көчәйде ки, студентлар хәтта лекция вакытында үзара тукмашуга кадәр барып җитәләр иде.

Өлкән абыйсы Александр белән бергә Николай Лобачевский да хәрәкәттәге армиягә китәргә тыпырчынып карады, ләкин яше җитмәү сәбәпле һәм чыгышлары дворян нәселеннән булмаганга күрә, аларның гаризасын кире кактылар.

Бу чорда Николай бик нык ябыкты, төшенке уйларга бирелде. Кайнап торган энергияле, тимердәй нык ихтыярлы егет бөтенләй бетәшеп, сырхау малайга охшап калды. Хәтта университетта укытыла торган фәннәр дә кызыксындырмый башлады аны. Корташевский киткәч, математика укытуны вакытлыча өлкән курс студенты Владимир Графка тапшырдылар. Ә ул гимназия курсларын — алгебра белән геометрияне кабатлаудан ары китә алмады. Математика фәненнән иптәшләренә караганда һәрвакыт алданрак барган Николайны гимназия курслары гына канәгатьләндермәде. Хәер, Граф үзе дә математика буенча Лобачевскийга тиңләшә алмый иде, әлбәттә. Николай акрынлап университеттан суына башлады, ә Граф укыткан дәресләргә бөтенләй йөрмәде. Студентлар ведомостен тикшергәндә Яковкин бу хәлне бик тә куанып кабул итте.

— Ниһаять,— дип мыгырданды ул эчке бер канәгатьләнү кичереп,— булачак бөек математикның да дәрте сүнде, димәк. Теге чакта Румовский галәҗәнаблары артыграк мактап ташлады бугай егетне...

Николай, чынлап та, үзен нәкъ директор уйлаганча тотты. Күпмедер вакытка геометрия белән кызыксынуы арткан кебек тә була аның. Элеккечә кайнарланып булмаса да, шактый авыр мәсьәләләрне тиз генә чишеп ташлый иде ул. Ләкин монысы да озакка бармады. Тиздән ул бөтенләй битарафланды һәм университет диварлары эчендә үзен артык кеше итеп хис итә башлады.

Эче тулы авыр уйлардан, сагыш-борчулардан арыну өчен, ул иртүк торып урамга чыгарга һәм тәмам хәлдән тайганчы күзе караган якка сәяхәт кылырга гадәтләнде. Арып-талып йокы камерасына кайта да урынына ава. Йокысыннан уянгач, бары тик бер максат — үзен эт булганчы йончыту максаты белән янә сәфәргә кузгала иде.

Ул арада яз да килеп җитте. Өер-өер булып агылган аксыл болыт арасыннан ара-тирә зәп-зәңгәр күк кисәкләре күренеп киткәләде, һавада сафлык, тереклек билгеләре шәйләнде. Ләкин Николайны язгы җанлану да сөендермәде. Ул үзен бөтен яшь гомерен бушка уздырган бәхетсез кеше кебек хис итте. Аудиториядә дә, китапханәдә утырганда да шундый төшенке хисләр, авыр тойгылар әзәрлекләде аны...

## 6

Кояшлы апрель көнендә Николай шәһәрдә йөреп керергә дип чыккан иде. Проломный урамнан барганда кибетчеләрнең һәм хезмәтчеләрнең:

— Ой, студено бара, студено! Карагыз әле, кылычы кәкрәйгән! — дип шаяртуларын ишетте.

Николайның бит алмалары алсуланып китте, һәм ул, озак уйлап тормыйча, тар тыкрыкка борылды. Болакка җиткәч, ирексездән туктап калды. Җәй көне бөтен шәһәргә сасы ис чыгара торган бу каналга Иделдән чиста су кереп тулган, бер-бер артлы баржалар тезелгән. Сокланырлык та шул!

Менә бурлаклар, Идел буенда үскән егетнең күңелен җилкендереп, таныш көйгә:

— Эй, ухнем! — дип сузып җырлап җибәрделәр һәм, йөк төягән баржаны үткәрү өчен, озын чылбыр ярдәмендә агач күперне күтәрә башладылар. Николай баржаның күпер астыннан чыкканын көтеп алды һәм аны Болак буйлап озата барды. Яр буен тутырып агылган халык белән бергә атлый торгач, ул Ташаяк ярминкәсенә барып җиткәнен дә сизми калды.

Ярминкәнең исеме җисеменә туры килеп тора: ташаякның, ягъни савыт-саба ише нәрсәнең төрлесе бар. Пыяла савыт-саба да күп, фарфоры да җитәрлек, балчыктан ясалганын инде әйткән дә юк; баржадан бушата торалар, сата торалар. Аннары тагын читтән китерелгән паласлар, Казанда эшләнгән түбәтәй, читек-кәвешләр сатыла. Бала-чага тирә-юньне күңелле

авазлар белән тутырып сыбызгы сызгырта, чыр-чу килә. Шуграк малайлар, кеше күрмәгәндә, су сиптереп качалар...

Якты кояш, ярминкәдәге ыгы-зыгы, күңеллелек Николайны да үз эченә бөтереп алды. Һәрхәлдә, аю биеткәнне күреп, егет туктап калды. Аю биетүче — каешланып беткән түбәтәй кигән, сыңар күзле татар агае — тырышып-тырышып юкә барабанын кага; ә юлдашы үзе ясаган скрипкада ниндидер көйне сыздыра. Аның кыланышын күреп көлми калырга мөмкин түгел: ат кылы тартылган смычогы нечкә көй чыгарганда — кашлары югары күтәрелә; смычок калын авазларга күчсә — каш түбән төшә. Смычок тизрәк йөрергә тотынган иде — моның кашы да бер өскә, бер аска сикерә башлады. Кара тутлы бу татар агаеның кашы-күзе биегәнне күреп, тирә-юньдәге һәммә халык шаркылдап көлә. Көлдерә алсаң, халык юмартлана һәм акча янчыгын чишеп җибәрә. Чыннан да, әнә бии-бии хәлдән тайган аю ал аяклары белән бүрек күтәреп мәйданны әйләнеп чыккан иде — шактый гына бакыр чыңлаганы ишетелде. Николай да бер бакыр акча салды.

Ярминкәдә туйганчы йөргәч, ул ыгы-зыгыдан аерылып тору һәм кош сайраганны тыңлау теләге белән шәһәр читенә чыкты. Университетка фәкать кичен генә, укуга ныклап тотынырга карар биреп, эшлекле кыяфәттә кайтып керде.

Вестибюльдә аны карт сторож туктатты:

— Кабул итү бүлмәсенә рәхим итегез,— диде ул шат тавыш белән.— Сезне анда әнкәгез күптәннән көтә.

Николай коридордан йөгереп килде дә кабул итү бүлмәсенең бусагасы төбендә катып калды. Анда иңенә чуар шәл салып, бер кулы белән Алексейны, икенчесе белән Александрны кочып, аның газиз әнисе утыра һәм сөенечләре йөзләренә чыккан улларына нәрсәдер сөйли иде. Нинди әйбәт аларның әниләре! Ярты ел күрешмичә торгач, бигрәк тә сагындырган икән шул. Әнисенең бик тә матур, алай гына да түгел, бик тә чибәр, сылу икәнлеген Николай әле менә шушы минутта гына абайлады. Йөз сызыклары килешле, җанлы икән бит әнисенең. Кашы чем-кара, күзе зур, карашы акыллы, ягымлы, якты иде. Ә тавышы, тавышы! Җырчыларныкы сыман сыгылмалы, яңгравыклы. Шушы сылу ханымның синең әниең булуы нинди зур бәхет!

Николай атылып килде дә әнисен ныгытып кочып алды.

— Әнием, берәр хәл булмагандыр ич? Әллә бабакай авырып киттеме?

— Юк, Коленька, юк. Шөкер, барысы да исән-саулар. Безнең хәлләр әйбәт, улым. Ләкин минә...— әни кеше зур булып ачылган күзе белән Николайга туп-туры карады. Аның карашы сагышлы һәм шул ук вакытта шелтәле иде.

— Утырыгыз, улым, утырыгыз! Мин бит сезнең аркада килдем монда...

Әнисе үпкәләгән яисә ачуланган чагында һәрвакыт «сез» дип сөйләшә.

— Минем аркада? — диде гаҗәпләнүдән авызы ачылып калган Николай.— Соң, әнием, мин бит...

— Минә, Григорий Иванович хат язган,— дип улын бүлдерде Прасковья Александровна, сумкасын ача-ача.

— Григорий Ивановичтан хат? Кайда ул хәзер, әнием? Нәрсә булган аңа?

— Менә бит! Сез үзегез белергә дә теләмәгәнсез. Ә бит ул сезнең өчен бик нык борчыла. Инде мине дә юл өзегендә, мең газап чигеп, кичүләрдә батып үлә язып, Казан тикле җиргә килергә мәҗбүр иттегез. Тыңлагыз менә, сезнең хакта ул нәрсә яза.— Прасковья Александровна хатны ачып укырга керешТе: — «Казаннан килгән күңелсез хәбәрнең тулысынча дөреслегенә әле мин үзем дә шикләнәм. Безнең иң шәп укучыбызның укуга дәрте суынуына һич кенә дә ышана алмыйм...»

Николай, артык дулкынлану сәбәпле, башта дәшми генә утырды, аннары пышылдап кына:

— Шулай шул,— дип куйды.— Лекцияләренә кермәдем, йөзләрен күрмәс өчен урамда йөрдем. Бу бинада, кая гына карасам да, Григорий Иванович исемә төшә. Ул Яковкиннарын күрәсем килми... Китаплардан гына өйрәнермен ахры...

— Григорий Иванович шуны да күздә тоткан шул менә,— диде ана, һәм аның йөзендә кайгы катыш елмаю чагылып китте.— Менә тыңла, аның язганын укыйм: «...Ихтимал, Николай мөстәкыйль рәвештә укырга җыенадыр. Әгәр шулай икән, ул бик нык ялгыша. Андый ысул белән тәрбияләнгән очракта кешегә иң нык тәэсир итә торган көч, яшь йөрәкләрне җилкендерә торган этәргеч, ягъни намуслы һәм инсафлы

булуга әйди торган ярышу мөмкинлеге читтә кала. Мондый мөмкинлекне гимназиядә һәм университетта очрата аласыз, чөнки ярыш ул күмәк тәрбия вакытында барлыкка килә. Аннан тыш, бай китапханә, физика кабинеты, ботаника бакчасы, төрле машиналарны фәкать уку йортында гына табарга мөмкин...»

Хатны укып бетергәч, Прасковья Александровна улына сораулы караш ташлады.

— Йә, Коля, нишлибез? Үзең хәл ит, университетта каласызмы, әллә минем белән Макарьевога кайтып китәсезме? Үзлегеңнән укырга, дим.

Николай кинәт кенә әнисенең битеннән үбеп алды да, аны-моны дәшмичә, ишеккә ташланды.

Прасковья Александровна Казанда калырга мәҗбүр булды.

Николай өч көн буе чытык йөз белән йөрде, әледән-әле каядыр югалгалап торды. Аны күзәтеп йөргән Александр әнисенә, туганының авыру Ибраһимов янында булуын, анда шактый озак утыруын, аннары сукно фабрикасына барып чыгуын һәм Бишбалтада судно төзүчеләр белән очрашуын хәбәр итте...

Николайның исә сүзләре кыска булды:

— Монда калам. Казанда укыячакмын.

Имтиханнарга кадәр вакыт бик аз калган иде инде. Николай дәресләренә бик ныгытып, кайчандыр аңлашылмаган сорауларына җавап эзләгән чактагы җитдилек белән, үҗәтләнеп тотынды. Иртә таңнан төн урталарына кадәр китапларыннан аерылмады.

Имтиханнар уңышлы узды. Прасковья Александровна шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Аның Александры «физика» фәне буенча ифрат та сәләтле булуын күрсәтте, төпчек улы Алексей университетның беренче курсына кабул ителде, ә Николай математикадан һәм натураль тарихтан бик яхшы билгеләре алды.

Макарьевога әниләре белән бергә җәйге вакансиягә уллары да кайтачаклар иде. Юлга таң алдыннан чыгарга ниятләделәр. Чөнки иртәнге салкында атларга да рәхәт, кешеләргә дә күңелле. Ә инде көндез, кояш кызуында берәр матур урында туктап, кичке салкынга кадәр ял итәргә мөмкин иде.

Иртәгә китәсе дигән көнне, ягъни унтугызынчы июльдә Николай Дмитрий Перевощиков янына саубуллашырга һәм җәй көне укыр өчен математика китапларын сорап торырга керде.

Балык каптыру турында сөйләшә торгач, ул Дмитрий янында шактый озак утырды. Шунда кинәт кенә ишек ачылып китте дә бүлмәгә йөзе качкан Василий Перевощиков атылып керде. Николайны күргәч, бөтенләй дерелдәп төште, акрын-акрын артка чигенә башлады.

— Тегендә, Казанка суында хәзер...— дип нәрсәдер әйтергә азапланды ул. Тик авызыннан сүзе чыкмады. Шул килеш караватка ташланды да, йөзе белән мендәргә капланып, үксергә тотынды.

— Вася! — дип җилкәсеннән тотып селкеде аны Дмитрий.— Вася! Ни булды? Әйтәсеңме, юкмы? Ни булды, Вася?

Василий, ниһаять, яшькә чыланган йөзен мендәрдән күтәрде.

— Әйтәм, ләкин аңар түгел,— дип, Николай ягына ымлап алды ул.— Аңар ярамый.

— Нәрсә? — дип урыныннан сикереп торды Николай.

— Син нәрсә? Әллә акылдан яздыңмы! — Дмитрий мендәрне почмагыннан эләктереп абыйсының баш астыннан сөйрәп чыгарды.— Әйт хәзер үк!

Вася капылт кына Дмитрийны этеп җибәрде, торып утырды.

— Анда Саша...— диде ул иренен чак кына кыймылдатып.— Саша Лобачевский суга батты. Панкратов ике мәртәбә чумып эзләде. Тик үзе дә чак кына төпкә китмичә калды...

Николайны яшен суккандай булды. Ул бераз һушын җыя алмый торды, аннары:

— Саша! — дип ачыргаланып кычкырып җибәрде һәм атылып урамга чыкты.

Ул Казанка ярына ничек килеп җиткәнен дә сизмәде. Тик ерактан ук яр буена җыелган халыкны күреп алды. Кайсы багор, кайсы бау тоткан юеш киемле кешеләр аңа юл бирделәр. Саша җирдә чалкан ята, кемдер өеннән алып килеп аның өстенә ак җәймә япкан...

Кайгылы хәбәрне анага әйтерлек кешене озак эзләделәр. Ләкин Николай өйгә җиткәндә, башкаларны туктатты.

— Кирәкмәс, үзем әйтәм,— диде ул тонык тавыш белән.

Прасковья Александровна китәргә тәмам әзерләнеп җиткән иде. Менә аның янына бүлмәгә Николай

килеп керде, артына борылып, ашыкмыйча гына ишекне япты...

Ишек төбендә калган иптәшләре кыймылдарга һәм сулу алырга да куркып тордылар. Бүлмәдән, ананың бер кычкырып куйганы ишетелде дә, тынлык урнашты. Елаган тавышы да, өзгәләнгәне дә ишетелмәде. Монысы һәркемнең күңелен шомландырды.

Ниһаять, ишек ачылды. Бусагада әнисен җитәкләгән Николай күренде. Икесенең дә күзләре кызарынган, әмма алар инде елаудан туктаганнар иде.

Прасковья Александровна акрын гына тавыш белән:

— Улым янына алып барыгыз мине,— дия алды.

Янә бер тәүлек үткәч, Сашаны җирләгәч, төнлә белән, Николай һәм Алексей әнкәләрен Макарьевка алып киттеләр.

Николай Лобачевскийның университеттагы беренче елы шулай зур кайгы белән тәмамланды.

## 7

Университеттагы тантаналы җыелыш император галиҗәнаблары Александр Павловичның туган көненә, ягъни 1807 елның 30 августына билгеләнгән иде. Яковкин бу бәйрәмгә купшы төс бирү өчен бөтен көчен җигеп тырышты. Моңа аны патша хәзрәтләренең юбилее Европадагы авыр хәрби-политик хәлнең йомшарган чагына туры килү генә түгел, университетта барган кискен көрәштә үзенә каршы булган кешеләрне «йөзтүбән» әйләндереп салуын бөтен шәһәргә күрсәтәсе килү теләге дә этәрде.

Тантана алдыннан, 30 августка каршы төнне, зур залда гомуми гыйбадәт булды. Гимназия бинасы «Күп санлы кәндилләр һәм шәмнәр белән яктыртылган иде». Бәйрәм көнне исә барлык хезмәткәрләр һәм укучылар Воскресенский чиркәвендә литургия, аннан соң — гимназиянең зур залында «тезләнеп рәхмәт вә шөкер догасы кылдылар».

Университет бәйрәме көндезге сәгать өчтә башланырга тиеш иде. Өр-яңа аксыл-көрән сюртук һәм шакмаклы панталон киеп куйган Яковкин билгеләнгән вакыттан күп алда килде. Аның кыланышларына, килеш-килбәтенә, горур кыяфәтенә карaганда, булачак тантана император галәҗәнабларына түгел, бәлки аның хөрмәтенә оештырылган дип уйларга мөмкин

иде. Менә инде сәгатьтән артык ул балерина елгырлыгы белән хөрмәтле кунаклар тирәсендә бөтерелә һәм бертуктаусыз елмая, тирә-юньдәгеләргә шат күңелле булып күренергә тырыша, хәлбуки, эчендә мәчеләр мыраулый иде. Чөнки ни сәбәптәндер шәһәрнең күренекле дин әһелләре һәм губернатор белән вицегубернатор соңга калдылар. Директор әледән-әле тәрәзәгә барып карый, әмма тегеләр күренми дә күренми. «Башларгамы икән соң, әллә тагын бераз көтәргәме?» — дип баш вата иде ул, җыелган халыкның сизелерлек дәрәҗәдә борчылуын күреп.

Соңгы рәттә утырган Николай Лобачевский, Яковкинның кыланышларына нәфрәтләнеп карый-карый, уйланды да уйланды: «Әгәр дә шушы бәндә директор булмаса, Григорий Ивановичны да урыныннан чыгармаслар иде, мин дә адәм рәтле укыган булыр идем, әнием килмәс һәм ел йомгаклары тантанасына кадәр без Казаннан китү турында уйлап та карамас идек, Саша да китәр алдыннан су коенмас һәм, әлбәттә, батып үлмәс иде...» Аның фикеренчә, төп гаеп Яковкинда, фәкать анда гына иде. Николай аны бөтен җаны-тәне, бөтен барлыгы белән күралмас булды.

Башында кайнаган уйлар егетнең күңелен шул кадәрле ярсытты ки, хәтта ул бер урында гына утыра алмады, залдан чыкты да, урамда йөреп керергә ниятләп, түбән төшә башлады. Тик вестибюльдә аны кемдер арттан әләктереп алды һәм усал тавыш белән:

— Син кая барасың, Лобачевский?! — дип сорады.

Бу Яковкинның яраткан шәкерте, моннан ике ай әлек кенә субинспектор, ягъни инспектор ярдәмчесе итеп билгеләнгән кандидат Петр Кондырев иде. Аның шыксыз ябык гәүдәсе, озын, төссез, ләкин шомартып таралган чәче һәрчак Лобачевскийның көләсен китерә иде.

Петр көнозын класс бүлмәләрендә, йокы камераларында актарынып-эзләнеп вә иснәнеп йөрер, һәрвакыт нинди дә булса ярамаган нәрсә күрер, һәммәсен исендә калдырыр. Кемне дә булса эзәрлекләргә аңа куп инде — кирәксә, фәрештәнең дә гөнаһын табар. Бәйләнчек, вакчыл Кондыревны студентларның берсе дә яратмый. Һәм менә бүген дә каршында калай әтәчтәй күперенеп торган Кондыревны күргәч, Лобачевский тыныч кына җавап бирә алмады.

— Ә минем кая баруымда синең ни эшең бар! — диде ул юри төрттереп.

— Ә миңа директор укучыларның берсен дә моннан чыгармаска күрсәтмә бирде. Менә-менә Казан архиепископы үзенең яраннары белән килеп җитәргә тиеш... Рәхим итеп, залга керегез, Лобачевский!

Николай үзалдына елмаеп куйды. «Менә ни өчен күзен тәрәзәдән алмаган икән Яковкин», дип уйлады ул эченнән генә. Ә Кондыревка болай диде:

— Миңа димәгәе, ник анда Христос үзе төшми күктән! Минем башым авырта, һавага чыгам.

— Бу башбаштаклык, Лобачевский! Мин бу хәлне директорга җиткерергә тиешмен!

— Бар әйдә, бар, йөгер! — диде Николай һәм урамга чыгып китте.

Көн күңелсез, болытлы иде. Салкын һәм дымлы һавадан инде көз сулышы сизелә. Ләкин тузгылган соры болыт тәрәзәсеннән кояш күренү белән, Николайның күңеле күтәрелеп китте. Һәм ул җитез адымнар белән Черек күлгә таба юнәлде.

Көндезге аш вакыты булганлыктан, Воскресенскаяда халык аз иде. Шулай да Николай бу урамнан тирәягына карамыйча эре генә, кара ефәк тасмага тагылган шпагасын сул кулы белән тотып, тигез вә нык адымнар белән узды.

Воскресенский чиркәвен узуга, аның күз алдында һич тә көтелмәгән бер хәл булды. Уң як тыкрыктагы тәбәнәк өйнең капкасыннан күзен кан баскан зур сыер ярсып килеп чыкты да агач тротуар буенча кушаяклап Кремльгә таба сикерде. Ниндидер хатын-кыз чәрелдәп җибәрде һәм шунда Николай тротуарда бер кайгысыз уйнап утырган сабый балаларны күреп алды. Ул сыерны ничек куып җиткәнен, бер сикерүдә аның йомры сыртына менеп атланганын үзе дә сизми калды. Хәзер инде, котырып чапкан хайванның озын кәкре мөгезеннән эләктереп, аны тротуардан читкә борырга кирәк иде. Монысын да егетләрчә башкарды Николай. Сабыйлар янына килеп җитәргә 3—4 адым кала, сыер, муены авыртуга чыдый алмыйча, таш юлга кыеклап чыкты һәм чак кына абынып егылмыйча калды. Николайның өчпочмаклы студент эшләпәсе башыннан очып төште дә урам буенча тәгәрәде.

Бу куркыныч манзараны кешеләр тын да алмыйча күзәтеп тордылар һәм, андый-мондый хәл булмагач, җиңел сулап куйдылар; сыер сыртыннан сикереп төшүенә, Николайны уратып алдылар. Ул да түгел, үлемнән котылган балаларның әти-әниләре, туган-ту-

мачалары килеп җитте. Алар тирә-яктагы шау-шудан бөтенләй югалып калган Николайны кочарга, үбәргә тотындылар. Урамнан узып барган отставкадагы полковник йолып алмаган булса, тагын нишләтерләр иде алар Николайны, шайтан белсен.

— Әфәнделәр, нишләп торасыз, әйдәгез, кыю студентны минем фаэтонда университетка озатып куйыйк. Аның батырлыгы иптәшләренә дә мәгълүм булсын!.. Янына менә бу үлемнән котылып калган сабыйларны да утыртыйк!..— дип, ул үз тәкъдимен тормышка ашырырга керешге.

Халык төркеме, шуны гына көтеп торгандай, университетка таба кузгалды. Бу вакытта, кунакларны каршы алырга дип, болдырга чыккан Кондырев университетка якынлашып килгән кареталарны һәм күп санлы кешеләрне күргәч: «Архиепископ үзедер, мөгаен, бала-чагалар да көтүе белән. Изге атакай аларга карета тәрәзәсеннән бакыр акча сибеп барадыр», дип уйлады һәм уңны-сулны карамыйча, Яковкин янына йөгереп керде дә, авыр имән ишекне шар ачык калдырып, килгән кунакларга тамчы да әһәмият бирмичә, сөрән салды:

— Директор әфәнде! Архиепископ!

Яковкин, студентлар оркестры башлыгы дирижер-композитор Новиковка башы белән ишарә ясап, баскычтан түбән төшеп китте.

Директор-профессор чыгып җиткәндә, халык төркеме университет алдында иде инде. Яковкин, төркемне аралап, карета янына уза башлады һәм кинәт, югалып калып, артка тайпылды. Чөнки ул иң алдагы фаэтонда ниндидер сабыйларны кочаклап утырган Николай Лобачевскийны күреп алды...

Өстә, җыелыш залында, тантаналы көйгә университет оркестры уйнап җибәрде. Көтә-көтә көтек булып беткән кунаклар (ә алар артыннан студентлар да), әдәп-йола кагыйдәләрен онытып, тәрәзәләргә ташландылар. Һәм бөтен бинаны диярлек гомум көлү авазлары дер селкетте. Университет һәм гимназия язмышын хәл итәргә кодрәтләнгән Яковкинның шундый сәер тамашага тап булуыннан көләләр иде яшьләр.

Ләкин императорның туган көненә көлү шаукымына бирелгән яшьләр өчен, ә бигрәк тә көн герое — кыю студент өчен бу мәзәк вакыйга ифрат та аяныч тәмамланырга мөмкин иде. Эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алган полковник бер каретаның кузласына сике-

реп менде дә булып узган хәл турында сөйләргә кирәште.

— Әфәнделәр! — диде ул икенче каттагы тәрәзәгә сарышкан абруйлы кунакларга һәм студентларга мөрәҗәгать итеп.— Биредә ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыкты булса кирәк. Шушы батыр егет, сезнең студентыгыз һәм иптәшегез, моннан 15 минут кына элегрәк, үзенең тормышын куркыныч астына куеп, менә шушы өч сабый баланы үлемнән коткарып калды. Әгәр дә ул ярсыган хайванны, сыртына сикереп менеп вә мөгезен каерып туктатмаган булса, теге сабыйлар һичшиксез һәлак булачак иде. Менә шуңа күрә дә публика аны, бөтен студентлар каршында рәхмәт белдерер өчен, бирегә алып килде...

Отставкадагы полковникның соңгы сүзләрен алкышлау күмеп китте. Студентлар, кул чаба-чаба, урамга атылып чыктылар. Әле тегендә, әле монда соклану авазлары яңгырады. Кемдер бар хәлгә кычкырып җибәрде:

— Күккә чөяргә, күккә!

Николай шул секундта ук һавага очты. Очты да, аяк-кулын бутый-бутый, яңадан уннарча йомшак кулларга килеп төште. Аны тагын... тагын чөйделәр... Аннары инде җыелыш залына күтәреп кереп киттеләр...

...Икенче көнне төшке аштан соң Николайны директор кабинетына чакырттылар. Яковкин аңа кичәге хәл өчен каты кисәтү ясады.

— Юк, мин сине мактарга җыенмыйм,— дип дәвам итте ул тавышын күтәрә төшеп.— Студентны сыерга атланып йөрү һич тә бизәми. Сыерга атланып йөрү өчен әллә ни зур акыл кирәкми.

— Болай әйтер өчен дә әллә ни зур җорлык һәм зирәклек кирәкми,— диде Лобачевский Яковкинга охшатыбрак.

— Нәрсә! Ах сине, малай актыгы! — дип, аяк тибеп акырды Яковкин. Аның кулы калтырый, ирене һәм яңаклары дерелди иде.— Бар, чыгып кит хәзер үк! Моның өчен сине инспекторның шнурлы кенәгәсенә теркәрләр...

Николай эшләпәсен эләктерде дә ишеккә юнәлде.

Гимназия бинасының ишегалды ягына караган болдырында күзен кысып, кояшка сыртын куеп соры мәче ята иде. Яковкиннар квартирасында кемнеңдер клавесинда уйнаганы ишетелде.

Николайның күңелен кинәт кенә җәбер хисе биләп алды. Аның хәтта тыны кысылды, үкереп елыйсы килде.

«Булды, җитте, мондый тамашаларга чик куярга вакыт,— дип үзалдына сөйләнде ул болдырдан төшешли.— Директор-профессор булдым дигәч тә разночинец студенттан ничек теләсә шулай көләргә, аны мәсхәрә итәргә димәгән лә. Ни өчен бит әле?.. Нинди начарлык эшләдем мин аңа? Моның өчен акыл кирәкми, имеш... Ничек оялмый ул? Әле мине дорфалыкта гаепләп маташа бит. Ә үзе...»

## *Алтынчы бүлек*

### 1

Корташевскийның университеттан куылуы, Александрның фаҗигале үлеме, ниһаять, сыер белән булган «тамаша» — болар барысы да Николайның җан тынычлыгын алды. Ниндидер коточкыч саташулар белән тулы йокысыз төннәр инде менә ике ай буе тынгы бирми иде аңа. Киләчәктә болай яшәп булмаячагын аңлый, тик нишләргә кирәклеген генә белми иде әле Николай.

Ул инде икенче курста укый һәм Казанга килгән чактагыдан бик нык үзгәргән иде. Кайчандыр тулы, түгәрәк йөзле, йомшак күңелле, ачык, шат малай иде ул. Ә хәзер ничектер тупасланды, килбәтсезләнде. Йөзенә кырыслык галәмәтләре чыкты, буйга үссә дә, күңеле зәгыйфьләнеп, кечерәеп калды кебек. Яшь йөрәген тетрәндереп узган коточкыч зур кайгы да, җан җәрәхәтләре дә чагыла иде аның йөзендә.

— Син нәрсә? Авырмыйсыңдыр ич? — дип сорыйлар иде бу көннәрдә аннан иптәшләре.— Йөзең качкан, күзең нурсызланган.

— Нишләп нурсызлансын? — дип кашын җыера Николай.— Хәлем әйбәт. Йокым туймады. Кичә озаграк утырганмын.

«Күз алдында шәм кебек эри» дип, яшь аралаш уйлый Алексей абыйсы турында.

Әбиләр чуагы җиткән иде. Аяз җылы көннәрнең берсендә дәресләрдән соң, Алексей Николайга шәһәр читенә чыгып саф һава сулап кайтырга тәкъдим ясады. Николай риза булды.

Алар Казанка буенда йөрделәр. Арча кырыннан иске койма белән аерылган ташландык Болхов паркына барып чыктылар. Андагы тирән чокырлар, ул чокырларда куе булып үскән төрле матур агачлар һәм куаклар, бормаланып аккан елга, аның еракка җәелгән ягының сөзәк яры — болар һәммәсе дә туганүскән Нижнийларын, чокырлы-чакырлы Почайна буйларын хәтерләтте.

Николайның йөзе яктырып киткән һәм күзе очкынланган сыман булды.

— Синең исеңдәме икән, Алеша, мин бервакытны шигырь язган идем,— дип эндәште ул энесенә.— Карт имән белән елга турында иде ул шигырь. Көлмә әле син. Хәзер мин аны хәтергә төшерәм...

Алар шулай, дөнья мәшәкатен читкә куеп, шактый озак йөрделәр. Яшел чирәм өстендә, көзге чәчәк арасында күбәләк куып кәефләнделәр, көймәдә йөзеп күңел ачтылар. Бүгенге көндә үз-үзләреннән һәм бөтен дөньядан канәгать булулары аларның йөзләрендә чагыла иде.

Кайтканда да ашыкмыйча гына кайттылар. Гимназия күршесендәге Тенишев йортына җиткәч, Алексей туктап калды. Ул йортның аскы катында химия класслары урнашкан, Алексей дәрестә әнә шунда булган иде. Хәзер дә кереп чыгарга уйладылар. Кабинет ишеген ачу белән, әчкелтем ис борыннарына килеп бәрелде. Йөткерергә тотындылар.

— Нәрсә соң бу? — дип сорады Николай, аптырап.

— Тәҗрибә бу, тәҗрибә, егетләр,— дип, шкаф артыннан күңелле тавышлы берәү җавап кайтарды.

Николай пышылдап кына:

— Эвестмы ул анда? — диде.

— Юк, безнең лаборант-механик Горденин, Никита Филиппович, алтын куллы кеше дә инде! — диде Алексей, сокланып, һәм ачык ишектән бүлмә эченә кулы белән күрсәтте: — Әнә күрәсеңме, нинди зур мич? Ул

мичтә өч утлык, бер казан бар. Шул мичкә һава өрдерү өчен күрекне механик үзе эшләде. Комиссия тикшерде. Фукс та, Эвест та, Запольский да бик мактадылар. Өстәвенә пыяла эшен дә яхшы белә. Химия кабинеты өчен әнә күпме пробирка, колбалар әзерләде. Биредә һәммә нәрсә аның кулы белән эшләнгән.

Алексей үзе сөйләгәнне абыйсының кызыксынып тыңлавын күреп сөенде. Ике туганның күптән болай иркенләп сөйләшә алганнары юк иде.

— Кышын Никита Филиппович бер ай буена Юшковның пыяла заводында булды... Менә кара, мин шунда утырам инде,— диде ул, төрле сыекчалар салынган банкалар тезелгән өстәл янына алып килеп.— Күрергә телисеңме минем нәрсә эшләгәнне?

— Минем өчен кызык булмас бит ул,— диде Николай, кыяр-кыймас кына. Ул инде кабат үзенең элеккеге рухи дөньясына бикләнеп өлгерде.

— Их син, шул математикаңнан башканы белергә дә теләмисең! — диде Алексей үпкәләп.— Ә Ломоносов барысына да вакыт тапкан. Математик та ул, философ та... Кара менә моны! — дип, киштәдән бер китапны алып күрсәтте.— «Химиянең файдасы турында». Кызыксынган бит... Вакыт тапкан бит...

Ломоносов дигәнне ишеткәч, Николай җанланып киткән төсле булды һәм китапка кулын сузды.

— Алмый гына тор әле! — диде Алексей һәм китапны киштәгә кире куйды.— Син башта минемниләр эшләгәнне күр. Мәсәлән, менә бу ике колбада кызыл һәм сары төстәге эремәләр. Ләкин алар берберсенә катнашмыйлар. Эрегән матдәне бер эремәдән икенчесенә ничек күчерер идең? — дип кинәт кенә абыйсына текәлде.

— Беренче эремәне парга әйләндерер идем,— диде Николай, озак уйлап тормыйча.

— Эремәне парга әйләндергән чакта эрегән матдәң дә очып бетсә? — дип, Алексей тагын сорау бирде.— Шул шул менә! Химияне дә алай ансат кына җиңеп булмый әле!

Алексей, артка борылып, шкафтан кара кәгазьгә уралган колбаны алды. Аңа төссез сыекча салынган.

— Сероуглерод булыр бу. Бик көчле эреткеч. Су белән катнашмый. Кара менә!

Ул, сөйли-сөйли, кызыл төстәге эремә салынган колбага шул төссез сыекчаны чак кына агызды, ан-

нары пыяла таяк белән болгатты. Оста фокус күрсәтүче кебек баш иеп, колбаны абыйсына сузды.

— Айн, цвай, драй! Хәзер кара инде!

Николай кулындагы колбаны, кызыксынып, яктыга тотты.

Сероуглерод судан өскә менгән. Тик инде аның төсе үзгәргән, кып-кызыл булган, ә су тонықланып калган.

— Күрдеңме?! — диде Алексей, җиңүче кыяфәте белән.— Су эремәсендәге матдәне сероуглерод үзенә алды. Кызык бит, ә! Судан да аерылды, теге матдәне дә үзенә ияртеп чыкты...

Кинәт, абыйсына гаҗәпләнеп караган хәлдә, тынып калды. Николай, колбаны күз турысында тоткан килеш, үзалдына мыгырдана иде:

— Ике катлау, диген... Әһә!.. Араларында уртак чик — су һәм сероуглеродны бер-берсеннән аерып торган өслек... Димәк, өслекне билгеләү өчен ике әйбернең бер-берсенә тиеп торуына игътибар итәбез. Сероуглерод әле тагын һавадан да өслек белән аерылып тора.

Николай тәрәзәгә якынрак барып, колбаны бер ерак тотып, бер якын китереп карады. Аның нәрсә эшләвен Алексей дәшмичә генә күзәтеп торды.

— Әгәр шулай икән...— дип сөйләнә бирде Николай, бөтен дөньясын онытып,— әгәр шулай икән, тигез күләм билгәгән һәм пространствога бер үк төсле тиеп торган әйберләр геометрик яктан тигез булалар. Әйе, әйе, табигатьтәге барча нәрсә өчен дә бер-берсенә тиеп тору хас, һәм ул аларның уртак геометрик үзенчәлеген тәшкил итә дә. Димәк, сызык һәм өслек турындагы тәгълиматны шуннан башларга кирәк.

Николай бик зур саклык белән колбаны өстәлгә утыртты. Аның күзендә шатлык балкый, маңгай җыерчыклары язылган иде. Күптәннән эзләгәнен бүген, ниһаять, тапты шикелле. Нокта, сызык һәм өслек турындагы төшенчәләрне хәзер инде ул үзе чыгара ала.

Абыйсының кыяфәте шулкадәр тиз алмашынганны шаккатып күзәткән Алексей дәшми генә басып торуын дәвам итте.

— Таптым бит, Алеша! — дип күтәренке тавыш белән әйтеп куйды Николай.— Синең химияң ярдәмендә таптым. Менә бит ул тәҗрибәнең роле. Тәҗрибә һәм фикер йөртү. Ике баскычны бергә китереп каплау. Дөрес әйткән Ибраһимов!

Ул аптырап басып торган энесен кинәт кочаклап алды һәм бүлмә буйлап әйләндерә башлады. Өстәлдәге банкаларны чак кына идәнгә бәреп төшермәде.

Шул ук кичне, иптәшләре төрлесе төрле якка таралышкач та, ул Григорий Ивановичка хат язарга утырды. Озак язмый торуы өчен гафу үтенеп, укытучысына үзенең серен ачты:

«...Тәүге нигездән, ягъни җисемнәрнең бер-берсенә орынуыннан чыгып, геометриянең башлангыч төшенчәләрен аңлатып була кебек.

*Җисем икенче бер җисемгә орынып торса һәм шул үзара орыну гына исәпкә алынса, ул җисемне ө с л е к дип атыйбыз. Һәр икесенең бер-берсенә орынып тормаган өлешләрен күздән төшерәбез.*

*Җисем икенче җисемгә кыл юанлыгында гына орынып торса, андый җисемгә с ы з ы к дибез. Бу очракта да бер-берсенә орынмаган өлешләрен читкә ташлыйбыз һәм кыл нечкәлегенә, каләм белән кәгазьгә ясалган сызык нечкәлегенә ирешәбез.*

*Һәм соңгысы. Җисем икенче җисемгә бер төрткедә генә орынса, аның орынмаган өлешләрен читкә ташласак, андый җисемгә н о к т а дибез. Бу юлы без ком бөртеге яки каләмнең кәгазьгә тиеп торган очы кадәр кечкенә җисем белән эш итәбез.*

*Шулай итеп, өслектә сызыкта һәм ноктада без игътибар үзәгенә җисемнәрнең фәкать бер-берсенә орынып торган өлешләрен генә алабыз...»*

Хатны язып бетергәч, Николайның өстеннән тау төшкән төсле булды.

Ишегалдына чыгып, бераз саф һава сулап керергә теләгән иде, кинәт хәтеренә килде:

— Ә Ломоносов? «Химиянең файдасы»...

Аның сандыгында Ломоносовның тулы сайланма әсәрләре саклана, тик галимнең химия турындагы хезмәте, ничектер кызыксыз тоелып, бүгенге көнгә кадәр укылмый ята иде. Көтмәгәндә, химиядән үткәрелгән тәҗрибә аркасында, геометриянең тәүге төшенчәләрен ачыклауга ирешкәч, Николай аны хәзер үк укырга булды. Моңа кадәр ничек игътибар бирмәде икән? Бу хезмәттә бит фәннең төрле өлкәләре — аерым алганда химиянең табигать тарихы һәм математика белән нык бәйләнгән булуы оста итеп күрсәтелгән. Химия турындагы китаптан математикага караган мәгълүмат алырмын дип кем уйлаган!

«Ни өчен табигый әйберләрне өйрәнүчеләр ошбу өлкәдә зур уңышка ирешә алмыйлар?» — дип сорый Ломоносов һәм үзе үк шуны аңлатып бирә: моның өчен галим бер үк вакытта химик та, математик та булырга тиеш. Химиктан зур теоретик белем, практик эш таләп ителә. Математик исә: «Уйлап табу һәм исбатлауда төгәллеккә күнегеп, табигатьнең иң тирән серләрен дә ача белергә тиеш»,— ди. Химияне бөек галим фәннең куллары дип, ә математиканы фәннең күзләре дип атый.

Бу хезмәттән Лобачевский үзенә кирәкнең һәммәсен дәфтәренә теркәде. Ахырда, нәтиҗә ясап, чын-чыннан математик булыйм дисәң — башка фәннәрне, аеруча тәҗрибәгә нигезләнгән фәннәрне: химияне һәм физиканы тырышып үзләштер, дип язып куйды.

Иртән беренче лекция математика, ә аны әле һаман студент Граф укый иде. Лобачевский, анда кермичә, химия белән materia medica * фәннәрен алып баручы адъюнкт Эвест янына, химия кабинетына юнәлде.

Ул Эвестның алгы бүлмәдә ниндидер металл кисәген утта кыздырып торган чагына туры килде. Аңар әле кырык та тулмаган, әмма үзенең тузгыган чәче һәм шапшак кыяфәте белән ул картрак күренә иде.

Николайның олылап сәламләвенә каршы ул, баш кагып кына, артсыз урындыкка ымлады һәм башлаган эшен дәвам итте. Эшен төгәлләгәч кенә егеткә сүз кушты. Николайның химия әлифбасын үзләштерергә теләге барлыгын белгәч, җанлана төште һәм эчке бүлмәгә — төп лабораториягә ияртеп алып керде.

Николай андагы әйберләрнең тәртипсез рәвештә аунап ятуларына һәм пычраклыкка таң калды, күңеле болганып киткән сыман булды.

Химик исә үз карамагына яңа студент килгәнгә шатланды, күрәсең.

— Химияне өйрәнгәнегез бар идеме? — дип шунда ук сорашырга тотынды.— Бөтенләй туры килмәдеме? Кайгырмагыз. Куып җитәрсез. Дару препаратлары эзләү белән шөгыльләнербез. Materia medica дип аталган махсус фән турында мәгълүматыгыз бармы? Минем лекцияләремә йөрергә Яковкиннан рөхсәт алыгыз.

---

* Materia medica — фармакология.

— Мин бит химия белән кызыксынсам да, табиб буласым килми,— дип куйды Николай, оялып кына.

— Анысы һич тә мәҗбүри түгел,— диде Эвест, өстәл өстендәге ниндидер пычрак приборларны рәткә китереп.— Безнең фән дару матдәләренең организмга ничек тәэсир итүен өйрәнә. Materia medica буенча сез минем беренче шәкертем булырсыз. Ни сәбәпледер һәммәсе химиягә язылa. Ә мин үзем хәтта materia medica фәнендә дә, дару өчен кирәкле матдәләр белән беррәттән, гадәттәге химик элементларга зур игътибар бирәм. Ләкин сез...

Эвест кинәт сөйләүдән туктады һәм Николайга, шаяртып, банка тоткан кулы белән янап алды.

— Ләкин сез бу турыда Яковкинга әйтә күрмәгез. Килештекме?

— Килештек! — диде Николай, елмаеп.

Эвестның исә елмаюдан йөзе бөтенләй җәелеп китте. Сүзен дәвам итәргә дип авызын гына ачкан иде, нәкъ шул вакытта күрше өстәлдә нәрсәдер чыжлап кайный башлады. Химик шул якка ташланды. Анда бер колбадан бу бөркелә, бүлмәгә сасы ис тарала иде. Николай бик канәгать булып чыгып китте.

Икенче көнне ул Эвестның лекцияләренә йөри башлады, ә кичләрен лабораториядә үткәрә торган булды. Яңадан-яңа ачышлар вәгъдә иткән фәнгә ул көннән-көн ныграк якынайды. Эвест, аның янына кереп-чыгып йөрсә дә, кайбер күрсәтмәләр бирү белән генә чикләнде. Укытучының мөстәкыйльлек тудыруы Николайга бик ошады. Һәм ул, башы-аягы белән тәҗрибәләргә чумды, «химик» дигән кушамат та алып өлгерде.

1808 елны ул янә шулай яңа мавыгу белән каршылады...

Яковкинның өстәл өстендә калын папка ята. «Студентларның шөгыльләре һәм өлгерешләре ведомосте». Профессор-директор бик төпченеп шуны актарып утыра. Кинәт аның тар маңгаендагы җыерчыклар язылды һәм нечкә иреннендә мыскыллы елмаю чагылды.

— Афәрин!.. Бик күркәм! — дип үзалдына ашыкмыйча гына сөйләнеп алды һәм очлап куелган бер өем каурый каләмнәргә сузылды.

Профессор-директорның шатлыгы күкрәгенә сыймый: математика лекцияләренә йөрергә язылган

студентлар исемлегендә ул Николай Лобачевскийны тапмады.

— Менә сиңа «математик»! Нәрсә эшләгән бит... Materia medica тирәсенә елышкан! Эвест үзенең берләнбер тыңлаучысын мактап бетерә алмый.

Яковкин ведомостьларны бик җентекләп тикшерүен дәвам итте.

— Минем киңәшне тотып, анасы медицинага аударган булса кирәк. Бар иде «математик» — юк инде «математик». Хәзер попечитель дә кызыксынмаячак. Безгә шул гына кирәк тә!

Директор кулындагы каурый каләм кәгазь өстеннән биеп кенә йөри. Шундый күңелле хәбәрне ничек итеп хөрмәтле попечитель хәзрәтләренә язмый түзәрсең? Хатны Яковкин бик зур осталык белән язды: әүвәл, төче телләнеп галиҗәнабның гаиләсен Яңа ел белән тәбрикләде, Казанны күреп китәргә чакырды... Хатның азагында, ялгыш ычкындырган кебек кенә, мондый сүзләрне тезеп китте: «Студент Николай Лобачевский үзен зур тырышлык белән медицина факультетына хәзерли» *. Аннары кабаттан кайтып тәбрик итте һәм изге теләкләр теләде.

— Борычлы булды бу хат! — дип кеткелдәде Яковкин һәм, сургучны мул тамызып, университет печатен шапылдатып сугып куйды.

Ләкин бу «борыч» Яковкин бөтенләй көтмәгән нәтиҗәләр китереп чыгарды.

## 2

...Санкт-Петербург.

Гранитка төренгән яр буйларына тезелеп киткән мәһабәт йортларга тия язып, Нева елгасы өстеннән кара-кучкыл болытлар йөзә.

Көннәр бозылырга торганын Степан Яковлевич Румовский алдан ук сизенә. Ничә әйтсәң дә, карт сөяк шул: төннәр буе сызланып чыга. Көндезге мәшәкатьләр генә бераз онытырга мәҗбүр итә.

* Бу хат Казан уку-укыту округы архивында сакланган һәм безнең заманда Н. И. Лобачевский турында язучыларның күпчелеген ялгыш юлга этәргән. Шуңа күрә алар студент Лобачевскийны медицина белән математиканың кайсына ябышырга белмәүче итеп сурәтлиләр. Ә бит университетта медицина буенча лекцияләрне профессор Браун һәм Фукс укыган, Лобачевский аларның лекцияләренә йөрмәгән. Materia medica фәненең нәрсә икәне укучыга мәгълүм булса кирәк.

Бу юлы юеш кар кичтән үк яварга тотынды. Озакка сузылыр ахры. Тагын йокы күрмим икән дип уйланып, Степан Яковлевич кабинетына юнәлде. Бүген килгән газета һәм журналларны өстән-өстән генә караштыргалап, хатларга күчте. Беренче чиратта ул Казаннан килгән хатны укырга кереште.

Казандагы хәлләр аңа бертөрле табышмак сыман тоела, былтыр университетта булып үткән күңелсез вакыйгаларның төп сәбәпләре һаман ачыкланып җитмәгән иде әле. Профессор Каменский һәм адъюнкт Корташевскийның бик борчылып сөйләүләренә карамастан, шулай ук губернатор Мансуров язган әләкләү хатына һәм башкаларның зарлануына карамастан, Румовский Казан университетында эшнең шундый ук аянычлы булуына ышанып җитмәде, профессор-директордан көнләшеп сөйлиләр, дип уйлады.

Ә менә Яковкинның үз хаты. Картлач аны акыллы язылган хат, эчкерсез хат дип кабул итте. Укыган саен профессор-директорга карата күңелендә туган шикләнү, җылы суга ташланган боз кисәге кебек, эреп бетте. Тукта, монысы нәрсә булды соң әле? «...Лобачевский үзен зур тырышлык белән медицина факультетына хәзерли».

Попечительнең чал кашы җыерылып өскә сикерде. Ул күзлеген рәтләде һәм бу могҗизалы сүзләрне кабаттан укып чыкты. Аннары хатны читкә куеп, терсәген өстәлгә чәнчеп, уйга калды.

Лобачевский... Карт попечитель бер өем китап белән утыручы малайны хәтеренә төшерде. Математика һәм философия китаплары иде бит анда. Иптәшләре ишегалдында шаулашып уйнап йөргәндә, бу малай башын да күтәрми укып утыра иде...

Аннары, студент булгач, геометриянең нигезләрен эзләү һәм өйрәнү белән мавыгып киткән иде шикелле. Һәрхәлдә, адъюнкт Корташевский бик мактаган иде...

Попечитель үзенең хәтер түреннән Яковкин белән сөйләшкәндәге сүзләрне тартып чыгарды. «Директор әфәнде, сез бу укучыны, Лобачевскийны, яхшы беләсезме?» — дип сорады. Яковкин аңа: «Белмичә ни, тискәре гимназист»,— дип, кабаланып җавап кайтарган иде. Профессор-директор өчен, димәк, ул малайның математикага, философиягә, чит телләр өйрәнүгә булган сәләте игътибарга да лаек түгел. Сабый чактагы шаяруларын күтәрә алмаган. Шундый кеше яшь буынны тәрбияләргә лаекмы? Алардагы талантны күреп алыр-

га һәм үстереп җибәрергә сәләтлеме? Хакыйкать менә шулай соңга калып ачыклана башлады.

Әгәр Лобачевский математикадан алай читкә тайпылган икән, димәк, моңа ниндидер сәбәп булырга тиеш. Башкача һич мөмкин түгел. Яшьлегендә Румовский үзе дә ялгыш адым ясый язган кеше.

Атмосферадагы электр тогы белән тәҗрибә ясаганда, аның яраткан профессоры Рихманны яшен сукты. Сөекле укытучысы үлгәч, студент Румовский бик нык кайгыга калды, иптәшләреннән читләште, Академиягә йөрми башлады. )Математикага һәм астрономиягә булган мәхәббәте сүрелгән төсле тоелды. Фәкать Ломоносовның химиядән укыган лекцияләренә генә йөрде. Бөек фән иясе шәкертенең тирән кичерешен аңлады һәм шунда ук егетне математикадан белем алу өчен атаклы математик һәм механик Леонард Эйлер янына Берлинга җибәрде. Яшь буынны аталарча тәрбия кылучы Михаил Васильевич аның математикадан бөтенләй китмәвен һәм китәргә тиеш түгеллеген аңлады, шуңа күрә аны бу фән өчен саклап калды.

Ә менә хәзер ул үзе, Фәннәр Академиясенең вице-президенты, Лобачевскийны геометриядән читләшергә мәҗбүр иткән сәбәпләрне ачыклый алдымы соң? Яковкинга ул теге чакта:

— Бу егетнең язмышы өчен сез фән каршында җаваплы,— дигән иде. Ә ул үзе җаваплы түгелмени?

Румовскийның күзе ирексездән Ломоносов портретына текәлде һәм... укытучысының күзләрендә кырыслык күргәндәй булды.

— Иртәгә үк Казанга китәм. Яковкин бар нәрсәне болгатып ташламадымы икән, үзем тикшерәм!

Шул сүзләрне әйтә-әйтә, Румовский креслодан сикереп тә торды... ыңгырашып кире килеп тә төште.

Степан Яковлевич берничә көн урыныннан кузгала алмыйча ятты. Аягының авыртуына, чыдый алмаслык булып, вөҗдан газабы өстәлде. Яковкинга шул чаклы ышаныч баглавына үкенде. Профессор Каменский белән адъюнкт Корташевскийның сүзләренә юкка гына колак салмаган ул, һәм аларны Казаннан куып бик начар эшләгән. Менә хәзер шуның нәтиҗәсен күрә. Математика өлкәсендә, һичшиксез, зур сәләткә ия булган Лобачевский читкә тайпылган...

Бу хатаны төзәтү юлларын табарга кирәк. Иң әүвәл Яковкинның эшен контрольгә алырга кирәк булыр. Якын айларда үзенең Казанга чыгып китә алмавы

эшне катлауландыра. Хәер, министрдан ревизор җибәртергә мөмкин ич. Университетны гимназиядән аерып, 1804 нче елгы уставта каралган автономия биргәндә, гимназия советындагы башбаштаклыкка чик куелыр иде. Тик аның өчен яңа бинаны тизрәк җиткерергә кирәк.

Югары уку йортында укыту эшенең сыйфатын яхшырту галимнәргә килеп терәлә; Казанда университет ачканчы ук, Румовский шуның кайгысына керешкән иде. Илдә галимнәр җитәрлек булмагач, андый кешеләрне читтән, бигрәк тә Германиядән чакыртырга туры килде. Ләкин аларның күпчелеге ышанычны акламады: акчага кызыгып, Россиягә килсәләр дә, җирле галимнәрне тәрбияләп үстермәү генә түгел, хәтта әле үсеп килә торганнарына да ирек бирмәде, төрлечә комачаулык ясады. Димәк, киләчәктә ул галимнәрне сайлабрак, фәкать чын күңелдән фәнгә бирелгәннәрен — Бернулли, Эйлер һәм Рихман кебекләрен генә чакыртырбыз. Шуның белән бергә, Россияне килмешәк сорыкортлардан арындыру өчен үзебезнең яшь галимнәребезне икеләтә тырышлык күрсәтеп тәрбияләрбез.

Румовский кабат-кабат әнә шундый фикергә кайта торды. Казанда университет оештырып җибәргән чакта ук аның күңелендә шул өмет яна иде. Ләкин башта уйлаганча килеп чыкмады. Хатаны төзәтергә һәм яңаларын эшләмәскә генә кала. Сәламәтлеге яхшырып, аякка басу белән, ул бу эшкә ныклап тотынырга булды.

## 3

...Ә Казан университетында тормыш иске юлдан бара бирде. Январь ахырында, студентларны зур залга җыеп, Яковкин «Студентларның тәртип кагыйдәләре» дигән нәрсәне игълан итте. Беренче мәртәбә кабул ителгән ул кагыйдәләр студент халкына файдалы әйбер түгел иде. Иң алгы планга моңа кадәр яшәп килгән җәзалар, куркыту һәм тыю чаралары куелган. Моны ишеткәч, яшьләр начальствога карата көлке җырлар, чәнечкеле эпиграммалар чыгарды. Николай Лобачевский бу эштә иң актив студент булды.

Ләкин озакламый аларның игътибарын башка нәрсә яулап алды.

Февраль башында бер көнне студентлар, йокыдан тору белән, надзирательләреннән яңа хәбәр ишеттеләр:

бүген төнлә шәһәргә Европаның танылган галиме профессор Мартин Христиан Бартельс килгән иде. Казан университетының беренче почетлы члены бирегә килә икән дигән имеш-мимеш күптән йөргәнгә, студентлар бу хәбәрне бик тиз күтәреп алдылар, аның нинди кеше булуы белән кызыксына башладылар.

Яңа профессор турында мәгълүмат бирергә субинспектор Петр Кондырев алынды. Аның сөйләвенә караганда, Бартельс ярлы гаиләдән чыккан. Башта ул ятимнәр йорты мәктәбендә укыган, соңыннан Брауншвейг училищесына барып кергән. Уналты яшькә җиткәч, укытучы ярдәмчесе булып эшли башлаган: балаларны матур язуга өйрәткән. Шулар арасында Гаусс фамилияле бер малай математиканы ифрат яхшы үзләштерә икән. Яшь аермалары сигез ел булуга карамастан, болар дуслашып киткәннәр. Бартельс аңарга кирәкле китапларны табышкан һәм үзе дә аның белән бергә математика өйрәнгән. Соңыннан атаклы математик, Петербург Фәннәр Академиясенең почетлы члены Иоганн Пфафф тәкъдиме белән, алар Геттинген университетына укырга кергәннәр.

Ә 1801 елда Гаусс, инде мәшһүр математик буларак, Россия Фәннәр Академиясенә чакырылгач, үз урынына Бартельсны тәкъдим иткән. Румовский Бартельсның галимлегенә бик югары бәя биргән, аның турында: «...немец җирендә туган беренче математиклардан, Германиядә аңа тиңнәр юк»,— дигән һәм Казан университетына чакырткан.

Кондырев сөйләгәнне Лобачевский зур кызыксыну белән тыңлады. Ул шунда ук, Бартельс лекцияләренә язылырга теләп, директордан рөхсәт алырга китте. Ләкин Яковкин аның сөйләп бетергәнен дә көтмәде.

— Тагын нәрсә җитмәгән иде! — дип сүзен бүлдерде.— Лобачевский әфәнде, сез кайчанга кадәр шулай профессор сайларсыз икән? Әле күптән түгел генә математикадан materia medica фәненә күчкән идегез, хәзер тагын математикага кайтмакчы буласыз! Бәлки, яңадан берәр нәрсә уйлап чыгарырсыз?

Лобачевский математиканы гына яратуын әйтергә теләде, ләкин, директорның мәкерле күз карашын очратып, тешен генә кысты һәм борылып чыгып китте.

Бартельсның лекцияләре март аенда башланып, һәр көнне иртәнге 7 дән 9 га кадәр һәм кичке 4 тән 6 га кадәр булырга тиеш иде. Профессор аналитик, яссы һәм сферик тригонометрияләрне, аларның мате-

матик географиядә һәм астрономиядә кулланылышын укытырга җыена иде.

2 март җитте. Лекция башланыр вакыттан бик күп алда студентлар математика аудиториясенә кереп тулдылар. Корташевский куылганнан бирле мондый хәлнең булганы юк иде әле. Бартельсның кереш лекциясенә өлкән студентлар һәм беренче курстагылар, шулай ук гимназистлар һәм аларның укытучылары җыелды. Расписаниедә геометриягә кагылышлы сүзләр булмаганга, Лобачевский директор каршына кабат кереп түбәнсенеп йөрергә теләмәгән иде, ләкин ул түзә алмады һәм, икенче катка менеп, математика аудиториясенә юнәлде. Нәкъ шул чакны аңа таба атлаучы урта буйлы, түгәрәк акыллы йөзле бер әфәнде һәм аның белән бергә килүче күркә шикелле киерелгән Яковкин күренде. Күз карашлары очрашкач, Николай директорның тантаналы көлемсерәгәнен күрде һәм, кире борылып, баскычтан йөгереп түбән төшеп китте.

Бу хәлне күреп Бартельс туктап калды, аптырап иңбашын җыерды һәм аудиториягә керде.

Ә Николай йокы бүлмәләренә атылып килеп кергәч тә йодрыкларын тиз генә ачмады. Вераз тынычлангач, иелеп, карават астыннан китап тутырылган сандыгын тартып чыгарды.

— Ярар, үзлегемнән өйрәнермен,— диде ул, ныклы бер карарга килеп.— Онытылганны хәтергә төшерим дә, иптәшләрдән артта калмаска тырышырмын.

Идәнгә утырган килеш, ул шунда ук эшкә тотынды. Ләкин аңа озак утырырга туры килмәде: бүлмәгә, шаулашып, бер төркем студент керде. Николайны күреп, Дмитрий Перевощиков бусагадан ук кычкырып җибәрде:

— Менә сиңа кирәк булса! Коля, син нигә лекциягә кермәдең? Берәр күңелсезлек бармы әллә?

— Беттемени лекция? Бик тиз,— диде Николай гаҗәпләнеп.

— Булмады ул!

— Бөтенләй булмады! — дип җавап бирделәр иптәшләре.

— Ничек инде ул алай? — Николай идәннән сикереп торды, алдына куйган китаплары төшеп китте.

— Мәзәк кенә килеп чыкты, Коля, әйтсәк, ышанмассың менә! — диде Панкратов, сүзгә катнашып.— Күз алдына китереп кара менә! Бартельс аудиториягә

кергәч: «Кем дә булса такта янына чыгып, нәрсәләр белгәнегезне күрсәтсен», диде. Александр Княжевич тотты да чыкты. Дифференциаллардан һәм коник кисемнәрдән шайтан муенын сындырырлык бернәрсәне эшләп ташлаган иде, Бартельс баштa күзенә ышанмый торды, аннары безгә: «Мондый студентларга лекция укыр өчен, минем үземә ныклап әзерләнергә кирәк»,— диде. Шуннан...— Панкратов пауза ясады һәм як-ягына карады.

— Безгә баш иеп, чыгып китте! — дип тәмамлады бер студент.

— Чынлапмы? — диде Николай, бик үк ышанып җитмичә.— Кара, ничек кызык иткәнсең! Молодец, Саша! — дип, дустының җилкәсенә сугып куйды.

— Болай килеп чыгар дип үзем дә уйламаган идем.— Княжевич оялып кына елмайды.— Мәшһүр математик дип шапырынуларына ачуым килде. Ә математика бездә чыннан да начар куелмаган икән...— диде һәм: — Начар куелмаган булган,— дип төзәтеп әйтте.

— Ибраһимовка рәхмәт моның өчен,— диде Перевощиков.— Тагын Корташевскийга рәхмәт... Хәзер кайларда йөри икән Григорий Иванович, шуны белсәң иде!..

Шулчак сүзгә Владимир Панаев кушылды. Теге чакта Лобачевский белән Аксаков арасында низаг килеп чыгуга сәбәпче Александрның энесе иде ул.

— Кичә мин Петербургтан хат алдым. Аксаковтан,— диде Владимир.— Григорий Иванович законнар төзү комиссиясендә эшли.

— Әйдәгез аңа хат язабыз! — дигән тәкъдим кертте Панкратов.— Бартельс хакында да язсак, бәлки, сөенер.

Бу тәкъдим барысына да ошады. Панаевны өстәл янына утыртып, алдына кәгазь, каләм куйдылар, һәм берсен-берсе бүлә-бүлә, нәрсә язарга икәнен әйтеп тора башладылар.

Лобачевский бер читтә торып калды. Ул, кычкырып елап җибәрмәс өчен, каты итеп иренен тешләде. Иптәшләренең шатлыгы аны кузгата алмады. Бартельс хәзерләнер, Бартельс лекция укыр, тик ул гына тыңлый алмас шул инде...

Аның бүлмәдән чыгуын беркем сизмәде.

## 4

Ибраһимов тагын каты авырып киткән икән. Николай бу турыда шактый соңга калып белде, шуңа күрә дә ашыгырга кирәк иде. Ашыкса да ул юынып, киенеп-ясанып, төзәтенеп өлгерде. Авыру кешенең күңелен күтәрер өчен җиләк-җимеш тотып бару гына җитми, аңа тышкы кыяфәтеңнең йөз яктырткыч булуы да шарт. Николай авыру Ибраһимов янына җыенуы турында Алешага да әйтеп тормады, ялгызы гына барасы килде.

Тын Бассейн урамындагы көмеш бүрекле мәһабәт ак тирәккә ышыкланган ике катлы агач өйдә аның күп мәртәбә булганы бар. Бу йортка челтәрле балконы да, үрмәле гөлләр дә бик килешеп тора. Менә хәзер өйтүр бакчасындагы чәчәкләр янында, юктан гына эш табып, чуар ситсы күлмәкле һәм зур салам эшләпәле егерме биш яшьләрдәге ханым — Ибраһимовның хатыны мәш килә иде. Николайның килүенә сөенсә дә ул үзен бик гади тотты, өйгә чакырырга ашыкмады, зур шатлыгын уртаклашкандай, чәчәкләре турында сөйләде.

Эшләпәсен һәм күчтәнәчен алгы яктагы түгәрәк өстәлчектә калдырып, Лобачевский кунак бүлмәсенә сиздермичә генә үтәргә теләгән иде дә, тик барып чыкмады, кабинеттан Ибраһимовның хәлсез тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?!

— Берүк, борчыла күрмәгез; әгәр торырга ярамаса, яныгызга килеп утыра алам...

Өй эчендә көзнең явын алырлык чисталык; тәрәзәләр, трюмо көзгесе елкылдашып тора. Кисея пәрдәләренең актылыгы, кардай ак эскәтер өстендәге пакь салфеткалар, нур өстенә нур дигәндәй — читлектәге кенәри тавышы — һәммәсе өйдә авыру кеше барлыгын сиздермәскә тырышалар сыман.

Эш бүлмәсе дә зур, якты иде. Тәрәзә янында агач әйберләр ясау өчен махсус верстак, шуның белән янәшә үк кирәкле инструментлар, ә идәндә — беләк чыныктыру өчен төрле авырлыктагы герләр. Бер стенаны тулысынча шүрлек һәм этажеркалар били. Аларда Ибраһимов өчен иң изге, иң кадерле китаплар — Платон вә Овидийдан алып Вольтер белән Державингача барлык атаклы философларның, шагыйрьләрнең Европа һәм Шәрык телләрендәге әсәрләре. Инде берничә

тапкыр Николай ул язма вә басма китапларны кулына алып актаргалап та карады, ләкин карандаш белән тамгаланган, сызгаланган Ломоносов, Державин, Аристотель, Бхаскара, Абугалисина, Низами әсәрләрендәге Ибраһимов үзенчә таныи күрә белгән уй-фикерләрне таркатудан курыкты. Чөнки Николай Ибраһимовны гына түгел, ә ул яшәгән өйне дә бөтен тулылыгы белән ярата. Хуҗа кеше, бу йортны салдырган полковникның малае гимназиядә Державин белән бергә укыган һәм булачак бөек шагыйрь бирегә килеп йөргән, дип инандырырга тели һәм моның белән сабыйларча горурлана да. Ибраһимов ышандыра белә, бәлки чынлап та аның фикере растыр.

Ишек ачык булса да тар гына диванга елышкан Ибраһимов күренми иде әле, тик китап шкафы пыяласының көзгедәй өслегендә шәүләсе генә сизелеп тора: күкрәгенә тикле җәймә ябынган да мендәргә сөялеп утырып нәрсәдер яза. Ябык, агарган йөзе, шул ук йөздә чем кара булып торган чигә сакалы зур ак мендәргә уелып кергән сыман. Бераз өстәрәк стенада әтисенең портреты эленеп тора — ордены да булган икән; янәшәдә үк — Державин рәсеме.

Николайга кинәт кенә ямансу булып китте, ул монда килүенә үкенә иде инде.

— Нигъмәт абый, мин вакытсызрак килгәнмен ахрысы?

— Әшнең бераз тыгызрак чагы шул,— укытучы бу сүзләрне кырыс, саңгырау тавыш белән әйтсә дә, Лобачевскийга ул тирән бер әчкерсез елмаю белән карады.— Тыңлагыз әле менә:

...То не в один глядим коран,
Плетем и вирши по улусу *.

Ибраһимов тыныч кына башласа да тавышы әкренләп гел көчәя барды:

Желаний край: дать миру мир,
Уму и совести — свободу,
Честь — доблестям, законам — скиптр,
Сан человечества — народу **.

---

* ...Коръән генә укып утырмыйбыз,
Шигырь чигәм ыруг хакында...
(Ирекле тәрҗемә.— *Ж. Т.*)

** Труды Казанского общества любителей отечественной словесности. Первая книга, Казань, 1815, 70—74 битләр.

— Бөтен шөгылем шушы инде,— дип төгәлләде Ибраһимов.

— Әллә үзегезнең шигырьләрме, Николай Мисаилович?

— Әйе шул.

— Шәп бит бу! — бераз уйланып торганнан соң Николай өстәп куйды.— Державинның «Фелица»сы кебек.

Ибраһимов көлде генә.

— Державинга хәтле күп кирәк әле...— Укытучы бераз ютәлләп алды да җан ачысы белән әйтә салды: — Тегеләй итәләр, болай итәләр, эткәлиләр-төрткәлиләр, сүз бирәләр — алдыйлар... Ә «Грамматика»м әле һаман җир белән күк арасында... Шул мәгънәсезләр белән гел уртак тел таба алмыйм, ничек ышандырырга белгән юк... Йә, нәрсә инде син басып торасың? Утыр, утыр, Николай... һәм исәнме?!

— Хәлегезне белим дип кергән идем,— Лобачевский укытучыга якынрак килде дә ирләрчә кул бирде, ләкин ябык, хәлсез кулны нык кысарга йөрәге җитмәде.

— Бераз катырак та чирләп алган идем, инде үтә бугай, бүген хәтта кәефем дә ярыйсы гына.

— Авырганыгызны ишеткәч егетләрнең кәефе кырылды. Инде мин иң алдан барып күрим дидем, бәлки берәр дару кирәктер?

— Авыру укытучыгызны онытмавыгыз өчен рәхмәт аныса,— диде ул калтыранган тавыш белән,— рәхмәт, күгәрченкәем, юата белүегез өчен рәхмәт...

Бу сүзләрне ул шундый тиз әйтте, хәтта борчылуын-дулкынлануын да сиздерми калды, тик карасу тирән күзләрендәге яшь бөртекләре генә аның эчке халәтен белдереп торалар иде.

Лобачевский авыруның урын җирендә аунап яткан язу-сызуларын күздән кичерде. Алар аның яңа шигырьләредер ахрысы.

— Сез үзегезне саклый белмисез, хәлегез яхшырганчы бераз чамалабрак эшләргә кирәк бит.

— Николай, син минем өчен бөтен Казанга бер якын кеше. Университетны ташларга җыенганыңны

---

И газиз җир: илгә иминлек бир,
Азатлык бир акыл, намуска.
Вөҗданыма — пакьлек, законнарга — хөрмәт,
Кешелекле караш — халыкка.

(Ирекле тәрҗемә — *Ж. Т.*)

ишеткәч тә бик нык борчылган идем.— Ибраһимов йөткерүеннән туктый алмыйча интекте. Хәзер ул тагын да ябыграк, хәлсезрәк булып күренде.— Сизеп торам, көчем бетеп бара, озак яшәүгә өметләнмим... Көннәрдән бер көнне миңа инде университет та, рус теле кафедрасы да кирәк булмас. Мине тик поэзия яшәтә. Хәтта төннәрен торып та язам, менә шулай сикереп торам да... Илһам — ул шундый зур көч икән! Дәрте дә үзеннән-үзе килеп тора, әйтерсең лә эчке бер рухың нидер пышылдый, ә син шуны күчереп язып кына барасың. Көне-төне сызгаласаң да ару-талу сизелми, киресенчә, канат үсеп чыккандай очынасың гына. Андый чакларда элеккеге күңел рәнҗүләре дә юк-бар нәрсә булып кына тоелалар. Язуымнан бүленергә теләмәгәч урамга чыгасы да — вакытны бушка әрәм итәсе дә килми. Әгәр шушы халәтне саклый алмаган булсам, моның кадәр язалмаган булыр идем.

Ул тигезсез юллар белән чуарланган кәгазьгә ымлады.

— Бәлки, кем өчендер болар барысы да чүп-чар гынадыр, тик миңа алар барыбер якын...

Ибраһимов сөйли дә сөйли, сөйләгән саен чиксез дулкынлануы ныграк сизелә: кирәкмәсә дә чәчен төзәткәли, юктан гына шигырьле кәгазьләрен тузгыткалый — берәрсен эзләгәндәй итә. Николай үз күзенә үзе ышанмагандай укытучысына сокланып карап торды — ничек нык үзгәреп китте әле ул — шигъри хисләр агышы аны канатлы кешегә әйләндергән.

— Кайвакытларда язгы Иделгә сәгатьләр буе карап торам-торам да... аны шигырьгә саласы килә. Син моны күз алдына китерә аласыңмы, юкмы икән?

— Беләм, беләм,— дип куанды Лобачевский,— мин үзем дә...

— Тагын бер хыялым бар әле... Җыр язачакмын. Ул җыр кешеләр күңелен уятырлык, бизәрлек, өметләндерерлек көчле, иркен һәм моңлы булырга тиеш, кайгы-хәсрәтләрен таратып матур киләчәккә рухландырырга тиеш! Барыбер язачакмын.. Кайбер юллары әзер дә инде:

> Не ищи меня, богатый,
> Ты не мил моей душе.
> Что мне, что твои палаты?
> С милым рай и в шалаше *.

---

* Н. М. Ибрагимов. Вечерком красна девица (песня).— Труды

Җырны дәвам итәргә теләгәндәй Ибраһимов үзенә генә аңлаешлы булган ниндидер көйне сызгыра башлады. Ләкин бу көй көтмәгәндә генә уянган кебек, көтмәгәндә генә сүнеп тә калды.

Кинәт ишек ачылып китте дә таныш тавыш ишетелде:

— Студент Лобачевскийны монда дигәннәр иде.

Университет лирикларының берсе Владимир Панаев иде бу.

— Әллә яңа шигырь алып килдеңме? — дип сәламләде аны Ибраһимов, куанычын яшерә алмыйча.

— Хәерле көн! Әле генә Аксаковтан хат алдым, шуны укып күрсәтмәкче булам.— Һәм Владимир калын пакеттан хат чыгарды. Дөресрәге, хат дип кенә әйтү җитмәс, бер китапчык кадәрле истәлек-язма иде ул.

«...Петербург кебек мәшһүр калада яшәсәм дә монарчы гел ялгызлыктан интегә идем. Үзеңә фикердәш табуы бигрәк тә кыен бит ул. Шушы көннәрдә генә, фатирыма кайтып керүгә бер сәер хат кисәгенә юлыктым:

«Хөрмәтле дустым Аксаков, мине яраланган килеш генерал Сабанеев алып кайтты. Полкның кирәкле тупчысы булганым өчендер, каретасын кызганмады. Мин хәзергә Алехинда туктадым. Синең монда икәнеңне белми идем, ул әйтте. Петр Балясников».

Алехинны хәтерлисездер әле, студент була алмаса да гимназиядә һәммәбезнең дусты иде ул. Шул ахмак директорның «хәер фатихасы» белән, начальствога каршы бунтта катнашуда гаепләп, гимназиядән кудылар да солдат итеп җибәрделәр бит аны. Хәзер ул хәрби министр Аракчеев җәнабларының яраткан генералы, канцелярия директоры Капцевичта адъютант булып исәпләнә икән... Инде аңлавыгызча, берничә минуттан без Балясников белән кочакланышып күрештек тә. Җәрәхәте әллә ни куркыныч булып чыкмады, тез астындагы сөяк арасына пуля кереп калган. Хәрби

---

Казанского общества любителей отечественной словесности. Книга первая, Казань, 1815. 289 бит.

Үгетләмә, бай, мөлкәтең
Җаныма азык түгел.
Алачыкны оҗмах итәр
Сөйгән яр әзли күңел... (Ирекле тәрҗемә.— *Ж. Т.*)

докторлар операция ясап торуны кирәк дип тапмаганнар, шул яралы килеш аны Петербургка дәваланырга җибәргәннәр. Мин аңа сокланып карап тордым. Безнең университет сәхнәсендә яралы офицер ролен башкарган театраль герой гына түгел иде ул, ә чын мәгънәсендә сугышчы, авыр яраланып та җәрәхәт сызлавын йөзенә чыгармыйча басып торучы батыр сугышчы! Алехин белән өчәүләшеп утыра торгач таң атканны сизми дә калганбыз. Үткәннәрне рәхәтләнеп искә төшердек ичмасам. Шулай да без күбрәк Балясниковны тыңларга тырыштык, ни дисәң дә күпне күргән кеше бит ул. Балясников бераз яктырганны гына көтте дә: барыбер хәрби министр янына керәм, дип йөдәтә башлады. Ярадан пулясын алмыйча кайтарып җибәргәннәре өчен бик нык ачуы чыккан аның. Ул яңадан сугыш кырына китәргә җыена. Алехин аны кире түндерергә тырышып үгетләп тә карады, Аракчеевның кырыслыгын белә торып аннан шәфкать көтү хәтәр өмет кенә булуын әйтте. Тик Балясниковның усал министрдан куркырга исәбе юк иде: «Дусларымның төне буе минем сызлануымнан интегеп чыгуын теләмим мин. Минем аерым, яхшы фатирларда үземнеке дип күкрәк кагып яшәрлегем бар. Хәрби министр белән ничек сөйләшәсен беләм мин, менә күрерсез, ул әле дәваланыр өчен акча да биреп чыгарыр. Ә хәзер, сау булып торыгыз!» Ул үзенә урын җәелгән якка кереп китте һәм без бүтән сөйләшеп тормадык та.

Өйгә кайткач берәр сәгать чамасы черем итеп алдым да эшемә киттем. Закон төзү комиссиясенең тәрҗемәчесе буларак күренеп китмичә ярамас иде. Комиссия директоры Розенкампф белән ашык-пошык кына аңлаштым да Алехиннарга йөгердем. Балясниковның ни хәбәр белән кайтканын тизрәк беләсем килде. Ул кайтып җитмәгән иде әле. Хәер, үзен озак көтәргә туры килмәде. Дөбердәгән тавышка тәрәзәдән карасам — Алехин тора торган йортның капка төбенә дүрт ат җигелгән карета килеп туктады. Хәрбиләрчә пөхтә киенгән лакей карета ишеген ачып Алехин белән Балясниковны төшерде. Аннан соң яралыны ике ягыннан тотып мин көтеп утырган бүлмәгә алып керделәр. Шаккаттым да калдым.

— Министрга рәхмәтемне җиткерергә онытма! — диде Балясников лакейга төксе генә. Лакей түбәнчелек белән баш иде дә чыгып китте. Карета күздән югалды.

Балясников искиткеч тыныч иде. Искитәрлек нәрсә булмагандай бердәнбер диванга барып ятты да яралы аягын ян таянгычка күтәрде (сызлавы җиңеләйсен өчен гел шулай итә иде ул).

— Алехин, син барысын да түкми-чәчми генә Аксаковка сөйләп бир, мин бераз черем итеп алам...

Балясников моны шундый итеп әйтте ки, хәтта үзенең тирән канәгатьләнү хисе кичергәнен яшерә алырлык та түгел иде.

— Ну, Аксаков, безнең Аракчеев янында күргәннәрне читтән генә күзәтеп торсаң — шаккатар идең! Балясниковны кабул итү бүлмәсенә өелешкән төркем арасында калдырдым да эш кәгазьләре күтәргән булып министр янына кереп киттем. Беркем бәйләнә алмый, чөнки генералым авырган чакта Аракчеев галиҗәнабларының үзенә мөрәҗәгать итәргә хакым бар. Эш кәгазьләре белән таныштыра башлаган гына идем, дежур ординарец керде дә: «Сугыш кырыннан яраланып кайткан гвардия офицеры сез галиҗәнабны күргә тели»,— диде.

— Яралы офицер әфәндегә әйт, минем әлегә вакытым юк, бераз көтеп торсын! — диде Аракчеев эшлекле һәм кырыс кына.

Мин оялдым, чак түздем, сүземне дәвам итсәм дә колагымда гел кабул итү бүлмәсендәге Балясников тавышы гына яңгырап торды... Озак та үтмәстән шул ук ординарец тагын килеп керде:

— Галиҗәнаб, гафу итегез, зинһар; яралы офицер көтеп тора алмыйм ди, җәрәхәтләре бик нык сызлый икән. Аннан соң, Рәсәйнең хәрби министры яралы рус офицерын көттерергә җөрьәт итмәс, ди ул.

Аракчеев агарынып китте — бу аның гадәттән тыш ярсу билгесе иде.

— Әйдә, керсен,— дип ысылдады ул, ачуын яшерә алмыйча.

Ишек гүя икегә шартлап ярылды, Балясников таякка таянып килеп керде. Әмма ул үзен бик сабыр һәм салкын тотарга тырышты: ихтирам белән баш иде, аннан буйсынулы һәм ялварулы карашын текәп сүзсез калды. Хәтта Аракчеевка бу күренеш ошады да бугай, ачуын җиңеп, уңайсызланган сыман гына сорап куйды:

— Ни үтенеч белән килдегез?

— Беренче үтенечем шул, утырып сөйләшергә мөмкинме? Юкса басып торырлык рәт юк, җәрәхәтем җи-

ңә...— Һәм Балясников, министрның «әйе!» дигәнен дә көтмичә, урындык алып утырды.— Министр әфәндем, сез миңа ярдәм итсәгез иде. Аягымда хәтәр пуля калды, берәр тәҗрибәлерәк докторыгызга әмер биреп шул пуляны алдырсагыз иде. Юкса, минем урыным фронтта, бер дә яралы солдат булып йөрисем килми. Аннан соң, яшим дисәм, минем үз куышым да юк бит әле. Ашау-эчү ягына килгәндә дә кесәмдә сукыр бер тиенем дә юк.

Бу сүзләр әкрен әйтелсә дә ничектер ышандырырлык нык һәм итагатьле яңгырады. Аракчеев нишләде дип уйлыйсыз? Мин аны инде Балясниковны «тотып ашар» дип уйлаган идем, ә ул миңа фәрман бирде:

— Хәзер үк бу офицерга өч йөз сум акча бирелгән булсын. Лейб-медик Штофрегенга язу җибәрегез, бүген үк яраланы карасын һәм дәвалый башлавы турында миңа рапорт бирсен. Офицерны синең җаваплылыкка тапшырам. Аңа шәп кенә фатир тап, хезмәтче ялла, өстәле гел мул булсын. Барысы турында да миңа җиткереп торырсың. Ә хәзер минем карета белән аны өенә илтеп куй!..

Баш идек тә чыгып сыздык, министр каретасы белән китереп тә куйдылар. Кеше ышанмаслык әкәмәт бу! Балясников сихерче ахрысы ул! Ерткычның ерткычы Аракчеев шәфкать күрсәтсен әле!..»

Алехин, үзе студент булмагач, Балясниковны бик үк яхшы белеп тә бетермидер, ә мин аның белән студент шулпасын бик күп чөмергән кеше. Алехинга да Балясниковның студентлар арасындагы авторитеты турында сөйләп бирдем, ышандырыр өчен истә калган бер вакыйганы да өстәдем. Балясников исә, аягы авыртуын да онытып, мин сөйләгәннәрне көлә-көлә тыңлап утырды.

Эшнең шулай шома гына бетүенә сөенеп шактый гәпләшеп утыргач, Балясников теләгенә буйсынырга туры килде: без аңа шул ук көнне менә дигән фатир табып бирдек. Иртәгесен Балясников янына Штофреген да килеп җитте. Ярасын саклык белән тикшереп чыкты да өметсез генә башын түбән иде. «Пуляны алып булмас, үзенең кыймылдаганын, сөяк арасыннан кузгалганын көтәргә туры килер», диде. Ниндидер май кулланырга кушты. Шул майны ярага сөртә торгач, Балясников бөтенләй көрәйде.

Алехин белән без көн саен Балясников янына килеп йөрдек. Ул инде хәзер театрга йөри, төрле китап

сатып ала, укый. Бигрәк тә сугыш турында фәнни чыганакларны яратып укый ул. Сөйгән-сөелгән кешеләре дә юк түгел. Бер уйласаң, дөньясы тигез иде, рәхәтләнеп яшә генә... Юк, аңа эш җитми икән. Ул төнге походларны, сугыш утларын, ачлыкны-ялангачлыкны, дары төтенен, туплар гөрелтесен, хәтәр сугыш тормышын сагына башлады. Ярасыннан пуляны ала алмаслыкларына ышангач, инде язмыш хөкеменең билгесез карарын көтеп торасы килмичә, ул яңадан сугыш кырына китеп барды. Аны атлы артиллерия ротасына командир итеп билгеләделәр...

* * *

Укытучысының йөрәккә үтеп керердәй көчле тәэсирле шигырьләре дә, дустының сокландыргыч сугышчан язмышы турындагы хәбәр дә Лобачевскийның күңел түрендә посып яткан тынгысыз өметенә җан керттеләр. Балясников холкындагы батырлык сыйфатын үзенә сеңдереп, аны нинди дер бөек эш гәүдәләнешендә күрергә теләде ул.

Тенишев йортына урнашкан химия лабораториясенә Николай бик яратып йөри башлады. Ирек лек тә, рәхәтлек тә, мавыктыргыч максат та сизә ул монда. Бирегә килеп керүгә аны бер җаваплылык тойгысы биләп ала. Эш өстәле янында, химик реакцияне күзәтеп, нинди дер нәтиҗә көтеп тору шул максатны гел якынайта бара сыман.

Аннан соң монда Мартин Бартельс белән дә очрашасы юк. Лекция бетүгә студентлар төркемендә зур канәгатьлек белән баскычтан төшеп баручы шат күңелле профессорны күзәтеп тору бәгырьгә тияр иде. Николай тыңламый калган һәм тыңламаячак лекцияләр, Яковкинның мәкерле елмаюлары һаман истә... Хәер, Николай аларны онытырга теләми дә. Буш аудиторияләрдә, йокы бүлмәсендә ял-ялгызы гына калгач ул укый да укый, аннан — уйга чума.

Химия дәресләренә йөри торгач, ул анда механик Горденин белән дуслашып китте. Әлеге остаз буш вакытлары булды исә, үзенең уйлап тапкан пиротехник ачышлары белән уртаклашырга бер дә иренми иде. Ул хәтта Николайны ракета ясарга өйрәтте. Алар төнлә белән икәүләшеп чыгалар да бер кешесез тын Арча кыры өстендә ракеталар очыралар. Очраклы юлчылар бу тамашаны сокланышып күзәтәләр иде. Сокланмас-

лыкмының: караңгылыкны чатнатып төн гөмбәзенә төрле төстәге йолдызлар бөркелсен әле! Баштарак әлеге шөгыльне сер итеп сакладылар. Шулай да кичләрнең берсендә саксызрак кыйландылар бугай: ракета гимназия ишегалдыннан күккә күтәрелеп, җитәкчеләрнең котын алды.

Котырынган директор гаеплеләрне эзләргә дип үзе тотынды. Иң элек ул шиклерәк дип саналган студентларның барысын да төшке ашсыз калдырды. Бик акыллы эш эшләдем дип уйлады ахрысы, бу хакта Советка да хәбәр итте:

«Августның 17 көнендә, иртән, студент Стрелков үз гаебен таныды: ракетаны ул җибәргән, ә аны аңа өлкән Лобачевский ясап биргән икән. Бу турыда Филипповский һәм янә берничә кеше белгән...»

Ракета вакыйгасының Лобачевский өчен шактый күңелсез очлануы мөмкин иде. Ул төнне янгын каланчасындагы солдат күз явын алырлык фейерверк күргәч йокы аралаш каушавыннан чаң каешын тартып җибәргән. Билгеле инде, якын тирәдәге йортлардан чиләк-көрәк күтәрешеп кешеләр йөгерешә башлаганнар. Әйе, булган кадәресе башбаштак студентны университеттан куып чыгарырга җитәрлек иде, ләкин Яковкин Лобачевскийны өч көнгә карцерга утырту белән генә чикләнеп калды. Хәер, тора-бара директор-профессорның бу «яхшылыгының» сәбәбе ачыкланды да: попечитель Румовский үтенече белән сенатор Данауровның Казан университетына ревизия ясарга киләчәге турында ишеткән икән ул.

Яковкин эштән куылган профессор Каменскийның аның өстеннән жалоба язып өлгергәнлегенә инанган иде. Болайга киткәч ревизиянең юньле-башлы бетмәячәгенә шик юк, шуңа күрә дә Яковкин үзенең китәсе юлына күпер сала башлады: Петербург түрәләре исеменә бик әчтәлекле хат, дәресрәге, эштән азат итүләрен теләгәнне сиздереп хәбәр җибәрде. Ул хат-гаризада төрле-төрле сәбәп күрсәтеп, үзен акларга да тырышты. Тик шунысы, директор-профессор Яковкин бераз соңгарак калган иде шул. Гариза китүгә бер көн үтмәде, Данауров Казанга килеп тә төште. Яковкин танышыр өчен барып та караган икән дә, тик сенатор аны кабул итмәгән. Бер атнадан соң очрашсалар да ревизор үзен бик кырыс тоткан. Аның озак вакыт танышырга теләмәвеннән, һәм очрашкач та латинча эндәшүеннән, төрле вак-төяк сәбәпләргә бәйләнүеннән үк Яковкин

өметләнер форсат калмавын тойган. Мәгәр, карт төлке дип исеме чыккан директорның алай җиңел генә баш иярга исәбе юк иде. Ул кабинетына бикләнә дә төн уртасына хәтле шәм яктысына карап төрле план кора, күңеленнән генә монысын үлчи, тегесен кисә... Иң мөһиме — рапортка бәйләнгән икән, ул рапортны «коры» килеш кенә бирергә ярамый.

— Кызлар колагы алтыннан коелган,— дип мыгырдана ул, ниһаять, ныклы бер карарга килеп,— сенатор да безнең кебек кеше... Дөрес, кыйммәткәрәк тә төшүе бар, тик нишләргә дә хәл юк, уны белән чыкса, меңе белән кайтыр әле!..

Директор берничә көннән соң сенатор белән шаһитларсыз гына очрашты. Нәтиҗә дә сөенечле булды...

Данауров университет эшләрен аннан-моннан гына карап чыкты да директорга булган нәфрәтен шәфкатькә алыштырды. Өстәвенә әле үзенең зур канәгатьлек хисен министрга гына түгел, ә император галиҗәнабларының игътибарына җиткерергә дә вәгъдә бирде.

Инде Яковкин эштән азат итүләрен белдереп язган хат-гаризасын кире алмакчы булды. «Шундый чакта университетны ташлап китү зур гөнаһ булыр, бу минем ходай алдындагы изге бурычым», дип яңа хат яза ул попечительгә.

Казан университетына килгән беренче хәтәр ревизия әнә шулай җиңел генә үтеп китте. Эшеннән куыласы Яковкинга әле дүртенче дәрәҗә Изге Владимир орденын да тапшырдылар.

Данауровның директорны үтереп мактаган донесениеләрен укыгач, Румовский аптырап калды. Бер укыды, ике укып чыкты ул аны. Соңыннан, көрсенеп, авыр сулап куйды:

— Күз күргесез эшләр... Тора-бара нишләр...

## 5

Университет ачылуга дүрт ел тулу көненә багышланган тантаналы акттан качып, Николай үзе яши торган бүлмәгә төште һәм, парад формасын салмыйча, хәтта шпагасын да ычкындырмыйча, кроватена ауды. Ак перчатка кигән кулын баш астына салып, тирән уйга чумды. Бүлмә буш, иптәшләре һәммәсе югары катта җыелыш залында. Тынып калган гимназия бинасында кинәт Яковкинның шат тавышы яңгырап ишетелде:

— Әфәнделәр! Әфәнделәр!..

Николайның иптәшләре, адъюнктлар, профессорлар — һәммәсе анда... Ни өчен ул анда түгел?.. Ни өчен?..

Нәкъ ике ел элек, 14 нче февральдә, ул студент исеменә лаек табылды һәм шпага алды. Ә нәрсәгә иреште? Ни математик чыкмады аңардан, ни химик... Иптәшләреннән артта калды: әнә Дмитрий Перевощиков, университетны тәмамлап, Сембер гимназиясендә укыта; тиздән Василий Перевощиков магистр * дәрәҗәсен алачак һәм студентларга лекция укыячак. Дөрес, Николайга караганда алар ике-өч яшь олырак та бит, ә яшьтәше Александр Княжевичны кая куясың? Ул да бит әнә бүген магистрлыкка кандидат дигән исемне алды. Ә Николай?..

Лобачевский ялт итеп караватына торып утырды. Аның башында ике төрле фикер тарткалаша иде.

«Корташевский киткәннән бирле синең математикадан бер генә лекциягә дә кергәнең булмады,— диде беренчесе.— Яковкин сине Бартельс лекцияләренә йөрергә язмасын да, ди, ә шуңа ирешү өчен син үзең нәрсә эшләдең? Бартельсның күзенә күренергә оялыр идең! Бик тиз бирештең син!»

«Бирешми торсын әле! — диде икенчесе.— Геометриянең нигезендә ни өчен Евклид постулатлары һәм аксиомалары ятканын уйлап баш ваттым мин».

«Баш ватудан узмадың шул...»

Югарыдан, залдан, музыка уйнаганнары ишетелде. Николай сикереп торды һәм бүлмә буйлап йөренергә тотынды. Әйе, бер елдан артык вакыт инде, аксиомалар турында фикер йөрткән саен, ул нәкъ әнә шул мәсьәләгә җитеп туктала, сихерләнгән кебек, шуннан уза алмый...

«Вакыт үтә бит,— диде теге бәйләнчек уй.— Бүгеннән башлап син инде өченче курс студенты. Тагын бер елдан тәмамлыйсың. Аннары нәрсә эшләргә уйлыйсың? Үз алдыңа куйган максатка ирешергә көчең җитәрме? Бер урында таптанмыйсыңмы? Күпме вакытны әрәм иттең бит! Ә нәрсә кырдың?..»

Николай, тәрәзә янына барып, пыялага маңгаен терәде. Бераз җиңелрәк булып китте.

— Үзем гаепле: үз көчемә артыграк ышандым.

---

* Магистр — кече гыйльми дәрәҗә (хәзергечә әйткәндә, фән кандидаты)

Университетта беркемнән киңәш тә, ярдәм дә сорамадым. Ә бит дусларча сөйләшсәң, бер-береңне аңласаң, бәлки, болай килеп чыкмаган булыр иде... Төзәтеп җибәргән булырлар иде...

Николай тәрәзә пыяласыннан маңгаен алды. Пыяла аның тирән күңел газабы кичергән йөзен күзгә шикелле чагылдырды. Кинәт, сискәнеп, артка чигенде ул. Өстән яңгырап ишетелгән музыка тавышына бүтән колак салмыйча, бүлмә буйлап йөренә башлады.

— Җисемнәрнең бер-берсенә орынып торуыннан чыгып башлангыч төшенчәләрне билгеләү дөрес булырмы икән? — дип, үзалдына сөйләнеп, фикер йөртте ул.— Ичмасам, бер математик шул фикергә кушылырмы?..

Шул чакны шыгырдап ишек ачылды, бусагада сторож карт күренде.

— Лобачевский әфәнде, сезгә посылка белән хат бар, почтальон китергән.

— Хат? — дип Николай кабатлап сорады, аның тавышы калтырап куйды. Һәм ул, сторожның җавап биргәнен дә көтмичә, коридорга атылып чыкты.

— Яшьләр безнең кебек атламый шул! Күр, ничек йөгерә! — диде карт, аңа сокланып.

Лобачевский хатны һәм посылканы алганга тиз-тиз генә кул куйды да, почтальонның учына карап тормыйча гына, бер көмеш акча төртте. Хат Григорий Ивановичтан иде.

Нәрсә икән бу хатта: шатлыкмы, әллә кайгымы? Коридорда ук егет калтыраган кул белән конвертны ачты һәм, ашыгып бүлмәгә кереп, укый башлады.

«Хатыгызга шул чаклы озак вакыт җавап язмый торуыма гаҗәпләнмәгез: чит илдә командировкада идем, әле шушы көннәрдә генә исән-сау Петербургка әйләнеп кайттым...» дип яза Корташевский.

Николай хатның кереш өлешен күз йөгертеп кенә укып чыкты; әмма ары киткән саен ныграк уйланырга мәҗбүр булды.

«Үз алдына ачык максат куеп, шул максатка ирешү өчен зур тырышлык күрсәткән, үз юлындагы барлык киртәләрне җиңә алган кеше генә көчле ихтыяр иясе дип санала. Бу сыйфатлар билгеле бер күләмдә, әлбәттә, һәркемдә диярлек бар, тик алар бик ерак яшеренгән булалар. Әнә шул сыйфатларны үстерергә кирәк... Үз-үзеңә һәрвакыт ышанырга, тик масаймаска гына кирәк...» дип яза Григорий Иванович.

Укытучысының бу сүзләре Николайны борчуга салды. Чөнки еллар буе дус булгач, аның инде тикмәгә алай әйтмәгәнен ул сизеп алды.

«Геометрияне нокта, сызык һәм яссылыктан башламыйча, киресенчә, конкрет җисемнәрдән башлап җибәрергә кирәк, дип дөрес әйтәсез. Әмма алгы планга аларның «орынуын» куйганда, сез геометриянең беренче чиратта ераклыкны үлчәү фәне икәнлеген хәтердән чыгаргансыз.

«Башлангыч»ны аеруча абстракт итеп, пространстводагы реаль формалардан ни ераклаштырган һәм фәкать формаль рәвештә логик фикерләүгә нәрсә китергән соң? Беренче чиратта, фән буларак геометрия алдына куелган максатны һәм бурычны Евклидның күрсәтмәве китергән».

— Ә мин моны ничек хәтердән чыгардым икән? — дип куйды Николай, хат укуын бүлеп.— Геометрия белән кызыксынуым да бит җир үлчәү аркасында булды.

Бераз тынычланып, укуын дәвам итте.

«Табигатьтә һәр җисемнең — ком бөртегеме ул, әллә кояшмы, өч төрле юнәлешкә — озынлыкка, киңлеккә һәм биеклеккә сузылышы бар... Бер юнәлештәге сузылышны — с ы з ы к, ике юнәлештәге сузылышны — я с с ы л ы к, ә өч юнәлештәгесен г е о м е т р и к җ и с е м дип атыйбыз.

Шулай итеп, өч төрле юнәлеше булган сузылыштан чыгып без геометриянең барлык тәүге төшенчәләрен табабыз: геометрик җисем, яссылык, сызык һәм нокта. Соңгысын, ягъни н о к т а н ы бер юнәлештә дә сузылышы булмаган урын дип билгелибез.

Дустым, Сезгә мин чын күңелдән язам, киләчәктә дә шулай ук язачакмын, шуңа күрә турысын әйткәнгә үпкәләмәгез. Кызганычка каршы, үзем турында геометрия белән шөгыльләнәм дип яза алмыйм. Департаменттагы бетмәс-төкәнмәс чиновниклык эше ул шөгыльне туктатып торырга мәҗбүр итте. Безнең өчен уртак фән бик күп серләрне яшереп саклаган, аларны башта сизү мөмкин булмаган. Хәзер Сез үзегез дә күргәнсездер, табигатьтәге башлангыч хакыйкатькә якынлашкан саен, ул кыенлыклар үскәннән-үсә бара. Хәер, бүредән курыккан — урманга бармый, диләр. Ә бит Казанда бик оста аучы бар: атаклы Гауссның укытучысы Бартельс.

Сезне университетта укуыгызның өченче елы башланып китүе белән тәбриклим һәм шул уңай белән Радищев әсәрләренең беренче ике томын җибәрәм, аларны миңа хәзер генә Мәскәүдән алып кайттылар».

Николай шул сүзләрне укыгач кына посылканы исенә төшерде. Төргәкне чишеп, китапларны алды. Беренче томның титул битендә тигез матур хәреф белән түбәндәге сүзләр язылган иде:

*«Өченче курс студенты Николай Лобачевскийга!*

*Радищевның рус халкына, аның иҗат көченә һәм бөек киләчәгенә чын күңелдән ышанып язган мәңгелек сүзләре Сезгә фән биеклекләрен яулаганда юл күрсәтүче йолдыз булсын!»*

Николай үзенең яраткан укытучысы җибәргән бүләкне күкрәгенә кысты. Аның йөзеннән караңгылык качты, күзе шатлыклы балкыды. Менә бит дуслыкның көче нәрсәдә! Моннан соң ул, әлбәттә, Бартельстан дәрес алачак. Ә Яковкин һичничек комачаулык итә алмас. Әйе, хәзер үк, Бартельсның өенә барып, Николай аңа геометриядә үзенә тынгы бирмәгән төшенчәләр турында сөйләячәк. Кирәк була калса, аның укучысы булып язылырга ярдәм итүен дә сорар...

Бүреген һәм перчаткаларын эләктереп, Николай урамга атылды.

Бартельслар гаиләсе университет кварталының Воскресенский чиркәүгә каршы почмагында инженер-подпоручик Спижарный салдырган ике катлы таш йортта яши иде.

Лобачевский звонок бавын тартты. Ишек ачкан горничнаядан:

— Ist Herr Professor zu Hause? * — дип сорады.

— Ja... ja **,— диде горничная һәм алгы бүлмәдән эчке ишеккә күрсәтте.

Николай, шактый иркен бүлмәгә килеп кергәч, як-ягына каранды. Китап тутырган шкафлар, өстәл һәм урындыклар, күн диван, фортепиано. Стеналардагы бик зур булмаган нәфис гравюралар, чикләвек агачыннан эшләнгән тартмалы, җиз герле сәгать һәм читтән китерелгән башка төрле җиһазлар бүлмәгә ят бер матурлык биреп торалар иде.

Түр ишектә Бартельс күренде. Аның өстендә өйдә кия торган зәңгәр сюртук һәм яшел панталон, сул

---

* Профессор әфәнде өйдәме? *(нем.)*

** Әйе... әйе *(нем.)*.

кулына озын челем тоткан. Профессор урта буйлы, зур башлы, куе озын чәчле, киң маңгайлы, бөркет борынлы кеше иде. Аның акыллы уйчан күзләре югалып калган студентка ягымлы итеп карадылар.

— Рәхим итеп утырыгыз... Сезгә нинди хезмәт күрсәтә алам? — диде Бартельс Николайга ул чакта модада булган француз телендә, тирән кәнәфигә ипләп кенә утыргач.

Лобачевский, бер урындыкның кырыена гына утырып, оялып кына немец телендә сүз башлады:

— Мин, профессор әфәнде, III курс студенты Николай Лобачевский булам.

— Танышуыма бик шатмын! — Бартельс ягымлы итеп башын иеп алды.— Мин сезне көттем. Әйе, әйе, гаҗәпләнмәгез. Non magister ad discipulum venire debet, sed discipulus ad magistrum *,— дип ашыкмыйча гына латинча бик матур итеп әйтте.

— Гафу итегез, һерр профессор, сез мине каян беләсез? — диде Лобачевский, кызарып, шул ук телдә.

Бартельс елмаеп куйды.

— Төрле телләрне белүегез бик күркәм,— диде ул немецча.—Латинны үзләштерүегез бигрәк мәгъкуль. Чөнки латин теле — бөтен фәннәргә фән; ул мәгърифәтнең һәр өлкәсенә үтеп керергә мөмкинлек бирә. Сезнең хакта, Лобачевский әфәнде, Петербургта профессор Корташевскийдан ишеткән идем.

— Григорий Ивановичтанмы? Ул сезнең белән минем турыда сөйләштемени? — дип куйды Николай, дулкынланып.

Бартельс яңадан башын иеп алды.

— Сөйләште, күп тапкырлар сөйләште. Сезнең турыда ул бертуган энесе шикелле кайгырта. Мин Казанга китәр алдыннан, махсус кереп, студент Лобачевскийга карата аеруча игътибарлы булуымны үтенде. Ул студент үзе минем янга килергә тиеш икәнне дә әйтте. Бераз кичегеп булса да, андый хәлне дә күрдек.

— Гафу итегез мине, профессор әфәнде...

— Анысы өчен борчылмагыз. Монда аннан әһәмиятлерәк нәрсә бар. Миңа Корташевский әфәнде, сезне геометрияне фәнни нигезләү мәсьәләсе кызыксындыра, дигән иде. Бу эшегезне бик мәгъкуль күрәм. Ләкин сез

* «Укучы янына укытучы түгел, ә укытучы янына укучы килергә тиеш».

шунысын тәгаен беләсезме икән: сез бит үз алдыгызга артык авыр, хәтта әле, мин әйтер идем, чишәргә мөмкин булмаган мәсьәлә куясыз. Ачыктан-ачык сөйләшик, Александриядә яшәгән атаклы галим Птолемей: «Тәүге нигезләрнең асылына төшенү мөмкин түгел, һәрхәлдә, бик читен эш», дип язган. Дөрес әйткән. Евклидтан соң ике меңнән артык ел үткән. Шул дәвер эчендә антик математиклар Папп белән Проклдан алып чорыбызның энциклопедистлары Даламбер белән Лежандрга чаклы яшәгән күренекле геометрлар һәммәсе, башлангыч геометрик төшенчәләрне һәм аксиомаларны үзләренчә аңлатырга, камилләштерергә тырышып, ул мәсьәлә өстендә баш ватканнар.

Ягылмаган каминга борылып, Бартельс челеменең көлен койды. Аннары, үзен игътибар белән тыңлап утыручы Николайга карап, яңадан сөйләргә кереште:

— Аларның хезмәтләре төрле исемдә дөнья күргән: *«Яңартылган Евклид»*, *«Һәртөрле таплардан азат ителгән Евклид»*, *«Геометрия элементларын камилләштерү тәҗрибәсе...»* — дип санап китте ул.— Шуны да әйтим, минем данлыклы шәкертем Гаусс та геометрияне нигезләү проблемасы өстендә инде берничә ел баш вата. Ә менә Евклидтан уңышлырак беркемнең хәл итә алганы юк әле. Шуның өчен, бөек эллинга мәдхия җырлыйк та, юкны эзләп көчебезне әрәм итмик. Математиканың югарырак өлкәләренә мөрәҗәгать итү дөресрәк булмасмы?

Бартельс бер дә кызмыйча, тыныч кына сөйләде, фәкать аерым очракларда гына матур челемен селеккәләп алды.

Лобачевский профессорның сүзләреннән уйга калды. Ә бит Дидро: «Фән өлкәсе иксез-чиксез кырны хәтерләтә; ул кырның кайбер урыннары караңгы, кайбер урыннары яктыдыр сыман тоела. Безнең хезмәтләребез әнә шул якты җирләрне киңәйтә төшәргә яки басудагы утларны ишәйтергә тиеш», дигән. Лобачевский әнә шул сүзләрне әйтергә теләгән иде, ләкин дәшми калды: профессорны бүлдерергә батырчылык итмәде. Ә теге, креслода җәйлап утырган килеш, сөйләвен дәвам итте:

— Геометрия нигезләрен яңача үзгәртеп коруга юл эзләп газапланырга кирәкме икән? Әйтик, геометрияне бөтенләй әзер хәлендә, мең еллык байлыгы белән кабул итсәк, аннан безгә ни зыян? Безнең эрага кадәр 300 ел элек Евклид тарафыннан камил систе-

мага салынган бу фәннең җимешләре һәртөрле белемнең нигезе һәм бөтен төгәл фәннәрнең фундаменты булып китмәдемени? Бу фәннең дөреслегенә карата бездә шик тудымыни? Аны яңадан үзгәртеп корырга кирәклек булдымыни?

Профессорның сүзләренә колак салгач, Николайның күңелендә каршылыклы уй туды. «Евклид геометриясенең дөреслеген тормыш, чынбарлык үзе раслый шул. Евклид төзегән геометриянең нигезендә аңлаешсыз билгеләмәләр ятканга карап кына йортлар ишелми ич әле... Шулаен шулай да бит...»

— Профессор әфәнде,— диде ул, ниһаять, бөтен кыюлыгын бергә туплап,— Евклид «Башлангыч»ы, бик борынгы заманнан булуына да, математикада безнең күренекле уңышларыбызга да карамастан, хәзергәчә үзенең тумыштагы кимчелекләрен саклап килә. Ә бит нинди генә фән дә чуалчык төшенчәләрдән башланырга тиеш түгеллеккә кем генә күнмәс икән?..

— Әмма Евклид системасы бүгенге көнгә кадәр иң камил, иң җитлеккән математик абстракция буларак яшәп килә, сез мәсьәләнең шул ягын истән чыгармагыз...— диде Бартельс, егеткә дусларча елмаеп.

— Чиктән тыш абстракт булганга күрә үзенә реаль нигез таба алмаган да шул,— дип аңа каршы төште Лобачевский. Хәзер инде ул тартынмый иде, тавышы да ныгып китте.— Евклидтан соңгы егерме гасыр эчендә абстракт төшенчәләрнең һәм аксиомаларның ачыкланмый килүе һич тә ярый торган хәл түгел. Геометрия шуның аркасында катып калган да... Ә Гераклит нәрсә дигән? Һәммә нәрсә үзгәреп тора, дигән...

Лобачевский сөйләгәндә Бартельсның нечкә ирен кырыйларында яратып елмаю чагылды. Зур бер галимнең тәҗрибәсез геометрга, аның кызып китүенә шулай елмаеп каравы иде бу.

— Дөрес, фәннәр күктән иңмиләр, бәлки түземле рәвештә бик күпләрнең хезмәте нәтиҗәсендә үсәләр,— диде профессор, елмаюдан һаман туктамыйча.— Бүгенге көндә геометрия нигезләрендә фикер чуалышы иксез-чиксез зур, анысы да дөрес. Минем уйлавымча, ул буталчыклыкның сәбәбе — тәүге геометрик төшенчәләрнең төп башлангычын, асылын билгеләүгә төрлечә килүдә. Төшендереп бирәм: борынгы заманда геометрия җирне аерым өлешләргә бүлү ихтыяҗыннан килеп чыга. Ул бүлемнәрне озын баулар ярдәмендә һәм адым белән үлчәгәннәр. Менә шуңа күрә беренче гео-

метрлар тәүге нигез итеп *өлеш, озынлык* һәм *киңлекне* алганнар. Ә инде шулар ярдәмендә нокта, сызык һәм өслек төшенчәләрен китереп чыгарганнар.

— Ничек итеп? — дип түземсезләнеп сорап куйды Лобачевский.

— Ә менә ничек итеп: җир участокларының чикләрен төгәл итеп билгеләү нәтиҗәсендә *киңлеге булмаган озынлык,* ягъни *сызык* төшенчәсе барлыкка килә. Шундый ук борынгы геометрик төшенчәгә — *«нокта — өлешләре булмаган нәрсә»* дигән төшенчәгә — ниндидер җисемне яки җир участогын абстракт рәвештә кечерәйткәннән-кечерәйтә бару нәтиҗәсендә ирешкәннәр булса кирәк.

— Ләкин һәрбер чын җисем, никадәр генә кечкенә булмасын, тагын да вак өлешләрдән тора бит,— дип, Лобачевский бик дулкынланып каршы төште.— Җисемне бүлгәләүнең чиге юк.

Бартельс канәгатьлек белдереп баш какты: кызып китә торган холкы булса да, егет ярыйсы ук төпле күренә иде.

— Мин сезнең белән килешәм. Борынгы грек философы Анаксагор: «Бар нәрсә, никадәр генә бүлгәләсәң дә, югалмый», дигән.

— Ничек матур әйткән бит! Профессор әфәнде, сез рөхсәт итсәгез, мин моны язып та алыр идем,— дип, Лобачевский кесәсеннән тиз генә куен дәфтәрен чыгарды һәм борынгы философның сүзен теркәп куйды.

Куен дәфтәрен кесәсенә яшергәч, ул яңадан бәхәскә керепте:

— Шулай да баягы мәсьәләдә мин борынгы геометрлар хаклы булган дип уйлый алмыйм. Бит өлеш, озынлык һәм киңлек төшенчәләре турыдан-туры табигатьтән алынмаганнар, ә безнең фикер йөртүебез нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Димәк, аларны башлангыч төшенчәләр итеп алу хата була.

Бартельс, тагын бер мәртәбә баш кагып, өстәлдәге тәмәке тартмасына сузылды, аннары тәмәкене акрын гына челеменә тутыра башлады.

— Борынгы геометрлар китереп чыгарган төшенчәләрне, әлбәттә, камил дип атарга ярамый,— диде ул.— Ләкин бит ул чакта геометрия хәзерге кебек киң мәгънәдә кулланылмаган. Ә без үзебез борынгылардан кайсы җиребез белән аерылабыз? Геометрияне нигезләп бирүдә без мәсьәләне бөтенләй чуалтып ташладык.

Хәзер һәрбер бәйләнчек геометр тәүге нигез сыйфатында үз билгеләмәләрен уйлап чыгара. Кайсы өч үлчәүле пространство ди, кайсы хәрәкәт ди, ә кайберәүләр хәтта җисемнәрнең бер-беренә орынуы...

— Һәм аларның киселеше,— дип өстәде Лобачевский, гаҗәпләнүдән күзен шар кебек итеп.— Профессор әфәнде, минем фикерне сез каян белдегез?

— Кичә генә Корташевский әфәндедән хат алдым,— дип аңлатып бирде профессор, көләч йөз белән.— Кызыклы фикер. Әмма Декарт һәм Кантның да фикерләре игътибарга лаек. Универсаль математиканың атасы Декарт һәммәсен хәрәкәт нәтиҗәсе дип аңлата. Аның карашы Евклид «Башлангыч»ындагы өслек һәм сызык төшенчәләреннән күп мәртәбә гадирәк. «Дөнья турындагы трактат»ында ул болай ди.— Бартельс язу өстәленнән бик матур тышлы бер китап алып, каурый каләм кыстырган җирен ачты һәм укый башлады: — «...нокта хәрәкәтеннән сызык, ә сызык хәрәкәтеннән өслек туа...» Йә, хәзер нәрсә диярсез? Хәрәкәт төшенчәсе тәүге нигез булырга хаклы түгелмени? Төнлә йолдыз атылганны күргәнегез бардыр бит: утлы нокта күк йөзенә сызык сызып үтә. Фейерверкның якты эз калдырып шартлаганын күргәнегез юкмы?

— Нигә булмасын, бар, бар...— диде Лобачевский һәм, ракета белән булган хәлне хәтерләп, елмаеп куйды.— Минемчә дә, хәрәкәт — иң лаек тәүге төшенчә.

— Ә өч үлчәнешле пространство? Һәркемгә мәгълүм булганча, барлык табигый җисемнәрнең дә өч төрле үлчәнеше була. Шуннан килеп мондый нәтиҗә чыга.— Бартельс ачык килеш яткан китапны алып, сүзен сүзгә аерып укырга кереште: «Геометрия пространство үзенчәлекләрен билгеләүче фән ул...»

— Кем әйткән аны алай дип?

— Минем ватандашым Иммануил Кант әйткән, менә шушы китапның авторы.

Профессор, имән бармагы белән кирәкле битне тоткан килеш, китапның тышын күрсәтте.

Лобачевский анда «Саф гакылны тәнкыйтьләү» дигән сүзләрне укыды.

— Күргәнегезчә, һәркем үз фикерен дөрескә саный һәм нәкъ шуны өстен чыгарырга тырыша,— диде Бартельс.— Моның нәтиҗәсендә һәммә нәрсә буталып беткән, өйрәнергә теләүчеләр геометриянең нигезеннән үк

куркалар. Менә безнең акыл сатуыбыз нинди нәтиҗә бирә...

— Профессор әфәнде, һәртөрле белемнең нигезендә бер үк табигать ята, димәк, геометрияне нигезләүдә дә карашлар берлеге булырга тиеш,— диде Лобачевский, үз фикерен яклап.

Геометриянең тәүге проблемалары хакында Бартельс моңа кадәр дә күп мәртәбәләр сүз көрәштергән кеше. Бөтен сорауларга да аның башында җавап әзер. Ул, мөгаен, Евклид геометриясенең кимчелекләрен һәммә кешедән яхшырак белә. Ләкин үзенең җан тынычлыгын бозарга теләмичә, геометрияне үзенчә корудан баш тарткан иде.

— Яшь чакта үзем дә кешелек дөньясына геометриянең серләрен ачып бирергә хыялланган кеше,— дип ашыкмый гына сөйләп китте профессор, берәр минут чамасы дәшми утыргач.— Ләкин хәзер андый өметем юк инде. Математикларның күбесе шундый язмышка очрады. Хәзерге көндә безнең Германиядә яшәүче кайбер галимнәр, уңышка ирешә алмагач, үзләрен юату өчен, төгәл итеп исбатлау яки нигезләү фәкать тар акыл ияләренә генә хас нәрсә ул, диләр.

«Тапканнар икән!» дип уйлап алды Лобачевский, ләкин профессорга бөтенләй икенче нәрсәне әйтте:

— Профессор, миңа лекцияләрегезгә йөрергә рөхсәт итсәгезче,— диде ул.

— Әлбәттә, йөрерсез,— диде Бартельс һәм аяк өсте торып басты.— Корташевский әфәнде ялгышмаган: сез бик өметле укучы. Бүгенге сөйләшүне дәвам иттерербез дип ышанам.— Ул өстәлдә яткан китапны алып Лобачевскийга сузды.— Сезгә, һичшиксез, Монтюклның «Математика тарихы»н укып чыгарга кирәк.

Лобачевский, китап өчен рәхмәт әйтеп, саубуллашты да урамга чыкты. Бу сөйләшү аның башындагы бөтен уйларын чуалтып ташлады. Саф һавага чыккач, җиңел һәм рәхәт булып китте. Әйе, фикерләрең ничек кенә дөрес булып тоелмасын, нәтиҗә чыгарганда барыбер ашыгырга ярамый икән. Бартельс дөрес әйтә булса кирәк: нигез итеп җисемнәрнең бер-беренә орынуын алган кебек, өч үлчәнешле пространствоны да, шулай ук хәрәкәтне дә алырга мөмкин шул. Димәк, тагын күп төрле нигезләрнең булуы мөмкин. Әгәр шулай икән, геометрияне төзү мәсьәләсенә бер генә төрле караш була алмый. Димәк, фәннең нигезендә үк башбаштаклык һәм караңгылык хөкем сөрәчәк...

Николай урамдагы йортларны да күрмәде, шинель чабуын йолыккалаучы җилне дә тоймады, һаман әле йокыдан уянып җитә алмаган кеше сыман, онытылып атлавында булды. Менә ул университетны үтте, элек гимназистлар манежы булган уйсулыкны узып, балык базарына таба юнәлде.

Кичке эңгердә салкын тагы да көчәя төшеп, базарда сату итеп туңган халык тарала башлады. Мичкә белән су ташучы татар агайлар да якты күздә кайтып җитү ягын карадылар.

Лобачевский такта кибетләр һәм туң балык төялгән чаналар яныннан берничә тапкыр урап чыкты. Астрахань, Пермь, Байкал байларының приказчиклары, кичке якта балыкны ярты бәясенә булса да сатарга тырышып, урамнан узучыларга товарларын мактыйлар. Атлары белән балык китерергә ялланган толыплы абзыйлар, туңмас өчен, бер-берсенә дөп-дөп сугалар һәм көрәшәләр иде.

Кемдер Николайның иңбашына кагылды.

— Сезгә нәрсә булды, Лобачевский? Күпмедән бирле артыгыздан йөрим, күрмисез.

Николай дертләп куйды һәм туктап калды. Аның каршында өр-яңа студент шинеле кигән ят бер егет басып тора иде.

— Әнә теге почмакта чәйханә. Әйдәгез, кереп җылынабыз! — диде ул «о» авазын бераз суза төшеп һәм Лобачевскийны җиңеннән тартты.

Николай, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгән кебек кашын җыерып, таныш булмаган егеткә карады да аңа ияреп китте.

Чәйханәнең ишеге, салкыннан зарланган сыман, шыгырдап ачылды, өй җылысы битләренә килеп бәрелде. Шакраеп каткан шинель гүя хәзер генә тәнгә суык бөрки башлады, һәм Николай калтыранып куйды.

Аның юлдашы бусаганы атлап керүгә:

— Ике стакан чәй! — диде һәм: — Әйдә, әнә тегендә җылырак булыр,— дип, түргә үк узды.

Кыек якалы ак күлмәк кигән половой шунда ук аларның алдына өстәлгә берсе зур, берсе кечкенә чәйнекләр китереп куйды.

Николайның юлдашы сүзгә генә түгел, ә эшкә дә оста булып чыкты: тиз-тиз чәй агызып, чынаяктагы шикәрен болгатырга да тотынды. Уналты яшьләрдәге бу егет шактый озын буйлы, киң җилкәле, таза гәүдә-

ле иде. Пәке белән кырдырган түгәрәк башын бик горур тота. Кара тутлы йөзендә бераз шадрасы да бар. Аның кысык күзе куе каш астына яшеренгән төсле тоела. Нечкә ирене бер караганда кырыс, икенче караганда балаларча шук кыяфәт биреп, алга чыгып торган иягенә бер дә туры килми иде. Лобачевский аны бер күрүдә ошатты.

— Сез мине җылыга бик вакытлы алып кердегез,— диде Николай һәм кинәт сүзен икенчегә борды: — Туктагыз әле, сез үзегез кем буласыз соң? Мине каян беләсез?

Моңа җавап итеп егет, дусларча елмаеп, кулын сузды.

— Әйдәгез, алай булгач — танышыйк. Симонов булам мин. Иван Симонов *. Астраханьнан килдем. Өч ай буена мондагы гимназиядә университетка хәзерләндем. Бүгенге тантаналы акт вакытында студент иттеләр. Шинелемне күрәсезме, әле иңнәре дә йомшарып җитмәгән.

— Ә мине каян беләсез? — диде Николай, соравын кабатлап.

— Зур сер түгел ул,— диде Симонов, көлемсерәп.— Таныш студентлар күрсәткән иде. Сезне математика белән дә, химия белән дә нык мавыга дип сөйләделәр. Яңа һөнәрегез өчен карцерда өч көн утыргансыз, диләр, дөресме шул?

Николай дәшмәде. Тик бераздан гына ул ашыкмыйча җавап бирде.

— Теләк — бер нәрсә, ә аңа ирешү — башка. Әйтик, математика белән кызыксынган һәрбер кеше үзен геометр дип атый алмый бит... Һәрбер пиротехник та чын-чынлап химик була алмый,— диде ул, елмаеп.— Ә ракета өчен утырып чыктым. Анысы дөрес.

Егетләр көлешеп алдылар.

Яңа танышы янында Николай үзен бик иркен тота башлады; ул чын күңелдән аңа рәхмәт әйтеп:

— Сез булмасагыз, катып үләр идем әле,— диде.

— Шулай шул менә! — диде моңа каршы Симонов.— Геометриядән баш тартырга уйламагыз да. Лә-

---

* Соңыннан Симонов атаклы галим булып китә. Антарктиданы ача. Казанда астрономияне өйрәнү эшен башлап җибәрә. Дөнья күләмендә билгеле күп кенә гыйльми җәмгыятьләрнең һәм уку йортларының почетлы члены итеп сайлана. Лобачевскийдан соң Казан университетының ректоры була.

кин ул абстракт фән белән мин дуслашып китмәм төсле. Чынбарлык якын минем күңелгә.

Симонов стаканын читкә этәрде дә, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, маңгаеннан тирен сөртте.

— Табигатьне бик яратам,— диде ул, сүзен дәвам итеп.— Гимназиядә чакны физика белән мавыгып киткән идем. Ахырга таба Галәмнең төзелеше, аның аерым кисәкләренең үзенчәлеге белән кызыксына башладым. Боларның һәммәсен астрономия аркылы белергә мөмкин. Шул фәнне ныклап өйрәнү өчен менә монда килдем, университетка кердем...

Ишек кабат шыгырдап ачылды. Чәйханәгә салкыннан бөрешкән кешеләр кереп тулды. Лобачевский, урындыктан торып, яңа танышына дәртләнеп кулын сузды.

— Без икебез дә бертөрлерәк фикер йөртәбез, ахры. Әйдәгез дуслашыйк... Хәзер монда сөйләшерлек түгел, тизрәк чыгып китик.

Университетка кайтып җиткәнче, алар бер-берсенә дусларча «син» дип эндәшү белән генә калмадылар, бәлки һәркайсы үзенең теләкләре һәм уңышсызлыкка очраулары турында сөйләп өлгерде. Үзара ярдәмләшергә вәгъдә биреп аерылдылар. Дустының кулын кысып, Николай бер төрле шатлык хисе кичереп:

— Көн саен күрешәбез, димәк? Иртәгә сәгать дүрттә миңа киләсең,— диде.

— Төп-төгәл дүрттә киләчәкмен,— диде Симонов та шат күңел белән.

Ә икенче көнне Николай бик каты башы авыртып уянды. Тәне ут яна, тамагы кипкән иде.

— Башым!.. Башым!.. Су!.. Су!..— диде ул, үзенүзе белештермичә ыңгырашып.

Саташудан туктап, күзен ачып җибәрсә — баш очында, мендәрен рәтләп, энесе басып тора.

— Уяндыңмыни? — диде Алексей, борчулы кыяфәт белән.— Син инде баядан бирле ыңгырашып ятасың, уяна гына алмыйсың. Калдырып китәргә курыктым. Хәзер су алып киләм.

Бүлмәгә надзиратель керде. Авыруның башын тотып карагач, хәзер үк врач Фуксны чакырырга кушты.

Таныш исемне ишеткәч, Николайга бераз җиңелрәк булган төсле тоелды.

1806 елның азагыннан башлап гимназиянең һәм университетның врачы булып шәһәрәте Казаннан читкә дә таралган медицина докторы Карл Федорович

Фукс эшләде. Фәнгә мөкиббән киткән булуына карамастан, кешеләр белән аралашучан, киң күңелле ул руслашкан немецны студентлар бик яраталар иде.

Аның тәэсиренә бирелеп, бервакыт Лобачевский да табигать белеме белән мавыгып китеп, кичләрен озаклап микроскоп янында уздыргалады...

Менә ишектә Фукс күренде. Ягымлы елмаеп, ул авыруның кровате янына килде, ниндидер юату сүзләре әйтеп, башыннан сыйпады. Аннары жилет кесәсеннән сәгать чыгарып, йөрәк тибешен санады, тамагын карады. Боларның барын эшләп бетергәч:

— Салкын тидергәнсез, дустым,— диде.— Дару эчеп кенә, урында ятарга туры килер. Югыйсә авыруыгызның икенче төс алуы ихтимал...

Доктор язып биргән дару кебек эче, күңелсез дүрт көн бик озакка сузылды. Авырудан бигрәк эшсез ятуы авыр иде Николайга. Иртәнге якта кәефе бераз гына яхшырган кебек тоелды, һәм ул шунда ук үзенә эш тапты.

Көн бик аяз булып, кояш үзенең алтын нурларын көлтә-көлтә итеп бүлмәгә койды. Николай сәгатьләр буе шул нурларда очып йөргән вак тузан бөртекләрен күзәтеп ятты. Шул чаклы тәртипсез очарлар икән! Җәйге җылы кичтә черкиләр очканнан бер дә ким түгел. Микроскоптан караганда су тамчысындагы чәчәк тузаны да әнә шулай бөтерелә бит. Шул чаклы тынгысыз булырлар икән! Нәрсәдән болай хәрәкәтләнәләр соң алар? Тузан бөртекләрен әле бер якка, әле икенче якка очарга, ниндидер күзгә күренмәгән киртәгә килеп бәрелгән сыман, юнәлешне кисәк кенә үзгәртергә нәрсә мәҗбүр итә? Тикмәгә алай очмый торганнардыр, моның берәр сере булырга тиеш. Тузан нәрсәдән барлыкка килә? Нәрсә ул тузан? Ком һәм таш кебек әйберләрнең вак кисәкчекләре. Ләкин бит ком да, таш та һавадан авыррак, алар хәтта суда да баталар. Ә ни өчен аларның вак кисәкчекләре бер түбән төшә, бер югары менә, әле уңга, әле сулга бертуктаусыз очып тора! Вак булгангамы? Юк, аннан түгел. Әйбернең зурлыгына-кечкенәлегенә карап, аның чагыштырма авырлыгы үзгәрми бит...

Николай шулай уйланып ятканда, аның хәлен белергә Симонов керде. Салкыннан бите алсуланган егет, килеп керүгә, елмаеп исәнләште һәм кроватька утырырга рөхсәт сорады.

— Утыр, утыр,— диде Николай.— Моннан яхшы-

рак күренер... Әнә кара әле, кояш нурында вак кына тузан бөртекләре ничек биешәләр!

— Биешсәләр, ни була?! — дип, гаҗәпләнеп җавап кайтарды Симонов һәм, күзен кысып, дусты күрсәткән якка текәлде.— Саныйсыңмы әллә син аларны? Монда тузан җитәрлек!..

— Мине башка мәсьәлә кызыксындыра,— диде Николай, терсәгенә калкып.— Синеңчә, Ваня, ул тузан ни өчен шулай хәрәкәткә килә?

— Әнә кая барасың икән! — Симонов дустының соравына җитди карамаганы өчен оялып куйды һәм бераз уйлап торгач: — Минемчә, һаваның бервакытта да тыныч тормавыннан киләдер,— дип җавап бирде.— Салкын һәм җылы агым бер-берсенә каршы агылганда тузан бөртекләрен дә хәрәкәткә китерә.

— Юк! — диде Николай.— Һава агымы һәрвакыт шактый зур күләмдә була һәм тузанны бер юнәлештә генә ияртеп алып китә. Салих бабайның мич якканын карап торганым бар. Эссе мич янында тәмәке төтене өскә күтәрелә. Салкын тәрәзә янында, киресенчә, аска төшә. Тузан бөртекләре бөтенләй башкача хәрәкәтләнә бит: берсе өскә менә, шуның күршесе үк түбән төшә, гомумән, төрлесе төрле юнәлештә оча.

— Һем...— диде Симонов, уйга калып.— Димәк, тузан бөртекләренең кайсы кая очуына һава агымы бер дә гаепле түгел. Син дөрес әйтәсең, болай булгач...

— Дөрес әйткәннән ни файда? Тузан бөртекләрен бер яктан икенче якка ыргытучы көчнең нәрсә икәнен белмим бит.

— Николай, син хәзергә куеп тор аны, уйлама аның турында. Болай да башың авырта. Уйлама.

Лобачевский ачуланып башын чайкады.

— Ничек уйламыйсың ди инде? Тузан бөртекләренең хәрәкәтләнүендә билгеле бер сәбәп, ачык бер мәгънә булырга тиеш! Галәм төзелеше турындагы фәндәге кебек, бу очракта да шул ук төп факторлар белән эш итәбез: пространство, җисем һәм хәрәкәт. Йолдыз йөрешенең билгеле бер законы булган кебек...

— Менә искә төшердең! — дип кинәт кычкырып җибәрде Симонов, дустының уйларын бүлдерергә теләп. Китаплары арасыннан зур форматлы бер брошюра тартып чыгарды.— Гимназия китапханәсеннән профессор Тимофей Осиповскийның бик кызыклы хезмәтен табып алдым менә...

— Осиповскийның, дисеңме? Кая, Ваня, тизрәк бир әле! — Николай түземсезләнеп кулын сузды.— Геометрия дәреслеге язган кеше булырга тиеш ул... «Пространство һәм вакыт...» Харьков университетында 1807 елның 30 августында булган тантаналы җыелышта сөйләгән нотык...» Пространство турында ничек дип яза икән, шуны белергә иде.

— Ул Германиянең иң яңа философларыннан саналган Кантка каршы бик кискен сүзләр әйтә.

— Кантка каршы, дисеңме? Профессор Бартельс аның «Саф акылны тәнкыйтьләү» дигән хезмәтенә карата уңай фикер әйткән иде.

— Нәкъ үзе! Осиповский шул хезмәткә бәйләнгән дә инде.

Ләкин шул чак аларның сүзләре өзелде. Доктор Фуксны ияртеп, директор Яковкин атылып килеп керде. Йөзендә ясалма елмаю. Бусаганы атлауга ул:

— Афәрин, афәрин! — дип үзенең соклануын белдерде.— Дуслыкны яратам мин. Авыруны иптәшләре ташламаганга, мин бик канәгать.

Симонов аны күреп торып басты. Яковкин аңа, әйдә утыра бир, дигән сыман итеп, кул гына селтәде һәм үзе дә кроватька килеп утырды. Лобачевскийга икенче кырыйга шуышырга туры килде.

— Дустым, сезнең организмыгыз йомшак,— дип акыл өйрәтергә кереште профессор-директор.— Организмыгызны төрле зарарлы нәрсәләрдән сакларга кирәк. Бөтенләй төсегез качкан бит! Шул чаклы ябыгырга ярыймыни?

Лобачевский:

— Директор әфәнде, мин...— дип сүзен башларга өлгермәде, Яковкин, шунда ук аны бүлдереп:

— Минем ишетүемә караганда, сез күп укыйсыз булса кирәк,— диде.— Авыру өчен китап дошман ул. Барыннан да бигрәк, китап уку белән артык мавыгып китеп, профессор Бартельс лекцияләренә йөри алмаячаксыз. Ә ул лекцияләрне калдырырга һич ярамый.

Николайның күзе дүрт булды. Нәрсә сөйли ул? Бартельс лекцияләренә йөрергә рөхсәт бирмәүче шул үзе түгелмени? Шуның аркасында бер ел әрәм китмәдемени?

Яковкинның очлы елтыр күзе Николай күзе белән очрашты, егетнең сүзсез сорауларыннан куркып читкә борылды. Ләкин үзен бик тиз кулга алды.

— Сәламәтләнгәч тә, һәммә лекцияләргә йөрергә

тырышыгыз,— диде ул, урыныннан кузгалып.— Хөрмәтле профессорыбыз Бартельсның лекцияләрен бер дә калдырмагыз. Ә хәзер сәламәтлегегез турында кайгыртырга миңа сүз бирегез.

Николай нәрсә диярге белмичә, аптыраган кыяфәт белән:

— Сүз бирәм,— дип әйткәнен үзе дә сизми калды.

— Менә шулай кирәк тә. Хушыгыз! — диде Яковкин һәм, елмаеп кулын болгый-болгый, Фуксны ияртеп, чыгып та китте.

Егетләр, бер-берсенә карашып, шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Өч көннән соң Николай беренче мәртәбә Бартельс лекциясен тыңлады.

Профессор сферик астрономиядә һәм математик географиядә тригонометриянең катнашы турында сөйләде. Тригонометрик функцияләрнең төп үзенчәлекләрен геодезик һәм астрономик исәпләүдә кулланыны аңлатты. Кечкенә вариацияләрне тикшерү өчен дифференциаль исәпләүнең башлангыч элементларын телгә алды һәм логарифмик функцияләргә дә кагылды. Студентларга, шулай итеп, математиканың төрле тармаклары бергә тоташканлыгы, бер бөтен булуы аңлашылды. Аудитория тып-тын иде.

Лобачевский профессорның һәр сүзен игътибар белән тыңлады. Бер ел буена Бартельс лекцияләренә йөрмичә, күпме нәрсәне белми мәхрүм калды бит!

— Барыбер куып җитәчәкмен! — диде ул, дәфтәренә профессор сөйләгәнне яза-яза.

Бартельс лекцияләрендә Николай эчке бәйләнешнең геометрия өчен генә түгел, гомумән, математика өчен хас бернәрсә икәнлегенә төшенде. Бу бәйләнеш нәтиҗәсендә математиканың төрле өлкәләре үзара катнашып, аралашып бетәләр икән.

Әнә шул ачыш Бартельс лекцияләренә булган игътибарны көчәйтте. Ә киләчәктә, яңа геометрия ачканда, моның никадәр зур файдасы тиячәген Лобачевский, әлбәттә, алдан белә алмый иде.

Көннәр берсеннән-берсе тизрәк үттеләр. Николай хәтта яз җиткәнен дә сизми калды. Ул бөтен барлыгы белән югары математикага бирелде, теориягә торган саен эчкәрерәк керә барды. Бартельс лекцияләреннән тыш, моңа тагын икенче бер нәрсәнең дә тәэсире булды.

Лобачевский авырып алганнан соң күп тә үтмәде, кичке гыйбадәткә керер алдыннан, студентларны көт-

мәгәндә генә утырыш залына җыеп алдылар. Алар кергәндә, профессорлар һәм укытучылар залда утыралар иде инде. Яковкин Петербургтан попечитель хәзрәтләреннән хат килгәнлеген игълан итте һәм тантаналы тавыш белән Румовский хатыннан шушы сүзләрне кычкырып укып чыкты:

— «Студентлар һәм кандидатлар арасыннан математика, физика, философия фәннәре белән шөгыльләнергә хәзерләнүчеләрнең күбрәк булуын теләр идем...»

Кемдер Лобачевскийның кулын каты итеп кысты. Борылып караган иде — Симонов икән.

— Яковкин ни өчен синең сәламәтлегең турында кайгыртканны, Бартельс лекцияләренә йөрергә рөхсәт иткәнне сизденме инде? — диде ул, көлеп.

Лобачевский баш какты: ул моны төшенгән иде.

Ялагай профессор-директорның кыланышларын дуслар бик дөрес аңладылар; Румовскийдан хат килеп төшкәч, аның коты алынган иде.

— Шул әшәке студентны нигә математикадан җибәрдең, дип бәйләнәчәк карт. Медицинага авышты, дип җитмәсә тагын үзем үк хәбәр итеп торам бит. Ишәк түгел диген инде, ә!

Хатаны төзәтеп, эшне җайга салгач, хәзер инде борчылырга урын калмады. Киресенчә, Лобачевскийны химиядән йолкып алып, математика фәннәренә кайтардым дип хәбәр итәргә мөмкин...

Тиздән ул субинспектор Кондырев аша аеруча зур уңыш казанган студентлар турында Советка рапорт бирдерде. Исемлектә Николай Лобачевский да бар иде. Кондырев гәрчә аңа карата, үзенә чөнечкеле эпиграммалар чыгарган өчен, күңелендә үч сакласа да, директорга каршы килә алмады һәм рапортка түбәндәгечә язарга мәҗбүр булды:

«Тулы бер елны исәпкә алып әйткәндә, иң яхшы тәртип үрнәкләре күрсәткән Николай Лобачевский, Доримедонт Самсонов, Алексей Пятов... начальствога хәбәр итәргә лаеклы дип табыла...»

Шуннан чыгып Совет үзенең карарында болай язды:

«Бу хакта протоколга теркәргә һәм, студентларны җыйнап, уңыш казанучыларны Совет каршында телгә алырга, соңра бу хакта попечитель һәм кавалер галиҗәнабларына махсус рапорт җибәреп хәбәр итәргә».

Румовскийның шикләнүләрен бетерү өчен, Яковкин әле моның белән генә дә чикләнмәде, бәлки «тәртибе өчен бүләкләү рәвешендә» Николай Лобачевскийны камера студенты итеп билгеләтте; инструкция буенча, камера студенты «йокы бүлмәләрендә иптәшләренең үзләрен ничек тотуларын һәм фән белән шөгыльләнүгә вакытны дөрес бүлү-бүлмәүләрен күзәтергә» тиеш иде.

Ләкин Николай начальствога ярарга тырышмады. Иптәшләренә карата ул һаман турылыклы һәм эчкерсез мөгамәләдә калды. Аның каравы, камера студенты дигән исем Николайга аена биш сум жалованье китерде. Зур байлык белән укымаучы Лобачевскийларга бу акча, әлбәттә, ярап куйды.

Рәсми карар булуга, Николай үзенең шатлыгын белдерү өчен әнисенә хат язарга утырды.

«Сөекле әнием,— дип язды ул.— Тиздән жалованье алачакмын. Ул акчаны ничек бүләрмен дигәндә, ике сумын сезгә җибәрермен, бер бик кирәкле китап, тагын кечкенә генә бүләк алырга уйлыйм... Кемгә икәнен сезгә әйтергә кыюлыгым җитми... Ләкин сез мине яхшы беләсез, начар юлга кереп китмәячәгемә ышанырсыз...»

Николай, хатны читкә куеп, уйга калды. Августның бер җылы айлы кичен хәтерләде. Студентлар кичке аштан соң университетның ишегалдына караган киң болдырына җыелдылар. Арада берсенең, Гроздовскийның, кулында кларнет чагылып китте. Ул бик матур итеп һәркемгә таныш халык көен уйнарга тотынды, иптәшләре Ибраһимов сүзләренә таныш җырны җырлап җибәрделәр:

Во поле березонька стояла,
Во поле березонька стояла.
Люли, люли, стояла,
Люли, люли, стояла...

Барысы да җырладылар. Университетның үз шагыйре Панаев, хыялга бирелергә яратучан егет, бераз уйланыбрак җырлады; Николай үз әнисенең яңгыравык тавышын да башкалардан аерды.

Кинәт өске катта Яковкин квартирасының тәрәзәсе ачылды. Николай ирексездән башын күтәрде һәм ай яктысында директорның зур гәүдәсен күрде. Мөгаен, айлы матур кич һәм күмәк җыр хәтта аңа да тәэсир иткәндер. Шул вакыт Яковкин белән янәшә

тагын ике кеше пәйда булды. Болары зифа буйлы кызлар иде. Алар түбән үк иелделәр һәм... студентлар хорына кушылып җырлый башладылар:

В чистом кудрява бушевала,
В тереме девица горевала.
Люли, люли, горевала,
Люли, люли, горевала...

Николай тәрәзәгә якынрак килде. Кызлар җыр белән мавыгып китеп, аны күрмәделәр. Яп-яшь кызлар иде әле алар: Парашасы уналтыда, Аннасы унбиштә. Аларның хәтфә тавышлары Николайның күңелендә ниндидер кылны чиртеп китте һәм бу инде сихри төнне тагын да тылсымлырак итте. Башка студентлар да, сихерләнеп, тәрәзәгә карап җырлый башладылар. Яковкинга бу хәл ошамады: ул шартлатып тәрәзәсен ябып куйды. Николай бераз вакыт канәфер куагы күләгәсендә басып торды һәм сиздермичә генә капкадан чыкты. Урамда да әле ул хорның:

Люли, люли, горевала,
Люли, люли, горевала,—

дип җырлаганын ишетте. Ләкин, кызларның йомшак тавышы булмагач, хорның аңа һич тә мәгънәсе калмады.

Йокыга талган шәһәр урамнары буйлап шактый йөреп, Николай торагына төн уртасында гына кайтты һәм ачык тәрәзәдән бүлмәгә керде.

Ә иртән уянгач, энесе Алексей:

— Тәрәзә сиңа үзе ачылып китте дисеңмени? Төн уртасына чаклы кайтмаячагыңны сиздем инде мин,— диде.

Николайга бу сәер тоелды, һәм ул:

— Нәрсәдән чыгып син алай уйладың әле? — дип сорады.

Энесе:

— Ике чибәрнең җырлавыннан тәэсирләнүеңне күрмәдеммени? — диде, көлемсерәп.

— Сөйләмә юкны,— дип, абый кеше аның сүзен өзде, тик үзенең кызаруын сизеп, бик нык гарьләнде.— Мин бит болай гына...

— Болай гына түгел дигән кеше юк бит әле сиңа,— дип, энесе һаман канга тоз салуын дәвам иттерде.

Абый кеше тизрәк сөлгене эләктерде дә юыну бүлмәсенә йөгерде. Үзе дә ныклап төшенеп җитмәгән тойгыларын Алексейның аңлавы аны шаккатырды.

...Чынлап та шулай икән шул. Менә хәзер, хат язып утырганда, ул моны икърар итәргә мәҗбүр булды. Әнисенә яза башлаган хатны язып бетермәвен күреп, авыр көрсенде. Каләме кулында булса да, күңеле үткәнгә кайтты...

Ә бер көнне ул зур бәхеткә иреште: аны кызларның икесе белән дә таныштырдылар. Хәзер инде ул аларны урамда күргән саен баш иеп исәнләшә. Кызлар да исәнләшәләр. Ә берсе, Анна исемлесе, кызарган да төсле тоела.

Ниһаять, ул Яковкинның олы кызлары өчен өйләрендә яки дачада үткәрә торган кичәләргә катнашырга рөхсәт алды.

Аларга еш очрашырга мөмкинлек юк, ә инде җиткән кызлы өйгә һәрвакыт кереп йөрергә фәкать туган-тумачаның яки вәгъдәләшкән егетнең генә хакы бар иде. Ул исә аларга туган-тумача да, шулай ук... вәгъдәләшкән егет тә түгел. Фәкыйрь студент, разночинец башы белән Яковкиннан фатиха ала алмаячак. Тик инде Анна үзе...

Кинәт кабынып киткән бу сөю хисе һәммә нәрсәне үзгәртеп ташлады. Моңа кадәр Николай башы-аягы белән фәнгә чумган, бөтен буш вакытын шуңа багышлый иде. Ә менә беренче мәхәббәт хисе тугач, күңеленә рәхәт булып китте, куен дәфтәрендә, математик формулалар белән янәшә... шигырьләр дә урын алды.

Бу турыда көн-төн уйларга мөмкин иде. Тик менә башлаган хатны бетерергә кирәк. Николай бөдрә чәчен сыйпап алды да яңадан каләменә тотынды: кайбер эшләрне эшләмичә калырга ярамый.

Әнисенә язып бетергәч, ул Корташевскийга яза башлады. Университет тормышындагы яңалыклар белән таныштырды. Воздвиженский урамда гимназия өчен төзелә торган йортның тиздән эше бетәчәген һәм шуннан соң университетның мөстәкыйль рәвештә яшәячәген белеп торуы Григорий Иванович өчен кызык түгелмени?

«Яңа билгеләнгән технология адъюнкты Федор Христианович Вуттиг безнең университет галимнәреннән беренче булып, андагы минераль байлыкларны һәм техника эшләрен өйрәнү максаты белән, җәй һәм көз айларын Уралда йөреп кайтты. Ул кайтканчы, 1809 елның 26 октябрендә, химия классына нигез салучы кадерлебез Федор Леонтьевич Эвест вафат булды. Химиядән хәзергә лекция укучы юк, ә лаборатория әйбер-

ләрен вакытлыча миңа кабул итеп торырга куштылар», дип язды Николай.

«Университетта типография ачылуы хакында Сезгә хәбәр иткән идем шикелле. Күптән түгел генә типографиянең беренче карлыгачы — адъюнкт Ибраһим Хәлфиннең «Татар теле әлифбасы һәм грамматикасы» дигән китабы чыкты. Беренче эш хакымнан ук шул китапны сатып алып татар телен яхшылабрак өйрәнәчәкмен.

Тагын нинди яңалык бар икән? Беткәндер инде. Әйе, онытып җибәргәнмен: Яковкин әфәнде орден алуын, ягъни дүртенче дәрәҗә Изге Владимир тәресе белән бүләкләнүен бик зур тантанага әйләндерде...»

Николайның кулына тоткан каләме һавада асылынып калды. Студентлар арасында телдән телгә күчеп йөртелгән эпиграмма кинәт хәтеренә килеп төште:

Господи Иисусе Христе!
Спас ты вора на кресте.
Теперь тебе другое горе —
Спасти крест на воре *.

Юк, моны язарга ярамый. Гәрчә Яковкин шуннан башкага лаек булмаса да, Анна бар бит әле...

## *Җиденче бүлек*

### 1

Язгы кичләрнең берсендә Лобачевский дворянское собраниегә балга барырга чакыргач, Симонов гаҗәпкә калды.

Гаҗәпләнмәслек тә түгел: моңа кадәр Николайның

---

* Тәредәге каракны
Коткаргансың, таңрем!
Хәзер инде коткар син
Карактагы тәрене.
(Шагыйрь Нигъмәт Ибраһимов язган эпиграмма.— *Җ. Т.*)

андый җиргә аяк атлаганы юк, ул фәкать шәһәр читенә генә чыгып йөрергә гадәтләнгән иде. Бик сирәк очракларда гына дуслары белән студентлар кичәсенә яки танцыга керә торган иде.

Ә менә Анна белән танышу барын да үзгәртте. Ул, акча түләп, надзиратель Мейснер үткәргән танцы дәресләренә йөри башлады. Анда ул салмак менуэт белән катлаулы контрдансны тиз үзләштерде һәм җитез полька-кадрильне дә җиңел биергә өйрәнде. Баллар, маскарадлар күңелле бер нәрсәгә әверелделәр. Ә бүген ул балга Анна чакырганга бара.

Дворянское собрание Воскресенский урамда фабрикант Дрябловның ике катлы пулатына урнашкан. Кайчандыр ул йортка Екатерина II туктаган булган һәм, Казан дворяннарының кабул итүеннән канәгатьлеген белдерү өчен, үзен Казанның беренче алпавыты дип атаган. Таш пулатның тәрәзәләреннән матур булып киң Идел һәм шәһәрнең түбәнгә җәелгән бистәсе күренә.

Арыслан башына охшатып эшләнгән җиз ишек тоткасына Николай зур дулкынлану белән тотынды. Егетләр киң һәм иркен вестибюльгә керделәр. Түшәмгә бавыз шәмнәр куелган авыр люстра асылган. Чишенү бүлмәсендә алар Владимир Панаевны очраттылар. Аның Парашага — Яковкинның олы кызына гашыйк булуын бөтен университет белә иде.

— Николай! — дип куйды ул, чәчен рәтләп торган җирдән, көзгедә иптәшләрен күреп.— Синең монда килүеңне ничек аңларга? Әллә бүген кояш икенче яктан чыктымы?

— Нинди генә кояш чыкты әле! — диде Симонов, күз кысып, һәм, аларның икесен дә култыклап, киң баскычтан икенче катка алып менеп китте. Баскычның буеннан-буена диярлек кызларын көтеп торучы егетләр тезелгән. Кайсының өстендә фрак, ә кайсылары офицер мундиры кигән.

Иркен зур залда инде пар-пар булып контрданс биергә тезелә башладылар. Ялтыравык төймәле кара-су-зәңгәр мундирлар кигән, кара муар тасма белән шпагалар таккан өч студент килеп керүгә, кызларның күзе шул якка юнәлде. Николай үзенең ябык төз гәүдәсе һәм куе бөдрә чәче белән иптәшләреннән аерылып тора иде.

Анна күренмәде. Әмма тиздән апасы белән алар да килеп җиттеләр. Мондый җиргә үзләре генә йөрер-

гә ярамаганлыктан, әдәп саклау йөзеннән, бер туталарын да ияртеп килгәннәр. Алар артыннан ук диярлек субинспектор Кондырев керде. Аннаның сул кулында үзе бүләк итеп биргән җилпәзәне күреп, Николайның йөзенә елмаю чыкты. Ә кыз исә, Лобачевскийны күргәч, кызарынып, аска карады.

Нәкъ шул минутта скрипкалар чыңлап куйды да контрданс башланып китте. Владимир мәгънәле итеп Николайга күз кысты, һәм алар, бер-берсен аңлап, кызларга табан юнәлделәр. Анна кулындагы җилпәзә дерелдәп куйган сыман булды. Биючеләргә мәһабәт ике пар килеп кушылды.

Кинәт Петр Кондырев профессор-директорның кызлары студентлар белән биегәнне күреп алды. Ә инде Лобачевскийны таныгач, бөтенләй кәефе кырылды. «Ничек итеп оялмыйча директор кызы белән биергә кирәк! Җитмәсә бит әле аның, субинспектор Кондыревның, күз алдында!..»

Ул озак уйлап тормады, кичәне ташлап, университетка чапты. Яковкинның кабинетында ут күренде, һәм ул, икенче катка менеп, курка-курка гына, ишек шакыды.

— Илья Федорович, гафу итегез...

— Килдегезме, бик шәп! — диде Яковкин, ярдәмчесенең сүзен бүлеп.— Менә мин полицмейстер Симонов әфәндегә хат яздым. Ничек чыкты икән, укыгыз әле.

Кондырев гаҗәпләнеп хатны алды, яктыга килде һәм укырга кереште.

— *«Хөрмәтле әфәндем Григорий Егорович!*

*Кичә, 1810 елның 22 апрелендә, Казан университетында укучы бертуган Лобачевскийлар — аларның олысына, ягъни Николайга, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, докторлар аеруча саф һавада йөрергә тәкъдим итәләр — башта Неялов паркында йөреп, Болхов паркы аша урамга чыгарга теләгәннәр. Ләкин ниндидер чит кешеләр, Болхов паркында йөрү тыела дип, аларга килеп бәйләнгәннәр. Үзләрен сторож дип атаган ул кешеләр нахакка Лобачевскийларга карата тупас мөгамәлә кылганнар, ягъни аларның студент икәнлекләрен белә торып, башта Сез галиҗәнаб каршына, соңра полициягә барырга мәҗбүр иткәннәр. Студентларның берсе дә беркемгә. бернинди начарлык эшләмәгән, шулай булуга карамастан, аларны полициягә илткәннәр...»*

Укый-укый, субинспектор зәһәреннән буыла башлады. Шул әдәп белмәүче малайны акылга утыртырга торганда, директор, үч иткәндәй, аны яклап хат яза. Нәрсәдән булыр икән бу? Анна сүзе белән йөрмидер бит?

Аның уйларын Яковкин бүлде:

— Укыгыз!

Субинспектор укуын дәвам итте:

— *«Студентларга карата мондый тупас мөгамәлә күрсәтү падишаһ хәзрәтләре тарафыннан грамота вә устав илә Казан университетына бирелгән хокукларга каршы килү була...»*

Яковкин, ярдәмчесе хатны укып бетергәч, аңа:

— Иртәгә иртүк полицмейстерның үз кулына тапшырырсыз,— диде.— Ә хәзер китәргә мөмкин... Туктагыз, миңа нәрсәдер әйтергә теләгән идегез түгелме?

Кондырев ничек итеп сүз башларга белмәде.

— Студент Лобачевский пансионнан китеп йөрергә сездән рөхсәт алдымы? — диде ул.— Моннан ярты сәгать элек мин аны дворянское собраниедә күрдем...

— Һем... Миңа кергән иде шикелле,— диде Яковкин, турыдан-туры җавап бирергә теләмичә.

Субинспектор бөтенләй югалып калды. Иңнәрен эчкә тартып, сүзне ничек итеп икенче нәрсәгә күчерергә белмичә, бер урында басып торды. Сүз таба алмагач, башын иеп саубуллашты да чыгып китте.

Яковкин, чиста кәгазь алып, попечительгә хат яза башлады.

«Совет һәм университет эшләре бүгенге көнгәчә, ходайга шөкер, яхшы бара, иминлек хөкем сөрә».

Имтиханнар алдыннан урнашкан тынлык, чыннан да, профессор-директорны сөендерә иде, һәм ул, язуын бүлеп, карага буялган кулы белән чукынып алды. Аннары язуын дәвам итте:

«Астрономия профессоры Литтров әфәнде исән-имин Казанга килеп җитте. Мин аны вакытлыча Великопольский йортына урнаштырдым. Аның үтенечен искә алып, өч укучы билгеләдем: Лобачевскийны, Линдегренны һәм Симоновны. Аннан тыш, ул тагын кайбер инструментлар сатып алу мәсьәләсен Сез галиҗәнаб каршында кузгатырга дигән иде...»

Яковкинның каләме әле шуннан соң да озак кыштырдады. Урынында ныгып калу өчен директор ялган вәгъдәләр бирүдән тартынмады. Ниһаять, эшеннән

канәгатьләнеп, кабинет ишеген бикләде дә, студентларның йокы бүлмәләренә күз салу теләге белән, коридор буйлап китте.

Кондырев дөрес әләкләгән: Николай Лобачевскийның кровате буш иде. Директор, башын чайкап, ишеккә юнәлгәндә, коридордан аяк тавышлары ишетеп алды. Ул, шәмен кулы белән ышыклап, читкәрәк китеп басты.

Кичәнең тәэсиреннән сихерләнгән Николай сагаюдан һәм аны-моны уйлаудан ерак иде. Балга барырга Анна чакырды. Ул аның белән бик озак биеде. Югары катлау гадәтләре рөхсәт иткәнгә караганда артыграк биеде. Алар сөйләшә-сөйләшә биеделәр. Тик нәрсә турында сөйләшкәннәрен генә Николай хәтерләми. Хәер, моның әһәмияте дә юк. Сүз белән әйтеп бирә алмаганын ул мөлаем күз карашы белән аңлатты.

Йокы бүлмәсенә кергәч, Николай туктап калды. Шәм директорның тар маңгаен һәм юка иренен яктырта иде. Тик бу юлы хәтта шул юка иреннәр дә гадәттә булмаганча елмаеп куйдылар.

— Ай-яй-яй,— диде Яковкин, башын чайкап.— Озак йөрисез, егеткәй, озак. Әйдәгез әле минем белән! — Киң коридорга чыккач, ул шәмне каплап торган кулын алды. Шәм үзенең тигез тонык яктысын һәр якка тигез сибә башлады. Николайның киң маңгаен, нечкә төз борынын, гаҗәпләнүдән киң булып ачылган шатлыклы күзен яктыртты.

«Матур бит, җен алгыры! — дип уйлады Яковкин ирексездән.— Акыл ягы да бар. Чыгышы белән разночинец та булмаса...»

— Күптән очрашырга туры килгәне юк,— дип, Яковкин үзенең татлы теле белән сүз башлады.— Камера студенты итеп билгеләгәннән бирле миңа бер мәртәбә дә, устав кушканча, донесение керткәнегез юк. Ләкин хәзер сүз ул хакта түгел. Менә сез үзегез тәртип бозасыз: начальство рөхсәтеннән башка балга йөрисез. Мин сезгә рөхсәт бирмәс идеммени?

Николай мондый мөгамәләдән югалып калды. Моның дус булып кылануы астында нәрсә ята икән? Бу сагаюны Яковкин да сизде. Аның иреннәре бер-берсенә ябышып куйды. Ләкин шунда ук аның йөзенә кабат елмаю чыкты. Яковкин шелтә катыш үпкә белән сүзен дәвам иттерде:

— Үзегез белмисез дә бит, ә мин һәрвакыт сезнең язмышыгыз турында кайгыртам. Мин сезне, Симонов-

ны һәм Линдегренны астрономия күзәтүләре алып бару өчен профессор Литтровка * беркеттем.

Николай өчен бу яңалык иде, әлбәттә.

— Профессор Литтровка?! — дип сорады ул, шунда ук җанланып китеп.

Лобачевскийның бу чаклы дәртләнүен күреп, директор бер-ике адым артка чикте.

— Хәзер кайда соң ул, профессор Литтров?

Студентны таң калдыруына шатланып, Яковкин эре генә итеп:

— Литтров әфәнде Казанга килде инде,— дип җавап кайтарды.— Аның белән очрашу өчен иртәгә кичке алтыда обсерваториягә рәхим итегез. Ә хәзер...— Яковкин бүлмә ишегенә ымлады.— Мондый шаяруларыгызны кабатламассыз дип ышанам.

— Ярар, директор әфәнде,— диде Николай, әсәрләнеп.— Сезгә бик зур рәхмәт. Китәргә рөхсәтме?

— Әйе, әйе! — диде Яковкин, ягымлы тавыш белән, һәм үзе дә борылып китеп барды.

Аның кулындагы шәм, коридорны яктыртып бераз баргач, борылышта күмелде. Николай исә, әле генә ишеткән сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, баскан урыныннан китә алмый озак торды. Бер көн эчендә шул чаклы бәхет ишелеп төшәр икән!..

Яковкин исә, квартирасына кергәч, үз-үзеннән канәгать бер кыяфәттә, кан тамырлары кабарып торган каты кулын угалап алды....

Икенче көнне, билгеләнгән сәгатьне түземсезлек белән көтеп алып, Николай гимназия өчен салынган яңа бинага юнәлде. Обсерватория шунда урнашкан иде.

Воскресенский урамыннан ул Гостиный дворга чаклы барды да тар гына бормалы тыкрыктан уңга кереп китте. Воздвиженский урамындагы ике катлы ак йортны ул ерактан ук күреп алды. Йортның авыр колонналары өстендә матурлап бизәп эшләнгән балкон, ә түбәсендә манара сыман пыялалы гөмбәз. Әнә шул гөмбәзне Яковкин обсерватория дип атый.

---

* Иосиф Литтров егерме биш яшендә чакны Краков университетында (кайчандыр Коперник укыган Ягеллон академиясендә) конкурс буенча астрономия һәм югары математика кафедрасын ала. 1803 елдан башлап Венада яши. 1809 елның язында Наполеон армиясе Вена шәһәренә керә, һәм обсерваторияне дары магазинына әйләндерәләр. Моңа хәтере калган Литтров Россиягә хезмәт итәргә теләген белдерә. Попечитель Румовскийга ул: «Башка дәүләтләрдә фәнгә салкын карыйлар, ә Россиядә фәнне хөрмәт итәләр», дип яза.

Йөрәге бик ашкынса да, Николай гимназиягә акрын атлап килеп керде, икенче каттагы залга менде.

Залда аны озын буйлы, бөкресе чыга төшеп торган карт сторож туктатты:

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады.

— Профессор Литтров кирәк иде!

— Менә бу ишектән кереп, өскә менегез,— диде сторож.— Серваторий шунда булыр.

Бормалы текә баскычтан капшана-капшана менәргә туры килде. Караңгыда Николай ниндидер ишеккә килеп төртелде. Ишекне ачып җибәрсә — түгәрәк зур бүлмә, һәр ягында тәрәзә. Бүлмә уртасында иске постау япкан озын өстәл. Өстәл өстендә кургаштан коелган кара савыты,ерактан карар өчен ике бакыр труба һәм тагын түгәрәкнең чиреген тәшкил иткән ниндидер астрономик инструмент. Алар янында матур итеп очланган каурый каләмнәр, бер өем кәгазь һәм китаплар. Өстәл тирәли бер рәт урындыклар тезелгән. Читтәрәк агач өчаяк өстенә көйләнгән аршын ярым озынлыгындагы зур труба да бар икән.

Өстәлнең аргы башында җәелеп кенә профессор Бартельс утыра. Аның кәефе яхшы иде.

Профессорның уң ягында, гөмбәзнең ачык күзе янында ук, урындык аркасына таянып, муенын алга сузып, егерме биш яшьләрдәге, озын буйлы, киң җилкәле, куе кызгылт чәчле, төскә-биткә әллә ни матур булмаган бер егет тора. Өстендә шактый таушалган панталон һәм катып беткән сюртук. Бу математикадан яңа билгеләнгән магистр Григорий Борисович Никольский иде.

Стена буендагы артсыз урындыкларда Иван Симонов һәм Осип Линдегрен утыра. Студентлар да, магистр да Бартельсның сөйләгәнен игътибар белән тыңлыйлар. Профессор һаман әле рус телен өйрәнергә теләми һәм менә хәзер, Литтров килгәнче, Лапласның «Галәмне тәфсилләп аңлату» исемле хезмәте турында немецча әңгәмә алып бара иде.

Профессорга һәм магистрга баш иеп, дусларына күз кысып алгач, Николай өстәл янына барып утырды.

Бартельс ашыкмыйча гына сөйләвен дәвам итте:

— Шулай ук философ Иммануил Кантның «Гомуми табигать тарихы һәм күк теориясе» дигән хезмәте космогониядә * шактый зур яңалык булды. Философ

* Космогония — күк җисемнәренең килеп чыгышын һәм үсешен өйрәнә торган фән.

үзенең ул хезмәтендә мин сезгә әле хәзер генә сөйләгән мәшһүр космогоник гипотезаны күтәреп чыкты. Ул галимне хаклы рәвештә чорыбызның иң зур фикер иясе дип саныйлар...

— Гафу итегез, профессор әфәнде,— дип кинәт сүзгә Лобачевский катнашты,— ләкин, минемчә, «Гомуми табигать тарихы»н иҗат иткән философ зур акыл иясе булудан тукталды шикелле. Чөнки акыллы кеше «Саф акылны тәнкыйтьләү» кебек нәрсә язмас иде.

Бартельсның гаҗәпләнүдән кашы өскә сикереп куйды. Ул, кабаланмыйча гына:

— Сез моны ничек аңлыйсыз соң? — дип сорады.

— Мин студент фикеренә кушылмыйм,— диде Никольский, арага төшеп.— Кант чаклы Кантка тел тидерергә беркемнең дә хакы юк.

— Кем соң ул Кант! — дип, кызып китеп, русчалатып җавап бирде Николай аңа.— Аның бөтен философиясе үзе язган саф акыл галәмәте. Шуннан артык берни түгел! — диде һәм, немецчага күчеп, Бартельска мөрәҗәгать итте: — Профессор әфәнде, Кант бит пространствоның безгә бәйсез рәвештә яшәвен бөтенләй инкарь итә, ул бит аны акыл тарафыннан иҗат ителгән дип таба.

— Бик дөрес,— диде профессор, тыныч кына.— Ә сез шуның белән килешмисезме?

— Алай дип әйтү котылгысыз рәвештә дөньяны, дөньядагы әйберләрне, күренешләрне инкарь итүгә китерә бит.

— Сез шулай дисезме?

— Мин әйтмим аны, рус математигы Осиповский әйтә.

— Аның белән генә чикләнми әле,— дип, Симонов та бәхәскә катнашты.— Кант әйткәнчә, пространство төшенчәсен акыл уйлап чыгарган булса, ул чакта геометрик пространство да тышкы дөньяның чагылышы була алмый. Ахмак фикер бит бу!

— Егетләр, юкка бәхәсләшәсез, профессор бик дөрес әйтә,— дип, магистр янә арага төште һәм профессор ягына баш иде.

Ә профессор үз фикерен әйтергә ашыкмый, ул бик зур кызыксыну белән яшьләр сөйләгәнне тыңлап утыра иде.

— Сез геометрия фәненең үзенчәлекле фән булуын, тәҗрибә нәтиҗәсендә үсмәгәнлеген төшенеп җитмисез,— диде Никольский Симоновка.— Әйе, математик

һәм геометрик корылмалар, саф акыл продукты буларак, тышкы дөньяга бәйләнешсез рәвештә яшәп киләләр. Шуңа күрә дә шул бөек Платон, математиканы өйрәнү кеше акылын материаль дөньядан аера һәм идеаль булган нәрсәне аңлау дәрәҗәсенә китерә, дип өйрәткән.

Никольский профессор ягына тагын бер мәртәбә күз төшереп алды һәм, профессор белән икесе бер караш та дип белеп, тантаналы рәвештә сүзен тәмамлады:

— Бу фикерне раслау өчен шуны әйтү дә җитә: матди дөнья кинәт кенә юкка чыкса да, математик үзенең фәнен үстерүне дәвам итә алачак.

Моңа кадәр аның сөйләгәнен тыныч кына тыңлап утыручы Лобачевский түзмәде:

— Табигать булмаса, геометрия булыр идемени?! — дип, Никольскийга текәлде.

Магистр нәрсә әйтергә дә белмәде. Аның бәхетенә каршы, нәкъ шул чакны ишек ачылып китте, һәм бусагада шәм тоткан озын сторож күренде. Бүлмәгә кергәч, ул читкә тайпылды, артыннан кереп килүче утыз яшьләрдәге, шактый юан гәүдәле, пөхтә итеп киенгән бер кешегә юл бирде.

Кунакны аягүрә басып каршыладылар.

— Хәерле кич, әфәнделәр! — диде кунак һәм баш иеп исәнләште.

Николай аны шунда ук танып алды. Бу мәшһүр академик-астроном Вишневский иде. Авылларның географик координаталарын билгеләү максаты белән Россия буйлап сәяхәт итеп йөри. Бүген университетка килеп, дәресләргә дә кереп утырды һәм Лобачевскийны бик мактады. Чөнки Николай авыр һәм катлаулы мәсьәләне тиз генә чишеп ташлады...

Академик бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты һәм, Николайны күргәч, ягымлы итеп елмаеп куйды.

«Таныды бит!» дип уйлады Николай, һәм аның бит алмалары кызарып китте.

Шул вакыт бүлмәгә, тиз-тиз атлап, Яковкин, аның белән бергә чандыр гәүдәле, кырыс кыяфәтле, куе бакенбардлы, өстенә фрак кигән бер әфәнде килеп керде. Аны күргәч, егетләр бер-берсенә карашып алдылар: көн аяз булуга карамастан, ул кеше кулына зур гына зонтик тоткан иде. Аның соры күзе тыныч һәм игътибар белән карый. Сулына караганда текәрәк күренгән уң кашы аның кыяфәтенә уйчанлык бирә. Бу шул яңа билгеләнгән профессор Литтров үзе булып чыкты.

Яковкин астрономны яшьләр белән таныштырырга кереште:

— Сәләтле математик магистр Никольский,— диде һәм урә каткан студентлар ягына кулын җәеп күрсәтте:— Болары киләчәктә сезнең ярдәмчеләрегез, астроном булачак егетләр: Николай Лобачевский, Иван Симонов, Осип Линдегрен.

— Бик шатмын,— диде Литтров, башын ия-ия. Ул русча бик үк чиста сөйләшә алмый иде.

Астрономия өйрәнү өчен билгеләнгән бүлмәне профессор Литтровның игътибар белән караштыруын сизгәч, Яковкин төшендереп бирергә ашыкты:

— Обсерваториябез тәрәзәләре ачылмалы итеп эшләнгән...

Бүлдермәсеннәр, тизрәк әйтеп калыйм дигән кебек, ул йотлыгып-йотлыгып сөйләде:

— Күргәнегезчә, обсерваториянең эчке ягы юка тактадан корылган һәм шул сәбәпле мич чыгарта алмадык, ләкин, аның караваы, биредә күк гөмбәзе сурәтен төшерергә мөмкин булачак. Ләкин анысы инде бездән түгел, бәлки...

Аның нәрсә сөйләгәнен аңлый алмыйча аптыраган академик Вишневский көтмәгәндә бүлдерде:

— Петербургтан киткәндә попечитель әфәнде яшен кайтаргычын искә алган иде. Бу хакта сезгә махсус хат язып, сызымнар да җибәргән булса кирәк. Ләкин нигәдер ул яшен кайтаргычыгыз күренми...

— Әйе шул, попечитель галиҗәнабларыннан миңа шундый әмер килде. Тик без аны эшләргә соңга калдык, төзелеш бетеп килә иде,— дип, Яковкин туры җаваптан качты.— Хәзер инде, аллага тапшырып, гадәттәге саклану чараларын кулланырга гына кала.

Астроном мондый җавапка шаккатты, иңнәрен җыерып куйды.

Тагын бераз сөйләштеләр дә, профессор-директор академикны түбәнгә алып төшеп китте. Аларга Бартельс һәм Никольский да иярде.

Укучылары белән ялгызы калгач, Литтров кулы белән өстәл янындагы урындыкларга күрсәтте һәм үзе дә утырды. Ул кереш сүз сөйләп тормады, астрономиянең тарихы белән таныштырырга кереште. Моңа кадәр катлаулы һәм чуалчык булып күренгән дөнья төзелешен гади генә итеп төшендереп бирде. Һәр нәрсә ачыкланды, һәр нәрсә үзенең исемен һәм урынын алды.

«Табигать күренешләренең серен өйрәнеп белү буш хыял гына түгел икән, фән аңа ирешә алачак икән,— дип уйлады Лобачевский, профессор сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый.— Килер вакыт, фән кешеләрне күк могҗизаларыннан курыкмаска өйрәтер. Мондый максатка гомереңне багышласаң да кызганыч түгел».

Студентлар профессор сөйләгәнне онытылып тыңладылар. Алар сторож яндырып чыккан шәмнәрнең вакыт-вакыт чытырдап куйганын да ишетмәделәр, төн якынлашканны да күрмәделәр. Тик инде күк йөзендә йолдызлар калыккач кына, профессор сөйләүдән тuктамакчы булды һәм:

— Безнең беренче әңгәмәбезне Лаплас сүзләре белән тәмамлау урынлы булыр кебек тоела. Ул үзенең *«Галәмне тәфсилләп аңлату»* исемле хезмәтендә болай дип яза,— диде һәм шунда ук, кирәкле битне табып, тантаналы төстә укып та җибәрде:— *«Фәндә уңыш казану өчен философның, бердән, чикләнмәгән хыял иясе булуы, икенчедән, кыю рәвештә фикер йөртүе, күзәтү һәм тәҗрибәне җентекләп үткәрүе зарур...»*

Шул сүзләрне укыгач, астроном китабын шап итеп япты да зонтигын алып, студентларны «йолдызларга якынрак» менәргә чакырды.

Егетләр, аптырап, аның артыннан иярделәр, тар баскычның агач култыксаларын шыгырдатып, гөмбәз өстенә менделәр.

Югарыга менгәч, алар кызык күренешкә хәйран калдылар. Зәңгәр күктә иксез-чиксез йолдызлар җемелди. Ә түбәндә урам буйлап кемнәрдер үтеп бара — аларның сөйләшкәне тонык кына ишетелә. Тәрәзәләрдә сирәк-мирәк ут күренә...

Идел ягыннан салкынча җил исеп куйды. Николайның йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Йолдызлар белән тәүге очрашуы аның хәтерендә гомер буе сакланачак иде.

Литтров мәйданчык уртасындагы түгәрәк урындыкка утырды да зонтигы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә аңлатырга кереште:

— Йолдызлар дөньясын яхшылап өйрәнү максаты белән, күк гөмбәзен борынгылар аерым өлешләргә бүлгәннәр. Шуларның һәркайсында бер тирәдәге йолдызларны төрле сурәтләргә охшатканнар һәм исемнәр биргәннәр...

Литтров, һавада берничә түгәрәк ясап, зонтигын түбән төшерде. Студентлар, гәрчә йолдызлар арасын-

да бертөрле аерма күрмәсәләр дә, карашлары белән күкне айкадылар.

— Әфәнделәр, хәзер безгә күк гөмбәзенең чуар картасыннан Җидегән йолдызны эзләп табарга кирәк. Чүмечкә охшаган ул йолдызлар төркеменә карап, без кайсы якның кайда икәнлеген беләбез. «Чүмеч»нең кырыендагы ике йолдыздан өскә таба туры сызык үткәрсәк, Тимерказык йолдызына килеп төртелербез. Ул йолдыз якты яна, һәм аны елның төрле фасылында күрергә мөмкин. Шуның буенча төньякны билгелибез дә хәзер инде астрономик зонтик ярдәмендә беренче мәртәбә күкне гизә башлыйбыз.

Литтров зонтын баш өстенә күтәрде һәм пружинасына басты. Зонтик җәелеп, аның эчке ягына бик зур осталык белән чигеп эшләнгән төньяк ярымшарының йолдызлы күге пәйда булды. Моны күргәч, студентлар таңга калдылар. Һәркемнең күзе нәкъ уртага чигеп куелган Тимерказык йолдызына текәлде.

Литтров, елмаеп, Николайга карап куйды, ләкин егетнең йөзендә уңайсызлану күреп, читкә борылды. Зонтны Тимерказык йолдызына каратып бераз авыштырды да Җидегәнне күктәге Җидегән йолдызга туры китерде. Аннары әле зонтик «бизәкләрен» һәм алар астындагы язуларны, әле күктәге йолдызларны күрсәтеп, күк гөмбәзенең төньяк ярымшарына кергән иң төп йолдыз төркемнәре турында сөйләп китте.

Дәрес төн уртасы авышкач кына тәмамланды. Университетка җиткәнче егетләр Литтровны мактап, аның галимлегенә сокланып кайттылар. Андый остаз бар чакта — өйрәнергә була иде.

Симонов белән ярышып укый торгач, Николай астрономиядә көннән-көн үзе өчен зуррак яңалыклар ача барды. Ул һәр кичне йолдызлар калыкканны түземсезлек белән көтеп алды, аннары обсерваториягә йөгерде, анда зур трубадан күк йөзен күзәтте. Баш әйләнерлек, акыл җитмәслек күренеш бит! Гади күз белән карап ике-өч йолдыздан артык күренмәгән төштә телескоп йөзне, хәтта әле аннан да күбрәкне күрсәтә. Йолдызлар дөньясы очсыз-кырыйсыз булып тоела. Кемнәр санап бетерер икән ул күк җисемнәрен? Галәм киңлеген кемнәр үлчи алыр икән?

Тик Лобачевский нәрсә белән генә мавыкмасын, ул һәркайда, һәркайчан яңалык эзли иде. Телескоп янында дежур торганда шулай бервакыт ул Юпитер белән Сатурнны күзәтте. Ләкин аларның хәрәкәтенә

сокланып кына калмады, бәлки ул планеталарны Кояш тирәсендә эллипслар ясап әйләнергә мәҗбүр иткән көч турында уйлана башлады. Гомумән, йолдызлар ничек егылып төшмиләр икән? Аларны нәрсә хәрәкәткә китерә икән?

Күзәтүләр алып барганда да, шулай ук лекция тыңлаганда да «ни өчен алай икән?» дигән сорау Лобачевскийга тынгылык бирмәде.

Еш кына ул таңны аудиториядә китап укып каршылады. Күн тышлы, зур форматлы, калын китаплардан ул борынгының бөек галимнәре язып калдырган фикерләрне өйрәнде. Литтровтан алып торып, хәзерге философларның һәм астрономнарның хезмәтләре белән танышты. Укучысының тырышлыгына һәм сәләтенә профессор сокланып карый иде. Ә Николай үзе борынгы телләрне белүенә сөенде һәм Корташевскийга күңеленнән рәхмәт укыды.

Николайны борчыган сорау күпләрне кызыксындырган икән. Аристотель үзенең «Физика»сында болай дип язган:

«Табигать хәрәкәтнең һәм үзгәрешнең башлангычы булу сәбәпле, табигатьне өйрәнгәндә без хәрәкәтнең нәрсә икәнлеген ачыкламый калдыра алмыйбыз, чөнки аны белмәү табигатьне аңламауга китерәчәк...»

Ләкин «физика»га эчкәре кергән саен, Николайның кәефе кырыла барды. Аристотель башта үзе табигатьтәге эчке хәрәкәтне икърар иткән иде, ахырда никтер мондый нәтиҗә ясый: «...җисемнәрнең барысын да ниндидер көч хәрәкәткә китерә... тәүге этәргеч көч булырга тиеш», ди.

Астрономиягә багышлап язылган китаплар арасында иң борынгысы булган «Альмагест»та да шундый ук фикер: планеталарның хәрәкәтен Клавдий Птолемей ниндидер этәргеч көчнең булуы белән аңлата.

Хәзерге астрономнар һәм философлар, бу мәсьәлә турында шактый күп сөйләсәләр дә, канәгатьләнерлек җавап бирә алмыйлар иде. «Фикерләү һәм тәҗрибә физикасының тәүге нигезләре» дигән китапны кулына төшерүгә, Николай комсызланып укырга кереште. Авторы Харьков университеты профессоры Афанасий Стойкович * «Хәрәкәт күренешләре» дип аталган

---

* Афанасий Стойкович Прага, Геттинген һәм Варшава университетлары гыйльми җәмгыятьләренең члены булып торган. Харьков университеты 1805 елда ачыла.

махсус бүлек тә бар икән. Автор шул бүлектә болай дип яза:

«Табигатьтә торгынлык юк, бәлки һәммә нәрсә пространствода үзенең мөнәсәбәтен үзгәртә, ягъни һәммә нәрсә хәрәкәттә. Материя һәм аның хәрәкәте бөтен бер табигатьне тәшкил итәләр... Ләкин материя үзлегеннән хәрәкәткә килә алмый, һәм бу яктан без аны җансыз кебек кабул итәбез...»

Хәрәкәт турында язганнарны Лобачевский кабат-кабат укыды, ләкин укыган саен каршылыкка очрады. Галимнәр һәрвакыт мәсьәләне бер төрле аңлатып, бөтенләй икенче төрле нәтиҗә чыгаралар диярлек.

«Әгәр ул галимнәр хаклы булса, пространство, хәрәкәт һәм материя һәркайсы үзенә аерым яши булып чыга. Димәк, алар арасында бертөрле дә эчке элемтә юк. Ул чагында Космостагы гаҗәеп төгәллекне, планета һәм кометаларның, тәртипсез рәвештә йөрмичә, Кояш тирәсендә билгеле бер тәртиптә әйләнүен ничек итеп аңлатырга соң?..» дип баш ватты Николай.

Андый чакта ул, борчылып, урындыктан сикереп тора да аудитория буйлап йөреп китә. Стенага җитеп, кире борылган саен, фикерләре дә күзгә күренми торган киртәгә килеп бәрелгән шикелле тоела. Моңа кадәр җисем, өч үлчәүле пространство һәм хәрәкәт турында күпме баш ваткан иде, әле һаман шул тәүге нигезләргә җитеп туктарга мәҗбүр була...

Әйе, Лобачевский нинди генә фән белән мавыгып китмәсен, геометрия проблемаларын һичбер вакыт оныта алмады. Киресенчә, астрономиядән профессор Литтровның лекциясен тыңлаганда һәм телескоптан йолдызлар хәрәкәтен күзәткәндә, бу фән белән геометрия арасында уртаклык эзләде. Ихтимал, геометриянең серләрен чишүгә юнәлтелгән кыю фикере нәкъ әнә шундый чакта тугандыр...

Бер көнне Литтров, кешелек дөньясының Галәмне өйрәнү дәрәҗәсенә ничек итеп ирешүен сөйләгәндә, күк җисемнәренең хәрәкәтенә дә кагылып үтте. Лобачевский моны бик игътибар белән тыңлады.

— Җирнең һәм башка планеталарның Кояш тирәсендә йөрүен беренче булып Коперник исбатлый,— диде профессор.— Ләкин ул, күктәге хәрәкәт үзенең тигезлеген сакларга тиеш, планеталар түгәрәк буенча йөрергә тиеш, дип уйлый. Аның тәгълиматын Иоһанн Кеплер тулыландыра, ягъни планеталарның хәрәкәт итү законын ача һәм шуның нәтиҗәсендә Птолемей

системасын тәмам юкка чыгара. Кеплер беренче булып астрономиягә коник киселеш төшенчәсен кертә һәм Җирнең Кояш тирәсендә эллипс ясап әйләнүен исбат итә. Ләкин ни өчен алай булуын төшенеп җитә алмый. Ә Галилей, снаряд очышының траекториясе аның авырлыгына бәйле икәнен ачса да, планеталарның хәрәкәтенә шул ук авырлыкның тәэсир итү мөмкинлеген аңламый. Шулай итеп, галимнәр күк җисемнәренең ни сәбәпле үзенә бер тәртип белән хәрәкәтләнүен шактый вакыт ачыклый алмыйлар.

Профессор, фикерен тупларга теләгән кебек, бераз сөйләүдән туктап торды. Студентлар түземсезләнеп көтеп утырдылар; беркем бер сүз әйтмәде.

— Бу сәбәпне Исаак Ньютон таба,— диде профессор сөйләвен дәвам итеп.— Бөек даһи тарту көче законын ача. Лаплас ул законга «табигать законы» дигән исем бирә. Һава кебек үк кирәкле һәм табигый булган ул законны без һәрвакыт очратабыз. Мәсәлән, алмагачтан алма өзелеп төшә икән — аны Җир тарта, ә Җирнең үзен Кояш тарта һәм орбита буйлап йөрергә мәҗбүр итә...

Лекция беткәч, Николай профессор янына килде.

— Профессор әфәнде, сез миңа берничә минут вакытыгызны бүлә алмассызмы?

— Бик рәхәтләнеп,— диде Литтров, ачык йөз белән.

— Ньютон үзенең «Табигый философиянең математик нигезләре» исемле хезмәтендә күктәге күренешләрне һәм диңгезләрнең ташуын тарту көченә таянып аңлатып бирә,— диде Николай.— Тик менә тарту көченең нәрсәдән барлыкка килүен генә әйтми.

— Тарту көченең булуы һәм Ньютон аңлаткан закон белән эш итү дә бик җиткән, әфәндем,— дип җавап бирде Литтров.— Димәк, бу закон безгә табигатьнең бөтен ишекләрен ача һәм серләрен өйрәнергә мөмкинлек тудыра. Сез шуңа канәгать түгелмени?

Николай башын түбән иде, җавап бирергә ашыкмады. Профессор көтте. Ул инде егетнең уйламыйча сөйләмәвен, тәпле фикер йөртүен сизеп өлгергән иде.

— Канәгать түгел шул,— диде Николай бераздан.— Хәрәкәтнең тәүге сәбәпләрен белми торып, кояш системасының барлыкка килүен ничек итеп аңлатырга соң?

— Сезнең бу соравыгызга Ньютонның үз сүзләре белән, гениаль хезмәтенә йомгаклау рәвешендә язган

сүзләре белән җавап бирергә мөмкин.— Литтров кулындагы китапны ачты да ашыкмыйча гына, һәр сүзенә басым ясап, укып чыкты: — «Планеталар һәм кометалар, яңа ачылган законнар нигезендә, даими орбиталары буенча туктаусыз әйләнеп торалар. Гәрчә алар тарту көче законы нигезендә орбиталарында калсалар да, ул законга таянып кына орбиталарның башлангыч урнашуы һич мөмкин булмаган...»

Профессор укудан туктап Лобачевскийга игътибарлы итеп карап алды.

— Сезнең соравыгыз бик урынлы. Бөек даһи бу турыда менә ничек яза, тыңлагыз,— диде ул һәм укуын дәвам итте: — «Кояш, планеталар һәм кометаларның шул чаклы мәһабәт урнашуы, әлбәттә, илаһи бер көчнең катнашыннан башка гына эшләнмәгән...»

— Алайса, кояш системасы тарту көчен алладан алган булып чыгамыни? — дип сорады егет, укытучысының сүзен бүлеп.— Алайса, нинди дә булса хәрәкәтнең асылын аңлатырга теләсәк, башлап кузгатып җибәргән көчкә, беренче хәрәкәткә китерүче акыл иясенә, ягъни аллага мөрәҗәгать итәргә тиеш булабызмыни?

— Әйе, хәзергә бүтән чарабыз юк,— диде Литтров, кызып китмичә генә.

Николай сүзсез генә баш иеп хушлашты да аудиториядән чыгып китте. Профессорның үз артыннан нинди зур кызыксыну белән карап калуын егет сизмәде.

— Кояш яктысында күренүчән тузан бөртекләрен хәрәкәткә китерүче дә шул ук алла булып чыга түгелме соң? Аларны бер яктан икенче якка куып йөрүдән башка мөһимрәк эше юк микәнни? — дип, үзалдына сөйләнеп, кызу-кызу атлады Николай. Гүя ул җавабын таба алмый аптыраган катлаулы сораулардан качарга тели иде.— Сорарга кешесе дә юк бит! Сорарга кешесе дә юк! — дип, гарьләнеп кабатлады ул.

## 2

Җәйге вакация үтеп, университетта инде 1810—1811 уку елына расписание дә әлделәр. Ә Лобачевский һаман әле Макарьевтан, әнисе янына кайткан җирдән, килә алмый ята: юк кына түләү бәрабәренә өч бай малаен гимназиягә керергә хәзерли. Гәрчә соңгы курс аның өчен бик җаваплы булса да, Николай Казанга

сентябрь башында гына — укулар башланып, ике атна узгач кына килеп җитте.

Якшәмбе көн булганга, пансионда ул иптәшләрен очрата алмады: төшке аштан соң кайсы кая таралышып беткәннәр иде. Николай да, урамга чыгып, базарга таба юнәлде.

Базарга җитәр-җитмәс үк, аны извозчиклар чолгап алды:

— Утыр!.. Садись, барин!..

Николай алардан көчкә котылды.

Балык базарында халык гадәттәгечә күп, шаушулы. Монда балыктан тыш тагын төрле ашамлык әйберләре: калач, пәрәмәч, казылык һәм шулай ук төрле эчемлекләр дә саталар.

Базар ыгы-зыгысына артык игътибар бирмичә, Николай Театр мәйданына юл алды. Матур таш йортлар тезелеп киткән Грузинский урамы буйлап баргач, тар гына тыкрыктан борылып, шәһәрнең төньягындагы бакчага — үзенең яраткан урынына килеп чыкты. Кызу килеп эсселәгән иде, баш киемен салды да кече капканы ачып керде.

Бакча бик матур җиргә, бормалы-сырмалы Казанканың текә ярына урнашкан. Елганың аргы ягында киң булып болын җәелгән, әрәмәлек һәм вак күлләр, еракта Идел һәм Ослан таулары мәһабәт булып күренә. Сулда Федор калкулыгы, анда еш-еш утырган бер катлы агач өйләр. Уңда исә бакчаларга күмелгән Подлужный бистәсе. Язгы ташу вакытында Казанканың сөзәк ягын су баса, ике-өч чакрымга җәелә, диңгезгә охшап кала. Шул вакыт судан калкып торган яшел утрауларга һәм ялгыз агачларга каравы күңелле була.

Николай бакчаның бердәнбер аллеясыннан барып, сәрви агачына елышкан ялгыз эскәмиягә утырды. Йөрәге ешрак тибә башлады. Күз алдына сөйгән кызы Анна килеп басты.

Алар шушында, текә яр буенда, сирәк кенә булса да очрашкалыйлар иде. Соңгы күрешүләрен хәтерләп, егет күзен йомды. Хуш исле җил аның битенә бәрелде, талгын рәхәтлек сирпеде.

Кинәт эскәмия артындагы сәрви куаклары кыштырдап куйды. Борылып караса — Анна. Өстендә алсу төстәге җәйге күлмәк, башында киң кырлы эшләпә, кара бөдрә чәче, дулкын-дулкын булып, эшләпә кырыеннан чыгарга теләгән кебек — кыз бик килешле, матур иде.

Николайның, аны күргәч, бар әйткәне:

— Сез түгелме соң?! — булды.

Кыз бу сүзгә елмаеп куйды, кызарынды. Аның зур соры күзе нурланып китте. Һәрхәлдә, Николайга шулай тоелды.

Анна, як-ягына каранып, якын ук килде.

— Мин шул,— диде ул, хәйләле елмаеп.— Очратуым яхшы булды әле... Сез монда икәнне сизенгән кебек... Бүген безнең дачада кичә. Иллюминация, фейерверклар белән булачак. Киләсезме?.. Юк-юк, миңа якын килмәгез. Бик ашыгам. Хушыгыз!

Анна текә ярга салынган сукмактан йөгереп төшеп китте дә шунда ук күздән югалды — куаклар гына кыштырдап алды. Николай кыз киткән якка бераз карап торды һәм бакчадан тизрәк чыгарга ашыкты. Кичәгә пөхтә, матур итеп киенеп, шпага тотып барасы бар. Димәк, хәзерләнергә кирәк.

Яковкиннарның шәһәр читендәге дачаларын ул яхшы белә. Өр-яңа өч өй, киң ишегалды, каралты-кура, ә бакчалары Казанкага чаклы сузылган. Анна тау башындагы бакчага әнә шуннан качып килгәли иде.

Аларның дачасында халык һәрвакыт күп була: кызлар, студентлар, яшь офицерлар. Әдәбият, фән һәм политика турында кызып-кызып бәхәсләшәләр. Алмагачлар астына утырып кына яки террасада чәй эчәләр. Биюләр оештыралар.

Николайның Анна белән иркенләп сөйләшә алган урыны да әнә шул дача булды. Анна күп укый, укыганын яхшы аңлый, көтмәгәндә үткен һәм акыллы фикерләр әйтеп, Николайны гаҗәпкә калдыра иде.

Билгеләнгән сәгатьне көчкә җиткереп, Николай Яковкиннар дачасына барырга чыкты. Анда җитәрәк ул Владимир Панаевны очратты. Аягына ефәк оек, өстенә ак жилет кигән, сюртугын җилбәгәй җибәргән бу егет бик чибәр булып күренде Николайга. Ләкин аның өстендәге зиннәтле киемнәре зур матур күзләрендәге моңсулыкка бер дә туры килми иде.

— Владимир! Сиңа нәрсә булды? Авырыйсыңмы әллә? — дип сораштыра башлады Николай борчылып.

— Авырырга уйлаганым да юк,— диде Панаев боек кына тавыш белән.— Эшләр начар: синең белән минем борынга чиертергә торалар бит әле.

— Берни аңламыйм.

— Аңлагач соң булыр,— диде Панаев, мәгънәле генә итеп.— Илья Федорович кызлары өчен күренек-

ләрәк пар эзләргә уйлаган. Әйе-әйе. Казанга барон Врангель килгән бит. Борынгыдан яшәп килә торган рыцарьлар фамилиясе. Яковкин инде аңа университетта хокук буенча экстраординар профессор булырга тәкъдим итеп өлгергән. Рыцарь, профессор. Ни өчен аңарга кияү дә булмаска, ә?

Панаев елмаерга теләгән иде, ләкин көлемсерәү урынына йөзе генә кызганыч кыяфәткә кереп сытылды.

— Бүгенге кичә — рыцарь өчен. Ә йортта җиткән кызлар. Төшенә башладыңмы инде?

Нәкъ шул вакыт террасадан Яковкинның тавышы яңгырады:

— Яшьләр, һәммәгез дә өйгә рәхим итегез!

Террасага унбишләп кунак җыелды. Гәрчә алар бер-берсе белән таныш булсалар да, нигәдер бүген әңгәмә куерып китә алмады. Күпләрнең күзе бакча ишегендә: яңа кунак турындагы фикер таралып өлгергән булса кирәк. Николай, күңелсезләнеп, терраса почмагына барып басты.

Бердәнбер сөйләүче кеше — тарих фәннәре буенча яңа магистр Петр Кондырев иде. Ул, кызларга ошарга тырышып, акыл сатып маташа: бөтен фәннәрнең нигезендә фикер байлыгы ята, кешенең акылы һәммә нәрсәдән алда туган, янәсе...

Кызлар, бер-берсенә карашып, тыңлаган сыман булдылар, ниһаять, аларның түземнәре калмады. Шаян холыклы Параша:

— Әткәй безгә алтын балыклар алып кайтты, әйдәгез күрсәтәм,— диде.

Кызлар, чыр-чу килеп, бүлмәгә кереп югалдылар. Террасада тагын да күңелсезрәк булып калды.

Кондырев, аптырап, сүздән туктады. Кем өчен генә сөйләргә соң инде?

Нәкъ шул вакыт бакча ишеге ачылып китте дә кунакларга таныш булмаган берәү килеп керде. Яше егерме бишләрдә булыр, төскә-биткә чибәр, өстендә кофе төсендәге пөхтә сюртук. Аның кыяфәтенә карап, галим булудан бигрәк, зур бер түрә дип уйларга мөмкин иде.

Яковкин, башкаларга сиздермичә генә, тәрәзәдән күзәтеп торган ахры: өйдән йөгереп чыгып, кунакны каршылады.

— Врангель әфәнде! Егор Васильевич! Рәхим итегез! — диде ул, төчеләнеп.— Ә без борчыла да башла-

ган идек инде. Менә монда рәхим итегез! Җәмгатем белән таныштырырга рөхсәт итегез... Кызларым кайда соң әле?..

Врангельне бик тырышып култыклаган хәлдә, көләч йөзле хуҗа үзенең кунакларына мөрәҗәгать итте:

— Таныштырырга рөхсәт итегез! Егор Васильевич Врангель.

Шул рәвешле таныштыру церемониясе беткәч тә әле кызлар күренмәде. Яковкин эшлекле кыяфәт белән:

— Террасада табын хәзерләгәнче, әйдәгез — мин сезгә кызларымның китапханәсен күрсәтим,— диде.

Врангельне култыклаган килеш, ул яшьләрнең һәммәсен кызларының кунак йортына ияртеп алып керде. Матур җиһазландырылган зур гына бүлмә. Стеналары инглиз рәссамнары эшләгән берничә гравюра белән бизәлгән. Алардан тыш, әле тагын алтын кысалы, дини сюжетлы ике картина да бар. Пыяла ишекле берничә китап шкафы тора. Ә тәрәзә янындагы бәләкәй түгәрәк өстәлдә матур гына аквариум. Кызлар шуны уратып алганнар һәм, чыр-чу килеп, икмәк валчыклары ташлыйлар.

Дәрәҗәле кунак, Яковкинның кызлары янына барып, сәлам бирде.

Николай, сөйгәненең йөзенә карап, аның эчке халәтен аңларга теләде. Анна һәрвакыттагыча үзен бик гади тота һәм тыйнак сөйләшә. Китапларын һәм альбомнарын күрсәткәндә дә Врангельнең нәзакәтле сорауларына хәтта бераз корырак итеп җавап кайтара. Шулай да Николай аңардагы үзгәрешне сизеп алды, күңеленә шик төште.

Ләкин сөйләшү тиздән гомуми төс алды. Яңа кунак, җаен туры китереп, клавесинга таба атлады.

— Сезнең уйнавыгызны үтенсәм, мәрхәмәт күрсәтмәссезме икән? — диде ул, Аннага мөрәҗәгать итеп.

Анна шунда ук, утырган җиреннән торып, клавесин янына килде һәм, бер дә ялындырмыйча, уйнарга керешге. Врангель, аның янына баскан килеш, ноталар актарды. Шуннан артык берни булмаса да, Николайның йөрәге тыныч түгел иде.

Башка вакытта Анна дәртләнеп, хискә бирелеп уйнаса, бу юлы ни өчендер җанланып китә алмады. Гайднның гүзәл һәм бай сонатасын гүя, күңел кичерешләре белән баетып, клавесин янында утырган кыз үзе уйнамады, бәлки уйнау техникасын үзләштергән бармаклары гына клавишлар өстендә йөрде.

— Тагын! Тагын! — дип, кунаклар яңадан-яңа әсәрләрне тыңларга теләк белдерделәр. Анна баш тартмады, ләкин берсен дә күңел биреп башкармады. Ниһаять, ул инструмент яныннан җиңел генә торды һәм капкачын ябып куйды.

— Мерси,— диде Врангель, аңа хөрмәт белән башын иеп.— Мадемуазель, сез чын артистларча уйныйсыз!

Анна да нәзакәтле итеп чүгеп җавап кайтарды. Күз-йөзендә Николай яраткан шаянлык чагылып алды.

— Уйнаган өченме ул рәхмәт, әллә сезне ялыктырган музыканы туктаткан өченме? — дип сорады.

Врангель шаяртуга шаярту белән җавап кайтарды: бу сорауга шаккаткан булып кыланды. Ләкин кызның йөзендәге шаянлык бик тиз сүнде.

Кунакларны террасада хәзерләнгән табын янына чакырдылар. Яковкин ачык йөз белән кыстарга тотынды. Аның игътибар үзәгендә, баягы кебек үк, булачак профессор Врангель иде.

Лобачевский белән Панаев икесе бергә туры килделәр.

— Күрәсеңме инде? — дип акрын гына сорап куйды Панаев.

Николай сүзсез генә тегенең кулын кысты.

Ләкин хуҗаның артык тырышуы нәтиҗәсендә табынның бөтенләй яме китте. Ул болай булды: кызларының ни дәрәҗәдә укыган, белемле икәнлекләренә кунакны шаккатырырга теләп, Яковкин сүзне астрономиягә борды; Никольский һәм Кондырев, бу фәннән хәбәрдар кешеләр буларак, үзләренең галимлекләрен күрсәтергә ашыктылар.

— Тәҗрибә нигезендә без нәрсә белә алабыз соң? Фәкать мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән кайбер күренешләрне генә белә алабыз,— дип акыл сатты Никольский, шактый зур бәлеш сыныгын кабып.— Ә инде мәсьәләне тирәнтен өйрәнгән очракта, ягъни пространство һәм хәрәкәтнең серенә төшенергә теләсәк, һичшиксез, бар нәрсәне аллаһе тәгалә яраткан дигән фикергә киләбез. Хәтта бөек Ньютон да...

— Шулай ук бөек Гераклит, хәтерегездә булса,— дип Николай аның сүзен бүлдерде,— дөнья һәммә нәрсәне үз эченә ала, аны бер төрле алла да, кеше дә ятмаган, ул мәңге яшәүче ут шары, дигән.

Моны ишеткәч, Кондырев тавышын күтәреп:

— Динсез! — дип әйтеп куйды.— Аллага болай тел тидерүегез мине шаккатыра!

— Ялгышасыз, ул һич тә динсез түгел,— дип Анна да сүзгә катнашмакчы булган иде, ләкин шулчак әнисенең куркынган һәм ачулы күз карашын очратып, кызарынды һәм сүзен әйтеп бетермәде.

Кызның кемнедер якларга теләвен, әлбәттә, Врангель дә сизми калмады. Аның кашы җыерылды, күзендә усал очкыннар кабынды.

— Ләкин әфәндем,— диде ул, Лобачевскийга мәсхәрәле караш ташлап,— ходай яратканны инкарь итсәгез дә, тарту көченең һәм гомумән хәрәкәтнең сәбәбен үзегезчә аңлата алмыйсыз булса кирәк?

Николайның иреннәре дерелдәп алды, тик сөйгәненең ялварулы карашын күреп кенә, бәхәсне туктатты.

— Аңлата алмыйм... хәзергә,— дип, соңгы сүзенә басым ясап җавап бирде дә сөйләшергә теләмәвен белдереп, читкә борылды.

Врангель җиңелчә генә иңбашын җыерды да, хуҗаларны ихтирам итү йөзеннән бәхәсне дәвам итмәвен күрсәтеп, башын аска иде.

— Әйе шул, картлар дөрес әйткәннәр: оста барда кулың тый, галим барда телең тый,— диде күркә кебек кабарынган Яковкин, Лобачевский ягына баш кагып.— Хәтерегезгә нык сеңдерегез, яшьләр: сан — бердән башлана, дөнья — ходай тәгаләдән. Шулай булмаган очракта философия дингә каршы булырга тиеш килеп чыга. Ә моның булуы мөмкин түгел... тиеш түгел.

Николай ничек кенә тыелып калырга теләмәсен, Яковкинның мәсхәрәле карашына түзеп тора алмады һәм акрын тавыш белән, аермачык итеп:

— Белемле кеше фәнгә, надан кеше дингә ышана,— диде.— Гиппократ шулай дигән.

Яковкин, ходай ормасын дигән сыман, учын өскә каратып, кулларын югары күтәрде.

Ләкин сүзгә артык катнашмый гына утырган хуҗа ханым иренә дорфа кыланырга ирек бирмәде, өстәл яныннан кузгалып:

— Кызларның бииселәре килә,— диде, хәйләкәр елмаеп.

Аның артыннан башкалар да кузгалды. Сүз шунда өзелеп калды. Никольский һәм Кондыревны исәпләмәгәндә, яшьләр моңа бик шатландылар. Бию өчен бакчага махсус әшләнгән мәйданчыкта өч музыкант

инструментларын көйли башладылар. Май салынган таш савытларда ут яндырылган. Күктән, шуңа өстәп, тулган ай да үзенең тонык нурын сибә. Менә килбәтсез зур канатлы арканатлар очып үтте, аларның чыелдавына кызларның чәрелдәп кычкырып җибәрүе кушылды. Бу бик мәзәк килеп чыгып, һәммә кешене көләргә мәҗбүр итте.

Николай Анна янына барырга торганда гына, Яковкинның кырыс тавышын ишетте.

— Лобачевский әфәнде, минем кабинетка кереп чыгыгыз әле,— диде профессор-директор.

Анна егеткә ялварып карады.

— Николай, зинһар, дим, кызмагыз.

Лобачевский сүзсез генә ризалык биреп башын иде дә, террасага менеп, аннан өй эченә керде.

Профессор-директор инде биек артлы креслога утырып өлгергән иде. Аның кыяфәте дә, шулай ук тавышы да теге вакытта бал-маскарадтан соң коридорда сөйләшкәндәге төсле түгел.

— Утырыгыз,— диде ул мәгърур гына, өстәл каршындагы үргән креслога күрсәтеп.— Ни өчен сез үзегезнең яшьтәшләрегез алдында шулчаклы әдәпсезлек, тотнаксызлык күрсәтәсез? — диде, кызганнан-кыза барып.— Әгәр сез акылга утырмасагыз, дингә каршы, ходай тәгаләгә каршы тел озайтуны дәвам итсәгез, тәртибегез турында попечитель галиҗәнабларына язарга мәҗбүр булачакмын. Сез аның ышанычын акламыйсыз. Күңелсез булса да, шуны әйтми кала алмыйм.

Яковкин, бер генә минутка сүзсез калып, үзенең корбанына текәлде. Лобачевский, бүлмәнең караңгы түр почмагына караган хәлдә, кымшанмый да утыра бирде. Аңардан бертөрле дә җавап ала алмагач, профессор-директор яңадан вәгазенә керепте:

— Кызым Аннага карата булган ниятегезне сизүемне һәм хупламавымны да әйтми кала алмыйм. Минем йортның ишеге сезнең өчен ачык икән, бу әле үзегезне әллә кемгә санарга хокук бирми,— диде һәм, креслосыннан калкып, зәһәрләнеп, болай дип өстәде: — Профессор-директор кызына өйләнеп, карьера ясарга, галим исеме алырга телисез булыр...

— Нәрсә, нәрсә? — дип кычкырып җибәрде Николай. Аның кулы кресло култыксаларын ныграк кысты, ирене нәрсәдер әйтергә теләп бер ачылды, бер йомылды. Ләкин шул вакыт: «Николай, зинһар, дим,

кызмагыз», дигән тавыш ишетелеп киткән төслө булды, һәм ул хәтта борылып карады.

Лобачевский өстәлгә якынрак килде дә тыелып кына:

— Анна Ильинишнага булган хөрмәтем аның әтисенә әйтергә тиешле сүзләрне йотып калырга мәҗбүр итә. Хушыгыз,— диде һәм, кырт борылып, кабинеттан чыгып китте. Ул, беркем белән саубуллашмыйча, урамга атылды.

— Профессор-директор кызына өйләнеп, карьера ясарга! — дип, гарьләнеп кабатлады ул.

Урамнан баручылар гаҗәпләнеп аңа борылып карадылар.

— Качарга моннан, качарга! — аның башында шул фикер, телендә фәкать шул сүзләр булды. Ләкин бераз баргач, аның хәтеренә күптән әйтелгән үгет килеп төште. «Гомеренең максаты итеп фәнгә хезмәт итүне куйган егет һәммәсен ташлап качар дип ышанасым килми...» Николай университеттан китәргә уйлап йөргән бер чакта аның әнисенә Григорий Иванович шулай дип язган иде. Юк, биргән антын Николай бозмаячак! Аңарга ышаныч баглаган Григорий Ивановичны алдамаячак! Ә Яковкин бервакытта да аны бу хыянәтне эшләргә мәҗбүр итә алмаячак!..

Подлужный бистәсенең чокырлы-чакырлы урамнарын үткәч, ташландык бакчага килеп чыкты.

— Болхов бакчасы! — диде ул һәм көтмәгәндә көлемсерәп куйды: Алеша белән безне менә шунда йөргән өчен полициягә илткәннәр иде ич.

Тирә-якта тынлык хөкем сөрә. Кайдадыр еракта дыңгырдап барган тәгәрмәч тавышы аермачык булып ишетелә. Ләкин бу тынлык һәм күктә җемелдәгән йолдызлар гына күңелдәге авыр хисне баса алмыйлар. Яковкинның дорфалыгы, Врангельнең үз-үзенә мөкиббән китеп, әдәпле булып кылануы һәм Аннаның аңа буйсынырга әзер торуы Николайга тынгы бирми, күз алдыннан һич китми иде.

Егет авыр гына ыңгырашып куйды. Төнге тынлыкны бозуыннан уңайсызланып, шунда ук үзен кулга алды.

Ай яктысында болын уртасындагы печән чүмәләсен күреп, шуңа табан юнәлде. Чүмәлә өстенә менеп, чалкан ятты. Күз алдыннан берәм-берәм Яковкин, Анна, Врангель үтте...

— Тәмам акылдан шашарсың, болай ярамый,

икенче нәрсә турында уйларга кирәк,— диде ул, үз-алдына сөйләнеп.— Бәхәс турында уйларга мөмкин менә. Әйе... Табигатьтә хәрәкәтләнүче җисемнәр, планетадан башлап тузан бөртегенә кадәр, һәммәсе дә алла тарафыннан кузгатып җибәрелгәнмени? Башка җавапның булуы мөмкин түгел, әйеме? Димәк, сезнеңчә, материя, пространство һәм хәрәкәт бер-берсенә бәйсез рәвештә яшәп килəләр... Димәк, геометрияне нигезләп бирү мәсьәләсендә дә төрле ысуллар яшәргә тиеш... Ә планеталар? Алар ни өчен тәртипсез рәвештә хәрәкәтләнмиләр, бәлки эллипслар буенча әйләнеп йөриләр?.. Башка җавапны тапсак, нәрсә дип әйтерсез?..

Күктәге ай шактый югары күтәрелде. Лобачевский төн уртасында гына йоклап китә алды.

Менә яңа көн туды. Йокы аралаш озынборын безелдәве ниндидер матур бер көй булып яңгырады. Шул көйне сокланып тыңлый торгач, Николай тәмам уянып китте, күзен ачып җибәрде. Һәм шунда ук аның хәтеренә кичәге рәнҗетелүе, мәсхәрә ителүе килде. Ләкин ул инде хәзер нәрсә эшләргә белми торган, көчсез һәм мескен бер кеше түгел, Анна өчен көрәшергә әзер торган батыр йөрәкле егет иде. Әйе, Анна әтисенә каршылык күрсәтә алмаса да, Николай тиз генә бирешмәячәк: сөйгәне өчен дә, үзе өчен дә көрәшәчәк!

Кинәт чүмәлә төбендә үлән кыштырдады. «Нәрсә булыр икән?» дип кызыксынды Николай. Чүмәлә өстеннән шуып төште дә бер-ике адым атлады. Шулчак яшел кәлтә аңардан читкә атылды, бик тиз күздән югалды, аның артыннан тик үлән сабаклары гына чайкалып калды.

Николай моңа шаккатып карап торды.

— Үлән кыймылдавыннан чыгып, кәлтәнең хәрәкәтен билгеләргә мөмкин,— диде ул, уйланып.— Һавадагы тузан бөртекләренең уйнаклашуы да шундый ук бер күренеш тәшкил итмиме?

Юк-бар сорау түгел иде бу. Тик менә җепнең очын табуы кыен иде. Уйлый торгач, гүя аның күз алдында яшен яшьнәп һәммә нәрсәне яктыртты: кәлтә йөгергәндә селкенгән үлән сабаклары кебек үк, тузан бөртекләре дә һава кисәкчекләре хәрәкәте нәтиҗәсендә уйнаклашалар.

Шулай булырмы? Әйе, нәкъ шулай булырга тиеш. Бер дөрес юлга кергәч, ул инде хәзер, һичшиксез, хәрәкәтнең серенә төшенәчәк.

Николай мундирының йомарланган урыннарын анн-моннан гына төзәткәләде, бармаклары белән чәчен тарады. Тик менә, шпага тагып та, эшләпәсез көе шәһәр буйлап ничек кайтып җитәргә? Хәзергә дворниклардан башка кеше тормагандыр әле, җан-фәрманга йөгерергә кирәк!

Иртәнге саф һавада сулавы рәхәт, атлавы җиңел иде.

Ә фикерләр Николай башыннан бер дә китеп тормыйлар. Кайда укыды соң әле ул һава турында? Ломоносовтамы, әллә инде Лукрецийдамы? Тизрәк ачыкларга, тизрәк табарга кирәк.

Арча кырында Лобачевский извозчикка утырды.

— Университетка! Тизрәк!

Кояш бераз күтәрелеп, чиркәү манараларының гөмбәзләрен ялтырата башлады. Урамнарда сирәк-мирәк кешеләр күренде. Кәрзин тоткан асраулар базарга элдертәләр. Су ташучы агайлар исә, буш мичкәләрен шалтыр-шолтыр китереп, елга буена ашыга. Пекарнялардан кайнар ипи исләре чыгып борынны кытыклый.

Тенишев йортына җиткәч, Николай извозчиктан төште дә ишегалды буйлап, сәрви куакларына яшеренә-яшеренә, үзләре яши торган бүлмә тәрәзәсенә килде. Менә бәхет — тәрәзә ачык булып чыкты. Бер минуттан ул инде бүлмә эчендә иде. Иптәшләре һәммәсе йоклыйлар, энесе Алексей гына уяу килеш ята иде.

— Төне буе күземә йокы кермәде,— диде ул абыйсына һәм шунда ук караватына торып утырды.— Кая югалдың син болай? Симонов күпме эзләде, миннән сорады! Чәчеңә каян салам ябышкан?

Николай, «тавышланма» дигәнне аңлатып, бармагын ирене янына китерде.

— Башка вакыт сөйләрмен. Хәзер комачаулама.

Ул китаплар салынган сандыгына иелде, аны ачып, нәрсәдер эзләргә кереште. Ломоносовның күн белән тышланган әсәрләрен тартып чыгарды. Энесенең, кул селтәп, башыннан ук одеялга төренеп, арты белән борылып ятуын ул бөтенләй күрмәде — караваты кырыена утырып укый башлады.

— «Һаваның аерым атомнары, бер-берсенә якын килеп, без күреп өлгергәнче, үзара бәрелешәләр, һәм, алар бер-берсенә тигән чакны, икенче атомнар бер-берсеннән этешеп, якындагы атомнарга барып бәреләләр дә янә читкә атылалар; шулай итеп үзара еш

кына этешү нәтиҗәсендә...» Николай китаптан башын күтәрде һәм җөмләне үз сүзләре белән тәмамлады: «Шулай, һавадагы тузан бөртекләренә өзлексез рәвештә бәрелеп, аларны да төрле якка күченергә мәҗбүр итәләр. Һавадагы тузан бөртекләренең туктаусыз хәрәкәттә булуы әнә шуннан килә. Аллага сылтау — бик зур ахмаклык».

Николай караватыннан торды, бүлмә буйлап бераз йөренде дә өстәл янына килеп туктады. «Ә соң һава атомнары үзләре ни рәвешле хәрәкәткә килгәннәр?» дип, кинәт кенә сорап куйды, аннары тагын китабына тотынды.

Шулай укып, берничә минут утырдымы, әллә берничә сәгатьме — Николай аны сизмәде. Ул бөек галимнең «Җылылык һәм салкынлыкның нәрсәдән килеп чыгуы турында уйланулар» дигән хезмәтеннән аерыла алмады. Укый торгач, иң кирәклесенә юлыкты: менә ич, җылылык материягә бәйле эчке хәрәкәт нәтиҗәсендә туа, дип аңлата Ломоносов! Димәк, хәрәкәтнең чыганагы материянең үзендә!

Зур шатлык кичергән Николай энесенең нәрсә әйткәнен башта аңламый торды. Алексей аны иртәнге чәйгә чакыра иде.

— Хәзер барам! — диде Николай, күтәренке рух белән.

Алексей аңа, бусагадан борылып:

— Чәчеңнән саламны алырга онытма! — дип кычкырды.— Киемеңне дә алмаштыр. Парадный формадан бармассың ич инде!

Лобачевский үзенең яраткан шөгыленә фәкать лекцияләр беткәч кенә кайта алды. Ә лекцияләр, үч иткән шикелле, озак булган сыман, вакыт акрын үткән сыман тоелды.

«Мондый нәтиҗәне ашыгып ясамадыммы икән?» дип шикләнде ул, укыган китапларын бер-бер артлы күз алдыннан үткәреп, бүлмә буйлап йөри-йөри.

Һәм Ломоносовтан соң Радищевның «Кеше, аның үлеме һәм үлемсезлеге турында» исемле хезмәтен кабат укырга кереште: бәлки, үземә кирәклесен табармын, дип уйлады ул.

— Боларын хәтерлим, боларын...— Лобачевский укырга тотынгач онытылып китте. 143 нче биттә ул мондый сүзләр укыды:

«Һәр җисем, читтән берәр көч тәэсир итми торып, торгынлык хәленнән чыга алмый... Торгынлык таби-

гать өчен хас күренеш дип икърар итү мәгънәсезлек булырга тиеш...»

— Хәрәкәтнең сере менә кайда икән! — диде Лобачевский үзалдына сөйләнеп.— Тагын нәрсәләр бар икән, карыйк әле,— дип, укуын дәвам итте: — «Табигатьтә һәммә нәрсә хәрәкәт иткәндә һәм яшәгәндә, бик кечкенә тузан бөртеге дә, чиксез зур җисем дә ирексездән үзгәреп, таркалып һәм кушылып торганда... дөньяда хәрәкәт яшәп килә, һәм бу аның матдилегенә хас, аңардан аерып алу мөмкин булмаган сыйфаты дип расларга хакыбыз бар».

Укып бетергәч, Николай бүлмә буйлап йөренеп алды. Бөек философның акыллы фикерләрен ахырынача аңларга тырышты.

Галәмдәге һәр күренеш — материянең мәңге үзгәреп торуы, мәңгелек хәрәкәте. Ә материя үзе исә бөтен табигатьне тәшкил итүче бердәнбер көч. Чиркәү дә, төрмә дә бу фикерне юкка чыгара алмаган һәм төрле Никольский — Яковкиннар да моны эшли алмаячак. Дөрес фикер яши һәм мәңге яшәячәк!

Шул вакыт кемдер, ишектән башын тыгып, аңа эндәште:

— Николай, без шәһәрдә йөреп кайтмакчы идек, сезнең дә теләгегез юкмы? — диде.

— Юк! — диде Николай кырт кисеп. Ләкин андый тупас җавабыннан уңайсызланып, әдәплерәк итеп: — Рәхмәт, мин чыга алмыйм шул,— дип өстәде.— Бер фикер килде әле...

— Карагыз аны, фикер эзли-эзли, булган акылыгыздан язмагыз! — дип, егетләр ишекне шапылдатып яптылар да көлешә-көлешә китеп бардылар.

Николай исә:

— Котылдым! — дип, иркен сулап, өстәлгә иелде. Шулай итеп, ул кем чакырганын да белми калды.

Димәк, материяне хәрәкәттән башка күз алдына китерү мөмкин түгел, ә материянең хәрәкәте пространствода бара. Менә ни сәбәпле тәүге геометрик төшенчәләрне билгеләгәндә нигез итеп җисемне яки өч үлчәүле пространствоны, я булмаса хәрәкәтне генә алуыбыз белән безнең һәркайсыбыз билгеле дәрәҗәдә хаклы булса, шул кадәр үк ялгыша да. Ә һәркем үз фикерен яклаганга күрә, геометрияне нигезләүдә карашлар берлеге була алмас кебек тоелган.

— Бу проблеманы хәл итәргә мөмкин ич! — дип

кычкырып әйтеп куйды Лобачевский.— Моның өчен хәрәкәттәге материягә таянып эш итәргә генә кирәк.

Николай бармагы белән күзен томалады һәм, күз алдына килгән картинаның бөеклегеннән таңга калган төсле, хәрәкәтсез торды. Аннары, башын бераз ял иттерергә теләп, китапларын сандыгына яшерде. Тик шунда ук аның йөрәге кысылып куйды. Әйе, күңелдәге әрнү бетмәгән, зур фикерләр белән мәшгуль булганда онытылып кына торган икән.

Бүген үк Аннаны күреп, һәммәсен хәл итәргә кирәк.

Николай озак уйлап тормады, тиз генә киенде дә Подлужныйга юнәлде. Сөеклесенең дачасына якынлашкан саен, хәтерендә Яковкинның сүзләре ныграк калкып чыкты: «Профессор-директор кызына өйләнеп, карьера ясарга телисез!» Николай адымнарын акрынайтты... Һәм шулчак рәшәткә аша Аннаның чәчәкле күлмәген күреп алды. Кыз, башын аска иеп, бакча юлыннан атлап бара иде.

Николай рәшәткәгә якын ук килеп, акрын гына тавыш белән:

— Анна! — дип эндәште.

Кыз борылып карады һәм елмаеп куйды. Рәшәткә янына йөгереп килде дә кулын тышкы якка сузды.

— Николай!

Егет аның кулыннан үпте.

— Николай,— дип кабатлады кыз, тавышын акрынайтып.

— Анна, әтиегез белән сөйләшү ничек беткәнен сез беләсезме? — дип сүз башлады егет.

— Беләм,— диде кыз, еламсыраган тавыш белән.

— Мине кабат сезгә килүдән мәхрүм иттеләр,— диде Николай.— Бүген мин бөтенләй өйдә кунмадым.

— Кайда кундыгыз? — дип, коты алынып сорады кыз.

— Печән чүмәләсе башында,— диде егет көлеп.— Сезне уйладым... Әтиегез кайчан миңа булган карашын үзгәртер икән дә, кайчан сезнең кулыгызны сорармын икән, дип кайгырдым.

Кыз авыр сулап куйды.

Лобачевский кинәт бүгенге баш ватуларын хәтерләде һәм фикерләрен сөйгәненә әйтми кала алмады.

— Врангель юкка сөенде кичә,— диде Николай, дулкынланып.— Хәрәкәт материянең үзендә барлыкка килә. Ломоносов та шулай яза, Радищев та. Сезгә

шуны әйтәсем килә: бөек галимнәрнең әсәрләрен кабат-кабат өйрәнергә кирәк, укыган саен белемең арта-чак. Музыка да нәкъ шулай бит. Мәсәлән, Моцартның «Юпитер»ын, Бетховенның симфонияләрен күпме генә тыңлама — барыбер бөтен эчтәлеген аңлап җиткермәскә мөмкин...

Лобачевский Аннага текәп караган иде — кызның йөзендәге үзгәрешкә гаҗәпләнде.

— Сезгә нәрсә булды? — дип сорады ул, кызның кулын кысып.

— Бернәрсә дә булмады,— диде Анна, кулын кире алып, һәм башын аска иде.— Сез мине ничек кенә яратсагыз да, фәнне өстенрәк күрәсез...

Николай дәшмәде: бу сүз белән килешергә дә, каршы әйтергә дә кыюлыгы җитмәде.

Авыр тынлыкны Анна үзе бозды.

— Киләчәк күрсәтер,— диде ул акрын гына тавыш белән һәм ике кулын да аңа сузды.— Николай, бәгърем, өметсез шайтан дигәннәр, бөтенләй үк өметне югалтмыйк әле.

Ә егет үбәргә дип иелгәч, Анна кулларын тартып алды да китәргә җыена башлады. Егетнең:

— Кайда күрешә алырбыз икән? — дигән соравына каршы:

— Белмим шул. Хушыгыз, Николай,— диде.

Егет, моның белән килешергә теләмичә:

— Анна! — дип мәрхәмәт көтеп карап калганда, кыз агачлар арасына кереп югалган иде инде.

## 3

Шуннан соң булган вакыйгалар һәммә нәрсәне үзгәртеп ташладылар.

Яковкинның күптәннән кәефе юк иде. Җәй көне үк Петербургтан аңа сайлаулар үткәрү өчен кызыл агачтан эшләнгән ящик белән утыз сөяк шар җибәрделәр. Попечитель үзенең хатында: «Ректор сайлагыз, факультетларга бүленешне булдырыгыз, һәр факультет саен декан сайлагыз», дип язган иде.

Моңа кадәр гимназиягә дә, университетка да Яковкин берүзе җитәкчелек итеп килде. Теләгәнчә расписание төзеде, яңа килгән профессорларга укыту сәгатьләрен һәм укучыларны билгеләде. Совет членнарыннан берәүнең дә бу эшләргә катнашырга хакы юк иде. Ә менә хәзер яшерен сайлауның эшне бозып ташлавы мөмкин.

Бу беренче сайлау аның университетта кылган башбаштаклыгына чик куячагын Илья Федорович аңлый иде. Дәрәҗәле чагында җиткән кызларын кияүгә биреп калырга, ә моның өчен бераз юньлерәк кешеләрне табарга кирәк. Берсенә барон Врангель ярар шикелле... Тик аның хөрмәтенә оештырылган беренче кичәдә үк динсез Лобачевский профессор-директорны кадерле кунаклар алдында чак кына хурлыкка төшермәде. Ә бит кайчандыр ул да, Румовскийга ошады дип, Корташевскийның шул кечегенә ачык йөз күрсәткән, хәтта кияү итү турында да уйлый башлаган иде.

Аллага шөкер, Врангель ачуланмаган икән! Сайлауда да җиңеп чыкса... Тик менә яшерен булуы гына...

Сайлау көне итеп 1810 елның 16 сентябре билгеләнгән иде, ул көн килеп тә җитте. Профессор-директор дөрес сизенгән икән: ректорлыкка үтмәде. Аның файдасына ак шар салучылар, үзе белән бергә исәпләгәндә, барлыгы өч кеше булды. Ә калганнар исә кара шар салды, тик аларның кемнәр икәнен Яковкин белә алмады. Аны тел һәм тарих фәннәре бүлегенә декан иттеләр. Кайгысыннан ул хәтта берничә көн авырып та ятты.

Үч алырга өйрәнгән Яковкин тиз генә тынычлана алмады, гаепле кешене эзләде. Аның шиге Лобачевскийга төште. Бервакыт ул шулай, студентларны котыртып, аның өстеннән губернаторга әләкләгән иде. Казаннан куылган Корташевскийның кушуы буенча, ул хәзер дә бөтен сайлаучыларны Яковкинга каршы котырткан булырга тиеш...

— Лобачевскийдан башка кеше түгел! Аннага үрелергә теләүче дә шул иде бит! — диде Яковкин, зәһәрен чәчеп.

Үч алу теләгенә бирелеп, ул шунда ук Кондыревны чакыртып, диннән язган студент артыннан күзәтү алып барырга боерык бирде.

Субинспектор исә Лобачевскийдан үч алу турында күптән хыялланып йөри иде; сөенеп, эшкә тотынды. Ул һәр көнне, Лобачевскийның күләгәсе шикелле, артыннан тагылып йөрде, аның һәр адымын калын куен дәфтәренә яза барды.

Кондыревның әләге дә, Яковкинның теләге дә икесе бер максатка — Лобачевскийны университеттан кудыру максатына юнәлтелгән иде. Ләкин ул талантлы егетнең нинди зур сәләткә ия булуы, математика-фи-

зика фәннәрен өйрәнүдәге тырышлыгы һәм зур уңышка ирешүе турында университет профессорларына да, шулай ук попечитель академик Румовский галиҗәнабларына да мәгълүм. Аны һичшиксез гаепле итеп күрсәтер өчен, шактый әһәмиятле фактлар кирәк иде.

...Көннәрдән беркөнне Лобачевский, ниндидер лекцияне тыңларга теләмичә, йокы бүлмәсенә килеп керде. Ни күрсен — Кондырев аның китапларын һәм дәфтәрләрен актара!

— Кеше өстәлен актарырга кем рөхсәт бирде сезгә, Кондырев әфәнде? — дип бусагадан ук кычкырды Николай.

Субинспектор баскан урынында катып калды. Кулыннан дәфтәрләре һәм китаплары төшеп китте.

— Сезгә минем язуларым кирәк булдымы? Шуларны Яковкинга илтеп, начальство каршында мине начар күрсәтергә телисезме?

Кондырев калтырап төште, бер сүз әйтмәде.

Лобачевский җитез генә иелеп идәндәге дәфтәрләрне алды да Кондыревка сузды:

— Мә, илт тизрәк, хәшәрәт!

Субинспектор, бу егетнең кызып китсә берни алдында да туктап калмаячагын белгәнгә, тизрәк камерадан сызу ягын карады.

— Тенти башладылар, тагын нәрсә уйлап чыгарырлар икән инде?! — дип, Николай чигәсен кулы белән кысты.— Мондый шартларда ничек укырга кирәк?! — Ул, тынычлана алмыйча, бүлмә буйлап йөренде.

Кем белән киңәшсен икән? Ибраһимов үлем хәлендә ята. Аннаны, аңардан ерак булсын өчен, Петербургка җибәрделәр. Ваня Симонов үзенең астрономиясеннән башка нәрсә турында уйларга да, сөйләшергә дә сәләтсез.

— Бартельс! Физика һәм математика бүлегенең яңа деканы! — дип куйды Николай һәм, дәфтәрләрен өстәл тартмасына яшереп, бүлмәдән атылып чыкты.

Бартельс кабинетында иде. Аның игътибарлы карашы һәрвакыт борын очына шуып төшә торган күзлеге аша егеткә текәлде.

— Нәрсәдер булган ахры? — диде ул, егетне диванга утыртып һәм үзе дә аның янына урнашып.— Күзләрегез әйтеп тора.

Аның шулай кайгыртучанлык күрсәтүе һәм ягымлы тавыш белән сөйләшүе Николайның күңелен эретеп җибәрде.

— Бетте, бетте,— диде Бартельс, шаярткан сыман һәм аңа үзен кулга алырга мөмкинлек биреп, сөйләргә керештe: — Сезне дингә каршы чыккан диләр! Советның үткән утырышында Яковкин әфәнде үзенең чыгышын тулысынча сезгә багышлады. Турысын гына әйткәндә, аның сөйләвеннән мин бернәрсә дә аңламадым. Сезнең килүегез бик яхшы булды, төшендереп бирерсез дип ышанам. Ягез, тыңлыйм!

Николай башыннан үткән күңелсез хәлләрне кызып-кызып сөйләде. Ләкин тиздән ул үзен борчыган фәнни эзләнүләргә, уйлануларга күчте һәм бер сәгать шул турыда сөйләде. Профессор аны бер дә бүлдермичә тыңлап утырды. Николайның сүзе беткәч кенә, бик нык дулкынланып:

— Бик күркәм эш! — дип бәя бирде.— Сез моңа кадәр беркем кулланмаган ысул белән тикшерә башлагансыз... Әйе шул! Сез үзегезнең укытучыларыгызны узып киттегез.

Егет, бу сүзләрдән уңайсызланып, башын чайкады.

— Юк, юк, профессор әфәнде! Әле бит минем бертөрле дә эш күрсәткәнем юк. Эзләнәм генә әле мин...

— Шул, шул менә! — дип аның сүзен бүлдерде профессор. — Эзләнәсез! Беркемдә булмаган тырышлык белән эзләнәсез! Мин ышанам — табачаксыз. Тик менә...— Бартельс урыныннан торып, кабинет буйлап сүзсез йөренеп алды һәм яңадан килеп утырды.— Тик менә сез чыннан да артык кыю фикер йөртәсез. Дөньяның барлыкка килүен чагылдырган төп мәсьәләләрне тикшергәндә без мондый кыюлыкка гадәтләнмәгәнбез. Яковкин әфәнде тикмәгә куркып калмаган икән шул. Мондый караш гомумән бик күпләргә ошамаячак. Чиркәүнең дөнья яратылу турындагы карашын юкка чыгара. Менә шуның өчен сезне күзәтеп йөриләр. Күңелсезлекләр килеп чыкмасын дисәгез, кайбер чаралар күрергә кирәк булыр: беренчедән, укыган китапларыгызны һәм язган дәфтәрләрегезне кичекмәстән яшерергә кирәк; икенчедән, вакытлыча, күз буяу өчен генә булса да, философик эзләнүләрегезне туктатып торырга кирәк...

Николайның сискәнеп китүен күргәч, Бартельс аны юатырга керештe.

— Бер дә кайгырмагыз,— диде ул аталарча ягымлы тавыш белән.— Мин бит вакытлыча дидем. Аннан тыш, сезгә башка нәрсә турында уйларга туры киләчәк, «Дифференциаль һәм интеграль исәпләүне» тә-

мамлагач та, мин сезгә ике яңа курс укырга керешәм: «Аналитиканың геометриядә кулланылышы» һәм «Аналитик механика». Беренчесен Монжга таянып, икенчесен Лагранжга таянып өйрәнәчәкбез. Баш ватарлык урыннар җитәрлек анда.

— Рәхмәт сезгә, профессор әфәнде,— диде Николай, диваннан кузгалып.— Сез миңа бик зур ярдәм күрсәттегез. Шуңа күрә мин сезгә килдем дә.

Бартельсның да күңеле нечкәрде. Аның күгелҗем зур күзләре ялтырап китте. Ул егеткә кулын сузды. Николай аның кулын ике куллап кысты.

— Ә менә сезнең философик карашларыгызга тәнкыйть күзе белән карарга, бик теләсәм дә, мөмкинлегем юк. Чөнки мин философ та, шулай ук табигать белгече дә түгел, мин математик,— диде Бартельс, егетне ишеккә чаклы озатып.— Тиздән Казанга минем бер дустым киләчәк. Броннер аның фамилиясе. Безнең университетка ул теоретик һәм тәҗрибә физикасы кафедрасына ординар профессор итеп билгеләнгән. Киң колачлы галим ул, бигрәк тә инде табигать беленең төрле өлкәләреннән мәгълүматы зур. Аның белән дуслашып китәргә мин үзем ярдәм итәрмен...

Ләкин профессор Франц Броннер белән Лобачевский бөтенләй башка шартларда танышты.

Ноябрь башында Николай беркөнне кичке якта Гостиный двордагы китап кибетенә юнәлде. Өстәл өсләрендә һәм киштәләрдә рус, татар, француз, немец, латин телендәге өр-яңа һәм бераз таушалган китаплар ята. Алар арасында оригинал һәм тәрҗемә романнар, дини китаплар, фәнни трактатлар һәм дәреслекләр бар. Пугинның ул кибетендә, моннан тыш, төрле географик карталар, гравюралар, картиналар сатыла. Монда хәтта сирәк очрый торган үсемлекләрнең — Альп җитене, Америка дөгесе һәм Кытай киндере орлыкларын табарга мөмкин.

Лобачевский сәүдәгәрнең шушы көннәрдә сатып алган китаплары белән кызыксынды. Авыр күн тышлы бу иске китапларның кайберләре шактый таушалган, берсенең хәтта почмагы көйгән...

Моны күргәч, егет «китапларның да үз язмышлары бар» дигән борынгы әйтемне хәтерләде.

Аның күңелен 1617 елны Амстердамда латин телендә басылып чыккан фәнни трактат җәлеп итте. Николай аны күңеленнән генә: «Күк сферасындагы үзгәрешләр» дип тәрҗемә кылды. Өстәлгә кире куясы

килми иде: Коперникның бөек хезмәте! Николай бу китап турында күп ишетсә дә, бүгенгә кадәр тотып караганы юк иде әле.

Егетнең дулкынлануын сәүдәгәр дә сизеп алды.

— Бик дөрес уйлыйсыз, мондый китап сирәк очрый,— диде ул.— Аның өчен хәтта ун сумны да кызганырга ярамый... Тик инде сезгә, китап сөюче студентка, мин өч тәңкәгә бирәм...

Лобачевский шунда ук кесәсенә тыгылды һәм, әлбәттә, берничә вак көмеш акчадан башка нәрсә таба алмады. Шулай да Коперниктан баш тартырга теләмәде.

— Калдырып торыгыз әле, икенче вакыт керермен,— диде ул кыю тавыш белән.

— Баш өсте,— диде Пугин һәм шунда ук китапны читкә алып куеп, аның урынына икенчесен тәкъдим итте. Монысы грек телендә иде.

— «Физика»,— дип укыды Николай һәм беркадәр паузадан соң: — Аристотель,— дип өстәде. Саргайган битләрне саклык белән генә ача башлады.

Кинәт кемдер аның җилкәсенә көчле кулын салды һәм яңгыравык матур тавыш белән грек телендә:

— Аристотель сезне күптән кызыксындырамы? — дип эндәште.

Лобачевский борылып карады һәм үз янында илле яшьләрдәге католик руханиен хәтерләткән бер кешене күрде. Яңак сөякләре чыгып тора, күзе бераз кысыграк, гаять үткен. Ә менә күз тирәсендәге тирән җыерчыклар аның ягымлы елмаюына ничектер килешми сыман.

— Таныш булыйк: Броннер — Аристотель! — диде руханига охшаган кеше. Егетнең гаҗәпләнеп карап торуын күргәч: — Гафу итегез, сезнең белән нинди телдә сөйләшергә мөмкин? — дип сорады.

— Немец телендә сөйләшергә мөмкин, хәер, мин сез әйткәннәрне аңладым, һерр Броннер,— диде Николай, хөрмәт белән баш иеп, грек телендә.

— Шул чаклы күп тел белгәч, сез студент Лобачевский булырга тиеш... Әйе бит?! — диде Броннер немец телендә һәм, шатланып, егеткә кулын сузды.— Көтмәгәндә очраштык! Сезнең белән танышуыма бик шатмын,— дип сүзен дәвам итте Броннер.— Әле бүген генә сезнең турыда профессор Бартельс сөйләгән иде. Нинди борынгы китапны алып читкә куйдыгыз? —

диде, бер кырыйда яткан сафьян тышлы иске китапны күрсәтеп.

— Коперникның «Күк сферасындагы үзгәрешләр» дигән трактаты. Мин аны алмадым, бәлки... алмам да әле.

Броннер шунда ук бу сүзләрнең серенә төшенде.

— Кыйммәтрәктер шул студент кешегә,— диде.— Шулай да андый китапларны ычкындырырга ярамый. Мин түлим сезнең өчен.

Алар урамга чыктылар. Көн шактый салкын, һава дымлы иде. Көчле җил исә, шәрә агачларны туктаусыз чайкалдыра. Лобачевскийның юка пальтосы бер дә җылытмый диярлек иде. Тиз кайтырга булдылар.

— Хәзер эшегез юкмы сезнең? — дип сорады Броннер.— Ул чагында мине университетка чаклы озатыгыз әле.

Профессор оялчан егетне дусларча култыклап алды, һәм алар Воскресенский урамы буйлап киттеләр.

— Петербургта чакта Корташевский, ә биредә Бартельс студент Лобачевский турында сөйләгәндә үк мин сезнең белән танышырга уйлап куйган идем. Ә менә бүген кулыгызда Аристотельне күрдем... Геометриядәге эзләнүләрегез ифрат үзенчәлекле булса кирәк. Сезнең яшьтә мин дә шулай дәртләнеп мавыга идем...

— Нәрсә белән мавыга идегез, һерр профессор? — дип, аның сүзен бүлдерде Лобачевский һәм, түземсезлек күрсәтүеннән уңайсызланып, комачтай кызарды.

Броннер студентка игътибар белән карап куйды һәм уйга калып:

— Нәрсә беләнме?..— диде.— Юк, сезгә яхшырак аңлашылсын өчен мин элек икенче нәрсәне сөйлим... Моннан илле ел чамасы элек Дунай буендагы кечкенә шәһәрдә — Гехштэдтта — аксыл чәчле бер малай дөньяга килә. Аның этисе эшче, кирпеч хәзерләүче эшче була. Тик аннан килгән акчага гына яшәргә мөмкин булмаганга, скрипка уйнап та кәсеп итә... Сезгә гаҗәп тоеладыр инде: скрипка һәм кирпеч!

Броннерның йөзе саргылт, ә тавышы артык моңлы тоела иде. Ул бераз тынып торды да Николайдан:

— Дустым, кызык булмаган нәрсә сөйләп сезне бик ялыктырмыйммы? — дип сорап куйды.

— Юк, юк, һерр профессор! Мин, киресенчә, бик шатланып тыңлыйм. Минем белән... болай итеп бик еш сөйләшмиләр.

— Миңа да бит еш сөйләргә туры килми. Димәк, ул малайның тарихын ахырына кадәр тыңларга вәгъдә бирәсез? Тыңлагыз, сөйлим. Ул малай бик башлы була, һәммә нәрсә белән кызыксына, кечкенәдән үк укырга-язарга өйрәнә. Ләкин өйләрендә китап сатып алырга түгел, ипигә дә акчалары җитми. Нәрсә эшләргә аптырагач, малай Бенедиктин орденына монахлыкка керә һәм, аерым хөҗрәдә яшәп, монастырьның бай китапханәсендә укырга мөмкинлек ала. Китап укыр өчен ул бар кыенлыкка, хәтта әле хөҗрәсендә чыелдашып чабып йөргән тычканнарга да түзеп яшәргә риза була.

Китапханәдә ул математиканы, механиканы, физиканы бик тырышып үзләштерә, perpetium mobile *не гамәлгә ашыру турында хыяллана. Хәтта әле оча торган машина уйлап табып, шул машинага утырып иректә кош кебек, күкләргә очарга һәм күңеле бизгән монастырьдан котылырга тели. Малайның фәнни хәзерлегенә югары бәя биреп, руханилар үз араларында зур галим булдырырга исәплиләр һәм аны монастырь акчасына Эйхштадт шәһәрендәге католиклар университетына укырга җибәрәләр.

Броннер, кинәт сүзен бүлеп, мәһабәт ак йорт каршында тукталып калды. Йортның ишеген таш арысланнар һәм шулар янына баскан сакчылар саклый иде.

— Бу нинди бина?

— Казанның хәрби губернаторы яши монда,— дип аңлатты Николай.— Әнә теге сарысы, кварталның буеннан-буена сузылганы — духовная семинария.

— Шулаймыни?! Димәк, университеттан куылган очракта, мин шунда эшкә урнаша алам! — диде профессор көлеп.

— Сез рухани булмагансыздыр ич?

— Әһе...— диде Броннер, ике төрле уйларга урын калдырып.— Хикәяне дәвам итик. Димәк, 1782 нче елның башында яшь монах университетта үзенең белемен арттыра башлый: математика фәннәрен үзләштерә, бигрәк тә җир үлчәү һәм астрономия белән ныклап мавыга. Галәмнең чиксез булуы, безнең кояш системасы кебекләрнең күплеге һәм аларда тереклек булу ихтималы аңарга тынгылык бирми. Дини китаплар инде аны кызыксындырмый. Һәм ул монахлык-

---

* Perpetium mobile (лат.) — мәңгелек двигатель.

тан баш тартып, иллюминатлар орденына * керә. Аристотель дигән кушамат ала. Ул яшерен союзның максаты — халыкны агарту һәм тормышны камилләштерү була. Тик менә хөкүмәт кенә моңа тыныч карый алмый һәм 1785 нче елда ул орденны тар-мар итә. Иллюминатларны эзәрлекләү башлана. Теге егетебез, әлбәттә, кулга алып төрмәгә япканны көтми, Швейцариягә кача. Анда ул үзен тулысынча фәнгә багышлый, галим дигән исем ала, төрле илләрдә яши һәм ниһаять... «Азиянең тәрәзәсе» булган Казанга килә... Шуның белән минем баштан үткәннәр дә бетә,— диде Броннер.

Алар инде бу вакыт университетка җиткәннәр иде.

— Сезнең баштан үткәннәр? — дип гаҗәпләнеп сорап куйды Лобачевский, профессорга текәлеп.

— Әйе шул,— диде профессор, егеткә сынап караган хәлдә.— Кирәкбезме?

— Рәхмәт, һерр профессор...— диде Николай, бик дулкынланып.— Ләкин хәзер керә алмыйм әле...

— Мин аңлыйм сезне...— Броннерның күз төпләрендәге җыерчыклары беткән сыман тоелды.— Мин хәзер сезнең хәлне аңлыйм, шуңа күрә баштан үткәннәрне сөйләдем дә. Вакытында бит мин үзем дә фән белән бик мавыккан кеше. Сез, дустым, минем янга теләгән чакны керегез. Хушыгыз! — Аның тавышында җылылык сизелә иде.

— Хушыгыз! — диде Николай һәм, профессорга хөрмәт күрсәтеп, ишекне ачып җибәрде.

Ул кичне Лобачевский бик соң әйләнеп кайтты: Броннерның авыр язмышы турында, үзенең күргәннәре турында уйлап йөрде. Әйе, фәнгә юлны тиз генә салырга мөмкин түгел икән! Бартельс дөрес әйткән: Броннер чынлап та зур галим икән!

...Франц Ксаверий Броннер исә кабинетында, уйга калып, тәрәзәдән карап тора. Буш урам... Чит шәһәр... Ят халык... Шул ят халык арасында күпме яшәргә туры килер?.. Ә ни өчен ул халык ят булсын ди аңа? Профессорның күңеле кинәт яктырып, йөзе ачылып китте. Менә бүген бер студент белән танышты, һәм, көтмәгәндә, беренче күргән кешесенә үзенең башыннан үткәннәрне сөйләп бирде. Ә бит аның биографиясендә

---

* Бу орденның исеме illuminato дигән латин сүзеннән алынган, мәгърифәт сүзенә туры килә.

политик яктан шактый шик тудыра торган детальләр бар...

Хәер, профессорга бүгенге сөйләгәннәренә үкенергә туры килмәде.

## 4

Лобачевский профессор Броннер белән көн саен диярлек очрашып, сәгатьләр буе сөйләшеп утыра торган булып китте.

Алар фән турында да, шулай ук мәгариф эшләренең бик түбән торышы турында да, хәтта фән үсешен тоткарлаучы крепостное право турында да берберсенә ышанып, эчкерсез рәвештә сөйләштеләр.

Андый сөйләшү вакытында бунтарь гадәтле профессорның күзе ут кебек яна башлый, йөзендәге һәр мускулы киеренке төс ала.

Броннер яныннан студент Лобачевский һәрвакыт рухланып чыга иде.

Хәзер инде ул, Бартельсның сак булырга киңәш итүенә карамастан, Ломоносов, Аристотель, Коперникның хезмәтләрен тырышып үзләштерде һәм хәтта Вольтер белән Дидроны да укый башлады.

«Ничаклы күбрәк укыса, шул чаклы хөр фикерлерәк була бара», дип язды аның артыннан армыйталмый күзәтү алып барган Кондырев. Лобачевский исә субинспекторга тупас итеп җавап бирүен һәм, аның «бакчасына таш атып», студентларны көлдерүен дәвам итте.

Николай профессор Бартельсның һәм профессор Литтровның бер генә лекциясен дә калдырмады һәм алар җитәкчелегендә югары математика һәм астрономиянең төрле өлкәләрендә фәнни-тикшеренү эше алып барды. Көннәр буе фән белән шөгыльләнеп ул үз өстендә кара болыт җыелганын сизми калды.

Субинспектор аңа бәла тагу өчен нәрсәләр генә эшләмәде! Инспектор журналына, Лобачевскийның «рөхсәтсез университеттан китеп йөрүләре» шикелле, ялган белешмәләрне һәм «тәрбияле кеше өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне боза, итагатьсезлек күрсәтә һәм начальствога буйсынмый» дип язган гаепләү кәгазьләрен терки барды.

Кондыревның яла ягуы нигезендә, «даими рәвештә тыелган эшләрдә катнашып студентларны供 аздыруы вә сүз тыңламавы өчен өлкән Лобачевскийга шелтә белдерергә һәм камерный студент буларак 60 сум иганә

алудан, шулай ук начальство рөхсәтеннән башка университеттан чыгып йөрүдән аны мәхрүм итәргә» дигән фәрман чыкты.

1811 елның 23 мартында булды бу. Николайга инде унсигезенче яшь, акчаның бик тә кирәк чагы. Әмма ялыктыргыч атналар уза торды, ә университетта аны яклап сүз әйтүче табылмады. Акча кытлыгы үзен көннән-көн ныграк сиздерде. Болай да инде агалы-энеле Лабочевскийлар әллә ни көр тормышта үскән кешеләр түгел. Гимназиядә дә, университетта да аларны кызгану йөзеннән бушлай укыттылар. Искереп-ертылып коелып төшәр дәрәҗәгә җиткәнче өстерәргә кушсалар да, бушлай кием-салым биргәләделәр, ашаттылар, яшәп торыр өчен тулай торакта урын да таптылар.

Ара-тирә Макарьеводан аз-маз акча килгәли, тик аны кулга алырга оят — әниләре болай да җитмәүчелектән интегә. Акча дигәнең ашау-эчү, кием-салым өчен генә түгел, театрга барырга, китап һәм бүләкләр алырга да кирәк бит. Ничек тә булса берәр әмәлен табарга иде.

Көннәрдән беркөнне, базар мәйданында каңгырап йөргән чакта, белдерү-афишалар белән ямалып беткән әйләнмәле барабан тирәсендәге халык төркеме күзенә чагылды. Якынрак килсә, әле генә яңа белдерү эленгән: «Сәүдәгәр Сафронов йортында торучы надворный советник Чемодуров фатирыннан эт югалды — төсе кара, зур түгел, күкрәгендә ак сызыгы да бар. Шушы этне табып губерна типографиясендәге каравылчыга тапшырган кешегә биш сум акча биреләчәк».

Николай бу кечкенә кара этне эзләп табарга булды, ни дисәң дә биш сум камерный студентның бер айлык хезмәт хакы бит. Шәһәр урамнарын сөреп шактый йөрде ул, бер генә ишегалдын да карамыйча калмады. Йөри торгач, ярым җимерек йортлар тезелешкән тар урам аны ташландык ком карьерына алып килде. Бу тирәләр дә шәһәр дип аталсын инде: юынтык су түгелгән пычрак күлләвекләрдә дуңгызлар аунап ята, бәйдәге кәҗәләр таптана, әтәч-тавыклар комда коена. Шунда ук ялан тәпиле, ыштансыз малайлар йөгерешеп йөри.

Николайның кәефе болай да юк иде. Әлеге манзараны күргәч чырае тагын да ныграк сытылды. Ул кинәт алҗып, сөмсере коелып киредән университет ягына таба атлады: «Акчасыз ничек торырга?..»

Әллә кайдан гына Гаврило Панкратовның саңгырау тавышы ишетелде:

— Каян шулай кәефеңне кырып җибәрделәр әле?

— Юк, берни дә юк...— дип тотлыкты Лобачевский. Аның коңгырт йөзенә алсу төс йөгерде.

— Яшермә! — Гаврило аны туганнарча иңбашыннан кагып куйды.— Юк, дускай, син яшермә... Сизәм бит мин. Әйләнә-тирәңдә һичкемне күрмисең, ничә тапкыр кычкырып та җавап дәшмәдең. Нәрсә булды?

— Әйттем бит инде, берни дә юк.

— Нәрсәңне дә булса югалттыңмы әллә?

Николай көч-хәл белән генә күз күтәреп бер карап алды да эч серен уртаклашырга, сагышын бушатырга теләде:

— Ишетмәдеңмени соң, камерный студентлыгымны алып мине бер тиенсез калдырдылар бит. Менә шуңа күрә дә, хәерче сыман капка саен сугылып, ниндидер Чемодуровның биш тәңкәлек этен эзләп йөрим.

— Алай икән! Беләм мин ул белдерүне... Рухыңны төшермә, андый гына күңелсезлекләр күп булыр әле ул... Әллә акча ягы миндә иркен дип беләсеңме, түзәм бит менә... Карале, Коля, синең берәр эш эзләп караганың юкмы?

— Нинди эш? — Николай аңламыйчарак торды.

— Әйтик, Казанда хәзер үз ташпулатларында яшәүче байлар бик күп. Паркет идәннәрен шомартырга кирәкме — кирәк! Шундый йортларның берсендә атнага ике тапкыр биеп кайтам мин. Түләвен әзрәк түлиләр, әлбәттә, шулай да акча инде, ә акча юлда аунап ятмый, бүген ышандык инде моңа...

Икенче көнне Панкратов аны үзе янына эшкә дә урнаштырды. Дүшәмбе һәм атна кич көннәрне барып, алар икәүләшеп Кабан күле буендагы бер ташпулатның идәнен шомарта торган булдылар. Бу йортка беренче кат килеп кергәндә Лобачевский үзен оҗмахка эләккәндәй хис итте. Урамда салкын яз, кырыс Идел җилләре исә, ә боларның өй эчендә көньяк җимешләре үсеп утыра; кәрҗиннәрдә төрле төстәге зур-зур чәчәкләр; пыяла шүрлекләрдә кыйммәтле асылташлар, җансыз булсалар да кызыктыргыч курчаклар...

— Бу затлы уенчыклар белән әфәнделәр үзләре уйнарга ярата,— ди Панкратов,— берсе-берсе генә дә йөзәр сумнан артык тора аларның...

Панкратов кыйммәтле нәрсәләр ватылудан шүрләптер, ахрысы, бу залны гел үзе җыештыра иде. Нико-

лайга күбесенчә балалар бүлмәсе белән кабинет-китапханә туры килә иде.

Кабинетта аяк очына гына басып йөрисе юк, җиһазлары барысы да имәннән; шкафларда алтын тышлы калын китаплар. Аларны күргәч Николай үзенең гарәпчә белмәвенә үкенеп куя, монда татарча китаплар бик аз бугай.

Балалар бүлмәсендә рәхәт ичмасам — якты, иркен, күңелле! Уенчыкларның иге-чиге юк. Курчаклары, туплары, кургаш солдатлары дисеңме? Шунда ук чит ил китаплары — рәсемнәре искитмәле. Николай аларга кагылмыйча түзә алмый. Шулчак ерак Макарьеводагы балачагы келт итеп искә төшә дә куя.

Дөресе белән ялганын бергә буташтырып бәйләнчек инспектордан сорап китү җаен тапкан саен, Николай үз эшен йорт хуҗасына ошардай итеп башкарырга тырышты. Инде бай, гимназиядә укучы өлкән улының студентлар белән дуслашып китүеннән бик тә канәгать булып, көнлек эш хакын арттырам дип торганда гына Казанда шаккатырырлык вакыйга булып алды.

Чыгарылыш имтиханнарына санаулы гына көннәр калып бара иде. Гадәттәгечә Панкратов белән икәү идән шомартырга килделәр. Балавызлап чыккач, бераз гына ял итеп алырга булдылар. Гаврило кунак бүлмәсенә чыгып китте, ә Николай аягына щеткасын кигән килеш кабинеттагы креслога утырып хыялга чумды: тиздән аңа көнлек мәһәрне арттырачаклар бит һәм ул әнисенә дә акча җибәрә башлар. Мөстәкыйль тормышның башлануы инде бу! Ә мөстәкыйль булу — димәк туган-тумачаларыңнан, Яковкиннардан бәйле булмау дигән сүз! Шушы өмет Николайга көчне өстәп кенә тора.

Эш бетәр алдыннан хуҗаның олы малае гимназист Каюм бәрелеп-сугылып кайтып керде, кулында шәһәрдә әле генә чыга башлаган «Казанские известия»нең яңа саны.

— Ишеттегезме,— дип кычкырды Каюм, бусагадан атлап керешкә үк.— Вәт ичмасам яңалык дисәң дә яңалык. Ниндидер француз шар белән һавага күтәреләчәк. Билләһи, менә ышанмасагыз укып карагыз!..

Лобачевский Каюм кулыннан газетаны йолкып алганын сизми дә калды. Каударланып укырга кереште: «Казанга килгән чит ил кешесе Тушель шушы июнь

аенда һавада сәяхәт ясарга җыена. Бу турыда әле махсус белдерү булыр...»

Һавага күтәрелеп баручы аэростат рәсеменә бик озак карап торды Николай. Аскы өлешенә бәйләнгән кәрҗиндә мыеклы бер кеше утыра.

Каюм Лобачевскийга текәлде:

— Чын хәл микән, әллә рәсемдә генәме?

Николай гимназист малайга Архимед законы турында сөйләп бирде. Җылы һаваның салкыннан җиңелрәк булуын, ә инглиз физигы Генри Кавендиш ачкан водород газының гадәти һавадан 14 тапкыр җиңелрәк икәнен төшендереп, ул, әлбәттә, йөк тә күтәрә алачак,— диде.

— Кирәк бит әй,— дип дәртләнеп куйды Каюм,— без дәресләрдә өйрәнә торган закон кешене һавага да күтәрә ала икән!

* * *

Менә көткән көн дә килеп җитте. Һава шарында очу тәҗрибәсе уздырылачак Арча кырына, Казан Швейцариясе дип аталучы таулы урынга якын гына яшел мәйданга иртәдән үк халык агылды. Шәһәрнең бөтен тынгысызы, яңалыкка сусаганы шунда җыелды. Әлбәттә, гадәттәгечә хатын-кызлар күбрәк иде: ак, яшел, кызыл, зәңгәр төстәге күлмәкләр, мәйданны бизәп, бәйрәмчә төс биреп тора. Урысча һәм татарча сөйләшүләр, тояк тавышлары, городовойларның акырулары — барысы бергә кушылып бәйрәм шавына әверелде.

Сәүдә итеп калырга ашыгучылар да күп иде. Төрле төстәге шарлар, әллә нинди уенчыклар, куас һәм прәннек сатучылары да җитәрлек.

Агалы-энеле Лобачевскийлар төркемне ерып алгарак үттеләр. Ялтыравык бакыр торбалар тоткан музыкант-солдатлар урнашкан беседка янында кәрҗин беркетелгән озынча зур өй чаклы һава шары аерымачык күренә иде инде. Шарның юка ярысы төрле төскә буялган — әйтерсең лә ярминкә балаганы. Үзлегеннән очып китмәсен өчен дүрт имән казыкка бәйләп тә куйганнар үзен — шар юан бауда салмак кына талпынып тора. Тәртип саклаучы городовойлар Николайны шарга якын җибәрмәделәр. Ак эшләпәле кызчыгын кулында күтәреп торып алҗыган барин:

— Тагын озакмы көтәргә? — дип сораган иде. Шуларның берсе:

— Нәкъ унынчы яртыда оча! — диде.

Бер карашка, очарга ыргылучы әкәмәт зур шар шушы хәтле халыкка әсир төшкән сыманрак иде.

— Француз, әнә француз килә! — дип шаулашты халык.

Агалы-энеле Лобачевскийлар, ниһаять, бу кыю французны үз күзләре белән күрделәр. Кигән киеме дә соклангыч иде аның. Килеп чыгышына кемдер әйтеп тә салды:

— Шәп-шәрә-ә-ә!

Юк, ул шәрә түгел, цирк акробатлары кебек алсу трико кигәнгә генә шулай күренә. Буйга-сынга төз үзе. Күкрәгенә дә, биленә дә бәллүр сәйлән уралган. Беләкләре соклангыч таза. Төскә-биткә дә чибәр икән: куе кара кашлы, кодрә чәчле, өскә кәкрәеп торган кара мыеклы, сакалы да килешле генә. Махсус басмага менгәч ул бөтен хатын-кызлар өчен аерым кыланыш ясап ике бармагын ирененә тидереп алды. Тегеләренә шул җитә калды, дер селкетеп «ур-ра!» кычкырдылар.

Аэронавт дүрт якка аерым-аерым баш иде дә үз телендә сөйләп китте:

— Сөйкемле мәдам һәм месье! Һава шарында сәяхәтем белән кызыксынып килүегез өчен зур рәхмәт. Бүген сез онтугысызынчы гасырның бер могҗизасын күрерсез. Тик болытлар итәгенә менеп киткәнче мин сездән бераз гына шәфкатьлелек өмет итәм — һәркайсыгыз хәленнән килгәнчә, минем зур чыгымнарымны бераз капларлык ярдәм итсәгез иде...

Күперчектән эре кыяфәт белән генә төшсә дә эшләпәсенә бакыр, көмеш, бик сирәк кенә алтын таңкалар ыргытып ташлауларын күргәч, кечерәеп калды бугай үзе... Аннан аэростатның кәрҗиненә кереп утырды да җәһәт кенә сигара кабызды. Публикага күз йөртеп чыккач ашыгып-ашыгып төтен йота башлады.

— Тартып кал, әлегә исән бит син,— диде теге кызын күтәргән барин,— мәтәлеп төшсәң соң булыр.

Алеша керпе кебек бөрешеп арткарак посты. Әйе, куркындыра шул. Музыкантларның гына исләре дә китми, французның кәефен күтәрергә теләгәндәй «дөмбердәтәләр» генә. Ә аңа ниндидер алтынсу эчемлек алып килделәр.

— Дару китерделәр! — Баягы барин сүзгә туймас кеше ахрысы.— Теге дөньяда болай сыйлап тормаслар шул...

Француз бер каплап кына стаканны бушатты да, мыегын бөтерә-бөтерә күк гөмбәзенә текәлде, биеклеген чамаларга тырыша диярсең. Аңа ияреп кәмит карарга җыелган халык та күккә карады — биек шул! Баш әйләнгеч биек! Тән чемердәп тора.

Николай бу французның батырлыгына гашыйк иде...

— Кузгалды! — дип шаулашты халык.

Дөрестән дә, бауны чиштеләр, һәм шар һавага ыргылды. Француз кыюлыгын саклап төркем өстенә кул изәде.

— Вәт батыр, тәвәккәл кеше бу!

Кыю иде шул бу француз. Аэростат туктауны белмәде, гел өскә күтәрелде. Агачлар да түбәндә генә калдылар. Быргылар, тәлинкәләр тагын да ныграк яңгырадылар. Халык дигәнең эшләпә, фуражка, түбәтәйләре төшеп киткәнен дә сизмичә күккә багынды. Сызгыру, шатлыклы үкерүләр ишетелде.

Лобачевский бөтен халык белән бергә дәррәү кузгалып куйды, тик әллә кайларга йөгерәсе юк, шар һәркемгә яхшы күренә иде. Әнә, француз кулъяулык очырды — зәңгәр кошчык булып агачка килеп тә кунды. Малайлар берсен-берсе йолка-йолка шул кулъяулыкны алып төшәргә җан талаштылар.

Күк йөзе чалт аяз. Җил дә талгын гына. Аэростат бер ноктада туктап калгандай итте дә әкренләп төньяк-көнбатышка таба юл алды.

— Яшәсен аэростат! Дилижансларга көн бетте!

Шаккатырлык хәл иде шул бу. Моңарчы оча торган шарлар турында күпме хикәятләр ишетелгәндер, ә менә үз күзең белән күргәч хәйран кызык икән...

— Ә кем белә,— дип сүзгә кушылды Николай тантаналы төс белән,— тора-бара, бәлкем әле җирдән һәм судан гына түгел, һавадан да йөк ташырбыз, кирәк җиребезгә барырбыз...

Һава агымы аэростатны үзенә ияртте. Мөгаен Казанка өстенә килеп җиткәндер. Кинәт һава шары күзгә күренеп сулыга башлады, инде аска таба ыргылуы да сизелә иде... Төшә торгач биек агачлар арасында күренеп кенә алды да, кайдадыр шунда юкка да чыкты.

Николайның тез буыны калтырый башлады — кызганды, бик кызганды ул французны. Бер Николай гына түгел, бөтен халык хәсрәткә батты. Тантана югалды.

Сүз һава шарыннан тизрәк йөри икән — французның Казанка болынлыгына исән-сау килеп төшкәнлеге турында хәбәр әйләнеп кайтты. Әллә ни куркыныч хәл булмаган булуын, кәрҗине генә җиргә бераз катырак бәрелгән ди бугай.

Ярты сәгатьләп үттеме-юкмы, җигүле ат аэронавтны янә Арча кырына алып килде. Үз итеп баш исә дә, француз инде артыгын кыланмады. Алҗыганлыгы сизелеп тора. Шулай да рухы күтәренке иде. Кичен бу очышны кабатларга теләвен белдерде һәм казанлылардан кем дә булса шәһәр манзарасын һавадан күзәтергә, хәйран кылырга теләмиме, дип публикага мөрәҗәгать итте.

Бу тәкъдимнән Николайның йөрәге ешрак тибә башлады, сулуы кысылган кебек булды. Шулай да ул аэронавт янына башкалардан алданрак килеп басты.

— Мин очарга телим! — диде Николай саф французча.

Аэронавт елмаеп аңа кулын сузды.

Кичен Арча кырына тагын шәһәр халкы җыелды. Бу юлы монда студентлар, гимназистлар, шәкертләр, гомумән яшьләр бик күп иде. Алар университетны тәмамлаучы Николай Лобачевскийның аэростатта ничек очуын карарга килгәннәр.

Старт алдыннан гына һава шарының чагыштырмача авыр яктырткыч газ белән тутырылган булуы һәм ике кешене кыенлык белән генә күтәрәчәге билгеле булды. Хәл мөшкелләнде: якорьсыз һәм бик аз гына балласт белән очарга туры киләчәк, димәк җиргә төшү читенләшә.

Билгеле инде, Николайга хәвеф-хәтәр турында уйларга соң: аның теләгән һәммәсе белә, ә хәлиткеч минутта гына очарга куркып адәм көлкесе булу аңарга үлем белән бер иде... Аннары — француз аэронавты яхшы репутацияле, нәрсә буласын белә торгандыр; әгәр андый-мондый хәл туа калса, аның белән бергә ул үзе дә үләчәк бит, дип Лобачевский үз-үзен тынычландырырга тырышты.

Нәкъ кичке сәгать җидедә «һава корабле» очып китәргә тиеш иде. Кысынкы кәрҗиндә аэронавтлар үз урыннарын алуга, имән казыкларга бәйләнгән бауларны чишәргә керештеләр. Шулчак старт мәйданчыгына ашыгудан һәм ачуыннан яңаклары кызарып бүртенгән инспектор Яковкин йөгереп керде дә:

— Туктагыз... бауларны ычкындырмагыз! — дип

сөрән салып кычкырды.— Лобачевский, хәзер үк төш аннан! Кем сиңа рөхсәт бирде, кем? Минем башыма җитәргә телисеңме? Юк, барып чыкмас бу башбаштаклыгың!..

Шул ук кичне Николай Лобачевскийны ике тәүлеккә карцерга яптылар.

Озак та үтмәде, аннан да шомлырак вакыйга булды.

Имтиханнар барганда, көннәрдән беркөнне, Яковкин студентларны актлар залына җыйды. Анда ул үзенең гайрәтле тавышы белән патша указын кычкырып укыды. Башкаладан килгән ошбу фәрманда: «Казна хисабына укучы разночинец студентларны гаеп эшләр эшләгән очракта университеттан чыгарырга һәм солдатка озатырга. Дворян балаларының андый эшен падишаһ әгъзәмгә хәбәр итәргә...» диелгән иде.

Разночинец белдембаш Лобачевскийдан котылырга, ниһаять, җайлы момент туды. Патша указында әйтелгән «гаеп эшләр» не теләсә кемнең теләсә ничек аңлавы мөмкин иде. Солдатка куарга бу әдәпсез студентны!

Кондырев, бер көнен әрәм итмичә, Яковкинга бик зур итеп рапорт язып тапшырды.

«Лобачевскийларның олысы соңгы өч елда күп вакыт әдәпсез булды, иптәшләре алдында тәрбиясезлек галәмәтләре күрсәтте, күп тапкыр җәзага тартылды, шулай да төзәлмәде; үзсүзле, кире холыклы булып, начальствоны тыңламады, үзе турында артык зур фикердә булды», дип язды ул.

Лобачевскийның төрле гаеп эштә катнашканы өчен генә дә 33 мәртәбә инспектор журналына теркәлгәнен искә алып, субинспектор мондый тәкъдим кертте: «бу студентны акылга утырту эше... кичектерелмәскә тиеш; яхшылык яки начарлык белән генә тәртипкә чакыруны начальство үзе хәл итәр».

Ә инде хәл иткәндә начальство яхшылыкка авышмасын өчен, Кондырев шул көннәрдә үк яңа рапорт тапшырды, монысында исә Николай Лобачевскийның дингә каршы чыгуын күрсәтте.

Динсез студентны университеттан, «гыйлем йортыннан» куу өчен шул гаепләре бик җиткән иде. Һәм инспектор Яковкин, бик рәхәтләнеп, студент Лобачевскийның тәртибен тикшерү мәсьәләсен Совет утырышына куйды.

Совет 1811 елның 10 июлендә җыелды. Совет бу мәсьәләне Яковкин тәкъдим иткәнчә хәл кылган оч-

ракта, Николай солдат шинеле киячәк: дворян нәселеннән булмагач, аны солдатка җибәрү өчен патша рөхсәте кирәкми иде.

Ләкин яла ягучылар бик нык оттырдылар. Физика-математика бүлеге профессорлары сәләтле студентны бердәм рәвештә яклап чыктылар. Нәкъ шул көннәрдә Казанга килеп чыккан академик Вишневский да аны яклады. Инспекторның мәкеренә үч итеп, профессорлар Бартельс, Литтров һәм Броннер коллектив тәкъдим керттеләр. «Николай Лобачевскийның математика һәм физика фәннәрендә ирешкән уңышларын һәм сәләтен искә алып, аны магистр дәрәҗәсенә күтәрергә»,— диделәр профессорлар, шуның нәтиҗәсендә аны университетта калдырырга һәм киләчәктә профессорлыкка хәзерләргә тиеш таптылар.

Бер яктан солдат шинеле кидерергә тырышсалар, икенче яктан профессор итәргә теләк белдерелде.

Шулай итеп, Николай котылып калды. Күпчелек тавыш белән Совет «ошбу егетне фән өчен сакларга тиешле» дигән карар чыгарды. Шул ук вакытта «шактый дәрәҗәдә динсезлек галәмәтләре күрсәткән өчен» аны тантаналы шартларда тәүбә иттерергә карар кылынды.

Советның ул карарын попечитель Румовский 1811 елның 3 августында раслаган һәм бер үк вакытта Лобачевскийның «искиткеч зур сәләтенә тап төшерүче тәртибе хакында» әйтеп китәргә кирәк тапкан. Николай, аның аталарча кырыс сүзен яхшы аңлап, төзәлергә вәгъдә бирде.

Берничә ай да узмады, Лобачевский абруй казанды: «Күк җисемнәренең эллипс рәвешендә хәрәкәт итүләре теориясе» дигән язма фәнни эше өчен аңа магистр дәрәҗәсе бирелде. Аның бу диссертациясен Бартельс болай бәяләде:

«Кыска гына шушы хезмәтнең күп урыннары авторның гаять зур математик сәләткә ия булуын күрсәтә, һәм бу сәләт киләчәктә дөньякүләм шөһрәт казаначак».

## МӘҢГЕЛЕК ҺӘЙКӘЛ

### (Эпилог)

Борынгы Казан шәһәренең чал Кремленнән тарихи Ленин урамы буйлап килгәндә, үзенең мәһабәт колонналары белән башка барлык биналардан аерылып тор-

ган университетка һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы йортына якынлашкач, һәркемнең күзе уртадагы җыйнак кына матур бакчага төшә. Анда, кара мәрмәр постамент өстендә, даһи галим, кешелек дөньясын таңга калдырган неевклид геометриясен иҗат итүче, Ватаныбызның ялкынлы патриоты Николай Иванович Лобачевскийның бюсты тора. Аның чиксез тирән уйларга чумган башы, киң маңгаендагы җыерчыклары безнең халыкка хас якты акыл, нык ихтыярлы характер һәм сынмас түземлек турында сөйли.

Ул һәрвакыт шушында, һәрвакыт безнең белән. Аны биредә, бу бөтен җир шарында данлыклы университет һәм СССР Фәннәр академиясе белән бергә күз алдына китерәсең. Алар — мәңге бергә калырга, мәңге яшәргә лаеклы кеше турындагы тарихи истәлекләр, рус һәм совет фәненең данлы үсеш юлын күрсәтүче дәлилләр.

1892 елны, тууына 100 ел тулу уңае белән, Лобачевскийга Казанда әнә шул һәркем өчен таныш һәйкәл куела. Аны ачкан чакта ялкынлы речь сөйләнә: «Бер генә үсемлек тә җирдән, бөек кешенең статуясы кебек, зур авырлык белән күтәрелеп чыкмый, ләкин аның каравы, бер генә үсемлек тә ул кадәр тантаналы үрләп китми, моннан да артыграк җимешләр бирми һәм үз тирәсенә бу хәтле күп әйбәт орлыклар чәчми».

Казандагы бу һәйкәл планетабыздагы галимнәр һәм укучы-яшьләр акчасына салына. Аны ачу Лобачевскийның хезмәтләренә бөтен кешелек дөньясының бик югары бәя бирүе була. Бу көнне Казан университетына шул заманның иң атаклы кешеләреннән күп телеграммалар һәм хатлар килә.

Казан университетының почетлы докторы Дмитрий Иванович Менделеев менә мондый тарихи телеграмма җибәрә:

«Геометрик белемнәр барлык төгәл фәннәрнең нигезен тәшкил итә, ә Лобачевский геометриясе — ул Россиядә фәннәрнең мөстәкыйль үсеше таңы булып тора. Чәчелгән фәнни орлык халыклар урып алыр өчен тишелеп чыгар».

Атаклы француз математигы Таннери Н. И. Лобачевскийны Яңа дөньяны, ягъни Американы ачкан Колумбка тиңли.

Инглиз галиме Клиффорд болай дип яза:

«Галенга карата Везалий ничек булса, Птолемейга

карата Коперник ничек булса, Евклидка карата Лобачевский да шулай ук булды. Коперник белән Лобачевский арасында кызыклы параллельлек бар. Коперник һәм Лобачевский — икесе дә чыгышлары буенча славяннар. Алар икесе дә фәнни идеяләрдә, карашларда революция ясадылар, һәм бу революцияләрнең әһәмияте бер үк төсле. Бу революцияләрнең гаять зур әһәмияте шунда ки, алар — Галәмне аңлау өлкәсендәге революцияләр булдылар...»

Ватаныбызның даһи улы Николай Иванович Лобачевский, фәндә революционер буларак, үз заманын йөз елларга алга узып китте. Аның тарафыннан ясалган бөек ачыш — неевклид геометриясе барлыкка килү — пространство турындагы төшенчәне чиксез киңәйтеп, тирәнәйтеп һәм тулыландырып, таныл-белүне камилләштереп, фәннең барлык тармакларын бик нык алга этәрде, ә Лобачевскийны илебез фәненең горурлыгына, титанына әверелдерде. Бу чын-чыннан мәңгелек һәйкәл булды.

Даһи философ-геометрның тормышы һәм күп яклы эшчәнлеге биредә, Казанда вә Казан университетында, үтә.

Һәрвакыт тирән белемгә омтылучы яшь Лобачевский фәннең төрле тармаклары белән тирәнтен кызыксына, бертуктаусыз эзләнә, иҗат итә. 1816/17 нче уку елында, егерме өч яшендә, ул инде математика профессоры.

Тагын ун елдан соң Николай Иванович Казан университетының ректоры итеп сайлана. Ул бу мактаулы вазифаны бертуктаусыз егерме елга якын башкара. Аның турыдан-туры катнашы белән университет биналарының гүзәл ансамбле үсеп чыга, фәнни китапханәнең эше җайга салына, «Гыйльми Язмалар» басыла башлый. Берүк вакытта ул үзенең киеренке педагогик эшчәнлеген, фәнни тикшеренүләрен дәвам итә һәм күп сандагы хезмәтләрен бастырып чыгара. Үләренә бер ел калганда, Казан университетының 50 еллык юбилеена багышлап, Лобачевский үзенең иң соңгы һәм иң зур күләмле әсәре «Пангеометрия»не иҗат итә — аны улына һәм яраткан шәкерте Ягофар Ибраһимовка телдән әйтеп яздыра, чөнки инде ул бу чакта дөм сукыр була.

1856 елның 12(24) феврале килеп җитә. Моннан нәкъ утыз ел элек Николай Иванович Казан университетының физико-математика факультеты утырышында үзенең Яңа геометрия ачуы турында игълан

иткән иде. Ә хәзер ул, патша хөкүмәте тарафыннан онытылган хәлдә, үлем түшәгендә ята.

Менә ул башын тәрәзәгә таба бора һәм, сүнгән күзләрен зуррак ача төшеп, туган университетын һәм студентларны күрергә тели... Тик кинәт башы авып төшә, һәм ул соңгы сулышын бирә... Ә өстәлдә, университет «Язмалар»ында басылып чыккан мәкаләсендә, аның яшьләргә карап әйтелгән саубуллашу сүзләре:

«Сезнең белән аерылышканда, сезгә иң яхшы сабак булырлык нәрсә әйтим соң? Сез соңрак туганлыктан, миңа караганда бәхетлерәк... Язмыш тарафыннан сакланып килгән дәүләтебез үзенең бөеклегенә акрынлап күтәрелә бара һәм ул җир йөзендә кешелекнең әле бер генә токымы да ирешә алмаган биеклеккә җитәр. Петр I заманы атаклы булды, әмма Россиянең иң бәхетле көннәре әле алда».

Николай Иванович Лобачевскийның алдан күреп әйткән бу ялкынлы сүзләре безнең илдә Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң тормышка ашты.

Лобачевский үз геометриясенең «молекуляр көчләрне» (хәзерге термин белән — атом энергиясе) вә Галәмне өйрәнүдә кулланылачагына ышаныч белдергән иде. Һәм менә неевклид геометриясе нигезендә бөек физик Эйнштейн үзенең «Чагыштырмалылык теориясе»н тудырды, бу тәгълимат исә атом энергиясен көнкүрештә куллана башлауга китерде (кара: Н. А. Черников. Геометрия Лобачевского как физическая наука. Объединенный институт ядерных исследований. Дубна, 1976). Ә кем белә, бәлки, тиздән, бик тиздән гравитация көче белән йөрүче ракеталарның иксез-чиксез Галәм буйлап сәяхәткә бару маршрутларын билгеләгәндә дә без Лобачевскийның «Пангеометрия»сеннән (латинча «пан» кушымтасы гомумилекне аңлата) файдаланырбыз!

Тәрҗеманов Җ. А.

Т87 Лобачевскийның яшьлеге: Роман.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.— 342 бит.

Бу документаль роман даһи математик Николай Лобачевскийның балачагын һәм яшьлеген, аның остазы талантлы шагыйрь вә педагог Н. М. Ибраһимов эшчәнлеген, ул чактагы Казан, гимназия университет тормышын тулы итеп сурәтли:

Т $\frac{4803010200-162}{М132(03)-86}$ 160—86. ББК 84.4(2Р-Тат)

ОЛЫ ҺӘМ УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

**Тарзиманов (Тарджеманов) Джавад Афтахович**

**ЮНОСТЬ ЛОБАЧЕВСКОГО**

**роман**

(на татарском языке)

Редакторы Л. Хәмидуллин
Художнигы Ф. Кадыйров
(заставка Г. Эйдиконныкы)
Художество редакторы Ф. Хасьянова
Техник редакторы Ә. Трофимова
Корректорлары Т. Шакирова, М. Мирсалихова

ИБ № 4279

Наборга бирелде 29.11.85. ПФ 01068. Басарга кул куелды 13.06.86. Формат 84×108 1/32. Типография кәгазе № 2. Гарнитура школьная. Печать высокая. Учетно-изд. табагы 18,7+форз. 0,34. Якынча басма табагы 18,1+форз. 0,2. Усл. кр. отт. 18,9. Тираж 4000. Заказ А-761. Бәясе 75 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

75 тиен